АКАДЕМИЯ НАУК РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
**Институт языка, литературы и искусства
имени Г. Ибрагимова**

# ЛЕКСИКОЛОГИЯ ТАТАРСКОГО ЯЗЫКА

В трех томах

III том

Первая часть

Казань
2017

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
**Г. Ибраһимов исемендәге**
**Тел, әдәбият һәм сәнгать институты**

# ТАТАР ЛЕКСИКОЛОГИЯСЕ

Өч томда

III том

Беренче кисәк

Казан
2017

**УДК 811.512.145´373**
**ББК 81.2Тат-3**
**Т 23**

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе*
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*Гыйльми советы карары нигезендә нәшер ителә*

«2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында ТР дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы кысаларында басыла

**Проект җитәкчесе** – филол. фән. докт., проф. **М.З. Зәкиев**

**Фәнни редактор** – филол. фән. докт., проф. **Г.Р. Галиуллина**

**Рецензент –** филол. фән. докт., проф. **К.Р. Галиуллин**

**Т 23** **Татар лексикологиясе:** өч томда / проект җит. М.З. Зәкиев; ред. Г.Р. Галиуллина. – Казан: ТӘҺСИ, 2017. – Т. III. 1 кис.– 536 б.
ISBN 978-5-93091-249-4

«Татар лексикологиясе»нең өченче томы беренче кисәгендә ономастика фәне һәм аның тармакларының формалашу тарихы һәм хәзерге халәте, татар телендә кулланылышта йөргән ялгызлык исемнәренең үзенчәлекләре яктыртыла. Хезмәттә ялгызлык исемнәрен өйрәнү ономастиканың тармаклары кысасында бирелеп, бу төр берәмлекләрнең барлыкка килү, үсеш-үзгәрешен, кулланылыш формаларын ачыклау тел белеме һәм ономастика фәне казанышларына нигезләнеп башкарыла, шулай ук, ялгызлык исемнәренең үзенчәлекле табигатен истә тотып, башка фәннәр материалына да мөрәҗәгать ителә.

Басма тел белгечләренә, аспирантларга, студентларга һәм татар әдәби теле белән кызыксынган киң катлам укучыларга тәкъдим ителә.

**УДК 811.512.145´373**
**ББК 81.2Тат-3**

**ISBN 978-5-93091-249-4**

© Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият
һәм сәнгать институты, 2017

# КЕРЕШ

Татар теленең сүзлек составында үзенчәлекле семантикага ия булган, барлыкка килү, ясалыш һәм кулланылыш даирәсе һәм мөмкинлекләре ягыннан башка төр берәмлекләрдән аерылып торган сүзләр – ялгызлык исемнәре бар. Әлеге төр берәмлекләрне өйрәнә торган ономастика фәне лексикологиянең бер тармагы булып санала, әмма ул башка тармаклар арасында үзенчәлекле урын били. Халык тарихы, мәдәнияте, теле, географик урыны һәм хәзерге яшәеш мохите белән бәйле мәгълүматлар ялгызлык исемнәрендә сакланганлыктан, ономастика фәне үз эченә гуманитар белемнәрне дә туплый. Хәзерге тел белемендә әлеге юнәлеш үз урынын тапкан фән буларак кабул ителсә дә, өйрәнелә торган тармакларның күплеге һәм яңадан-яңа мәсьәләләренең барлыкка килүе белән, ул үзенең актуальлеген югалтмый, киресенчә, аның өйрәнү юнәлешләре киңәя бара.

Хәзерге татар теле белемендә ономастика зур үсешкә ирешкән, фәнни мәктәп буларак формалашкан һәм шактый казанышлары булган фән санала. Аның барлыкка килүе һәм интенсив рәвештә үсеше XX гасырның 60 нчы елларына туры килә. Татар ономастика өлкәсендәге беренче системалы фәнни эзләнүләр филология фәннәре докторы, профессор Г.Ф. Саттаров исеме белән бәйле. Татар ономастикасы фәненең формалашуы, аның төрле тармакларга аерылып үсеп китүе, Казан төрки-татар ономастикасы фәнни мәктәбенең оешуы – барысы да галимнең тынгысыз һәм тырыш эшчәнлегенең нәтиҗәсе булып тора. Хәзерге татар ономастикасы казанышлары – профессор Гомәр Фәез ул Саттаров һәм аның укучыларының дистәләгән еллар дәвамында алып барган хезмәт җимеше. Укучылар игътибарына тәкъдим ителгән

«Татар лексикологиясе»нең бу томында (III том, беренче кисәк) галим Г.Ф. Саттаровның фәнни тәгълиматлары һәм карашлары, методологиясе нигез итеп алынды, татар ономастикасы фәненең төрле юнәлешләрендә фәнни эзләнүләр алып баручы укучылары тарафыннан үстерелде һәм яңартылды.

Лексикология проектының җитәкчесе – академик М.З. Зәкиев, фәнни редакторы – филология фәннәре докторы Г.Р. Галиуллина.

Бу басмада, татар ономастикасының җентекле өйрәнелгән тармакларына караган фәнни тикшеренүләр белән беррәттән, әлегә кадәр өлешчә генә өйрәнелгән юнәлешләрне яктырту да максат итеп куелды. Монография үз эчендә ваграк тармакларны берләштергән җиде өлештән тора.

Беренче бүлектә ономастика фәне турында гомуми мәгълүмат бирелеп, ялгызлык исемнәренә хас төп мәгънәви һәм функциональ үзенчәлекләр аерыла. Әлеге бүлек филология фәннәре докторы Г.Р. Галиуллина тарафыннан эшләнде.

Икенче зур бүлекне татар антропонимикасы тәшкил итә һәм ул үз эчендә кеше исемнәре, фамилия һәм кушаматлар кебек бүлекчәләргә аерылып тикшерелә. Татар антропонимикасы турында гомуми мәгълүматлардан гыйбарәт бүлекчәләрне һәм «Татар кеше исемнәре» бүлеген филология фәннәре докторы Г.Р. Галиуллина, «Татар фамилияләре», «Татар кушаматлары» бүлекләрен филология фәннәре кандидаты Г.С. Хаҗиева язды.

Өченче зур бүлектә татар топонимикасының төп тармаклары: гидронимика, ойконимика, оронимика, урабанонимика өйрәнелә. Татар топонимикасы фәненә багышланган гомуми бүлекчәләр һәм «Татар ойконимикасы», «Татар урбанонимикасы» бүлекләре филология фәннәре кандидаты Г.К. Һадиева тарафыннан эшләнде. «Татар гидронимикасы» бүлегенең авторы – филология фәннәре кандидаты О.Р. Хисамов. «Татар оронимикасы» бүлеген филология фәннәре кандидаты Р.Ш. Шаһиев язды.

Дүртенче бүлек үз эчендә татар теле белемендә чагыштырмача яңа саналган эргонимика тармагын өйрәнүне максат итеп куя. Аның авторы – филология фәннәре кандидаты Р. Әмирова.

Бишенче бүлек татар этнонимикасына багышлана, аны академик М.З. Зәкиев язды.

«Татар ономастикасының башка тармаклары» дигән алтынчы бүлектә космонимика, зоонимика, мифонимика, прагматони-

мика кебек татар теле белемендә чагыштырмача аз өйрәнелгән тармаклар ачыклана. «Татар космонимикасы» бүлеген филология фәннәре кандидаты Х.Х. Кузьмина, «Татар зоонимикасы» бүлеген филология фәннәре кандидаты Э.И. Сафина, «Татар мифонимикасы» бүлеген филология фәннәре кандидаты Г.С. Хаҗиева, «Татар прагматонимикасы» бүлеген филология фәннәре докторы Г.Р. Галиуллина язды.

Җиденче бүлектә ономастика һәм стилистика чигендә торган шактый үзенчәлекле поэтик ономастика тармагы өйрәнелә. Бүлекнең авторы – филология фәннәре кандидаты Г.Х. Зиннәтуллина.

Хезмәтнең библиография өлешен филология фәннәре докторы Г. Галиуллина эшләде.

«Татар лексикология»сенең өченче томы татар теле белемендә киң таралыш тапкан нигезләмәләрне истә тотып, шул ук вакытта гомуми тел белеме һәм ономастика фәнендә таралыш тапкан төркемләүләргә, фәнни нигезләмәләргә таянып башкарылды. Фактик материал саналган ономастик берәмлекләр татар телендә һәм татар җирлегендә сакланган һәм кулланылган тел материалын хасил итә.

# ТАТАР ОНОМАСТИКАСЫ ФӘНЕНӘ КЕРЕШ

## § 1. Ономастика фәне турында төшенчә, аның өйрәнү объекты һәм юнәлешләре

Телнең лексик системасында башка төр лексик берәмлекләрдән үзләренә генә хас мәгънәви, төзелеш-ясалыш үзенчәлекләре, үсеш һәм кулланылыш закончалыклары, система барлыкка китерергә сәләтле механизмнары белән аерылып торган берәмлекләр – ялгызлык исемнәре бар. Бу төр берәмлекләрне өйрәнә торган фән ономастика дип атала.

Ономастика (грек теленнән *onomastike* – исем кушу сәнгате) – тел белеменең ялгызлык исемнәрен өйрәнә торган тармагы. Шул ук вакытта бу термин белән ялгызлык исемнәре җыелмасын да атыйлар (Языкознание. Большой энциклопедический словарь, 2000: 347).

Ономастика фәне ялгызлык исемнәренең асылын, барлыкка килүен, телдә озак вакыт файдалану барышында барган үсеш-үзгәрешләрләрен, аралашу нәтиҗәсендә башка телләрдән алыну һәм кулланылыш үзенчәлекләрен, башка фәннәр, телнең бүтән тармаклары белән бәйләнешен тикшерә. Бүгенге көндә ономастика кешелек турындагы фәннәр арасында төрле юнәлешләрдә өйрәнелгән тармаклардан санала, чөнки ул һәм синхроник, һәм диахроник планда кешелек тормышының барлык өлкәләрендә кулланыла торган мәдәни, тарихи һәм тел күрсәткече вазифасын башкара.

Ономастикага кагылышлы мәгълүматлар бик күп рухи ядкярләрдә, борынгы язма истәлекләрдә сакланып калган. Аларга нигезләнеп, кешелек җәмгыятенең тарихын, көнкүреш аермалыкларын, традицияләрен һәм тел үзенчәлекләрен өйрәнү мөмкинлекләре

киң. Ономастик тикшеренүләр төрле халыкларның күченү-миграция юлларын һәм элекке яшәү урыннарын, тел һәм мәдәни бәйләнешләрен, телләрнең бик борынгы халәтен һәм аларның диалектларының мөнәсәбәтен ачыкларга да ярдәм итә. Әлеге үзенчәлекләр ономастиканың тел белеме, тарих, этнография, психология, социология, география, маркетология һәм башка фәннәрнең өйрәнү объекты булуына юл ача. Ономастика буенча эзләнүләрнең объекты, юнәлешләре, методологиясе әлеге фән буенча тупланган белемнәрнең күләменә карап үзгәрә, төрләнә бара. Бүгенге көндә ономастика, төрле фәннәрнең фәнни-теоретик методологиясен берләштергән, шул нигездә эзләнүләр алып бара торган фәнара тармак буларак, формалашу һәм үсеш кичерә.

Ономастиканың өйрәнү объекты булып ялгызлык исемнәренең барлыкка килү һәм исем-атама бирү (номинацияләү) мотивлары, бер төрдән икенче төргә күчү сәбәпләре һәм үзенчәлекләре, территориаль һәм иҗтимагый таралышы, сөйләмдә кулланылышы, ялгызлык исемнәренең иҗтимагый һәм психологик аспектлары, юридик статуслары, әдәби әсәрләр кысасында кулланылышлары тора. Ономастика шулай ук лингвистик планда ялгызлык исемнәренең фонетик, семантик, этимологик ясалышын, грамматик һәм башка үзенчәлекләрен дә анализлый. Бүгенге көндә ономастика тел белеме составында, аерым алганда, лексикологиянең бер тармагы буларак өйрәнелә.

Ономастик тикшеренүләрнең аспектлары һәм өйрәнү объектлары күптөрле: аның тасвирлама, теоретик, тарихи, гамәли, әдәби һәм этник төрләре аерыла.

*Тасвирлама ономастика* ономастик тикшеренүләрнең объектив нигезен тәшкил итә, тупланган материалга гомумфилологик анализ ясый һәм аны лингвистик яктан ачыклый. *Теоретик ономастика* ономастик системага хас гомуми закончалыкларның үсешен һәм яшәешен тикшерә. *Тарихи ономастика* – ялгызлык атамаларның барлыкка килү тарихын, исемнәрнең төрле эпоха, чор реалийларында чагылышын билгели. *Гамәли ономастика* исем бирү практикасы белән бәйле, исемнәрнең җанлы сөйләм телендә яисә язма телдә кулланылыш үзенчәлекләрен тикшерә, атау яисә исем бирү белән бәйле проблемаларны өйрәнә, картографларга, биографларга, библиографларга, юристларга, тәрҗемәчеләргә гамәли киңәшләр бирү, күрсәтмәләр эшләү белән шөгыльләнә. *Әдәби*

*ономастика* әдәби әсәрләрдә урын алган ялгызлык исемнәренең поэтикасын өйрәнә. *Этник ономастика* – этнос һәм аларның төркемнәре, кабилә, халык атамларының барлыкка килүен, этнонимнарның башка төр атамалар (топоним, антропоним, зооним) белән үзара мөнәсәбәтен, этнонимнарның тел атамалары – лингвонимнар белән бәйләнешен тикшерә (Суперанская, 1998: 20). Соңгы елларда ономастика фәнендә *региональ ономастика* – билгеле бер төбәктәге атамаларның үзенчәлекләрен өйрәнү белән бәйле ономастик тикшеренүләр активлаша бара.

Ономастика фәне үз эченә берничә тармакны алып, шактый катлаулы структура-төзелеш тәшкил итә. Традицион рәвештә, аны түбәндәге тармакларга аерып өйрәнәләр:

1. Антропонимика – кешеләргә эндәшү, атап мөрәҗәгать итү өчен хезмәт итә торган исем, ата исеме (отчество, патроним), фамилия, кушамат, криптоним, псевдонимнарны өйрәнә торган тармак.

2. Топонимика – ономастиканың географик объект атамаларын, аларның килеп чыгышын, төзелеш-ясалышларын, кулланылыш үзенчәлекләрен, таралыш ареалларын өйрәнә торган тармагы. Үз чиратында, өйрәнү объектларына карап, әлеге тармак үзе берничә бүлекне берләштерә: гидронимика (су чыганаклары атамалары); оронимика (ландшафт-рельеф атамалары); ойконимика (торак пункт атамалары); микротопонимика (бер төбәккә караган географик объект атамалары) һәм микротопонимиянең бер төре булган урбанонимика – шәһәр эчендәге географик объект атамаларын өйрәнә торган тармаклар.

3. Зоонимика – ономастиканың хайван, кош-корт кушаматларын өйрәнә торган тармагы.

4. Космонимика – барлык төр күк җисемнәре атамаларын өйрәнә торган тармак.

5. Теонимика – аллалар, изге затлар исемнәрен өйрәнә торган тармак.

6. Эргонимика – төрле оешма, учреждение атамасы булган ономастик берәмлекләрне өйрәнә торган тармак.

7. Прагматонимика – әйбер-товар исемнәрен, маркаларын өйрәнә торган тармак.

8. Поэтик ономастика – матур әдәбиятта һәм фольклор әсәрләрендәге ялгызлык исемнәрен өйрәнә торган тармак.

9. Этнонимика – ыруг-кабилә, халык һәм милләт атамаларын өйрәнә торган тармак.

Хәзерге ономастика фәне – үзенең методологиясе һәм проблематикасы булган комплекслы лингвистик юнәлеш. Ономастик эзләнүләр, ономастик берәмлекләрнең табигатен билгеләргә генә түгел, аерым халыкларның миграцион процессларын, телләрнең борынгы торышын, тарихи үсеш-үзгәрешен, төрле халыкларның мәдәни һәм тел контактларын, хәзерге яшәештәге иҗтимагый-мәдәни процессларны ачыкларга да ярдәм итә. Җәмгыятьтә барган үзгәрешләргә тиз бирешүчәнлеген, барлыкка килүләре һәм кулланылышлары экстралингвистик факторларга тулысынча диярлек бәйлелеген истә тотсак, ономастик берәмлекләр текстларның, тарихи һәм археологик материалларның хронологиясен билдерүдә да әһәмиятле роль башкаралар.

Югарыда әйтелгәнчә, ономастика, лингвистиканың бер тармагы буларак, лингвистик тикшеренү методларына нигезләнә, шул ук вакытта, өйрәнү объектының төренә, тикшеренү өлкәсенә һәм юнәлешенә карап, башка фәннәрнең, аеруча тарих, география, этнография, культурология, социология, әдәбият белеме фәннәренең дә методологиясен файдалана. Болардан кала, ономастикада археология, биология, теология, философия, психология фәннәре материаллары, метод һәм алымнары да кулланыла. Шунлыктан аның тикшеренү метод һәм алымнары да күптөрле. Шул ук вакытта үзенчәлекле табигате, өйрәнү объектларының комплекслы булуы ономастика фәнен, башлыча лингвистик методларга таянса да, тел белеменең башка тармаклары арасында, билгеле бер дәрәҗәдә мөстәкыйль булуын да күрсәтә. Тел белемендә бу тармакны лингвистика кысасыннан чыгарырга, нигездә лингвистик методларны куллануын, әмма шул ук вакытта бер төркем гуманитар, кешелек турындагы, төгәл фәннәр белән белән тыгыз бәйләнешен искә алып, аерым бер фән буларак кабул итәргә кирәклеген искәртәләр (мәсәлән, О.Н. Трубачев, А.К. Матвеев һ.б.). Әмма бу төр берәмлекләр тел законнары нигезендә барлыкка киләләр, үсеш-үзгәреш кичерәләр, шунлыктан зур күпчелек галимнәр аның тел белеме тармагы булуын шик астына куймыйлар.

Ономастика фәнендә кулланыла торган метод һәм алымнар, өйрәнү юнәлешенә бәйле, алар төрлеләнергә, бер-берсеннән аерылырга мөмкин. Әмма ономастиканың һәр тармагында кулланыла торган төп методлар бар. Шуларның кайберләренә тукталып үтик. Ономастика фәнендә барлык гуманитар һәм төгәл фәннәрдә

кулланыла һәм иң киң таралганнардан *тасвирлама метод* әһәмиятле санала. Ул ономастик материалны тасвирлаганда, системалаштырганда, төркемнәргә аерганда, материалга сыйфат һәм сан ягыннан характеристика биргәндә кулланыла. Аның нәтиҗәсендә топонимикада төрле исемлекләр (сулык атамалары исемлеге, торак пункт атамалары исемлеге һ.б.), антропонимикада исем, фамилияләр картотекасы, төрле сүзлекләр, каталог, индекслар формалаша. *Чагыштырма-тарихи метод* төрле вакыт кысаларында кулланылышта йөргән ономастик берәмлекләрне чагыштырып өйрәнүгә йөз тота. *Структур метод* ономастик берәмлекләрнең төзелешен өйрәнүдә мөһимнәрдән санала. *Генетик* метод ялгызлык исемнәренең кардәшлеген аңлатканда кулланыла. *Ареаль метод* ялгызлык исемнәренең охшаш элементлар ареалын аерып күрсәтә. Бу метод аеруча топонимика тармагында әһәмиятле, чөнки теле яки бу таралыш өлкәсендә, территориядә кулланылган ономастик берәмлекләр, вакытлар үтү белән, билгеле бер халыкка, мәдәнияткә бәйләнешен югалтырга мөмкин, ягъни бу территориядә башка халыклар яшәүгә карамастан, ономастикада үткән тарих сакланып кала, аларның географик таралыш даирәсен өйрәнү ареаль метод ярдәмендә башкарыла. Әлеге ысул белән *ономастик картография методы* тыгыз бәйләнгән. Ул ономастик карталар төзү һәм карта материалларын ономастик тикшеренү өлкәсендә кулланыла. Әлеге методларның һәр икесе география фәне белән, аның тикшеренү методологиясе белән тыгыз бәйләнештә яши. Бүгенге көндә әлеге методларның һәр икесе ономастик карталар төзүдә алыштыргысыз санала. Ономастиканың башка тармакларында ареаль һәм ономастик картография методлары азрак кулланылса да, бу өлкәдә перспектив эзләнүләр алып бару мөмкинлекләре шактый киң. Ономастик берәмлекләрнең, аерым бер формант таралыш һәм кулланылыш зоналарын барлау, антропонимик, космонимик, эргонимик һәм башка төр берәмлекләрнең карталарын төзү юнәлешендә киң эшчәнлек алып бару әһәмиятле. *Типологик метод* төрле ономастик системаларда уртак, охшаш, билгеле бер закончалык нигезендә барлыкка килгән күренешләрне өйрәнгәндә кулланыла. *Региональ метод* аерым бер регионның ономастикасын өйрәнүдә иң мөһимнәрдән салала. *Семиотик метод* ономастик берәмлекләрнең тамга, билге буларак кулланылуын тануга нигезләнгән, аның нигезендә онимнар асылына салынган лингвистик һәм экстралингвистик

мәгълүмат ачыклана. Семиотик метод онимнарның билге буларак яшәешен, аларның дифференциаль билгеләрен, тел берәмлекләре аша бирелү мөмкинлекләрен, система буларак формалашуын, ономастиканың, аның төрләренең системалылыгын ачыклый. *Лингвопсихологик метод* семиотик метод белән бәйле, ул онимның тамга, билге буларак барлыкка китергән ассоциацияләрне өйрәнүдә, ялгызлык исемнәрен сайлау, атама бирү мотивларын ачыклауда төп терәк санала. *Статистик метод* ономастик берәмлекләрнең, аерым модельләрнең активлыгын, аларның үсеш тенденцияләрен билгеләүдә кулланыла. *Этимологик метод* оним яки аның нигезендә яткан этимон-апеллятивны ачыклый. *Стилистик метод* әдәби әсәрләрдә, фольклорда, сөйләмдә ялгызлык исемнәренең атау, идеологик, тасвирлама, эстетик, символик һәм башка функцияләрен, әдәби агым (классицизм, сентиментализм, романтизм, символизм, реализм һ.б.) һәм оним сайлау бәйләнешен, төрле жанрларда кулланылган ялгызлык исемнәре һәм аларның символик роле, ялгызлык исемнәренең тәэсири көчен өйрәнгәндә әһәмиятле санала.

Югарыда саналганнардан тыш, стратиграфик, герменевтик, модельләштерү, текстологик анализ, диахроник һәм синхроник анализ, реконстукцияләү ысулы, социолингвистик мәгълүматлар җыю методлары һәм башка төр эзләнү метод һәм алымнары да ономастик материалны өйрәнгәндә кулланыла.

Ономастика буенча материалларның шактый вакытлар дәвамында җыелып килүенә карамастан, дөнья лингвистикасында аның фәнни статусы XX гасырның 30 нчы елларында гына билгеләнә. Беренче Халыкара ономастик конгресс (1930) Франциядә А. Доз инициативасы буенча оештырыла (Языкознание. Большой энциклопедический словарь, 2000: 347).

Ономастикага караган материалларга килгәндә, аларның туплануы, әйләнешкә кертелүе күп гасырлар дәвамында бара. Мәсәлән, төрки-татар ономастикасына караган аерым материалларны борынгы язма истәлекләрдә очратырга мөмкин. Күренекле ономатолог Г.Ф. Саттаров билгеләгәнчә, татар ономастикасының башлангычы X гасырга карый, гарәп сәяхәтчесе һәм дипломаты Әхмәд бине Фадланның 921–922 елларга караган язмаларында борынгы болгар кеше исемнәре, болгар һәм башкорт кабиләләре атамалары һәм топонимия буенча мөһим мәгълүматлар теркәлгән. Галим татар ономастикасының үсешен өч этапка аера: X гасыр –

XIX гасыр урталары; XIX гасырның икенче яртысы – XX гасырның беренче чиреге; соңгы этап үзе ике чорга бүленә: 1) 1920 еллар уртасыннан 1950 елларга кадәр; 1960 елдан 1970 елларга кадәрге чор (Саттаров, 1970). Күрсәтелгән этаплардан соң, татар ономастикасы фәне үсешендә мөһим чорлар буларак 1980–2000 һәм 2001 еллардан хәзерге көннәргәчә этапны аеру зарур.

Беренче этапның әһәмиятле үзенчәлеге буларак, Г.Ф. Саттаров сәяхәтчеләр тарафыннан ономастик материал туплануын, ономастиканың яралгы хәлдә булуын, атамаларга аңлатмаларда хаталар булуга карамастан, аларның әһәмиятлелеген ассызыклый (Саттаров, 1970: 12). Аерым алганда, Мәхмүд Кашгариның «Дивание лөгатет-төрк» (1074) сүзлегендә борынгы төрки халык һәм кабиләләре телләренең, бай апеллятив лексикасын гына түгел, ономастикасы да урнаштырылуы, әлеге материалның төрки ономастиканы өйрәнүдәге әһәмиятен ассызыклый. Чыганак буларак, XIII–XIV гасырларда болгар, ә XV–XVIII гасырларда татар эпиграфик һәйкәлләрендә теркәлгән борынгы болгар һәм татар антропонимнары зур кыйммәткә ия була. XVI–XVII гасырларга караган Казан язу кенәгәләрендә XVI гасыр Казан географик атамалары һәм кеше исемнәренә кагылышлы бай лексик материал туплана. XVII йөзләрдә Урта Азия, Себер, Кавказ һәм башка җирләргә үткәрелгән сәяхәтләр нәтиҗәсендә тупланган бай топонимик материал һәм XVIII гасыр башында төзелә башлаган географик карталар әле дә мөһимлеген югалтмый. Хисаметдин Мөслиминең «Тәварихы Болгария», XVIII гасырда язылган хезмәтләрдән, өлешчә генә булса да, татар топонимиясен һәм антропонимиясен яктырткан хезмәтләрдән академик Г.Ф. Миллерның «Описание живущих в Казанской губернии языческих народов» (1791) китабында Казан губерниясенең кайбер географик атамалары турында материаллар бирелгән. «Описание Сибирского царства» (1750) хезмәтендә себер татарларында шәһәр һәм авыл атамаларының килеп чыгышы тарихлары ачыклана. Сәяхәтче П.И. Рычковның «Топография Оренбургской губернии» (1762) китабында төрки (татар, башкорт, казак, каракалпак, нугай, һ.б.) топоним һәм этнонимнарына аерым бүлекләр багышланган, шулай ук Казан шәһәре атамасының килеп чыгышына да урын бирелгән. В.Н. Татищев сораулыгы буенча 1737–1738 елларда Сембер канцеляриясендә төзелгән рус-татар кульязма сүзлегендә, уртаклык исемнәре белән беррәттән, Сембер провинциясенә

караган күп кенә татар чыгышлы шәһәр, зур авыл, тау, елга, күл атамалары күрсәтелгән. 1779 елда Федор Черный географик атамаларга бай Казан губернасының генераль картасын бастырып чыгара. Болар барысы да әлеге чорның мөһим моментларыннан санала.

Икенче этапта Г.Ф. Саттаров татар топонимнары һәм антропонимнарын җыю, өйрәнү эшенә җитдирәк якын килү сизелүен искәртә, бу чорда ономастик материалны өйрәнү лингвистлар һәм төбәк тарихын өйрәнүчеләр – Г. Чернышевский, В. Вельяминов-Зернов, М. Лаптев, А. Артемьев, С. Мельников, А. Сергеев, Р. Игнатьев, С. Шпилевский кулына күчә. 1870 елларда Казан университеты каршында «Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте» ачыла, аның каршында ономастик түгәрәк тә оеша һәм бу берләшмәдә В.В. Радлов, Н.И. Золотиницкий, И.А. Износков, В.К. Магницкий, татарлардан Г.Н. Әхмәров, В.Г. Тимофеев, К.Г. Насыйри һ.б. актив фәнни эшчәнлек алып баралар. Әлеге галимнәрнең хезмәтләре нәтиҗәсе буларак, XIX гасырның 80 нче елларында Казан топонимик мәктәбе оешу татар ономастикасының икенче этабы үсешендә хәлиткеч роль уйный. Беренче инкыйлаптан соң (1905) татар әдипләреннән Г. Тукай, Ф. Әмирхан һ.б.ларның татар вакытлы матбугатындагы чыгышлары, А. Гераклитов, Һ. Атласи, Н. Спасский кебек белгечләрнең эшчәнлеге XX гасыр башы татар ономастикасының төрле яклы үсеше өчен аерым фәнни нигез ролен үти.

Өченче этапның беренче чоры (1920 еллар уртасыннан 1950 елларга кадәр) тел белеме фәнендә барган зур үзгәрешләргә туры килә. Ономастика буенча да әлеге чорда махсус лингвистик планда әзерләнгән хезмәтләр күренә башлый. Аерым алганда, Камил Туйкәнең «На пути исследования языка», Җамал Вәлидинең «Наречие каринских и глазовских татар» мәкаләләре, Гали Рәхимнең «Программа по изучению сел» хезмәтләре әлеге рәткә керәләр. Шулай да бу этапта ономастика буенча гомуми хезмәтләр булмый, теория бөтенләй эшләнмәгән диярлек. Ономастикага караган хезмәтләр нигездә иллюстратив һәм тасвирлама характерга ия. Шуңа да карамастан, әлеге чор ономастиканың алдагы үсеше һәм формалашуының башлангычы булып санала. 1920 еллар уртасы – 50 нче еллар ахыры татар ономастикасы фәненең алдагы үсеше һәм формалашуы өчен җирлек ролен үти.

Өченче этапның икенче өлешендә (1960 елдан 1970 елларга кадәрге чор) ономастик атамаларга игътибар көчәя, төрле

ономастик темаларга караган хезмәтләр чыга башлый. Аларда мөһим теоретик мәсьәләләр, ономастик тикшеренүләр методикасы үзәккә алына. Ономастик атамалар белән кызыксыну арта. Тел гыйлеменең әлеге бүлеге аша, ягъни атаманың тарихы, асылына бәйле рәвештә тарих, археология, лингвистика, этнография, этногенез һәм башка фәннәр күп сорауга җавап таба ала. Бу чорда басылган хезмәтләрнең теоретик нигезе ныклы, фәннилек сизелерлек көчәя. Аерым хезмәтләрдән түбәндәгеләрне атау зарур: Һ.В. Йосыпов «Введение в булгаро-татарскую эпиграфику» (1960) китабында болгар каберташ язмаларын борынгы болгар һәм мөселман-гарәп юнәлешенә аера; Р.А. Сафиуллин «К вопросу о названиях малых рек Среднего Поволжья» мәкаләсендә, төрле чыганакларга нигезләнеп, елга атамаларын ачыклый; 1960 елда Оренбург дәүләт педагогика институты укытучылары Н.Я. Лойфман һәм А.С. Попов читтән торып уку бүлеге студентлары өчен зур булмаган «Топонимические названия Оренбургской области» кулланмасын нәшер итәләр. Анда Оренбург өлкәсендә очрый торган төрки чыгышлы топонимнар да урын алган. Аларны автор алфавит буенча урнаштырган һәм өч телгә (башкорт, татар, казак) таянып, якынча этимологияләрен дә аңлатырга тырышкан.

Татар ономастикасында топономастика мәсьәләләрен икетеллелек, телләрнең кушылуы, рус һәм татар телләренең бер-берсенә тәэсире планында тикшерү аспекты да актуальләшә. Бу өлкәдә Г. Ибраһимов, Р. Субаева һ.б. актив эшчәнлек алып баралар.

1963 елдан татар ономастикасын тикшерү татар теле кафедрасының фәнни тикшеренүләр планына кертелә. Әлеге тикшеренүләр ономатолог-галим Г.Ф. Саттаров җитәкчелегендә алып барыла һәм зур нәтиҗәләргә китерә, ягъни татар ономастикасы фән буларак оеша һәм Казан төрки-татар ономастикасы фәнни мәктәбе формалаша.

1966 елда Ф.С. Фәсиевнең «Путешествие в мир личных имен» («Казан утлары» журналы, № 10) мәкаләсендә автор, уртаклык исемнәреннән аермалы буларак, ялгызлык (кеше) исемнәренең үзенчәлекләрен аерып күрсәтә.

1960 еллар уртасыннан, төбәк атамаларын өйрәнүче Казан телчеләре һәм тарихчылары гына түгел, Ульяновск, Свердловск, Мәскәү, Йошкар-Ола һ.б. шәһәрләрләрдә эшләүче галимнәр дә татар ономастикасына игътибарларын юнәлтәләр.

Ул елларда Урта Себер һәм өлешчә себер-татар топонимиясен өйрәнү белән Томск шәһәрендә профессор А. Дульзон Һәм аның шәкертләре М. Абдрахманов, В. Попова, О.Молчанова һ.б. шөгыльләнә.

В.А. Никоновның 1966 елда басылып чыккан «Кыскача топонимик сүзлеге» төрки-татар топонимнары, гидроним, оронимнарының туплануын һәм килеп чыгуын бирелеше ягыннан игътибарга лаеклы хезмәт.

1965 елда «Совет энциклопедиясе» нәшриятында «РСФСР халыкларының ялгызлык исемнәре белешмәсе» дөнья күрә. Анда татар теленең ялгызлык исемнәре дә урын алган. Әлеге бүлекне филология фәннәре докторы А.А. Юлдашев төзи.

Бу чорда татар топонимиясенә кагылышлы мәсьәләләр Н.А. Баксаков, Г.И. Донидзе, А.П. Дульзон, Е.Г. Корнилов, Э.М. Мурзаев, А.И. Попов, Б.А. Серебрянников, А.В. Суперанская һәм башка галимнәрнең хезмәтләрендә чагыштырма-тарихи планда яктыртыла.

Төрки-татар ономастикасы мөстәкыйль фәнни юнәлеш булып 1970 елларда, ономатолог галим Гомәр Фәез улы Саттаровның эшчәнлегенең нәтиҗәсе буларак, формалашып җитә. Гомәр Фәез улы – киң җәмәгатьчелеккә татар тел гыйлеме өлкәсендәге зур галим-белгеч, дөньякүләм танылган тюрколог-ономатолог буларак билгеле. Казан төрки-татар ономастикасы фәнни мәктәбе 1963 елдан Казан дәүләт университетының татар теле кафедрасы кысаларында формалаша башлый һәм аның нигезләнүе, үсеше профессор Г.Ф. Саттаров эшчәнлеге белән бәйле.

1963 елдан татар ономастикасын тикшерү «Татар ономастикасы нигезләре» һәм «ТАССР топонимиясе» темалары белән Казан дәүләт университеты татар теле кафедрасының фәнни планына кертелә. 1964 ел урталарыннан татар ономастикасы өлкәсендә системалы эзләнүләр башланып китә. Студентларның фәнни эшчәнлеге, экспедицион эзләнүләре белән беррәттән, татар ономастикасына караган тарихи-этимологик, лексик-семантик, сүз ясалышы һәм норматив (кеше исемнәренең орфографиясе) якларына кагылышлы тикшеренүләр үткәрелә башлый. Г.Ф. Саттаровның «ТАССР антропотопонимиясе» (1975) дигән темага язылган докторлык диссертациясеннән соң бу өлкәдә киң кырлы эшчәнлек башланып китә.

1976–1980 еллар аралыгында Казан төрки-татар ономастикасы фәнни мәктәбе татар лексикологиясе һәм ономастикасы өлкәсендә өч юнәлештә эшчәнлек алып бара: 1) татар теле лексикасының генетик-тарихи катламнары; 2) Казан урамнары атамалары сүзлеге, Казан топонимиясе, Казан шәһәре һәм урам исемнәренең барлыкка килүе; 3) гарәби чыгышлы татар кеше исемнәре.

Беренче юнәлеш татар теле лексикасын тарихи планда өйрәнүне максат итеп куя. Тикшерелә торган телнең кайсы телләр белән кардәш булуын белү өчен тел лексикасының генетик-тарихи катламнарын ачыклау мөһим булып тора. Уртак фонетик-морфологик һәм лексик күренешләргә ия булу фактын танып, төрки, монгол, тунгус-маньчжур телләренең алтай гаиләсенә берләшүе әйтелә. Татар лексикасын алтаистика фәненә нигезләнеп, чагыштырма-тарихи метод ярдәмендә тикшерү фәндә татар теленең калыплашу процессын тәгаенләргә мөмкинлек бирә.

Беренчеләрдән булып татар теленең сүзлек составы, гомумалтай катламыннан башлап, тарихи планда фәнни тикшеренүләрдә яктыртыла. Эшнең нәтиҗәләре буларак түбәндәгеләр китерелә:

1. Татар лексикасының төп өлешен төрки-татар сүзләре алып тора. Бу, үз чиратында, телдә гомумалтай, гомумтөрки, болгар, кыпчак, угыз һәм татар катламнарының булуы турында сөйли.

2. Телләр кардәшлеге турындагы алтай теориясенә нигезләнеп, татар теленең төрки телләрнең иң борынгы чорына барып тоташуы билгеләнә.

3. Фин-угор телләрендәге төрки-татар (прототөрки, прото-болгар) сүзләре татар телендә болгар компонентының булуын раслап килә.

1986–1995 еллар аралыгында ономастик эзләнүләр ике юнәлештә алып барыла: 1) татар антропонимикасы һәм татар халкының килеп чыгышы мәсьәләләре һәм 2) Урта Идел һәм Урал буе төрки-татар топонимнары тарихи планда өйрәнелә.

1996–2006 елларда үткәрелгән фәнни тикшеренүләр актуаль, перспективалы һәм приоритетлы мәсьәләләрне колачлый. Казан төрки-татар ономастикасы фәнни мәктәбе вәкилләре алдына «Төрки-татар ономастикасы, диалектлары һәм лексикасын татар халкының этногенезы һәм лингвоэтнотарихына кагылышлы мөһим мәсьәләләр яктылыгында тарихи-лингвистик тикшерү» максаты куела. Билгеле бер төбәк ойконимиясен, топонимиясен,

микротопонимиясен тарихи-лингвистик анализлау, татар антропонимиясен тикшерү өлкәсендә нәтиҗәле эзләнүләр алып барыла. Поэтик ономастика юнәлеше шулай ук игътибар үзәгендә була.

XXI гасырның икенче яртысына төрки-татар ономастика мәктәбе ныклы теореотик нигезләнгән, фәнни тикшеренүләрнең конкрет объекты һәм предметы тәгаенләнгән фәнара тикшеренү юнәлешендәге зур тармакка әверелде.

Татар ономастикасы буенча басылып чыккан хезмәтләр, башлыча, тасвирлама, региональ һәм гамәли ономастика кысасында башкарыла, шул ук вакытта фәнара тикшеренүләр дә башкарыла.

Бүгенге көндә татар телендәге ялгызлык исемнәре монографик планда тасвирлама-структур яссылыкта өйрәнелде (Г.Ф. Саттаров, Ф.Г. Гарипова, А.Ф. Субаева, Х.Ф. Исхакова, Г.Р. Галиуллина, З.Ф. Әхәтова, Р.И. Куряева, О.Р. Хисамов, Р.И. Хаҗиев, Р.Ш. Шаһиев, Г.С. Хаҗиева-Демирбаш, М.З. Вәлиева, Г.М. Ниязова һ.б.), ономастик берәмлекләрнең диахроник планда үсеше анализланды (Г.Ф. Саттаров, М.З. Зәкиев, Ф.Г. Гарипова, А.Г. Шәйхуллов, Г.К. Һадиева, С.И. Гафурова һ.б.), әдәби әсәр кысасында кулланылышы тикшерелде (Р.Х. Гаррапова, А.Р. Биктимерова, В.М. Гарипова-Хәсәншина, Г.Х. Зиннәтуллина, С.С. Арсланова һ.б.), ономастик лексиканың текст ясау мөмкинлекләре, реклама текстларын тудырудагы роле билгеләнде (А.Ә. Гафурова, Л.Ф. Осипова), оешма атамалары монографик өйрәнелде (Г.Р. Галиуллина, Р.М. Әмирова һ.б.), региональ ономастикага багышланган күпсанлы хезмәтләр дөнья күрде (Х.Ч. Алишина, Ф.Х. Гыйльфанова, Р.К. Садыйкова, Г.Г. Тимерханова, Ф.А. Ваһапова, Г.Ф. Тимканова, Л.Х. Айтбаева, А.К. Гәрәева, Ф.С. Сәлимҗанова һ.б.), лингвокультурологик аспектлары һәм социомәдәни даирәдә кулланылышы тикшерелде (Г.Р. Галиуллина, А.Ф. Азнабаева һ.б.).

Нәтиҗә ясап әйткәндә, хәзерге татар ономастикасы комплекслы эзләнүләр таләп итә, тел белеменең киң катлам фәнара метод һәм алымнарга нигезләнеп өйрәнелә торган катлаулы структура хасил иткән тармагы булып тора.

## § 2. Ялгызлык исемнәренең семантик һәм функциональ үзенчәлекләре

Ялгызлык исеме яки оним (латин теленнән калька *nomen proprium*; *оним* – грек теленнән *onoma, onyma* – исем, атама) дип

әйбер, күренешләрне, кешеләрне башкалардан аерып, конкретлаштырып, индивидуальләштереп атый торган сүз, сүзтезмә яисә җөмләне атыйлар (Языкознание. Большой энциклопедический словарь, 2000: 473).

Ялгызлык исемнәре бик борынгы чорлардан ук гади кешеләрнең һәм галимнәрнең игътибарын үзенә җәлеп иткән. Югарыда әйтелгәнчә, хәзерге көндә ялгызлык исемнәре күптөрле фән өлкәләренең тикшеренү объекты булып тора, алар белән телчеләр, географлар, тарихчылар, этнографлар, психологлар, әдәбиятчылар кызыксына. Шулай да мондый берәмлекләр, беренче чиратта, лингвистлар тарафыннан ономастик лексика буларак җентекле тикшерелә, чөнки ялгызлык исемнәре, нинди генә өлкәгә карамасын (мәсәлән, кешегә, хайваннар дөньясына, космоска, географик объектларга, елга-чишмәгә, китапка яисә коммерция фирмасына), ул барыбер тел системасына буйсына, тел законнары буенча барлыкка килә һәм үзгәрә, аның билгеле закончалыклары буенча яши һәм кулланыла. Ялгызлык исемнәре, беренче чиратта, тел һәм мәдәният бергәлеген чагылдырган, халыкның тарихи дәверләрдәге хәрәкәтен бөтен катлаулылыгы һәм тулылыгы белән күрергә ярдәм итә торган өлге, модель буларак күзаллана.

Бу төр лексика – халыклар турында мәгълүмати чыганак, шунлыктан ул билгеле бер чорның гына түгел, халыклар яшәешенең барлык этапларын үз эченә берләштергән семиотик система да булып тора.

Шулай итеп, ономастик лексика – телнең лексик системасының состав өлеше. Күмәклек сүзләр кебек үк, бу төр сүзләр дә аерым бер телнең фонема һәм морфемалары ярдәмендә тел закончалыкларына буйсынып ясала, башка сүзләр белән синтаксик бәйләнешкә керә. Аларның зур күпчелеге күмәклек сүзләрдән ясалган, әмма телнең ономастик системасына күчкән бу берәмлекләр күмәклек сүзләргә хас үзенчәлекләрен югалтып, үзгә структурага, семантикага һәм кулланылышга ия булалар. Ономастик берәмлекләрне аера торган тагын бер билге – аларның телдән тыш экстралингвистик факторларга тыгыз бәйләнештә булулары, ягъни бу төр берәмлекләрнең кулланылыш ешлыгы һәм үзенчәлеге иҗтимагый, сәяси, мәдәни һәм психологик факторларга аеруча бәйле булуы.

Ялгызлык исеме – аерым бер субъект яки объектны башкалардан аера торган билге, символ. Бу төр лексика, күмәклек сүзләре

кебек үк, хәтта активрак та, башка телләргә шактый җиңел үтеп керә, әмма бу очракта аларның тәрҗемә ителмәүләрен, мөмкин кадәр тулырак фонетик тышчасын саклауларын, фонетик һәм грамматик закончалыкларга тулысынча буйсынмавын, телнең сүзлек составында гына түгел, бәлки аннан читтә дә иркен кулланылышта булуларын ассызыклау зарур.

Югарыда саналган үзенчәлекләр нигезендә бу төр берәмлекләрне күмәклек сүзләрдән аерып, аларның барлыкка килүе, үсеше һәм кулланылышына тәэсир иткән факторларны тулаем истә тотып махсус өйрәнү таләп ителә.

Ономастик лексиканың семантик һәм кулланылыш үзенчәлекләре белән кызыксыну күптәннән килә, шуңа карамастан, әлегәчә бу төр сүзләрнең мәгънә белдерү һәм функциональ мөмкинлекләре турында фикер төрлелеге күзгә ташлана. Бу, беренче чиратта, ялгызлык исемнәренең составы төрле булу һәм шунлыктан кулланылышта төрле характер алулары белән аңлатыла. Бер төркем ялгызлык исемнәре табигатьләре ягыннан күмәклек сүзләргә якын торса (мәсәлән, прагматоним, эргоним һ.б.), икенчеләре исә билге, тамга характерында булып, табигатьләре белән апеллятив лексикада шактый аерылалар, мәсәлән, антропоним, топоним, гидроним һ.б.лар шундыйлардан санала.

*Ялгызлык исемнәре* дигән атама бары тик исем сүз төркеменә генә хас, ягъни сүзләрне күмәклек һәм ялгызлык төркемнәренә бүлү башка сүз төркемнәрендә очрамый. Исемнәрнең дә бары тик конкрет төренә генә ялгызлык исеме төркемчәсе хас, ә абстракт исемнәр исә бу үзенчәлеккә ия түгел, чөнки алар кешедә акустик һәм күреп кабул итә торган ассоциацияләр уятмый (Суперанская, 1973: 105). Исемнәрнең мондый үзенчәлеккә ия булуы семантик яктан киң булуларына, сөйләмдә әһәмиятле роль уйнауларына ишарәли.

Исем сүз төркеменә караган сүзләрне күмәклек һәм ялгызлык исемнәргә бүлеп йөртүдә төп критерий буларак лексик мәгънәгә ия булу, төшенчә белән бәйләнеш һәм реаль чынбарлыктагы күренеш һәм предметларны атау мөмкинлеге алына. Билгеле булганча, лексик мәгънә – сүзнең эчке табигате, һәм ул барлык сүзләрдә дә бертөрле була алмый. Күмәклек сүзләр тулы семантик структурага ия булса, ялгызлык исемнәренең мәгънәви ягы шактый үзенчәлекле санала. Бу төркемгә кергән исемнәр предмет яки субъектларны атау өчен хезмәт итә торган тамга, билге буларак яшиләр, аларның

эчке формасы кулланучылар өчен күмәклек сүзләренә хас дәрәҗәдә әһәмиятле түгел. Ялгызлык исемнәре аерым объектив мәгълүмат тапшырмыйлар, объект яки субъектны төрле яклап тасвирламыйлар, төшенчә белән бәйләнешләре дә күмәклек сүзләрдәге кебек тыгыз түгел, алар зур төркем предмет, объект, процесс һ.б.ны атамыйлар. Алар өчен аерым бер предмет белән бәйләнеш беренче планга чыга. Шуңа карамастан, ялгызлык исемнәре, апеллятив лексикага караганда, күбрәк мәгълүмат саклый, чөнки бу төр лексика тел турында гына түгел, телдән тыш мәгълүматны тапшырырга да сәләтле, мәсәлән, *Сөембикә проспекты* – Татарстан Республикасының Чаллы шәһәрендәге төп магистральләрнең берсе, 1516–1566 елларда Казан ханлыгы белән идарә иткән легендар ханбикә Сөембикә (төрки-татар чыгышлы кеше исеме) хөрмәтенә кушылган; *Вилен* – рус теленнән алынган Владимир Ильич Ленин исеменең аббревиатур варианты, татар антропонимиконына XX гасырның 20 нче елларында килеп кергән ир-ат исеме.

Кешелекнең әйләнә-тирәсен символлаштырган мәдәният коды ялгызлык исемнәрендә аеруча нык чагылыш таба. Бу яссылыкта алар уникаль берәмлекләр санала. Ялгызлык исемнәренең табигатенә хас каршылык аларның семантикасына бәйле, дидек, чөнки тел берәмлекләре буларак сакланган мәгънәләре һәм кулланылу барышында мәгънә киңәю үзенчәлекләре семантик тотрыклылыкны югалтырга мөмкин. Ономастик лексиканың мондый үзенчәлеген тел белгечләре белән бергә, философлар да билгеләп килде. Мәсәлән, XX гасырда философлар тарафыннан әйтелгән кайбер фикерләргә тукталып үтик: Л. Витгенштейн фикеренчә, ялгызлык исеменең мәгънәсе бары тик сөйләм барышында гына ачылырга сәләтле, сөйләмдә ул индивидның дифференциаль билгеләрен берләштергән сөйләм семантикасына ия, икенче бер индивидка күчкәндә бу билгеләр үзгәрергә мөмкин. Логик семантика кысасында Г. Фреге (1997), соңрак аның теориясен үстергән А. Чёрч ялгызлык исемендә мәгънә һәм денотатны аералар. Бу концепция Б. Рассел (1982; 1999) хезмәтләрендә дә чагылыш таба, аларда ялгызлык исеменең семантикасын ачыклау өчен исемне тасвирлый торган аңлатма булу зарур, диелә (мәсәлән, *Җәлил* – «Моабит дәфтәрләре»нең авторы, бөек татар шагыйре һ.б.). Әмма бөтен ялгызлык исемнәренә дә мондый төр тасвирлама куллану мөмкин дә, урынлы да түгел, аерым алганда, топонимик берәмлекләргә карата

куллану үзен беркадәр акласа, антропонимнарга исә бу бөтенләй мөмкин түгел.

Әлеге фикерләргә каршы логик семантика мәктәбе вәкиле С. Крипке (1982) яңа төр концепция тәкъдим итә. Ялгызлык исеме сигнификатка ия түгел, бәлки алгы планга референт белән бәйләнешне кую дөресрәк булыр, диелә аның хезмәтендә.

Ялгызлык исеменә салынган хәбәр, референция төрле тасвирламаларсыз да аңлашыла, чөнки кем яки нәрсә турында сүз барганын аңлау өчен тасвирлама мәҗбүри түгел, атала торган субъект яки объект белән исем катгый рәвештә бәйләнештә тора, теләсә кайсы очракта ул шул ук объект яки субъектны атый.

XX гасыр урталарыннан ялгызлык исеменең мәгънәсен ачыклау мәсьәләсе ономатологлар кулына күчте. Нәтиҗәдә ялгызлык исемнәренең семантикасына караган өч төрле караш формалашты. Бер төркем галимнәр (Л.М. Щетинин, В.А. Никонов һ.б.) ялгызлык исемнәре мәгънә һәм төшенчә белдерергә сәләтле, диләр һәм онимның өч төрле мәгънәсен аералар: 1) этимологик (сүз ономастик берәмлеккә әверелгәнчегә кадәр булган мәгънәсе); 2) ономастик мәгънә; 3) ономастик берәмлекнең апеллятивка күчкәннән соң барлыкка килгән мәгънәсе.

Икенче төркем галимнәр (Е.М. Галкина-Федорук, Т.М. Гарипов, Е. Курилович) ялгызлык исеме бары тик аерым бер субъект яки объектны гына атый, мәгънәсе юк, индивидуаль эчтәлеккә генә ия, дигән капма-каршы фикерне алга сөрәләр.

Өченче төркем галимнәр (А.А. Реформатский, О.С. Ахманова, А.В. Суперанская) ялгызлык исеменең мәгънәсе булуын таныган хәлдә, төшенчә белән бәйләнешләрен инкяр итәләр. Мәсәлән, А.А. Реформатский фикеренчә, «ялгызлык исемнәренә хас булган төп үзенчәлек – алар, аерым бер төркем әйберләр белән мөнәсәбәттә торган хәлдә, атау мәгънәсенә ия, әмма бернинди төшенчә белдермиләр» (Реформатский, 1996: 66), А.В. Суперанская: «ялгызлык исеме турыдан-туры төшенчә белән бәйләнмәгән, телдә төгәл һәм конкрет коннотациягә ия түгел», – дип яза (Суперанская, 1973: 324).

Н.И. Толстой, алдагы фикерне кире кагып, ялгызлык исемнәре, телдән тыш, индивидуаль мәгълүматка, эчтәлеккә ия, әмма күмәклек сүзләренә хас булганча, бер төрдәге предметларга хас семантик билгеләрне берләштергән, гомумиләштерә торган мәгънәгә ия түгелләр, дигән фикерне алга сөрә (Толстой, 1997: 397).

Безнең фикеребезчә, ялгызлык исемнәренең табигате И.А. Воробьёв хезмәтләрендә тулырак ачылган (Воробьёв, 1971: 1–8). Галим онимнарның денотатив, сигнификатив һәм структур компонентлардан торган мәгънәви структурасы булуын һәм бу яктан аларның күмәклек сүзләргә якын торганлыгын, әмма һәр компонентның үзенә генә хас үзенчәлекләре булуын ассызыклый. Аның әһәмияткә лаеклы тагын бер фикере: һәр төр ялгызлык исеменең атау һәм кулланылу үзенчәлеге милли һәм региональ традицияләргә тыгыз бәйләнгән.

В.И. Супрун ономастик кырның семантик структурасын тасвирлап, телдә лексик мәгънәсе булмаган берәмлекләр юк, дигән фикер белдерә (Супрун, 2000: 18). Галим ассызыклаганча, «ялгызлык исеменең төп идентификацияли торган семасы онимның атала торган субъект денотаты белән мәҗбүри бәйләнешендә ачыла, башка семалары исә милли ономастика параметрларын чагылдыра торган өстәмә төсмер буларак кулланыла» (шунда ук: 20). Исемнең коннотациясе лексик-грамматик, деривацион, фонетик-интонацион һәм башка шундый тел һәм телдән тыш факторларга бәйле барлыкка килә.

Шулай итеп, ялгызлык исемнәренең табигатенә бәйле төрле фикерләр әйтелеп, бүгенге көндә күпчелек галимнәр тарафыннан әлеге төр берәмлекләрнең телнең лексик системасында яшәүләрен, тел закончалыкларына нигезләнеп үсеш-үзгәреш кичерүләрен тану алгы планга чыга.

Ялгызлык исемнәренең семантик структурасында өч компонент аерыла: денотат, сигнификат и коннотат. Ялгызлык исеменең денотаты булып, аталган объект яки субъект тора. Ялгызлык исеменең денотаты – исем-атаманы йөртүче объект яки субъект. Исемнең денотаты зур бер төркемнән аерым бер предмет, субъектны аерып алып атарга ярдәм итә. Бер үк исем-атаманы берничә субъект яки объект йөртүгә карамастан (мәсәлән, бер үк антропоним берничә субъектка бирелергә мөмкин, шулай ук бер үк исем төрле шәһәрдәге урамнарга атама буларак хезмәт итә ала), аларны нәкъ бертөрле дип әйтеп булмый. Ялгызлык исеме бу төр исем-атаманы йөртүче объект яки субъектны гомумиләштерми, аларның һәрберсе уникальлекләрен исемгә бәйле генә югалта алмый, шул даирә өчен хас мәгънәгә ия булалар. Теләсә нинди ялгызлык исеме, нинди даирәдә әйтелгәнгә бәйле, аерым ассоциацияләргә, мәгънәгә

ия, мәсәлән, *Бауман урамы* Татарстан Республикасында яшәүчеләр өчен башкалабыз Казан шәһәренең төп урамы белән бәйле күзаллаулар тудыра, шулай ук *Гөлнәзирә, Айрат, Рамил, Илшат* һ.б. шундый исемнәр татар милләтеннән булган кешегә ишарә итә.

Сүзнең семантик структурасындагы икенче компонент – сигнификат. Күмәклек сүзләрдә сигнификатив мәгънә төшенчә аша реальләшсә, ялгызлык исемнәрендә исә ул бер генә зат яки предмет белән бәйле була, аның турында, аңа гына хас булган билгеле бер мәгълүматны чагылдыра. Ялгызлык исеменең сигнификатив эчтәлеге – исемне сайлаганда туа торган күзаллаулар ул.

Шулай итеп, ялгызлык исеменең семантик структурасындагы ике компонент – денотат һәм сигнификат бердәнбер объект яки субъектны атауда ачыла.

Семантик структураның өченче компонентын коннотатив эчтәлек тәшкил итә. Коннотацив мәгънә – сүзнең төп, атау, денотатив мәгънәсен тулылындырып килә торган эмоцональ-экспрессивлыкка, стилистик бизәк, төсмергә ия лексик мәгънә компоненты (Татар лексикологиясе, 2015: 59). Әлеге компонент турыдан-туры лексик мәгънә составына кермәсә дә, татар телендә сөйләшүчеләр өчен ул тотрыклы һәм милли традицияләрне чагылдыра торган компонент санала.

Ялгызлык исеменең коннотатив мәгънәсе кулланылышта ике төрле ачыла. Беренчесе – сөйләмдә турыдан-туры үз функциясендә төрле стилистик кушымчалар ялганып килеп, сүз барган объект яки субъектка карата төрле мөнәсәбәт белдерүе (мәсәлән, *Яшә, **Казаным**!; **Арчаларга** барсаң, бәгырем...; Ак **Иделкәй** буе андызлык; Сания**кәй**, Нәфисә**кәй**, Гөлназ**ым**, Гүзәл**ем*** һ.б. (http://www.corpus.tatar/main.htm)).

Коннотатив мәгънә ачылган икенче очрак – ялгызлык исеменең сөйләмдә башка бер функциядә килүе. Билгеле булганча, ялгызлык исемнәренең сөйләмдәге функцияләре шактый киң. Алар бик җиңел рәвештә күмәклек сүзләр рәтенә күчәргә сәләтле һәм бу үзенчәлек ялгызлык исемнәренең семантикасына бәйле бәхәсләргә урын калдыра.

Ономастика фәнендә ялгызлык исемнәренең башка функциядә, башлыча күмәклек сүзләре рәтендә килүләре төрле термин белән атап йөртелә. Шулар арасында киң таралганы – д е о н и м л а ш у, д е о н и м и з а ц и я (кайбер хезмәтләрдә а п е л л я т и в а ц и я)

күренеше дип атала. Әлеге төр күчеш барышында ялгызлык исеме үзенең югарыда саналган төп семантик үзенчәлекләрен югалтып, күмәклек сүзләренә хас билгеләр белән тулылана, ягъни уртак билгеләре булган бер төркем предмет, процесс, билге һ.б.ны атый башлый, гомумиләштерү сәләтенә ия була, төшенчә белән ныклы бәйләнеш хасил итә һ.б. Танылган ономатолог А.В. Суперанская моны түбәндәгечә аңлата: «Тамгалар системасы булган тел катламына күчкәндә, ялгызлык исеме билгеле бер дәрәҗәдә интеллектуаль мәгълүматка ия булырга тиеш. Бу мәгълүмат онимга логик-предмет рәтләре белән бәйләнеш булдырырга ярдәм итә. Ялгызлык исеменең интеллектуаль мәгълүматка ия булуы аның күмәклек сүзләр рәтенә күчүенә китерә» (Суперанская, 1978: 7). Шул рәвешле ялгызлык исеме күмәклек сүзләрнең асыл сыйфатларына ия була башлый, ул *атап кына калмый*, бәлки *белдерә дә башлый*, мәсәлән, *донжуан* – гыйшык маҗаралары эзләгән ир-ат затын атау өчен; *мәҗнүн* – өметсез мәхәббәт корбаны булган ир-егеткә карата; *биби* – аңгыра, беркатлы кызга карата, *дизель* – уйлап табучы һәм аның ачышы нәтиҗәсе двигатель тибы; *бостон* – шәһәр атамасы һәм биредә эшләнгән тукыма төре; *кашемир* – шәһәр атамасы (Кашмир) һәм тукыма төре; *әлдермеш* (суы) – авыл атамасы һәм шул авылдагы чишмә суы һ.б. Алар сөйләмдә күмәклек сүзләр вазифасын башкаралар, мәсәлән: *Журналист дигән һөнәремне яшереп, сөйгән кызым ташлаган бәхетсез* ***мәҗнүн*** *кыяфәтенә кереп юлга чыктым...* (http://corpus.tatar/main.htm). *Шул рәвешле беткән иде җыр һәм нотык, чыкты да мәйданга бер* ***мәҗнүн*** *– өтек!* (Ш. Бабич).

Бу төр сүзләрне күмәклек һәм ялгызлык исемнәре арасында торган арадаш берәмлекләр буларак караучылар да бар. Рус һәм инглиз телендәге ялгызлык исемнәренең кулланылыш һәм үзара күчеш үзенчәлекләрен өйрәнгән Р.З. Ханичев аларны *апеллонимик интерподсистема* дигән термин белән атауны тәкъдим итә (Ханичев, 2004: 4). Аның фикеренчә, бу төр лексемалар ике төрнең берсенә дә карамый, чөнки аларның аермалы булган сыйфатлары бар. Чыннан да, бер төркем ялгызлык исемнәре татар телендә дә ялгызлык исемнәре рәтеннән китеп, күмәклек сүзләр рәтенә күчеп җитмәгән. Түбәндәге мисалларда моны ачык күрергә мөмкин: *Безнең төбәкнең үз «****Шәкүр карагы****» бар ахры: теге авылдан да атлар югалган, моннан да – хәбәрләр йөреп кенә торды* (http://corpus.tatar/main.htm). *Янымда басып торучы апа, миңа*

*ишарәләп: Күр әле,* ***Тукай теленнән*** *бизеп барабыз лабаса, – дип канәгатьсезлеген белдереп алды* (http://web-corpora.net). *Кабатлап әйтәм, әгәр Такташ якташларыннан берничә егет* ***Такташ телендә*** *язып, син генә чит телдә язсаң, ул хәтле борчылмас идем* (http://web-corpora.net).

Ялгызлык исемнәренең һәм күмәклек сүзләренең тыгыз бәйләнеше тел даирәсендә атау һәм идентификацияләү функцияләренә ия булган шактый хәрәкәтчән берәмлекләр хасил булуга китерә. Аларның семантикасы атау гына түгел, белдерү үзенчәлегенә дә ия булуларына ишарәли. Мәгънә ягыннан ике яклы булулары аларның коммуникатив һәм сәнгати рольләрен киңәйтә. Ике функцияле тамгаларның телдә кулланылышы түбәндәге нәтиҗәләргә китерә: 1) телнең кулланылыш даирәсен киңәйтә; 2) тел тамгаларының кулланылыш ешлыгын арттыра; 3) тел системасының үзара бәйләнешен арттыра; 4) аерым бер телдә сөйләшүчеләрнең гомуми фикерләү мөмкинлекләрен күрсәтә.

Ялгызлык исеменең күмәклек сүзләр рәтенә күчүе очрагында оним очраклы-ситуатив мәгълүматны белдерә башлый һәм аерым предмет, күренешләр белән логик бәйләнешкә керә, аерым бер милли-мәдәни даирәгә билгеле булган эчке формага ия була. Н.В. Подольскаяның «Словарь русской ономастической терминологии» хезмәтендә күрсәтелгәнчә, бу төр күчешнең түбәндәге төрләре аерыла: 1) зат исеме – зат; 2) зат исеме – әйбер; 3) урын атамасы – әйбер; 4) зат исеме – эш-хәл; 5) урын атамасы – эш-хәл; 6) зат исеме – үлчәү атамасы (Подольская, 1988: 55).

Күмәклек сүзләр рәтенә күчү процессында ялгызлык исеме һәм фонетик, һәм семантик үзгәртүләргә дучар булырга мөмкин, мәсәлән, *арча читеге* – мисалында урын атамасы һәм әйбер мөнәсәбәте белән бергә, семантик үзгәреш тә күзәтелә, ягъни читекнең күннән ясалганына да ишарә сизелә. Шулай ук тагын бер искәрмә: барлык халыклар өчен универсаль күчешләр белән бергә (мәсәлән, зат исеме – үлчәү атамасы (*ампер, ватт, вольт* һ.б.), һәр халыкның мәдәниятенә, милли үзенчәлегенә бәйле үзенә генә хас күчешләре дә күп була, аерым алганда, татар телендәге *шомбай, биби, мәҗнүн, хуҗа насретдин* һ.б. кебек сүзләр шундыйлардан санала. Ялгызлык исемнәренең апеллятив лексика рәтенә күчү сәбәпләреннән экстралингвистик факторлар алгы планга чыга, чөнки кайсы да булса ялгызлык исеменең бу төр күчешкә дучар ителүенә

тел үсешеннән бигрәк, иҗтимагый, мәдәни, сәяси факторларның тәэсире көчлерәк. Бу процесс өчен ялгызлык исеменең халык арасында киң таралыш табуы, аерым бер вакыйга, әсәр, эш-хәлнең танылуы мөһим.

Ялгызлык исемнәренең семантик үзенчәлекләреннән тагын бер әһәмиятле ягы – трансонимизация күренеше. Трансонимлашу (трансонимизация) – ялгызлык исеменең бер төркемнән икенче бер ялгызлык исеме төркеменә күчүе (Подольская, 1988: 138). Бу күренеш деонимизация күренешеннән аерыла, чөнки биредә оним күмәклек сүзләргә хас үзенчәлекләргә ия булмый, бары тик үзе кебек башка бер төркем ялгызлык исеменә әйләнә. Мәсәлән, *Алсу* – кеше исеме, кибет атамасы; *Ак Барс* – кибет атамасы, хоккей клубы атамасы, банк атамасы, кошчылык фабрикасы һ.б.; *Чулпан* – кеше исеме, кибет атамасы, фирма атамасы; *Байкал* – күл атамасы, газлы эчемлек атамасы; *Болгар* – этноним һәм торак пунктлар атамасы. Мисал өчен, Түбән Кама районында *болгар* этнонимыннан ясалган Болгар авылы урнашкан, әлеге атама Әлмәт һәм Лениногорск районнарында да очрый.

Фәнни хезмәтләрдә, нинди төр ялгызлык исеме күчешенә бәйле барлыкка килгән *трансантропонимизация* (антропонимик берәмлекләрнең башка төркемгә күчеше), *транстопонимизация* (топонимик берәмлекләрнең башка төргә күчеше) һ.б. шундый атамалар да очрый, әмма һәрберсенең асылы аерым бер төрдәге ялгызлык исеменең башка оним рәтенә күчүенә кайтып кала.

Ялгызлык исемнәре рәтенә күз салсак, трансонимлашу күренеше нәтиҗәсендә составын тулылындыра торган төркемнәргә топоним, эргоним һәм прагматонимнарны кертергә була, алар, башлыча, антропоним, этнонимнар хисабына ономастик составларын даими тулылындыралар, антропонимнар исә бу процесска аз бирешәләр. Аларның составы, нигездә, күмәклек сүзләре (деонимлашу) күренеше нәтиҗәсендә тулылына.

Шулай итеп, ялгызлык исемнәренең мәгънәви һәм функциональ потенциалы шактый киң, алар, телебезнең эчке ресурсларыннан тыш, башка телләрдән һәм мәдәниятләрдән алынган семантик мөмкинлекләрне дә үзләренә туплаган, сөйләмдә кулланылыш процессында яңадан-яңа мәгънә төсмерләре белән тулыланырга сәләтле гаять дәрәҗәдә катлаулы берәмлекләр булып торалар.

# ТАТАР АНТРОПОНИМИКАСЫ

## § 3. Татар антропонимикасын өйрәнү тарихы

Татар ономастикасы XX гасыр урталарында формалашып, шул чордан бу өлкәдә системалы рәвештә фәнни тикшеренүләр барлыкка килде дисәк тә, аның башлангычы борынгы чорларда теркәлеп калган төрле чыганакларга барып тоташа.

Мөстәкыйль тармак булып оешканчы, татар ономастикасы шактый озын юл үтә. Аны өйрәнү өчен әһәмиятле чыганаклар булып грек-византия (б.э.к. IV – б.э. XII йөзләре), кытай-монгол (б.э.к. III – б.э. XIII йөзләре), әрмән (V–XIII йөзләр), гарәп-фарсы (IX–XV йөзләр), рус чыганаклары (X–XVIII йөзләр), Европа сәяхәтчеләре һәм галим-географлары язып калдырган хезмәтләр һ.б. күрсәтелә. Аларда, Идел болгарлары һәм башка кабилә-кавемнәр хакындагы тарихи һәм мәдәни мәгълүматлар белән беррәттән, гидронимнар, топонимнар, этнонимнар да урын алган (Гарипова, 1994: 8).

Уртак төрки ономастик мирасны барлаганда борынгы Орхон-Енисей руник истәлекләрендә, соңрак уйгыр юридик документларында теркәлеп калган материалларны атау кирәк. Жанры ягыннан тарихи-биографик, эпитафик, кыя-ташларга, корылмаларга язылган руник язмалар, магик һәм дини текстлар, юридик документлар һ.б. формаларда булган рун язуларында теркәлгән материаллар төрки антропонимиянең чыганаклары, борынгы ышанулар, төркиләрнең дөньяга карашлары, тарихи шәхесләрнең исем-титул бирелү үзенчәлекләре һ.б. турында мәгълүмат бирә.

Идел буе төркиләренә караган ономастик материалларны 921–922 елларда Идел Болгарстанына килгән Әхмәт бине Фадлан

тарафыннан язылган чыганак-сәяхәтнамәдә күрәбез. Биредә шактый зур ономастик материал – кабилә атамалары, топонимик материаллар белән бергә, кеше исемнәре турында да бай мәгълүмат тупланган.

Борынгы төрки ономастиканы өйрәнүнең нигезләре Мәхмүт Кашгари, Әбү Рәйхан әл-Бируни хезмәтләренә барып тоташа. Мәхмүд Кашгариның «Диване лөгатет-төрк» (1074) сүзлегендә борынгы төрки халык һәм кабиләләре телләренең бай апеллятив лексикасын гына түгел, борынгы төрки ономастикага караган алыштыргысыз материаллар да урнаштырган. А.Н. Кононов бу хезмәтне: «XI гасыр төркиләренең тормышын, ..., этноним, топонимнарын, кабиләләр бүленешен, туганлык терминнарын, ... титуллар, төрле статустагы кешеләрне атый торган берәмлекләрне, терминнар, шәһәр, торак пункт атамаларын, ... тарихи шәхесләр һәм мифик геройларның исемнәрен ... дини һәм этник терминология турында мәгълүмат бирә торган бердәнбер чыганак булып тора», – дип билгели (Кононов, 1972: 5–6).

Чыганак буларак, XIII–XIV гасырларда болгар, ә XV–XVIII йөзләрдә татар эпиграфик һәйкәлләрендә теркәлгән борынгы болгар һәм татар антропонимнары зур кыйммәткә ия.

Татар антропонимиясенә караган кыйммәтле материаллар нәсел шәҗәрәләрендә сакланып калган. Татар шәҗәрәләрен өйрәнүгә зур өлеш керткән М.И. Әхмәтҗанов үзенең хезмәтләрендә (1981, 1991, 1995, 2002 һ.б.) күп гасырлар дәвамында тупланып килгән фактик материалны фәнни әйләнешкә кертеп, татар антропонимикасы фәнендә XIII–XX гасыр һәм хәзерге көн исемнәр системасының үсеш-үзгәреш тенденцияләрен күрсәтә.

Тарихи антропонимияне чагылдырган чыганаклардан XVI–XIX гасырларга караган «Ревизские сказки», Казан язу (писцовые) кенәгәләрен аерым атап китү зарур. Аларда шул чорларда яшәгән кешеләрнең исемнәре белән бергә, хуҗалык алып барулары, нинди катлауга караулары, яшәгән урыннары теркәлгән. Һәм исемнәрне русча язу барышында алдагы чорларга күчкән антропонимик вариантлар, исем бозылу үзенчәлекләре, беренче тапкыр фамилия куллану, аның төрләре күрсәтелгән. Әлеге кенәгәләрне фәнни әйләнешкә керткән тарихчылардан М.Г. Госманов, С.А. Мартьянов, И.П. Ермолаев, Д.Ә. Мостафина һ.б.ларны атарга кирәк.

XVI–XVII гасырлар Казан өлкәсенә караган язма истәлекләр К.Р. Галиуллин, Э.А. Исламова (2000); К.Р. Галиуллин, А.Р. Гыйзәтуллина (2008, 2010); К.Р. Галиуллин, Р.Р. Шакирова (2009) хезмәтләрендә теркәлгән, соңрак бу материаллар интернет-сүзлекләр формасында да (http://www.klf.kpfu.ru) тәкъдим ителде. Биредә шулай ук тарихи антропонимиягә караган материаллар системалаштырып бирелә.

1863 елда язылган «Исследование о касимовских царях и царевичах» хезмәтендә В. Вельяминов-Зернов татар кешеләренә кушылган иске исемнәр турында бай материал бирә. Биредә, татар исемнәренең ясалышы, лингвистик үзенчәлекләре һәм мәгънәләре аңлатыла. Галим, беренчеләрдән булып, халыкның җанлы сөйләм телендә кушма исемнәренең кыскартылуын күрсәтә. Шулай ук Касыйм ханлыгында кулланылган катлау титулларын саный, аларның кайберләре исем ясауда катнашуын күрсәтә (Саттаров, 1970: 14–15).

С. Мельниковның «Акты исторические и юридические и древние царские грамоты Казанской и других соседних губерний» (1859) китабында XVI–XVII гасырларда Казан һәм Зөя гаскәр башлыкларына бирелгән хан грамоталары урнаштырылган. Биредә Казан өлкәсенә караган тарихи, статистик, юридик, топографик, ономастик мәгълүматлар белән бергә, гарәп һәм фарсы исемнәре белән чагыштырганда ешрак кулланылган татар исемнәре, атасының исеме, ярымфамилияләр тупланган.

Казан топонимия мәктәбе вәкиле Н.И. Золотницкийның «Алфавитный список древних исторических инородных имен, преимущественно встречающихся в исторических и юридических актах и служащих объясенению названий населенных местностей Казанской губении» хезмәтендә XVII гасырга караган 147 татар кешесенең исеме һәм фамилиясе теркәлгән.

В.К. Магницкийның Идел буенда яшәгән төрки халыкларның ономастикасын өйрәнүгә керткән өлеше бик зур. 1905 елда аның Казанда басылган «Чувашские языческие имена» хезмәтендә төрле фонетик варианттагы 10000 борынгы төрки (чуваш, татар һ.б.) исемнәр алфавит тәртибендә бирелгән (Саттаров, 1970: 32). Бу хезмәт борынгы болгар-татар антропонимиясен, шулай ук борынгы мари (чирмеш) исемлеген өйрәнүдә әһәмиятле чыганак булып тора. Авторның икенче хезмәте – «Алфавит языческих имен

черемис Елабужского уезда» дип атала. Анда исламгача чорда кулланылган 399 ир-ат һәм 245 хатын-кыз исеме тупланган. Аларның күпчелеге исламгача кадәр булган антропонимик материалны берләштерә. Бу хезмәт төрки, фин-угор халыкларының борынгы заманнарда уртак антропонимик фондны куллануын исбатлый торган кыйммәтле материал исәпләнә.

Татар антропонимиясен тарихи яссылыкта өйрәнүдә әһәмиятле чыганак булып 1884 елда Казанда басылган «Труды статистической экспедиции, снаряженной в 1883 году Казазнским губернским земством» (3 беркетмәдә, 118 бит), 1890 елда шулай ук Казан университеты типографиясендә басылган, И.Ф. Токмаков тарафыннан әзерләнгән «Сборник и указатель документов и рукописей, относящихся к Казанской губернии и хранящихся в московском главном архиве Министерства Иностранных дел и его библиотеке» басмалары да зур роль уйный. Биредә, башка төр документаль материаллар белән бергә, кеше исемнәре, аларның нинди катлауга караулары да теркәлгән.

Идел буенда яшәүче төрки халыкларның антропонимиконын өйрәнүдә һәм туплауда Н.И. Ашмарин эшчәнлеген ассызыклау кирәк. Аның 1902 елда басылып чыккан «Болгары и чуваши» хезмәтендә Кубрат, Аспарух, Тервил, Север, Вихтун, Ослан һ.б. шундый борынгы исемнәрнең этимологиясен аңлатуга урын бирелә. Бу максаттан лингвистик анализда татар кеше исемнәрен дә куллана. Үз чиратында, бу хезмәттә бирелгән анализга җентекле бәяләмәне Г.Ф. Саттаров тагын да үстерә, тулылындыра (Саттаров, 1970: 37).

Татар антропонимик системасын өйрәнүдә кызыклы чыганаклар рәтенә махсус циркулярлар, календарь һәм исемлекләрне дә кертергә кирәк. Мәсәлән: «Вәгазь намә рисаләсе ирләргә вә хатын-кызларга исемнәре белән бәян ителгәндер» (1846), «Исеме Аллаһе тәгалә әл-хәсәни» (1848), «Авради Фәтхия», (1865), «Исем» (1895), Ахун Бендуковның «Исем. Балага күркәм исем бирергә киңәш һәм укучы сабыйларга һәдия кылырга муафыйк китап» (1899, 1900), Кәримовларның «Унбер Әхмәт исемнәре» (1914); Шиһабетдин бине Мелла Габделгазиз бине Рахматулланың «1896 ел календаре», 1897 елда Р. Фәхретдинов тарафыннан төзелгән «Оренбург мөселман диния нәзәрәте тарафыннан төрле елларда муллаларга җибәрелгән циркулярлар җыентыгы».

XIX йөзнең икенче яртысында татар антропонимик системасын өйрәнүгә татар галимнәре Ш. Мәрҗани, К. Насыйри, Г. Әхмәров зур өлеш кертә.

Шиһабетдин Мәрҗани үзенең ике томлык «Мөстәфад әләхбар фи әхвали Казан вә Болгар» (I том, Казан, 1885; II том, Казан, 1900) хезмәтендә Болгар һәм Казан ханлыгы тарихын өйрәнү барышында бик күп санлы ономастик материалны да куллана. Хезмәттә урын алган күренекле татар шәхесләренең шәҗәрәләре кеше исемнәрен өйрәнүдә шулай ук кыйммәтле чыганак булып тора. Алар нигезендә татар теленә гарәп һәм фарсы исемнәренең килеп керү чорларын, үзенчәлелкәрен, таралыш ешлыгын, борынгы исемнәрнең яңа төр алынмалар белән кушылуыннан татар антропонимиясендә барлыкка килгән яңалыкларны өйрәнү әһәмиятле нәтиҗәләргә ирешергә мөмкинлек бирә.

Шул ук авторның 6 томлык «Вафийәт әл-әсляф вә тәхийәт әләхляф» кулъязма хезмәте гарәп телендә язылган һәм шәҗәрәләргә, 643–1889 елларда яшәгән галим, әдәбиятчы, шагыйрь, җәмәгать эшлеклеләренең биографияләренә багышланган.

XIX гасырның 70 нче елларында төрки-татар ономастикасына, шул исәптән антропонимия өлкәсенә караган фәнни мәгълүматларны системалы туплау һәм эшкәртү чоры башлана. 1878 елда Казан университетында «Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте» оешу төбәкне өйрәнүгә гаять зур этәргеч була. Тарихи-этнографик тикшеренүләр алып бару, шул исәптән ономастик материал туплау һәм аны өйрәнү җәмгыятьнең төп эшчәнлекләреннән берсе булып тора. Җәмгыять каршында ономастик түгәрәк оешып, аның составына күренекле галимнәр Н.Я. Агафонов, И.А. Бодуэн-де-Куртенэ, Н.П. Загоскин, И.А. Износков, Д.А. Корсаков, В.Н. Поливанов, П.А. Пономарев, В.В. Радлов, С.М. Шпилевский һәм башкалар керү әлеге өлкәгә игътибарның зур булуын дәлилли. Казан университетында ирекле тыңлаучы буларак белем туплаган К. Насыйри Җәмгыять эшендә актив катнаша башлый һәм 1885 елдан ул аның хакыйкый әгъзасы булып санала (Галиуллина, 2015: 14).

К. Насыйри татар ономастикасына бәйле гаҗәеп бай мәгълүмат туплый. Татар тарихы, этнографиясе өлкәсендәге эшчәнлеге белән үрелеп барган бу гамәл, соңрак, татар тел белемендә зур бер фәнара тармак саналган ономастика фәне барлыкка килүгә,

төрки-татар ономастика гыйльми мәктәбе формалашу һәм үсүгә зур этәргеч булды. Татар мифологиясе, фольклорына бәйле чыганакларны барлау, кабер ташларын, язма документларны тикшерү белән беррәттән, К. Насыйри теге яки бу төбәк, авыл тарихына караган мәгълүматларны барлауга һәм системалаштыруга да зур игътибар бирә. Мисал өчен, үзенең туган төбәге Зөя өязенең кайбер авыллары һәм Зөя каласы турындагы материаллары татар ономастикасының топонимия һәм антропонимия, этнонимия тармаклары өчен кыйммәтле чыганак булып торалар. Казан император университетында ирекле тыңлаучы булып белем алу, соңрак университет каршындагы танылган «Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте»нең хакыйкый әгъзасы булып тору галимнең бу өлкәдәге эшчәнлегенә уңай тәэсир итә. К. Насыйри төрле шәҗәрәләр туплауга аерым игътибар бирә. Мисал өчен, аның Казан университеты китапханәсендә сакланган кульязмалары арасында пәйгамбәрләр шәҗәрәсе, нәсел шәҗәрәсе һәм атасы Габденнасыйрдан башланган шәҗәрә бирелә. Галим, шәҗәрәләр язу белән беррәттән, аерым топонимик берәмлекләргә этимологик анализ да биреп бара. Мисал өчен, К. Насыйриның «Зөя өязе авыллары» хезмәте тулысы белән авылларның барлыкка килүе, үсеше, атамаларының килеп чыгышын ачыклауга багышланган. Һәр авылга бәйле мәгълүмат аерым бер мәкалә буларак формалаштырылган. Авылларга караган эпитафик язмалар, тарихи риваятьләр, кульязма документлар, шәҗәрә һәм топонимнарны комплекслы өйрәнеп, галим 21 авыл тарихына һәм топонимиясенә анализ бирә. Барлык мәкаләгә хас структура түбәндәгедән гыйбарәт: авыл барлыкка килү вакытына бәйле мәгълүмат, нигез салучы кешегә бәйле мәгълүмат (нигездә, галим анализлаган авылларның зур күпчелеге кеше исеменә нисбәтле барлыкка килгән) һәм аның шәҗәрәсе, географик характеристика, авыл тарихына караган документ, кабер ташъязмаларына, башка чыганакларга күзәтү, кайбер халык авыз иҗаты ядкярләреннән мисаллар китерү, әһәмиятле роль уйнаган микротопонимнар булса, аларны күрсәтү. К. Насыйри тарафыннан тәкъдим ителгән бу алым хәзерге көндә дә ономастик материалны бәян итүдә кулланыла.

Өйрәнгән шәҗәрәләре нигезендә К. Насыйри татар халкының этногенезына кагылышлы фикерләрен дә белдерә, аерым алганда, Казан татарлары формалашуда болгар кабиләләренең ролен күр-

сәтә, татар милләте формалашу процессында барган үзгәрешләр, Урта Идел һәм Кама буенда яшәгән башка кабиләләрнең йогынтысы турында язып калдыра.

Тарихчы Г. Әхмәров хезмәтләрендә шулай ук топонимик, антропонимик материалга зур урын бирелә. Галимнең 1903 елда «Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте»нең «Известия»сендә дөнья күргән (т. XIX, 2 нче чыгарылыш) «О языке и народности мишарей» мәкаләсендә мишәрләрнең килеп чыгышын ачыклау максатында лингвистик материалны, шул исәптән кеше исемнәрен, фамилияләрне, торак пункт атамаларын да анализлый. Өстәмә материал буларак кына каралса да, автор мишәрләрдә кулланылган исемнәрдә борынгылык сакланганлыгына, фонетик үзгәрешләргә, Казан татарларының исемлегеннән аермалы моментларга ишарә итә. Күпсанлы мисаллар белән исбатлап барылган әлеге фикерләр татар антропонимикасының уртак һәм үзгә аспектларын алга таба билгеләүдә фәнни нигез буларак хезмәт итте.

XX гасыр башында татар исемнәренә кагылышлы фикерләр күренекле язучы-әдипләр, җәмәгать эшлеклеләре тарафыннан да әйтелә. Рухи мирасыбызның асылын тәшкил иткән, татар милләтенең теле һәм мәдәниятенең көзгесе булган исемнәр системасына Габдулла Тукай аеруча игътибар бирә. Публицистикасында, ачы телле сатира әсәрләрендә, дусларына язган хатларында Габдулла Тукай һәрвакыт исемнәргә гаять зур игътибар бирә. Татарлар арасында кулланылган исемнәрнең милли рухта булуы зарурлыгын, исемнең җисем белән тәңгәллегенә булган мөнәсәбәте әдипнең «Гаҗәп түгелме?» (1906), «Исемнәремез хакында» (1911), «Казанга кайтыш» (1912), «Мәкаләи махсуса» (1913) һәм башка хезмәтләрендә ачык чагыла.

1914 елда «Мәктәп» журналының 5 нче санында Ф. Әмирханның «Татар кеше исемнәрен татарчалаштыру хакында»гы мәкаләсендә татар исемнәренең алынмалар белән чуарлануы, төрки чыгышлы исемнәрнең юкка чыгуына борчылып язган фикерләре фәнни әһәмияткә ия.

Октябрь инкыйлабыннан соң, татар телен системалы өйрәнү активлашса да, ономастик материалны өйрәнүдә мондый продуктивлык күзәтелми.

1948 елда Финляндиядә Хәсән Хәмидулланың «Исем көннәре календаре» басылып чыга, автор башка халыкларда булган мондый

төр календарьнең татарларларда булмавы, яшьләрнең аңа ихтыяҗы зурлыгын ассызыклый. Анда гарәп һәм латин шрифтында аерым бер көнгә беркетелгән, килеп чыгышлары ягыннан төрки, гарәп һәм фарсы, татар телләренә караган ир-ат һәм хатын-кыз исемнәре бирелгән (Саттаров, 1970: 64).

XX гасырның 60 нчы елларыннан татар антропонимиясенә багышланган махсус монографик хезмәтләр күренә башлый. Һ.В. Йосыповның «Болгар-татар эпиграфикасына кереш» (1960) китабында, мәсәлән, күпсанлы экспедицияләр нәтиҗәсендә тупланган борынгы татар кеше исемнәренә тарихи, лексик-фонетик анализ бирелә.

1966 елда Ф.С. Фәсиевнең «Казан утлары» журналында кеше исемнәренең күмәклек сүзләрдән аермасы, килеп чыгышлары һәм башкарган функцияләре ягыннан үзенчәлекләрен фәнни-популяр стильдә яктырткан «Кеше исемнәре дөньясына сәяхәт» исемле мәкаләсе басылып чыга.

1963 елдан башлап, татар антропонимикасын Г.Ф. Саттаров өйрәнә башлый, соңрак аның җитәкчелегендә Казан университетында дөньякүләм билгеле Казан төрки-татар ономастика мәктәбе формалашып, җитди нәтиҗәләргә иреште.

1960–1980 елларда әлеге фәнни мәктәп кысасында татар антропонимиясенә кагылышлы тикшеренүләр нигездә тарихи-этимологик, лексик-семантик, сүз ясалышы һәм норматив (кеше исемнәренең орфографиясе) юнәлешендә үткәрелә. Бу проблемаларны яктыртуга Г.Ф. Саттаровның күпсанлы хезмәтләре, мәкаләләре багышлана. 1975 елда галимнең «ТАССР антропотопонимиясе» дигән темага докторлык диссертациясе яклавы татар антропонимиясен өйрәнүнең яңа баскычка күтәрелүенә этәргеч була.

1981 елда галимнең татар исемнәрен тупланган «Татар исемнәре сүзлеге» дөнья күрә. Татар исемнәренең төп нигезен тәкъдим иткән бу беренче аңлатмалы сүзлектә 10 меңгә якын (төрдәшләре белән 15 меңнән артык) кеше исеме тупланган һәм аларның этимологияләре бирелгән.

1986–90 еллар аралыгында антропонимия өлкәсендә үткәрелгән эзләнүләр 2 юнәлештә алып барыла: 1) татар антропонимикасы һәм татар халкының килеп чыгышы мәсьәләләре һәм 2) гарәби чыгышлы татар кеше исемнәрен тарихи-лингвистик яктан тикшерү. Гомәр Фәез улы беренче булып татар антропонимнарын тарихи-лингвистик аспектта фронталь өйрәнә, ул җыелма ономас-

тик материалны тикшерүгә комплекслы якын килә. Ныклы нигез булдыру өчен, аерым фактларга гына тукталырга түгел, ә өйрәнелә торган мәсьәләгә кагылышлы барлык фактлар җыелмасын алырга кирәк, дип саный автор. Ул татар теленең антропонимик системасын булдыру, аны теоретик тасвирлау, татар теленең ономастик подсистемасының структурасын ачу, аның барлыкка килү, үсү һәм кулланылу юлларын, закончалыкларын ачып бирү өстендә эшли.

Г.Ф. Саттаровның «Исемең матур, кемнәр куйган?» (1989) монографиясендә эзлекле тарихи-лингвистик аспектта татар исемнәренең килеп чыгышы, барлыкка килүенең сәбәп-мотивлары, сабыйга исем сайлау һәм кушуның милли традицияләре һәм исемнәребезнең хәзерге төп үсеш тенденцияләре бәян ителгән.

Аның «Татар антропонимикасы» (1990) хезмәте тулысы белән шушы темага багышланган. Биредә Г.Ф. Саттаров антропонимик номинатив категорияләрне, башкара торган вазифалары һәм кулланылыш үзенчәлекләреннән чыгып, икегә бүлә: төп антропонимик номинатив категория – исем; өстәмә антропонимик номинатив категорияләр – кушамат, әтисенең исеме һәм фамилия. Автор кеше исемнәренең барлыкка килү, формалашу, үсү-үзгәрү процессы җәмгыятьнең иҗтимагый-тарихи һәм мәдәни-идеология эволюциясе, иҗтимагый-икътисади формацияләргә бик тыгыз бәйләнгәнлеген әйтә һәм шушы җәһәттән татар телендә кеше исемнәренең барлыкка килү һәм үсеш эволюциясен тарихи планда өч чорга бүлеп карый: 1) мәҗүсилек ышанулары, йолалары тәэсирендә булган борынгы төрки чор (безнең эра башлары – X йөз); 2) ислам дине һәм шәригате кануннары йогынтысыда булган икенче чор (X йөз – XX йөз башы); 3) Бөек Октябрь социалистик инкыйлабыннан соңгы чор (1917 елдан башлап, бүгенге көнгәчә).

Татар антропонимиясен тарихи-лингвистик планда җентекле итеп тикшерү-анализлау татар халкының тарихын, этнографиясен, этногенезын һәм тел тарихын, бигрәк тә тарихи лексикологиясен өйрәнү өчен зур әһәмияткә ия булу белән беррәттән, башка төрки һәм төрки булмаган халыкларның антропонимик системасын өйрәнү өчен дә бик мөһим. Бу хезмәт башка төрки халыкларның антропонимик системасын өйрәнүдә дә фәнни-методологик нигез ролен башкара.

1998 елда Г.Ф. Саттаровның «Татар исемнәре ни сөйли?» дигән хезмәте нәшер ителә. Биредә, милли исемнәребез хәзинәсе

мөмкин кадәр бай, тулы булсын дигән максатны тормышка ашыруны күздә тотып, төрле чыганаклардан җыйналган 15 меңгә якын (төрдәшләре белән 20 меңнән артык) татар ир-ат һәм хатын-кыз исеме туплап бирелгән. Аларның татарча һәм русча дөрес язылышлары, генезислары күрсәтелгән, лексик мәгънәләре һәм этимологияләре аңлатылган. Әлеге хезмәт өч бүлектән тора. Беренче бүлектә теоретик материал яктыртылса, икенче бүлектә сүзлек бирелгән, өченче бүлектә исә бала тууга һәм исем кушуга бәйле гореф-гадәт һәм йолалар тулысынча чагылыш тапсын өчен, төрле авторларның язмалары тәкъдим ителә, татарларда кешегә эндәшү-мөрәҗәгать итү сүзләре бирелгән.

Төрки-татар ономастикасын өйрәнү эше татарлар яшәгән башка төбәкләрдә дә үсеш алды. Уфада бу эш А.Г. Шәйхулов һәм аның шәкертләре эшчәнлегенә бәйле. А.Г. Шәйхулов Идел–Урал этнолингвистик регионында яшәүче төрки, монгол, фин-угор һәм һинд-Европа (славян) халыкларының рухи мәдәниятен өйрәнү юнәлешендә киң колачлы эш алып бара. Ул – Идел–Урал регионы антропонимиясе һәм топонимиясен тарихи-лингвистик аспектта тикшерүгә күп көч салган галим. Танылган тюрколог Н.А. Баскаков җитәкчелегендә ватан тюркологиясендә беренчеләрдән булып борынгы төрки чыгышлы антропонимнарның мәгънәсендә, мотивлаштыру һәм исем бирүдә булган уртак һәм аермалы якларны реконструкцияләүнең методологик якларын билгеләнде. Галимнең фәнни нәтиҗәләре «Справочник личных имен народов РСФСР» (1970) җыентыгында урын алды. 1983 елда Уфада аның «Татарские и башкирские личные имена тюркского происхождения» хезмәте дөнья күрде.

2000 елда Мәскәүдә «Наука» нәшриятында Х.Ф. Исхакованың «Сопоставительная грамматика татарких и русских собственных имен» китабы нәшер ителде. Биредә антропоним һәм топонимнарны чагыштырма-грамматик аспектта өйрәнүнең беренче тәҗрибәсе тәкъдим ителә. Ягъни әлеге берәмлекләрнең структурасы, ясалыш үзенчәлекләре, кешегә эндәшү формулаларының татар һәм рус телләрендәге вариантлары, төрләнеш үзенчәлеге, татар телендәге ялгызлык исемнәренең рус телендә бирелеше кебек мәсьәләләр карала.

Татар антропонимиясен өйрәнү XX гасыр ахырыннан бүгенгәчә Г.Ф. Саттаров нигез салган традицияләргә таянып, аның шәкертләре тарафыннан башкарыла.

М.А. Җәләлиева рус һәм Европа телләреннән кергән исемнәрнең килеп чыгышын, кулланылыш үзенчәлекләрен, бу төр алынмаларның үтеп керү сәбәпләрен лингвистик концепция кысаларында өйрәнә (1985).

Ф.Л. Мәҗитова татар фамилияләрен тарихи-лингвистик аспектта тикшерә (1986).

Бүгенге көндә үзенең фәнни мәктәбен булдырган, себер татарларының антропонимиясен өйрәнүне системалы башкарган галимә Х.Ч. Алишина 1999 елда «Себер татарларының ономастикасын тарихи-лингвистик өйрәнү (Төмән өлкәсе мисалында)» дигән темага докторлык диссертациясе яклый. Аның «Ономастикон сибирских татар» исемле ике томлы фундаменталь монографиясе дә аерым игътибарга лаек (1999). Биредә себер татарларының антропонимик системасы формалашуга һәм аның үсешенә бәйле бай фактик һәм теоретик мәгълүмат урын алган.

Татар антропонимиясен комплекслы өйрәнүдә Г.Р. Галиуллина эшчәнлеген билгеләү зарур. Ул Г.Ф. Саттаров җитәкчелегендә 1999 елда «XX гасыр Казан татарларының антропонимиясе» дигән темага кандидатлык, 2009 елда «Лингвокультурологик аспектта татар антропонимиясе» темасына докторлык диссертацияләрен яклый. Татар телендә беренчеләрдән булып, татар антропонимиясен лингвокультурологик яссылыкта комплекслы өйрәнә, татар теленең антропонимик системасының барлыкка килү һәм үсешенә тәэсир иткән төп лингвомәдәни традицияләрне билгели, кеше исемнәре системасына башка мәдәниятләрдән үтеп кергән мәдәни һәм тел элементларын ачыклый, татар антропонимик системасы үсешенә хәлиткеч йогынты ясаган экстралингвистик факторларны билгели. Аның тарафыннан татар теленең ономастик даирәсен комплекслы өйрәнүнең лингвомәдәни моделе эшләнгән (Галиуллина, 2008).

Региональ антропонимияне өйрәнү юнәлешендә татар телендә шактый зур эш алып барыла. Мәсәлән: Ф.С. Сәлимҗанованың «Татарстан Республикасы Тау ягы антропонимик системасына тарихи-лингвистик анализ» (2002), Г.С. Тимерханованың «XX гасырда Яр Чаллы шәһәре татарлары антропонимиясе» (2002), Ф.Г. Ваһапованың «XX гасырда Түбән Новгород татарлары исемнәренә тарихи-лингвистик анализ» (2004), Г.Ф. Тимканованың «XX гасырда кулланылган Төмән шәһәре татар кеше исемнәренә тарихи-

лингвистик анализ» (2005), З.М. Хөснуллинаның «Казан шәһәре татар фамилияләре» (2006) һ.б. хезмәтләр дөнья күрде.

2007 елда татар исемнәрен тирәнтен анализлаган ике хезмәтне билгеләп үтәргә кирәк: Г.С. Хаҗиева, ир-ат исемнәрен төрле чыганакларга таянып, тарихи-лингвистик яктан өйрәнде һәм «Татар ир-ат исемнәренә тарихи-лингвистик анализ» дигән темага, М.З. Вәлиева шул ук юнәлештә хатын-кыз исемнәрен тикшереп, «Татар хатын-кыз исемнәренә тарихи-лингвистик анализ» дигән тема буенча кандидатлык диссертацияләре якладылар һәм бүгенге көндә дә татар антропонимиясен төрле яклап өйрәнү өлкәсендә нәтиҗәле эшлиләр.

Себер татарлары антропонимиясен этнолингвистик яссылыкта комплекслы өйрәнеп, Ф.Х. Гыйльфанова докторлык диссертациясе яклады (2010).

Татар антропонимикасының өйрәнелү тарихына күзәтү ясау әлеге өлкәнең борынгы заманнардан ук игътибар үзәгендә булуын, татар теле белемендә бу юнәлештә киң колачлы эшчәнлек алып бара торган фәнни мәктәп формалашуын, бүгенге көндә кеше исемнәре системасы төрле яссылыкларда эшләнгән комплекслы монографик хезмәтләргә бай булуын күрсәтә.

### § 4. Антропонимика фәненә гомуми билгеләмә

Антропоним (грек. *anthropos* – кеше, *onyma* – исем) – кешеләргә эндәшү, атап мөрәҗәгать итү өчен хезмәт итә торган исем (*Фәрит, Булат, Ләйсән, Мөхәммәт, Сабир* һ.б.), әтисенең исеме (отчество) (*Галиевич, Инсафовна, Илһам улы, Нәкыйп кызы* һ.б.), фамилия (*Сөнгатуллин, Вафина, Ганиев, Бәширов* һ.б.), кушамат (*Тыпыш, Олыколак, Ябалак Рөстәме, Борын Рәшит, Иләк Сарасы* һ.б.), тәхәллүс (псевдоним) (*Дәрдемәнд* (Закир Рәмиев), *Акъегет* (Рөстәм Фәйзуллин) һ.б.) ул.

Кеше исемнәре, әтисенең исеме, фамилия, кушамат, тәхәллүс, криптонимнарның (яшерен исем) килеп чыгышын, төзелешясалыш, кулланылыш үзенчәлекләрен, үсеш-үзгәреш закончалыкларын, антропонимнарга хас мәгълүматларны өйрәнә торган ономастиканың бер тармагы антропонимика дип атала (Языкознание..., 2000: 36). Антропонимика фәне шулай ук матур әдәбият, фольклор әсәрләрендә, миф һәм әкиятләрдә кулланылган антропонимнарны да өйрәнә.

Телнең антропонимнар җыелмасы **антропонимия** (**антропонимикон**) термины белән атап йөртелә.

Антропонимика тармагы ономастика фәне формалашкан чорларда ук аерым бер мөстәкыйль тармак буларак аерылып чыкты. Әлеге фән шәхси исемгә салынган һәртөрле мәгълүматны, аерым алганда, кешене сыйфатлый торган билгеләр, затның нәселе, гаиләсе, ата-анасы белән бәйләнешен, нинди милләт вәкиле булуын, шөгыле, кайсы төбәк кешесе булуын, нинди социаль катламга каравын һ.б. шундый үзенчәлекләрне өйрәнә. Шулай ук соңгы елларда бу фәннең өйрәнү объектларына антропонимның сөйләмдә башкарган функцияләре, атау-номинацияләү, идентификация ясау, дифференциацияләү, кешенең дини күзаллауларына, яшенә, социаль статусына, иҗтимагый яки гаилә хәленә, башка милләтләр арасында яшәешенә, башка дингә күчүенә һ.б.ларга бәйле исем алмаштыру да керә.

Антропонимика ике төрле була: теоретик һәм гамәли. Теоретик антропонимика антропонимнарның барлыкка килү һәм үсеш, структур-ясалыш закончалыкларын, антропонимик система, антропонимнарның модельләрен, тарихи һәм генетик катламнарын, тел системасы һәм антропонимик система бәйләнешен, кулланылыш үзенчәлекләрен өйрәнә. Татар антропонимикасы буенча башкарылган фәнни хезмәтләр (мәсәлән, Г.Ф. Саттаров, Г.Р. Галиуллина, Х.Ч. Алишина, Ф.Л. Мәҗитова, М.З. Вәлиева, Г.С. Хаҗиева-Демирбаш һ.б.ларның хезмәтләре), тулысынча диярлек, шушы аспектта башкарылган. Теоретик антропонимика ономастиканың башка тармакларында кулланылган фәнни методлар һәм алымнар белән эш итә.

Гамәли антропонимика исемнәрдәә әдәби тел нормасының сакланышын, антропонимның төрле телләрдә бирелү үзенчәлекләрен, антропонимик сүзлекләр төзү мәсьәләләрен тикшерә. Татар телендә бу аспектта башкарылган хезмәтләрдән Г.Ф. Саттаровның сүзлекләрен атау зарур. Галимнең «Татар исемнәре сүзлеге»ндә (1981) 10 меңгә якын (төрдәшләре белән 15 меңнән артык) кеше исеме тупланган һәм аларның этимологияләре бирелгән. Шул ук авторның 1998 елда дөнья күргән «Татар исемнәре ни сөйли?» дип аталган сүзлегендә төрле чыганаклардан җыйналган 15 меңгә якын (төрдәшләре белән 20 меңнән артык) татар ир-ат һәм хатын-кыз исеме туплап бирелгән. Аларның татарча һәм русча дөрес язылы-

шлары, генезислары күрсәтелгән, лексик мәгънәләре һәм этимологияләре аңлатылган. Әлеге сүзлекләр аңлатмалы сүзлекләр рәтенә керә.

2005 елда дөнья күргән «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә кушымта буларак (832–847 битләр) татар халкында актив булган кайбер кеше исемнәре һәм аларның мәгънәләре (чыганак телне дә күрсәтеп) бирелгән. Бу белешмәлектә аермалы яклардан исем компонентының да (мәсәлән, *иш-, -задә, -етдин* һ.б.) күрсәтелүен атарга кирәк.

Гамәли антропонимика юнәлешендә эшләнгән тагын бер хезмәт – «Татарча-русча кеше исемнәре һәм фамилияләр сүзлеге» (2006). Әлеге сүзлекнең авторлары – Г.Ф. Саттаров, Р.Г. Әхмәтьянов, Ф.Ә. Ганиев, И.А. Абдуллин, Г.С. Сабирҗанов, К.Р. Галиуллин, Г.Р. Галиуллина. Сүзлек паспорт һәм загс идарәләре хезмәткәрләренә, төрле дәүләт оешмаларына, массакүләм мәгълүмат чараларына татар кеше исемнәре һәм фамилияләренең орфографиясе буенча кулланма буларак тәкъдим ителгән.

Антропонимнарны, мәгънәләренә карап, түбәндәге төрләргә бүлеп йөртәләр:

1. Кеше исеме (*Мөнир, Васыйл, Марат, Әнвәр, Мөхәммәтгали, Маһинур, Әминә, Лилия, Габидә, Шәмсекамәр, Эльвина, Язгөлем*) – кешене атый һәм идентификацияли торган төп берәмлек. Ул антропонимик берәмлекләр арасында үзәк урынны тота һәм ялгызлык исемнәренең табигатен ачыклаганда нигез вазифасын үти. Антропонимнарның башка төрләреннән аермалы буларак, алар беренчел саналалар һәм табигатьләрендә семиотик билгеләр өстенлек итә. Татар телендәге кеше исемнәре системасы ачык, даими үсеш-үзгәрештәге тамгалар системасы буларак яши.

2. Әтисенең исеме (отчество, патроним, мәсәлән, *Вәлиевич, Рөстәмович, Илшатовна, Илгизовна, Дамир улы, Айрат кызы* һ.б.) – балага әтисенең исеменә бәйләп кушыла торган нәсел исеменең бер өлеше. Хәзерге татар телендә ул бер буынлы санала, ягъни турыдан-туры баланың әтисенә ишарәли. Татар телендә соңрак формалашкан берәмлек булып тора, исем белән бергә ата исемен куллану рәсми-хөрмәтләү төсмеренә ия, стилистик максатлардан (хөрмәт, ярарга тырышу, кинаяләү һ.б.) исемнән башка да куллана ала. Мәсәлән, *Саматович безнең белән кул биреп исәнләште* (http://www.corpus.tatar/main.htm). Татар антропонимиясе

тарихында ата исеменә (отчествога) хас үзенчәлеккә ия булган Исем *углы* Исем (*Тынәхмәд бинең углы Иштирәк*) һәм Исем *бине* Исем (*Кара би бине Балым бик*) моделенең әһәмияте тагын да зуррак булып, баланы нәсел белән бәйли торган, фамилия урынында йөргән берәмлек буларак кулланылган.

3. Фамилия (нәсел яки гаилә атамасы – *Лотфуллин, Госманов, Вәлитов, Мөхәммәтов* һ.б.) кешенең аерым бер нәселгә каравын күрсәтә торган исем, кеше исеме белән берлектә төп идентификацион категория санала. Татарларда хәзер кулланылышта йөри торган формада, шактый соң, рус антропонимиконы тәэсирендә формалаша, беренче фамилияләр XVI гасырның икенче яртысында рус писцовый кенәгәләрендә теркәлгән (Галиуллина, 2014: 198).

4. Кушамат – кешенең холкына, физик сыйфатына, яшәү барышында барлыкка килгән берәр үзенчәлегенә, ниндидер охшашлыкка нигезләнеп башкалар тарафыннан бирелгән өстәмә, рәсми булмаган исем (*Тиктормас, Зимагур, Күркә, Мыштым, Сыйрак, Саесканнар* һ.б.). Кушамат кеше тормышының төрле этабында бирелеп, чагыштырмача тар катлам кешеләргә генә билгеле булырга мөмкин.

5. Тәхәллүс (псевдоним) – кешенең чын исеме белән бергә куллана торган ясалма, уйлап табылган исеме. Татарларда псевдоним куллану иҗтимагый, мәдәни тормышта актив катнашкан кешеләргә хас, мәсәлән, *Сания Гыйффәт* (Сания Кадыйрова), *Ләбиб Лерон* (Леронов Лемон Леронович), *Луиза Янсуар* (Луиза Шарова) һ.б. Соңгы елларда массакүләм аралашу чаралары активлашкач, интернетта псевдоним (ник) куллану киң катлам кешеләрендә дә еш күзәтелә: *КоЯшКаЙ, Татар кызы, Дөбершатыр, Татар малай* һ.б.

6. Криптоним (яшерен исем, имза) – әдәби әсәрдә авторлыкны билгеләргә мөмкин булмасын өчен кулланыла торган исем. Мәсәлән, Г. Тукайның *Адвокат, Айнюк Самакай малае, Гъ., Дугъры, Җен* яшерен имзалары. Киң таралыш тапкан криптоним торабара псевдонимга әйләнергә мөмкин.

7. Әдәби әсәрләрдәге антропонимнар (әдәби антропонимика) – әдәби әсәрдә, фольклор, миф һ.б.ш.ларда кулланылган антропонимнар (*Акбикә, Әпипә, Гали Вәлиеч, Сафыч, Муза, Дилемма* һ.б.).

Хәзерге татар исемнәре системасында ике (*Галиев Мансур, Сәхипгәрәева Миләүшә*) һәм өч буынлы (*Шиһапов Айдар Илнурович,*

*Сафина Галия Искәндәровна*) антропонимик модель киң таралган һәм рәсми форма буларак кабул ителгән. Шулай ук Исем Ата исеме *улы* (*Алмаз Галимҗан улы*), Исем Ата исеме *кызы* (*Айгөл Фәнис кызы*) модельләре дә актив кулланыла.

Татар теленең антропонимиясе гаять катлаулы һәм төрле катламнардан торган системаны хасил итә. Гомумән, төрки телләрнең антропонимик системасы башка телләрнең антропонимиясеннән составы һәм генезисы ягыннан шактый аерыла. Бу, беренче чиратта, исемнәрнең килеп чыгышлары ягыннан төрле булулары һәм төзелеш-ясалыш чараларының күп булуы һәм универсальлегенә бәйле. Хәзерге татар теленең антропонимиконында төрки-татар, гарәби, фарсы, рус һәм Европа телләреннән кергән исемнәр кулланыла. Төрле чыганакларга караган мөстәкыйль берәмлекләр һәм антропоформантлар шактый иркен рәвештә кешеләр өчен яңа төр исемлекләр ясауда катнаша ала, мәсәлән, *гөл* компоненты белән генә дә хәзерге татар телендә төрле чыганакларга караган зур төркем хатын-кыз исемнәре бар: *Гөлчәчәк* (төрки-татар), *Гөлназ* (фарсы), *Гөлҗиһан* (фарсы), *Гөльяз* (фарсы + төрки-татар); *Гөлҗамал* (фарсы + гарәп), *Гөлшаһидә* (фарсы + гарәп) һ.б.

Татар антропонимиясенең даими тулыланып торуына ишарәли торган тагын бер үзенчәлек – телдә яңа исем ясау традициясе киң таралыш тапкан. Әйтик, рус антропонимик системасын билгеле бер дәрәҗәдә чикле дип атыйлар, чөнки төп исемлекне латин, грек телләреннән кергән традицион исемнәр хасил итә, яңа төр исемнәр ясалса да, бу процесс рус телендә пассив, ә татар телендә даими рәвештә төрле экстралингвистик сәбәпләр (мода, ата-ана теләге, даирә тәэсире һ.б.) аркасында исем ясау киң таралыш тапкан. Соңгы берничә дистә елда гына да татар телендә моңарчы кулланылмаган исемнәр барлыкка килде һәм популяр исемнәр рәтенә керделәр: *Ясминә, Ралина, Милана, Азалия, Сәгъдиана, Самира, Самир, Радмир, Эвелина, Рафина* һ.б. Аларның ясалышында төрле телләргә караган исем компонентларының янәшә килүе күзгә ташлана.

Антропонимик системаның берәмлекләреннән кеше исемнәре, аларга нисбәтле барлыкка килгән отчестволар, кушамат, псевдоним иң ачык һәм даими үзгәреп тора торган тармаклардан санала. Ә инде фамилия, әдәби антропонимнар ясалышында беркадәр тотрыклылык һәм чикләнгәнлек күзәтелә.

Антропонимик системаны өйрәнү нигездә ике юнәлештә бара. Беренче юнәлеш телнең милли антропонимиясен тасвирлауга йөз тотса, икенчесе исә аерым бер регион, төбәк антропонимиясен өйрәнүне алгы планга куя. Нигездә, милли антропонимика телдә норма буларак кабул ителгән вариантларга игътибарын юнәлтә.

Татар теленең милли антропонимиясен өйрәнү барышында исемнәр системасында күзәтелгән төп тенденцияләр, татар антропонимиясендә барлык төбәкләр өчен уртак саналган структурясалыш модельләре һәм кулланылыш үзенчәлекләре өйрәнелә. Бу яссылыкта татар теле һәм мәдәнияте үсеше тарихында күзәтелгән әһәмиятле чорларның антропонимик системага тәэсире бәян ителә. Әйтик, татар милли антропонимиясе үсешендә төрки-татар халкының үсешенә бәйле төп мәдәни һәм тарихи дәверләр тирән эз калдырган. Хәзерге татар антропонимиясе төрки-татар, көнчыгыш, рус һәм Европа мәдәниятләре һәм телләренең традицияләрен берләштергән катлаулы, әмма бербөтен система тәшкил итә. Бабаларыбыз ислам дине кабул иткәнчегә кадәрге чорда төрки җирлектә формалашкан исемнәр системасы, X гасырдан башлап ислам һәм көнчыгышның бай традициясенә таянып, меңнәрчә еллар үсеш-үзгәреш кичерә. XX гасырда рус теле, Европа телләренә һәм мәдәниятләренә хас тамга, билгеләр үтеп кереп, татар җирлегендә милли үзенчәлекләр белән керешеп, яңача реальләшү формаларын алды. Татар халкы исемнәр системасы өчен ят булган әлеге берәмлекләрне үзләштереп кенә калмады, бәлки исем бирүдә милли традицияләргә нигезләнеп, аларны татар антропонимиконына яраклаштырды (Галиуллина, 2008: 301).

Төбәк (региональ, диалекталь) антропонимикасы аерым бер төбәккә караган торак пунктларда, районнарда яшәүче халык телендә кулланылышта булган кеше исемнәре, кушаматлар һәм фамилияләр җыелмасын өйрәнә (Сәлимҗанова, 2009: 3). Төбәк антропонимиконы милли исемлекнең бер өлеше саналса да, аның үзенә генә хас билгеләре һәм үзенчәлекләре шактый. Беренчедән, региональ антропонимия милли үзенчәлекләрне берләштерә, биредә әдәби телдә һәм милли антропонимиконда кулланылмаган берәмлекләр урын ала һәм исемнәрнең вариантлары киңәя, икенчедән, аерым регионда сакланып калган диалекталь үзенчәлекләрне, борынгы тел формаларын, гореф-гадәт һәм традицияләрне, матди һәм рухи мәдәният ядкәрләрен барлау мөмкинлеге

туа. Бу, үз чиратында, татар теленең үсеш тенденцияләрен, башка телләр һәм мәдәниятләр өлкәсендә булган багланышларны теркәргә һәм системалаштырырга булыша. Диалекталь антропонимик материаллар шулай ук топонимнарның генезисын, этимологиясен төгәлрәк ачыклау өчен дә мөһим чыганак булып хезмәт итә (Сәлимҗанова, 2009: 4). Башка төрки, рус, фин-угор һ.б. телләр белән үзара багланышларны билгеләүдә дә бу төр материаллар кыйммәтлеләрдән санала.

Шулай итеп, ономастиканың антропонимика тармагы телдә үзенчәлекле билге, тамга вазифасын үти торган берәмлекләрне өйрәнә. Бу төр берәмлекләрнең яшәеше, тел үсеше һәм кулланылышына хас төп үзенчәлекләр белән бергә, экстралингвистик факторларга да бәйле була. Антропонимиянең төп берәмлекләре кешене атау өчен хезмәт итә һәм халыкның мәдәни, тарихи үзенчәлеген, характерын чагылдыра.

## ТАТАР КЕШЕ ИСЕМНӘРЕ

Кеше исеме – халыкның яшәеше, тормыш кыйбласы, милли мәдәнияте, тарихи үткәне турындагы мәгълүматларны үзенә туплаган мәдәният берәмлеге, шунлыктан халыкның үзаңын, психологиясен, характерын, менталитетын аңлауда алар зур урын алып тора. Кеше исеме шулай ук чорның мәдәни һәм иҗтимагый йөзен күрсәтә, җәмгыятьтәге үзгәрешләргә бәйле рәвештә кешеләрнең дөньяга карашын ачык чагылдыра.

Халыкның исемнәр системасы формалашу һәм билгеле бер юнәлештә үсеш кичерү үзеннән-үзе бармый. Аның нигезе гаиләдә салына, гаиләдә яңа туган балага сайланган исем, үз чиратында, бөтен исемнәр системасында теге яки бу исемнең популярлашуына, я булмаса югалуына китерергә мөмкин. «Исем – милләтнең көзгесе» дигән мәгълүм гыйбарәдән аңлашылганча, халыкның яшәеше, тормыш кыйбласы балаларга кушылган исемнәрдә ачык чагыла. Татар халкының тарихын күзаллаганда исемнәр куллану тарихына күз салу җитә. Төрки-татар халкы тормышында исламгача чор, ислам кабул итү, Казан ханлыгының яулап алыну чоры, Октябрь инкыйлабына кадәрге һәм аннан соңгы дәвер, бүгенге вазгыятебез балаларга кушылган исемнәрдә төгәл чагыла.

Кайсы гына территориядә яшәмәсен һәм нинди генә дин вәкиле булмасын – кешеләрнең исемне илаһилаштыруына, милли мәдәният белән бәйләнешенә карата бертөрле караш яши. Аның нигезе бүген генә барлыкка килмәгән, ул борынгы чорларда, кешелек җәмгыятенең балалык чорларыннан башлана. Исемне мәдәниятнең аерылгысыз өлеше итеп карау төркиләр өчен генә түгел, башка халыклар өчен дә хас. Һәр халыкның тарихында үзенчәлекле исемнәр катламы ачык күренә. Мәсәлән, борынгы славяннарда «добр», «свет», «свят», «мир», «слав» компонентлы исемнәр киң таралыш тапкан була, грекларда һәм римлыларда кешелеклелек сыйфатларына зур урын бирелә, гарәп һәм яһүдләрдә Аллаһы Тәгаләгә буйсынуны күрсәткән исемнәр күбрәк кулланыла, төркиләрдә һәм борынгы германнарда баланың көчле, сәламәт, матур булуын, мул тормышта яшәвен теләгән исемнәр киң таралыш таба.

Кеше исеме – аерым бер кешене башкалардан аера һәм индивидуальләштереп күрсәтә торган билге, атама. Алар, телнең лексик системасында төп урынны биләгән күмәклек сүзләр кебек үк, тел законнарына буйсынып барлыкка киләләр, әмма аермалы якларыннан берсе итеп аларның тәрҗемә ителмәве, үзләренең фонетик тышчасын мөмкин кадәр тулырак саклавы, фонетик һәм грамматик закончалыклар белән чикләнмәве, бер үк вакытта аерым телнең сүзлек составы кысасында һәм аннан читтә дә яши алуларын әйтергә кирәк.

Антропонимика тармаклары арасында кеше исемнәре аерым игътибарны таләп итәләр, алар иң киң таралган төр саналалар һәм ономастик кырның үзәгендә яшиләр. Исемнең мәдәният символы булуы, катлаулы табигате борынгы чорларда ук исемгә гаять зур игътибар җәлеп иттерә. Борынгы дини-мифологик ышанулардан алып, соңрак дәверләрдә күренекле философлар, галимнәр хезмәтләрендә дә исемнең асылын, табигатен аңларга тырышу киң таралган. Бүгенге көнгә кадәр галимнәр кеше исеменең серен ачарга омтылалар, аны лингвистик, психологик, фәлсәфи, тарихи, культурологик, физик яссылыкта өйрәнәләр. Тагын шуны билгеләп үтәргә кирәк: телнең антропонимик системасы дигән вакытта, беренче чиратта, аның кеше исемнәре системасы күзаллана, ә инде фамилия, ата исеме, кушамат һәм башка антропонимик берәмлекләр билгеле бер дәрәҗәдә икенче планга күчә. Шунлыктан бу бүлектә антропонимик система һәм кеше исемнәре системасы кебек терминнар билгеле бер дәрәҗәдә тәңгәлләштереп бирелә.

Тел белемендә кеше исемнәрен өйрәнүгә багышланган хезмәтләр шактый. Алдагы бүлектә аларның күбесенә күзәтү бирелде, шулай да ватан антропонимикасын төрле яклап өйрәнгән һәм хезмәтләре белән танылган В.Н. Никонов, Н.А. Баскаков, А.В. Суперанская, Н.В. Подольская, В.Д. Бондалетов, Г.Ф. Благова, Г.Ф. Саттаров, В.И. Супрун, Л.М. Щетинин, Т.Ж. Жанузаков, Ш. Жапаров, Э.А. Бегматов, В.У. Махпиров, А.Г. Шайхулов, Т.Х. Кусимова, О.Т. Молчанова, М.Э. Рут, Н.И. Шатинова, В.Я. Бутанаев, И.А. Андреева, З.Б. Чадамба, Э.Ф. Чиспияков, С.И. Вайнштейн, А.Г. Митрошкина кебек галимнәрне атау зарур.

Төрки телләрдәге кеше исемнәрен өйрәнүгә зур өлеш керткән галимнәрдән Г.Ф. Миллер, В.В. Радлов, В.В. Бартольд, Н.А. Аристов, В.К. Магницкий, Н.И. Золотницкий, Н.И. Березин, Каюм Насыйри, Н.И. Ашмарин, В.А. Гордлевский, А.Н. Самойлович, С.Е. Малов, Н.К. Дмитриев, В.А. Никонов, Г.Р. Алиев, С. Атаниязов, Н.А. Баскаков, Г.Ф. Благова, В.У. Махпиров, Э.Л. Бегматов, Т.М. Гарипов, А.Г. Гафуров, Г.Ф. Саттаров, Т.Ж. Жанузаков, Ж. Жапаров, С.К. Кенесбаев, Т.К. Кусимова, О.Т. Молчанова, З.Г. Ураксин, Г.Е. Корнилов, Н.И. Егоров, Ф.Г. Хисамитдинова, А.Г. Шайхулов, И.А. Андреева, Г.В. Косточаков, Г.И. Кульдеева һәм башкаларны аерып атау кирәк.

Югарыда аталган галимнәрнең хезмәтләрендә кеше исемнәре системасын һәрьяклап комплекслы өйрәнү нигезләре салынган. Бүгенге тел белемендә кеше исемнәрен өйрәнү юнәлешләре күптөрле, шулар арасыннан лингвистик, лингвокультурологик, этно-, социо-, психолингвистик юнәлешләрнең актив үсешен билгеләп үтәргә кирәк. Кеше исемнәрен өйрәнүдә зур мөмкинлекләр бирә торган антропонимик тикшеренүләр методикасы гуманитар фәннәрнең төрле өлкәләрендә отышлы һәм уңышлы кулланыла ала. Еш кына антропонимик мәгълүматлар теге яки бу проблеманы өйрәнгәндә бердәнбер чыганак ролен үтәргә яки фәнни әйләнешкә кергән мәгълүматларны тулылындырырга мөмкин.

Биредә без татар кеше исемнәрен ономастика фәнендә кабул ителгән юнәлештә, килеп чыгышлары, исем бирелү мотивлары, кеше исемнәре системасының төзелеш-ясалыш үзенчәлекләренә бәйле карыйбыз. Әлеге тармакның экстралингвистик факторлар белән бәйләнешен истә тотып, тарихи һәм мәдәни фактларга да тукталабыз.

## § 5. Татар кеше исемнәренең генетик катламнары

Татар теле, шул исәптән антропонимик системасы формалашу – дәвамлы процесс. Аның барлыкка килүендә төрки кабиләләр белән берлектә, башка кабилә һәм халыклар, аларның мәдәниятләре дә актив катнаша. Бу төр бәйләнышлар гасырлар дәвамында кеше исемнәре системасында берегеп калган. Шунлыктан кеше исемнәре системасын тарихи яссылыкта эволюцион процесс буларак өйрәнү татар тарихын, мәдәниятен, гореф-гадәт һәм традицияләрен, фикерләү үзенчәлеген тулы бер картина буларак күзалларга ярдәм итә.

Татар антропонимик системасы үзенең тарихи үсешендә зур һәм катлаулы юл кичергән. Төрле тарихи дәверләрдә лингвистик һәм мәдәни алынмаларның тәэсирен кичереп, катлаулы структура булып формалашып, әкренләп кешене социаль идентификацияли торган бүгенге формасын алган. Кеше исемнәре системасындагы иң әһәмиятле үзгәрешләр һәм яңа формалар, телнең эчке үсешенә бәйле булудан бигрәк, тышкы факторлар тәэсирендә барлыкка килгән. Шул сәбәпле, татар теле һәм җәмгыяте үсешендәге аерым этапларга бәйле рәвештә кеше исемнәренең генетик катламнары да барлыкка килә, үзара керешә, яңа формалар ала.

Антропонимика фәнендә кеше исемнәрен генетик яктан төркемләүдә төрле принциплар кулланыла, шулар арасында киң таралыш тапканы – катламнарга аерып төркемләү. Телдә кулланылган барлык исемнәр төп ике катламга: телнең үз сүзләре нигезендә ясалган антропонимнар һәм алынма антропонимнарга аерыла.

Г.Ф. Саттаров әлеге бүленешне тагын да конкретлаштырып, татар антропонимиясенә мөнәсәбәтле түбәндәге лингвогенетик катламнар күрсәтә:

1) гомумалтай кеше исемнәре;
2) борынгы төрки катлам;
3) иске төрки-татар кеше исемнәре;
4) гарәби чыгышлы кеше исемнәре;
5) фарсы теленнән кергән исемнәр;
6) рус һәм аның аркылы Европа телләреннән кергән исемнәр;
7) яңа татар кеше исемнәре (Саттаров, 1990).

Хәзерге татар телендә кулланылган исемнәрне генетик яктан ачык күзаллау өчен түбәндәге катламнарга аерырга кирәк:

1. Төрки-татар чыгышлы кеше исемнәре катламы.
2. Башка телләрдән алынган кеше исемнәре катламы:
   а) гарәби чыгышлы исемнәр;
   ә) фарсы теленнән кергән исемнәр;
   б) рус теленнән кергән исемнәр;
   в) Европа телләреннән кергән исемнәр;
3. Катнаш төзелешле исемнәр.
4. Яңа татар исемнәре.

Әлеге төркемләүне тагын да конкретлаштырырга мөмкин. Мәсәлән, төрки чыгышлы исемнәр составында Г.Ф. Саттаров күрсәткән гомумалтай төркемен, алынмалар рәтендә борынгы алынмалардан кытай, монгол һ.б. телләрдән алынган исемнәрне дә билгеләргә кирәк, әмма аларның составы зур булмаганлыктан һәм борынгы чорларда ук төрки телдә кулланганлыктан, аларны зур төркемнәр составында күрсәтеп үтәбез.

Төрки-татар чыгышлы кеше исемнәре катламы генетик яктан гомумалтай һәм борынгы төрки исемнәргә барып тоташа. Бу төр исемнәр хәзерге төрки, монгол һәм тунгус-маньчжур телләрендә кулланыла. Г.Ф. Саттаров билгеләгәнчә, алар борынгы лексик берәмлекләр нигезендә барлыкка килгәннәр: татар телендә – *алтын,* башка төрки телләрдә – *altun* «алтын», тунгус-маньчжур телләрендә – *алтан,* монг. – *алтан,* бурят. – *алта(н)* «алтын». Чагыштыр: татар телендә: *Алтын, Алтынбай, Алтынчәч;* бурятларда *Алтан, Алтан Хайша, Шагай*; *Altun gayan, Altun qara, Altun taj sanun, Altun tamgan* – борынгы төрки кеше исемнәре. Татар телендә – *бай,* монолларда – *баян,* бурят. – *баян* «бай», тунгус-маньчжур телләрендә – *bajan* «бай», борынгы төрки телдә – *buj* «бай». Чагыштыр: *Байбулат, Байтимер, Байбуга* – татар телендә, *Баян, Баяндай* – бурят кеше исемнәре, *Buj buga* – борынгы төрки кеше исеме; татар телендә – *арслан,* монг. – *арслан(г),* бурят. – *арсалан,* маньчжур. – *арсалан,* борынгы төрки телдә – *arslan* «арслан». Чагыштыр: *Арслан, Арсланбану* – татар, *Арсалан, Арсаланжаб* – бурят кеше исемнәре, *Arslan balban, Arslan tegin* – борынгы төрки кеше исемнәре. Татар телендә – *Чулпан*, монг. – *Цолман*, бурят. – *Солбан(г),* эвенк. – *Чолбан* «Венера» (планета). Чагыштыр: *Чулпан* – татар кеше исеме, *Шолпан, Шолпанбай, Шолпанкул* – казак кеше исемнәре (Саттаров, 1990: 119).

Төрки-татар чыгышлы исемнәр татар антропонимиконының үзәген тәшкил итә һәм күп кенә төрки халыклар өчен уртак фонд булып тора. Татар җирлегендә алар ислам динен кабул иткәнче кулланыла, аннан соңгы этапларда акрынлап кулланылыштан төшеп калалар. XIX гасыр татар анропонимик системасында бу төр исемнәр юк дәрәҗәсендә.

Октябрь инкыйлабыннан соң аларның бер төркеме яңадан кулланылышка кайтып, хәзерге татар исемнәр системасында йөриләр, мисал өчен бүгенге көндә иң актив төрки-татар чыгышлы исемнәрдән *Арыслан, Чәчкә, Чулпан, Йолдыз, Алмас, Энҗе, Тимерхан, Алтынай* исемнәрен, *ил* компоненты кушылып ясалган *Илүсә, Илгиз, Илтөзәр, Илгиз, Илгиз, Илбарис, Илгенә* кебек ир-ат һәм хатын-кыз исемнәрен атарга кирәк. Соңгылары яңа татар исемнәре катламы буларак карала, чөнки алар XX гасырда татар теле җирлегендә барлыкка килеп, хәзерге татар антрпопонимиконының состав өлешен хасил итәләр.

Хәзерге татар антропонимиконында төрки-татар чыгышлы кеше исемнәре күп түгел, алар, башлыча, борынгы төркиләрнең мифологик ышануларын, табигатькә табынуларын чагылдыралар. Без алдагы бүлекчәдә борынгы төрки бабаларның исем кушу үзенчәлекләрен тулырак бирербез, биредә төрки-татар чыгышлы исемнәрнең төп билгеләренә тукталып үтәбез.

Хәзерге татар телендә кулланылган төрки чыгышлы исемнәрнең төп үзенчәлекләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт: беренчедән, аларның семантикасы ачык, аларга салынган мәгънәне бик җиңел аңлап була. Икенче төрле әйткәндә, исем нигезендәге мәгънә, исемнең бирелү үзенчәлеге төрки телдә сөйләшүчеләргә җиңел аңлаешлы. Мәсәлән: *Аяз, Буран, Чулпан, Айтуган*, *Айтулды, Бикә, Чәчәк, Алтын, Туйкилде, Биктимер, Таңсылу, Айтуган* һ.б.

Икенчедән, төрки чыгышлы исемнәр структурасы шулай ук үзенчәлекле, аларның зур күпчелеге ике, өч иҗекле структураны хасил итә. Мәсәлән: *Арыслан, Нугай, Бикә, Алтын, Алтынай, Аяз, Айсылу, Айбикә* һ.б. Төрки-татар чыгышлы исемнәр борынгыдан килгән традицияләрне дәвам итә, аларның төзелеше аз компонентлы, җиңел әйтелешле булулары белән аерылып тора.

Бу төр исемнәрдә денотат – исем бәйләнеше ачык чагыла, ягъни исем нигезендә яткан объект, предмет, күренеш ачык аңлашыла. Әмма бу үзенчәлек төрки исемнәрнең башлангыч чорында

гына күзәтелә, алга таба исемнәр эчтәлегендә күчерелмә мәгънәлелек алга чыга. Бу үзенчәлек аеруча төсләр нигезендә ясалган исемнәрдә ачык күренә. Мәсәлән: *Карабай, Акбаш, Алтынай, Алтынчәч, Караби/Карабәк* һ.б.

Күзәтүләрдән күренгәнчә, исламгача чорда кулланылган бу төр исемнәрдә «денотатив мәгънә – ассоциатив мәгънә – семиотик мәгънә / тамга, билге» бәйләнеше ачык формалашып җитә.

Хәзерге татар телендә иң киң таралган төрки-татар чыгышлы исем һәм исем компонентларын атап үтәбез:

– күк җисемнәре атамалары нигезендә ясалган кеше исемнәре: *Йолдыз, Чулпан*, *Күктимер, Айтуган, Айбулат, Айбикә, Айсылу, Айтуган, Айтулды, Айгөн/Айкөн* һ.б.

– хайван, кош-корт атамаларыннан ясалган кеше исемнәре: *Арыслан, Илбарис, Бүрехан*, *Бөркет* һ.б.

– *таш, алтын, көмеш, булат, тимер, бакыр* кебек металл, минерал атамалары нигезендә ясалган төрки чыыгышлы исемнәр: *Тимер, Тимербулат, Тимур, Тимерхан, Миңтимер, Байтимер, Таштимер, Биктимер, Тимербай, Тимеркәй, Бикташ, Ташмөхәммәт, Булат, Корыч, Алтынай, Көмешсылу* һ.б.

– апеллятив лексика нигезендә ясалган хатын-кыз исемнәре: *Сылу, Миңсылу, Иркә , Чәчәк, Алмас, Тукай*, *Юлдаш* һ.б.

Шулай итеп, төрки-татар чыгышлы кеше исемнәре хәзерге татар телендә актив кулланылышта булмасалар да, аларда төрки халыкларның үткәне турында бай мәгълүмат саклана.

Башка телләрдән алынган кеше исемнәре катламы. Ялгызлык исемнәрен күмәклек сүзләрдән аера торган үзенчәлекләрнең иң әһәмиятлесе булып бу өлкәдә алынмаларның күпләп кулланылуы тора. Лексик системаның бер генә өлкәсендә дә ономастик, аеруча кеше исемнәре өлкәсендәге кебек алынмалар иркен һәм җиңел кулланылмый. Бу – барлык телләргә хас универсаль күренеш. В.А. Никонов күрсәткәнчә, французларда француз теле нигезендә ясалган исемнәр юк дәрәҗәсендә, барлык исемнәр дә Римнан католик дине белән килеп кергән, русларда да рус теленнән кергән исемнәр бик аз күләмдә, чөнки чиркәү борынгы рус исемнәрен тыйган, аларга алмашка Византиядән кергән латин һәм грек чыгышлы исемнәр кулланылган. Галим шулай ук төрки халыкларда да төрки исемнәр түгел, гарәп һәм фарсы чыгышлы исемнәр өстенлек алуын ассызыклый. Ул шулай ук бер генә төр-

кем сүзләр дә (кеше исемнәреннән кала), чит телләрдән кергән сүзләргә бай түгел, бәлки бу өлкәдә антропонимнар белән бары тик фәнни-техник терминология генә ярыша ала, дип билгели (Никонов, 1974: 6). Чыннан да кеше исемнәре системасында, телнең үз сүзләреннән бигрәк, алынмалар өстенлек итә, шуның өстенә, алар чит телнең матди тышчасын, мәгънәсен, килеп чыгышын саклый һәм күпаспектлы булуы белән характерлана. Күзәтүләрдән күренгәчә, еш кына алынма исемнәр телдә төгәл формалашкан вариантны тапканчы, вакытлы фонетик һәм орфографик тышчада да кулланылалар, шуның өстенә күптөрле морфологик таркалулар, ассоциацияләр һәм башка төрле үзгәрешләр күзәтелергә мөмкин. Телебезгә килеп кергән алынмаларның башлангыч этапларда вакытлы график формалар да очратырга мөмкин.

Алынма исемнәр, вакытлар үтү белән телнең милли антропонимиконында тиешле урыннарын тапсалар да, халыкара, төрле телләр берәмлеге булу сәләтен югалтмыйлар.

Югарыда әйтелгәнчә, татар кеше исемнәре системасында кулланыла торган исемнәрне генетик яктан гарәби һәм фарсы чыгышлы, рус теленнән кергән исемнәр һәм Европа телләреннән кергән исемнәр төркемнәренә бүләбез.

Гарәби һәм фарсы чыгышлы исемнәр. Бу төр исемнәр татар антропонимиконының нигезен тәшкил итәләр. Аларның телебезгә һәм мәдәниятебезгә үтеп керүе берничә төп этапны берләштерә.

Башлангыч чорда мөселман исемнәре, нигездә, югары даирә кешеләре арасында гына кулланыла. Мәсәлән, ислам дине кабул ителгәннән соң, болгар ханы Алмыш *Җафар бине Габдулла* дигән исем ала. Соңрак тәхет варислары үзләренә мөселман исемнәре алалар һәм әмир титулына ия булалар: *әмир Әхмәд, әмир Талиб, әмир Мөэмин, әмир Шәмгун* һ.б. X–XI гасырга караган язма чыганаклардан күренгәнчә, бу төр исемнәр бик чикле кулланылышта булалар.

XI гасыр язма истәлеге булган М. Кашгариның «Диване лөгатет-төрк» хезмәтен тирәнтен өйрәнгән В.У. Махпиров фикеренчә, сүзлектә бирелгән кеше исемнәренең 70%ын гомумтөрки чыгышлы исемнәр тәшкил итә (Махпиров, 1990: 11).

XIII–XIV гасыр Алтын Урда чорына караган документлар, эпитафик язмалар һәм башка чыганакларда гарәби һәм фарсы чыгышлы исемнәрнең активлашуы күренә. Аларның күбесе дини

эчтәлекле, Мөхәммәт пәйгамбәр һәм аның якыннарына багышлап куелган исемнәр санала.

Алтын Урда таркалганнан соң, төрки-татар антропонимиясе ике юнәлештә үсә: бер яктан, төрки традицияләрне саклаган исемнәр кулланылышта йөри, икенче яктан, алынмаларның кулланылышы активлаша. XV–XVI гасырларда бу төр исемнәрнең активлашуына мөселман Көнчыгышы белән сәяси, мәдәни бәйләнешләрнең көчәюе дә тәэсир итә. Әлеге чорга хас үзенчәлек – эчтәлегендә турыдан-туры дини мотивлар чагылмаган исемнәр тарала башлый. Мәсәлән: *Дәүләт (байлык, бәхет), Хәлил (тугры дус), Гөлбостан (гөлләр бакчасы), Зөһрә, Нур Солтан* һ.б.

Казан ханлыгы яулап алынгач, антропонимнар көчләп чукындыруга каршы бер чара буларак хезмәт итә башлыйлар, бу чорда ислам белән бәйләнешле исемнәр киң катламга ныклап таралу кичерә һәм бу процесс үзенең иң югары ноктасына XIX гасыр ахыры XX гасыр башында ирешә. XIX гасырда исем кушуда тагын бер яңа традициягә нигез салына. Ул – катлаулы төзелешле *Мөхәммәтрәхим, Габделгаффар, Габделрәшит, Сөйфелмөлек, Вәлибикмөхәммәт, Бибинәгыймә, Бибитәскирә, Маһисорур, Зәйнәпфатыйма, Миңлегөлҗиһан* кебек исемнәр кулланудан гыйбарәт. М.И. Әхмәтҗанов билгеләгәнчә, «XX гасыр башына татар исемнәренең 98%ы гарәп-фарсы чыгышлы материалдан тора» (Әхмәтҗанов, 1995: 9).

Октябрь инкыйлабыннан соң мөселман исемнәренең кулланылышында кискен борылыш барлыкка килә. Атеизм идеологиясе нәтиҗәсендә дин искелек калдыгы буларак кабул ителә башлый, шуңа бәйле ислам белән бәйле һәр нәрсәгә табу салына, ислам татар тормышында тоткан урынын югалта. Мондый сәясәт нәтиҗәсендә татарлар арасында ислам динен чагылдырган исемнәрнең кулланылышы кискен кимүе, соңрак бөтенләй төшеп калуы күзәтелә. Әмма гасырлар буена ислам һәм көнчыгыш традицияләре кысаларында тәрбияләнгән халкыбыз бу исемнәрдән бөтенләй ваз кичмичә, аларның яшәешен дөньяви эчтәлекле, этик һәм эстетик зәвыклы *Дилшат, Фәрхат, Мәрдан, Раушан, Фирдәвес, Гәүһәр, Гөлназ, Гөлшат, Диләрә, Дилбәр, Маһия, Миләүшә, Нәркис* һ.б. исемнәрдә дәвам итә. XX гасырның 30 нчы елларыннан милли исемлегебездә гарәби һәм фарсы чыгышлы яңа исемнәр пәйда була. Мәсәлән: Казан шәһәрендә 1940–

1950 еллар аралыгында *Рөстәм, Равил, Наил, Рәшит, Шамил, Наилә, Сания, Фәридә, Фирая, Гөлфия, Рәшидә, Рәйсә* исемнәре иң актив кулланылган антропонимнар рәтендә йөрделәр.

Мөселман дине белән бәйле исемнәрнең кулланылышында яңа бер чор XX гасыр ахырына туры килә. Белгәнебезчә, бу чор диннең яшәешебезгә яңадан әйләнеп кайту чоры буларак характерлана. Фактик материаллар күрсәткәнчә, татар исемлегенә *Габдулла, Ибраһим, Кәрим, Әмир, Мөхәммәт, Рамазан, Гомәр, Ислам, Әхмәт, Кәримә, Әминә, Хәдичә, Фатыйма* һ.б. исемнәр әйләнеп кайтты.

Ислам дине кабул ителгән чордан алып, хәзерге чорга кадәр алар телебезгә үтеп керү, урыннарын табу процессларында татар җирлегендә төрле үзгәртүләргә, яңарышка дучар ителделәр. Алар белән бергә, татар исемнәр системасын тамырдан үзгәрткән яңалыклар да килеп керде. Аерым алганда, борынгы төрки исемнәрдә кешенең табигать белән бергәлеге ачык күренеп торса, мөселман исемнәре, башлыча, ислам символы буларак кулланыла башлыйлар. Аларда исем асылына салынган символик мәгънә алгы планга чыга башлый. Бу төр исемнәр, гарәп яки фарсы теленең кайсына каравына бәйсез рәвештә, кешенең мөселман диненнән булуын күрсәткән символ дәрәҗәсендә кабул ителәләр.

Рус һәм Европа телләреннән кергән исемнәр. Татар теленә рус һәм Европа телләреннән сүзләр үтеп керү процессы – шулай ук дәвамлы күренеш, гасырлар дәвамында славян кабиләләре белән сүз алмашу нәтиҗәсендә ике якта да зур катлам алынма лексика формалаша. Рус теле аша Европа телләреннән сүзләр алыну процессын галимнәр XVI гасырдан башлап, ә активлашу процессын XVII–XVIII гасырга бәйләп аңлаталар (Хайруллин, 2000: 132–133). Антропонимик системага исә бу төр лексика бары тик XX гасырның икенче дистәсендә Октябрь инкыйлабыннан соң гына килеп керә башлады. Кыска вакыт аралыгында кулланыуга карамастан, татар исемнәр системасында алар үз урыннарын таптылар һәм татар антропонимиясе үсешенең төп тенденцияләрен билгеләүдә роль уйный башладылар.

Рус һәм Европа телләреннән исемнәр алынуны өч периодка бүлеп карау дөрес булыр, чөнки яңа төр исемнәрнең телебезгә, рухи дөньябызга килеп керүе һәм кулланылуы бертөрле түгел. Татар исемлеген өйрәнү нәтиҗәсендә түбәндәге чорларны аеруны кулай күрәбез:

1) Беренче период 1923–1949 елларны үз эченә ала. Бу чор әлеге төр алынмаларның татар исемлегендә бик сирәк күренеш булуы, яңа төр исемнәрне кабул итүдә төрлелек, һәр матур яңгыраган сүзне исем итеп балаларга кушу күренеше белән характерлана, мисал өчен, *Медуза, Диззимуна, Кримгильда, Интерна, Искра, Тэмп, Социал, Иниза, Авангард* кебек исемнәрне китерергә була. Бу чорда популяр булган ир-ат исемнәреннән *Альфред, Агат, Рафаэль, Бабеф, Эдуард, Маркс, Рэн,* хатын-кыз исемнәреннән *Луиза, Роза, Флера, Розалия, Майя* исемнәрен атау кирәк.

2) 1950–1985 елларны эченә алган икенче чор алынма исемнәрнең күпләп кулланылуы белән характерлана. Аларның зур күпчелеген танылган шәхесләрнең, әдәби әсәр геройларының исемнәре, географик объект атамалары, үсемлек дөньясына караган атамалар һәм асылташ атамалары алып тора. Әлеге чорда традицион рус исемлегеннән кергән исемнәр балаларга бик аз кушыла, ә инде Европа телләреннән кергән исемнәр төркемендә тотрыклылык чагыла. Балага исем сайлаган вакытта яңгырашы матур исемнәргә аеруча зур игътибар бирелә башлый, әмма исемнең мәгънәсенә битарафлык шактый сизелә. Бу чорда татар исемнәр хәзинәсенең нигезендә яткан традицияләр буенча исем алу тенденциясе ачык күренә (мәсәлән, үсемлек дөньясын чагылдырган исемнәр, асылташ атамаларына нигезләнеп ясалган исемнәр). Шунысын да искәртү кирәк: бу чорда татар исемлегендә кайбер яңа төр алынма исемнәрнең ныклап берегүе күзгә ташлана. Мәсәлән: *Альберт, Рафаэль, Ренат, Марат, Эдуард, Роза, Эльмира, Альбина, Венера, Луиза, Лилия* һ.б.

3) Өченче периодка 1985 елдан бүгенге көнгә кадәрге чор керә. Аның үзенчәлекле ягы булып милли исемнәр белән аваздаш антропонимнарның популярлашуы тора. XX гасырның 80 нче еллар урталарында җәмгыятебездә барлыкка килгән үзгәрешләр рус һәм Европа телләреннән исемнәр кабул иткәндә дә үзен сиздерә. Милли телебезгә игътибар арту, шул ук вакытта дөнья мәдәниятенә омтылу татарлар арасында исем сайлауда да яңа мөмкинчелекләр ачты. Халкыбыз заманчалыкка омтылу белән бергә, яңгырашы ягыннан татар исемнәренә якын булган берәмлекләрне сайларга тырышты. XXI гасырның беренче дистәсендә татарлар арасында иң популяр алынмалардан *Алина, Диана, Аделина, Артур, Камилла, Тимур, Руслан, Карина, Эмиль, Азалия, Регина, Элина, Рената,*

*Камила, Данил, Марат, Марсель, Эвелина, Лилия, Дамир, Лиана, Альберт, Альбина, Эльвина* исемнәрен атарга кирәк. Өченче чорда кулланылышта йөргән рус һәм Көнбатыш Европа телләреннән кергән исемнәрне сайлауда тотрыклылык урнашты. Шулай ук яшь гаиләләрдә заманча исемнәрне кушу тенденциясе көчәюен билгеләп үтәргә кирәк.

Катнаш төзелешле кеше исемнәре катламы дигәндә, компонентлары төрки-татар һәм алынма катламнарга караган кушма кеше исемнәрен күз алдында тотабыз.

Татар антропонимиконында мондый төр исемнәр шактый таралыш тапкан. Аларның телебездә кулланылу тарихы да шактый вакыт аралыгын үз эченә ала. Беренчеләрдән булып диярлек, бу төр исемнәр ислам динен кабул итү нәтиҗәсендә төрки телгә үтеп кергән алынмалар кулланып, яңа төр катнаш исемнәр ясау очракларында күзгә ташлана. Мондый төр катнаш төзелешле исемнәрнең XVIII гасыр ахырына кадәр төрки-татарлар арасында йөрүе билгеле. Мисал өчен, *Юныс әл Болгари, Ибраһим әс Сувари, Исламкол, Акмөхәммәт, Колмөхәммәт, Дәүләткилде, Җанбакты* һ.б. (Галиуллина, 2011: 49; 2015: 70) исемнәрне әйтергә була. Бу төр исемнәрне М.И. Әхмәтҗанов ярымтөрки, ярыммөселман исемнәре дип тә атый (Әхмәтҗанов, 1991: 102).

Соңрак катнаш төзелешле исемнәр составы төрле телләрдән кергән компонентларның кушылуы нәтиҗәсендә дә баеды. Мәсәлән: *Фазылъяр, Моратхуҗа, Вилнур, Айназ, Гөлшат, Гөлнәзирә, Дилфизә* һ.б.

Хәзерге татар исемнәр системасында катнаш төзелешле исемнәрнең киң таралыш тапкан модельләре түбәндәгеләр:

1. Төрки-татар (т-т.) компоненты + гарәби чыгышлы (гар.) компонент: *Илнур* (ир-ат исеме) *ил* (т-т.)+ *нур* (гар.); *Илсаф* (ир-ат исеме) *ил* (т-т.) + *саф* (гар.); *Илфәния* (хатын-кыз исеме) *ил* + *фән* (гар.) + *ия; Илфизә* (хатын-кыз исеме) *ил* (т-т.) + *физә* (гар.); *Айнур* (ир-ат исеме) *ай* (т-т.) + *нур* (гар.); *Айзилә* (хатын-кыз исеме) *ай* (т-т.) + *зилә* (гар.).

2. Гарәби чыгышлы компонент + төрки-татар компоненты: *Әмирхан* (ир-ат исеме) *әмир* (гар.) + *хан* (т-т.); *Әбухан* (ир-ат исеме) *әбу* (гар.) + *хан* (т-т.); *Шәмсебикә* (хатын-кыз исеме) *шәмс* (гар.) + *бикә* (т-т.); *Нурбәк* (ир-ат исеме) *нур* (гар.) + *бәк* (т-т.); *Нурсөя* (хатын-кыз исеме) *нур* (гар.) + *сөя* (т-т.), *Фәнсөя* (хатын-кыз исеме)

*фән* (гар.) + *сөя* (т-т.); *Фәнүсә* (хатын-кыз исеме) *фән* (гар.) + *үсә* (т-т.) һ.б.;

3. Төрки-татар компоненты + фарсы (фар.) чыгышлы компонент: *Илфат* (ир-ат исеме) *ил* (т-т.) + *фат* (фар.); *Илназ* (ир-ат исеме) *ил* (т-т.) + *наз* (фар.); *Айгөл* (хатын-кыз исеме) *ай* (т-т.) + *гөл* (фар.); *Айзифа* (хатын-кыз исеме) *ай* (т-т.) + *зифа* (фар.); *Айзирәк* (хатын-кыз исеме) *ай* (т-т.) + *зирәк* (фар.); *Айшат* (ир-ат исеме) *ай* (т-т.) + *шат* (фар.), *Миңлегөл* (хатын-кыз исеме) *миң(-ле)* (т-т.) + *гөл* (фар.); *Миңлезирәк* (хатын-кыз исеме) *миң(-ле)* (т-т.) + *зирәк* (фар.)

4. Фарсы чыгышлы компонент + төрки-татар компоненты: *Гөлүсә* (хатын-кыз исеме) *гөл* (фар.) + *үсә* (т-т.); *Гөлбикә* (хатын-кыз исеме) *гөл* (фар.) + *бикә* (т-т.); *Гөлбүләк* (хатын-кыз исеме) *гөл* (фар.) + *бүләк* (т-т.); *Гөлйөзем* (хатын-кыз исеме) *гөл* (фар.) + *йөзем* (т-т.); *Җиһанбикә* (хатын-кыз исеме) *җиһан* (фар.) + *бикә* (т-т.); *Җиһансылу* (хатын-кыз исеме) *җиһан* (фар.) + *сылу* (т-т.) һ.б.

5. Гарәби чыгышлы компонент + фарсы компоненты: *Габдуллаҗан, Шәрифҗан, Муллаяр, Гыйлемдар, Галиябану, Фәндүсә, Фаягөл, Нурсинә, Нуршат* һ.б.

6. Фарсы компоненты + гарәби чыгышлы компонент: *Шаһимансур, Гөлзаман, Бибинур, Гөлфинур, Бибифәридә, Гөлшаһидә* һ.б.

Генетик яктан төрле телләргә караган әлеге антропонимик берәмлекләр татар кеше исемнәре составын баетуда шактый зур роль уйныйлар.

Яңа татар исемнәре катламы дип Октябрь инкыйлабыннан соң барлыкка килгән һәм үзенең составында төрки-татар, алынма чыгышлы исемнәрне берләштергән катламны атыйбыз. XX гасырның икенче дистәсеннән башлап, татар исемнәре үсешендә иҗтимагый яшәеш, шул чорга хас үзенчәлекәр белән бергә, кеше яшәгән милли даирә тәэсиренең тыгыз керешүе күзәтелә. Дөньяга яңача караш, рухи тормышка яңа кыйммәтләр үтеп керү татар исемнәр хәзинәсенә татар теле җирлегендә барлыкка килгән, татар халкының рухи һәм матди дөньясын чагылдырган яңа татар исемнәренең кулланылышка керүенә юл ачты. Халкыбыз, башка телләрдән исемнәр алу белән генә чикләнмичә, татар теленең үз җирлегендә яңа исемнәр уйлап табуга да йөз тотты. Бер яктан, милли традицияләр, икенче яктан иҗтимагый даирә төрле телләрнең лексик, фонетик һәм морфологик чаралары ярдәмендә яңа исемнәр уйлап табуга этәрде. Шуның нәтиҗәсендә татар телендә

үзенең составы, төзелеше ягыннан татар халкы өчен яңа булган исемнәр катламы барлыкка килде.

Башлангыч чорда яңа татар катламы телебездә традицион кулланылып килгән исем компонентлары, күмәклек сүзләр ярдәмендә ясалды. Мисал өчен, уңай эчтәлекле *Ирек, Үлмәс, Нәфис, Алмас, Гүзәл, Кояш, Алма, Бүләк, Асыл* исемнәре, аерым чорда популяр булган әдәби әсәр геройлары исемнәре *Кадрия, Илсөяр, Резедә, Газинур, Сәйдәш, Ләйлә, Җәлил* шундыйлардан.

Яңа татар катламы төрки чорда актив кулланылып та, ислам тәэсирендә төшеп калган *ил, ай, таң, бәк* компонентлары ярдәмендә ясалган *Илсаф, Илнар, Илназ, Илүсә, Айгөл, Таңсу, Таңнур, Таңсылу, Нурбәк, Илбәк* һ.б. шундый исемнәр исәбенә дә, *гөл, наз, фән (Гөлназ, Гөлнара, Гөлгенә, Гөлсара, Назил, Назгөл, Сафназ, Фәнил, Фәнир, Фәнисә)* компонентларының кушма исемнәр составында активлашуы нәтиҗәсендә дә байый.

Яңа татар катламының тагын бер үзенчәлеге – җыйнак, берничә иҗектән генә торган кушма исемнәр кулланылу. Мәсәлән: *Айгизә, Айгөл, Айзат, Илгиз, Илсөя, Илсөяр, Нурбәк, Гөлшат, Гөлсаф, Гөлнара, Гөлфия, Айназ, Илназ, Фәнсөяр, Фәндүс, Фәнүсә, Фәнүс* һ.б.

Югарыда әйтеп үткәнчә, яңа татар катламын хасил иткән исемнәр төрле чыганакларга карыйлар һәм төзелешләре ягыннан җыйнак, әйтергә җиңел исемнәрдән торалар. Бүгенге көн исемнәр системасында әлеге тенденция ныклап урнашты һәм татар исемлегенең нигезен компактлы исемнәр хасил итә. Авыр әйтелешле исемнәргә алмашка килгән яңа татар исемнәре үзләренең оригиналь булулары, җыйнаклыклары белән бик тиз таралыш таптылар. Моңарчы балаларга кушылмаган гарәби һәм фарсы чыгышлы уңай мәгънәгә ия булган, халкыбызның зәвыгын, дөньяга карашын чагылдырган *Динар, Зөлфәт, Рамил, Рәис, Рәүф, Өлфәт, Зөлфия, Дилә, Ләйсән, Ләйлә, Миләүшә, Наилә, Назия, Рәзинә, Рамилә, Рәзилә, Рәмзия, Сөмбел* һәм башка шундый исемнәр дә яңа татар исемнәре катламының состав өлешен хасил итә.

Әлеге катлам хәзерге татар антропонимиконында төп урынны алып тора, аның составы апеллятив лексика рәтендә йөргән уңай семантикалы сүзләр: *Күңел, Хәят, Ихтыяр, Асыл, Ханым, Максат, Бүләк*; топоним и этнонимнар: *Идел, Иделә, Иделия, Сармат*; атаклы әдипләр, әдәби герой исемнәре, татар халкы арасында

танылган шәхесләрнең *(Сөембикә, Йосыф, Фәрхад, Сәйдәш, Салават, Илһам, Зәйнәп, Әлфия)* исемнәре хисабына да байый.

Шулай итеп, татар теленең кеше исемнәре системасы генетик яктан шактый төрле. Милли исемлегебезнең үсешен, хәзерге торышын күрсәткән бу берәмлекләр татар рухи мәдәниятенең аерылгысыз өлешен хасил итә.

### § 6. Татар халкында исем бирү мотивлары

Татар исемнәренең бирелү мотивлары гасырлар дәвамында формалашып килгән. Бу мәсьәлә соңгы елларда басылып чыккан хезмәтләрдә аерым игътибар үзәгенә алынган. Татар телендә Г.Ф. Саттаров, беренчеләрдән булып, исем бирү мотивларын төгәл, тулаем төркемләп бирде. Галим үзенең «Татар антропонимикасы» (1990) хезмәтендә исемгә булган игътибар, кызыксыну асылын ачыклап, исем кушуда гасырлар дәвамында формалашкан һәм камилләшкән мотивларны тәфсилләп язды.

Галим билгеләвенчә, кешелек җәмгыяте һәм тел эволюциясе кеше исемнәре өлкәсендә ике тарихи-лингвистик катлам тудырган: 1) җанлы һәм җансыз табигатьнең конкрет предметлары һәм күренешләрнең атамалары белән мөнәсәбәтле кеше исемнәре. Бу төр исемнәр кешелек җәмгыятенең түбән баскычында ук барлыкка килгәннәр. Алар, башлыча, тамыр сүзләрдән гыйбарәт булганнар һәм тора-бара күбесе кушма төзелешле кеше исемнәрен ясауда актив катнаша торган компонентларга әверелгәннәр; 2) абстракт төшенчәләрне белдерүче сүзләргә нигезләнеп ясалган кеше исемнәре. Бу төр исемнәр кешелек җәмгыятенең дөньяны танып-белүе, аң үсеше алга китү, камилләшү белән бәйләнешле рәвештә барлыкка килгәннәр. Кеше исемнәрендә халык тормышының төрле ягы: җәмгыять төзелеше, хуҗалык итү ысулы, сыйнфый һәм туганлык-кардәшлек мөнәсәбәтләре, дөньяга карашы, мифологиясе, дини ышанулары, гореф-гадәтләре, аң-белем һәм әхлакый-эстетик зәвык дәрәҗәсе чагыла (Саттаров, 1998: 13). Кеше исемнәре барлыкка килүдәге әлеге ике төр тарихи-лингвистик нигез һәм алар белән бәйләнешле күренешләр, йола-гадәтләр, мотив-традицияләр дөньядагы барлык халыкларга да хас.

Тюрколог-ономатологлар тарафыннан төрки халыкларның кеше исемнәрен мәгънәви (семантик) яссылыкта төрлечә классификацияләүләре билгеле. Хәзерге вакытта шулардан уңышлысы

булып атаклы венгр тюркологы-антропонимисты Л. Рашони классификациясе санала (Rasonyi, 1953). Л. Рашони классификациясенең асылын төрки исемнәрне барлыкка килү мотивлары буенча төрле лексик-тематик төркемнәргә аеру тәшкил итә.

Күренекле совет ономатологы В.А. Никонов «Имя и общество» хезмәтендә төрки халыкларның исемлеген өйрәнү барышында Л. Рашони классификациясен өлге-схема итеп ала һәм төрки телләрдәге кеше исемнәрен түбәндәгечә өч төп төркемгә аерып карый: 1) меморатив (багышлау) исемнәр; 2) дескриптив (тасвирлау-сурәтләү) исемнәр; 3) дезидератив (теләк) исемнәр (Никонов, 1974: 96).

Иң борынгы төрки-татар кеше исемнәренең барлыкка килү сәбәп-мотивларының асылын мәҗүсилек нигезе тәшкил итә. Алар мәҗүсилек идеологиясенә хас булган төрле ышанулар, йолалар, традицияләр йогынтысында барлыкка килгәннәр. Мәҗүсилек ышанулары, йолалары ифрат күп төрле булганнар. Шулардан борынгы төрки-татар кеше исемнәрен барлыкка китерүдә 1) тотемистик ышанулар, 2) анимистик ышанулар, 3) күк-тәңре, күк җисемнәре культы һәм туганлык терминнарының роле һәм йогынтысы аерата зур булган.

Икенче бер зур төркем борынгы исемнәребезнең барлыкка килү мотив-чыганаклары болгар-татарларда балага исем кушу белән бәйләнешле борынгы ышануларга, йолаларга һәм традицияләргә кайтып кала.

Г.Ф. Саттаров болгар-татарларда балага исем кушу белән бәйләнешле йола-ышануларны һәм традицияләрне, үз чиратында, тагын ике төркемгә аера.

I. Баланың ата-анасының, туган-кардәшләренең, нәсел-ыруының теләге, хис-кичерешләре, бу бала шундый сыйфатка, холыкка, чин-дәрәҗәгә ия булсын иде дигән ниятләре яткан ышанулар, йолалар һәм традицияләргә нисбәтле исемнәр. Мондый исемнәрне, бирелү йола-мотивларыннан чыгып, түбәндәге төркемчәләргә аерып була:

1) сословие терминнарына нисбәтле кеше исемнәре;

2) сүзнең магик көченә ышанып, бала яныннан усал көчләрне качыру, аларны куркыту нияте белән кушылган исемнәр («саклау яки профилактик исемнәр»);

3) «бәби тапмый» дип аты чыккан, озак вакытлар бала тапмаган киленне, бала тапкач, аклау исемнәре;

4) баланың сау-сәламәт булуын теләү исемнәре;

5) баланың авырулардан терелүен, сәламәтләнүен теләү исемнәре;

6) баланың көчле, батыр-гайрәтле булуын теләү исемнәре;

7) баланың бәхетле, мул ризыклы, мал-мөлкәтле булуын теләү исемнәре;

8) баланың озын гомерле булуын теләү исемнәре;

9) баланың булуын, дөньяга килүен, тууын теләү исемнәре («бала келәве»);

10) баланың нәсел-ыруны дәвам иттерүче, ишәйтүче, нәсел чылбырының яңа бер буыны булуын теләү исемнәре;

11) баланың матур-чибәр, якты-нурлы йөзле булуын теләү исемнәре;

12) баланың әти-әнисенә, туганнарына кадерле, якын, татлы, ләззәтле булуын белдерүче исемнәр;

13) бала тууга әти-әнисенең, туганнарының сөенү-шатлану хисләрен белдерүче исемнәр;

14) баланың көтеп алыну яки алынмавын белдерүче исемнәр;

15) баланың укымышлы, галим булуын теләү исемнәре;

16) баланың берәр төрле һөнәр иясе булуын теләү исемнәре;

17) баланың акыллы, тәүфыйклы, ата-анага таяныч, ярдәмче-булышчы булуын теләү исемнәре;

18) гаиләдә баланың үлемен яки тууын туктатырга теләү исемнәре;

19) баланың тугрылыклы, гадел, ышанычлы, керсез, саф булуын теләү исемнәре;

20) ата-ана һәм туган-кардәшләренең баланың үзләренә иптәш, дус, юлдаш булуын теләү исемнәре;

21) баланың теге яки бу мифик, фольклор, әдәби әсәр герое, тарихи шәхес кебек булып үсүен теләү-багышлау исемнәре.

II. Асылларында баланың үзенә нисбәтле төрле ышанулар, йолалар, гадәт-традицияләр яткан исемнәр. Моңа яңа туган баланың 1) төс-килбәте, 2) тугач күзгә ташланып торган әгъзасы, 3) ясаган хәрәкәте, 4) туу урыны, 5) туганда физик (физиологик) яктан ничек булуын (сәламәт, чирле, берәр әгъзасы артык яки ким һ.б.), 6) үз (законлы) әтисенең булу-булмавы, 7) нәсел-ыруда, гаиләдә ни рәвешле пәйда булуы, 8) туу вакыты (елы, ел фасылы, ае), 9) кайсы көнне тууы (бәйрәм көн, изге көн һ.б.), 10) бала туганда

һава (табигать) торышы, 11) баланың туу тәртибе (гаиләдә ничәнче бала булып тууы), 12) бала туганчы әтисе яки, тугач, әнисенең үлүе (әтисе яки әнисе төсе, истәлеге булуы), 13) баланың каты авырулардан терелеп исән калуы, 14) баланың холкы (характеры) мотив булган ышанулар, йолалар һәм традицияләргә нисбәтле кеше исемнәре керә (Саттаров, 1990: 10–13).

Г.Р. Галиуллина татар антропонимиясендә исем бирү мотивларын лингвомәдәни традицияләр кысасында карый (Галиуллина, 2008). Аның фикеренчә, хәзерге татар антропонимиясендә исем тамга, билге вазифасын үти, балага исем сайлаганда, беренче чиратта, аның яңгырашы, уңай ассоциацияләр тудыруы, милли исемлектәге урыны, аннан соң исемгә салынган мәгънә исәпкә алына.

Татар исемнәр системасындагы берәмлекләрнең бирелү мотивларын милли мәдәният кысасында карау зарур, чөнки исем кешене милли мәдәнияткә алып керүче беренче баскыч санала. Шунлыктан без татар исемнәренең бирелү мотивларын милли мәдәният контекстында карауны уңышлы дип саныйбыз, бу рәвешле карау милли мәдәният берәмлеге булган антропонимнарның асылын, барлыкка килү тарихын тулырак күзалларга ярдәм итә. Хәзерге татар кеше исемнәре системасының формалашу һәм бүгенге көндәге халәте төрки-татар, ислам һәм көнчыгыш, рус һәм Европа мәдәниятләренең кушылмасы, синтезы нәтиҗәсендә барлыкка килгән һәм бербөтен система буларак оешкан.

Милли исемлегебез формалашуда төрки традицияләрнең роле. Нинди генә территориядә яшәмәсен һәм нинди дин вәкиле булмасын – кешеләрнең исемне илаһилаштыруы, аның серлелегенә, милли мәдәният белән бәйләнешенә бертөрле караш яши. Аның нигезе бүген генә барлыкка килмәгән, ул борынгы чорларда, кешелек җәмгыятенең балалык вакытларыннан башлана. Исемне мәдәниятнең аерылгысыз өлеше итеп карау төркиләр өчен генә түгел, башка халыкларга да хас. Мәҗүсилек чорында исемнең илаһи көченә ышану көчле була. Барлык халыкларның да борынгы дини-мифологик ышануларында исемнең магик көчкә ия булуы турында легендалар сакланып калган. Татар халкының борынгы бабалары – төркиләр сүзнең, шул исәптән исемнең, сихри көчкә ия булуына ышанганнар. Сүзнең бөеклегенә табыну, аның тәэсир көченә ия булуына ышану балага исем сайлаганда зур әһәмияткә ия

була. Балага кушылган исем аны явыз рухлардан, кара көчләрдән, хәвеф-хәтәрләрдән саклый, дигән ышану нигезендә борынгы төрки бабаларыбызның исемнәр системасы формалаша.

Борынгы төркиләр табигать кочагында, табигать белән гармониядә яшиләр, шунлыктан табигать күренешләрен изгеләштерү, аларның магиясенә ышану тормыш-көнкүрешнең һәр өлкәсен чорнап алган була. Бүгенге төркиләрнең, шул исәптән татарларның да, көнкүреш йолаларында билгеле бер дәрәҗәдә сакланып калган бу ышанулар кешенең табигать белән бергәлеген, аның табигать баласы булуын дәлилли. Табигатьтә тәрбия алу, табигатьнең һәр күренеше кешегә йогынты ясавына ышану борынгы исемнәрдә ачык чагыла. Борынгы җәмгыятьтә исем аша кешенең табигать белән кушылуы барлыкка килгән, табигать күренешләрен җанландыру, илаһилаштыру балага исем кушуда, башка төр йолаларда яшәгән. Гомумән, кешенең иҗтимагый, шәхси тормышы табигать кануннарына тулысынча буйсынган була.

Борынгы кешенең дөньяга мифологик карашы, борынгы төркиләрнең тормыш тәҗрибәсе кешене ул йөрткән исем белән бер итеп карауга кайтып кала. Кеше үзе йөрткән исем белән тыгыз бәйләнештә яши, исем кешенең асылын алыштырырга сәләтле, исем кешенең киләчәгенә тәэсир итә, аның яшәешен билгели кебек ышанулар төрки бабаларыбыз өчен исем кушуда төп рольне үтәгән. Борынгы төрки дини-мифологик күзаллауларда исем сихри инструмент буларак карала, һәм кешенең исеме саклау, профилактика, куркыту вазифаларын үти. Шунлыктан балага исем кушу гаять әһәмиятле йолаларның берсенә әверелә. Исемне кешенең җаны итеп карау, Тәңре тарафыннан кешене сакларга сәләтле булуына ышану исемгә бик зур вазифалар йөкләгән.

Идел буе Болгар дәүләте территориясендә исламгача булган дәвердә кулланылган исемнәрнең эчтәлегенә карасак, без аларда мәҗүси ышануларның ике төренең – тотемизм һәм анимизмның – киң таралганлыгын күрәбез. Алар нигезендә бабаларыбызның исемнәр системасы формалашкан һәм ислам дине киң таралганчы үсеш кичергән. Аларның кайтавазын бүгенге XXI гасыр исемлегендә дә очратырга була.

*Тотемизм* – башлангыч дин формасы, аның нигезендә берәр кабилә, ыругның табына торган тотемы, ягъни хайван, үсемлек яисә бүтән табигать күренеше, аның сыны, сурәте ята. Тотем

кабиләгә нигез салучы буларак күзаллана, һәм кабилә аның исемен йөртә. Галимнәр төркиләрдә тотемизм күренешенең барлыкка килүен күчмә тормыш белән бәйләп аңлаталар. Табынган хайванның көчен, гайрәтен изгеләштерү, кабилә кешеләренең һәрберсен шул хайван белән тиңләштерү аша борынгыларның дөньяга карашы формалаша. Тормышның һәр ягын тотем хайван белән бәйләү борынгы төркиләрдә кулланылышта йөргән календарьда да күренә. Мәсәлән, *Барс елы, Йылан елы, Эт елы, Кой/куй елы* һ.б. Борынгы Турфан текстларында теге яки бу авырудан котылу өчен бирелгән дәвалау алымнарында, им-томнарда да тотем хайван белән бәйлелек сизелә.

Борынгы төрки җәмгыятьтә югары даирә кешеләре үзләренең килеп чыгышын төрле хайваннарга бәйле аңлатканнар. Аларның күбесе борынгы ташъязма истәлекләрендә сакланып калган. Мәсәлән: *Arslan, Aşına, Bars, Buqa, Küçük, Temır, Qaban, Qulan, Teka, Togan* һ.б. Бүген дә татарлар арасында, бигрәк тә авыл җирлегендә, гаиләләрнең кушаматлары бар. Нигездә алар теге яисә бу хайван, кош-корт атамасы белән бәйле һәм нәселнең холкына, аерым сыйфатларына ишарә итәләр. *Күркә Нурый, Әтәч Гали нәселе, Куяннар нәселе, Тукраннар нәселе, Каз Салих хатыны* рәвешле авыл халкында бер-берсен атау, эндәшү формаларының нигезе тотемистик ышануларга барып тоташа.

Төрки кабиләләрнең барлыкка килүе бүре белән бәйләп аңлатыла. Һун кабиләләренең, кыпчакларның һәм Алтын Урда ханнарының эләмнәрендә бүре башы сурәтләнә. Исламгача булган исемнәр системасында да *бүре* сүзе катнашып ясалган исемнәр кулланыла. Алар *Бүребай, Бүрехан, Башбүре, Бүриш* кебек исемнәр, соңрак *Байбурин, Буркиев, Буриев, Бурикаев* кебек фамилияләрдә сакланып калган (Саттаров, 1990: 15).

Бүре белән бергә төркиләрдә барсны изге хайван итеп карау да киң таралган була. Идел буе Болгар дәүләте территориясендә казу эшләре алып барган археологлар барс сурәте төшкән көнкүреш кирәк-яраклары, савыт-сабалар табалар. Борынгы төркиләрдә барс компонентлы ир-ат исемнәре еш кулланыла (Саттаров, 1990: 15). Моның дәвамын хәзер дә күрәбез. Әйтик, *Барсил, Айбарис/Айбарыс*, *Илбарис, Бибарс, Акбарс* кебек исемнәр бүген ир балаларга кушыла. Бу, мөгаен, *Арслан* исеме белән берлектә, ислам тәэсирендә төшеп калмаган бердәнбер очрактыр.

Балага изге хайван белән бәйле исемнәр кушканда аңа тотем сыйфатлары күчә, дигән ышану яшәгән. Татар халкында арсланның көчен, гайрәтен балада күрергә теләү *Арыслан* исеменең еш кушылуына китергән. Борынгы текстларда *Arslan balban, Arslan tegin, Arslan Bilge Tengri ilig* исемнәре сакланып калган. Бүгенге татарлар арасында да әлеге исем ир балаларга шактый актив кушыла.

Борынгы бабаларыбызның исемнәрендә ачык чагылыш тапкан тагын бер төр дини-мифологик ышану формасы булып анимизм тора.

*Анимизм* – рух, җан яшәешенә ышану (Мечковская, 1998: 12). Табигать белән гармониядә яшәү, үзен тудырган табигатьнең илаһилыгына, бөеклегенә табыну борынгы кешенең рухи дөньясына кешегә хас сыйфатларга ия булган аллалар, рухлар, мифик затларны алып керә. Табигать күренешләрен кеше белән тиңләү, кешегә хас сыйфатлар бирергә омтылу табыну гына түгел, бәлки аларның кешегә ярдәм итү, зыян салу мөмкинлегенә ышануны көчәйтә.

Борынгы төрки бабаларыбызның төп табыну объекты булып Космос (Галәм) тора. Борынгы мифологиядә күк төп алла – Тәңре – тарафыннан яратылган. Үзенә буйсынган башка аллалар белән берлектә Тәңре җир йөзендә булган һәрбер вакыйга белән идарә итә, кешеләренең язмышларын һәм яшәү вакытын билгели. Аның яшәү урыны булып күк йөзе санала. Шуңа бәйле, борынгы бабаларыбыз күк йөзендә булган һәр җисемгә табынганнар. Бу төр табынулар, үз чиратында, кеше исемнәренә дә күчкән. *Тәңребиргән, Тәңребирде, Тәңрекол* кебек исемнәрнең ир балаларга гына кушылуы, *тәңре* сүзе белән янәшә *биргән, бирде, кол* кебек сүзләрнең килүе Тәңренең кеше язмышы белән идарә итүен исбатлый торган бер мисал булып тора. Төрки халыкларның милли антропонимиконында *Тәңре* компонентлы исемнәр таралыш тапкан. Мәсәлән, үзбәк телендә – *Тангриберган, Тангрикул*, казакларда – *Тәңірбирген, Тәңірбирди, Тәңіркул*, мәмлүкләрдә – *Тенгри-Бирмиш, Тангри Берди* исемнәре.

Татарларда ислам дине киң таралганчы, *тәңре* компонентлы исемнәр кулланылышта йөри. Хәтта XVI–XVIII йөз язма истәлекләрендә дә бу төр исемнәрне очратырга була. Соңрак мондый исемнәр кулланылыштан төшеп калсалар да, халык хәтерендә алар югалмыйлар, бәлки *Аллабирде, Аллабиргән, Аллагол, Ходайбирде, Кудайбакты/Ходайбакты* кебек ир-ат исемнәре традицияләрнең дәвамчанлыгын күрсәтә.

Борынгы төркиләрнең күк йөзендәге җисемнәргә табынуы, исемнәр өлкәсенә дә үтеп кереп, күп дәверләр милли исемнәребезнең асылын тәшкил иткән. Мондый төр ышанулар түбәндәге исем һәм исем компонентларында сакланып калган:

– *ай* компоненты белән ясалган космонимик ышанулар нигезендә барлыкка килгән исемнәрдә: *Айкай, Айдар, Айтуган, Айбулат, Айваз, Айвар, Айдин, Айнур, Айзат, Айдар, Айдис, Айгөл, Айзидә, Айдан, Айсинә, Айсылу, Айзилә, Айназ,* һ.б.;

– *таң* лексемасы белән ясалган исемнәрдә: *Таңкилде, Таңтуган, Таңатар, Таңсу, Таң, Таңгөл, Таңчулпан, Таңсылу, Таңнур;*

– төрки чыгышлы исемнәр составында сакланып калган *каган, хан, тархан, бәк, бай* кебек социаль детерминативлар нигезендә ясалган антропонимнарда: *Әмирхан, Әбухан, Касыймхан, Миңлехан, Мәхмүтхан, Мәүлетхан, Сәетхан, Сәлимхан, Тимерхан, Фәезхан, Ханлар, Ханкилде, Ханвәли, Хәмәтхан, Вәлихан, Габделхан, Тимерхан, Илхан, Ирхан, Хан, Илбәк, Нурбәк, Нурбик, Нариманбәк, Бикбулат, Әнвәрбәк* һ.б.

– *кот* сүзе синонимы булган *ураз,* соңрак шушы ук традициянең дәвамы булып фарсы теленнән кергән *җан* компоненты белән ясалган исемнәрдә: *Котлыяр, Котлык, Котлыбулат*, *Уразбакты, Уразгуҗа, Уразмөхәммәт, Уразали, Салихҗан, Әмирҗан, Җанбәк, Җанбай, Җанәхмәт, Мөбарәкҗан, Мәхмүтҗан, Җантаһир* һ.б.

Анимистик ышанулар нигезендә барлыкка килгән тагын бер төркем исем Җир белән бәйле. Борынгылар җирне, аның белән бәйле барлык предмет һәм күренешләрене изгеләштергәннәр. Җир-ана культы уңыш чыганагы буларак төркиләрдә генә түгел, башка халыкларда да яши һәм хатын-кыз белән бәйле аңлатыла. Бу төр ышанаулар борынгы төрки, соңрак төрки-татар исемнәрендә дә түбәндәге очракларда яңгыраш таба:

– *таш, алтын, көмеш, булат, тимер, бакыр* кебек минерал һәм металл атамаларына нигезләнеп барлыкка килгән исемнәрне борынгы бабаларыбыз җир байлыкларын баланы явыз көчләрдән, авырулардан саклау чарасы буларак ышанулары нигезендә кушканнар. Әгәр гаиләдә бер-бер артлы балалар үлсә, яңа туган сабыйга *таш, тимер, булат* кебек сүзләр катнашкан исемнәр бирергә тырышканнар, чөнки бу сүзләрнең мәгънәсе, бүген барыбызга да таныш булганча, ныклык, катылык, бирешмәс кебек төшенчәләрне

үз эченә ала. Борынгы ышанулар буенча табигатьтәге һәр предметнең, шул исәптән, металл һәм минералларның да, җаны бар, һәм алар балага үзләренең сыйфатларын бирә алганнар. Урал-Алтай берлегенә караган телләрдә *таш, тимер, булат* сүзләре катнашып ясалган исемнәр зур бер төркем хасил итә: *Гантөмөр, Төмөрбаатар* – монгол телендә, *Тумэр, Тумэрхэн, Уумэрхэн (тумэр – тимер*) – бурят телендә, *Дямир, Полад* – азәрбайҗан телендә, *Ташбика, Биктимир, Тимерлан, Тимербек, Тимербулат* һ.б. – башкорт телендә, *Demır, Demıralp, Demırel, Demırhan* – төрек телендә, *Болат, Болатбек, Тасболат, Тастемир, Темиргали, Темирбай* – казакларда, *Тимер, Тимербулат, Тимур, Тимерхан, Миңтимер, Байтимер, Таштимер, Биктимер, Тимербай, Тимеркәй, Бикташ, Ташмөхәммәт, Булат* – татар телендә. Мисаллардан күренгәнчә, әлеге исемнәр, башлыча, ир балаларга кушыла, саклау-профилактика вазифасыннан тыш, аларның мәгънәсендә баланың көчле, бай булуын теләү дә ята (Галиуллина, 2008: 98).

Табигать күренешләренә табыну үсемлек, чәчәк, агач атамаларыннан ясалган кеше исемнәрендә дә чагыла. Бу төр ышануларның тамыры мифологиянең архаик формаларыннан килә. Борынгы төрки мифологиядә үсемлекләр өч космик дөньяны – күкне, җир өстен һәм җир астын тоташтырган чылбыр буларак карала. Борынгы төрки исемнәр дөньясында үсемлекләр дөньясы белән бәйле исемнәр күп түгел. Аерым алганда, *Çeçak* – чәчәк, *Çınar Çeçak* – чинар агачының чәчәге (хатын-кыз исеме); *Japdu terak* – агач атамасы (ир-ат исеме); *Kamala Açarı, Kamala Anantasırı – kamala* – санскрит телендә лотос чәчәге кебек исемнәр язма истәлекләрдә теркәлеп калган. Соңрак бу традиция төрки-татар исемнәр дөньясында да дәвам итә. *Байтирәк, Зәйкуак, Имән, Имәнкол, Иштирәк, Алма, Йөзем, Өрек, Юкә* кебек исемнәр шундыйлардан. Ислам дине йогынтысында исемлегебез үзгәреш кичергән дәвердә дә дәвамчанлык саклана, алай гына да түгел, гарәп, фарсы телләреннән бик күп яңа төр исемнәр үтеп кереп, исемлегебезне баета. Флора белән бәйле исемнәр, башлыча, кыз балаларга кушыла башлый. Хатын-кызларны гөл белән тиңләү, төркиләрдә генә түгел, барлык мәдәниятләрдә дә киң таралыш тапкан. Төрки халыкларда бу традициянең борынгы чорлардан ук килгәнлеге мәгълүм. Татар халкының милли аңында да хатын-кыз матурлыгы гөл белән бәйләп карала. Кыз баланы гөлгә тиңләү аның матур,

иркә, ягымлы булуын теләүгә нигезләнгән. Үсемлек, гөл атамаларыннан ислам йогынтысында гарәп һәм фарсы телләреннән шактый исемнәр үтеп керә. Мәсәлән: *Ләлә, Ясминә, Нәргиз-Нәргизә, Рәйхан/Рәйхана, Сөмбел/Сөмбелә, Далия, Сәрви/Сәрби, Зәйтүнә, Зәйтүнгөл, Миләүшә, Зиләйлә, Нилуфәр, Ясминә, Гөлнар/Гөлнара, Гөлшат, Наргөл, Нарисә, Наринә* һ.б. исемнәр.

Кеше исемнәрендә матурлык төшенчәсен белдерү юлларының милли аңга ныклап урнашуы рус теленнән һәм рус теле аша Европа телләреннән түбәндәге яңа төр исемнәр үтеп керүгә юл ачты: *Лилия, Флорид/Флорида, Флора, Флёра, Флёр, Ландыш, Фиалка* һ.б.

Шулай итеп, татар халкында исем бирү мотивларының нигез ташы борынгы төрки традицияләргә барып тоташа, алар исә, халыкның милли аңында сакланып, буыннан-буынга кеше исемнәре аша тапшырылып килә.

Татар кеше исемнәре системасында ислам дине һәм көнчыгыш мәдәнияте тәэсирендә барлыкка килгән традицияләр.

Төрки-татар исемнәр системасы формалашуда һәм аның үсешендә ислам диненең, Көнчыгыш мәдәниятенең әһәмияте әйтеп бетергесез. Идел буе Болгар дәүләтендә рәсми рәвештә ислам динен кабул итү тормышның барлык якларына да зур йогынты ясый. Ислам динен таратуда кеше исемнәренең роле гаять зур булганлыктан, миссионерлар һәм дин әһелләре тарафыннан моңа аеруча игътибар бирелә, шулай да гарәп исемнәренең бабаларыбыз арасында таралуы шактый озакка сузыла. Моның төп сәбәбе мәҗүси йола һәм ышануларның халык аңыннан кинәт кенә юкка чыкмавына бәйле. Борынгы традицияләрнең кинәт кенә югалмавына бер дәлил булып XVIII гасыр ахырына кадәр төрки-татарлар арасында катнаш төзелешле исемнәр кулланылуы тора. Мисал өчен Идел буе Болгар дәүләтенең эпитафик истәлекләрендә, татар шәҗәрәләрендә теркәлеп калган *Юныс әл Болгари, Ибраһим әс Сувари, Исламкол, Акмөхәммәт, Колмөхәммәт* һ.б шундый исемнәрне китерергә була. Гарәп-фарсы исемнәре XV–XVI гасырларда гади халык арасында тарала башласа да, Алтын Урда дәүләте чорында, соңрак Казан ханлыгында да катнаш исемнәр кушу тенденциясе дәвам итә.

Килеп чыгышлары ягыннан гарәп һәм фарсы телләреннән булган бу төр исемнәрне Г.Ф. Саттаров лексик-семантик яктан ике

зур төркемгә бүлеп өйрәнә: 1) асылларында ислам дине төшенчәләре яткан алынма исемнәр; 2) асылларында дөньяви эчтәлекле гарәп-фарсы сүзләре яткан алынма исемнәр (Саттаров, 1990: 186).

Әлеге төркемләүгә нигезләнеп, әлеге төр исемнәрне дини эчтәлекле һәм дөньяви эчтәлекле исемнәргә аерып, исем бирүдәге төп мотивларга тукталу урынлы булыр.

*Дини эчтәлекле* исемнәр арасында төп урынны Аллаһы Тәгаләнең күркәм исемнәре, Мөхәммәт пәйгамбәргә мөнәсәбәтле исемнәр һәм башка пәйгамбәрләрнең исемнәре алып тора. Аларның татар җирлегендә киң таралган төрләре түбәндәгеләр:

*алла-улла* сүзен кулланып ясалган исемнәр: *Галимулла, Хәкимулла, Хәбибулла, Сибгатулла, Фәтхулла, Нурулла, Габдулла* һ.б.;

*дин* сүзе белән ясалган исемнәр: *Бәдретдин, Кыяметдин, Гарифетдин, Әшрәфетдин, Борһанетдин, Динислам;*

*ислам* сүзе ярдәмендә ясалган антропонимнар: *Нурислам, Шәйхелислам, Фәхрислам, Исламетдин, Исламгали, Исламгәрәй* һ.б.

Аллаһы Тәгаләне олылауга, аңа табынуга корылган, мәгънәләрендә исламның төп асылын чагылдырган гаделлек, бераллалык, тугрылык, хәрам эшләрдән тыюга өндәү, изгелек кебек төшенчәләр яткан теофор исемнәр: *Рахман* (шәфкатьле), *Рәхим* (мәрхәмәтле), *Мәлик* (патша), *Газиз* (кадерле), *Җәббар* (кодрәтле), *Халик* (яктыртучы), *Бари* (бар кылучы), *Фәттах* (юл ачучы, җиңүче), *Хәбир* (хәбәрдар), *Хәлим* (сабыр), *Гафур* (гафу кылучы), *Гали* (бөек), *Рәшит* (дөрес), *Раззак* (туйдыручы), *Котдус* (изге), *Сәлам* (иминлек), *Сәми* (югары дәрәҗәле), *Мөэмин* (инанучы), *Басыйр* (зирәк, акыллы), *Гаффар* (кичерүче), *Гадел – Адел* (тугры, намуслы), *Шаһит* (күрүче), *Латыйф* (шәфкатьле), *Кәбир* (бөек) һ.б.

Мөхәммәт пәйгамбәр исем-эпитетлары, аның якыннарының исемнәренә нигезләнеп ясалган антропонимнар: гарәп телендәге حمد *(дан, таныл)* тамырыннан барлыкка килгән *Мөхәммәд, Әхмәд, Мәхмүд, Хәмид* исемнәре, Мөхәммәт пәйгамбәрнең *Мостафа, Әмин, Расулулла*, *Расул*, *Нәби* кебек исем-эпитетлары, пәйгамбәрнең хатыннары һәм кызларының исемнәре һәм эпитетлары *Әминә, Хәдичә, Фатыйма*, *Радия/Разия*, *Өммегөлсем*, *Рокыя*, *Зәйнәп*.

Мөселман дөньясында изгеләр рәтендә пәйгамбәрнең оныклары – Фатыйманың уллары – *Хәсән* белән *Хөсәен* карала. Идел буе Болгар дәүләте ислам динен кабул иткән беренче көннәрдән алып, әлеге исемнәр ир балаларга кушыла башлый. Бүгенге көнгә кадәр

татарлар арасында бу исемнәр үзләренең активлыкларын югалтмыйлар, аеруча дини гаиләләрдә алар шактый еш кушыла. Татарлар арасында Хәсән һәм Хөсәен исемнәрен игезәк ир балаларга, я булмаса бер-бер артлы туган балаларга кушу традициясе саклана. Дини кануннар нигезендә үле туган яисә яшьли үлгән ир балаларны әлеге исемнәр кушып җирләү бар, үле туган яисә тугач вафат кыз балаларга Хәсән белән Хөсәеннең әниләре исеме – Фатыйма исемен кушалар.

Иудаизм, христиан диннәрендә изгеләштерелгән пәйгамбәр исемнәре (аларны һәр мөселман кешесе белергә тиеш санала): *Адәм, Ибраһим* < борынгы яһүди телендә *Авраам, Муса < Моше, Ильяс < Яхве,* грекча *Белиос,* русча *Илья, Гайсә < Йехошу, грекча Иисус, Исхак < Исаак, Давыт < Давид, Сөләйман < Шэломох < Соломон, Идрис < Енох, Нух < Ной, Худ < Эвер, Салих < Муфасаил, Лут < Лот, Исмагыйль < Исмаил, Якуп < Иаков, Йосыф < Иосиф, Харун < Аарон, Шуайб, Әюп < Иов, Зөлкифл < Исаия, Юныс < Иона, Яса < Елисей, Зәкәрия < Захария, Яхья < Иоанн, Гозәер < Ездра.*

Ислам мәдәнияте йогынтысында төрки-татар исемлегенә үтеп кергән традицияләр шактый. Аларның формалашуында һәм үсешендә суфичылык тәгълиматы, Көнчыгыш поэзиясе йогынтысы, аң-белемгә омтылу, дини бәйрәм һәм йолаларны үтәү зур роль уйный. Боларның барысы да билгеле бер дәрәҗәдә татар исемлегендә сакланып калган, әмма аларның һәрберсенә махсус тукталмыйча, төрки-татарларга үтеп кергән, соңрак татар исемлегенең төп нигезен тәшкил иткән, бүгенге исемлегебезнең дә асылы саналган *дөньяви эчтәлекле исемнәр* куллануны атау зарур.

Ислам дине, мөселман дөньясы белән танышу барышында татарлар исемнәр дөньясын дини эчтәлекле исемнәр белән генә түгел, ә Көнчыгыш мәдәниятен чагылдырган башка төр исемнәр хисабына да баеттылар. Идел буе Болгар дәүләтенә мөселман дине фарсы мәдәнияте элементлары белән үрелеп үтеп керә. Фарсы һәм гарәби чыгышлы исемнәр бабаларыбыз тарафыннан мөселман исемнәре буларак кабул ителә, аларның төрле мәдәният үрнәкләре булуы үзен артык сиздерми. Төрки-татарлар арасында гарәп сүзләренең, шул исәптән исемнәрнең, таралуында фарсы поэтик ядкярләренең роле гаять зур була. Хәзерге галимнәр билгеләвенчә, Идел буена ислам дине, Багдад аша түгел, географик яктан да, тел,

әдәбият, тарих ягыннан да болгарларга якын булган Урта Азия руханилары аша үтеп кергән (Ибраһим һ.б.: 2002: 21).

Мөселман дине белән сугарылган фәнни трактатларның, әдәби әсәрләрнең, гомумән көнчыгыш мәдәниятенең таралуы дөньяви эчтәлекле исемнәрнең күпләп кулланыла башлавына китерә. Беренче карашка алар турыдан-туры мөселман күзаллауларын, ислам символикасын чагылдырмаса да, исем кушу мотивларын ныклап өйрәнгәннән соң, без бу төр исемнәрдә дини күзаллаулар белән эчке бәйләнешне җиңел тоябыз.

Ислам, көнчыгыш тәэсирендә татарлар арасында *белем, матурлык* төшенчәләре белән бәйле исемнәр куллану традициясе ныклап урнашуын күрергә була. Әлбәттә, гарәп һәм фарсы телләреннән төрле предмет, табигать күренеше атамалары, башка төр матди дөнья атамалары кеше исеме буларак үтеп керә, әмма мондый төр исемнәр кушу борынгы төркиләр арасында да булганлыктан, алар төрки-татарларның исемнәр системасы үсешенә зур йогынты ясамаган, үсеш юнәлешен билгеләгән төп күрсәткеч булмаган.

Мөселман фәлсәфәсендә *белем* иң алдынгы урыннарны били. Урта гасырда Көнчыгышта төгәл фәннәр бик нык үсештә була, шунлыктан белемгә омтылу, фәнгә хөрмәт белән карау – гадәти күренеш, һәм ул мөселман идеологиясенең нигезендә ята.

Баланың укымышлы, зыялы булуын теләү гаиләдә балага исем сайлаганда зур роль уйный. Татарлар арасында *галим, гыйлем, гакыйль, фәһем*, *зирәк, фән* кебек сүзләр ярдәмендә ясалган *Галим, Галимшаһ, Галимҗан, Галимулла, Галимә, Галимәбану, Галимәнур*; *Гыйльметдин, Гыйлемшаһ*, *Гыйлемдар, Гыйлемхан, Гыйльмебану, Гыйльмениса, Гыйльмесылу*; *Гакыйль/Гакыйлә; Фәһим/Фәһимә (Фәим/Фәймә), Фәһми/Фәһмия, Фәһимҗан*, *Фәһимулла; Зирәк, Айзирәк*, *Гөлзирәк*, *Илзирәк; Фәнгиз/Фәнгизә, Фәнгыйль, Фәндар, Фәндил/Фәнилә, Фәндүс/Фәндүсә, Фәнис/Фәнисә, Фәнзүр, Фәндәс, Фәнзаман, Фәнил, Фәнияр, Фәния, Фәндилә, Фәнзия, Фәнзилә, Фәнүз/Фәнүзә, Фәнсөяр, Фәнзирәк* һ.б. исемнәр кулланылышта йөри. Хәзер аларның күбесе балаларга еш кушылмасалар да, *фән, зирәк* сүзләре ярдәмендә ясалганнарын татарлар яңа туган балаларга шактый бирәләр.

Китерелгән исемнәрнең мәгънәсе һәр татар кешесенә җиңел аңлашылса да, татар исемнәре системасында *гыйлем* төшенчәсе белән бәйле, әмма мәгънәсен сүзлекләр ярдәмендә генә ачыклап

була торган берәмлекләр дә очрый. Аерым алганда, *Зәки* (үтәли күрүче): *Зәки/Зәкия, Зәкиҗан, Зәкиулла*; *Галләм* (барысын белүче): *Галләметдин, Галләмия*; *Гариф* (галим, белемле): *Гарифҗан, Гарифулла, Гарифә, Гарифәбану* (мишәр диалектында *ариф* вариантында кулланыла: *Ариф, Арифетдин, Арифә*); *Гыйрфан* (мишәр диалектында *ирфан* – белем, үтә күрүчән; акыллы): *Гыйрфан/Гыйрфания, Гыйрфанетдин, Ирфан*; *Ләбиб/Ләбибә* (акыллы), *Вакыйф/Вакыйфа* (аңлаучы, белүче), *Фазыл* (галим кешенең эпитеты), *Равия* (фикерләү), *Зыя* (интеллект); фарсы теленнән алынган *Дана* (белемле иясе, галим), *Данис* (белем, фән), *Данияр* (белемле) һ.б. шундый исемнәр әлеге төркемгә керә.

Гыйлем белән бәйле исемнәр рәтендә *Мөгаллим/Мөгаллимә* (укытучы, остаз), *Мөдәррис* (укытучы), *Талип/Талибә* (студент), *Тәуфыйк* (тәрбияле), *Инсаф* (тәрбияле, тыйнак, әдәпле), *Әдип/Әдибә* (тәрбияле, әдәпле, укымышлы), *Факих* (мөселман хокукын белүче), *Ирадә/Ирада* (теләк, максат, ихтыяр көче) һ.б.ларны атап китәргә кирәк, чөнки мөселман фәлсәфәсе белем иясен акыл белән генә бәйләми, бәлки аның тәрбияле, инсафлы, башкаларга үрнәк булырлык шәхес булуын ассызыклый. Татарларда югарыда саналган исемнәрнең мәгънәсенә салынган төшенчәләр элек-электән югары бәяләнеп килә, балаларны тәрбияләү барышында халык педагогикасының асылын нәкъ менә әлеге төшенчәләр алып тора.

*Матурлык* төшенчәсен белдергән исемнәрнең, ислам дине, фарсы мәдәнияте үтеп кергәнче үк, төрки-болгар бабаларыбыз исемлегендә кулланылышта йөрүен искәрткән идек. Мөселман цивилизациясе бу төр традициянең яңа юнәлеш алуына юл сала. Мәдәниятләр багланышы нигезендә дөньяны кабул итүдә яңа алымнар, төрләр барлыкка килә һәм алар, телдә генә түгел, гомумән яшәештә чагылыш таба. Көнчыгышта матурлыкка дан җырлау, аны илаһи бөеклеккә күтәрү киң таралган. Бу сыйфат көнчыгыш әдипләрнең әсәрләре аша татар мәдәниятенә дә үтеп керә һәм ныклап урнаша. Кешенең эчке һәм тышкы матурлыгын татар әдипләре бүген дә көнчыгыштан кергән, татар җирлегендә милли күзаллаулар белән баетылган образлар үрнәгендә тасвирлыйлар. Мондый үзенчәлек татар кеше исемнәр хәзинәсен дә читләтеп үтмәгән. Татар кеше исемнәрендә матурлык төшенчәсен белдергән берәмлекләр, нигездә, ике төркемгә берләшәләр. Беренчесе

кешенең тышкы матурлыгын сурәтләсә, икенче төркем исемнәр кешенең эчке матурлыгын чагылдыралар.

*Матурлык* төшенчәсе хатын-кыз исемнәрендә чагыла. Алдагы бүлектә без борынгы төркиләрдә хатын-кызны үсемлекләр, чәчәкләр белән тиңләштерү традициясе яшәвен тасвирладык. Хатын-кызларның матурлыгын сурәтләгәндә асылташ, минерал атамаларын куллану көнчыгыштан үтеп кергән һәм гасырлар дәвамында татарлар арасында әһәмиятен югалтмаган традицияләрнең иң көчлеләреннән санала. Дөнья мәдәниятенә, шул исәптән татар дөньясына, үтеп кергән әкиятләр, поэзия, проза үрнәкләре аларда тасвирланган асылташлар белән, хатын-кыз матурлыгын шул минераллар белән тиңләү таң калдыра. Хатын-кыз гүзәллеген асылташ белән тиңләү кеше исемнәре системасына да күчә. Татарлар арасында киң таралыш тапкан *Гәүһәр, Җәүһәрия, Гөлгәүһәр-Гөлҗәүһәр* (*гәүһәр* – фарсы теленнән, *җәүһәр* – гарәп теленнән, «энҗе бөртеге» мәгънәсенә ия); *Фирүзә, Фирәзә, Фруз/Фруза, Фәйрүзә, Фирүз* (*Фирүз* – борынгы фарсылардан билгеле, парфян патшалары йөрткән әлеге исем «якты, нурлы» мәгънәсенә ия); *Мәрҗән, Мәрҗәнә, Мәрҗәния, Гөлмәрҗән, Мәрҗәнбану* (*мәрҗән* – гарәп теленнән – коралл); *Зөбәрҗәт, Зөмрәт*, *Зөмәррә* (*зөбәрҗәт* фарсы теленнән – «изумруд» мәгънәсендә); *Дөррия, Дөрбану, Дөрбиби, Дөррелбикә, Дөрниса, Мәрвәр, Мәрвия, Мәрвәрит*, *Мәрвәрбану, Гөлмәрвәр, Мәрвәрсылу (дар/дөр,* аның фарсы телендәге мәгънәдәш сүзе *мәрвәр* – «энҗе бөртеге» мәгънәсенә ия).

*Энҗе* сүзен кулланып ясалган хатын-кыз исемнәре борынгы төрки чорда ук билгеле була. *Чжу* (энҗе) сүзе кытай теленнән борынгы чорда ук үтеп керә. Кытайда шулай ук кыз балага асылташ, минерал атамаларын исем итеп кушу традициясе борынгыдан килә. Кыз балага *чжу* компоненты белән исем кушканда аның бердәнбер, кадерле булуын, энҗе бөртегенең гади кабырчыкка яшеренгән матурлыгына тиңләп, баланың рухи яктан да матур булуын телиләр. Борынгы төрки бабаларыбыз чорында ук үтеп кергән традиция ислам дине кабул ителгәннән соң, әлеге мәгънәгә ия яңадан-яңа исемнәр үтеп керүгә сәбәпче була. XX гасырда бу төркем рус һәм көнбатыш телләреннән кергән исемнәр белән тагын да байый: *Энҗе, Энҗия, Энҗебикә; Фәридә* (гарәп теленнән), *Маргарита* (грек теленнән). Асылташ, минерал атамаларын исем

буларак куллану традициясенең дәвамын без XX гасырда *Рубин/ Рубина* (латин теленнән), *Бриллиант* (француз), *Алмаз/ Алмазия* (грек) исемнәрендә дә күрәбез. Татар кешесе асылташ образында матурлык, байлык, муллык, рәхәт тормыш төшенчәләрен күрә. Моннан кала, асылташ атамаларыннан ясалган исем йөртүченең табигый, эчкерсез, саф булуын теләү дә исем кушу мотивларыннан берсе булып тора. Асылташ, минерал образларына салынган *матурлык* төшенчәсендә хатын-кызның тышкы матурлыгы гына түгел, әхлакый сафлыгы да күзаллана.

Хатын-кыз матурлыгын күк җисемнәре белән тиңләү традициясе борынгыдан килә, дидек. Гарәп һәм фарсы телләреннән исемнәр алу барышында бу традиция сакланды, бүгенге көн татар исемнәре системасына күз салсак, без инде көнбатыш телләреннән алынган исемнәрдә дә әлеге традициянең дәвамын күрәбез. Татар телендә кулланыла торган *Зөһрә* исеме Венера планетасының гарәпчә атамасыннан ясалган. Бу исемгә булган игътибар гасырлар буена дәвам итә. Хәзерге татар кеше исемнәре системасында да бу исем үзенең лаеклы урынын биләп тора. Борынгы төркиләрдә кулланылган *Алтын йолдыз* исеме, соңрак төрки-татарларда *Йолдыз,* гарәп теленнән кергән *Зөһрә,* XX гасырда латин теленнән алынган *Венера* исемнәре традицияләр дәвамчанлыгын дәлиллиләр.

Балага матурлык теләү аны матди объектлар белән генә тиңләүгә кайтып калмый, еш кына матурлык төшенчәсен белдергән сүзләр үзләре исем буларак кулланыла. Мондый төр исемнәр бирүнең чишмә башы борынгы чорга тоташа, аерым алганда, татарларда бүгенгә кадәр кулланылып килгән сылу компонентлы *Сылу, Миңсылу, Айсылу, Сылуназ, Сылугөл, Гөлсылу, Нурсылу, Сылуниса* кебек исемнәрне атарга кирәк. XX гасырда татарларда *Гүзәл, Гүзәлия, Гүзәлсылу* исемнәре кушыла башлады. Гарәп һәм фарсы мәдәнияте бу төр исемнәр рәтен тагын да баетты, хатын-кызның матурлыгын төрле яклап сурәтләгән сүзләр исемнәр рәтендә кулланыла башлады. Мәсәлән, хатын-кызның гәүдә матурлыгын тасвирлаган *зифа* сүзе ярдәмендә *Зифа, Зифабикә, Миңзифа, Гөлзифа, Гайнезифа*; матур, гүзәл мәгънәсен белдергән *рана* сүзе ярдәмендә *Рана, Рания;* шул ук мәгънәдәге *дил* сүзе белән *Диләрә, Диләфрүз, Дилбәр, Диләрия*, *Диләрәм;* татар телендә актив кулланыла торган *наз* компоненты кушылып *Айназ, Гөлназ, Илназ, Сәрбиназ, Назлыгөл*, *Шаһназ*, *Сафназ*. *Наз* компоненты башлап

хатын-кыз исемнәре генә ясаса, XX гасыр ахырларыннан алып, ир-ат исемнәре составында кулланылуы арта бара.

Әлбәттә, югарыда санаган исемнәр белән генә матурлык төшенчәсен белдергән исемнәр рәте чикләнми. Гарәп һәм фарсы телләреннән матурлыкны төрле яклап тасвирлаган кеше исемнәре гаять күп, алар хатын-кыз исемлегендә генә түгел, ир-ат исемнәр системасында да зур урын билиләр. Бер төркем исемнәрнең мәгънәсе татар кешесе өчен җиңел аңлашылса, икенчеләренең мәгънәләрен бары тик сүзлекләр ярдәмендә генә белеп була (мәсәлән, *Латыйф/Латыйфа*, *Дилназ*, *Лотфия*, *Зөлфинур, Зөлфия, Зөлфирә, Алчирә, Гөлчирә, Маһруй, Гөлсинә, Нурсинә, Айсинә* һ.б.), ләкин аларның барысы да баланың матур, һәр яклап камил, сәламәт булуын теләүгә юнәлгән.

Телебездә, мәдәниятебездә ныклы урын биләгән ислам традицияләре кеше исемнәре системасында аеруча киң таралган. Ислам дине тәэсирендә үтеп кергән гарәби һәм фарсы чыгышлы исемнәр, татар җирлегендә яңарып, төрки бабаларыбыздан килгән борынгы исем кушу традицияләре белән үрелеп, милли кеше исемнәре системасы формалашуда төп нигез булдылар.

Татар кеше исемнәре системасында рус һәм Европа мәдәниятләре тәэсирендә барлыкка килгән традицияләр.

Татарларның рус, Көнбатыш мәдәнияте белән танышуы күптән башланса да, исемнәр өлкәсендә мондый төр багланышлар булмый, чөнки исем ул – мәдәният көзгесе, башка телдән исем алу өчен, милли психологиядә үзгәреш башланырга тиеш, шуның нәтиҗәсендә генә бер мәдәнияттән икенчесенә исемнәр үтеп керә ала. Ислам идеологиясе тәэсирендә үсеш кичергән татар халкы башка милләтләрнең семиотик билгеләрен кабул итми. XX гасырда булган мәгълүм вакыйгалар халык аңына зур йогынты ясады, ул, әлбәттә, кеше исемнәре системасында кичекмәстән чагылыш тапты.

Октябрь инкыйлабының беренче елларыннан татар тормышына, татар теленә күпләп яңа төшенчәләр, сүзләр, исемнәр килеп керә. Аларның байтагы киң катлам кешеләргә аңлашылмый, әмма үзләренең ят булулары, матур яңгыраулары белән җәлеп итәләр, шунлыктан башлангыч чорда татар исемлегенә эстетик зәвыклы исемнәр белән бергә, мәгънәсез, я булмаса ямьсез эчтәлекле исемнәрнең килеп керүе күзәтелә.

Әлеге төркем исемнәр татар антропонимик системасының үсешендә хәлиткеч борылыш ясарга этәргән бер үзенчәлек алып килде, ул да булса – балага исем кушу мотивларына игътибар кискен кимү, исем сайлаганда аның эчтәлегенә караганда, тышкы яңгырашның төп рольне үтәве. Телебездә яңа берәмлекләрне кабул итү һәм аларны куллану традициясе булмау татар кеше исемнәр системасының нигезе какшауга, тотрыклылык югалуга китерде. Моның төп сәбәбе яңа исемнәрне сайлау традициясе булмауга һәм татар исемлегенең төп нигезен тәшкил иткән дини эчтәлекле исемнәрнең кулланылыштан төшеп калуы нәтиҗәсендә халыкның югалып калуына кайтып кала. Балага исем сайлаганда, яңалыкка омтылу, сүзнең матур яңгырашына гына игътибар итеп, мәгънәсен бик аңлап җиткермәү нәтиҗәсендә татарларда исем саф символ, билге сыйфатында кулланыла башлады. Моңа мисал итеп, *Рафаэль, Ренат, Фердинанд, Эдуард, Эдвард, Марсель, Алиса, Аида, Венера, Луиза, Римма, Эльза, Эльмира, Флера, Лилия, Эльвира* һ.б. исемнәрне китерергә була.

Рус һәм Европа телләре һәм мәдәниятләре тәэсирендә татар кеше исемнәре системасында түбәндәге үзенчәлекләр барлыкка килде:

балага бу төр исемнәрне кушканда эчке мәгънә белән бәйләнешкә, исем бирү мотивларына битарафлык;

традицион рус исемлегеннән антропонимнар алу, мәсәлән, *Арина, Вера, Оксана, Светлана, Андрей, Борис, Валерий, Валериан, Виктор, Измаил, Леонид, Олег, Денис* һ.б.;

яңа идеологияне пропагандалаган инкыйлаби эчтәлекле исемнәр куллану һәм кыскартылма исемнәр уйлап табу күренеше: *Вил, Мэлс, Вилор, Марлен, Марклен, Лемар, Ленарис, Лесталь; Вилен, Лениза, Ленар, Ревнер*. Исемнәр сайлауда югары зәвыкка, сәнгати эзләнүләргә йөз тоткан халкыбыз, бәхеткә, бу төр исемнәрнең мәгънәсез булуына тиз төшенде: алар XX гасырның 40 нчы елларына кадәр актив рәвештә балаларга кушылса, соңыннан бөтенләй кулланылыштан төшеп калдылар. Бүгенге татар исемлегендә *Лениза, Ленар, Дамир* кебек матур яңгырашлы берничә исем генә яшәвен дәвам итә;

рус теле аша күмәклек сүзләрдән яисә географик объект атамаларыннан ясалган исемнәр килеп керүе дә күзәтелә. Мәсәлән: *Уран/Урания, Радий, Идея, Марс, Марсель/Марсил, Рим, Эльбрус/*

*Ильбрус, Казбек, Адлер, Индия*, *Атлас, Бриллиант, Идеал, Азия* һ.б.;

бер төркем алынмаларда татар исемнәр хәзинәсенең нигезендә яткан традицияләр буенча исем сайлау тенденциясе ачык күренә, мәсәлән, үсемлек дөньясын чагылдырган исемнәр, асылташ атамаларына нигезләнеп ясалган исемнәр: *Лиана, Лилия, Роза, Ландыш, Рубин, Алмаз* һ.б.;

Көнбатыш мифологиясеннән аллалар һәм аерым геройлар исемнәре үтеп керә: *Марс* (сугыш алласы), *Амур* (мәхәббәт алласы), *Атлас* (борынгы рим мифологисендә титан исеме), *Спартак* (баш күтәргән гладиаторлар башлыгы), *Индира* (борынгы һинд мифологиясендә сугыш, яшен алласы. Татар халкы арасында таралуы И. Гандиның популярлыгы белән аңлатыла), *Аида* (борынгы грек мифологиясендә Аид – җир асты патшасы), әлеге исемнең рус, татар һәм элеккеге Советлар Союзы территориясендә яшәгән халыклар арасында популярлыгы Дж. Вердиның «Аида» операсы белән бәйле, шулай ук *aida* сүзе гарәп телендә «файда» мәгънәсенә ия. Исемнәрне өйрәнүче галимнәр *Аида* исеменең килеп чыгышын әлеге сүз белән дә бәйләп карыйлар;

XX гасыр ахырларыннан хәзергәчә чорда антропонимиконда татар милли, традицион исемнәренә аваздаш, тышкы формалары охшаш исемнәргә игътибар арту: *Камилла – Камилә, Аделина/Адель – Адилә/Гадилә, Карина – Кәримә, Тимер – Тимер, Руслан – Арыслан* (соңгы ике исем этимологик яктан төрки телгә барып тоташа);

татар традицион исемнәр системасына яңа традициянең – исем составында моңарчы бөтенләй булмаган, я булмаса бик сирәк кулланылган элементларның бик нык активлашуы: *Элдар, Элиза, Эллина, Элиса, Эльвар, Эльвин, Элзилә, Эльмин, Эльнар, Элнара, Эльшад, Эмир, Энвер, Эрик, Эрлан* һ.б.

Шулай итеп, татар кеше исемнәре системасында хәзерге көндә исем бирү традицияләре һәм мотивлары билгеле бер дәрәҗәдә трансформация кичерә, борынгыдан килгән төрки мотивларга нигезләнгән, ислам дине һәм Көнчыгыш мәдәнияте тәэсирендә камилләшкән һәм үсешендә яңа бер баскычка күтәрелгән исемнәр, рус һәм Европа традицияләре йогынтысында сан ягыннан гына түгел, сыйфат ягыннан да үзгәрә, балага исем сайлаганда антропонимның эчке потенциалы түгел, тышкы формасы төп рольне уйный башлый.

## § 7. Татар кеше исемнәренең төзелеш-ясалышында төп үзенчәлекләр

Татар телендә кеше исемнәренең ясалышы шактый үзенчәлекле һәм үз эченә төрле ысулларны берләштерә. Ономастик катламнарның башкаларында шактый пассив күренеш булган фонетик вариантлылык антропонимик системада продуктив ысуллардан санала (мәсәлән: *Туйкилде ~ Туйгилде, Буранкол ~ Бурангол, Замфира ~ Земфира ~ Зәмфирә, Рәмиз ~ Рәмис* һ.б.). Бу аңлашыла да, чөнки ялгызлык исемнәрендә эчке мотивациягә караганда, аларның тышкы формасы, яңгырашы, авазлар тудырган ассоциацияләр әһәмиятле роль башкара, исем сайлау барышында антропонимның бу үзенчәлеге беренче планга чыга. Татар кеше исемнәре системасында фонетик вариантлылык исем сайлау мотивларына гына тәэсир итеп калмый, орфографик хаталар барлыкка китерә, шунлыктан бу мәсьәләне алдагы бүлекчәдә тулырак карап үтәрбез.

Еш кына фонетик вариантларның һәрберсе мөстәкыйль исем буларак та кабул ителә башлый, мисал өчен *Адел – Гадел, Адилә – Гадилә, Алия – Галия*, *Нәргиз~Нәркис* һәм башка шундый төрле исемнәрне китерергә була.

Татар антропонимиконында кушымчалау ысулы белән исем ясалышының түбәндәге киң таралыш тапкан үзенчәлекләре күзәтелә:

1. *-а/-ә, -ия* кушымчасы ярдәмендә кеше исемнәре ясалышы татар телендә иң киң таралган ысуллардан санала. Башлыча бу кушымча хатын-кыз исемнәрен ясыйлар, шунлыктан аларны женес төрләнешен күрсәткән билге буларак та кабул итәргә мөмкин. Род/женес категориясе булмаган телләрдә аерым бер женескә карауны белдерү максатыннан сүз ясалыш чаралары, аерым лексик берәмлекләр (мәсәлән, татар антропонимиконында матурлык төшенчәсен белдергән исемнәрнең зур күпчелеге – *Иркә, Сылу, Гүзәл, Чәчкә*, аерым титул атамалары – *Бикә, Бану* хатын-кыз женесен белдерүдә катнаша) кулланыла. Татар теленең исемнәр системасында бу рольне югарыда аталган кушымчалар башкара. Алар, башлыча, гарәп һәм фарсы телләреннән кергән исемнәргә кушылып, хатын-кыз исемнәрен ясыйлар. Мәсәлән: *Назыйм – Назыйма, Таһир – Таһира, Вәсил – Вәсилә, Мөнир – Мөнирә, Мәгъсүм – Мәгъсүмә, Газиз – Газизә, Зәки – Зәкия, Габит – Габидә, Салих – Салиха, Гали – Галия* һ.б. Әлеге кушымча этимологик яктан

гарәп теленә барып тоташа һәм татар теленә исемнәр алынганда, шул тел үзенчәлеге буларак килеп кергәннәр (Галиуллина, 2008: 248). Соңрак татар телендә барлыкка килгән яңа татар исемнәре дә бу кушымча ярдәмендә ясала башлый. Мәсәлән: *Дамир – Дамира, Динар – Динара, Илгиз – Илгизә, Руслан – Руслана, Илнар – Ильнара, Илһам – Илһамия, Илдар – Илдария.*

Хәзерге татар исемнәре ясалышында әлеге кушымчалар түбәндәге үзенчәлекләргә ия:

1) гарәби һәм фарсы чыгышлы ир-ат исемнәренә ялганып, хатын-кыз исемнәре ясыйлар: *Әмир – Әмирә, Сәит – Сәидә, Самир – Самирә;*

2) яңа татар һәм Европа телләреннән кергән исемнәргә ялганып, хатын-кыз исемнәре ясыйлар: *Идел – Иделә – Иделия, Марсель – Марсела – Марсилә - Марсилия, Уран – Урания, Алмаз – Алмазия*, *Нурлан – Нурлана*;

3) аерым хатын-кыз исемнәренә ялганып, төрдәш исемнәр ясыйлар: *Гүзәл – Гүзәлия, Гөлнар – Гөлнара, Гөлфәр – Гөлфәрия, Рауза – Раузия, Иркә – Иркия, Назлы – Назлия*;

4) бинар исемнәргә ялганып, хатын-кыз исемнәре ясыйлар: *Раушан –Раушана – Рушания, Фирдәүс – Фирдәүсә, Нәргиз – Нәргизә, Җәүһәр – Җәүһәрия;*

5) хатын-кыз исемнәрендәге әлеге кушымчалар төшеп калып, ир-ат исемнәре ясала: *Назилә – Назил, Альмира – Альмир, Эльмира – Эльмир, Радмила – Радмил, Ильвина – Ильвин.*

2. *-лы/-ле* кушымчасы ярдәмендә исем ясалу ономастик даирәнең башка катламнарында актив булса да, кеше исемнәрендә актив кулланылмый, аны күбрәк кушма төзелешле исемнәрнең беренче компоненты буларак очратырга мөмкин: *Назлы + гөл, Нурлы + җиһан, Нурлы + хода, Миңне + зөһрә, Миңле + нур, Миңле + заһир* һ.б.

3. *-кай/-кәй* иркәләү-кечерәйтү кушымчасы ярдәмендә исем ясалу очраклары*: Гөлкәй, Илкәй, Тукай, Иркәй*. Бу кушымча исламгача булган чорда да актив кулланылышта була: *Йорткай, Тумакай, Күскәй, Алкай, Илкәй, Каракай, Тимеркәй, Әбзикәй, Җизкәй*; *Чуракай, Күзкәй, Тиңкәй, Абакай, Ташкай, Камкай, Йөзлекәй, Котлыкай.*

Фарсы теленнән кергән *-дар* компоненты ир-ат исемнәре ясауда катнаша: *Айдар, Сердәр*, *Илдар, Гыйлемдар* (гыйлем), *Сәрдәр* һ.б.

Гарәп теленнән кергән *-ат* кушымчасы ярдәмендә *Илфират, Рәфигать, Фәсихәт, Нәүфәт, Фидаят* кебек исемнәр ясалган.

Татар кеше исемнәре ясый торган актив антропокомпонентлардан түбәндәгеләрне күрсәтергә кирәк:

– төрки чыгышлы актив антропокомпонентлардан ***бикә:*** *Гөлбикә, Нурбикә, Миңлебикә;* ***бик/бәк:*** *Биктимер, Бикмөхәммәт, Бикбулат, Нурбәк, Галибәк, Айбәк, Алимбәк;* ***хан:*** *Хантимер, Ханвәли, Ханбәк, Ханбулат, Хан, Тимерхан, Миңлехан, Айхан, Ирхан, Илхан, Гыйлемхан, Мөхәммәтхан;* ***тимер:*** *Тимеркәй, Тимербулат, Тимерҗан, Тимергали, Тимерлан, Миңтимер, Җантимер, Байтимер, Айтимер* кебекләрен атарга кирәк.

– фарсы теленнән кергән ***задә*** компоненты кулланылып, ир-ат һәм хатын-кыз исемнәре ясала: *Гөлзадә*, *Илзадә*, *Шаһзадә*, *Нурзадә*, *Айзадә;* фарсы теленнән кергән ***биби, бану, гөл, маһи*** компонентлары: *Гөлбану, Зәйнәпбану, Маһирбану, Миңлебану, Сәгадәтбану, Сәйдәбану*; *Бибибану, Бибизәйнәп, Бибикамал, Бибинур, Бибигаян, Бибигайшә, Бибисара, Бибиҗиһан*; *Гөлнәзирә, Гөлҗамал, Гөлшаһидә, Гөлзәйнәп, Гөлшат, Гөлнара, Гөлназ, Гөлсирин; Наргөл, Нургөл, Фаягөл; Маһибәдәр, Маһиҗамал, Маһикамал, Маһинур, Маһитап, Маһисорур, Маһибану* һ.б.

Шулай ук фарсы теленнән кергән ***шаһ, җан*** ир-ат исемнәре ясагыч компонентлары: *Шаһидулла, Шаһмансур, Шаһиулла, Шаһиәхмәт, Шаһгали, Шаһвәли, Мәхмүтша, Вәлиша, Мөхәммәтша, Гаделша, Мөбәрәкша; Җантимер, Җанәхмәт, Җангали, Җаннур, Әмирҗан, Галимҗан, Закирҗан, Сабирҗан, Салихҗан, Сәлимҗан, Фазылҗан, Хәмәтҗан, Хәсәнҗан* һ.б.

Гарәп теленнән кергән ***габд-, габде-, габдел-:*** *Габдулла, Габделрахман, Габделбакый, Габделсамат, Габделхәбир, Габделхәким, Габделҗан*; ***алла – улла:*** *Галимулла, Гарифулла, Зәбирулла, Идиятулла, Кәримулла, Нәбиулла, Нигмәтулла, Сабирулла;* ***дин:*** *Динәхмәт, Динмөхәммәт, Динислам, Акмалетдин, Борһанетдин, Гайнетдин, Имаметдин, Камалетдин, Мөхәммәтдин, Садретдин* һ.б.

Сүзләр кушылу (исем компонентлары кушылу) юлы белән ясалган кеше исемнәре татар телендә зур күпчелекне тәшкил итә һәм бу озак дәверләр аралыгында формалашкан исемлегебезнең төп сыйфатларыннан берсе санала. Татар телендә кушма исемнәрнең түбәндәге модельләре киң таралган:

1. Исем + исем: *Ай + гөл < Айгөл, Таң + су < Таңсу, Ил + дан < Илдан, Ай + булат < Айбулат Ай + җан < Айҗан* һ.б.

2. Исем + сыйфат: *Миң + зифа < Миңзифа, Ай + сылу < Айсылу, Гөл + саф < Гөлсаф, Биби + садә < Бибисадә.*

3. Сыйфат + исем: *Назлы + гөл < Назлыгөл, Ал + гөлем < Алгөлем, Асыл + бикә < Асылбикә, Миңле + камал < Миңлекамал, Нурлы + камал < Нурлыкамал, Гыйльми + бану < Гыйльмибану*

4. Сыйфат + сыйфат: *Миңле + сылу < Миңлесылу, Зифа + сылу < Зифасылу.*

5. Исем + кисәкчә: *Гөл + генә < Гөлгенә, Ил + генә / гинә < Илгенә, Илгинә.*

6. Исем + фигыль: *Гөл + үсә < Гөлүсә, Ил + үсә < Илүсә, Ил + сөяр < Илсөяр , Ил + гизәр < Илгизәр, Ил + төзәр < Илтөзәр, Ай + туган < Айтуган* һ.б.

Татар халкында исем ясауда үзенчәлекле бер сыйфат булып яңа исемнәр ясау сәнгате тора. Исемнәр уйлап табу һәм аны яңа туган балаларга кушу процессы XX гасырның 20 нче еллар урталарыннан аеруча җанланды. Дәүләтнең диннән аерылуы нәтиҗәсендә балаларга исем сайлауда ирек бирелде, ата-аналар балаларга үзләре теләгәнчә исем кушарга омтылдылар, кайбер гаиләләрдә бала исеменең оригиналь, кабатланмас булуына зур игътибар бирелә башлады. Исем ясау процессы халык иҗаты дәрәҗәсенә күтәрелде. Яңа исем гаилә өчен генә актуаль, билгеле булган гаять әһәмиятле мизгелләрне, шәхесләрне, вакыйгаларны чагылдыра. Башкалар өчен исем кушу мотивы, ясалу үзенчәлекләре аңлашылмаска да мөмкин. Шунлыктан ясалган исемнең мотивын, мәгънәсен ачыклау бик авыр, аны гаилә әгъзалары белән якыннан аралашу, сорашу нәтиҗәсендә генә белеп була. Мөгаен, шул сәбәпледер, татар исемнәр системасында кулланылышта йөргән исемнәрнең аңлатмалы сүзлеген төзү, мәгънәсен ачыклау процессы да шактый катлаулылардан санала. Күзәтүләрдән күренгәнчә, гаиләдә уйлап табылган исемне кушу иҗтимагый-сәяси стабильлек булмаган чорда бик активлаша. Татар телендә исем ясау сәнгатенең чәчәк ату чоры Октябрь инкыйлабыннан соң башлана һәм төрле дәрәҗәдә бүгенге көнебезгә кадәр дәвам итә. Бу процесс активлашуның икенче этабы XX гасыр ахыры – XXI гасыр башына туры килә.

Исем ясау түбәндәге юнәлешләрдә бара:

1. Традицион исемнәрнең берәр хәрефен яисә исем өлешен үзгәртеп ясалган исемнәр. Бу төр исемнәр телдә кулланылышта йөргән исем модельләре нигезендә ясала. Мәсәлән, *Альвина* исеме татар телендә кулланылышта йөргән *Альбина* исеменнән, *Эльдар* исеме традицион *Илдар* антропонимыннан ясалган. *Эльнур > Илнур, Элмас > Алмас, Эльфат > Илфат, Дилора > Диләрә, Эльвина > Эльвира, Алзирә, Элзирә > Илзирә, Алсинә > Илсинә, Илмар > Илмир, Эльнара > Илнара, Салминаз, Салбиназ > Сәрбиназ, Айназ > Гөлназ* һ.б.

2. Еш кына кушма төзелешле исемнәрнең бер өлешен үзгәртеп яңа исем ясау күзәтелә: *Назгөл > Гөлназ, Наргөл > Гөлнар, Нуршат > Гөлшат, Илшат, Гөлшан > Гөлшат, Илсун > Илсур, Ирхан, Илдан* (татар телендә ир балаларга кушыла торган *Илхан* исеме бар), *Алгөлем, Айзинә*.

3. Баланың ата-анасы, якыннарының исемнәрен кушу юлы белән ясалган исемнәр: *Нурфидә > Нурания* һәм *Фирдания* исемле өлкән кызларының исемнәрен кушып ясалган исем; *Нилфәр* (ир бала исеме) > *Наил + Фәридә; Раннур > Ранис + Нурия; Залевиль* (ир бала исеме) > *Зәлия* (ата-анасы исемнең рус телендәге яңгырашындагы беренче иҗекне кулланган); *Далвас* (ир бала исеме) > *Далия + Васил, Зариус* (ир бала исеме) > *Зарифа + Усман.*

4. Мәгънәләрен аңлап булмый торган исемнәр: *Билгус, Рейнард, Даниф (Данис?), Радэль, Адина, Эрлан, Эльмин, Эльман, Риана, Радем, Рувлан* һ.б.

5. Рус һәм Европа телләре үрнәгендә яңа исем ясау: *Рузана, Рушана, Раяна, Идалия, Алан/Аллан/Элан, Мариам, Найли, Ринэль.*

5. Рус яисә Көнбатыш телләреннән кергән күмәклек сүзләр ярдәмендә исем ясау күренеше телебездә XX гасырның 70 нче елларына кадәр күзәтелде. Бу төркемгә кергән исемнәрнең күбесе сирәк кулланылышка ия һәм вакыт сынавын үтмичә, төшеп калдылар: *Фикус, Фарил/Фарель, Фрак, Эрот, Флюс*, *Флюсә, Лира, Термос, Дизель, Заря, Дельфин, Греф, Лимон* һ.б. Исемнәргә хас булмаган тискәре мәгънәләре белән ямьсез ассоциация уяткан бу исемнәрнең кулланылыш традицияләре һәм үсеш җирлекләре булмады.

Шулай итеп, исем ясау сәнгате татар халкы тормышында үз урынын тапкан, асылда ул гасырлар дәвамында килгән традицияләргә нигезләнеп башкарыла. Әлеге юл белән татар исемнәр

системасын баетуның уңай ягы булып соңгы елларда шактый таралган татар антропонимиконының яңа берәмлекләр белән баюы тора, очраклы бер көнлек исемнәр уйлап табылса да, алар, халыкның эстетик зәвыгына туры килмәгәнлектән, кулланылышка кереп китә алмыйлар.

Нәтиҗә ясап, татар кеше исемнәренең ясалыш модельләре һәм юллары күптөрле булуын, шулар арасында уңышлылары булган кебек, очраклы, вакытлы берәмлекләр ясалуын дә белгеләргә кирәк.

### § 8. Татар кеше исемнәренең орфографиясе һәм транслитерация мәсьәләсе

Кеше исемнәренең язылышы һәм башка телләрдә бирелү мәсьәләсе ономатологлар хезмәтләрендә даими игътибар үзәгендә тора. Бу аңлашыла да, чөнки бу төр берәмлекләрнең орфографиясе лингвистик проблема гына түгел, ул хокукый, социологик, психологик һәм башка аспектларда да мөһим. Исемнәр язылышындагы төрлелек кешенең җәмгыятьтәге урыны, яшәеше, туганлык мөнәсәбәтләре юнәлешендә дә шактый кыенлыклар тудырырга мөмкин. Татар телендәге кеше исемнәре һәм фамилияләрнең язылышы, аларны рус телендә бирү үзенчәлекләре фән һәм белем бирү оешмаларында гына түгел, дәүләт һәм муниципаль структураларында да өйрәнү, куллану объектына әйләнде. Татар телендәге кеше исемнәрен унификацияләү, аларны рус телендә бирүнең актуальлеге загс һәм мәгълүмат чараларының көндәлек эшчәнлегендә дә нык сизелә. Әйтергә кирәк, татар кеше исемнәре орфографиясе һәм аларны башка телләргә транслитерацияләү проблемалары махсус тирәнтен эзләнүләр сорый, әлегәчә бу юнәлештә диахроник планда эшләнгән, проблеманы тирәнтен яктырткан хезмәтләр юк дәрәҗәсендә.

Хәзерге вакытта татар телендә 15 меңнән артык кеше исеме бар дип исәпләнә. Бу состав туктаусыз үзгәреп, тулыланып тора, шунлыктан татар антропонимиконы орфография күзлегеннән даими җентекле тикшерүгә һәм унификацияләүгә мохтаҗ. Татар графикасының берничә тапкыр алмашынуы, XX гасырда исемнәр системасында яңа исемнәрнең күпләп барлыкка килүе һәм бу процессның орфографик планда ирекле баруы телдә вариантлылыкка юл калдырды. Югарыда әйтелгәнчә, исемнәрнең язылышы

лингвистик проблема гына түгел, юридик планда да әһәмиятле булуын искә алсак, бала тугач, аны теркәгәндә язылган исем вариантын үзгәртү шактый кыенлыкларга һәм хокукый чикләүләргә очрый. Шунлыктан бер үк исемнең төрлечә язылган вариантларын татар телендә күпләп очратырга була. Мәсәлән: *Фәим/Фәймә – Фәһим/Фәһимә, Фуад – Фуат – Фоат – Фоад, Ренат – Ринат – Ренад – Ринад, Замфира – Земфира – Зәмфирә, Флера – Флюра – Флүрә, Ленар/Ленара – Линар/Линара* һ.б. Кайбер очракларда татар халкы арасында аларның бер төркеме мөстәкыйль исемнәр буларак та кабул ителә, моңа мисал итеп *Флера – Флюра – Флүрә, Розалия – Рузалия, Әдһәм – Әзһәм, Рәдинә – Рәзинә, Рәзиф – Рәдиф* һәм башка шундый төрдәге исем вариантларын китерергә мөмкин.

Вариантлылык телнең фундаменталь үзенчәлекләреннән санала һәм ул тел берәмлекләренең барысы өчен дә хас күренеш. Вариантлылык дигәндә, тел берәмлекләренең төрлечә бирелеше, модификациясе, тел нормасыннан читләшүе күздә тотыла. Антропонимик системада вариантлылык башка төр берәмлекләргә караганда киңрәк таралыш тапкан. А.В. Суперанская билгеләвенчә, вариантлылык ялгызлык исемнәренең асылына салынган. Бу аларның апеллятив, төшенчә белән бәйләнеше көчсез булганлыктан һәм телнең мөмкинлекләренә (бер үк фактларны, күренеш һәм мөнәсәбәтләрне төрлечә бирү ысуллары) бәйле барлыкка килә (Суперанская, 1969: 171).

Татар телендә исемнәрнең фонетик вариантлары кулланылу төрле факторларга бәйле. Вариантларның берише тел кулланылышына бәйле ихтыярсыз, мәҗбүри барлыкка килсә, икенчеләре исә очраклы, факультатив була. Татар телендәге вариантлылык мәсьәләсенең тарихы (аеруча фонетик вариантлылык киң таралган булуын ассызыклау зарур) күптәннән килә. Төрки-татар антропонимиконы үсешенең башлангыч чорында ук барлыкка килсә дә, бу күренеш XX гасырда исемнәрне унификацияләү мәсьәләсе тугач, аеруча мөһим проблемага әйләнде.

Татар исемнәрендәге вариантлылыкның иң киң таралган төре, алда билгеләгәнчә, фонетик вариантлылык санала. Ул графикага бәйле барлыкка килә. Татар телендәге төп язма истәлекләр гарәп графикасы белән язылганлыгын, ә аның татар авазлары системасына туры килмәвен галимнәр, аерым алганда, Х.Р. Курбатов,

М.И. Мәхмүтов, В.Х. Хаков, Ф.М. Хисамова, Җ.Г. Зәйнуллин һәм башкаларның хезмәтләрендә әйтелде. Тикшерүләр күрсәткәнчә, төрле чорларда кергән гарәп һәм фарсы алынмалары татар теленең орфографик һәм орфоэпик нормаларына һәрчакта да туры килеп бетми. Бу аеруча кеше исемнәре системасында күзгә ташлана. Аларның график формасы беркадәр читтә калып килде, гәрчә сөйләмдә аларның зур күпчелеге телебезнең фонетик нормаларына буйсындырылып әйтелсә дә. Исемне теркәүченең ни рәвешле язып куюы, язылышта нинди вариант кулланылуы алга таба татар телендәге исемнәрнең фонетик вариантлары таралуга китерде. Аның киң таралышын һәм документаль расланган вариантларын без Казан ханлыгы яулап алынганнан соң теркәлгән документларда, мисал өчен, XVI–XVII гасырларда һәм соңрак чорларда тупланган Писцовый кенәгәләрдә, башка төр шундый язма чыганакларда очратабыз. Исемнәрнең тулысынча диярлек үзгәртелгән вариантлары, соңрак рус язма чыганакларында таралыш табып, тора-бара аларның кайсы тел берәмлеге икәнен дә аңлап булмас дәрәҗәгә җиткән очракларны күзәтергә мөмкин. Мәсәлән: *Таңатмыш – Тагатмыш, Ходайбирде – Кувабердеи, Тәңребирде – Терибердеи, Акбулат – Ахпалат, Алмас – Олмас* һ.б. (Галиуллина, 2014: 196).

XX гасырда Октябрь инкыйлабыннан соңгы беренче дистә елларда загс хезмәткәрләренең игътибарсызлыгы яки язылышны белмәве бу процессны тагын да киңрәк масштабка чыгарды. Тагын шуны ассызыкларга кирәк, татар халкы арасында махсус рәвештә традицион исемнәрне үзгәртеп, охшаш вариантлар ясау күренеше дә киң таралган. Мәсәлән: *Ирек – Эрик, Илдар – Элдар, Элиза – Эллиза, Илзилә – Элзилә, Ирлан – Эрлан* һ.б. Бу төр вариантлар семантик яктан да, эстетик зәвык һәм миллилек ягыннан да эчтәлеккә ия түгел.

Шулай итеп, татар исемнәре системасында һәм сузыклар, һәм тартыклар өлкәсендә фонетик вариантлар барлыкка килде.

Хәзерге татар кеше исемнәре өлкәсендә киң таралган рәсми вариантларның төрләрен карап үтик, биредә диалекталь сөйләмдә кулланылган вариантлар каралмый. Орфографик нормаларга туры килгән вариантлар аерып күрсәтелде:

1. Сузыклар чиратлашуы өлкәсендә түбәндәге типик вариантларны очратырга мөмкин: ***ә ~ а:*** *Рәбига ~ Рабига; Һадия ~ Һәдия, Әлинә ~ Алинә, Фаез ~ Фәез;* ***и ~ е:*** *Линар ~ Ленар, Линиза ~*

*Ленизa;* ***о ~ у:*** *Розалия ~ Рузалия, София ~ Суфия, Вилсор ~ Вилсур;* ***е ~ э:*** *Рафаель ~ Рафаэль, Радель ~ Радэль;* ***и ~ э:*** *Ирек ~ Эрик, Илина ~ Элина, Имиль ~ Эмиль, Илнар ~ Элнар, Илвар ~ Элвар, Илназ ~ Элназ;* ***ә ~ э:*** *Әмир ~ Эмир, Әнвәр ~ Энвер* һ.б.

2. Тартыклар чиратлашуга бәйле исем вариантлары: ***д ~ т:*** *Мөхәммәд ~ Мөхәммәт, Мәхмүд ~ Мәхмүт, Рафид ~ Рафит, Хәмид ~ Хәмит, Фуад ~ Фуат, Азад ~ Азат, Морад ~ Морат, Илшад ~ Илшат, Заһид ~ Заһит, Эдуард ~ Эдуарт, Эдвард ~ Эдварт, Фердинанд ~ Фердинант, Радмир ~ Ратмир;* ***г ~ х ~ к:*** *Мәргубә ~ Мәрхубә, Мәсгуть ~ Мәсхуть ~ Мәскут, Нәргиз ~ Нәркис, Әсгәр ~ Әскәр, Әсгать ~ Әскать;* ***з ~ с:*** *Рәмиз ~ Рәмис, Гөлназ ~ Гөлнас, Азим ~ Асим, Фәриз ~ Фәрис, Нәргиз ~ Нәркис, Илгиз ~ Илгис;* ***д ~ з:*** *Дөфәр ~ Зөфәр, Әбудәр ~ Әбузәр, Элида ~ Элиза, Әдһәм ~ Әзһәм, Рамазан ~ Рамадан, Рәдинә ~ Рәзинә;* ***җ ~ й (я):*** *Җәзилә ~ Язилә, Җәсминә ~ Ясминә; б~п: Зәйнәб ~ Зәйнәп, Якуб ~ Якуп.*

Сүз башында көнбатыш диалектка хас үзенчәлек булган «г» фонемасын төшереп калдыру юлы белән барлыкка килгән вариантлар: *Габдулла ~ Абдулла, Гали ~ Али, Гаяз ~ Аяз, Газиз ~ Азиз, Газизә ~ Азизә, Гадил ~ Адил, Гадел ~ Адел, Гадилә ~ Адилә, Галия ~ Алия, Гамилә ~ Амилә, Гайшә ~ Айшә* һ.б.

Мондый төр вариантлылык исемнәр системасының яшәешен, аны тәртипкә салу мәсьәләсен шактый авырайта, шунлыктан җыелган материалны унификацияләү мәсьәләсе, бу өлкәдә тиешле тәҗрибә булмаганлыктан, шактый катлаулы эш. Татарча кеше исемнәре орфографиясе, аларның рус телендә бирелеше аерым очракларда яңалык та булып тора. Бу – табигый күренеш. Күп гасырлар буена хата белән язылып килгән кеше исемнәренең дөрес язылышын берьюлы тулысынча хәл итергә мөмкин түгел.

Татар кеше исемнәренә бәйле бу кыенлыклардан арыну юнәлешендә 2006 елда Г.Ф. Саттаров, Р.Г. Әхмәтьянов, Ф.Ә. Ганиев, И.А. Абдуллин, Г.С. Сабирҗанов, К.Р. Галиуллин, Г.Р. Галиуллиналар тарафыннан әзерләнгән, паспорт һәм загс идарәләре хезмәткәрләренә, төрле дәүләт оешмаларына, массакүләм мәгълүмат чараларына татар кеше исемнәре һәм фамилияләренең орфографиясе буенча кулланма буларак, «Татарча-русча кеше исемнәре һәм фамилияләр сүзлеге» дөнья күрде. Биредә татар ир-ат һәм хатын-кыз исемнәре, фамилияләре, ата исемнәренең татар һәм рус телләрендә дөрес язылышы, транслитерация, кушымчалар ялгану

үзенчәлекләре тәкъдим ителә. Түбәндә шул сүзлектә бирелгән кайбер материалларкулланылды.

1. Нечкә нигезле татар исемнәренең уртасында яки ахырында килгән *ә* хәрефе *л* хәрефеннән соң рус телендә *я* хәрефе белән бирелә: *Гөләндәм – Гуляндам, Ләбиб – Лябиб, Фәләх – Фалях, Камилә – Камиля, Вәсилә – Василя, Тәнзилә –Танзиля.*

2. Исем уртасында килгән *ә* хәрефе *л* хәрефеннән соң килеп, *ә* хәрефеннән соң *й* хәрефе килсә, *ә* хәрефе рус телендә *е* хәрефе белән бирелә: *Зөләйха – Зулейха, Ләйсән – Лейсан, Ләйлә – Лейля.*

3. Нечкә нигезләрдә *ә* хәрефе *к* хәрефеннән соң килсә, ул рус телендә *я* хәрефе белән бирелә: *Иркә – Иркя, Чәчкә – Чачкя, Бикә – Бикя (Сююмбикя).*

4. Башка очракларда кеше исемнәрендәге *ә* хәрефе, кагыйдә буларак, *а* хәрефе белән белдерелә: *Зәки – Заки, Кәрим – Карим, Мөршидә – Муршида, Мәүлидә – Маулида, Әдһәм – Адгам.*

5. Татар исемнәрендәге *ө* хәрефе, кагыйдә буларак, *у* хәрефе белән бирелә: *Гөлнур – Гульнур, Зөлфәт – Зульфат, Өлфәт – Ульфат, Мөбарәк – Мубарак.*

6. Татар исемнәрендәге *ө* һәм *о* хәрефләре, алдагы *й* хәрефе белән бергә килгәндә, *ю* хәрефе белән бирелә: *Гөлйөзем – Гульюзум, Йөзембикә – Юзумбикя, Йолдыз – Юлдуз.*

7. Татар исемнәрендәге *о* хәрефе рус телендә *у* хәрефе белән бирелә: *Котдус – Кутдус, Морат –Мурат, Солтан – Султан.*

8. Татар исемнәренең уртасында килгән *е* хәрефе, *[ө]* авазы кебек әйтелсә, рус телендә *у* хәрефе белән бирелә: *Гөлсем [гөлсөм] – Гульсум, Йөзем [йөзөм] – Юзум.*

9. Исем уртасындагы *ы* хәрефе, *[о]* авазы кебек әйтелсә, рус телендә *у* хәрефе белән бирелә: *Йосыф [йософ] – Юсуф, Очкын [очкъон] – Учкун.*

10. Татар исемнәрендәге *ү* хәрефе рус телендә, кагыйдә буларак, *у* хәрефе белән бирелә: *Фәнүзә – Фануза, Әнүзә – Ануза, Мәхмүт – Махмут, Рәүф – Рауф.*

11. Татар исемнәренең уртасында килгән *ү* хәрефе, нечкә сузык янындагы *л* хәрефеннән соң килсә, ул рус телендә *ю* хәрефе белән бирелә: *Илүсә – Илюса, Гөлүсә – Гулюса, Илүзә – Илюза.*

12. Татар исемнәрендәге *ң* хәрефе рус телендә *н* хәрефе белән бирелә: *Таңсылу – Тансылу, Миңнурый – Миннури, Миңлехан – Минлехан, Миңлеяр – Минлеяр.*

13. Татар исемнәрендәге һәм фамилияләрендәге *җ* хәрефе рус телендә өч төрле юл белән бирелә:

1) *дж* хәрефләре белән: *Җәлил – Джалиль*, *Җәүдәт – Джаудат*, *Галимҗан – Галимджан*, *Хуҗа – Ходжа (Ходжа Насретдин)*, *Хаҗи – Хаджи (Хаджимурат);*

2) хатын-кыз исемнәрендәге *җ* хәрефе рус телендә *ж* хәрефе белән дә бирелергә мөмкин: *Мөнҗия – Мунжия*, *Энҗе – Энже*, *Хаҗирә – Хажира;*

3) исемнәр ясаганда *җ* хәрефе рус телендә *з* хәрефе белән дә бирелергә мөмкин: *Хаҗинур – Хазинур, Галимҗан – Галимзян.*

14. Татар исемнәрендәге *һ* хәрефе рус телендә *х* хәрефе белән бирелә: *Гәүһәр – Гаухар, Шаһморат – Шахмурат, Зөһрә – Зухра, Һидият – Хидият, Һади – Хади.*

Аерым очракларда *һ* хәрефе *г* хәрефе белән дә бирелергә мөмкин: *Заһит – Загит, Заһир – Загир, Шиһап – Шигап, Фәһим – Фагим, Борһан – Бурган.*

15. Татар исемнәре уртасындагы *ый* рус телендә *и* хәрефе белән бирелә: *Сәгыйр – Сагир, Сәгыйть – Сагит, Гыйлемхан – Гилемхан, Гасыйм – Гасим.*

Исем уртасындагы *ый* рус телендә *ы* хәрефе белән дә бирелергә мөмкин: *Фатыйх – Фатых.*

16. Татар исемнәре ахырындагы *ый* рус телендә *и* хәрефе белән бирелә: *Газый –Гази*, *Барый – Бари*, *Бакый – Баки*, *Нәкый – Наки.*

17. Татар телендәге исемнәрдә нечкә иҗек ахырындагы *л* хәрефе рус телендә *ль* белән бирелә: *Гөлнур – Гульнур, Гөлсем – Гульсум, Гадел – Гадель, Илдус – Ильдус*; *Илсур – Ильсур.*

Октябрь инкыйлабыннан соң башланып, хәзерге чорга кадәр телебезгә актив керә торган алынма исемнәрне (мәсәлән, *Роберт, Рафаэль, Альберт, Венера, Диана, Эльмира, Карина, Эмилия, Артур,Эльвина, Эльмира, Диана* һ.б.) татарча язуда график принципны куллану зарур.

Соңгы елларда татар телендә активлашкан гарәп һәм фарсы исемнәрен русча язылышта бирергә тырышу очраклары да активлашты, мәсәлән, *Аиша, Айша, Самира, Ясмина, Лайла* һ.б. Бу төр исемнәрнең язылышы традицион язылышка, ягъни татар теленең фонетик закончалыкларына буйсындырылып бирерлергә тиеш: *Айшә, Самирә, Ясминә, Ләйлә* һ.б.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, татар кеше исемнәренең орфографиясе һәм рус телендә бирү мәсьәләсе бүгенгәчә тулаем хәл ителгән дип булмый, бу өлкәдә махсус тикшеренүләр һәм бердәм кагыйдәләр системасы эшләү, татар исемнәренең тулы җыелмасын үз эченә алган орфографик сүзлек төзү көнүзәк мәсьәләләрнең берсе булып тора.

## ТАТАР ФАМИЛИЯЛӘРЕ

### § 9. Татар фамилияләренең формалашу тарихы

Фамилия – (*familia* латин телендә *гаилә, өй* дигәнне аңлата) кешенең аерым бер гаиләгә караганлыгын күрсәтә торган антропонимнарның бер төре (Подольская, 1978: 155). Рус теле белемендә фамилияләрнең үсеше, формалашу этаплары, семантик үзенчәлекләре В.Д. Бондалетов, А.М. Селищев, В.К. Чичагов, Ю.Ю. Марченкова, И.А. Королева, Н.Н. Парфенова, Л.С. Плавинская, Е.С. Еремина, Т.Г. Смирнова, В.И.Вершинин һ.б.ларның хезмәтләрендә тикшерелә. Төрки тел белемендә, аерым алганда, карачай-балкар телендә (Биджиева, 2002), казак телендә (Ниетбаева, 1993), кыргыз телендә (Жапаров, 2009), төрек телендә (Şahin, 2016) фамилия антропонимик берәмлек буларак синхрондиахроник аспектта өйрәнелә. Татар телендә фамилияләр Г.Ф. Саттаров, Ф.Л. Мәҗитова, Г.С. Тимерханова, З.М. Хөснуллина хезмәтләрендә тарихи-лингвистик аспектта өйрәнеләләр.

*Фамилия* сүзе рус теленә поляк теле аша *нәсел* сүзенә синоним буларак кулланылышка керә, әмма XIX гасырда мәгънәсен үзгәртә һәм «гаилә» төшенчәсен белдерә башлый. Билгеле булганча, *фамилия* термины, номинатив берәмлек буларак, Төньяк Италиядә XI гасырда кулланылышка керә. Фамилия Италиядән французлар, инглизләр һәм башка Европа халыклары арасында киң тарала. Европа халыкларын «фамилияләштерү» XII–XIX гасырга кадәр дәвам итә. Алманнар арасында «фамилияләшү» күренеше, XII гасырда башланып, XIX гасырга кадәр дәвам итә.

Рус теле белемендә фамилияне белдерү өчен *кушамат, прозвание* терминнары кулланыла. 1818 елда Россия Дәүләт советында *фамилия* сүзен *гаилә, нәсел* мәгънәсендә аңларга кирәклек, әлеге сүзнең «кушамат» төшенчәсенә тәңгәл булмавы хакындагы мәсьәлә күтәрелә. Фамилия термины «Ревизская сказка» матери-

алларында 1849 елда беренче тапкыр теркәлеп, «гаилә кушаматы» төшенчәсен алыштырып килә башлый.

Татар телендә дә фамилияләр, рус телендәгечә, исемнәргә *-ов/-ова, -ев/-ева, -ин/-ина, -ский/-ская* кушымачалары ялганып ясалалар *(Габдриев – Габдирева, Хаков – Хакова).* Шулай ук алар белән *беррәттән, -ин/-ина* кушамчасы да параллель рәвештә кулланыла. Кулланылыш ешлыгы ягыннан *-ов/-ова* кушымчасы татар фамилияләре составында ешрак очрый. Рус телендә исә уртаклык исемнәрен ясауда *-ов/-ова* кушымчасы продуктив түгел, *-ин* кушымчасы, киресенчә, туганлык атамаларында (*мамин, сестрин, дядин* и др.), кечерәйтү исемнәрендә (*Колин, Сашин, Сонин* һ.б.) тартым кушымчасы вазифасын үти.

Фамилияләр – кешене төгәл идентификацияләү кирәклеге ихтыяҗында барлыкка килгән антропонимик берәмлекләр (Фролов, 2005: 103). XVI гасыр урталарында рус фамилияләренең күпчелегендә *-ов/-ев/-ин* кушымчалары кулланыла. Русларда чиркәүдә бирелгән (крестильный) һәм көнкүреш исемнәре фамилия ясауда катнашалар. Бу исә, үз чиратында, омоним исемнәр кулланылышыннан коткара, чөнки чиркәүдә бирелгән исемнәр фондының кулланылыш даирәсе чикле була (Унбегаун, 1989: 16). Рус антропонимик системасында кенәз һәм бояр фамилияләре – XV–XVII гасырларда, сәүдәгәр фамилияләре – XVI–XIX гасырларда, крестьян фамилияләре – XVIII–XIX йөзләрдә формалашып бетәләр (Фролов, 2005: 104). Ревизия кенәгәләрендә фамилия «гаилә прозваниесе» терминын алышытырып, 1849 елда кулланыла башлый. Паспортлашу чорында – XX гасырның 30 нчы елларында СССРда фамилия киң кулланышка кертелә.

Татар фамилияләре формалашуның беренче этабы борынгы төрки антропонимик система формалашудан башланып китә. Орхон-Енисей чыганакларында ук фамилия антропонимик берәмлегенең беренче яралгылары күренә башлый, алар социаль титулны күрсәтү, нәселне аеру, мирас мәсьәләләрен хәл итү максатында барлыкка киләләр: *Čur Tegin, Beg Čur, Kül Čur Ayluç Tarkan, Altun Tamgan Tarkan, Kegilinç Tarkan* һ.б. Өстәмә антропонимик берәмлек буларак, фамилия ата яки баба исеме, сословие титулы буларак исем янәшәсендә кулланыла. Мәсәлән, *Tutuq* «баш әмер бирүчесе» титулы түбәндәге исемнәрдә фамилия вазифасын үти: *Adak Tutuq, Alp Tutuq, Budak Tutuq h.б.* Аерым бер гаилә әгъзаларының

исемнәре янында нәселне аеру максатында *бәк, бай, ай, иш, җан* кебек компонентлар кулланыла. Аерым алганда, борынгы төрки антропонимик системада фамилия, ата яки бабасының исеме, кушамат яки сословие титулы шәхесне идентификацияләү вазифасын башкара. Борынгы Орхон-Енисей язмаларында *elči čor kuč bars, atım el toγan tutuq, bag tarqan ögä tirig* һ.б. кебек фамилияләр функциясен алыштырган компонентлар билгеләнәләр.

Ислам дине кабул ителгәч, Бөек Болгар дәүләтенең башка илләр белән икътисади-сәяси, дипломатик элемтәләренең ныгуы, гарәп факихләре һәм мөгаллимнәре тарафыннан мәктәп-мәдрәсәләрдә татар теле аша мөселман диненең укытыла башлавы кешене идентификацияләүдә өстәмә чараларның кирәклеге ихтыяҗын арттыра, һәм гарәп антропонимик системасы законнары нигезендә фамилия формалаша. Бөек Болгар дәүләтендә күренекле галимнәрнең, дин әһелләренең исемнәрендә түбәндәге антропонимик модельләрнең кулланылышын билгеләргә мөмкин: *Хуҗа Әхмәд әл-Болгари, Хәмид бине Идрис әл-Болгари, Якуб бине Ногман әл-Болгари, Сөләйман бине Даут ал-Саксани-Сувари, Борханетдин Ибраһим әл-Хәнәфи, Ибраһим әл-Казани, Ибраһим бине Сөләйман әс-Сараи* (Мәрҗани, 1989: 142).

Алтын Урда чорында фамилия функциясен башкара торган берәмлек рәсми антропонимик категория булмый, чөнки өстәмә антропонимик берәмлекләрнең атадан балаларга күчүе киң таралмаган була. Фамилия функциясен үти торган *улы/кызы* кебек өстәмә антропонимик берәмлекләр Алтын Урда чорына караган каберташ язмаларында, тарихи чыганакларда фамилия вазифасын үти: *Хәмәд угылы Хәсән угылы Мәчкә; Әхрәҗ угылы Әбхәм угылы Әршид угылы Мәхмүд; Ильяс угылы Исмәгыйль угылы Мөхәммәд, Бәчек угылы Мәмәк Йувари угылы Исхак угылы Йосыф хаҗи, Исмәгыйль угылы Хәсән угылы Муса угылы Мөхәммәд, Иләм угылы Хаҗи кызы Җәкәр* һ.б. (Становление..., 2011: 401). Алтын Урда чорына караган хатын-кыз исемнәрен билгеләүдә дә шул ук антропонимик модель кулланылышта була: *Әхмәд Хаҗи улы Хәсән Хаҗи кызы Рабига, Иләм угылы Хаҗи кызы Җәкәр, Әхмәд Хуҗа угылы Хәсән Хуҗа кызы Рәйзу* һ.б. Хатын-кызны идентификацияләүдә өстәмә антропонимик берәмлек булып иренең исеме кулланыла: *Госман әл-Болгари кызы Хөсәен хатыны Җәкәр Әлти, Мур бәй хатыны Йосыф Йувари угылы Йосыф Йувари кызы Гафифә Заһи-*

*дә* һ.б. (Становление, 2011: 406–410). Алтын Урда чыганакларына караган каберташ язмаларында урынга нисбәтле фамилияләрне дә очратырга мөмкин: *Садреддин әл-Ширвани, Хуҗа угылы Госман угылы Ибраһим әл-Сувари, Юныс әл-Болгари* һ.б. (Гариф, 2011: 12–24). Алтын Урда чорында исламның төрле юнәлешләре киң таралган була *(*Мухаметшин, 2007: 14), әлеге юнәлешләр исә фамилия вазифасын үти торган берәмлекләрдә дә чагыла: *Борһанетдин Ибраһим Хозыр ал- Хәнәфи.* Дини юнәлешләрнең чагылышы *Хәнәфи, Шафи, Суфи* кебек фамилияләрдә сакланып кала. Хәзерге антропонимикада исә әлеге фамилияләр нигезендә кеше исемнәре дә шактый еш кулланылышта йөри: *Хәнәфи – Хәнәфия, Шафи – Шафия, Суфи – Суфия.*

Билгеле булганча, ислам дине кабул ителгәннән соң, антропонимик системада да гарәп исем системасына хас антропонимик модельләр кулланылышка кереп, урта гасырда һәм аннан соңгы чорларда кеше турында өстәмә мәгълүмат бирә торган төшенчәләргә (шәхеснең туган урыны, мәзһәбе, ата-бабасы*) -и/ -ый* изафә кушымчасы ялганып барлыкка килгән антропонимик берәмлекләр фамилия вазифасын башкаралар: *Мәхмүд Кашгарлы, Шиһабетдин Мәрҗани, Борһанетдин Ибраһим Хозыр Хәнәфи, Бәчек угылы Мәмәк Йувари* һ.б. Моннан тыш, урта гасырларда исем белән янәшә ата-баба исеме бернинди кушымча алмыйча патронимик фамилия функциясендә дә кулланылган: *Кадыр Гали-бәк, Таҗетдин Ялчыгол.*

Казан ханлыгы чорына караган каберташ язмаларында фамилия вазифасын үти торган берәмлек *угылы/кызы* өстәмә антропонимик берәмлек чаралары ярдәмендә белдерелә: *Садир угылы Идегәй, Мансур Исхак угылы, Чура угылы Гали Мәрдән, Кунак Хуҗа бай угылы Җийан Хуҗа* һ.б. Атасы исеменнән тыш, хатын-кыз исемендә өстәмә идентификацияләү вазифасын иренең исеме үти: *Җәгъфәр кызы Гали хатыны Айбикәч, Әҗем угылы Бик-Бау хатыны Акбикәч, Шәех Галинең хатыны Нәүрүзсолтан* һ.б.

Казан ханлыгы руслар тарафыннан яулап алынганнан соң, шәхесне атауда, билгеләүдә аерым үзгәрешләр керә башлый. Тарихи чыганаклардан мәгълүм булганча, XV–XVI гасыр урталарыннан башлап, татар антропонимик системасы рус антропонимик моделе нигезендә формалаша. Тарихи чыганакларда кеше исемнәренә *-ов/ -ев/-ин* кушымчаларының ялганып ясалган фамилияләре очрый.

1565–1568 елларда Н.В. Борисов һәм Д.А. Кикин тарафыннан язылган «писцовые» һәм «межау» кенәгәләрендә татар фамилияләренең төрле катлау арасында кулланылышын күзәтергә мөмкин: *Көнәй Чакмак* (Куней Чикмаков), *Уразкилде Акъялов* (Разгилдей Акьелов), *Мостафа Байчирү* (Мустапа Байчиреев) һ.б. 1602–1603 еллардагы «писцовые» кенәгәләрендә йомышлы татарлар арасында түбәндәге фамилияләр теркәлгән: *Кайбула Карамышев, Айтуган Янчурин, Карай Урусов, Текей Енчурин, Исекей Мусин, Ангильдиш Мусин, Салтанай Салтангулов, Курмыш Абдулов* һ.б. XVI–XVII йөзләрдә хатын-кыз фамилиясе иренең исеме белән күрсәтелә: *Кадышевская жена Девленей*. Димәк, рус антропонимик моделе нигезендә барлыкка килгән татар фамилияләре XVI–XVIII йөзләргә караган рус чыганакларында билгеләнә башлыйлар һәм төрле иҗтимагый катлауга караган татарларны идентификацияләү вазифасын үтиләр. Кенәз яки алпавыт катлавына караган татарларның шәхесен билгеләгәндә, фамилия белән беррәттән, ярымотчество да кулланыла башлый: *Тойгелдей князь Уразгелдеев сын, Кучюк Тегишев, Ишей Хозяшев сын Сюндюков, Емамаметка Юнгушев сын Турачиков* (Галиуллина, 2014: 196).

Россиянең тарихи процессында яшәргә мәҗбүр ителгән Идел буендагы барлык рус булмаган халыкларның антропонимик системаларында үзгәрешләр билгеләнсә дә, гарәп-фарсы, төрки телләргә хас исем кушу, атау традицияләре, исем модельләре көнкүреш дөньясында яшәешен дәвам итәләр. XVII–XVIII гасырга караган ташбилгеләрдә традицион милли калыпка нигезләнгән антропонимик модельләрне очратабыз: *Кадрәк мирза угылы Исәнәк мирза, Айыш угылы Дусай, Килмөхәммәд Ишман угылы, Чирүче угылы Килмөхәммәд* (Әхмәҗанов, 2011). 1763 елгы Ревизия кенәгәләрендә мәгълүматлар фамилия + исем моделендә биреләләр: *Салиха Хасанова 35 лет взята Казанского уезда деревни Тонсар Татаринов дочь; Муслима Мусалимова 20 лет взята Казанского уезда из деревни Нового Кызылъяр Татаринов дочь; Ишмамета жена вдова Гуля Нормаметова 19 лет взята из Казанской губернии* (Ревизская сказка, ф. 3, оп. 2, 438). XVIII гасыр эш кәгазьләрендә татар фамилияләре байтак очрый*: Сәгыйть Хәлфин, Әхмәт Сөләйманов, Япей Ибраев, Яхъя Арсланов* һ.б.

XVIII йөз ахырында сәүдә элемтәләрен ныгыту максатында, йомышлы татарларга паспортлар бирелә һәм анда фамилия

рәсми атау берәмлеге булып йөри башлый. Казан ратушасының 22 фондында татарларга бирелгән паспортлар хакында керем кенәгәләре, шулай ук паспорттагы мәгълүматларны үз эченә туплаган төпләмәләр саклана. Шул рәвешле, рәсми документларда фамилияләрнең кулланылышы рус теленә хас, ягъни ата яки баба исеменә *-ов/-ова, -ев/-ева, -ин/-ина* кушымчаларын кушу нигезендә барлыкка килеп, XIX йөзнең икенче яртысында – XX йөз башында тәмам формалашу процессын кичерә. XIX гасырга караган «Ревизская сказка» материалларында фамилия рус теленә хас антропонимик моделендә үсешен дәвам итә: *Рахматулла Ишметов, Рахматулла Ишекеев, Мухаммет Исхаков, Рахматулла Мухаметов, Ибатулла Мухамматрахимов* һ.б. (Ревизская сказка, ф. 3, оп. 2, ед. хр. 138). XIX гасыр башларында, фамилия беләнберрәттән, отчество антропонимик берәмлегенең дә тәгаенләнүен күрәбез: *Сабухаккулы Бурханова сынъ Сагитдин, Сабуханкул Бурханов Тумашев, Мурадым Исхаков Уразгелдеев, Абубекир Халитов Уразгелдеев* һ.б.

XX гасыр башында метрика кенәгәләрендә традицион милли антропонимик калып нигезендә кеше турында мәгълүматлар языла: *Әхмәтвафа Сәйфи угылы Миңлехәят, Миңлеәхмәт атасы Нигъмәт Вәли угылы; Атасы Шиһабетдин Гыйззәтулла улы Сәләхетдин* (Метрик кенәгә, 1906, ф. 204, тасв. 177, эш 938). 1916 елгы «Оренбург диния нәзарәтенең белешмәләрендә» фамилияләрнең татарлар арасында киң таралмавы, ләкин рекрутлыкны билгеләү өчен кирәк булуы турында әйтелә (О работе имам…, 1916: 16 – 21). Нәсел фамилиясе булмаган очракта, рәсми документларда баба исеме кулланыла. Затлы нәселләрдә яки йомышлы катлауда фамилия мирас буларак күчкән һәм метрикаларда да фиксацияләнгән (ТР Милли архивы, ф. 204, тасв. 180, эш 65, б. 200).

Антропонимик категория буларак, татар фамилияләренең формалашуы төрле катлау вәкилләре арасында төрлечә бара. Татарларда рус антропонимик системасына хас фамилияләр XV–XVI гасырда югары катлау династияләрендә, төрле дәүләт эшләре белән идарә итүчеләр арасында барлыкка килә. Фамилия билгеле бер гаиләне берләштергәнгә, нәселдәнлекне, аерымлыкны белдергәнгә күрә ханнар, морзалар арасында киң тарала.

Татарның ярлы катлавы гражданлык хокуклары, законнар, милек мөлкәте белән эш итмәгәннәр, җәмгыять тормышында актив

катнашмаганнар, шуңа күрә дә алар озак еллар фамилия йөртү хокукыннан мәхрүм булганнар. Түбән катлау вәкилләренең күбесе ерак авылларда яшәгәнгә күрә, фамилия алу аларга Октябрь инкыйлабыннан соң гына мөмкин булган.

Шулай итеп, чыганаклар нигезендә шартлы рәвештә татар фамилияләре формалашуның түбәндәге этапларын билгеләргә мөмкин: борынгы төрки антропонимик системага хас фамилияләрнең киң таралуы (V–X гасырлар); фамилияләр формалашуының урта гасырлар чоры (X–XV гасырлар); фамилияләрнең татар ханнарында, әмир, морзаларында формалашуы (XIV – XVI гасырлар); фамилияләрнең йомышлы татарларда һәм татар сәүдәгәрләре арасында таралуы (XVII–XVIII гасырлар); фамилияләрнең урта хәлле шәһәр кешеләре катлавында, мөселман руханилары һәм урта хәлле крестьяннар арасында таралуы (XVIII–XIX гасырлар); ярлы катлау шәһәр кешеләре арасында һәм крестьяннар арасында фамилияләрнең формалашуы һәм фамилиянең тулысы белән формалашып җитү этабы (XVIII–XIX гасырлар).

## § 10. Татар фамилияләренең төзелеш-ясалышында төп үзенчәлекләр

Татар телендә кеше исемнәре, кушаматлар, этнонимнар фамилияләр ясалу өчен нигез булып хезмәт итә торган төп ономастик категорияләрне тәшкил итәләр.

Татар фамилияләренең байтагы кеше исемнәренә (шәхеснең атасы, бабасы, ерак бабасы исеменә) нигезләнеп ясала. Казан шәһәренең 10 мең татар фамилиясенең 85%ы кеше исемнәренә нигезләнгән (Хуснуллина, 2009: 8). Генетик яктан татар фамилияләренең нигезендә яткан кеше исемнәренең зур күпчелеген гарәп-фарсы исемнәре алып тора. Мәҗүси ышануларга, хайваннарны, кошларны, балыкларны, агачларны, үсемлекләрне илаһилаштыру, ата-баба культы һәм башка дини ышануларга, йолаларга нигезләнгән борынгы төрки компонентлы фамилияләр дә татар исемиятендә аерым урын тоталар. Борынгы төрки кеше исемнәренә нигезләнгән фамилияләр: *Акташев* (Акташ), *Сарбашев* (Сарбаш), *Кучуков* (Көчек), *Сатлыков* (Сатлык), *Уразов* (Ураз) һ.б.

Ислам дине кабул ителгәч, татар исемиятендә гарәп-фарсы исемнәренең таралуы фамилияләрдә дә чагылыш таба: *Зарифуллин* (Зарифулла), *Сәйфуллин* (Сәйфулла), *Хаҗиев* (Хаҗи) һ.б.

Гарәп-фарсы чыгышлы кеше исемнәренең мәгънәләре аңлашылмаганга, исем нигезенә төрле иркәләү-кечерәйтү кушымчалары ялгана, шулай ук төрки нигезле исемнәргә хас кыскару формалары да кулланыла башлыйлар. Шул рәвешле, тулы вариантлы исемнәргә нигезләнгән фамилияләр белән беррәттән, кыскартылган вариантлы фамилияләр дә кулланылышта йөриләр. Тулы вариантлы кеше исемнәренә нигезләнеп ясалган фамилияләр: *Мөстәкыйм – Мөстәкыймов, Кашаф – Кашафов, Бикмулла –Бикмуллин* һ.б.

Кыскарган формадагы исемнәргә иркәләү-кечерәйтү кушымчалары ялганып ясалаган фамилияләрне дә очратырга мөмкин: 1) *-ай/-әй/-ый/-и,/-уй/-үй: Әлмөхәммәт – Әлми – Әлмиев, Бикмулла – Бикмәй – Бикми – Бикмиев* һ.б.; 2) *-ак/-әк/-як/-ук/-үк: Мөстәкыйм – Мөстәк – Мөстәков, Сираҗетдин – Сирук – Сируков* һ.б. 3) *-аш/-әш, -ыш/-еш, -үш/-уш/-юш: Акмулла – Акмуш – Акмушев; Габдулла – Абдюш – Абдюшев*; 4) *-уч/-үч, -ач/-әч: Минһаҗ – Миначев –Миначев; 5) -кай/-кәй Мәүләкәй – Мәүли – Мәүләкәев* һ.б.

Компонентларының кыскаруы нигезендә ясалган фамилияләр үзләре берничә төргә бүленәләр: 1) апокопа, ягъни алынма исемнең икенче өлеше төшеп кала*: Садретдин – Садри – Садриев, Гайнетдин – Гайни – Гайниев, Шәрифулла – Шәриф – Шәрифов* һ.б.; 2) аферезис, ягъни кушма төзелешле алынма исемнең беренче компоненты төшеп кала: *Габденур – Нур – Нуров, Галисәлам – Сәлам – Сәламов, Габдеразыйк – Разыйк – Разыйков* һ.б.; 3) синкопа, ягъни алынма сүзнең уртасында булган авазларның һәм иҗекләрнең төшеп калу очраклары: *Гаетмөхәммәтов – Аетмөхәммәтов – Аймәтов* һ.б.; 4) әдәби телдә булып та, диалектка тулысынча кереп бетмәгән тартыклар белән бәйле аллонимнарга нигезләнгән фамилияләр (увуляр [г] авазы сүз башында яки сүз уртасында әйтелми кала: *Габбасов – Аббасов, Габлегалиев –Абделгалиев* һ.б.

Татарларда фамилияләр ясалышында билгеле бер роль уйнаган антропонимик берәмлек – ул *кушамат*. Татар фамилияләре арасында *Алабашев* ала+баш патронимик компонентларына, *Чапкынов* – чапкын, *Куркин* – күркә, *Сулагаев* – сулагай, *Башмаков* – башмак кебек кушаматларга нигезләнгән фамилияләр булып билгеләнәләр. Көнбатыш диалектта һәм керәшен татарларында кушаматларны рус теленә тәрҗемә итү юлы белән ясалган фамилияләр дә очрый. Мәсәлән, тугыз – девять – *Девятков*, кучкар – баран – *Баранов*, кәҗә – козел – *Козлов* һ.б. Ясак түләүдән азат ителгән

йомышлы татарларны, шул исәптән лашманчыларны казак дип атап йөрткәннәр. Шушы атамага мөнәсәбәтле татарлар арасында *Казаков* дигән фамилия кулланыла. Кушаматлар нигезендә ясалган фамилияләрнең түбәндәге төрләрен билгеләргә мөмкин:

1. Кешенең физик һәм психологик халәтен билгеләгән кеше исемнәре: *Акбашев* (ак баш), *Начаров* (начар), *Саранов* (саран), Батыров (батыр), Кылыев (кылый) һ.б.

2. Туганлык мөнәсәбәтләрен чагылдырган терминнардан ясалган фамилияләр: *Апаев* (апай), *Тутакаев* (тутакай, өлкән апа)*, Бабаев* (карт кеше, бабай), *Атаев* (ата) һ.б.

3. Чин-сословие титулларына, профессия атамаларына нигезләнеп ясалган фамилияләр: *Алпаутов, Баев, Йөзбашев, Тарханов, Биков, Субашев* һ.б. Билгеле булганча *-чы (-че)* кушымчасы һөнәр, мәсләк атамаларын ясауда катнаша: *Бакырчин* (Бакырчы), *Сунарчин* (Сунарчы), *Урмачеев* (Урманчы) һ.б.

4. Хайван һәм балык кушаматларыннан ясалган фамилияләр: *Бурсыков* (бурсык), *Чуртанов* (чуртан), *Боланов (*болан) һ.б.

5. Корт-кош исемнәреннән ясалган фамилияләр: *Чебешев* (чебеш), *Кучатов* (кучат, әтәч), *Күгәрченов* (күгәрчен) һ.б.

Фамилияләр ясауда нәсел кушаматлары аерым урын тота. Нәсел кушаматларының фамилияләргә әйләнүен М.Я. Морошкин затлы нәселләрнең геральдик традицияләренә нисбәтле карый, шулай ук укымышлылыкның һәм сәүдәнең алга китүенә бәйле аңлата (Морошкин, 1867: 34), Е.П. Карнович илнең сәяси үсешенә нисбәтле күрә (Карнович, 1886: 21), А.М. Селищев аерым бер феодалның нәселен билгеләү максатында кулланылган дип саный (Селищев, 2003: 45). Мәсәлән, татар шәҗәрәләрендә Дәүекаевлар нәселе билгеләнә. Әлеге нәсел Кырым ханнары даирәсеннән булган Дәүекәйгә нигезләнеп ясалган (Татар шәҗәрәләре, 2013: 202). Тобол татарлары арасында кулланылган *Аксаков, Алашеев, Аракчеев, Артаков, Артыков, Басманов, Беклемишов, Шадрин, Юшков, Алабышев, Барбашин* кебек фамилияләрнең нәсел кушаматлары нигезендә барлыкка килүләре мәгълүм (Вафеев, Выхрыстюк, Файзуллина, 2012: 33).

Татар фамилияләрен ясауда топонимик берәмлекләр аерым роль уйный. Әлеге төр фамилияләрнең ясалышы татар халкының күченүе белән аңлатыла. Топонимик берәмлекләргә *-ский/-ская* кушымчалары, яки татар теленә хас *-лы/-ле* кушымчалары ялганып,

кайсы төбәккә караганлыкны ассызыклаган фамилияләр барлыкка киләләр: *Ф. Уральская, Фатыйх Сәйфи-Казанлы, Г. Казанский, Самаров, Крымов, Амурский, Бухарский, Минский* һ.б. Шәрык халыкларының зур күпчелегендә, шул исәптән болгар-татарларда урта гасырның IX–XIV йөзләрендә һәм соңрак әдәбият, сәнгать һәм фән эшлеклеләре, фарсы теленнән алынган *-и/-ый, -ви* кушымчалары ярдәмендә, туган урыннары һәм ата-бабалар исеменә нигезләнеп ясалган фамилияләр йөртәләр: *Мәхмүт Болгари*, *Мәүлә Колый, Г. Утыз Имәни, Сәйф Сараи* һ.б. XX гасырның 30 нчы елларында татар интеллигенциясе арасында фамилияне яки фамилия-псевдонимнарны топонимга нигезләнеп алу шактый активлаша.

Татарларда фамилияләр ясауның тагы бер чыганагы – этнонимнар. Татар антропонимик системасында этнонимнар нигезендә ясалган фамилияләр аз санда күзәтелә. Мәсәлән: *Нугаев* (ногай), *Башкиров* (башкорт), *Татарская* (татар), *Үзбәков* (үзбәк), *Болгарская* (болгар), *Чувашев* (чуваш), *Черкасов, Черкесов* (черкас – черкес Карачаево-Черкесс Республикасында яшәгән халыклар), *Байтирәков* (байтирәк – төрки нәсел исеме), *Чермешов* (элек мариларны шулай атаганнар) һ.б.

Аппелятив лексика нигезендә ясалган фамилияләр матур яңгырашлы һәм мәгънәви яктан эчтәлекле уртаклык исемнәренә нигезләнәләр. Аларны ясалма фамилияләр дип атарга мөмкин: *Чибәркәева, Матуров, Ильская, Ватнов, Айский* һ.б. Кайбер очракта кулланылышта икеле фамилияләр дә очрый.

Татар халкында фамилияләрне калькалаштыру аерым урын тота. Әлеге төр фамилияләр татарларның төрле локаль мәдәниятkә хас вариантларында күзәтелә. Мәсәлән, калька фамилияләр зур күпчелек мишәрләрдә һәм керәшен татарларында очрый. Нигезләрендә төрки сүз яткан фамилияләрне әйтү һәм язу русларда транслитерацион кыенлык тудырганга, калька фамилияләр формалаша. Әлеге фамилияләр тәрҗемә итү нигезендә барлыкка килә. Керәшен татарлары татар исемен яки фамилиясен русчага алыштырганда һәм чит телдән кергән нигезләрне тәрҗемә итеп булмаган очракта бөтенләе белән русчага алыштырганнар: *Зайцев* (куян), *Комаров* (черки), *Кукушкин* (күке), *Журавлев* (торна) һ.б.

Байтак татар фамилияләрендә локаль мәдәниятkә хас булган фонетик үзенчәлекләр чагылыш таба: *Дәрҗеманов (Тәрҗеманов), Рәзмәтов (Уразмәтов), Әднәгулова – Әзнәголова (Әтнәгулова)*

– урта диалект вәкилләре; *Еналиева – Юналеева – Йаналеева (Җангалиев), Янишев – Чанишев (Җанишев), Миначев (Минһаҗев)* – көнбатыш диалект вәкилләре, *Шихов (Шәехов), Чаппарова (Җаббарова), Тусмөхәммәтова (Дусмөхәммәтова)* – көнчыгыш диалект вәкилләре үзенчәлекләрен чагылдырган.

Татар фамилияләренең семантикасы татар халкының кардәш һәм кардәш булмаган халыклар белән тыгыз мөнәсәбәтен, татар халкының тарихи үсешен, рухи һәм матди мәдәниятенең үзенчәлекләрен, дөньяга карашын чагылдыралар.

## § 11. Татар фамилияләренең орфографиясе һәм транслитерация мәсьәләсе

Татар фамилияләренең дөрес язылышы мәсьәләсе һәрвакыт актуаль булып тора. Фән һәм белем бирү учреждениеләрендә, дәүләт һәм муниципаль структураларда, паспорт, туу турында таныклыкларны әзерләүдә татар фамилияләрен стандартлаштыру проблемасы һәрвакыт көн кадагына суккан мәсьәләләренең берсен тәшкил итә. Әлеге мәсьәлә тел сәясәтендә барган үзгәрешләргә бәйләнелешле рәвештә барлыкка килә. Шуны истә тотып, кеше исемнәреннең язылышында һәм транслитерацияләүдә туган кыенлыкларны хәл иткән, татарлар арасында яшәп килгән милли үзенчәлекләрне, фәнни прицилпарны исәпкә алган «Татарча-русча кеше исемнәре һәм фамилияләр сүзлеге» (2006) дөнья күрә. Һәм хәзерге көнгә кадәр исем һәм фамилияләрнең дөрес язылыш прициплары, татар телендәге фамилияләрне рус телендә бирү әлеге сүзлеккә нигезләнә. Әлеге параграфта фамилияләрнең дөрес язылыш һәм транслитерацияләү мәсьәләсе әлеге сүзлеккә нигезләнеп бирелде.

Татар фамилияләренең зур күпчелеге гарәп-фарсы сүзләреннән ясалган һәм төзелеш-ясалышлары телебезнең фонетик системасына яраклаштырылган. Фонетик принципка нигезләнгән фамилияләр орфографиядә әйтелгәнчә язылалар.

Кушма исемнәргә нигезләнеп ясалган фамилияләрдәге исем компонентлары кушылып языла: *Дәүләткилдиев, Солтанбәков, Әхмәтвәлиев* һ.б.

Татар фамилияләрен язуда һәм рус телендә бирүнең аерым бер закончалыклары бар. Шулай да татар фамилияләрен рус телендә бирүдә абсолют төгәл схемалар белән эш итеп булмый.

Тартык аваз хәрефләренә тәмамланган ир кеше исемнәреннән ир кеше фамилиясе ясаганда *-ов* кушымчасы ялгана: *Сәфәр – Сәфәров – Сафаров, Әмир – Әмиров – Амиров* һ.б.

Кайбер авазларга (*и, ый, ш*) беткән һәм нечкә сузык янындагы *л* хәрефенә тәмамланган исемнәрдән ир кеше фамилиясе ясаганда *-ев* кушымчасы ялгана: *Хаҗи –Хаҗиев – Хазиев, Бәдри – Бәдриев – Бадриев, Зәки – Зәкиев – Закиев, Садрый – Садрыев – Садриев, Гамил – Гамилев – Гамилев, Сәйдәш – Сәйдәшев – Сайдашев* һ.б.

Кайвакытта *Хаҗиев, Галиев, Валиев* фамилияләренең язуда түбәндәге вариантларын күрергә мөмкин: *Хаҗи – Хаҗеев, Гали – Галеев, Вәли – Вәлеев* һ.б. Мондый язылыш орфографик законнарга туры килми. Татар теленең орфографик кагыйдәләре буенча, кушымча сүзнең нигезенә ялганырга тиеш: *Хаҗи + ев – Хаҗиев, Гали + ев – Галиев, Вәли + ев – Вәлиев* и др.

Тартык аваз хәрефләренә тәмамланган ир кеше исемнәреннән хатын-кыз фамилияләре ясаганда *-ова* кушымчасы кулланыла: *Сәфәр – Сәфәров – Сәфәрова, Әмир – Әмиров – Әмирова, Булат – Булатов – Булатова* һ.б.

*И, ый, ш* һәм нечкә сузык янындагы *л* хәрефенә тәмамланып, исемнәрдән хатын-кыз фамилияләре ясаганда, *-ева* кушымчасы кулланыла: *Хаҗи – Хаҗиев – Хаҗиева – Хазиева, Бәдри – Бәдриев – Бәдриева – Бадриева, Зәки – Зәкиев – Зәкиева – Закиева, Садрый – Садрыев – Садрыева – Садриева, Гамил – Гамилев – Гамилева, Сәйдәш – Сәйдәшев – Сәйдәшева – Сайдашева* һ.б.

*А, ә* һәм е хәрефләренә тәмамланган исемнәрдән ир кеше фамилияләре ясаганда *-ин* кушымчасы ялгана. Исемнәрендәге соңгы *а, ә* һәм *е* хәрефләре бу очракта *-ин* кушымчасы тарафыннан йотыла: *Гата – Гатин, Хәмзә – Хәмзин* һ.б.

*А, ә,* һәм *е* хәрефләренә тәмамланган исемнәрдән хатын-кыз фамилияләре ясаганда, *-ина* кушымчасы кулланыла. Исемнәр ахырындагы *а*, *ә* һәм *е* хәрефләрен *-ина* кушымчасы алмаштыра: *Гата – Гатина, Гайсә – Гайсина* һ.б.

*-улла*га тәмамланган исемнәрдән ир кеше фамилияләре ясаганда, кагыйдә буларак, *-ин* кушымчасы ялгана. Бу очракта *-ин* кушымчасы исем ахырындагы *а* хәрефе урынына кулланыла: *Сәйфулла – Сәйфуллин – Сайфуллин, Миңнулла – Миңнуллин – Миннуллин, Гатаулла – Гатауллин* һ.б.

*-улла*га тәмамланган ир кеше исемнәреннән хатын-кыз фамилияләре ясалганда *-ина* кушымчасы ялгана. Бу очракта *-ина* кушымчасы исем ахырындагы *-а* кушымчасын йота: *Сәйфулла – Сәйфуллина – Сайфуллина, Миңнулла – Миңнуллина – Миннуллина, Гатаулла – Гатауллина* һ.б.

Әлеге нигезгә беткән ир кеше исемнәренә *-ов/-ова* кушымчасы ялганып та фамилияләр ясалырга мөмкин: *Хәйрулла – Хәйруллова, Вәлиулла – Вәлиуллова*. Әлеге вариантлар норма булып килә алмыйлар, ләкин кулланырга мөмкиннәр.

Татар фамилияләрен ясауда *-ский/-ская* кушымчасы күпчелек очракта әлеге фамилияне йөртүченеке булуын аңлата яки урын атамаларын белдергән нигезләргә ялгана. Мәсәлән, *Айский, Болгарский, Ильская, Корбанский, Минский, Казанский, Бугульминский* һ.б. Күпчелек очракта, бу антропонимнарның нигезендә топонимнар, матур эчтәлекле һәм яңгырашлы уртаклык исемнәре булган сүзләр яисә кушамат фамилияләр ята. Әлеге кушымча фамилиянең нигезендә нинди аваз булуына бәйсез ясала.

Тартык аваз хәрефләренә тәмамланган ир кеше исемнәреннән ир кеше отчестволары ясаганда, *-ович* кушымчасы ялгана: *Исхак – Исхакович, Якуп – Якупович, Нәсим – Нәсимович* һ.б.

Тартык аваз хәрефләренә тәмамланган ир кеше исемнәреннән хатын-кыз отчестволары ясаганда, *-овна* кушымчасы кулланыла: *Исхак – Исхаковна, Якуп – Якуповна, Нәсим – Нәсимовна.*

*А* һәм *ә* хәрефләренә тәмамланган ир кеше исемнәреннән ир кеше отчестволары ясаганда, *-ович* кушымчасы ялгана. Бу вакытта *-ович* кушымчасы исем ахырында килгән *а* һәм *ә* хәрефләрен йота: *Сафа – Сафович, Мирза – Мирзович, Гата – Гатович* һ.б.

*А* һәм *ә* хәрефләренә тәмамланган ир кеше исемнәреннән хатын-кыз отчестволары ясаганда, *-овна* кушымчасы ялгана. Бу вакытта *-овна* кушымчасы исем ахырында килгән *а* һәм *ә* хәрефләрен йота: *Сафа – Сафовна, Мирза – Мирзовна, Гата – Гатовна* һ.б.

*И, ый, я, у* һәм нечкә сузык янындагы *л* хәрефенә тәмамланган ир кеше исемнәреннән *-евич* кушымчасы ярдәмендә ир кеше отчестволары ясала: *Гани – Ганиевич, Вәли – Вәлиевич, Барый – Барыевич* и һ.б.

*И, ый, я, у* һәм нечкә сузык янындагы *л* хәрефенә тәмамланган ир кеше исемнәреннән хатын-кыз отчестволары ясаганда, *-евна*

кушымчасы ялгана: *Гани – Ганиевна, Вәли – Вәлиевна, Барый – Барыевна* һ.б.

Татар исемнәрендә фарсы чыгышлы *җан* компоненты рус телендә ике вариантта (*-джан* һәм *-зян* язылышында) бирелә: *Габдуллаҗанов – Габдуллазянов, Шакирҗанов – Шакирзянов, Рәхимҗанова – Рахимзянова* һ.б.

*Җ* хәрефеннән башланган татар фамилияләре рус теленә *з* хәрефе белән бирелә: *Җәлилов – Зялилов, Җиһаншин – Зиганшин* һ.б.

Татар телендә *һ* хәрефе рус телендә *г* хәрефе белән бирелә: *Заһитов – Загитов, Борһанов – Бурганов* һ.б.

Фамилияләрнең татар язылышында сүз уртасында ике *л* язылса, рус телендә язылган татар фамилияләрендә дә ике *л* язылырга тиеш: *Сәйфуллин – Сайфуллин, Вәлиуллин – Валиуллин, Галиуллин* һ.б.

Татар телендәге [*ый*] дифтонгы рус телендә [*и*] белән транслитерацияләнә: *Гыйбадуллин – Гибадуллин* һ.б.

Димәк, татар фамилияләренә хас орфографик законнар бар, икетеллелек шартларында барлыкка килгән транслитерация үзенчәлекләре дә билгеләнә. Фамилияләрнең язылыш законнары телнең үз төзеклеге өчен генә түгел, ә халкыбызның көндәлек аралашуында, бигрәк тә рәсми эшләр һәм аңлашулар барышында дөреслек, ачыклык һәм төгәллек өчен гаять дәрәҗәдә әһәмиятле.

## ТАТАР КУШАМАТЛАРЫ

### § 12. Кушаматларның төрләре

Кушамат (*кушама* (кушма), *ат* (исем) сүзләрен кушу юлы белән ясалган) кешенең рәсми, төп исеменә кушма, өстәмә мәгълүмат бирә. Исем, ата исеме, фамилиягә образлы эмоциональ-экспрессив төсмерләр хас булмаса, кушамат коннотив, эмоциональ-экспрессив төсмерләргә ия мәгънә бирә. Кушамат – кешенең үзенчәлекле сыйфатларын яки җәмгыятьтәге урынын ачу максатында җәмәгатьчелек яки кешеләр тарафыннан бирелгән, рәсми булмаган исем. Аерым очракларда кушаматлар, рәсми төс алып, исем, фамилия, ата исеме белән бергә дә килергә мөмкин. Мәсәлән: *Петр Беренче, Бөек Патшабикә* һ.б. Кушаматларның шәхси яки төркемнәргә хас төрләрен аерып карыйлар (Энциклопедический словарь-справочник..., 2008: 146). «Татар теленең аңлатмалы

сүзлеге»ндә кушаматка «конспирация өчен яки кешеләрдән көлеп, мәзәк өчен бирелгән исем» дип аңлатма бирелә (ТТАС, 2005: 299). Кушамат – антропонимның бер төре, үзенчәлекле характерга ия, аерым бер тормыш шартларына бәйле рәвештә кешегә бирелгән өстәмә исем (Подольская, 1978: 115).

Рус теле белемендә кушамат рус ономатологлары С.И. Зинин, Н.В. Подольская, А.М. Селищев, А.В. Суперанская, Н.Н. Ушаков, З.П. Никулина тарафыннан өйрәнелә. Е.Ф. Данилина, И.Ю. Карташева, Т.Т. Денисова, Ю.Б. Воронцова, Ж.Д. Маюрова, Е.С. Шостка, А.Н. Лангнер, Н.В. Дранникова, Т.В. Шпар һ.б. диссертацияләрендә кушаматларның лексик-семантик үзенчәлекләре теоретик яктан нигезле итеп тикшерелә.

Татар антропонимикасында кушамат Г.Ф. Саттаров, С.И. Гасимова хезмәтләрендә җентекле итеп өйрәнелә. Г.Ф. Саттаровның 1973 елда «Совет мәктәбе» журналында «Татар кушаматлары» дигән мәкаләсе дөнья күрә. Әлеге мәкаләдә галим шәхси кушаматларның 21 төркемен аерып күрсәтә (Саттаров, 1973: 47). С.И Гасимова «Татар кушаматларына тарихи-лингвистик анализ» дип исемләнгән диссертациясендә татар кушаматларына комплекслы анализ ясый, аларның лексик-семантик, структур-төзелеш үзенчәлекләрен актырта, кушаматларның килеп чыгышларына, үсеш закончалыкларын тикшерә (Гасимова, 2006).

Төрки тел белемендә кушамат башкортларда – Г.А. Амиргалина, кумыкларда – Р.А. Мусаева, каракалпакларда – Ю.Н. Хоҗалепесова, азәрбайҗаннарда – А. Курбанов, М.Н. Чобанов, үзбәкләрдә – Э. Бегматов, кыргызларда – Ш. Жапаров, казакларда – Т.Җ. Жанузаков, төрек тел белемендә Ю. Кенан Караҗан, Мехмет Семих тарафыннан яктыртыла.

Рус теле белемендә Н.В. Подольская кушаматларның түбәндәге төрләрен аерып күрсәтә: мелиротив кушамат – кешенең аерым бер яхшы сыйфатын, дәрәҗәсен билгеләү өчен хезмәт иткән исем; коллектив кушамат – аерым бер кешеләр төркеменә, гаиләгә, нәселгә, этник төркемгә бирелгән исем; шаярту кушаматы – кешене кимсетү, көлү максатында кулланылган исем; түбәнсетү кушаматы – кешене түбәнсетү максатында, сүз белән түбәнсетү өчен бирелгән исем; мәктәп кушаматы – мәктәптә укыган чорда бирелгән кушамат (Подольская, 1978: 116). Рус лингвисты А.М. Селищев исә кешенең физик кимчелекләрен ачу һәм кешегә

хас тискәре сыйфатларны күрсәтү кушамат белән исемне аеруда төп критерий дип билгели (Селищев, 2003: 407). Аның фикеренчә, борынгы чорда кушамат сүзнең мәгънәсенә тәңгәл килмәгән, ә сүз тамгасы функциясен генә үтәгән (Селищев, 2003: 408). Рус теле белемендә җирле мәдәниятккә бәйле кушаматлар Д.К. Зеленин тарафыннан аерыла. Мондый кушаматларны ул «присловье» дип атый һәм «бер затка гына түгел, ә географик яки этнографик берлектәге төкемгә хас кушаматлар» дип билдерә. Рус теле белемендә әлеге төр кушаматларны Н.В. Дранникова Себер территориясендә яшәүче рус халкының традицион мәдәнияте кысаларында өйрәнә (Дранникова, 2005). Ул кушаматны тел һәм фольклор арасында торган антропонимик категория буларак билгели. Кушамат фольклоры йола контекстында интертекстуаль мөнәсәбәттә төрле жанрларның барлыкка килүенә китерә. Димәк, кушаматлар аерым бер лексемаларга, мәкаль һәм әйтемнәргә, поэтик текстка, нарративка бәйле килергә мөмкин (Дранникова, 2005: 21).

Т.В. Шпар индивидның тышкы кыяфәтен һәм физик үзенчәлекләрен, холкын-характерын, һөнәри эшчәнлеген яки социаль статусын билгеләү семантик яктан мотивлашкан кушаматларны ачыклауда төп критерий дип саный. Кешенең физик үзенчәлекләрен чагылдырган кушаматлар күпчелекне тәшкил итеп, кешегә характеристика бирәләр, аның буен, гәүдәсен, чәч төсен, физиологик кимчелекләрен күрсәтә (Шпар, 2012: 14).

*Кушамат* термины составындагы *ат* сүзенең борынгы төрки телдә булуы аның бик күптәннән барлыкка килүен һәм, төп исемгә өстәмә буларак, элек-электән кулланылуын раслый. Борынгы заманнарда кушаматлар фамилия функциясен башкарганнар, ягъни кеше исеменә өстәлеп, шәхесне тагын да конкретлаштырганнар. Орхон-Енисей язмаларында, М. Кашгариның «Диване лөгатеттөрк» хезмәтендә, исем белән бергә, кушамат та аерым функция үти. М. Кашгариның әлеге сүзлегендә *at* сүзенең беренче мәгънәсе исем дип күрсәтелсә, икенче мәгънәсе – кушамат (Махмуд ал-Кашгари, 2010: 112).

Борынгы төрки язмаларда кушамат кешене төрле яктан сыйфатлап килә. Мәсәлән, Орхон-Енисей язмаларында кешенең физик һәм психологик үзенчәлекләрен сыйфатлаган кушаматлар төп исемгә ялганып килә һәм кешене төрле яктан характерлыйлар. Орхон-Енисей ташъязмаларында еш очрый торган *bilgä* кушаматы

«акыллы» (Кормушин, 2008: 318; Orhun Yazıtları, 2008: 129; ДТС, 1969: 99), *alp* «1) укчы, 2) герой, батыр, 3) курыкмас, кыю» (Кормушин, 315: Orhun Yazıtları, 2008: 120; ДТС, 1969: 36); *küčlüg* – «кыю, көчле» (Orhun Yazıtları, 2008: 156; ДТС, 1969: 323) дигәнне аңлаталар. Шул рәвешле, борынгы төрки чорның акыллы, көчле, кыю кеше образын реконструциялиләр. Исемнәрдән күренгәнчә, *bilgä* «акыллы» компоненты бинар исемнәрдә кулланыла. Эпитафик язмаларда чагылыш тапкан Билге Каган акыллы, сакчыл, йомшак күңелле кеше булган, шуңа күрә әлеге компонент исем составында килеп акыллылык мотивын чагылдыра (Айдаров, 1971: 102).

Борынгы төрки язмаларда көч мотивы *Küč* (Orhun Yazıtları, 2008: 156; ДТС, 1969: 322) кушаматы нигезендә чагылыш таба*: Küç Barlığ, Küç Kül Tutuk, Küç Tegin, Küç Temir, Kılıç Küç Kara, Küç Kıyagan.* Борынгы төркиләр көчнең Тәңре тарафыннан бирелүенә ышанганнар һәм әлеге кешеләрнең дә Тәңре тарафыннан яратылуына инанганнар. Борынгы төрки антропонимик системасында беренчел һәм икенчел антропонимик берәмлекләр арасында аерма булмый, әлеге категорияләр бер вазифа башкарганнар.

922 елда ислам диненең рәсми рәвештә кабул ителүе антропонимик системага да сизелерлек йогынты ясый. Мөселман мәдәнияте тәэсирендә антропонимик системада кушамат һәм исем антропонимик категорияләре арасына чик куела. Гасырлар дәвамында мөселман анторопонимик системасы белән янәшә төрки антропонимик системасы да кулланылышта була. Кешенең тормышын күзалларга мөмкинлек биргән титуллар, кушаматлар озак вакытлар исем белән бергә кулланылышта йөри. Мәсәлән, Алтын Урда чоры чыганакларында да традицион борынгы төрки исемнәрнең кулланылышын күзәтергә мөмкин: *Биш Куртук, Бука Тимур, Бәк Тимур, Ильбука, Ильтутмуш, Караболат, Карабаһадир* һ.б. (Становление..., 2011). Алтын Урда чоры чыганакларында борынгы төркиләрнең исемнәрендә хайван атамаларының кушамат ролендә килүе күзәтелә: *Бука Тимур, Биш Бука, Арык Буга* һ.б. Хайван тотемнары белән бирелгән кушаматлар шәхеснең нәсел-нәсәбе, ыру башлыгының исеме турында да мәгълүмат бирәләр.

XVI–XVII гасыр «писцовая» кенәгәләрендә исем белән кушамат аерылып бетмәгән антропонимик компонентлар очрый: *Кучук* (кечкенә), *Кәтүк* (кечкенә); *Тулыбай* < «тулы + бай»; *Күкеш, Сы-*

*тыш* кушаматларының сәламәт булмаган балага бирелүе турында искәртелә (Писцовая книга – 1, Писцовая книга – 2).

XVIII гасырга караган «Ревизия кенәгәләрендә» исемнәр белән бергә кушаматлар кулланылышы күзәтелә: *Карабаш Гали, Сабай Ишкенә* һ.б. *Карабаш, Сабай* кебек компонентлар кушамат ролен үтәп, рәсми кенәгәләрдә теркәлгәннәр. Тарихи чыганакларда төрки-татар исемнәренең зур өлешен кушаматлар тәшкил итәләр. Татар исемнәре, бер яктан, кушамат буларак кыскарып үзгәреш кичерсә, икенче яктан, әлеге кушаматлар гарәп һәм рус теленең яңгыраш, үзенчәлекләренә бәйле бозыла: *Мамай (Мәмеш, Мәмәд, Махмед) Мөхәммәд*, *Камай (Камалетдин), Колай (Коләхмәт), Малей (Мәли, Малик), Шамса, Шемай, Шәмәй, Шәмси (Шәмсетдин), Баһау, Багыш, Баһдан (Баһаветдин)*. Тарихи чыганакларда кешенең үзенчәлекләрен сыйфатлаган кушаматлар да бирелгән: *Кылый Гали, Тупас, Чуан Төмән, Йомык, Алабаш, Елый Бирде, Каражҫан, Аксак Тимер, Тәбәнәк, Аңнамас, Артык* (Ревизская сказка, ф. 3, оп. 2). Мәсәлән, *Мамайның* (Олы Урда ханы) икенче исеме буларак язмаларда «*Тетякъ» (Титәк, Тинтәк*) атамасы күрсәтелә.

Кушаматлар аралашуны җиңеләйтү, кем турында сүз барганын төгәл, ачык белдерүче антропонимик чара булып санала. Г.Ф. Саттаров кушаматларны зур өч төркемгә бүлеп карый: 1) нәсел-ыру кушаматлары, 2) шәхси кушаматлар; 3) локаль культурага нисбәтле кушаматлар (Саттаров, 1973: 46). Әлеге төркемнәрнең үзләренә генә хас билгеләре, үзенчәлекләре бар. Инде аларның төрләренә тукталып китик.

Нәсел-ыру кушаматлары бер генә шәхескә карамыйча, туганлык мөнәсәбәтләрендә торган бер төркем, берничә гаилә, нәсел кешеләрен үз эченә ала. Бу төр кушаматларның үзенчәлекле ягы булып, буыннан-буынга күчүчәнлек, дәвамчанлык санала. Мәсәлән, *Чупай* кушаматы нәсел чылбырын бәйләү вазифасын үти (Татар шәҗәрәләре, 2013: 98).

Димәк, нәсел-ыру кушаматы шул ук вакытта аны билгеле бер нәсел, гаилә эченә алып керә. Әлеге төр кушаматларның килеп чыгышын һәм мәгънәләрен татар халкының борынгы бабалары яшәгән чордан, болгар катламыннан һәм башка кардәш һәм кардәш булмаган телләр материалларыннан эзләгәндә ачыклап була. Кушаматның төрләре әдәби әсәрләрдә кулланылып,

этномәдәни текст вазифасын үтиләр һәм әдип иҗат иткән чорга хас үзенчәлекләрне, образлар системасын барлыкка китерүдә, персонажларның үзара мөнәсәбәтләрен интерпретацияләүдә зур роль уйный. Татарларның локаль культураларында, аерым алганда, Түбән Новгород татарларының Камка авылында *Нәмай, Тукай, Бакнәй* кебек нәсел кушаматларының билгеләнүе ассызыклана (Милли-мәдәни мирасыбыз: Түбән Новгород, 2011: 26). Әдип тарафыннан әсәр тукымасына кертелгән кушаматлар әсәрнең әдәби-эстетик концепциясен тормышка ашыруның бер чарасы булып, аның темасын һәм тирән мәгънәви идеясен ачарга ярдәм итәләр. Мәсәлән, нәсел-ыру кушаматлары Г. Ибраһимов хикәяләрендә билгеләнеп, аларга аерым игътибар ителә. Әлеге төр кушаматларны куллану авторга нәсел җебен барлауда оста әдәби алым буларак файдаланыла: «Бара торгач, «ала» сы төшеп югала, «саескан» исеме «малайга кушамат булып ябышып кала. Зурайгач, бай крестьян булгач та төшми. Сөләйманнан нәсел буенча Нурыйларга күчә. Кимсетеп әйткәндә: «Саескан» дип, «Саескан Нурый» дип, «Саескан Нурый Фәтхиясе», «Саескан Нурый балалары» дип йөртәләр.

Ш ә х с и  к у ш а м а т л а р дип конкрет шәхескә караган кушаматны атыйлар. Конкрет шәхесне белдереп, шәхси кушамат һәрвакыт берлек санда гына кулланыла: *Шөлди, Кабартма, Морҗа, Нәкыйп Борчак* һ.б. Нәсел-ыру кушаматларыннан аермалы буларак, барлык шәхси кушаматларның да диярлек барлыкка килү мотивлары, сәбәпләре билгеле. Татар әдәбиятында язучылар шәхси кушамат тагуны аерым әдәби алым итеп кулланалар һәм әдәби әсәрләрдә кушамат тагылуның мотив-сәбәпләрен ачыклаган матур үрнәкләр белән күп очрашырга мөмкин. Мисал итеп, Ә. Сәлах «Аккан сулар...» әсәрендә авыл җирлегендә кушамат тагу турында болай дип яза: «Безнең авыл халкы бер-берсенә кушамат куярга хирыс. Ялгыш авызың кыйшайса да сиңа кушамат чәпәп куялар. Капка Минач абзыйның кушаматы бер генә түгел берничә иде. Сугыштан яраланып аксак аяк белән кайтканда бу абзый: «Мин бик зур елга – Кунай елгасын кичкәндә ранный булдым» – дип сөйләп йөргән өчен безнең мишәрләрдә шул җиткән. Ләкин алдан бирелеп дистәләрчә еллар буе аклап килгән «Камка» кушаматы үз позициясен тиз генә бирмәгән: Минач абзый элеккечә «Камка» булып калган, ә үсеп килгән улы Салихка «Кунай». кушаматы

тагылып киткән» (Казан утлары, 2017, № 3: 7–8). Шәхси кушаматлар реаль чынбарлыкка туры киләләр һәм аның белән тыгыз бәйләнелештә торалар. Әлеге төр кушаматлар шәхеснең яшь үзенчәлекләрен, мәсләген, характер үзенчәлегенә мөнәсәбәттә барлыкка киләләр. Кайберләре исә теге яки бу эшне башкарган вакытта да тагылып калалар: *Итекче, Тимерче, Кырык Тартмачы* һ.б.

Мари Эл Республикасы Бәрәңге районына оештырылган экспедиция вакытында түбәндәге шәхси кушаматлар тупланыла: *Кәтүкнекеләр, Мамыклар, Черки Зиннуры, утыр Мәннан, Козгын Абдулы, Тукран, Көртлек, Чыпчык, Таракан Мансуры, Күкәлти, Эчәге Мансуры, Арыш Абдулы* һ.б. (Милли-мәдәни мирасыбыз: Мари Эл татарлары. Бәрәңге, 2012: 159).

Локаль культурага бәйле кушаматлар дип туганлык мөнәсәбәтләрендә тормаган, ләкин территориаль яктан бәйләнешле булган кешеләр тарафыннан берләштерелгән кушаматларга әйтәләр. Әлеге кушаматлар күплек санда бирелә, ә берлек санда кулланылса, шул төркемнең, коллективның бер вәкилен генә күрсәтә. Локаль культурага бәйле кушаматлар аерым бер җирле берләшмәне идентификацияләүгә тәэсир итә торган төрле стереотип күзаллауларга нигезләнеп ясалалар. Мәсәлән, һәрбер коллектив кушамат «үз» һәм «чит» төркемнәре белән билгеләнгән берәр сыйфат аерып тора. Бер үк номинация төрле локаль төркемнәрдә төрле сыйфатларга ия булырга мөмкин. Томск татарларының топонимиясен өйрәнүче О.Р. Хисамов саз ягы татарларының «*тычкан тухум*», яки «*черки тухум*» дип аталып йөрүләрен билгели (Хисамов, 2016: 11). Биектау районы Дөбьяз, Әрәз, Торнаяз, Каракүл авылларында яшәүчеләрне Казан базарына сөт, катык ташыганга «*әче катыклар*» дигән кушамат тагып йөртәләр. Әлеге кушаматлар локаль-территориаль кушамат төренә керә.

Димәк, татар антропонимик системасында кушаматлар, этномәдәни тирәлекнең мөһим берәмлеге буларак, исем йөртүче белән исем бирүче арасындагы уңай яки тискәре мөнәсәбәтне билдереп, кешегә хас характер үзенчәлекләренең күләмен яктыртып, аерым бер локаль-территориаль, нәсел-ыруга хас үзенчәлекләрне чагылыдырып, исем бирүченең прагматик максатларын тормышка ашырып, шәхси һәм тирә-юнь, мохит, дөнья картинасын ачуда исем бирү сәнгатенең мөмкинлекләрен тулысы белән реальләштергән антропонимик берәмлекләрне тәшкил итәләр.

## § 13. Татар халкында кушамат бирү мотивлары

Кушаматлар, номинатив, шәхесне идентификацияләү, аеру вазифасыннан тыш, әдәби стилистик функция дә үтиләр. Вербаль-семантик яктан караганда, кушаматларда исем бирү сәнгатенең төрле мөмкинлекләре ачыла. Когнитив яктан кушаматлар милли үзбилгеләнү һәм милләтнең характер үзенчәлекләрен чагылдыру мөмкинлегенә ия. Прагматик яктан караганда, кушаматлар билгеле бер социаль катлауның төрле коммуникатив шартларын яктырталар. Мәсәлән, татар кушаматлары арасында билгеле бер вакыйгаларга бәйле кушаматлар бар: *Капчык Мөхәммәтҗан* (колхозда арыш урлауга бәйле вакыйгага нисбәтле), *Баттат Фәүзия* (баттат ашау вакыйгасына бәйле тагылган кушамат) һ.б.

Матур әдәбиятта кушаматлар, әсәр тукымасына эмоциональ-экспрессив төсмерләрне куертып, образны тагы да калкурак күрсәтү максатында, татар авылы колоритының тулы бер палитрасын чагылдыруда язучылар тарафыннан отышлы кулланыла: *Буйга зурлыгы өчен аны Озын Хафиз дип йөртәләр* (Г. Ибраһимов «Алмачуар»). *Күршенең калын Низами дигән берәү калага бара икән* (Г. Ибраһимов «Тирән тамырлар»). *Аның артыннан Назлы килен Гыйззелбанат, Төхфәтнең хатыны Усал тел килен Мәрфуга, аларга ияреп бергә үскән кызлар* (Г. Ибраһимов «Татар хатыны ниләр күрми»).

Әгәр язучы кушаматны милли антропонимиконының үзенчәлекләренә туры китереп кулланса, образның семантик-стилистик яктан мәгънә күләме арта яисә әсәр турында тулаем фикер тирәнәя. Кушамат шәхеснең яшен (*Йөз яшь Сафа*), җәмгыятьтәге урынын (*Тимерче Фатыйх, Повар Фатыйма*), физик һәм психологик кимчелекләрен (*Чатан Шәмси, Чукрак Хәлил*), шәхескә карата булган тискәре яки уңай мөнәсәбәтен (*Яхшы Рамилә, Яман Фәрит*) дә чагылдырырга мөмкин. Нигездә әлеге шәхес турындагы мәгълүматлар әсәр контексты эчендә ачылалар. Хәзерге татар әдәбиятында Ахир, Ф. Бәйрәмова, Р. Газиз, Н. Гыйматдинова, Т. Галиуллин, Ә. Сәлах, Р. Батулла кебек күренекле язучылар иҗатларында кушаматларны, әдәби алым буларак оста итеп файдаланалар: *Кыргыз Әхмәдулла* (Ә. Сәлах «Аккан сулар...»); *Бәкер Вафич* (Р. Газизов «Гаян абый хат укый»); *Пытыр Хәлимәсе* (Ахир «Кәбисә елы») һ.б.

Тотемистик карашлар нигезендә барлыкка килгән кушаматлар хәзерге татар антропонимик системасында да традиция нигезендә

сакланалар. Шәхси кушаматлар исә теге яки бу шәхеснең төрле сыйфатларына нигезләнгән метафорик эчтәлек биреп, чыгышлары буенча реаль чынбарлык белән тыгыз бәйләнештә булалар. Алар кешенең гомуми, хосусый, физик һәм рухи сыйфатларын, профессиясенә, яшәү урынына һәм башка мотивларга нигезләнеп кушылалар. Балага исемне, тугач та, әти-әнисе бирсә, кушаматны кешенең яшәү дәверендә төрле этапларында коллектив яки аерым кешеләр куша. Бу төр кушаматлар составы, иҗтимагый һәм мәдәни тормыш контекстында даими үзгәреп, яңарып торалар.

Шәхси кушаматларның күбесе кешенең теге яки бу сыйфатын, рухи яки физик билгеләрен турыдан-туры атау юлы белән ясала: *Ут Җамал, Баламык Дания, Мыштыр Рушан, Пөхтә Камилә, Гамьсез Фәрит* һ.б. Кешенең рухи яки физик сыйфатларын теге яки бу предметка, күренешкә, кош-корт яки хайванга охшату нигезендә барлыкка килгән кушаматлар байтак. Мәсәлән, *Күсе* – төрле әйбер җыярга һәвәслек, *Борча* – кечкенә буйлы, бик хәрәкәтчән яки тиктормас кешегә тагылган кушамат; *Акылбай* – акыллы булганга тагылган кушамат, *Чүпрәкбаш Дилбәр* – надан булганга бирелгән кушамат һ.б. Шәхси кушаматлар кешенең профессиясенә (*Итекче Гата, Маляр Саҗидә* һ.б.), эшләү яки яшәү урынына (*Су буе Гайшә, Мамадыш Саимә, Түбән оч Лилия* һ.б.), милләтенә (*Үзбәк Сания, Әрмән Галиясе*), социаль чыгышына (*Зимагур Азат, Укытучы Алия* һ.б.), берәр сүзне еш кабатлау яки үзенчә әйтүенә (*Р-Р-Р-Р Әдилә, Ватык Трактор Сәмих*), рәсми исемен бозып әйтүгә мөнәсәбәтле рәвештә дә (*Сәмук –Сәмигулла, Әптерүч – Габдерәүф, Шәмәй – Шәмсетдин* һ.б.) барлыкка килгән. Топонимнарга яки микротопонимнарга нигезләнеп ясалган кушаматлар, башлыча, шәхеснең нинди торак пункттан булуына яки кая да булса барып кайтуына мөнәсәбәтле рәвештә барлыкка килеп, этномәдәни тирәлекне билгелиләр: *Норма Сәми*, *Норма Ягъфәр*, *Чишмә башы Газиз*, *Өчиле Зөлкамал*, *Көҗмә Микулай* һ.б.

Этнонимнарга нисбәтле кушаматлар кешенең теге яки бу милләт вәкиле булуына яки әлеге милләт вәкиленә физик яктан охшашлыгына ишарәли: *Чирмеш*, *Үзбәк бабай*, *Мишәр Галия* һ.б. Матур әдәбиятта исә әлеге кушаматлар шәхеснең милли чыгышына яки аның башка этник төркем вәкилләренә берәр ягы белән охшашлыгына яисә бәйләнешенә нисбәтле кулланылалар.

Татар антропонимик системасында антропонимнарга мөнәсәбәтле кушаматлар билгеләнәләр. Әлеге төркемгә караган кушаматлар шәхеснең ерак бабасына бәйле яки аның икенче берәүгә охшату җирлегендә барлыкка килә: а) шәхеснең нәселенә нигез салган ерак бабасының исеменә нисбәтле кушаматлар: *Гайфи Исхагы*, *Шаһи Саниясе*, *Куян Сәхие*, *Куян Зарифы*, *Куян Кәримулласы, Куян Вакыйфы*; *Галәви Шакиры*; ә) шәхеснең үз исемен бозып әйтү нигезендә ясалган кушаматлар: *Сөләй Әмәт* (Әхмәтне бозып әйтү юлы белән барлыкка килгән кушамат), *Нурла* (Нурулла исеменнән), *Дәлтүн* (дальтон сүзен дөрес әйтә белмәгәнгә), *Прох* (Прохов Вадим).

Шәхеснең кәсебе-һөнәренә, профессиясенә яки эшләү урынына мөнәсәбәтле кушаматлар да чагылыш таба. Мондый кушаматлар күбесе хәзерге профессия атамаларына нигезләнеп ясалганнар. Шулай ук хәзерге вакытта онытылып бара торган һөнәр, кәсеп исемнәренә нисбәтле кушаматларның да очравы күзәтелә: *Сунарчы Сәбәк*, *Атҗабар Минниса*, *Итекче Җиһанша*, *Тимерче Нотфый*; *Көтүче Хөснетдин*, *Прит Әлфинур, Силсәвит Мәдинә*, *Умартачы Равил* һ.б. Шәхеснең яки аның ата-бабаларының титулына, социаль чыгышына мөнәсәбәтле кушаматлар да очрый: *Зимагур Булат*, *Алпавыт Шәйхи*, *Зимагур* һ.б.

Кешенең характерында аерата калку тискәре яки уңай сыйфатларының исеме, еш кына, аңа кушамат итеп тагыла: *Түтүт Гарифы*, *Сәдака Миңнехан*, *Шәвәли Шәвәлиеч*; *Канәгать Мыштым, Псих Сәлимгәрәевич*; *Кире Урай*, *Дуамал Касыйм*, *Җүләр Әйдүш* һ.б. Г. Ибраһимов әсәрләрендә персонажларның эш-хәрәкәтләре, төс-кыяфәте, сөйләшү манерасы, мәсләк үзенчәлекләре нигезендә тагылган кушаматалар билгеләнә: *Аны һәммәсе кимсетәләр, яратмыйлар, җәберлиләр, теләгәнчә мыскыллыйлар, исеме белән дәшмичә, башы зурлыктан, «Тубал» дип кенә йөртәләр* (Г. Ибраһимов «Уты сүнгән җәһәннәм»). Биредә кулланылган *тубал* сүзе денотатның зур башлы булуын гына сыйфатлап калмый, ә хикәядә Тубалның аң-белемгә, гыйлемгә омтылучан булуын ассызыклау өчен файдаланыла. Персонажның кушаматы «тубал булу», ягъни артык күп уйлаудан яки шау-шудан баш авыраю дигән мәгънәгә дә барып тоташа.

Шәхеснең тышкы физик билгеләрен характерлый торган кушаматлар хәзерге татар әдәбияты әсәрләрендә зур күпчелекне

тәшкил итәләр: *Бүдәнә Салих*, *Бәләкәй Камилә*, *Сары Сәвия*, *Агулы теш Миңлегали*, *Зур колак Иван*, *Ташмаңгай, Тимертән*, *Киңкүкрәк Иван*, *Таз*, *Чатан Хәниф*, *Шадра, Таз, Бөкре* һ.б. Шәхеснең чиренә нисбәтле кушаматлар: *Кылый Нигмәтҗан, Бөкре Гафият, Чулак Газиз, Чатан, Кылый, Аксак* һ.б.

Кушаматта кулланылган квалитативлар иркәләү-кечерәйтү төсмерләренең киң спектрдагы мәгънәләрен бирәләр, үз чиратында әлеге коннотатив мәгънәләр кешегә карата гына түгел, ә сөйләм субъектына карата да мөнәсәбәт чагылдыралар. Кешенең төскыяфәтен, хәрәкәтләрен, тормышка карашын характерлый торган кушаматлар арасында нигездә тискәре семантикага ия сүзләр урын алган. Әсәрдә башка кешеләрдән аеру максатында, квалификатив принцип нигезендә, теге яки бу сүзнең семантик тулылыгына басым ясаган кушаматлар персонажның тышкы кыяфәтенең үзенчәлекләрен сыйфатлыйлар: *Тирә-якта аларның авыллары Бикъярны: «Көяз», – дип, «Бикъяр көязләре» дип мыскыллап сөйлиләр* (Г. Ибраһимов «Татар хатыны ниләр күрми»). *Базарда юк кына нәрсә өчен теге Сыераяк Хәмди белән әрләшеп китте* (Г. Ибраһимов «Татар хатыны ниләр күрми»). *Тиле Әхмәт үз ирке белән диярлек килеп бирелде* (Г. Ибраһимов «Тирән тамырлар»).

Нәсел тамгасын белдерә торган хайван атамалары яки билгеле бер хайван, кош-корт ияләренә охшату нигезендә барлыкка килгән кушаматлар да очрый: *Бүре Гыйбадулласы, Бүре Бадул, Бүре Әскый; Күгәрчен Мөхетдин, Шимпанзе, Кабантеш Сәгъдәт, Чикерткә Рәхимәсе* һ.б. Г. Ибраһимов «Татар хатыны ниләр күрми» әсәрендә *Кәҗә Солтаны* кушаматы тагылуын болай дип аңлата: «Сабираның атасы Солтан заманында сунарчы булган, диләр. Бервакыт үзенең бер дус адәмендә әче балны эчеп, кызыбрак чыккан да зур мөгезле ак кәҗәне болан дип, поши дип, аты белән куып киткән, диләр. Авылдагы дошман байлары, җәй, кыш мәптекккә ятучы бер аксак хәлфәгә тутырган тавык, илле тиен акча биреп, зур бәет чыгарттылар. Бу бәетне, өйдән өйгә кереп, садака җыеп йөрүче бер сукыр хәерчегә ятлаттылыр. Халыкка бик кызык тоелды. Бер тиен акча, ике йомырка биргән һәркемгә сукыр хәерче Солтан турындагы бәетне укып чыга торган булды. Шуннан солтанга – Кәҗә Солтан дип ат куштылар» («Татар хатыны ниләр күрми»).

Шәхес белән бәйләнешле берәр кызыклы вакыйга яисә аңа карата әйтелгән нинди дә булса көлкеле сүзгә нисбәтле кушаматлар

да аерым урын тоталар. Кушаматлар көлке тудыру алымы буларак кулланылалар һәм әсәр тукымасына реальлек төсмерләре өстиләр. Мәсәлән, язучы Р. Газиз «Кичер, кичерә алсаң...» әсәрендә геройга кушамат тагылуын болай дип аңлата: «Безнең авылда Вәгыйз абыйның гына ике кушаматы бар. Берсе – Герман, чөнки бу – аның яраткан сүгенү сүзе. Икенчесе соңгы елларда гына тагылды. Анысы – Күкеле сәгать. Әйе шул. Нәкъ тәрәзәсе шалт итеп ачылып, аннан ялт итеп Вәгыйз абый башы атылып чыккан авылдашлары таккан кушамат. Авыл тарихында булмаган байлык, бер кешегә ике кушамат («Кичер, кичерә алсаң...»). А. Хәлимнең «Сәер никрут» хикәясендә Күгәрчен Мөхетдин исемле персонажның кушаматы яраланган күгәрчен вакыйгасына бәйләнелешле аңлатыла. Әсәрдә Мөхетдин бодай өеменнән кошларны куганда, агач көрәк белән сугып, бер күгәрченне каты җәрәхәтли. Шул яраланган кошны ике учына алып, ул ярты көн елап утыра. Күгәрченне өенә алып кайта. Медпунктка фельдшер янына алып төшә. Шуннан соң гына күгәрчен исән кала. Әлеге вакыйгадан соң Мөхетдинне Күгәрчен Мөхетдин дип атый башлыйлар.

Кушаматлар эмоциональ-экспрессив тирәлектә барлыкка килеп, әдәби алым буларак, язучылар тарафыннан отышлы кулланылалар. Хәзерге татар әдәбиятында әлеге әдәби алымның бик уңышлы мисаллары күзәтелә. Әдәби әсәр тукымасына кертеп җибәрелгән кушаматлар телнең этномәдәни тирәлегенең моделен гәүдәләндереп, әсәрнең төп мәсьәләләрен һәм тирән фикерләрен, әдәби-эстетик концепциясен чагылдыру алымы ролен үтиләр. Кушаматларның антропонимик трансформацияләре, сюжет линияләрен куерту, эмоциональ-экспрессив яки юмористик төсмерләр бирүдән тыш, геройның характер үсеш-үзгәрешен дә ачарга ярдәм итәләр.

# ТАТАР ТОПОНИМИКАСЫ

## § 14. Топонимика фәненә гомуми билгеләмә

Ономастик системаның бер өлешен топонимия тәшкил итә. Топонимика фәненә тулырак аңлатма бирү максатыннан, беренче чиратта, ономастик система турында аңлатма бирү күздә тотыла. Ономастик система – «аерым бер этносның билгеле бер вакыт аралагындагы эчке яктан оешкан ономастик модельләр бердәмлеген күз алдында тота торган тел системасының бер өлеше» (Суперанская, 1984: 175). Телнең ономастик системасында концептуаль әһәмияткә ия булып *ономастик даирә*, *ономастик өзлексезлек*, *ономастик кыр*, *рәт*, *универсалия* кебек төшенчәләр санала.

Билгеле бер халык тарафыннан билгеле бер вакыт аралыгында реаль, фараз ителгән һәм фантастик объектларны атау өчен кулланылган барлык төр ялгызлык исемнәр комплексы ономастик даирә төшенчәсен тәшкил итә (Суперанская, 2009: 9). *Ономастик даирә* дәвердән дәвергә, халыктан халыкка аерым бер исем-атамалар, төрле категориягә караган объектларны белдергән лексик катламнар исәбенә үзгәреш кичерә. Төшенчәнең әлеге үзенчәлегеннән чыгып, *ономастик даирә* атап килгән объектларына бәйле төстә аерым төркемнәргә бүленә. Ономастикада алар, атау объектларына карап, *топонимнар, антропонимнар, зоонимнар, космонимнар, фитонимнар, эпонимнарга* бүлеп өйрәнеләләр. Бу төркемнәрнең һәрберсе реаль (*реалоним*), яисә уйланма (*мифоним*) объект атамаларын үз эченә кертә.

Төрле төркемнәргә караган ялгызлык исемнәр үзара тыгыз бәйләнештә торалар. Әлеге бәйләнеш ономастик өзлексезлек, яисә ономастик континуум дип атала (Суперанская, 2009: 12). Өзлексезлек, безнең барлыгыбыздагы һәр күренеш кебек үк,

һәр даирәдә һәм вакыт эчендә үсеш кичерә, һәм аның мәдәни өзлексезлектән гыйбарәт булган үз үзенчәлеге бар. Әлеге мәдәни өзлексезлек төрле ил һәм мәдәният кешеләре тарафыннан барлыкка китерелгән үзенчәлекле исемнәр бәйләнешенә ия. Географик атамалар ничек кенә үзгәрмәсен, яңалары белән беррәттән, элекке атамалар да сакланып кала. Шуның белән бергә, борынгырак атамалар, халыкның элеккеге күчешләрен тасвирлап, җирлекне башка территорияләр белән бәйли ала. Географик атамаларда кешенең исем-кушаматларын очратабыз, яисә, киресенчә, фамилияләрдә без кешенең туган җире атамасын табабыз. Бер-берсе белән төрле мөнәсәбәтләргә кереп, ялгызлык исемнәр ономастик даирәнең теге яки бу төркемен баеталар. Шуңа нисбәтле, күп гасырлар дәвамында халыкларның бер объект исемен башка объектка шул ук исем белән күчерүе ономастика фәнендә *трансонимлашу* дип атала (Теория и методика..., 1986: 46).

Ономастикада килеп чыгышлары башка класска караган ялгызлык исемнәреннән барлыкка килгән географик атамаларны эпонимик ясалышка (эпонимик ясалыш – кеше исемнәренә, фамилияләргә, этнонимнарга һ.б.га нигезләнеп ясалган топонимнар), ә турыдан-туры күмәклек исемнәреннән ясалган ялгызлык исемнәрен апеллятив ясалышка кертәләр (Подольская, 1969: 142). Мәсәлән, *Аксубай* авылы атамасының эпонимы *Аксубай* дигән борынгы төрки-татар кеше исеме, *Шадрин* фамилиясенең эпонимы *Шадра* кушаматы. Татарстанның Минзәлә районындагы *Шадрин* авылының исеме *Шадрин* фамилиясенә нигезләнеп ясалган. Ул кушамат *Шадрин* фамилиясе йөрткән шәхеснең этисенә, бабасына бите *шадра* булудан чыгып тагылган булган, ягъни бу кушамат үзе турыдан-туры күмәклек сүзгә (апеллятивка) нигезләнеп барлыкка килгән (Саттаров, 1998: 10).

Этнотопонимнар да эпонимик ясалыштан гыйбарәт булалар. Мәсәлән, мукшы (мордва халкы составына кергән кабилә исеме) этнонимыннан Арча районында *Мукшы*, Аксубай районында *Иске Мукшы, Яңа Мукшы* дигән авыллар барлыкка килгән.

Ономастик кыр – билгеле бер төр онимнан торган ономастик яссылыкның бер өлеше (Подольская, 1978: 103). Ономастик материалны систематик оештыруда *ономастик кыр* һәм *ономастик рәтләр* иерархиясе әһәмияткә ия. *Ономастик рәт* – телнең лексик-морфологик материалы белән чикләнгән уртак дифференциаль

билгеләргә ия онимнар җыелмасы. Ялгызлык исемнәрен чагыштырма планда өйрәнү барышында *ономастик унверсалияләр* кебек уртак үзенчәлекләр калкып чыга. *Ономастик универсалияләр* – күп төрле телләргә хас булган, кешелекнең атау өлкәсендә уртак фикер барышын гәүдәләндергән ономастик күренешләр (Подольская, 1978: 100).

Ономастик системага хас үзенчәлекләрнең берсе – ономастик даирәнең бар өлешләренә караган исем системаларының бер-берсе белән бердәмләшүе.

Ономастикага караган башка өлкәләр белән аваздаш булган системаларның берсе – т о п о н и м и к  с и с т е м а. Э.М. Мурзаев аңа түбәндәге билгеләмәне бирә: «*Топонимик система* – географик атамаларның барлыкка килү процессында кагыйдә буларак кабатланган үзенчәлекле билгеләр җыелмасы» (Мурзаев, 1974: 24–25). Ономаст А.В. Суперанская әлеге төшенчәне тагын да тулыландырып: «*Топонимик система* ул – территориаль яктан оешкан топонигезләр һәм топоформантлар, шулай ук аларның үзара бәйләнеш кагыйдәләре һәм ысуллары җыелмасы», дип әйтә (Суперанская, 1984: 108). Н.В. Подольская аны түбәндәгечә күрсәтә: «Билгеле бер территориядә, билгеле бер вакытка һәм этноска караган аерым бер рәвештә оешкан топонимнар җыелмасы» (Подольская, 1978: 46). Димәк, *топоним* – теге яисә бу географик объектны башкалардан урын, вакыт, тел һәм язу контексты мөнәсәбәтендә аеру өчен хезмәт иткән ялгызлык исем.

Топонимик системаны т о п о н и м н а р (грек. *topos* – урын, урынчылык, өлкә, ил; *onoma* – исем, атама) (Подольская, 1978: 136), ягъни теләсә кайсы географик объект атамасы тәшкил итә. Үзенчәлекле билгеләре буенча алар *ойконим, ороним, гидроним, микротопоним* һ.б.ларга бүленәләр. Топонимик система төрле телләрдәге топонимик материалны аерым бер сыйфатларга ия топонимик төркемнәргә берләштерә. Димәк, топонимик система күп очракта тел уртаклыгы белән түгел, ә территориаль уртаклык белән билгеләнә, чөнки төрле телдә сөйләшүче халык яшәгән чиктәш территорияләрдә әлеге күренеш системалы характерда була. Шулай итеп, система бер үк территориядә төрле вакытта һәм төрле телләр нигезендә формалашкан атамаларны якынайта да. Бу очракта система, уртак кануннарга буйсындыру, аларга охшашлык төсмере бирү һәм аларның дифференциацияләнүенә этәргеч булу

нәтиҗәсендә, аерым бер топонимнарны үзгәртеп коруда әһәмиятле урын тота.

Билгеле бер регионның топонимик системасы үзенчәлекләре җирле халыкларның психологиясе, үзаңы, көнкүреше, әйләнә-тирә дөньяны күзаллаудагы уртаклыктан гыйбарәт. Төрле регионнарның топонимик системасы бер-берсеннән аңа кергән элементлар составы һәм аларның үзара бәйләнеше белән аерылып тора. Топонимнар җыелмасы – *топонимия* –топонимика фәне кысаларында өйрәнелә. Ул ономастиканың бер бүлеге булып тора.

Топонимика – ул географик объектларның барлыкка килү һәм үсеш тарихын, таралышын, кулланылышын, лингвистик төзелешен, формасын, семантикасын (мәгънәви ягы), синонимиясен, орфография (дөрес язу) һәм орфоэпия (дөрес әйтү) кагыйдәләрен эшкәртә, шулай ук картографиядә кабул ителгән шрифтларны кулланып, язудагы системаларга таянып, атамаларны картада сурәтләү ысулларын өйрәнә. Топонимика тел белеменең иң мавыктыргыч һәм кызыклы өлкәләренең берсе. Аның өйрәнү объекты – *топоним*, ягъни нинди дә булса географик объектның исеме.

Топонимик стратиграфия аерым бер халыкның озак вакытлар дәвамында бер территориядә яшәве нәтиҗәсендә барлыкка килгән топонимнар комплексы булып тора (Мурзаев, 1974: 25). Димәк, топонимик тикшеренүләрнең иң әһәмиятле бурычларының берсе – теге яки бу атаманың таралыш чикләрен билгеләү. Әлеге чикләр бу төр һәм формантларның таралыш ареалларын тәшкил итәләр. Аларны өйрәнү теге яки бу халыкның тарихи үткәндәге күченүләрен күзәтергә, халык миграциясен билгеләргә ярдәм итәргә мөмкин.

Топонимик спектр дип кайсы да булса бер территориядә килеп чыгышы ягыннан башка телләргә караган географик атамалар җыелмасына әйтәләр. Мәсәлән, Татарстан территориясендә төрки-татар, фин-угор, рус һ.б. телләргә караган атамалар бар. Торак пункт атамалары спектры, кагыйдә буларак, гидронимнар спектрыннан аерыла.

Географик атамаларның структурасын тәшкил иткән элементлар рәтенә *топонигез, топоформант* һәм *топонимик апеллятивлар* кебек төшенчәләр карый. Алар топонимик система эчендә каралалар.

Топонигез – географик атаманың мәгънәви компоненты, ягъни топонимның нигезе (Суперанская, 1984: 175). Топонигезләр

мөстәкыйль рәвештә кулланылмыйлар. Алар һәрвакыт ярдәмче элементлар белән тулыландырыла һәм формалаштырыла. Мондый ярдәмче элементларны *топоформантлар* дип атыйлар. Топоформант – бер яисә берничә кушымча ярдәмендә формалашкан, топонимнарны махсус сүзләр буларак танытуга хезмәт иткән һәм аларның билгеле бер төркем, төр, рәткә караганына ишарә ясаган топоним составындагы ярдәмче компонент (Суперанская, 1984: 175). Теләсә кайсы топонимның состав өлешен тәшкил иткән әлеге ике компонентны бер-берсеннән аерып карау мөмкин түгел, чөнки, структур яктан караганда, формант һәр топоним составында, хәтта бер сүз буларак каралган топонимнарда да бар. Топонигезләрне икегә: императив һәм факультатив төрләргә аерырга мөмкин. Беренчеләре «объект табигате – топоним» сызыгында торалар. Шунлыктан алар географик объект ландшафтын билдергән сүзләр белән генә чикләнәләр. Икенчеләре исә, «кеше һәм аның эшчәнлеге»н тәшкил итәләр.

Топонимик апеллятивлар, ялгызлык исемнәрдән аермалы буларак, *уртаклык исемнәре* дип атала (Подольская, 1978: 37). Топонимик апеллятивлар шактый җиңел ялгызлык атамасын барлыкка китерә торган сүзләр категориясенә керәләр. Алар, үзләренең лексик мәгънәләрен югалтып, онимик нигез булып калалар. Апеллятив лексиканың ялгызлык исемнәрен ясавы борынгы ысуллардан санала.

Югарыда тасвирланган элементлар топонимнарның эчке һәм тышкы билгеләрен, ягъни топонимик модельләрне – топонимик төргә берләштергән топонимнарның ясалу формуласын тәшкил итә (Подольская, 1978: 145).

*Топонимик төр* телнең характерлы төрләрен ачыклый һәм телләр классификациясенә барып тоташа. *Топонимик модель* һәм *топоформанттан* аермалы буларак, топонимик төр – топонимиканың барлык аспектларын үз эченә алган комплекслы төшенчә. Моңа шулай ук топонимнарның төзелеш-ясалыш үзенчәлекләре дә, топоним составындагы элементларның үзара нинди мөнәсәбәттә торулары да карый.

Шулай итеп, катлаулы топонимик системаларның берсе буларак, теләсә кайсы телнең топонимик системасы үзенчәлекле шартларда формалаша һәм системалы өйрәнүне таләп итә. Ул үзара бәйләнештә торган, ономастик даирәнең барлык өлкәләренә

караган элементларны үз эченә ала һәм, шул рәвешле, үзенчәлекле материал булып тора.

## § 15. Топонимика фәненең тармаклары

Географик объектларның атамалары объектның үзе, аның тарихы һәм лингвистик табигате турында күп төрле мәгълүмат саклыйлар. Бу мәгълүматларны өйрәнү белән топонимика фәне шөгыльләнә. Һәрбер телнең, шул исәптән татар теленең дә, топонимиясе тел яшәеше хәрәкәтенең гаять катлаулы һәм үзенчәлекле иҗтимагый бер организмын тәшкил итә. Менә шуңа топонимика – билгеле бер региондагы топонимик фактларны, күренешләрне һәм процессларны күпьяклы өйрәнеп, читен сорау-проблемаларны дөрес чишәргә омтылып, ирешелгән объектив гыйльми нәтиҗәләрне киң җәмәгатьчелеккә тәкъдим итүче катлаулы комплекслы фән ул.

Географик атамаларны өйрәнә торган топонимика фәне, совет елларында ук кулланышка кергән традицион классификация нигезендә, берничә тармактан тора. Топонимиканың су чыганаклары исемнәрен – гидронимнарны тикшерә торган бүлеге *гидронимика*, ландшафт-рельеф атамаларын өйрәнә торган бүлеге *оронимика*, торак пункт исемнәрен тикшерә торган бүлеге *ойконимика*, җирле зур булмаган географик объектларның атамаларын өйрәнә торган бүлеге *микротопонимика*, урам исемнәрен өйрәнә торган бүлеге *урбанонимика* дип атала. *Гидроним, ороним, ойконим* һ.б. ономастик терминнардагы *-ним* кушымчасы грекча «исем, атама» мәгънәсендәге *onoma* сүзеннән килә, ягъни *гидроним – гидрос* «сулык» исеме, *ойконим – ойкос* «тору урыны, торак пункт» исеме, *ороним – орос* «тау-чокыр» исеме (Подольская, 1978: 103, 105, 136).

Соңгы елларда ономастика фәнендәге әлеге традицион бүленеш беркадәр яңартылып, тулыландырылып бирелә башлады.

Оронимнар (грек. *ορος* – тау; *ονομά* – исем, атама) – орография объектлары булып теркәлгән рельеф формаларын атый торган берәмлекләр. Бу тармакка тау, калкулык, тигезлек, чокыр, мәгарә, куышлыклар һ.б. геоморфологик объектларны белдергән ялгызлык исемнәр карый. Мәсәлән: *Чатыр тау, Бакыр тау, Тәмте кылган даласы, Лобач тавы, Лабыш таулары, Калатау, Кызлар тавы, Үзәнсигез* (болын исеме) һ.б. Оронимнар арасында аерым төр буларак, спелеонимнарны (грек. *ςπήλαιον* – мәгарә; *ονομά* – исем, атама) – җир асты табигый куышлыкларын һәм рельеф формала-

рын белдергән берәмлекләрне аерып чыгаралар. Мәсәлән: *Бакыр тау мәгарәсе* (Сарман районы), *Антон чокыры* (Кама Тамагаы районы), *Орымширмә* (Теләче районы) авылы «озын тирән чокыр» һ.б.

Гидронимика (грек. *ύδωρ* – су; *ονομά* – исем, атама) – үз эченә барлык су объектлары атамаларын алган тармак. Биредә кое, буа, чишмә, инеш, елга, күл, диңгез һәм океан (шулай ук аларда урнашкан култык, бугаз һ.б.) атамалары өйрәнелә. Су объектлары шактый күп булганга күрә, аларның атамалары да берничә төркемгә берләштерелә: 1) потамонимика (грек. *ποταμός* – елга; *ονομά* – исем, атама) – елга, инеш атамаларын өйрәнә торган юнәлеш. Мәсәлән: *Идел, Нократ, Агыйдел, Чулман елгалары, Болак* һ.б.; 2) лимнонимика (грек. *λίμνή* – күл; *ονομά* – исем, атама) – күл, буа, сусаклагыч атамаларын өйрәнә торган юнәлеш. Мәсәлән: *Камышлы Күл, Түбән оч буасы, Байсар күле, Кабан күле, Куйбышев сусаклагычы* һ.б.; 3) океанонимика (грек. *Ωκεανος* – океан; *ονομά* – исем, атама) – океан исемнәре. Җир шарында бары тик санаулы океаннар булганга күрә, бу иң аз атамадан торган төркем. Мәсәлән: *Тын океан, Атлантик океан, Төньяк Боз океаны, Һинд океаны, Көньяк океан;* 4) пелагонимика (грек. *πέλαγος* – диңгез; *ονομά* – исем, атама) – диңгез һәм аларның өлешләренең (култык, бугаз, агым һ.б.) атамаларын өйрәнә торган өлкә. Мәсәлән: *Әдрән диңгез, Босфор култыгы, Кызыл диңгез, Кара диңгез* һ.б.; 5) гелонимика (грек. *έλος* – саз; *ονομά* – исем, атама) – саз атамаларын өйрәнә торган өлкә. Мәсәлән: *Мук сазы, Дәйди сазы, Сарсаз һ.б.*

Урман, парк, агачлык, куаклык атамаларын дримонимика (грек. *δρΰμος* – урман; *ονομά* – исем, атама) дип аталган юнәлеш өйрәнә. Мәсәлән: *Вәли урманы, Карга куагы, Кырыклы урманы, Озын куак, Бүре кулы һ.б.*

Ойконимика (грек. *οἶκος* – яшәү урыны; *ονομά* – исем, атама) – халыклар тупланып яшәгән урын, торак пункт атамаларын өйрәнә торган юнәлеш. Монда да берничә төркемне күрсәтергә мөмкин: 1) астионимика (грек. *άστεíος* – шәһәр; *ονομά* – исем, атама) – шәһәр исемнәрен; 2) комонимика (грек. *κώμη* – авыл; *ονομά* – исем, атама) – авыл исемнәре өйрәнә торган юнәлеш. Астионимика урбанонимикага (лат. *urbanus* – шәһәрнеке; греч. *ονομά* – исем, атама) – урам, тыкрык, проспект, мәйдан атамаларына бүленә. Мәсәлән: *Ирек мәйданы, Кол Гали урамы, Яшьлек*

*проспекты* һ.б. Шулай ук годонимика (грек. *όδος* – урам; *ονομά* – исем, атама) – туры сызыкка урнашкан урам исемнәре; агоронимика (грек. *Άγορα* – мәйдан, базар мәйданы; *ονομά* – исем, атама) – шәһәр эчендәге мәйданнар, базар территориясе атамалары да аерым төркемнәргә бүлеп өйрәнелә.

Дромонимика (грек. *δρομος* – юл; *ονομά* – исем, атама) – юл атамаларын (мәсәлән: *Себер юлы*, *Ырынбур юлы, Рус базы юлы, Казан-Арча юлы*); агроонимика (грек. *άγρος* – сөрү җире; *ονομά* – исем, атама ) – кыр атамалары (мәсәлән, *Арча кыры, Олы саз кыры* һ.б.) өйрәнә торган юнәлешләр дә бар.

Хоронимика (грек. *όρος* – ызан, чик; *ονομά* – исем, атама) – территориаль бүленештәге ызаннарны, чикләрне атый торган берәмлекләр (мәсәлән: *Куакбаш ызаны*, *Сабир мулла ызаны* һ.б.)

Әлбәттә, әлеге бүленешне гомум кабул ителгән һәм соңгы бүленеш дип әйтеп булмый. Топонимика фәне бүгенге көндә дә актив үсеп килә торган өлкәләрнең берсе, шуңа күрә бу классификация киләчәктә яңартылуны сорый.

Топонимиягә *мотивлаштыру (атау максаты)* үзенчәлеге хас. Атау максаты – теләсә кайсы ялгызлык исемнең билгеле бер объектны атау өчен сайлануы, яисә уйлап чыгаруының экстралингвистик сәбәбе ул.

Топонимик тикшеренүләр, матди мәдәният һәм тарихи чыганакларга таянган хәлдә, атамаларның телен, этник керешү-хәрәкәтләрне – этногенезны һәм шул территориядәге субстрат, адстрат һәм суперстрат күренешләрне ачыклауда зур әһәмияткә ия. Топонимиянең иң борынгы атамаларыннан саналган гидроним һәм ойконимнарның ингерент сыйфаты булып, атау максаты ролендә *субстрат* лексиканың байтак өлешен куллану тора. В.А. Жучкевич билгеләп үткәнчә, *субстрат* – билгеле территория чикләрендә үзара мөнәсәбәткә керү, яисә көрәшү нәтиҗәсендә башка тел тарафыннан җиңелгән тел дип аңлана. Шул ук вакытта кайсы телнең җиңеп чыгуы – җирле халыкныкымы, әллә күченеп килгән халыкныңмы – монда бернинди роль дә уйнамый (Жучкевич, 1980: 104).

Гидронимия, ойконимия составында субстрат һәм алынма исемнәрнең байтак булуы нәтиҗәсендә, аларга *адаптацияләнү* (исемнең, озак вакыт дәвамында кулланылу, үзгәрү, телгә яраклашуы нәтиҗәсендәге үзгәрешләр) хас. Адаптацияләнү *фонетик* рәвештә булырга мөмкин, бу очракта ул түбәндәге фонетик

үзгәрешләрне үз эченә ала: аваз төшү, аваз алмашыну, протетик һәм эпинтетик кушымчалар барлыкка килү, авазларның урыннары алмашыну (метатеза), морфемалар чигендә аваз югалу (гаплология). Мәсәлән, *Субаш Аты, Югары Аты, Түбән Аты, Урта Аты* авыллары (Арча районы) исемнәре мари теле белән аңлатыла. Мари телендә *аты* > *ото* «алан», «кечкенә урман» мәгънәсен белдерә. Биредә мари телендәге [о] авазының [а] авазына күчеше күзәтелә.

*Морфологик адаптация* – редукция нәтиҗәсендәге кушымчалар югалуын, *агглютинация* – сүзьясалыш кушымча ярдәмендә атама формалашу юлы, *деглютинация* – чит тел кушымчасын югалту, грамматик кагыйдәләргә буйсынуын үз эченә ала. Мәсәлән, *-ык/-ек* кушымчасы фигыль нигезенә ялгану нәтиҗәсендә процессның, хәрәкәтнең, эшнең нәтиҗәсен белдергән географик атамалар ясалган. *-ык/-ек* кушымчасы ярдәмендә ясалган *көек* сүзе байтак кына татар һәм рус авыллары атамалары составында чагылыш таба. Мәсәлән: *Көек* (Алабуга, Балтач, Саба, Лаеш, Питрәч районнарны); *Киекбаш* (Балтач районы), *Алга Көек, Югары Көек, Түбән Көек* (Әтнә районы); *Зур Көек, Кучкән Көек, Өлге Көеге* (Кукмара районы); *Көек-Ерыкса, Керәшен Көеге* (Мамадыш районы); *Зур Көек* (Биектау районы); *Кече Көек* (Яшел Үзән районы) һ.б. Борынгы заманнарда кешеләр куе урманнар арасына килеп утырганнар. Ачык урын ясап авылны нигезләү һәм чәчүлек җирләре – кыр-басу барлыкка китерү өчен, урманны яндырганнар. Шушы ысул белән барлыкка китерелгән чәчүлек җирләрен *Көек басу, Көек кыры*, шул урыннарга корылган авылларны *Көек* дип исемләгәннәр (Саттаров, 1992: 56–57). *Көек* орографик терминының чагылышы куе урманнар күп булган Казан арты территориясе өчен характерлы. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *көек* сүзенең терминологик мәгънәсе теркәлмәгән, чөнки *көек* сүзе, урманны яндырып әзерләнгән чәчүлек җирләрен аңлаткан орографик термин буларак, хәзерге татар телендә кулланылмый. *Көек* термины татар теленең тарихи лексикасы, татар халкының этнографиясе һәм игенчелек тарихы өчен игътибарга лаеклы.

*Логик адаптация* эллипсис (атама компонентларының берсе югалуы яки төшеп калуы) ярдәмендә калкып чыга. Мәсәлән, *Әйшә* > *Гайшәбикә* (Яшел Үзән, Биектау районнары) авылы исеме атаманың бер компоненты төшеп калу нәтиҗәсендә ясалган.

Географик атамаларның аерылгысыз сыйфатларының берсе – алар формалашуында төрле чаралар катнаша. Һәрбер телдә, тарихи шартлар нәтиҗәсендә, үзенә генә хас булган топоформантлар барлыкка килә. Телнең бар төрле сүзьясалыш кушымчаларыннан топонимия шактыйларын сайлап ала. Аларның кайберәүләре еш кулланыла, кайберәүләре борынгы булып кала, һәм әлеге төркемнәр, дәвергә карап, гел үзгәреп тора.

Төрки телләрдәге топоформантлар һөнәр атамасын аңлатучы *-чы/-че* кушымчасы, бер предметның икенче предметка каравын белдергән *-лы/-ле* кушымчасы, ниндидер предмет җыелмасын күрсәткән *-лык/-лек* кушымчасы, күплекне белдергән *-лар/-ләр* кушымчасы, шулай ук *-мыш/-меш, -ан/-ән, -сар/-сәр* һ.б. кушымчалардан гыйбарәт. Мәсәлән: *Азмыш, Тулмыш елгалары* (Казансу елгасы бассейны). *Сукачы күле* (Яуширмә елгасы бассейны, Чистай районы), *Тимерче күле* (Олы Сөлчә елгасы бассейны, Аксубай районы), *Тимерче* авылы (Биектау районы), *Игенче* авылы (Мөслим, Тукай районнары), *Япанчы* авылы (Әтнә районы), *Карамыш* (Чирмешән районы), *Туктамыш* (Биектау, Теләче районнары) һ.б.

Географик атаманың үзгәрүе яисә алмашынуы тарихта еш очрый һәм топонимиянең үзенчәлеге булып тора. Атаманың үзгәрүе гадәттә тарихтагы катлаулы вакыйгаларга бәйле була: сугышлар, баш күтәрүләр, идарә алмашынуы һ.б.

Шулай итеп, төрле типтагы үзенчәлекле исем системалары катлаулы характердагы ялгызлык исемнәреннән гыйбарәт. Ономастик системаның үзендә дә, аның өлеше булган топонимик системада да, төрле исем системалары барлыкка килүенә йогынты ясаган лингвистик һәм экстралингвистик факторларның үзара тыгыз бәйләнештә торулары күзәтелә.

Озак еллар топонимика фәне белән аерым кешеләр генә шөгыльләнеп килделәр. Соңгы елларда топонимик тикшеренүләргә, ягъни географик атамаларны өйрәнүгә кызыксыну артты. Аларны җыеп системага салу, килеп чыгышларын ачыклау, төрле яклап классификацияләү һәм этнолингвистик яктан тикшерү интенсив төс алды. Соңгы вакытта географик атамаларның тарихчылар, географлар һәм лингвистлар тарафыннан интенсив өйрәнелүе очраклы хәл түгел. Бу топонимиканың фәнни үсеше белән бәйләнешле. Топонимика лингвистларга, тарихчыларга, географларга халыкның тарихи үткәннәре, теле географик мохитенең күп кенә бәхәсле

якларын ачу, хәл ителмәгән мәсьәләләрен аныклау өчен кыйммәтле фәнни материаллар бирә (Саттаров, 1998:15). Географик атамаларны өйрәнү нәтиҗәсендә теге яки бу регионның тарихи үткәне, хуҗалык үсеше, географик үзенчәлекләре, халык тарихы, топоһәм этногенезы, тел тарихы һ.б. ачыла һәм аныклана.

Топонимика фәнен «җир теле»н өйрәнүче фән дисәң дә була. Аны ниндидер аерым бер фән кысаларында гына өйрәнү дөрес һәм мөмкин эш түгел. Топонимик тикшеренүләр тел белеме, география һәм тарих, археология фәннәре казанышларын файдалану ярдәмендә генә башкарыла ала. Шул ук вакытта топонимика, микротопонимика, антропотопонимика, этнотопонимика, ойконимика, гидронимика һ.б. мәгълүматлары тел тарихы, тарихи лексикология, диалектология, халык тарихы,топо- һәм этногенез, этнография, археология, география кебек фәннәр өчен кыйммәтле чыганак булып торалар, бу фәннәрне тагын да үстерүдә үзләреннән шактый зур өлеш кертәләр.

## ТАТАР ГИДРОНИМИКАСЫ

### § 16. Татар гидронимиясен өйрәнү тарихы

Кеше тормышында географик атамаларның ролен, аларның кеше яшәешенә тәэсирен аңлатып бетерү шактый катлаулы. Кешеләр җирдә яшиләр, җир буйлап хәрәкәт итәләр, дөнья якларын билгелиләр, җир киңлеге күзаллаулары белән эш йөртәләр. Шуңа күрә дә топонимнар географик объектларга атама булып, һәм шул рәвешле аталган объектларны башкалардан аерып куеп, кешеләргә тирә-яктагы мохиттә ориентлашу мөмкинлеге тудырып, үзенчәлекле бер адрес тамгалары вазифасын да башкаралар. Топонимнарның кеше тормышындагы төп функциясе дә нәкъ менә шуннан гыйбарәт.

Географик объектларга атамалар бик борынгы заманнарда ук бирелгән. Бу атамалар, буыннан буынга күчә барып, бүгенге көнгәчә артык зур үзгәрешләр кичермичә, безгә килеп җиткәннәр. Менә шуңа алар әйләнә-тирәнең табигате, халыкның теле, тарихы, тормыш-көнкүреше, хуҗалык итү ысулы, гореф-гадәтләре турында байтак кына бик борынгы һәм кыйммәтле мәгълүматларны хәбәр итүче чал тарих хәбәрчеләре булып саналалар (Саттаров, 1998: 4).

Сулык атамалары, барлык топонимнардан да үзгә буларак, үзләре атаган объектларның табигый үзенчәлекләре белән аеруча

тыгыз бәйләнештә торалар. Тел ягыннан караганда, алар архаик берәмлек саналалар.

Гидронимнар – (борынгы грек телендә *гидро- ΰδωρ* – су; *оним- ὄνομα* – исем) барлык төр су объектларының (океан, диңгез, елга, күл, шарлавык, инеш, чишмә һ.б.) атамалары, топонимнарның бер төре. Үзләре *пелагонимнарга* (диңгез атамалары), *лимнонимнарга* (күл, буа атамалары), *потамонимнарга* (елга атамалары), *пеюнимнарга* (кечкенә елга, инеш атамалары) *гелонимнарга* (сазлык атамалары) бүленәләр.

Узган гасырның 90 нчы елларыннан башлап, дөньяда географик атамаларны өйрәнүгә кызыксыну аеруча артты. Топонимнарны системага салу, килеп чыгышларын ачыклау, төркемләү һәм стратификацияләү интенсив төс алды. Атамаларны өйрәнү белән, тел галимнәре генә түгел, тарихчылар, географлар да шөгыльләнә башлады. Чөнки топонимика фәне халыкның теле, тарихы турында географик мохитнең күп кенә бәхәсле якларын ачарга фәнни материал бирә. Географик атамаларны өйрәнү нәтиҗәсендә теге яки бу регионның тарихи үткәне, хуҗалык үсеше, географик үзенчәлекләре, халык тарихы, топо- һәм этногенезы, тел тарихы һ.б. ачыла һәм аныклана (Саттаров, 1998: 15).

Татар тел белеменең башка тармакларыннан аермалы буларак, татар лексикологиясе, гомумән, чагыштырмача соң формалашкан һәм аз өйрәнелгән өлкә санала. Лексиканың төрле катламнарына, шул исәптән топонимикага караган фактик материалны туплау һәм өйрәнүгә бәйле аерым хезмәтләрнең әзерләнү һәм дөнья күрү тарихы шактый тирән дәверләргә барып тоташуына карамастан, татар теле лексикасын системалы һәм фәнни өйрәнүгә багышланган хезмәтләр XX гасырның 30–40 нчы елларында гына басыла башлый. Шулай да, төрки-татар лексикасының диахроник планда үсешен һәм үзгәрешен билгеләргә ярдәм итә торган күп санлы чыганаклар татар теленең сүзлек составын һәм аны өйрәнә торган фән тармагының формалашу һәм үсеш этапларын тулаем күзалларга ярдәм итә (Татар лексикологиясе, 2015, т. 1: 14–15).

Төрки-татар топонимнары турындагы беренче мәгълүматларны без борынгы грек-византия чыганакларында ук очратабыз. Төрки топонимнар шулай ук әрмән, гарәп-фарсы, кытай-монгол һәм, соңрак, рус чыганакларында да китерелә. Әхмәт бине Фадлан

Идел Болгарына сәяхәте вакытында (921–922 еллар) үзенең язмаларында *Чиремшән, Майна, Кондызча, Отыг (Үтәк), Сок, Кинал* һ.б. гидронимнарны теркәгән.

Ибне Рустәнең «Книга драгоценных драгоценностей» (903–913 еллар) хезмәтендә Идел буе халыклары һәм аларның күршеләре турында кызыклы мәгълүматлар китерелә. Шулай ук монда кайбер су чыганакларының атамалары да язылган: *Итиль, Хазар диңгезе* (Каспий диңгезе), *Рум диңгезе* (Кара диңгез) һ.б.

Мәхмүт Кашгариның «Диване лөгатет-төрк» (XI гасыр) сүзлегендә, алдагы бүлекләрдә билгеләнгәнчә, болгар кабиләләренең тел үзенчәлекләре бирелә. Үзенең картасында ул Болгар һәм Сивар (Сувар) шәһәрләрен, ялгышып, *Каспий диңгезе* янына ук урнаштыра. Әлеге хезмәттә шулай ук *Этил* (Идел), *Эртиш* (Иртыш) елгаларының атамалары да телгә алынган. Мәхмүт Кашгари, беренчеләрдән булып, кайсы бер атамаларның этимологиясен бирү омтылышын ясый (Мурзаев, 1974: 28).

Төрки-татар топонимнары турындагы аерым мәгълүматларны без шулай ук Әбу Исхак әл Истахри, Ибне Хакукал, Әбү Хәмит әл Гарнати хезмәтләрендә дә очратабыз.

Кытай чыганаклары, нигездә, Себердәге һәм Ерак Көнчыгыштагы төрки халыклар (борынгы төркиләр, хуннар, сөннәр һ.б.), аларның тел үзенчәлекләре, тарихлары, топонимнары турында хәбәр итә. Идел буе регионындагы *Идел, Аях* (Җаек) кебек гидронимнар «Монголларның күңел түрендәге хикәяләре» («Сокровенные сказания монголов») дигән борынгы монгол әдәбияты үрнәге булган хезмәттә китерелгәннәр.

Төрки-татар атамалары XI–XVII гасырларда рус елъязмаларында да телгә алына башлыйлар. Бу чыганакларда («Повесть временных лет», «Слово о полку Игореве» һ.б.), нигездә, Рус дәүләтенең болгарлар белән сугышлары турында язылган. Шулай ук ике дәүләт арасындагы икътисади һәм мәдәни багланышларга да урын бирелә. *Җүкәтау, Кирмән, Ашлы* кебек Болгар шәһәрләре турында да хәбәр ителә. Теге яки бу вакыйганы тасвирлаганда әлеге елъязмаларда *Идел, Кама, Чирмешән* (Черемисан), *Болак, Илет, Иске-Казан, Кара Болак, Мишә, Нурма, Ашыт, Зөя, Карлы, Бола, Тархан, Бүре* кебек гидронимнар телгә алына.

XVII гасырдан руслар беренче географик карталарын төзи башлыйлар. Бу карталар Урта Азиягә, Себергә, Кавказга һәм

Россия империясенең башка төбәкләренә үткәрелгән экспедицияләргә нигезләнеп эшләнәләр. Шундый карталарның беренчесе булып 1600 елда төзелгән «Большой чертеж» исемле географик хезмәт санала. Әлеге хезмәттә Россия җирләре турында билгеле булган бөтен мәгъүмат урнаштырылган. Алар төрле вакытта җыелган материалларга нигезләнә. Кызганычка каршы, «Большой чертеж» бүгенге көнгә кадәр килеп җитә алмаган, аның бары тик аңлатма язуы гына сакланган (Баскаков, 1969: 24). Әлеге аңлатма язуында «Географик күрсәткеч» урнаштырылган. Анда без бик күп татар гидронимнарын очратабыз: *Кама, Ык, Чишмә, Минзәлә, Волга, Бүре, Карлы, Сикәнәс, Олы Чынлы, Чаллы, Майна, Кече Чынлы, Бола, Акташ, Инеш, Зәй, Уратма, Тигәнәле, Зөя, Шонталы* (Книга к Большому Чертежу / под. ред. К.Н. Сербиной. М.-Л., 1959). XIX гасырда русларда карта төзү эше инде шактый киң җәелә. Карталар бик күпләп эшләнә башлый. Әлеге карталарда без татар гидронимнарын күпләп очратабыз.

Алга таба гидронимнарны өйрәнү өчен чыганак итеп XIV–XVIII гасырлардагы Дәүләт акты материалларын һәм XV–XVII гасырларның «Писцовый» кенәгәләрен күрсәтеп үтәргә кирәк. Әлеге документларда без кеше исемнәрен генә очратып калмыйбыз, искиткеч күп гидронимнар һәм башка топонимнарны да таба алабыз. Алда санап киткән чыганаклардан аермалы буларак, бу документларда зур сулык атамалары гына теркәләмәгән, ә күп кенә кечкенә елга, елгачык, инеш, күл һәм буа атамалары да урын алган. Чөнки әлеге материалларда кайсы җирнең кемнеке икәнлеге, кемнең кем белән нинди җирләр өчен судлашып йөргәннәре дә язылган. Шуңа күрә географик объект атамалары шактый тәфсилләп язылган.

Топонимнарны өйрәнү өчен тагын бер әһәмиятле чыганак булып төрле сүзлекләрне атарга кирәк. Югарыда без инде М.Кашгариның сүзлеген атап киткән идек. Аннан тыш XIII–XIV гасырлар чигендә яшәгән гарәп галиме Ибне Мөһаннаның «Китабе тәрҗемәи фарси вә төрки вә магулый» сүзлеген, «Кодекс Куманикус» сүзлеген, 1581 елда хаҗи Бәйрәм Хаҗи Булат төзегән «Гарәпчә-төркичә сүзлек» хезмәтен һ.б. сүзлекләрне искә алып китү кирәк.

Рус телендә төзелгән беренче сүзлекләрдән В.Н.Татищевның «Лексикон»ын атау зарур. Әлеге сүзлектә 1500 мәкалә урын алган.

Шуларның шактый өлеше Урта Идел буе топонимнарына һәм гидронимнарына багышланган.

XIX гасыр башы һәм аеруча икенче яртысында Россиядә басылып чыккан географик сүзлекләрдә, табигый ки, төрки-татар топонимиясенә дә зур урын бирелә. Мәсәлән, «Географический словарь Российского государства, сочиненный в настоящем оного виде Л.М. Максимовичем и А.М. Щекатовым» (М., 1801, ч. 1; М., 1809, ч. 2–7) һәм «Семенов П.П. Географическо-статистический словарь Российской империи» (СПб., 1863, Т. 1; СПб., 1865, Т. 2; СПб., 1867, Т. 3; СПб., 1873, Т. 4; СПб., 1885, Т. 5) сүзлекләрендә Казан, Уфа, Самара губерналарындагы елгалар турында мәгълүматлар китерелгән. П.П. Семенов сүзлегенең 6 нчы томы тулысында Түбән һәм Урта Идел атамаларына багышланган. Бу өлкәләр шактый тәфсилләп тасвирлана. Бу сүзлектә без *Волга, Кама, Вятка, Ашыт, Чишмә, Майна, Олы Чирмешән, Кече Чирмешән, Болак, Зөя, Ерыклы, Шонталы, Нокса, Зәй, Актай, Ошма, Кабан, Казансу* һ.б. бик күп елга исемнәрен очратып кына калмыйбыз, ә бәлки аларның һәртөрле географик характеристикалары белән дә танышабыз.

Бу өлкәдәге мөһим чыганаклар рәтендә Болгар дәүләте чорында иҗат ителгән «Кыйссаи Йосыф» (Кол Гали), «Ана вә угыл» дастанын; Алтын Урда чоры чыганакларыннан «Кыйссасел-әнбия» (Насреддин Рабгузи), «Нәһҗел-фәрадис» (Мәхмүд Болгари әс-Сараи), «Мәхәббәтнамә» (Харәзми), «Хөсрәү вә Ширин» (Котб) һ.б.; Казан ханлыгы чорының Мөхәммәдъяр, Өмми Камал әсәрләрен, «Мәҗмәгыль-кавагыйд» хезмәтен һ.б.; XVII–XVIII гасыр әдәбиятыннан Мәүлә Колый, Габдессәлам, Габдрәхим Утыз Имәни һ.б. әсәрләрен; XIX гасыр – XX гасыр башына караган Г. Кандалый, Ә. Каргалый, Һ. Салихов, Ш. Зәки, Ә. Уразаев-Кормаши, М. Акъегет, З. Бигиев, Р. Фәхретдин, Ф. Кәрими, Г. Исхакый, Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан, Г. Тукай һ.б.ның әсәрләрен дә атау кирәк. Аларда без төрле дәрәҗәдә антропонимнарны да, топонимнарны да, шул исәптән бик күпләп гидронимнарны да очратабыз.

Гидронимнарны өйрәнү өчен тагын бер әһәмиятле чыганак булып кабер ташъязмалары тора. Аерым алганда, XIII–XVIII гасыр болгар-татар эпитафияләрендә антропонимнар, топонимнар, гидронимнар һәм этнонимнар шактый теркәлеп калган. Алар турында без Хөсәен Фәезханов, И.А. Износков, Н.Ф. Катанов, Г.Н. Әхмәров, Н.И. Ашмарин, С.Е. Малов, Л.Җ. Җәләй, Н.Ф. Калинин,

Г.Ф. Йосыпов, Ф.С. Хәкимҗанов, М.И. Әхмәтҗанов хезмәтләреннән таныша алабыз.

Топонимнар төрле ярлыкларда, грамоталарда, тарханлык язуларында һәм акчаларда да очрый.

Татар топонимнарын фәнни рәвештә өйрәнү XIX гасырдан башланып китә. Урта Идел топонимнарын, беренчеләрдән булып, С.М. Шпилевский, Шиһабетдин Мәрҗани, Каюм Насыйри, Н.И. Ашмарин, А.П. Ковалевский, Н.И. Золотницкий, П.И. Рычков, В.В. Радлов, И.А. Износков, В.К. Магницкийлар яза башлый.

С.М. Шпилевский хезмәтендә *Олы һәм Кече Чирмешән, Актай, Майна, Минзәлә, Зәй, Шиш*мә һ.б. бик күп татар елга атамалары китерелә. Ул аларның географик яктан төгәл урыннарын билгели, елгалар турындагы легендаларны да терки.

XIX гасырның 70 нче елларында Казан университетында «Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте» оештырыла. Әлеге оешманың әгъзалары арасында В. Радлов, Н. Золотницкий, И. Износков, В. Магницкий, В. Тимофеев, К. Насыйри, Г. Әхмәров кебек шул чорның күренекле галимнәре була. Әлеге галимнәрнең эшчәнлеге нәтиҗәсендә XIX гасырның 80 нче елларында Казан топонимика мәктәбенә нигез салына (Саттаров, 1970: 8).

Татар ономастикасын өйрәнүгә тарихчы Һ.В. Йосыпов та үзеннән зур өлеш кертә. Аның хезмәтләрендә болгар-татар гидронимнарының фонетик үзенчәлекләре карала (1960; 1971; 1971).

XX гасырның 60 нчы елларыннан башлап татар ономастикасын өйрәнүне Г.Ф. Саттаров башлап җибәрә. Аның эшчәнлеге инде алдагы бүлекләрдә шактый яктыртылды. Галимнең «Татарстан АССРның микротопонимиясе» (Казан, 1965), «Татарстан АССР антропотопонимнары» (Казан, 1973), «Мәктәптә туган як ономастикасы» (Казан, 1984), «Татар топонимиясе» (Казан, 1998) хезмәтләрендә татар гидронимнарына да шактый зур игътибар бирелә. Г.Ф. Саттаровның 1975 елда «Татарстан АССРның антропотопонимиясе» дигән темага язылган докторлык диссертациясендә дә гидронимнар тирән анализлана.

Татарстан топонимнарын, шул исәптән гидронимнарын, Р.Х. Субаева ике теллелек аспектында өйрәнде. Аның гидронимнарга өйрәнүгә багышланган «О названиях рек и озер Среднего Поволжья» хезмәте бар (1961). Галимә башка хезмәтләрендә дә гидронимнарга шактый зур игътибар бирә.

Гидронимик берәмлекләрне өйрәнү өлкәсендә галимә Ф.Г. Гарипованың эшчәнлеге аерым урын тота. Төрле топонимнарны өйрәнүгә карамастан, Ф.Г. Гарипованың төп фәнни юнәлеше – гидронимия. Ул 1975 елда «Гидронимия Заказанья Татарской АССР (на материале бассейнов рек Ашит, Казанки, Меши и Шошмы)» дигән темага кандидатлык диссертациясен, 1991 елда «Исследования по гидронимии Татарстана» дигән темага докторлык диссертациясен яклый. Аның «Татарстан гидронимнары сүзлеге»ндә генә түгел (Казан, ике китапта, 1984, 1990), «Татарстан микротопонимнары сүзлеге» (Казан, ике китапта, 1992, 1993), «Татар топонимнары сүзлеге» (Казан, 2010) хезмәтләрендә дә гидронимнар төп урынны алып торалар.

Ф.Г. Гариповадан соң татар гидронимнарын үзләрен генә аерып алып махсус өйрәнүче галимнәр юк дип әйтергә мөмкин. Ләкин топонимиягә караган төрле хезмәтләрдә гидронимнарны да тикшерү, анализлау дәвам итә. 1998 елда Г.К. Һадиева Казан ханлыгы чоры ойконимнарын өйрәнеп, кандидатлык диссертациясен яклый. 2001 елда О.Р. Хисамов тарафыннан Көнбатыш Кама аръягы ойконимиясе буенча диссертация яклана. Көньяк-көнчыгыш Кама аръягы топонимнарын Р.Ш. Шаһиев өйрәнә. Ульяновск өлкәсе топонимнары буенча Р.К. Садыйкова хезмәт яза. Себердәге төрки-татар топонимиясен өйрәнеп З.М. Калгаманова, З.С. Камалетдинова, С.З. Рәхимбакиев кебек галимнәр дә кандидатлык диссертацияләрен яклыйлар һәм үз хезмәтләрендә гидронимнарга шактый зур урын бирәләр.

Татар гидронимнары турында мәгълүматлар, аларга анализ тел белеменең башка өлкәләренә багышланган хезмәтләрдә дә, аерым мәкаләләрдә дә урын ала. Бу нисбәттән Р.Г. Әхмәтьянов, М.З. Зәкиев, Ф.С. Фәсиев, Ф.М. Хисамоваларның хезмәтләре бик әһәмиятле. Җ. Вәлиди, Л. Җәләй, Д. Тумашева, Л. Мәхмүтова, Н. Борһанова, Ф. Йосыпов, Ф. Баязитова, Д. Рамазанова кебек галимнәрнең фәнни хезмәтләре аерым төбәкләрдәге гидронимнарның һәм топонимнарның тел үзенчәлекләрен ачыклауда зур ярдәм күрсәтәләр.

Гидронимнар турындагы тарихи материалларны без М.Г. Госманов, М.И. Әхмәтҗанов, А.Х. Халиков, Р.Г. Фәхретдинов, Һ.В. Йосыпов, С.Х. Алишев, Д.М. Исхаков һ.б. бик күп галимнәрнең хезмәтләрендә очратабыз.

Димәк, татар телендә гидронимнарны өйрәнү гаять киң колач алган. Чыганакларда һәм фәнни хезмәтләрдә теркәлгән материаллар татар ономастикасы, тел тарихы фәннәренә генә түгел, тарих, этнография, география фәннәре өчен дә кыйммәтле санала.

## § 17. Гидронимик терминнар

Э.М. Мурзаев топонимик тикшеренүләр, иң беренче чиратта, җирле географик терминнарны җыеп системага салудан башланырга тиеш, дигән фикердә тора. Чөнки бу терминнар атамалар барлыкка килүдә зур роль уйныйлар, этимологик ачкыч хезмәтен башкаралар һәм географик берәмлекләрне ачыклап, аерып классларга, төрләргә үк бүлеп күрсәтәләр.

Татар топонимиясен, бигрәк тә микротопонимиясен, формалаштыруда, гомумтатар телендә (әдәби телдә) кулланыла торган географик номенклатура терминнарыннан тыш, җирле географик терминнар да актив катнашкан (Саттаров, 1998: 11). Мәсәлән, *ачы, ачылык* – сазлык урын, елга ташып киткәннән соң калган тозлы, уйсу җир; *яргак, тарлау* – таудан ташу вакытында су агып төшә торган урын; *тоба* – упкын, суның тирән җире; *чоңгыл* – елганың тирән урыны һ.б.

Г.Ф. Саттаров күрсәтеп үткәнчә, татар топонимиясенең күмәклек сүзләрдән барлыкка килгән атамаларның зур күпчелеге җирле географик номенклатура терминнарына нигезләнеп ясалганнар (Саттаров, 1998: 12). Славян, төрки, фин-угор, монгол, тунгус-маньчжур һ.б. халыклардагы топонимнарның күбесе җирле географик терминнардан тора.

Җирле географик терминнар борынгы заманнарда ук барлыкка килгәннәр. Алар буыннан буынга күчеп, артык зур үзгәреш кичермичә, бүгенге көнгә кадәр килеп җиткәннәр. Шуңа күрә дә әлеге терминнарга нигезләнеп ясалган топонимнар иң борынгы атамалар булып саналырга хокуклы. Татар теле географик терминнарга бик бай тел. Г.Ф. Саттаров мәгълүматларына караганда, татар телендә һәм диалектларда төрле географик объектларны белдерү өчен 5000 нән артык термин кулланыла (Саттаров, 1998: 18).

Җирле географик терминнарны классификацияләгәндә, иң беренче чиратта, аларның табигый географик объектка яки ясалма географик объектка караганлыгын билгеләргә кирәк. Бу яктан без географик терминнарны ике зур төркемгә аерабыз:

1. Табигый географик объктларга караган җирле географик терминнар.

2. Ясалма географик объектларга караган географик терминнар. Әлеге төрләрнең үз эчләрендә һәркайсын тагын ике төркемгә аерырга мөмкин.

Табигый географик объектларга караган җирле географик терминнар түбәндәге төрләргә бүленә:

1. Су чыганакларын белдерә торган (диңгез, елга, чишмә, күл, саз, буа һ.б.) гидрографик терминнар.

2. Җир өсте рельефы объектларына мөнәсәбәтле (урман, тау, калкулык, чокыр, кыр, юл һ.б.) орографик терминнар.

Ясалма географик объектларга караган географик терминнар шулай ук ике төркемгә бүленә:

1. Торак пунктларны (шәһәр, авыл, хутор һ.б.) һәм аларның өлешләрен (урам, мәйдан, бистә, оч һ.б.) белдерә торган ойконимик терминнар.

2. Төзелеш-каралтыларны белдерә торган (йорт, сарай, баз, мунча, койма, капка, зират, лапас һ.б.) терминнар (Саттаров: 1998).

Таралышы һәм функцияләре ягыннан географик терминнарны тагын ике төркемгә бүлергә мөмкин: төр (родовые) терминнары һәм төрчә (видовые) терминнар (Мурзаев, 1970: 18). Төр терминнарына төрле киңлекләрдә шактый таралыш алган, нигездә, гомум төрки телгә нисбәтле атамаларны кертәләр. Идел, күл, саз, елга, су һ.б. терминнар шундыйлардан. Төрчә терминнарга исә бер үк типтагы географик объектларның (мәсәлән, күлләрнең) төрле рәвешләрен күрсәтә торган *җан, чүгәт, тоба, күлләвек* кебек диалекталь атамалар керә. Алар таралыш ягыннан да, кулланылыш ягыннан да чикләнгән булалар.

Күренекле топонимист галим Г.И. Донидзе төрки телләрдәге гидронимик терминнарны лексик-семантик яктан 5 төркемгә бүлеп карый (Донидзе, 1969: 16–17). Г.Ф. Саттаров әлеге классификациягә тагын ике пункт (6, 7 пунктлар) өсти (Саттаров, 1998: 20–21). Гидронимик терминнарның лексик-семантик яктан бүленеше бу хезмәттә дә әлеге классификация нигезендә бирелә.

1. Төрле озынлыктагы һәм төрле характердагы елгаларны белдерүче җирле гидрографик терминнар: *су, елга, идел, инеш, дим, ык, мута, суыксу, ом, бору, түз, борын* һ.б.

***Су***. Әлеге термин иң активлардан санала. Чыганагы белән гомумтөрки саналган бу сүз, төрлечә фонетик яңгыраштa барлык төрки телләрдә диярлек кулланыла. Борынгы төрки телдә ул *sub, suv, sү* формасында кулланылган (Радлов, 1911: 787–790). Төрле төрки телләрдә *су, сув, суу, суг, һыу, шыв* һ.б. вариантлары бар (Гарипова, 2011: 166).

Топонимиядә су термины, *сыеклык* төшенчәсен аңлатудан бигрәк, «елга» мәгънәсен белдерә. Көнчыгышка таба (мәсәлән, Көнбатыш Себер җирләрендә) әлеге тенденция көчәя бара. Новосибирск өлкәсендә, Томск өлкәсендә яшәүче себер татарлары *елга* термины урынына хәзер дә *су* терминын кулланалар. Төрки телләрнең күбесендә термин *елга* мәгънәсендә дә, *сыеклык* мәгънәсендә дә актив кулланышта йөри.

Термин башка терминнар составында да актив кулланыла: *агымсу, аксу, карасу, сарысу, суыксу* һ.б. *Су* термины үзе генә ниндидер су чыганагы атамасы булып сирәк кулланыла, мәсәлән, *Суг елгасы*. Ләкин ике, өч сүздән торган гидронимнар составында еш кулланыла: *Олы Суг, Кече Суг*. Енисей һәм Абакан елгалары бассейннарында *суг* сүзе белән гидронимнар күп ясалган: *Казынсуг, Сарысуг, Демирсуг, Изагсук; Алтайда: Суг, Сугат, Карасуг, Менсуг* (Молчанова, 1979: 91).

Кайбер гидронимнар составында *су* термины булуы ачык аңлашылмаска да мөмкин. Галимнәр *Чебакса* (*чебак* – чабак + *са ~ су* – елга), *Ерыкса* (*ерык* + *са ~ су* – елга) , *Инса* (*ин ~ иң* – иңү, түбән төшү + *са ~ су* – елга), *Мораса* (*мор ~ мур* < монгол «мурэн» – елга + *са ~ су* – елга), *Шуширмә* (*шу ~ су* + *ширмә* – чокыр, елга) һәм тагын *Шушар, Шәүширмә, Шуалан, Одиакса, Кабырза – Кёбюрзуг, Егоза – Игесу* һ.б. бик күп атамаларның составында *су* термины бар дигән фикердә торалар (Саттаров, 1998: 22–23; Гарипова, 2011: 166–167; Абдрахманов, Бонюхов, 1966: 159–169).

***Елга.*** Бу сүз борынгырак вакытта бары тик уртача зурлыктагы агым суларны атау өчен генә кулланылган. Хәзерге татар телендә әлеге термин белән зур елгаларны да, кечкенәрәк елгаларны да атыйлар: *Зөя елгасы, Ык елгасы, Кама елгасы, Чирмешән елгасы* һ.б. Төрле фонетик вариантларда әлеге сүз күп төрки һәм монгол халыкларында очрый. Каракалпак телендә – *җылга*, чуваш телендә – *йалка*, казак телендә – *жилга*, монгол телендә – *жалга* һ.б. Татар диалектларында *җылга* варианты очрый (ТТЗДС, 2009, 195).

*Елга* термины үзе дә аерым елга атамасы булып шактый зур территориядә таралган. *Елга – Кама кушылдыгы* (Балык Бистәсе районы), *Олы Сөлчә кушылдыгы* (Аксубай районы), *Олы Үләмә кушылдыгы* (Апас районы), *Бөре елгасы кушылдыгы* (Кукмара районы), *Ык елгасы кушылдыгы* (Актаныш районы) һ.б. (Гарипова, 2011: 141).

Күп кенә гидронимнарның составында *елга* термины башка апеллятивлар белән бергә кулланыла: *Нарат елгасы, Урта елга, Артышлы елга, Зират елгасы* һ.б.

Термин ойконимнар составында да шактый актив. Мәсәлән, *елга* термины Татарстан Республикасындагы 28 торак пункт атамасы составында очрый: *Карамалы Елга, Кәкре Елга, Кара Елга, Мөгезле Елга* һ.б. (Гарипова, 2011: 141).

Бүгенге көндә билгеле булган гидронимнарның (аеруча борынгырак гидронимнарның) күбесе мәгънә ягыннан шулай ук *елга* гидрографик терминына мөнәсәбәтле. Борынгы кеше, табигый объектларга атама биргәндә, атама эзләп артык интекмәгән. Ул елганы *елга* дип, тауны *тау* дип, күлне *күл* дип атаган. *Чирмешән, Идел, Чулман, Обь, Енисей, Ык* һ.б. бик күп атамаларның асылында *су* гидрографик термины ята.

***Чалбар.*** *Чалбар* гидрографик термины белән елга яки инешнең кушылдыгын атыйлар. *Салбар* формасында монгол телендә, себер гидронимиясендә *елга култыгы, кушылдыгы* мәгънәсендә кулланыла (Кузьмина, 1969: 35).

Татарстанда әлеге термин гидронимнар ясауда да катнашкан: *Чалбар* – Кече Мишә суы кушылдыгы, *Чалбар инеше* – Мишә суы кушылдыгы (Гарипова, 2011: 178).

2. Елга объектларының төрле өлешләрен белдерүче терминнар: *баш, авыз, тамак, култык, бүрән, комрак, борын* һ.б.

Бу төр гидрографик терминнар күпчелек очракта кеше әгъзалары белән бәйле. *Авыз* гидрографик термины «елга, инеш коя торган урын, тамак» дигәнне аңлата. *Аяк* термины төрле сөйләшләрдә «агымсуларның түбәнге агымын, елга тамагы» дигән мәгънәне бирә. *Баш* термины «елганың башланган урыны, югары агымы» дигәнне аңлата. *Борын* – «коры җирнең су чыганакларына очлаеп кергән урыны». *Бот* термины «елга» кушылдыгын аңлата. Китерелгән терминнардан башка тагын кеше әгъзалары белән бәйле булган *бугаз, кул, култык, тамак* терминнары актив кулланылышта йөри.

Югарыда китерелгән терминнар, гидрографик терминнар буларак кына түгел, төрле гидронимнар һәм башка топонимнар составында да актив кулланылар. Мәсәлән, *Камышлытамак* (Башкортстанның Бакалы районында авыл атамасы), *Кече култык елгасы* (Майна елгасы кушылдыгы), *Юкәле кул* (Шәбез елгасы кушылдыгы), *Бәләкәй бот* (Бәтке елгасы кушылдыгы), *Бозбаш* (Самара өлкәсе Камышлы районында татар бистәсе) һ.б. Кайбер очракларда әлеге терминнар үзләре генә дә атама булып килергә мөмкиннәр: *Култык* – Кама Тамагы районыннан агып үтә торган Ылгыма елгасының кушылдыгы, Биектау районында Ашыт суы кушылдыгы; *Тамак* – Биектау районындагы бер кечкенә елга һ.б.

Кеше әгъзалары белән бәйле гидрографик терминнардан һәм алардан ясалган атамалар башка төрки халыкларда да күпләп очрый. Бу гаҗәп түгел, чөнки кеше әгъзалары төрки халыклар өчен уртак апеллятивлар булып саналалар. Алар борынгы төрки чордан ук билгеле. Ә инде кеше әгъзаларын гидрографик термин буларак куллану, гомумән, күп халыкларга хас күренеш. Без моны гомумкешелек күренеше дип тә атар идек.

Әлбәттә, елга объектларының төрле өлешләрен белдергән терминнар кеше әгъзаларына бәйле сүзләр белән генә чикләнми. Алар шактый күп. Мәсәлән, Көнбатыш Себер татарларында шактый актив рәвештә *бүрән* термины кулланыла. Ул русча *старица* дигән терминга туры килә, ягъни, елга агымының иске юлын аңлата. Елга вакытлар узу белән үзенең юнәлешен үзгәртә, элекке юлында *бүрән* барлыкка килә. Ул төп елга агымына кушылган булырга мөмкин, үзе генә аерым, күл булып та калырга да мөмкин. *Бүрәннәр* аеруча Иртыш елгасы буенда күп очрый. Иртыш буендагы татар авылларының һәрберсенең үз *бүрәне* бар дисәк тә ялгыш булмастыр.

3. Фонтан рәвешендә җир астыннан бәреп чыга торган су чыганакларын белдерә торган терминнар: *чишмә, чыгыш, кизләү, мәңгәр, сарку, типкән, болак, шытсу, кулак* һ.б.

***Чишмә*** әлеге типтагы гидрографик терминнар арасында иң актив кулланылышта булганы һәм иң киң таралганы санала. Аның фонетик вариантлары да шактый: *чишмә, сишмә, тишмә, шишмә*. Мишәр диалектында *кизләү* яки *күзләү* термины кулланыла. Төрле сөйләшләрдә *чишмә* сүзе урынына *сулык, чура, чукрак, чыганак, чыгыш, чыгым, күзләвек, кулак* һәм, хәтта, *бала елга* дигән терминнар да очрый.

*Чишмә* термины татар теленә фарсы теленнән кергән. Чыганак телдә *чәшм* сүзе «күз» дигән мәгънәне белдерә. *Чәшмә* сүзе шулай ук «источник, родник, ключ» мәгънәләрен белдерү өчен дә хезмәт итә.

*Чишмә* гидрографик терминына һәм аның синонимик вариантларына бәйле рәвештә төрле топонимнар һәм микротопонимнар барлыкка килгән. Мәсәлән: *Чишмә* – Актаныш һәм Мөслим районнарында авыл атамасы; *Салкын Чишмә* – Баулы, Питрәч, Әлмәт районнарындагы инеш һәм авыл исемнәре, *Күкчишмә* – Мамадыш районындагы инеш һәм авыл атамалары. Терминның башка синонимик вариантларына килсәк, алар белән дә бихисап атама ясалган. Мәсәлән: *Җидекизләү* – Апас районындагы торак пункт атамасы, *Чыгыш елгасы* (*чишмәсе*) – Спас районы Янбакты авылы чишмәсе һ.б. (Саттаров, 1998: 48).

Төрле төрки телләрдә *чишмә* һәм шул ук мәгънәдә кулланылучы *болак* гидрографик терминыннарының *булак, чешме* (азәрбайҗан), *шишмә* (башкорт), *булак, шешме* (каракалпак), *булак* (тува), *bulak* (төрек), *булак, чешме* (төрекмән), *булокъ*, *чашма* (үзбәк) вариантлары кулланыла. Татар телендә *болак* термины бүген «чишмә» мәгънәсендә кулланылмый. Ләкин югарыда күренгәнчә, күп төрки телләрдә ул бүген дә шул мәгънәдә кулланыла. Кайбер төрки телләрдә ике термин да бергә йөри, икенчеләрендә икесенең берсе генә.

4. Акмый торган су объектларын белдерүче җирле географик терминнар: *күл, чүгет, күтер, җан, күләвек, кылы, пүрән, чоңгыл, саз, сазлык, сеңгәк, түмгәклек, пылата, лай, купак, кәркә, баткак* һ.б.

Әлеге тип гидрографик терминнарын үзләрен 2 төркемгә бүлеп карарга мөмкин:

а) *күлне белдерүче гидрографик терминнар*. *Күл* гидрографик термины – гомумтөрки сүз. Теге яки бу фонетик вариациядә ул барлык төрки телләрдә дә очрый.

Зурлыгына, күл өстенең һәм төбенең формасына, урнашу урынына һ.б.га карап, күлләр берничә төргә бүленәләр. Татар халкы тарафыннан аларга төп, иң күзгә ташланып торган физик-географик үзенчәлекләре ассызыкланган терминнар бирелгән (Саттаров, 1998: 53). Бараба татарлары камышлык уртасындагы күлне атау өчен *чүгет* термины кулланалар. Татар теленең кайбер

сөйләшләрендә өсте үлән белән капланган, сазлыкка әверелгән күлне *күтер* дип йөртәләр. Урал сөйләшләрендә кечкенә күлне белдерү өчен *җан* терминын кулланалар. Болардан тыш, сөйләшләрдә төрле формадагы күлләрне белдерү өчен *кылы* (кечкенә күл), *кылым* (кечкенә күл), *бүрән* (вакытлыча ясалган күл), *комак* (такыр төпле күл), *чоңгыл* (вакытлыча ясалган күл), *семе* (сазлык күл), *чүгет* (сазлык күл), *су алка* (вакытлыча ясалган күл), *күләвек* (вак күл) терминнары кулланылышта йөри.

Югарыда китерелгән гидрографик терминнарга нигезләнеп, татар топонимиясенең шактый гидронимнары, ойконимнары һәм микротопонимнары ясалган. Мәсәлән: *Әҗәкүл* – Актаныш районында авыл һәм күл атамасы; *Аккүл* – Буа, Лениногорск, *Аккүл-Бигәнәй* – Саба районнарындагы атамалар. Татарстанда *Кара Күл, Бикүле, Якты Күл, Күл Черкен, Күлбаш* һ.б. бик күп татар авыллары атамалары ясалган;

ә) *сазны белдерүче гидрографик терминнар. Саз* гидрографик термины шулай ук гомумтөрки характердагы термин булып тора. Теге яки бу фонетик вариациядә ул төрки телләрдә очрый. Мәсәлән, кыргыз, хакас телләрендә *саз*~*сас*, казак – *саз,* чуваш – *шур,* башкорт – *шар* (Гарипова, 2011: 160).

Сазлык, баткак җирне аңлату өчен татар теле сөйләшләрендә төрле терминнар кулланыла. Чистай сөйләшендә *түмгәклек, баткылык, пылата* сүзләре, эчкен сөйләшендә – *семелек,* сергач сөйләшендә – *сеңгәк, сеңгелчәк*, мәләкәс сөйләшендә – *сазамак,* камышлы сөйләшендә *ачы* терминнары кулланыла. Төрле сөйләшләрдә шулай ук *сазлавык, ачылык, купкы, лай, купак* терминнары да бар.

Республикабызда әлеге терминнар нигезендә ясалган *Сарсаз, Сарсаз-Тралы, Сарсаз-Әрәмә, Татар Сарсазы, Рус Сарсазы, Сазтамак, Иләксаз, Югары Баткак, Баткак, Бикәсаз, Каенсаз* һ.б. бик күп ойконимнар бар. Әлеге терминнар белән ясалган микротопонимнарның саны бихисап.

5. Ясалма су объектларын белдерүче җирле гидрографик терминнар: *кое, буа, бәке, коток, калуда, оро, бийә, борот, пурт, пырут, пәке, кодык, козык, ярлау, үке* һ.б.

Әлеге төр терминнарның үзләрен 3 төркемгә бүлеп карау кирәк:

а) *коены белдерүче гидрографик терминнар*. Төрки телләрдә *кое* сүзен белдерү өчен *гую* (азәрб.), *кудук* (алтай), *кудык* (казак),

*кудук* (кыргыз, таҗик, тува, үзбәк), *куйы* (ногай), *киуп* (төрек) һ.б. вариантлар кулланыла (Гарипова, 2011: 153).

Татар теленең диалект һәм сөйләшләрендә – *коток* (себер татарларында), *калуда* (чистай сөйләше), *оро* (эчкен сөйләше).

Татар топонимиясендә *кое* гидрографик термины белән ойконимнар һәм зур топонимнар ясалмаган. Алар бары тик микротопонимиядә генә урын алалар: *Чәй суы коесы, Ферма коесы, Садрыйлар коесы, Мәдрәсә коесы* һ.б. (Саттаров, 1998: 63);

ә) *буаны белдерүче гидрографик терминнар*. Татар телендә тирән чокырны, ермакны, инешне, елганы төрле материал белән буып барлыкка килгән ясалма су саклагычын *буа* сүзе белән атап йөртәләр.

Татар теленең төрле сөйләшләрендә *буа* сүзе нигездә төрле фонетик яңгырашта кулланыла: *буа, бөйә* (казан арты сөйләшләрендә)*, бийә* (дөбьяз)*, бүwә* (минзәлә, урал сөйләшләрендә)*, буwа* (буа-тархан)*, бума* (шарлык)*, бөгә, бүгә* (мамадыш) вариантлары (Саттаров, 1998: 64).

Төрле фонетик яңгырашлы *буа* терминыннан тыш, рус теленнән татар теленең кайбер сөйләшләренә *пруд* сүзенең дә төрле фонетик вариантлары кулланылышка кергән: *борот* (урал сөйләшләрендә)*, пырт* (нократ-кистем)*, пурт, прыт, порт, пырут* (темников)*, пырыт* һ.б. Себер татарларында тагын *туан* термины да кулланылышта йөри.

*Буа* терминыннан һәм аның вариантларыннан шактый топонимнар ясалган: *Буа* – Буа районының үзәге, *Татар Буас*ы – Буа районындагы, *Иске Буа, Яңа Буа* – Кайбыч районындагы, *Югары Биябаш, Урта Биябаш, Түбән Биябаш* – Апас районындагы, *Буа* – Спас районындагы авыллар.

Терминга бәйле микротопонимнарның саны бихисап;

б) *Бәкене белдерүче гидрографик терминнар*. Әлеге төшенчәне белдерү өчен татар теле сөйләшләрендә *кой* (эчкен)*, уке* (касыйм)*, кодык, козык, кодок, козок, вәке* (хвалын)*, wәке* (чистай)*, ярлау* (тара)*, пәке* (бөре) терминнары кулланылышта йөри.

6. С у  о б ъ е к т л а р ы н ы ң  т ө б е  һ ә м  я р ы н ы ң  т ө з е л е ш  х а р а к т е р ы  б е л ә н  м ө н ә с ә б ә т л е  җ и р л е  г и д р о г р а ф и к  т е р м и н н а р: су төбендә барлыкка килгән чокыр, чоңгылларны (рус. *омут*) атау өчен – *чумгыл* (урал сөйләшләре)*, ирем* (урал сөйләшләре)*, умыт* (касыйм)*, йарлау* (тара)*, казан* (тау ягы

сөйләшләре), *әйләнмә* (норлат-кайбыч); суның иң тирән урынын атау өчен – *соңгыл* (минзәлә), *чокырча* (казан арты сөйләшләрендә), *дугай* (әтнә урынчылыгы), *җылу* (түбән кама керәшен сөйләшендә), *ярлау* (себер диалектларында); шарлавыкны атау өчен – *көзән елгасы* (минзәлә), *шарлык* (сарман урынчылыгы), *шарылдавык* (сергач, чупрәле), *шабырдаwык* (дөбьяз); елга ярларын белдерү өчен – *верех* (кузнецк), *кыр* (тобол, түмән), *сай йагасы* (тара), *җаргыч* (түбән кама керәшеннәре), *каш* (себер татарлары диалектларында) һ.б.

Урал татарлары сөйләшендәге *тоба,* чистай сөйләшендәге *кабак* термины «текә ярлы, сазламык елга урынын» һәм «текә ярлык, тирән, суы акмый торган күл» мәгънәләрен белдерә.

Әлеге терминнар топонимнар ясауда шактый продуктив: *Кабак суы* (Теләче районындагы елга атамасы), *Ирен* (Әлмәт районындагы елга һәм авыл атамасы), *Тоба* (Әгерҗе һәм Түбән Кама районнарындагы авыллар атамасы), *Төбәк-Чокырча* (Арча районындагы татар авылы) һ.б.

Гомумтөрки *яр* термины белән ясалган топонимнарны төркиләр яшәгән барлык төбәкләрдә очратырга мөмкин: *Акъяр, Кызылъяр, Ташлыяр, Караъяр, Сарыяр*.

7. Елга ярларына мөнәсәбәтле рәвештә якларны, ориентирны, урынны белдерә торган гидрографик терминнар: *юач-йуwач* (нократ-кистем), *аргы як* (урта һәм көнбатыш диалектының күп сөйләшләрендә), *арьяк* (шулай ук), *арҗак* (шулай ук), *вайар* (касыйм), *арак* (сергач), *кичү* (күп сөйләшләрдә нигездә шулай), *табар* (буа-тархан, камышлы, чистай, мәләкәс, хвалын), *кицмә* (чүпрәле, чергач), *чыгыш* (дүртөйле). Бу терминнар елга арьягын һәм кичүне белдерәләр.

Әлеге гидрографик терминнар белән ясалган топонимнар һәм микротопонимнар түбәндәгеләр: *Арьяк болыны* (Лаеш районы Татар Сараланы авылы), *Аргы саз* (Актаныш районы Аккүз авылы), *Табар елгасы* (Зөя елгасының кушылдыгы), *Табар Черкене* (Апас районындагы авыл атамасы), *Ташкичү* (Арча, Тукай, Ютазы, Буа районнарындагы авыллар), *Нратлы Кичү* (Минзәлә районындагы авыл), *Кичү елгасы* (Әлмәт районындагы елга) һ.б. (Саттаров, 1998: 72–73).

Гомумән алганда, татар телендә бүген кулланылышта йөргән терминнар арасында гомумтөрки терминнар өстенлекне алып тора,

дип нәтиҗә ясарга кирәк. Татар теленең төрле сөйләшләрендә алар нигездә бер-берсеннән фонетик яктан гына аерылалар. Шул ук вакытта кайбер төбәкләрнең үзләренә генә хас булган географик терминнар да очрый.

## § 18. Татар гидронимнарының этнолингвистик катламнары

Татар теленең лексик хәзинәсе бик борынгы заманнарда формалаша башлаган. Барлык топонимнар арасында да гидронимнар иң борынгылары санала. Шуңа күрә дә күп географик терминнар һәм алардан ясалган топонимнар төрки халыклар яши торган, яки элек яшәгән бөтен территорияләрдә дә очрыйлар, аларның күбесе төрки халыклар өчен, тагын да тирәнрәк керсәк, бөтен Урал-Алтай телләре гомумилеге өчен уртак ядкярләр булып торалар.

Тарих дәвамында җәмгыятьнең үсеше белән бәйләнешле рәвештә, башлыча, күмәклек сүзләрнең башта географик терминнарга һәм соңгыларының географик атамаларга әверелүе нәтиҗәсендә, аерым бер телдә сөйләшүче халыкның һәм шул халык яши торган территориянең топонимик системасы формалашкан. Теге яки бу урында, регионда, тарихи һәм географик шартлар, телләр һәм халыкларның үзгәреп торуы нәтиҗәсендә бер генә илнең дә географик номенклатурасының генезисы бер телгә яки халыкка гына кайтып кала алмый. Ул, күп катламлы ясалыш тәшкил итеп, һәрвакыт төрле чордагы һәм төрле тел элементларыннан торган хәлдә, эзлекле рәвештә акрынлап барлыкка килгән (Мурзаев, 1974: 323).

Татар гидронимиясенең барлыкка килүенә һәм формалашуына бик күп төрле лингвистик һәм экстралингвистик факторлар тәэсир ясаган. Бүгенге көндә татарлар аеруча компакт яши торган Татарстан Республикасындагы атамаларга гына игътибар белән карасак та, без әлеге территориянең кимендә биш этник дөньяның – борынгы иран кабиләләренең, фин-угор, төрки, монгол һәм славян халыкларының «контакт зонасы» икәнлеген күрәбез. Шуның нәтиҗәсендә Татарстан һәм аның белән чиктәш территорияләр топонимиясенең шактый катлаулы стратиграфик катламнары барлыкка килгән. Алар, үзара керешеп китеп, бер-берсенә көчле йогынты ясаганнар. Этногенетик яктан караганда татар топонимиясе бик катлаулы күренеш тәшкил итә.

Татар халкының этногенезы шактый яхшы өйрәнелгән өлкә. Аның составына төрле халыклар төрле дәрәҗәдә кереп

урнашканнар дип әйтергә мөмкин, әлеге халыкларның эзләрен без топонимиядә дә ачык күрәбез.

Г.Ф. Саттаров татар топонимиясен генеалогик яктан 8 төркемгә аерып карый:

1. Урал-Алтай телләре гомумилегенә карый торган топонимнар;
2. Алтай телләре гомумилегенә карый торган топонимнар;
3. Төрки-татар топонимнары;
4. Фин-угор телләренә нисбәтле топонимнар;
5. Борынгы иран телләренә нисбәтле топонимнар;
6. Монгол теленнән кергән топонимнар;
7. Гарәп-фарсы телләреннән кергән сүзләрдән ясалган топонимнар;
8. Рус теленнән һәм аның аша Көнбатыш Европа телләреннән кергән сүзләрдән ясалган топонимнар.

Татар гидронимнарын да этнолингвистик яктан нигездә шушы төркемнәргә аерып карарга кирәк.

1. Урал-Алтай телләре гомумилегенә карый торган гидронимнар. Әлеге төркемгә карый торган топонимнарны аерып билгеләү җиңел түгел. Бүгенгә кадәр тарихи-чагыштырма метод белән Урал-Алтай телләренең географик терминнарын, топонимнарын анализлап чыккан хезмәтләр юк дәрәҗәсендә. Шуңа күрә Г.Ф. Саттаров әлеге төркемгә, бүгенге татар телендә кулланылышта йөргән *ак ~ агым ~ агын, са ~ су, урман ~ орман, алан, кыр, лап* (казан арты сөйләшләрендә «тигез җир» мәгънәсендәге сүз) географик терминнарны һәм алардан ясалган топонимнарны гына мисал итеп китерергә мөмкин, дип күрсәтә (Саттаров, 1998: 350). А*к, агым, агын* терминнары белән ясалган топонимнар: Алтайда – *Агынакты елгасы*, Азәрбайҗанда – *Ахынджа елгасы*, Көнчыгыш Тянь-Шаньның көньяк тау битендә *Каракыракын, Каракумышакын, Суакынсай елгалары* билгеле.

*Су* сүзе татар гидронимиясендә шактый күп су чыганаклары атамаларында һәм алардан барлыкка килгән башка топонимнарда очрый. Мәсәлән: *Суык су елгасы* (Мамадыш районы), *Су башы газизләре чишмәсе* (Спас районындагы чишмә), *Сулы әкә* (Кама Тамагы районында Коры Үләмәнең сул кушылдыгы), *Карасу* (Башкортстанның Әбҗәлил районындагы елга) һ.б. Татарстанда 11 ойконим составында су компоненты кулланыла: *Югары Суыксу, Аксу, Карасу* һ.б.

О.Т. Молчанова тикшеренүләре су терминының үзе генә аерым су чыганагы атамасы булып бик сирәк (*Суг елгасы*) кулланылуын күрсәтә. Термин күбрәк ике, өч сүздән торган гидронимнар составында кулланыла (Молчанова, 1979: 91). Төрки халыклар яшәгән территориядә әлеге гидронимнар бихисап очрый. Мәсәлән, *Енисей* һәм *Абакан елгалары* бассейннарында күп гидронимнар *суғ* сүзе белән ясалганнар: *Казынсуғ, Сарысуғ, Демирсуғ; Алтайда: Суғ, Суғат, Карасуғ, Менсуғ* (Молчанова, 1979: 528–529). Төрле төрки халыкларда *су* сүзенең төрле фонетик вариантлары һәм алардан ясалган гидронимнар бар: *суғ, суg, зуг, сунг, су, зу, суг, шу, шыв, суу, сув* һ.б. Әлеге апеллятив барлык төрки халыкларда да бар дисәк тә, ялгыш булмастыр.

Борынгы төрки телдә *су* сүзе су (вода) мәгънәсендә кулланылган *sub~sug~suw* сүзенә барып тоташа (ДТС, 1969: 512–513, 515). Төрки телләрдә бу сүз, суны аңлату белән бергә, «елга» төшенчәсендә дә кулланылган һәм кулланыла.

Нәтиҗә ясап, әлеге төркемгә караган гидронимнарның артык күп түгеллеген һәм начар өйрәнелгәнеген күрсәтеп үтәргә кирәк.

2. Алтай телләре гомумилегенә карый торган гидронимнар. Алтай телләре гомумилегенә төрки, монгол һәм тунгус-маньчжур телләре төркемнәрен кертеп карыйлар. Әлеге төркемгә шактый күп географик терминнар керә: *болак, елга, арка, арт, кул, дала, кап, каб, кабы, бөре, ой (уй), кыя, түбә, сала, кабан* һ.б.

***Болак.*** Татар телендә *болак* – «елга, елгачык, инеш, чишмә, чыганак, канал» мәгънәләрендә кулланыла. В.В. Радлов аны үзенең сүзлегендә «Казан татарларында инеш, Казандагы канал исеме» дип терки (Радлов, 1911: 18–38). Заманында *Болак* – Казансу елгасының сул кушылдыгы саналган. Л.З. Будагов, М.Р. Фасмер, Э.В. Севортян сүзлекләрендә бу терминның, төрле фонетик вариантлары белән бергә, гагауз, төрек, казак, кыргыз, үзбәк, каракалпак, кумык, кабарда-балкар һ.б. төрки телләрдә «чишмә, инеш, ермак, канал, арык, су чыганагы, кизләү, күлләвек, сулык» мәгънәләре китерелә (Будагов, 1869; Фасмер, 1986; Севортян, 1974). Монгол телендә шул ук мәгънәдә *булак, булук, бурят* телендә *булаг,* калмык телендә *булг* вариантлары кулланыла. Күпчелек галимнәр *булак* термины күләме зур булмаган елга атамалары составына керә, дигән фикердә торалар.

Топонимист галимнәр Э.М. Мурзаев һәм В.Э. Мурзаевалар *булак (булага)* термины Монголиядән Балканга кадәр таралган дип күрсәтәләр (Мурзаев..., 1959: 303).

*Болак~булак* термины кайбер географик киңлекләрдә фонетик кына түгел, ә бәлки мәгънәви дә үзгәрешләр кичерә: аерым бер урынчылыкта корып барган елгаларны аңлата, икенче бер җирдә калкулык-тауларның атамалары составына керә. Мәсәлән, Тянь-Шаньда *Чимбулак яссы таулыгы*, Азәрбайҗанда *Гейбулак* һәм *Агбулак* атамалы тау сыртлары бар һ.б. (Гарипова, 2011: 137).

Татарстанда *болак* сүзе үзе генә дә, катлаулы атамалар составында да кулланыла: *Тигән булак елгасы* (Алексеев районы), *Сары болак* (Актай елгасының кушылдыгы), *Кара болак* (Кече Чирмешән елгасының кушылдыгы), *Озын болак* (Майна елгасы кушылдыгы) һ.б. Бу термин микротопонимнар составында да ифрат күп очрый. Мәсәлән: *Болак чишмәсе* (Болак суы бассейны, Саба районы), *Болак шишмәсе* (Олы Мишә елгасы бассейны, Саба районы).

***Бөре.*** *Бөре* орогидрографик термины елга ярларының геоморфологик үзенчәлегенә нисбәтле рәвештә барлыкка килгән. Берсе өстенә икенчесе өелеп, җыерылып менгән күп кенә киртләчләрдән, җир сырлары, катлам җыерчыклардан гыйбарәт булган агым су ярларын *бөре, бөреле* термины белән атап йөрткәннәр һәм мондый ярлы елгаларны Бөре, Бөрө яки Бөреле дип исемләгәннәр (Саттаров, 1998: 368).

Шул ук автор әлеге терминның асылында *бөрү* «сырлар, җыерчыклар ясап җыю, җыеру, бөрештерү» фигыле ята, дип күрсәтә (Саттаров, 1998: 368).

Топонимистлар арасында әлеге термин асылында *бүре* сүзе ята дип санаучылар да бар (П.И. Рычков, А.А. Камалов, Ф.Г. Гарипова һ.б.).

*Бөре* термины ярдәмендә шактый күп гидронимнар һәм башка географик атамалар ясалган. *Бөре елгасы* – Нократ елгасының уң кушылдыгы (Татарстанның Кукмара һәм Мамадыш районнарында), *Бөре (Бөрсу)* – Агыйдел елгасының уң кушылдыгы (Башкортстанның Бөре районында), *Бөре* – елгачык (Башкортстанның Мишкә районында), *Бөре суы* – елга (Татарстанның Балтач районында), *Бөре елгасы* – Казкаш елгасының уң кушылдыгы (Татарстанның Саба районында), *Бөреле елгасы* – Казансуның сул кушылды-

гы һ.б. Әлеге елга янына утырган шактый гына авыллар һәм хәтта шәһәрләр (*Бөре – Бирск*) әлеге атаманы йөртәләр.

*Бөре* термины килеп чыгышы ягыннан алтай телләре кардәшлеге чорларына барып тоташа.

Төрки телләрдән телеутларда *пуре* – «җыерчыклы, киртләч таулар; таучык өстендәге таучык», борынгы төрки телдә *бӱр* – «җыеру, тарту», *бӱриш* – «җөй, бөрмә», *бӱрмә* – «җыерма, бөрмә»; азәрбайҗан телендә *бӱрӱшмәк* – «1) җыерылу, тартылу, куырылу, 2) җыерчыклану», *бӱрӱшӱк* – «1) бөрмә, җыерчык, 2) бөрешкән, җыерчыкланган»; башкортларда *бөрмә* – «бөрмә (киемдә), бөрмәләү»; каракалпакларда *бӱр* – «бөрмә, җыерма ясау», *бӱрме* – «бөрмә, җыерма (киемдә)»; алтай телендә *бӱрме* – «бөрмә» һ.б. (Саттаров, 1998: 368) мәгънәләрен аңлата.

Монгол телләрендә *бори* – «тау бите, кашы; сөзеклек, янтык»; бурятларда *боори* – «калкулык, калку, биек урын; тау бите» мәгънәләрендә йөри.

Тунгус-маньчжур телләреннән эвенкларда *бор* – «таучык», *бори* – «таш таучык», *борикти* – «үр, калкулык» (Саттаров, 1998: 369) дигән төшенчәләрне аңлата.

Алтайда *бӱре* компоненты катнашында *Бӱре, Чай-Бӱре, Бай-Бӱре-Туу* һ.б. географик атамалар ясалган (Молчанова, 1979: 34).

3. Төрки-татар теленә нисбәтле гидронимнар. Татар теленә нисбәтле булган гидронимнарның һәм гидронимик терминнарның иң зур күпчелеге борынгы төрки телгә барып тоташа: *йарык, көл/күл, сув/су, тамак, күтер.* Болгар теленә барып тоташкан терминнар да бар: *сар/шар/саз, сырма/ширмә, җырмак/җырма, бөйө/буа, бәке, инеш, йуwач* һ.б.

Бөтен төрки телләр өчен дә уртак, гомумтөрки характердагы гидронимнар өстенлекне алып торалар. Мәсәлән, татар телендә «өстенә су чыгар-чыкмас яки чыгып торган баткак җир» мәгънәсен белдергән *саз* гидрографик термины гомумтөрки телгә нисбәтле. Бу сүз башка төрки телләрдә түбәндәге формаларда кулланыла: алтай телендә *саз-сас* (баткак; сазлы); башкортларда *һаз;* себер татарларында, хакас телендә *сас;* кыргызда *саз* (саз, сазламык болын); төрек телендә *saz* (камышлык, камыш); азәрбайҗан телендә *сас* (саз үләне) һ.б.

Сүзнең мәгънәсе һәм фонетик тышчасына бәйле рәвештә фикерләр төрлелеге күзәтелә, мәсәлән, Э.М. Мурзаев, *сай* сүзе дә

*саз/сас* сүзенең фонетик варианты, дигән фикердә тора (Мурзаев, 1984: 491).

*Саз* термины төрле тип гидронимик атамалар составында да еш очрый, аерым алганда: Алексеев, Апас районнарында *Сазлы елга*, Апас районы Әлмәндәр авылында *Саз күле*, Мамадыш районында *Сазлык елгасы* бар. Әлеге терминны кулланып егермедән артык ойконим ясалган. Микротопонимнарның санын әйтүе дә авыр, алар бихисап. Украинада *Сазих-Дере, Саз-Кор* исемле елгачыклар бар. Көнбатыш Себердәге Бараба даласында *Саскүл* һәм *Соскүл* атамалы күлләр бар.

Татарларда елганы *җай* термины белән атап йөртүләре дә билгеле. Ә.Ш. Әфләтунов, *Зәй, Җаек* гидронимнарының нигезендә борынгы татар телендә елганы белдергән әлеге термин ята, дип саный (Әфләтунов, 1960: 164).

Әлеге төркемгә тагын *Чирмешән, Сөн, Идел, Агыйдел, Чаллы, Ык, Аксу, Карасу, Каракүл, Аккүл, Сарыкүл, Сасы күл, Ачы күл, Акташ, Кара диңгез, Карабай, Казансу, Каратай, Кирәмәт, Казкаш, Зәй, Үләмә* һ.б. бик күп гидронимнарны китерергә мөмкин. Алар төрки халыклар яши торган бик зур территориягә таралганнар.

*Ширмә* сүзе белән ясалган атамаларга анализ ясап китик. Гидронимның генезисы болгар теленә нисбәтле. Чуваш телендә *çырма* сүзенең ике мәгънәсе бар: елга һәм тирән чокыр мәгънәләре. Чуваш галиме В.Г. Егоров бу терминның нигезендә *çыр* («су юып ашау, ишү») тамыры ята дип аңлата (Егоров, 1964: 226). Чагыштыр: угор *яр,* төрекмән, кыргыз *жар*, казак *жыра*, азәрб. *јарган* – «чокыр», төрек *irmak* – «елга», татар әдәби телендәге *ерганак*, татар теленең урта диалектындагы *җырганак, җырма(к)* сүзләре *йар ~ җир ~ йыр ~ çыр (йару~ йыру~ җиру)* тамырыннан (Саттаров, 1998: 384–385).

Татарстан буйлап аккан елгалар арасында *Олы Чирмешән, Кече Чирмешән* һәм *Чирмешән елгалары* да бар. Яуширмә авылына исем биргән *Яуширмә елгасы* да республика җирләреннән ага. Башкортстанда *Чирмәсән* атамалы елга бар. *Чирмешән* гидронимы болгар *ширмә ~ чирмә* («елга, тирән чокыр») + гомумалтай *шән~сән* («елга, елгачык») компонентларыннан тора һәм «елга + елга» конструкциясен тәшкил итә.

*Ширмә* сүзе ойконимнар ясауда да актив катнаша: *Караширмә, Орымширмә, Икширмә, Шуширмә, Ямәширмә, Яуширмә, Коширмә, Гулширмә* һ.б.

*Ширмә* сүзе кебек үк, Идел буе болгарлары теленә нисбәтле тагын бер гидрографик термин – *чаллы.* Ул борынгы болгар-татар телендә «таш» төшенчәсен белдергән *чал~чул* сүзеннән ясалган (Саттаров, 1998: 384), чуваш телендә әлеге сүзнең фонетик варианты *чул* лексемасы бүген дә «таш» дигәнне аңлата. Чувашлар Түбән Новгород шәһәрен Чулхала (Ташкала) дип йөртәләр.

*Чаллы* сүзе белән бик күп гидронимнар һәм ойконимнар ясалган. Авыл атамалары арасында *Тәберде Чаллысы, Бирдебәк Чаллысы, Бикчурай Чаллысы, Үри Чаллысы, Мәмли Казак Чаллысы, Котлыбөкәш Чаллысы* һ.б. бар. Гидронимнар: *Чаллы елгасы* (әлеге атама белән Татарстан аша 7 елга агып үтә), *Чаллы сазы* (Коры Үләмә суы бассейны, Кама Тамагы районы), *Чаллы суы* (Кама елгасы кушылдыгы, Тукай районы) һ.б.

4. Фин-угор телләренә нисбәтле гидронимнар. Урта Идел – Кама буе җирләре фин-угор гомумилеге формалашкан территория булып санала. III–IV гасырларда әлеге территориядә, башлыча, фин телле һәм иран телле кабиләләр яшәгән (Саттаров, 1998: 392). VI–VII гасырларда инде фин телле кабиләләр төрки кабиләләр белән үзара тыгыз бәйләнешләрдә яшәгәннәр. Соңрак монда болгарлар килеп урнаша һәм мөнәсәбәтләр яңа баскычка күтәрелә. Болгарлар Идел–Кама буендагы башка кабиләләр өстеннән сәяси гегемонлык урнаштыралар (Татарстан АССР тарихы, 1970: 37).

Археологик, тарихи һәм ономолингвистик тикшеренүләр Татарстан топонимиясенең һәм аның белән күрше территорияләр топонимиясенең иң борынгы этнолингвистик катламын генезислары фин-угор һәм иран телләренә кайтып кала торган топонимнар, антропотопонимнар һәм этнотопонимнар һәм җирле географик терминнар тәшкил итүен күрсәтә (Саттаров, 1980, № 1: 32–37).

Килеп чыгышлары белән фин-угор телләренә карый торган җирле географик атамаларның күбесе топонимнар составында чагылыш таба, Мисал өчен, Әлмәт районында *Кәшер* атамалы елгачык бар. Аның ярларына Кәшәр атамалы берничә авыл да урнашкан. Г.Ф. Саттаров әлеге елганың *кә, кәү, кау, кү* топонигезләре фин-угор телләренә нисбәтле дигән фикердә тора (Саттаров, 1998: 393–394). Чагыштыр: фин телендә *kivi*, эрзя-мордва телендә *kev*, мари телендә *кү*, ханты телендә *kew* – «таш», коми-зарян телендә дә *ки* сүзе кайчандыр «таш» мәгънәсендә кулланылган. Вычегда елгасы бассейнында *Кишер (Кишор) елгасы* һәм *Яреньга*

*елгасының кушылдыгы Киваж* атамалары да шул турыда сөйли. *Кишор* – «ташлы елга», ә *Киваж* – «ташлы кушылдык» дигән мәгънәне бирә (Общее языкознание, 1973: 98).

Татарстандагы *Күшер, Күңгәр, Куәм, Кавал (Ковали)* ойконимнарының асылында да шушы лексик берәмлек ята дип әйтә алабыз.

Балтач районында *Сасна* атамалы инеш һәм аның янында Түбән Сасна, Сасна Пүчинкәсе дигән авыллар бар. Сасна атамасы да фин-угор телләренә нисбәтле дип карала. Манси телендә *сос ~ шош* гидрографик термины «инеш», «кечкенә елга» дигәнне аңлата, *-на* топоформанты әйбернең булуын, барлыгын белдерә торган кушымча. Шул рәвешле Сасна атамасы «инешле» дигәнне аңлата. Балтач районында тагын әлеге лексема белән ясалган *Шошма* гидронимы да бар. Саба районында *Чайшур* (борынгы төрки телдәге *чай ~ сай ~ зәй* – «елга» + удмурт телендәге *шур ~ шор* – «елга» сүзләренә барып тоташа) гидронимының да икенче элементы шул ук топоформанттан тора.

Бу төркемгә кергән тагын бер термин – *норма/нурма*. Казан артында *Норма (Нурма)* атамасы йөрткән дүрт елга бар: *Кирмән елгасының уң кушылдыгы, Олы Мишә елгасының сул кушылдыгы, Уштарма елгасының сул кушылдыгы, Шошма елгасының уң кушылдыгы*. Шулай ук әлеге гидронимга нисбәтле ясалган *Нурма, Нурмабаш* авылларының атамалары да Казан ханлыгы чорыннан ук билгеле. Тагын Әтнә районында *Норма күле*, Питрәч районында *Норма сазы* бар.

*Нурма* гидронимының асылында манси телендәге *норма* – «1) елга, инеш, 2) борын, 3) күл» сүзе ята (Глинских, 1978: 151).

*Нокса суы* – Казанка елгасының уң кушылдыгы атамасының килеп чыгышы удмурт телендәге *нюк* – «киң чокыр, сыза» + бор. төрки *са* – «су» (ягъни «сулы чокыр, сыза») сүзләренә нисбәтле (Саттаров, 1998: 397).

Фин-угор телләренә нисбәтле гидронимнарга тагын мисал итеп *Сарсаз, Зөя, Ия* һ.б. бик күп атамаларны китерергә була.

5. Борынгы иран телләренә нисбәтле гидронимнар. Борынгы иран теленнән кергән географик терминнар һәм топонимнар татар телендә иң борынгы стратиграфик катламнарны тәшкил итәләр.

Безнең эрага кадәр I меңьеллык урталарыннан башлап, савромат-сармат кабиләләре бертуктаусыз диярлек, Кама аръягы

далаларында күчеп йөргәннәр һәм биредә курган тибындагы берничә, шул исәптән Агыйделдә *Киишкин* һәм *Ык елгасы* буенда *Мактама* дигән каберлекләр калдырганнар (Саттаров, 1998: 400). Сармат кабиләләре, билгеле булганча, иран кабиләләре саналалар.

Бүгенге көндә Татарстан территориясендә сакланып калган иран телләренә нисбәтле гидронимнарны да шушы вакытлардан калган дип исәпләргә кирәк.

Килеп чыгышы борынгы иран телләренә нисбәтле гидронимнарга борынгы иран сүзе *ранга* («кыяк») һәм аңа кушып әйбернең бер урында күп булуын, туплам-җыелмасын белдерә торган *сар ~ зар* кушымчасы белән ясалган *Рангазар* гидронимын кертәбез. *Рангазар* гидронимы «ярларында кыяк күп булып үскән урын» төшенчәсен бирә. *Рангазар елгасы* Мәллә елгасының сул кушылдыгы. Әлеге гидронимга бәйле рәвештә Сарман районында *Рангазар* һәм *Рангатамак* дигән ойконимнар да барлыкка килгән. Буа районында да *Ранга* дигән чуваш авылы бар.

Г.Ф. Саттаров *Мишә* гидронимының да иран телләренә мөнәсәбәтле булуы турында әйтә (Саттаров, 1998: 401–402). Ул гидронимны иран телләрендәге *бешә* «урман, имән» сүзенә нисбәтле булырга мөмкин дип күрсәтә. Әлеге гидроним белән мишәр этнонимының тамыры бер үк булырга мөмкин. Бу турыда фәнни әдәбияттә инде шактый язылды.

Татарстандагы өч елга *Кенә* атамасын йөртә. Аларның берсе *Бөре елгасы кушылдыгы*, икенчесе *Уштарма елгасының уң кушылдыгы*, һәм соңгысы *Шушма елгасының уң кушылдыгы*. Гидронимга нигезләнеп *Кенәбаш* (2), *Югары Кенә, Түбән Кенә, Кенәгор, Кече Кенә, Балды Кенә, Иске Кенә* ойконимнары барлыкка килгән. Аларда татар, мари, удмурт милләтләренең вәкилләре яши.

Мари телендәге *кыне* – «киндер» дигәнне аңлата. *Кенә* елгаларына әлеге исем, ярларында кыргый киндер үсемлеге күп булып үскәнгә бирелгән. Ф.И. Гордеев мари теленә *кыне* сүзе исә бик борынгы заманнарда ук иран телләреннән кергән дип саный (Гордеев, 1985: 83). Дөрес, *Кенә елгасына* атаманы борынгы иран кабиләләре вәкилләре биргәнме, яки марилар шулай атаганмы? Монсын бүген әйтүе авыр. Шәхсән без, атама мари теле аша кергән дигән фикердә торабыз. Борынгы иран теленә нисбәтле гидронимнар, башлыча, фин-угор телләре аша кергән суперстрат лингвистик берәмлекләр дип уйлыйбыз.

6. Монгол теленә нисбәтле гидронимнар. Аларның зур өлеше гомумалтай чорына карый. Биредә без төп игътибарны Алтын Урда чоры монгол теленә нисбәтле гидронимнарга юнәлтәбез. Әлеге чорга нисбәтле гидронимнар зур катлам тәшкил итмиләр, чөнки Алтын Урдада монголлар үзләре дә күп булмаган. Шулай да бу катламны инкяр итеп булмый. Әлеге катламның татар телендә кулланылуына бәйле рәвештә Г.Ф. Саттаров болай дип яза: «Болгар иленә килгән монгол феодаллары, баскаклар һәм башка йомышлы кешеләрнең этник (монгол) чыгышы, телләре, исемнәре, профессияләренә һ.б.га мөнәсәбәтле рәвештә, болгар-татар телендә кайбер географик терминнар, топонимнар (башлыча антропо-этнотопонимнар) һәм гидронимнар, икенче төрле әйткәндә, татар теле географик терминологиясе һәм топонимиясенең монгол катламы барлыкка килгән» (Саттаров, 1998: 405).

Татарстанда, аерым алганда Кукмара районы җирлегендә, монгол теленнән кергән *ус* «елга, су» сүзе белән ясалган гидронимнар бар. Мәсәлән, *Сәрдәүс елгасы* (*сәрдә* – үлән атамасы), *Өске, Кәркәүс, Үрәс елгалары*. Түмән өлкәсе Тобол районында да *Өс* атамалы елга бар. Татарстанда әлеге сүз белән *Өстәмак, Сәрдәүс, Кәркәүс, Югары Өскебаш, Үрәсбаш, Түбән Урас* ойконимнары да ясалган.

Топонимнарны өйрәнгән галим В.Ф. Барашков Ульяновск өлкәсендә монгол теленә нисбәтле *Ус, Баянгол* (монг. *баян* «бай» + *гол* «елга»), *Муранка* (монг. *мүрән* «елга») гидронимнары турында язып чыкты (Барашков, 1973: 20–31).

Монгол телендә *цагаан/чаган* сүзенең ике мәгънәсе бар: 1) ак; 2) өрәңге.

Ф.С. Фәсиев татар теленә *чаган* сүзе монгол теленнән кергән дигән фикердә тора (Фасеев, 1969: 189). Татарстанның Балтач районында *Чаган елгасы* бар. Ул *Ушма елгасына* коя. Ф.Г. Гарипова елга атаманы ярлары буенда үскән чаган («өрәңге») агачларына мөнәсәбәтле рәвештә алган дип саный (Гарипова, 1984: 128).

7. Гарәп-фарсы телләренә нисбәтле гидронимнар. 922 елда Идел буе Болгар дәүләте ислам динен рәсми кабул иткәннән соң, бу гидронимнар тормышның төрле өлкәләренә караган сүзләр белән бергә керә башлый, әмма аларны телдә күп дип әйтеп булмый. Сәбәбе: төрки-татар телендә елга атамалары системасы, гарәп-фарсы сүзләре кергәнче үк, шактый вакыт алда формалаш-

кан булалар. Әлеге телләргә нисбәтле атамалар, нигездә, кечерәк гидронимнар арасында очрый.

Елга атамалары арасында фарсы теленә нисбәтле иң киң таралган гидроним *чишмә* гидрографик термины белән ясалган. Татарстанда әлеге термин белән 24 елга һәм елгачык, инеш атамасы бар. Гидронимнар арасында *чишмә* сүзе состав өлешләрендә дә (*Карачишмә елгасы*), аерым-аерым да, төрле фонетик вариантларда да (*Шишмә елгасы*) кулланыла. *Чишмә* сүзе белән бер Татарстанда гына да 57 ойконим ясалган. Ул, шулай ук, бихисап күләмдә төрле топоним һәм микротопонимнарда, я булмаса, аларның состав өлешендә очрый.

*Чишмә* – фарсы телендәге «күз» мәгънәсендәге *чашм ~ чешм* (Персидско-русский словарь, 1960: 163) яисә «чыганак, чишмә»не белдерә торган *чашме* (Персидско-русский словарь, 1960: 164) сүзенә барып тоташа.

Югарыда әйтелгәнчә, гарәп-фарсы теленә нисбәтле гидронимнарны без, нигездә, кечерәк сулык атамалары (күл, инеш, чишмә, сазлык һ.б.) арасында очратабыз. Аларның да иң зур күпчелеген кеше исемнәренә, башлыча ир-ат исемнәренә, нигезләнеп ясалган гидронимнар алып тора: *Абидулла сызасы* (Сөлчә суы кушылдыгы, Чирмешән районы), *Абрай тамагы елгасы* (Шушма елгасы кушылдыгы, Арча районы), *Алгази чокыры* (Мәме суы кушылдыгы, Кама Тамагы районы), *Әбҗәлил бабай чишмәсе* (Рәҗәп суы бассейны, Спас районы), *Әбүбәкер елгасы* (Петйалка елгасы кушылдыгы, Яшел Үзән районы), *Әдәм елгасы* (Кече Чирмешән елгасының сул кушылдыгы, Аксубай районы), *Әдһәм күле* (Бидәңге суы бассейны, Тәтеш районы), *Әлмәмәт елгасы* (Көек елгасы бассейны, Балтач районы), *Әмин инеше* (Аты елгасы бассейны, Арча районы), *Әнвәр күле* (Ык елгасы бассейны, Баулы районы), *Әхмәт елгасы* (Кирмән суы кушылдыгы, Мамадыш районы, тагын 2 шушы исемдәге елга бар), *Баһави елгасы* (Кугубор елгасы бассейны, Балтач районы), *Бәшир чишмәсе* (Бәйрәкә елгасы бассейны, Баулы районы) һ.б. Шулай да хатын-кыз исемнәренә нигезләнгәннәре дә очрый (нигездә чишмә атамалары): *Бибигайшә әби кизләве* (Чынлы елгасы бассейны, Чүпрәле районы), *Биби елгасы* (Нырсы су кушылдыгы, Теләче районы; Сайа суы кушылдыгы, Биектау районы), *Вәлимә елгасы* (Арбаш елгасы кушылдыгы, Балтач районы), *Габизә чишмәсе* (Симет елгасы бассейны, Саба районы), *Габидә*

*абыстай кизләве* (Бола суы бассейны, Апас районы), *Гайниямал күле* (Кама елгасы бассейны, Әгерҗе районы) һ.б.

Ислам дине белән бәйле сүзләргә нигезләнеп барлыкка килгән гидронимнарны да билгеләп үтү зарур: *Әҗәл күле* (Әрә суы бассейны, Яшел Үзән районы), *Әүлия чишмәсе* (төрле районнарда бик күп очрый), *Зәм-зәм суы, Зәм-зәм чишмәсе* (Сулы елгасы бассейны, Балык Бистәсе районы). *Зират елгасы* – Татарстанда *зират* лексемасы кушып ясалган тагын 22 елгачык атамасы бар, күп санлы зират күлләре һәм чишмәләре һ.б.

Фарсы сүзләре ярдәмендә ясалган гидронимнарга *базар, бәйрәм* лексемалары ярдәмендә бирелгән атамаларны китерергә мөмкин: *Бәйрәм күле* (Кырлай елгасы бассейны, Биектау районы; Шәмәк елгасы бассейны, Биектау районы) *Базар елгасы* (Кече Мишә елгасы бассейны, Саба районы), *Базар күле* (Тигәнәле елгасы бассейны, Алексеев районы). *Базар* сүзенә нисбәтле гидронимнар Казакстанда, Кыргызстанда, Кавказда очрыйлар.

8. Рус һәм Көнбатыш Европа телләренә нисбәтле гидронимнар. Телебезгә рус теле сүзләре IX гасырда ук керә башлый. 1552 елда Казан ханлыгы рус дәүләте составына кушылгач, бу процесс тагын да көчәя. Вакытлар дәвамында татар теленә рус теленнән һәм Көнбатыш Европа телләреннән шактый гына географик терминнар керә. Аларга нигезләнеп, географик атамалар ясала. Гарәп-фарсы гидронимнары кебек үк, рус теленнән кергән атамалар да, гадәттә, зур булмаган сулыкларга, инеш-елгачыкларга, күл һәм чишмәләргә бирелә.

Бу гидронимнарны берничә төркемчәгә бүлеп карарга мөмкин:

1) рус теленә нисбәтле географик терминнардан *мулата* (рус. *болото*) Кама Тамагы сөйләшендә «пычрак, баткак» мәгънәсендә; *пырт, пырут* (рус. *пруд*) нократ-кистем, темников, гәйнә сөйләшләрендә «буа» мәгънәсендә һ.б.;

2) рус теленә бәйле гидронимнарның күбесе шулай ук антропонимнарга нисбәтле: *Александр күле* (Бола суы бассейы, Буа районы Александровка авылы булган), *Аленка елгасы* (Кече Чирмешән елгасы бассейны, Әлки районы), *Антон кизләве* (Инеш елгасы бассейны, Алексеев районы), *Борис елгасы* (Бүрсет суы кушылдыгы, Мамадыш районы), *Волоткин елгасы* (Чынлы елгасы кушылдыгы, Чүпрәле районы) һ.б. Әлеге гидронимнарның бер өлеше татар теленең әйтелешенә яраклаштырып кулланыла: *Антуннар чишмәсе*

(Шонталы елгасы бассейны, Алексеев районы), *Астафи күле* (Аксар суы бассейны, Зәй районы) – Астахиев фамилияле алпавытның җире шушы күл янында булган, *Әндери елгасы* (Чаллы елгасы бассейны, Балык Бистәсе районы) – Әндери бу елгада тегермән тоткан һ.б.;

3) теге яки бу кеше (алпавыт, бояр, сәүдәгәр) белән бәйле атамалар: *Бояр күле, Бояр чишмәсе* (Макса суы бассейны, Саба районы) – аерым мәгълүматлардан аңлашылганча, элек бу җирләрнең хуҗасы бояр булган;

4) хуҗалык эшчәнлеге белән бәйле бер төркем гидроним: *Алибастрлы су* (Казан суы бассейны, Биектау районы), *Дальнесбоз елгасы* (Тәмте елгасы бассейны, Саба районы), *Железянка суы* (Олы Үләмә суының сул кушылдыгы, Тәтеш районы), *Завод елгасы* (әлеге исемне Татарстанда 10 елга йөртә), *Забур суы* (Кама елгасының уң кушылдыгы, Мамадыш районы), *Завозной күле* (Кама елгасы бассейны, Лаеш районы);

5) совет идеологиясе белән бәйле гидроним: *Звезда инеше* (Брыс елгасы бассейны, Лаеш районы);

6) ярларында теге яки бу үсемлекнең, агачларның үсүе, кошкорт, хайваннар белән бәйле гидронимнар: *Березовка суы* (Шонталы суының сул кушылдыгы, Алексеев районы), *Гусинный сазы* (Актай суы бассейны, Спас районы), *Далинка елгасы* (Олы Мишә елгасының кушылдыгы, Питрәч районы), *Дубрау елгасы* (Су кизләү елгасының кушылдыгы, Чистай районы) – рус телендәге *дубрава* «имәнлек» сүзенә мөнәсәбәтле һ.б.;

7) суының пычраклыгына бәйле рәвештә барлыкка килгән атамалар: *Вонючка елгасы* (Кама елгасы бассейны, Кама Тамагы районы), *Грязнуха* (Актай суының кушылдыгы, Спас районы; Бизнә елгасының уң кушылдыгы, Спас районы; Прость суының сул кушылдыгы, Чистай районы);

8) сулыкларның башка сыйфатларына бәйле рәвештә барлыкка килгән гидронимнар: *Дребедень елгасы* (Кичү елгасының уң кушылдыгы, Әлмәт районы) һ.б.

Бүлеккә гомуми нәтиҗә ясап әйткәндә, татар теленең гидронимиясен дә һәм гидронимик терминнарын да тарих дәвамында барлыкка килү һәм үсеш-үзгәрешеен күзәтеп, генеалогик һәм хронологик яктан 8 төркемгә бүләргә мөмкин икәнлеге ачыкланды. Шулардан иң борынгы төркемнәр Урал-Алтай телләре һәм Алтай

телләре гомумилекләренә карыйлар. Гарәп-фарсы һәм рус, Европа телләренә нисбәтле гидронимнар чагыштырмача яшьрәк. Әлеге телләргә бәйле атамалар, нигездә, зур булмаган сулыкларга бирелгән, чөнки зур елгалар һәм күлләргә атамалар борынгырак чорларда беркетелеп калган.

## § 19. Татар гидронимнарын номинацияләү принциплары

Номинация теориясен өйрәнү хәзерге тел белеме өлкәсендә иң әһәмиятлеләрдән санала. Атау яки номинация процессы бик катлаулы күренеш һәм аның асылын ачу өчен бик күп сорауларга җавап бирергә кирәк: атауның үзенчәлеге, аңа тәэсир итүче лингвистик һәм экстралингвистик шартлар, эчке мәгънәне тамгалар системасы ярдәмендә бирү үзенчәлекләре һ.б.

Топонимик системаларның топонимнары үзләре белдереп килгән объектлар турында төрле төшенчә бирәләр. Объект атамаларының үзенчәлекләре кешеләрнең объектларны субъектив кабул итүләре, аларның хуҗалык эшчәнлегенә әһәмияте, башка кешеләргә яки объектларга мөнәсәбәте аша чагыла. Бу, үз чиратында, номинациянең принципларында, типларында һәм ясалу ысулларында чагылыш таба.

Атама бирү принцибы дигән вакытта без, нигездә, атамаларның барлыкка килү ысулларын, юлларын күз алдында тотабыз. Атаманың барлыкка килүенә нәрсә сәбәпче булган, ни өчен нәкъ шулай аталган, атама белән ул белдергән объект арасында нинди бәйләнеш бар? Бу сорауларга җавап атама бирү үзенчәлеген ачыклаганда табыла.

Ономастика фәнендә килеп чыгышлары башка класска караган ялгызлык исемнәреннән барлыкка килгән ялгызлык исемнәрен эпонимик ясалышка, ә турыдан-туры күмәклек исемнәреннән ясалган ялгызлык исемнәрен апеллятив ясалышка кертәләр (Подольская, Суперанская, 1969: 142).

Атама бирүнең төп өч принцибы бар: географик объектның сыйфатына карап атама бирү, объект белән кеше мөнәсәбәтләренә бәйләнешле рәвештә атама бирү һәм объектның башка объектларга мөнәсәбәтеннән чыгып атама бирү. Гидронимнарның атау принципларын билгеләү өчен без атамаларга семантик анализ ясау иң кулай ысул дигән фикергә кушылабыз. Анализ өчен нигез итеп шушы өч принципны алабыз.

Семантик классификацияләрнең төрле вариантлары бар. Без иң кулай төркемләү дип Ф.Г. Гарипова тарафыннан тәкъдим ителгән классификацияне таптык. Китерелгән мисаллар авторның шәхси картотекасыннан алынды һәм Ф.Г. Гарипованың «Татар топонимнары сүзлеге»нә таянып язылды.

Татар гидронимнарының иң зур күпчелеген татар теле нигезендә аңлатыла торган атамалар хасил итә (Гарипова, 2011: 200).

**1.** Географик объектның сыйфатына бәйле рәвештә барлыкка килгән атамалар.

Тормыш алып бару өчен ихтыяҗлары зур булган географик берәмлекләрнең физик-географик үзенчәлекләре халык күзенә иң беренче булып ташланган дисәк дөрес булыр. Күпчелек очракта нәкъ менә һәр географик объектның үзенә генә хас билгеләре атама кую өчен нигез булып хезмәт иткән. Мондый үзенчәлекләрнең үзләрен берничә төркемгә бүләргә мөмкин:

1. *Су чыганакларының аерым билге, үзенчәлекләрен, аерым характерларына мөнәсәбәтле рәвештә барлыкка килгән атамалар:*

а) су чыганаклары чыгарган тавышка нисбәтле атамалар: *Шарлавык елгасы* (Атасы елгасы бассейны, Әлки районы), *Шарлама елгасы* (Шия суы кушылдыгы, Мамадыш районы), *Шырылдавык чишмә* (Актай елгасы бассейны, Спас районы), *Көйле күл* (Башкортстан Республикасы, Дуван районы). В. Малыгин *Ом* елгасының атамасын бараба татарлары телендәге *ом* – «тын, тыныч» сүзенә нисбәтле дип яза (Малыгин, 1926: 134);

ә) су чыганакларының сулы яки коры булуларына нисбәтле рәвештә барлыкка килгән атамалар: Татарстан җирлегендә генә дә *Коры елга* атамасы белән 50 елга бар; ике *Коры күл,* берничә *Корыган чишмә*, *Коры сыза* һәм *Корыган сазлык* гидронимнары, *Юеш елгасы* (Олы Мишә елгасы бассейны, Саба районы) бар;

б) географик объектларның күләмен, зурлыгын, озынлыгын, тирәнлеген, тышкы формасын һ.б. сыйфатларын чагылдырган атамалар. Бу үзенчәлекләрне аерып аңлату өчен «күл», «елга», «чишмә», «инеш», «саз» һ.б. терминнарны ачыклап *кече, кечкенә, олы, озын, кыска, юан, кәкре, нечкә, түгәрәк, нәзек, тар* һ.б. кебек аергыч эпитетлар кулланыла. Мәсәлән: *Зур елга* (Иделнең кушылдыгы, Югары Ослан районы), *Зур күл* (10 нан артык атама), *Кәкре елга* (5 гидроним), *Кәкре күл* (20 гидроним), *Озын күл* (Орнаш елгасы бассейны, Арча районы), *Озын елга* (Чынлы елгасы

кушылдыгы, Чүпрәле районы), *Олы күл* (Татарстанда гына да 21 гидроним) һ.б.;

в) сулыкларның температурасыннан, ис-тәменнән, чисталыгы-пычраклыгыннан чыгып бирелгән атамалар: *Салкын чишмә елгасы* (Ашыт елгасы бассейны, Арча районы), *Суыксу чишмәсе* (Орым суы бассейны, Тәтеш районы), *Баллы ширбәт елгасы* (Олы Мишә елгасы кушылдыгы, Саба районы), *Сасы күл* (Гөбенә суы бассейны, Яшел Үзән районы), *Татлы күл* (Чиләбе өлкәсендә), *Ачы күл* (Курган, Томск өлкәләрендә) һ.б.;

г) төскә мөнәсәбәтле рәвештә барлыкка килгән атамалар. Мондый төр гидронимнар татар топонимиясендә генә түгел, гомумән, төрки топонимиядә ифрат зур урынны алып торалар. *Аксу, Карсу, Зәңгәр күл, Аккул, Сары күл, Сары елга, Кара үзән* тибындагы гидронимнарны Татарстан җирлегендә генә түгел, төрки халыклар яши торган бөтен территориядә бик күпләп очратырга мөмкин.

2. *Су чыганакларының төбе, туфрагы һәм грунт үзенчәлекләренә нисбәтле атамалар.*

Ачыклаучысы булып ком, таш, чуерташ, торф, акбур, алебастр һәм металл исемнәре килгән су чыганаклары, таулар, табигый байлыклар тупланган урыннарны атап күрсәтүләре белән зур әһәмияткә ия. Мәсәлән: *Ташлы елга* (Мәме суы кушылдыгы, Кама Тамагы районы), *Таш өсте елгасы* (Тирмән туйралыгы кушылдыгы, Яшел Үзән районы), *Торф елгасы* (Карлы елгасы кушылдыгы, Буа районы), *Бакыр базы елгасы* (Ушма суы бассейны, Мамадыш районы), *Бакыр тавы чишмәсе* (Кугубор елгасы бассейны (Аксубай районы). Чит өлкәләрдә: *Бәлчекле күл* (Самара өлкәсе Похвистнев районы), *Ком чишмәсе* (Башкортстан Республикасы Камышлы районы), *Төпсез күл* (Свердловск өлкәсе Әртә районы) һ.б.

3. *Үсемлекләр һәм хайваннар дөньясына нисбәтле гидронимнар.*

Татар су чыганакларының зур бер өлешен үсемлек һәм хайваннар дөньясына мөнәсәбәтле рәвештә барлыкка килгән атамалар тәшкил итә. Мондый төр атамалар башка халыклар өчен дә характерлы (Гарипова, 2011: 214). Алар түбәндәге билгеләрдән чыгып бирелгән:

а) агачларның төрләрен чагылдырган гидронимик атамалар. Мәсәлән: *Каенлы елга* (Алан Сырнасы елгасы кушылдыгы, Арча районы), *Каенлы күл* (Елга бассейны, Балык Бистәсе районы),

*Каен елгасы* (Ылгыма суының сул кушылдыгы, Кама Тамагы районы), *Зирекле елга* (Багана елгасы кушылдыгы, Чистай районы), *Тирәк елгасы* (Мортыш елгасы кушылдыгы, Сарман районы), *Юкәле куак елгасы* (Имәлле елгасы басейны, Апас районы), *Имәнле елга* (Зәй елгасы кушылдыгы, Зәй районы) һ.б.;

ә) су чыганакларының янында, ярларында, эчләрендә камыш, җикән, мүк һ.б. үсемлекләр үсүгә карап бирелгән атамалар. Мисаллар: *Камышлы елга* (Бикләнелгасының сул кушылдыгы, Тукай районы), *Мүкле күл* (Чистай районы), *Җикәнле күл* (Шәмәк елгасы бассейны, Биектау районы) һ.б. Бу төр гидронимнар арасында иң актив кулланылганнары *камыш* лексемасы белән ясалганнары. Алар бөтен Евразия киңлегенә таралганнар;

б) хайван, җәнлек атамаларына нисбәтле атамалар. Татарлар яшәгән барлык җирләрдә дә төрле хайван һәм җәнлек атамалары гидронимнарда һәм топонимнарда чагылыш таба: *Аю елгасы* (Шушма елгасы бассейны, Лениногорск районы), *Аю күле* (Казан суы бассейны, Арча районы), *Сыер елгасы* (Өләс елгасы бассейны, Балтач районы), *Бүре елгасы* (Арбаш елгасы бассейны, Балтач районы), *Куян елгасы* (Кама елгасы бассейны, Алексеев районы). Чит өлкәләрдә: *Сарык чишмәсе* (Самара өлкәсе, Камышлы районы), *Сыер кизләве* (Кулаткы елгасы бассейны, Ульяновск өлкәсе, Иске Кулаткы районы); *Кәҗә күле, Эткүл, Аю күле, Аткүл, Тайкүл* (Чиләбе өлкәсе) кебек гидронимнар очрый;

в) кош, балык, бака, сөлек, елан һ.б. исемнәргә нисбәттән барлыкка килгән атамалар. Мондый төр атамалар татар гидронимиясендә шактый еш очрыйлар. Мәсәлән: *Аккош күле* (төрле җирләрдә бик еш очрый), *Үрдәк күле* (Атасы суы бассейны, Әлки районы), *Тәкәрлек сазы* (Кече Мишә елгасы бассейны, Саба районы), *Казлы күл* (Баулы районы), *Елан елгасы* (Шубан елгасы кушылдыгы, Балтач районы). Чит өлкәләрдә: *Тутыш кош кизләве* (Ульяновск өлкәсе, Иске Кулаткы районы), *Сазанлы күле* (Башкортстан, Чишмә районы), *Балыклы* (Ашкадар елгасының сул кушылдыгы, Башкортстан), *Торналы күл* (Курган өлкәсе) һ.б.

4. *Гидронимнарның үзара яки башка объекталар белән мөнәсәбәтенә бәйле рәвештә барлыкка килгән атамалар.*

а) су чыганакларының үзара яки бүтән объектка карата урнашу урыннарына нисбәтле атамалар: *Магазин елгасы* (Талкыш елгасы бассейны, Чистай районы), *Канау елгасы* (Кече Сөлчә

елгасының сул кушылдыгы, Аксубай районы), *Зират чишмәсе* (Олы Сөлчә елгасы бассейны, Аксубай районы), *Җәйләү елгасы* (Нократ елгасы бассейны, Лениногорск районы) һ.б.;

ә) су чыганакларының үзара яки бүтән объектка карата урнашу урыннарына нисбәтле атамалар. Алар мәгълүм бер объекттан чагыштырмача ераклыкны белдерәләр: *Бирге Кабан, Урта Кабан, Ерак Кабан, Аргы Кабан* – Казан шәһәре территориясендәге күлләр. *Аргы елга* (Бәйрәкә елгасы бассейны, Баулы районы), *Олы Чирмешән* (Идел елгасының кушылдыгы), *Кече Чирмешән* (Олы Чирмешән елгасының кушылдыгы) һ.б.;

б) башка предметлар һәм күренешләр белән чагыштыру җирлегендә туган метафорик гидронимнар. Мондый атамалар, нигездә, кече елгалар, күлләр, гомумән алганда, микротопонимнар өчен хас. Зур гидронимнар да мондый күренеш күзәтелми. Кайбер гидронимнарның тышкы формасы кайвакыт кешенең физик кыяфәтен, яки киемен, я булмаса башка берәр төрле предметны хәтерләтә. Мәсәлән, *Күзлекле күл* (Актай суы бассейны, Спас районы), *Иркә күл* (Калмия елгасы бассейны, Актаныш районы), *Бала елгасы* (Наласа суы бассейны, Арча районы), *Камыт күл* (Башкортстан, Күгәрчен районы) һ.б.;

в) эмоциональ-экспрессив гидронимнар. Аерым гидронимнарда эмоциональ мәгънәләр бик калку итеп күрсәтелә: *Бетле күл* (Олы Мишә елгасы бассейны), *И суы* (Шушма суы бассейны) һ.б.;

г) микъдар-күләм, сан, чама һ.б. шундый төшенчәләргә нисбәтле гидронимнар. Мәсәлән: *Өч чат елгасы* (Ишем елгасы бассейны, Аксубай районы), *Биш имәнле елга* (Инеш суы бассейны, Кукмара районы), *Биш елгасы* (Бирәзә елгасы бассейны, Арча районы) һ.б. Тәртип саннары гидронимнар ясауда кулланыла: *Беренче елга, Икенче күл, Өченче чишмә* һ.б.

**2.** Кешеләрнең матди тормышы, хуҗалыгына нисбәтле гидронимнар.

Татар гидронимнарның шактый зур өлеше халыкның рухи дөньясы, матди тормышы, хуҗалыгына нисбәтле рәвештә барлыкка килгән һәм алар бу өлкәгә караган төрле чорлардагы мәгълүматларны үзләренә туплаганнар (Гарипова, 2011: 229). Аларда халыкның шөгыле, төрле һөнәрчелек һәм хезмәт атамалары чагылыш таба:

а) игенчелек, умартачылык, тимерчелек һ.б. шундый һөнәрләргә нисбәтле рәвештә барлыкка килгән гидронимнар. Мисаллар:

*Арыш суы* (Олы Мишә елгасы бассейны, Питрәч районы), *Игенлекләр елгасы* (Каратай елгасы бассейны, Лениногорск районы), Татарстан территориясе буенча агучы тагын *Янык, Тарлау, Ышна, Көек* елгаларының атамалары, *Умарталык елгасы* (Бөрсет елгасы бассейны, Мамадыш районы), *Алачык елгасы* (Наласы суы бассейны, Арча районы) һ.б.;

ә) Кустарь һәм ярымкустарь сәнәгать шөгыльләренә нисбәтле гидронимнар: *Бакыр заводы елгасы* (Олы Мишә елгасы кушылдыгы), *Күкертле елгасы* (Куак елгасы бассейны, Лениногорск районы), *Дегет базы елгасы* (Кирәмәт елгасы кушылдыгы, Аксубай районы) һ.б.

**3.** Халыкның иҗтимагый тормышы һәм рухи мәдәнияте белән бәйләнешле гидронимнар.

Әлеге гидронимнарда төрле тарихи вакыйгалар, гореф-гадәт, ышанулар, бәйрәм атамалары, туганлык терминнары, социаль һәм дини титуллар, төшенчәләр, кеше исемнәре һәм этнонимнар чагылышы таба:

а) тарихи вакыйгалар, халык гадәтләренә, ышануларына, бәйрәмнәренә һ.б.га нисбәтле рәвештә барлыкка килгән гидронимнар. Төрки халыклардагы язгы бәйрәм, Нәүруз бәйрәме атамасы *нәүруз* лексемасы белән аталган гидронимнар татар гидронимиясендә очрыйлар: *Нәүрүз* (Кече Мишә елгасы кушылдыгы), *Нәүрүз чишмәсе* (Ата елгасы бассейны). Төрле вакыйгаларга бәйле атамалар: *Көрәш күле, Шәкертләр күле, Орыш елгасы* (Ульяновск өлкәсе, Иске Кулаткы районы), *Корбан күле* (Актай суы бассейны, Спас районы), *Зәрә елгасы* (Кесмәс елгасы кушылдыгы), *Чүк елгасы* (Аты елгасы бассейны), *Сөрән* (Сәрдә елгасы кушылдыгы, Арча районы) (Зәрә, Чүк, Сөрән – элеккеге дини һәм халык бәйрәмнәре атамалары), *Кирәмәт елгасы* (Ашыт елгасының кушылдыгы, Биектау районы) (*Кирәмәт* сүзе – «гыйбадәт кылу, гыйбадәт кылу урыны» дигәнне аңлата). Шушы ук циклдан «изге» сүзе белән ясалган гидронимнар да. Әлеге сүз белән ясалган гидронимнар татарлар яши торган, яки яшәгән барлык урыннарда да табыла дисәк тә ялгыш булмастыр: *Изгеләр елгасы* (Каратай елгасы бассейны). Әлеге сүз белән гидронимнар арасында иң еш ясалган гидрографик объект итеп чишмәне күрсәтү кирәк;

ә) туганлык терминнарына нисбәтле гидронимнар. Мондый тип гидронимнарга *әби, бабай, ата, ана, бала* һ.б кебек туганлык

терминнары ярдәмендә ясалган сулык исемнәрен кертеп карарга кирәк: *Әби күле* (Минзәлә елгасы бассейны), *Бабай күле* (Зөя елгасы бассейны), *Аналык елгасы* (Куак елгасы бассейны), *Кыз елгасы* һ.б.;

б) социаль төркем титулларына нисбәтле гидронимнар: *Тархан елгасы* (Бидәңге елгасының кушылдыгы), *Ханнар елгасы* (Кече Бахта елгасының кушылдыгы), *Алпут суы* (Кече Мишә суы кушылдыгы, Саба районы), *Алпавыт күле* (Әрә суы бассейны, Яшел Үзән районы), *Алпавыт елгасы* (Зөя елгасы кушылдыгы, Буа районы). Хан, тархан сүзләре белән ясалган атамалар төркиләр яшәгән башка төбәкләрдә дә очрый. Мәсәлән, Осетиядә *Ханч, Ханша* топонимнары бар;

в) дини төшенчәләргә, терминнарга нисбәтле рәвештә барлыкка килгән гидронимнар: *Мулла елгасы* (Ашыт суы кушылдыгы, Әтнә районы.), *Пуп елгасы* (Олы Яклы елгасы бассейны, Чүпрәле районы), *Мулла күле* (Кече Мишә суы бассейны) һ.б.;

г) антропонимнарга нигезләнеп ясалган гидронимнар барлык халыкларның топонимиясендә, шул исәптән гидронимиясендә дә гаять күп очрыйлар. В.А. Никонов моның турында болай дип яза: «... теләсә нинди зур һәм кечкенә җир кисәкләре кемнеңдер шәхси милкенә әверелә башлый. Бу чорда «нәрсә», «нинди» дип куелган сораулар урынына «кемнеке» дигән сүзгә җавап алына торган топонимнар ясала» (Никонов, 1965: 50).

Безнең регионда антропонимнарга нигезләнгән атамалар зур елгалар өчен хас түгел. Кайбер авыл атамалары һәм алар яныннан ага торган елгалар онимик пар хасил итәләр. Әгәр мондый парларның нигезендә кеше исемнәре ятса, авыл атамасы, яныннан аккан шул ук исемдәге елга атамасына караганда, борынгырак була, чөнки кеше исеме башта авыл атамасы итеп бирелә, авыл исә шул исемне йөрткән кеше тарафыннан нигезләнә. Соңыннан гына бу исем шул авыл янындагы су чыганагы атамасы булып кулланыла башлый (Гарипова, 2011: 250). Ягъни татар гидронимиясендә антропогидроним теге яки бу сулыкның хуҗасына нисбәтле рәвештә генә барлыкка килмәгән. Чишмәләргә, мәсәлән, исем, гадәттә, аны карап, чистартып торган кеше исеменнән чыгып бирелә. Мәсәлән: *Әхмәт елгасы* (Чишәмә елгасы кушылдыгы, Лениногорск районы), *Федот суы* (Зичә елгасы кушылдыгы, Зәй районы), *Шәйдуллан чишмәсе* (Мичән елгасы бассейны, Саба районы), Татарстаннан читтәге төбәкләрдә: *Гөлбидә елгасы* (Чувашстан), *Байтуган*

(Сок елгасының уң кушылдыгы, Самара өлкәсе, Камышлы районы), *Үтәмеш елгасы* (Олы Чирмешәннең уң кушылдыгы, Самара өлкәсе Шонтала районы) һ.б.

Тагын бер үзенчәлекне күрсәтеп үтәргә кирәк: татар гидронимнары кеше исемнәренең кыскартылган формаларына нигезләнә (Саттаров, 1973: 4). Мәсәлән: *Сирай чишмәсе* (Сираҗетдин исеменең кыскартылган варианты), *Камай чишмәсе* (Камалетдин), *Кашай чишмәсе* (Кашафетдин) һ.б. Гидронимнар арасында хатын-кыз исемнәренә нигезләнеп ясалганнары артык күп очрамый;

д) этнонимнарга нисбәтле гидронимнар. Бүгенге нинди генә континентны, нинди генә территорияне алып карасак та, ул урында бер генә халыкның яшәмәвен күрәсең. Урта Идел – Урал алды территориясе дә төрле этник төркемнәрнең очрашып, кушылып, бер-берсен алмаштыру процесслары кичергән урын. Әлеге күренешләр топонимиядә дә чагылыш тапмый кала алмаган. Мәсәлән: *Биләр елгасы* (Кече Чирмешән елгасының сул кушылдыгы, Алексеев районы), *Болгар елгасы* (Урсала елгасының уң кушылдыгы, Әлмәт районы), *Бәҗәнә суы* (Ык елгасының уң кушылдыгы, Актаныш, Минзәлә районнары), *Коман суы* (Ык елгасының сул кушылдыгы, Мөслим районы), *Табын суы* (Симет елгасы кушылдыгы, Саба районы), *Кыпчак елгасы* (Мөслим районы), *Башкорт кизләве, Аса кизләве, Мукшы чишмәсе, Кална чишмәсе* һ.б.

Нәтиҗә ясап, әйткәндә, су чыганакларының физик-географик үзенчәлекләрен чагылдырган атамалар шул берәмлекләргә хас булган барлык төр физик сыйфатларны ачыклыйлар. Бу яктан татар гидронимиясе башка халыкларныкыннан аерылмый диярлек. Елгаларның физик үзенчәлекләре халыкка бәйле рәвештә аерыла алмый.

Татар халкы кайчандыр яшәгән, яки яши торган төбәкләрдәге хайван, үсемлек атамаларының барысы да диярлек гидронимиядә чагылыш тапкан. Бу шулай ук бөтен халыклар өчен дә хас күренеш.

Кешеләрнең эшчәнлеге һәм көнкүрешенә мөнәсәбәтле атамалар җәмгыять тормышының үсеше дәвамында җирле халыкның эшчәнлегенә, көнкүрешенә, мәдәни дәрәҗәсенә, эстетик зәвыкларына һ.б. бик күп сыйфатларына нигезләнеп ясалганнар. Бу төркемгә кергән атамалар, күрше һәм башка халыклар гидронимиясенә дә хас уртак күренешләрне ачу белән бергә, бар тик татар халкы өчен генә характерлы булган үзенчәлекле якларны, шулай

ук татар халкына гына хас рухи мәдәниятне, ышануларны һ.б.ны ачыкларга мөмкинлек бирә.

Гидронимнар арасында антропонимнарга нигезләнеп ясалган зул елга чыганаклары очрамый дип әйтергә мөмкин. Кеше исемнәренә нигезләнеп, зур булмаган су чыганакларының атамалары барлыкка килгән. Алар арасында ир-ат исеменә нигезләнеп ясалган гидронимнар иң зур күпчелекне алып тора.

## § 20. Татар гидронимнары төзелеш-ясалышында төп үзенчәлекләр

Гидронимнарның төзелеш-ясалыш үзенчәлекләрен өйрәнү өчен төрле ысул-алымнар кулланыла, төрле төркемләүләр тәкъдим ителә.

Топонимик формантларны аерып, анализ ясауны беренче тапкыр И.А. Износков (1885) В.П. Семенов-Тянь-Шанский (1916) хезмәтләрендә очратабыз. Шулай да атамалар составында еш кабатланган формантларга беренче булып А.Х. Востоков (1812) игътибар иткәнен ассызыкларга кирәк.

В.Н. Топоров һәм О.Н. Трубачев (1962) әлеге анализның ысулларын, методын эшлиләр.

Поляк галиме, ономатолог С. Роспонд узган гасырның урталарында топонимнарны, беренчеләрдән булып, структур-грамматик яктан анализлый башлый. Шулай ук үзләренең классификацияләрен А. Ванагас (1966), В.А. Жучкевич (1968), А.В. Суперанскаялар (1973) тәкъдим итәләр. Алар, нигездә, атамаларны гади һәм катлаулы төрләргә бүлеп карыйлар.

Татар топонимиясен өйрәнү тарихында атамаларның төзелеш-ясалыш калыплары мәсьәләренә беренче булып Г.Ф. Саттаров игътибар итә. Ул синтаксик, морфологик принципларны нигез итеп ала һәм, төзелешләренә карап, топонимнарны дүрт төркемгә бүлә: 1) иярүче һәм ияртүче кисәкләр төзелешен тәшкил итә торган атамалар; 2) ияртүче кисәктән башка кулланыла торган топонимнар; 3) иярүче кисәктән башка кулланылыш алган топонимнар; 4) исем+фигыль төзелмәсеннән ясалган атамалар.

Без, әлеге хезмәттә, Ф.Г. Гарипованың «Исследования по гидронимии Татарстана» (1991) басмасында китерелгән классификациягә таянып эш иттек. Әлеге төркемләү Ф.Г. Гарипова тарафыннан махсус гидронимнарның үзенчәлекләренә туры ки-

тереп эшләнгән, үз чиратында галимә алда эшләнгән бүленешләргә таяна.

Татар гидронимнарын төзелеш-ясалыш үзенчәлекләре ягыннан, иң беренче чиратта, ике зур төркемгә аерып карыйбыз: гади һәм катлаулы төзелешле атамалар.

Гади атамалар дип без бер генә сүздән торган атамаларны атыйбыз. Алар үзләре ике төргә бүленәләр: кушымчалардан башка барлыкка килгән (тамыр) гидронимнар һәм кушымчалар ярдәмендә ясалган (ясалма төзелешле) гидронимнар.

1. *Тамыр гидронимнар.* Бу төркемгә *саз, чишмә, елга, күл, су* кебек апеллятивлардан ясалган гидронимнарны кертеп карарга мөмкин. Шулай ук бу төркемгә *Ашыт, Ык, Сөн, Мишә, Идел, Шәбез, Чулман* һ.б. кебек гидронимнарны кертергә кирәк. Тамыр гидронимнар үзләре өч төркемгә аерыла:

а) бер иҗектән торган тамыр гидронимнар: *Зәй, Ык, Сөн, Сон, Чаж, Зөя* һ.б.;

ә) ике иҗектән торган тамыр гидронимнар: *Актай, Майна, Бахты, Кама, Чулман, Шишмә, Бола, Урал, Җаек, Ыргыз, Мишә, Камыш, Лашман* һ.б.;

б) өч иҗектән торган тамыр гидронимнар: *Чирмешән, Табанай, Мәүләшә, Кондырча, Кычыткан, Ликанур, Агыйдел* һ.б.

2. *Ясалма төзелешле гидронимнарга* кушымчалар ярдәмендә ясалган атамаларны кертәләр. Алар түбәндәге кушымчалар ярдәмендә ясала:

*-лык, -лек, -лы, -ле* кушымчалары гидронимнар ясауда иң продуктив кушымчалар саналалар. *-лык, -лек* кушымчасы нигездә үсемлек, агач, кош, хайван, балык һ.б. сүзләргә ялганып «тамырда күрсәтелгән предметларның җыелу, туплану урынын» аерып күрсәтә (Тумашева, 1964: 25). Мәсәлән: *Имәнлек, Урманлык, Каенлык, Таналык, Чаганлык* елгалары атамалары шундыйлардан.

*-лы/-ле* кушымчасының гидронимнарда, нигездә, өч төрле мәгънәсе кулланыла: мотивлаштыручы сүз буларак хайван һәм кош, үсемлек һәм агач исемнәре кулланыла: *Зирекле, Камышлы, Усаклы, Котлы* һ.б.; елга һәм аның рельефы үзенчәлекләрен белдергән исемнәргә кушылып, бу җирлекнең үзенә генә хас билгеләрен ассызыклый: *Комлы, Ташлы, Майлы, Бурлы* һ.б.; исемнәргә кушылып тамырда күрсәтелгән теге яки бу предметның барлыгын ассызыклый: *Бакчалы, Шаулы, Күзлекле, Казыклы* һ.б.

*-сар/-сәр* кушымчасы шушы урында тупланып үскән аерым агачларның, үсемлекләрнең күп булып үсүен күрсәтә: *Каенсар, Имәнсәр, Юкәсәр, Карамасар, Зирексәр* һ.б.

*-ан/-ән* кушымчасы гидронимиядә шулай ук шактый продуктив кушымчалардан санала: *Каран, Шуран, Шубан, Чаган* һ.б. Әлеге кушымча белән ясалган атамаларның мәгънәсен бүген аңлатуы шактый авыр. Мондый төр гидронимнар төрки халыклар яшәгән бөтен җирдә дә очрыйлар. Украина территориясендә генә дә кырыкка якын шундый атама билгеле.

*-ма/-мә* кушымчасы, фигыльгә ялганып, шуннан аңлашылган эш-хәл нәтиҗәсен белдерә торган предмет исемнәре ясый (Борһанова, 1980: 73). Әлеге кушымчалар ялгызлык атамаларын ясауда артык продуктив түгел: *Бөгелмә* (Зәй елгасы кушылдыгы, Бөгелмә районы), *Акма* (Шия елгасы кушылдыгы, Мамадыш районы), *Шарлама* (Куак елгасы кушылдыгы, Лениногорск районы), *Әйләнмә күл* (Сөн елгасы бассейны, Актаныш районы), *Айрылма* (Олы Сөлчә елгасы кушылдыгы, Аксубай районы) һ.б.

*-мыш/-меш* кушымчасы бүгенге көндә сүз ясауда катнашмый торган, продуктивлыгын югалткан кушымча, әмма ул шактый гидронимда сакланып калган: *Бөкмеш башы елгасы* (Мишә елгасының кушылдыгы, Саба районы), *Азмыш, Тулмыш елгалары* (Казансу елгасы бассейны). Кушымча төрки халыклар яши торган территорияләрдә дә еш очрый. Татар телендә шулай ук антропонимнар составында да сакланып калган: *Баймыш, Туктамыш, Үтәмеш* һ.б.

*-лар/-ләр* күплекне белдерә торган кушымча, башка төр онимнар ясауда катнашкан кебек, бу өлкәдә дә күзәтелә: *Морзалар күле* (Әгерҗе елгасы бассейны, Азнакай районы), *Сәетләр күле* (Сәкия елгасы бассейны, Мөслим районы), *Йасылар күле* (Чирмешән елгасы бассейны, Апас районы), *Көтүчеләр елгасы* (Ульяновск өлкәсе) һ.б.

*-мак/-мәк* кушымчасы белән ясалган атамалар шулай ук киң кулланылышка ия түгел: *Артмак елгасы* (Кече Чирмешән елгасы кушылдыгы, Чистай районы), *Азмак елгасы* (Бөгелмә елгасы кушылдыгы, Бөгелмә районы), *Ермак елгасы* (Олы Чирмешән елгасы кушылдыгы, Нурлат районы) һ.б.

*-чы/-че* кушымчасы, исемгә ялганып, затның исемен яисә профессиясен белдерә торган атамалар ясый. Бу кушымча гидро-

нимнар ясауда бик үк актив кулланылмый: *Сукачы күле* (Яуширмә елгасы бассейны, Чистай районы), *Тимерче күле* (Олы Сөлчә елгасы бассейны, Аксубай районы), *Балыкчы елгасы* (Зөя елгасы бассейны, Апас районы) һ.б. Күп булмаса да төркиләр яшәгән башка төбәкләрдә дә очрый.

*-вык/-век* кушымчасы аваз һәм образ ияртемнәреннән ясалган фигыльләргә ялгана һәм тавыш яки образны тудыручы исем ясый (Тумашева, 1964: 75): *Шарлавык чишмәсе* (Ата елгасы бассейны, Әлки районы), *Гөрләвек елгасы* (Олы Чирмешән елгасы бассейны, Нурлат районы), *Гөрелдәвек чишмәсе* (Шилнә суы бассейны, Тукай районы) һ.б.

*-ыш/-еш* кушымчасы шулай ук искергән кушымчалардан санала һәм бүгенге көндә продуктив түгел. Аның ярдәмендә ясалган гидронимнар эш яки хәлнең процесс формасын белдерәләр: *Җайыш елгасы* (Бизнә елгасының уң кушылдыгы, Спас районы), *Сайыш елгасы* (Шилнә елгасы кушылдыгы, Тукай районы), *Артыш елгасы* (Чалпы елгасы кушылдыгы, Баулы районы) һ.б. *Баеш, Аеш, Бигеш* антропонимнары булганлыгы да мәгълүм.

*-ча/-чә* кушымчасы белән ясалган гидронимнар иркәләү-кечерәйтү мәгънәсен белдерәләр (Гарипова, 2011: 276): *Зичә елгасы* (Зәй елгасының уң кушылдыгы, Зәй районы) атамасы Зәй елгасының кечерәйтү кушымчасы нигезендә ясалган варианты *Зәй > Зәйчә > Зичә; Сөлчә елгасы* (Олы Сөлчә елгасының кушылдыгы, Аксубай районы), *Кондырча елгасы* (Кече Сок елгасының кушылдыгы, Самара өлкәсе) һ.б.

Шулай итеп, татар гидронимнарын барлыкка китерүдә иң актив кулланыла торган кушымчалар итеп *-лы/-ле, -лык/-лек, -ан* кушымчаларын күрсәтергә кирәк.

Катлаулы төзелешле гидронимнар. Барлык төрки телләрдәге кебек, татар телендә дә гидронимик атамаларның зур күпчелеге синтаксик яктан тигәлләүле мөнәсәбәткә нигезләнгән, ияртүче + ияртүче кисәкләр төзелмәсен хасил итәләр. Иярүче кисәк вазифасын исем, сыйфат, сан, рәвеш һ.б. сүз төркемнәре үтиләр. Атаманың иярүче өлеше бер, ике яки берничә сүздән торырга мөмкин. Ияртүче кисәк функциясен географик термин башкара (Гарипова, 2011: 276).

Югарыда язылганнан чыгып, катлаулы төзелешле гидронимнарны түбәндәге төрләргә бүлеп карыйбыз:

1. *Ияртүчесе исем һәм исем төзелмәләреннән, ияртүчесе апеллятивлардан гыйбарәт гидронимнар:*

а) исемнең исемне янәшә тору чарасы аша ияртүеннән ясалган, ягъни изафә бәйләнешнең беренче формасына нигезләнгән атамалар: *Таш елга, Атау елга, Чишмә елга, Улак чишмә, Сыер куак* һ.б.;

ә) исемнең исемгә янәшә тору һәм тартым кушымчасы аша ияртүеннән ясалган, ягъни изафә бәйләнешнең икенче формасына нигезләнгән гидронимнар. Мәсәлән, кеше исемнәре белән ясалганнары: *Ахун инеше, Сәйфи күле, Корбан сазы, Тимүк күле* һ.б.

Мондый тип атамалар ияртүчесе зат исемнәренә мөнәсәбәтле рәвештә барлыкка килгән атамалар, ияртүчесе үзара янәшә тору чарасы белән бәйләнгән шәхес исемнәре һәм ияртүчесе тартым кушымчасы алган (*Заһит елгасы, Җиһан сазы, Хаҗәр сазы*) атамаларга һәм ияртүчесе шәхес исеме + туганлык термины, ияртүчесе тартым кушымчасы алган атамаларга (*Морат бабай чишмәсе, Шәех бабай чишмәсе*) бүленәләр.

Шушы ук төркемдә тагын башка төрле очраклар булырга мөмкин. Ияртүчесе шәхес исеме + дини термин, ияртүчесе тартым кушымчасы алган термин (*Мөхәммәт мулла чишмәсе, Самат мөәзин суы*); ияртүчесе агач яки башка үсемлек атамасы, ияртүчесе тартым кушымчасы алган термин (*Камыш чишмәсе, Карама чишмәсе*); ияртүчесе кеше кулы белән ясалган корылма, ияртүчесе номенклатура термины (*Тегермән елгасы, Амбар елгасы, Ферма елгасы*); ияртүчесе орографик яки гидрографик апеллятив, ияртүчесе номенклатура термины (*Атау елгасы, Чишмә елгасы, Алан чишмәсе*); ияртүчесе кош һәм хайван исеме, ияртүчесе номенклатура термины (*Карга күле, Каз күле, Торна чишмәсе*); тагын ияртүче кисәкләр этноним, географик эчтәлекле атамалар, ниндидер социаль, дини атамалар һ.б. булырга мөмкин (*Кыпчак елгасы, Басу чишмәсе, Бай елгасы* һ.б.).

2. *Ияртүче кисәге сыйфатлардан гыйбарәт булган төзелмәләр:*

а) ияртүче кисәге төп сыйфатлар булган атамалар. Моның сыйфат исемгә һәрвакыт янәшә тору чарасы аша бәйләнә һәм исеменнән аңлашылган әйберне, төшенчәне төсе, күләме, формасы, рәвеше, тәме, исе, температурасы һ.б. үзенчәлекләре ягыннан белдерә. Мисаллар: *Кара күл* (Балтач районы), *Ак чишмә* (Самара өлкәсе, Камышлы районы), *Озын күл* (Әгерҗе районы), *Тирән елга* (Бөр

елгасы бассейны, Кукмара районы), *Зур күл* (Чувашстан, Батыр районы), *Кәкре күл* (Актай суы бассейны, Спас районы), *Түгәрәк күл* (Актай суы бассейны, Спас районы), *Нечкә күл* (Иж елгасы бассейны, Әгерҗе районы), *Салкын чишмә* (Аналык суы бассейны, Лениногорск районы), *Сасы күл* (Башкортстан, Илеш районы) һ.б.;

ә) иярүче кисәге ясалма сыйфатлар белән белдерелгән атамалар. Мондый атамаларның иярүчесе *-лы, -ле, -лык, -лек, -сар, -сәр* кушымчалары белән ясалган сыйфаттан, ияртүчесе номенклатура терминыннан тора: *Баланлы елга* (Олы Мишә елгасы кушылдыгы, Питрәч районы), *Имәнле елга* (Зәй елгасының кушылдыгы, Зәй районы), *Каенсар елгасы* (Шәмәк суы кушылдыгы, Биектау районы), *Умарталык елгасы* (Бүрсет суы кушылдыгы, Мамадыш районы), *Камышлык елгасы* (Самара өлкәсе) һ.б.

3. *Иярүче кисәк булып саннар кулланыла торган атамалар.*

Сан исемгә янәшә тору чарасы аша иярә, ияртүчесе күплек кушымчасы алмый, чөнки сан белән ачыклану аркасында күплек кушымчасына ихтыяҗ калмый. Иярүче сан географик берәмлекнең төгәл санын, тәртип ягыннан ничәнче урында торуын белдерә: *Өч күл* (Майна суы бассейны, Спас районы), *Биш елга* (Майна елгасы кушылдыгы, Спас районы), *Беренче күл* һәм *Икенче күл* (Иж суы бассейны, Әгерҗе районы) һ.б.

4. *Иярүче кисәге төрле фигыль формаларына нигезләнгән гидронимнар.*

Татар гидронимиясендә ачыкланучы өлеше фигыль формалары яки фигыль формалары белән бәйләнешкә кергән башка сүз төркемнәре кушылып ясалган тезелмәләрдән торган атамалар байтак. Мондый атамаларның барлыкка килүләре шушы берәмлекләр янында булган берәр төрле истә калырлык, халык игътибарын җәлеп итә торган вакыйгалар белән бәйләнешле була. Гадәттә мондый атамалар вак су чыганаклары, микрогидромнимнарга бирелә (Гарипова, 2011: 285).

Мондый гидронимнарны төзелешләре ягыннан ике һәм өч составлы синтагмаларга бүлеп карарга кирәк.

Ике составлы синтагмаларга иярүчесе үткән заман сыйфат фигыльнең *-ган* формасына нигезләнеп ясалган фигыль, ияртүчесе термин булган атамалар: *Казыган елга* (Шушма суы бассейны, Балтач районы), *Чумган күл* (Самара өлкәсе, Әртә районы), *Атлаган чишмә* (Самара өлкәсе, Камышлы районы) һ.б.

Ияручесе *-ар, әр, -р* кушымчасы ялганып ясалган киләчәк заман сыйфат фигыль, ләкин мәгънәсе хәзерге заман сыйфат фигыльнең аналитик формасаныкы кебек. Мәсәлән, *Үргәагар елгасы* (Шушма елгасы кушылдыгы, Балтач районы), *Атчабар елгасы* (Ык суы кушылдыгы, Баулы районы) һ.б.

Өч составлы синтагмалар ияручесе шәхес исеме яисә кумәклек + үткән заман сыйфат фигыльнең *-ган* формасына нигезләнеп ясалган сүз, ияртүчесе термин (*Ат алган елга, Бала киткән күл*) һәм ияручесе сыйфат +кумәклек исем + сыйфат фигыльнең *-ган* формасына нигезләнеп ясалган фигыль, ияртүчесе термин (*Ак сыер баткан саз, Кара эт үлгән ермак*).

Гидронимнарга төзелеш-ясалыш ягыннан анализ ясаганнан соң, түбәндәге нәтиҗәләргә килергә мөмкин.

Ялгызлык атамаларының һәм апеллятивларның ясалыш ысуллары бер-берсеннән бик нык аерылмыйлар, ләкин кумәклек исемнәре ясауда катнашкан бөтен кушымчалар да ялгызлык атамаларын ясауда актив булмаска мөмкин. Гидронимнар ясауда иң актив кулланыла торган кушымчалардан *-лы/-ле, -лык/-лек* кушымчаларын билгеләргә кирәк.

Ияруче өлешендә исем формалары яткан катлаулы төзелешле гидронимик атамаларга төзелеш, ясалыш ягыннан тикшерү гидронимнарның күпчелек өлеше изафә бәйләнешнең икенче төре белән формалашкан булуы билгеле булды.

Изафә бәйләнешнең өченче төренә нисбәтле рәвештә ясалган географик берәмлекләр татар топонимиясендә бик аз.

Ияртүче өлеше төрле фигыль формаларына нигезләнеп ясалган атамаларның күпчелеге үткән заман сыйфат фигыльнең *-ган* формасына таянып ясалган гидронимнардан гыйбарәт.

## ТАТАР ОЙКОНИМИКАСЫ

### § 21. Татар ойконимикасын өйрәнү тарихы

Татар халкының атамалар дөньясы – кызыклы һәм киңкырлы өлкә. Милләтнең көнкүреше, тарихы, теле, яшәү рәвеше гасырлар дәвамында атамаларда сакланып кала. Халыкның яшәү өчен мөһим булып саналган урыннары махсус атамалар – ойконимнар – ярдәмендә билгеләнә. Әлеге атамаларның фән өчен кыйммәтле та-

рихи һәм лингвистик чыганак булуын галимнәрнең аларга карата елдан-ел арткан кызыксынуы дәлилли.

Топонимия юнәлешенең бер тармагы булып саналган ойконимия, халыкның этник, тарихи һәм мәдәни үсеш-үзенчәлекләрен ачыклауга юнәлгән фән буларак, үз актуальлегендә шик тудырмый. Дөрес булган лингвистик нәтиҗәләр ясау өчен тел составының һәр өлешен, бигрәк тә составында шактый «үле формалар» саклаган ойконимнар өлкәсен анализлау таләп ителә. Географик атамалар, чагыштырмача аз күләмле үзгәрүгә дучар булган категория буларак, халыкның теле һәм тарихына кагылышлы кыйммәтле чыганак булып тора. Гасырлар үтү белән, торак пункт атамалары, төрле табигать күренешләрен, халыкның тирә-яктагы чынбарлыкка мөнәсәбәтен, тел үзенчәлекләрен чагылдырып, буыннан буынга үзгәрешсез күчеп бара. Шуңа нисбәтле, ойконимиканы тирәнтен өйрәнүгә, аңа кагылышлы мәсьәләләрне дөрес чишүгә байтак фән тармакларына караган гомумфәнни фикерләүнең торышы бәйле.

Ялгызлык исемнәренең мәгънә эчтәлекләренә игътибар кешелек цивилизациясенең таңында ук туган. Борынгы Мисыр дәүләтендә үк язылган, географик атамалар җыелмасы һәм аларның классификацияләреннән гыйбарәт булган текстлар билгеле. Антик чорда Демокрит, Платон, Аристотель кебек фәлсәфәчеләр, атамаларны өйрәнү белән кызыксынып, ялгызлык исеме асылын ачу белән шөгыльләнгәннәр. Әлеге чор галимнәре, тикшерү объектыннан бигрәк, өйрәнү методына игътибар иткәннәр. Бүгенге көндә ялгызлык исеменең лингвистик яктан тикшерелүе кабул ителгән булса, борынгы чорларда ул күбрәк логик яктан өйрәнелә. Географик исемнәргә килгәндә, әлеге дәвер тарихи-географик хезмәтләрнең географик атамаларны аңлату белән үрелеп килүе билгеле. Ул вакытта топонимик этимологияләр билгеле бер мифологик сюжетка бәйле булганнар, ләкин, объектның географик үзенчәлекләренә бәйле, чынбарлыкка якын булган аңлатмалар да очрый.

Ономастика өлкәсенә караган күп кенә концептуаль хезмәтләр Т. Гоббс, Дж.Ст. Милль, Х. Джозеф, Б. Рассел, Г. Лейбниц кебек логик-галимнәр идеяләре белән бәйле. Әлеге галимнәр антик фәлсәфәчеләрнең традицияләрен дәвам итеп, А. Нурен, М. Бреаль, В. Брендаль, П. Кристоферсон һ.б. лингвистлар хезмәтләренә таянганнар (Суперанская, 2012: 55–77).

Мәхмүт Кашгариның «Диване лөгатет-төрк» (XI йөз) дигән хезмәтендә төрки телләрнең зур ономастик даирәсе чагыла (Кашгари, 2005: 1288). Тюрколог А.Н. Кононов фикеренчә, әлеге хезмәт: «...XI гасыр төркиләрнең тормышы, этноним һәм топонимнар, кардәшлек терминнары, титуллар һәм төрле вазифадагы зат исемнәре, азык-төлек, эчемлек, кыргый һәм йорт хайваннары атамалары, терлекчелек терминнары һәм номенклатурасы, шәһәрләр, хастә, дәва исемнәре, анатомик терминология, кыйммәтле казылмалар, хәрби, спорт, административ терминология, мифологик һәм тарихи каһарман исемнәре, дини һәм этник терминологиягә кагылышлы бердәнбер чыганак», – булып тора (Кононов, 1972: 6). Димәк, Мәхмүт Кашгари хезмәтендә төрки халыкләрның тарихи-географик мирасы сакланып калган.

Рус дәүләте, Казан ханлыгын яулап алып дистә еллар үткәч, 1565–1568 елларда, Казан һәм Зөя өязләренең яңа административ бүленеше буенча торак пункт атамалары теркәлгән һәм халык саны исәпкә алынган исәп кенәгәләре булдыра. XVII–XVIII гасырларга караган исәп кенәгәләрендәге мәгълүматлар татар топонимнарының тарихи-лингвистик катламнарын ачу өчен әһәмиятле чыганак булып торалар. Аларда шәхес исемнәре, авыл һәм су чыганаклары атамалары теркәлеп калган. Е.И. Чернышев «Селения Казанского ханства» дигән мәкаләсендә, исәп кенәгәләрен тикшереп, 700 атаманы барлый (Чернышев, 1971: 284–292; 2014: 264–302). Казан өязе татар авылларының бай тарихлы, аларның күп кенә мөһим вакыйгалар белән бәйләнеше бу авыллар атамаларын өйрәнүнең актуаль булуы турында сөйли.

XVI йөздә язылган Хисаметдин Шәрәфетдин бине Мөслими «Тәварихы Болгария» дигән хезмәтендә Болгар дәүләте территориясендәге авыллар, урман, тау, елга атамалары һәм кеше исемнәре турында байтак кына мәгълүматлар урнаштыра (Сатаров, 1970: 8 ).

Географик номенклатураны өйрәнүнең әһәмияте тарихи география белән билгеләнгән. Беренче карталарга ил исемнәрен теркәүчеләрдән, В.П. Семенов-Тян-Шанский, Л.С. Берг, А.Х. Востоков, В.Н. Татищев һ.б. галимнәр топонимик тикшеренүләргә зур өлеш керткәннәр. Топонимиягә географиянең бер өлеше буларак карап, алар картографик методны куллану мәсьәләсен күтәргәннәр. Топонимиягә игътибар арту географик атамаларны өйрәнү белән

шөгыльләнгән махсус комиссия һәм җәмгыятьләр барлыкка китергән. Шул рәвешле, Россия күләмендә географик терминологияне өйрәнү комиссиясе 1847 елда Рус Географик җәмгыяте кысаларында калкып чыга. Җәмгыять әгъзалары топонимия проблемаларын күтәргән төрле лингвистик хезмәтләр бастыралар. 1877 елда Казанда үткәрелгән IV Археологик съездда катнашучылар тәкъдиме буенча Казан Император университетында «Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте» оештырыла. Оештыручылар арасында В.В. Радлов, Н.Я. Агафонов, И.А Бодуэн-де-Куртенэ, Н.П. Загоскин, И.А. Износков, Д.А. Корсаков, В.Н. Поливанов, П.А. Пономарев, Н.И. Золотницкий, С.М. Шпилевский, Г.Н. Әхмәров, К.Г. Насыйри кебек күренекле галимнәр була. Оешманың максаты булып элекке Болгар-Хазар һәм Казан-Әстерхан ханлыклары территориясендә яшәгән рус һәм башка милләткә караган халыкларның бүгенге һәм үткәнге чорда торышын өйрәнү тора (Общество археологии, истории, и этнографии при Казанском университете http://wikipedia.org/wiki/).

1887–1930 еллар аралыгында җәмгыять Идел буе халыкларының тел, тарих, фольклор, иҗтимагый һәм гаилә эчендәге мөнәсәбәтләр, хуҗалык, дини ышанулар, мәдәният өлкәләрен тикшерүгә юнәлгән зур эшчәнлек алып барган. Оешманың «Известия Казанского общества археологии, истории и этнографии» исемле вакытлы басмалары чыгарылган. Әлеге басмаларда этнолингвистик, топонимик тикшеренүләр дә урын алган (http://snor.ru/?m=articles&an=sc_130). 1904 елда Казан университеты каршында составында И.А. Бодуэн-де-Куртенэ, А.Д. Руднев, А.А. Шахматов кебек күренекле галимнәр булган картографик комиссия оештырыла.

Соңрак чит илләрдә дә атамаларны өйрәнү киң таралыш ала. 1923 елда Англиянең гомум топонимик эшләрен алып баруга юнәлтелгән «Топонимик җәмгыять» формалаша. Соңрак алар Франция, Германия, Польша һәм Көнбатыш Европаның башка илләрендә дә таралыш ала. Польша, Германиядә тюркологияне өйрәнү үзәкләре оеша. Бу үзәкләрдә эшләүче галимнәрнең төрки атамарны өйрәнүгә багышланган хезмәтләре басылып чыга.

XIX икенче яртысында Идел буеның тарихы, шәһәрләре һәм авыллары турындагы хезмәтләр басыла башлый. Мәсәлән, Г.И. Перетятковичның 1877 елда «Поволжье в XV–XVI веках: очерки по истории края и его колонизации» дигән хезмәте дөнья күрә.

Шиһабетдин Мәрҗани 1885 елда язылган «Мөстафадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» дигән тарихи хезмәтендә Болгар дәүләте, Казан ханлыгы тарихларын һәм Рус дәүләтенә кушылганнан соңгы татар тарихын яктырта, шулай ук хезмәтендә топонимик берәмлекләрдән киң куллана.

Татар ойконимиясен фәнни өйрәнү XIX йөзнең ахырларында башлана. Бу чорда татар топонимиясе үсешенә С.М. Шпилевский, И.А. Износков, Н.И.Ашмарин, Н.И. Золотницкий, В.К. Магницкий, Г.Н. Әхмәров, К.Г. Насыйри зур өлеш кертәләр.

С.М. Шпилевскийның 1877 елда Казанда басылып чыккан «Древние города и другие булгаро-татарские памятники в Казанской губернии» дигән хезмәтендә этнонимнар, авыл атамалары, Казан атамасының килеп чыгышы аңлатыла (Шпилевский, 1877: 585).

XIX йөз ахырларында И.А. Износков Казан, Лаеш, Мамадыш өязләре авыл исемнәре, татар топонимиясе белән кызыксына башлый. Аның тырышлыгы белән бик күп татар авылларының һәм алар янынннан агып уза торган елга-инешләрнең исемнәре теркәлеп калган. И.А. Износков хезмәтләрендә ойконимнарның этимологияләре, төзелеш-ясалыш калыплары анализланган (Износков, 1884; 1885; 1893).

Урта Идел буе топонимнары турында Н.И. Золотницкий (1884), Н.И. Ашмарин (1902) һ.б.ның хезмәтләре басылып чыга.

Казан университеты каршындагы «Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте»нең гыйльми әгъзасы булган Каюм Насыйри үзенең «Зөя өязе авыллары» хезмәтендә Зөя өязе авылларын һәм шул авыллардагы кабер ташы язмаларын өйрәнеп, байтак авылларның бик борынгыдан, болгар заманнарыннан бирле яшәгәнлекләрен язып калдыра (Насыйри, 1975). Каюм Насыйриның ономастика өлкәсендәге эшчәнлеге Г.Ф. Саттаров, Г.Р. Галиуллина, Ә.Ш. Йосыпова, Г.К. Һадиева хезмәтләрендә яктыртыла.

Татар халкының бик мөһим байлыгы – ул кабер ташларындагы язулар-эпиграфик истәлекләр. Алар ойконимнарны өйрәнү өчен әһәмиятле чыганаклар булып торалар. Эпитафик истәлекләр Х.Ф. Фәезханов, И.А. Износков, Н.Ф. Катанов, Л.Җ. Җәләй, Н.Ф.Калинин, Һ.Ф. Йосыпов, Ф.С. Хәкимҗанов, М.И Әхмәтҗанов һ.б. хезмәтләрендә өйрәнелә. Каберташ язмаларында күп кенә авыл исемнәре сакланып калган.

Идел Болгарстаны җирендә беренче табылган, укылган таш 1173 елда куелган булган, ләкин ул сакланмаган (Алишев, 2006: 42). Каберташ язмалары хәзерге авылларның тарихын болгар заманнарына ук алып барып җиткерә. Аларда борынгы ойконимик берәмлекләр сакланып калган. Болгар-Казан чорына караган кабер ташларын тарихчы Һ.В. Йосыпов тикшерә (Юсупов, 1960: 165). Ул Казан шәһәре атамасы һәм башка ойконимик берәмлекләрне өйрәнүгә үзеннән зур өлеш кертә.

Болгар чоры эпитафиясенең тел үзенчәлекләрен Ф.С. Хәкимҗанов өйрәнә (Хакимзянов, 1978: 206). М.И. Әхмәтҗанов Казан артындагы авылларның тарихын кабер ташларындагы язмалар, шәҗәрәләр һәм риваятъләрдәге хәбәрләр буенча тикшерә (Әхмәтҗанов, 1999). Тарихи чыганаклар, эпитафик язмалар, шәҗәрәләр һәм археологик тикшерү нәтиҗәләре җиде йөздән артык авылның Болгар, Алтын Урда, Казан ханлыгы чорларында ук яшәгәнлеген күрсәтә.

Ф.С. Фәсиевнең «XVIII гасырда иске татар телендәге эш кәгазьләре» (1981), Ф.М. Хисамованың «XVIII йөздәге татарча эш кәгазьләренең тел үзенчәлекләре» (1981), «Татарский язык в восточной дипломатии России» (2012) дигән хезмәтләрендә күп кенә географик берәмлекләр, авыл атамалары искә алына.

Г.Ф. Саттаров, беренчеләрдән булып, татар ойконимиясенә кагылышлы тарихи-этимологик, лексик-семантик, сүз ясалышы, этимологик пландагы тикшеренүләр үткәрә. Аның татар ойконимиясенә багышланган беренче монографик хезмәте 1971 елда «Ни өчен шулай аталган? Татарстан топонимнары» дигән исем астында басылып чыга. Автор бу хезмәтендә Казан шәһәренең нигезләнү вакыты, шәһәр атамасының мәгънәсе турында аңлатмалар бирә. Татарстан районнары һәм район исемнәренең килеп чыгышын, аларның тарихларын яктырта. 1975 елда галим, тюркологиядә беренчеләрдән булып, төрки-татар ономастикасы буенча «Антропотопонимия Татарской АССР» (1975) дигән темага докторлык диссертациясе яклый. Ул докторлык диссертациясендә һәм «Татарстан АССРның антропотопонимнары. Татарстан авылларының исемнәре» (1973) дигән монографиясендә, бик күп фактик материалларга нигезләнеп, Татарстанның авыл исемнәрен тарихи-лингвистик яктан тикшерә. Хезмәттә төрки-татар кеше исемнәренә, фамилияләргә һәм кушаматларга нисбәтле авыл

атамаларының ясалышы, этнолингвистик катламнары өйрәнелә. Бүгенге көндә дә фәнни яктан ачыкланып бетмәгән болгар катламы һәм шул катламга караган болгар антропотопонимнарына анализ ясала. Г.Ф. Саттаров тикшеренүләрендә авыл атамаларының 50% ы антропоойконимнардан барлыкка килүен исбатлый, ягъни 3942 торак пункттан 1968 енең атамасы кеше исемнәренә нигезләнеп барлыкка килүен билгели. Галимнең «Мәктәптә туган як ономастикасы» (1984), «Атамалар дөньясына сәяхәт» (1992), «Татар топонимиясе» (1998) һ.б. хезмәтләре татар ойконимиясенә багышлап язылган.

Профессор Г.Ф. Саттаров татар теле белемендә күпсанлы яшь галимнәр тәрбияләгән шәхес. Аның җитәкчелегендә фәнгә аяк баскан, ономастиканың бер тармагы булган ойконимия өлкәсендә актив эш алып барган күренекле галим, профессор Ф.Г. Гарипова хезмәтләре аерым игътибарга лаек. Галимә борынгы чыганакларга, археология, тарих, тел материалларына нигезләнеп, Казан арты һәм Тау ягы авылларының тарихын, авыл исемнәренең мәгънәсен ачыклап фәнни хезмәтләр язды. Аның «Борынгы Болгар шәһәрләре» (1990), «Авылларны сөям җаным-тәнем белән» (1994), «Авыллар һәм калалар тарихыннан» (2001; 2003), «Хәтеремнән чыкмый һич тә...» (2003), «Духовный родник: знаменитые татарские деревни» (2005), «Рухи башкалабыз: мәшһүр татар авыллары» (Казан, 2005), «Авыл – милләтебезнең җаны» (Казан, 2011) һ.б. хезмәтләрен җәмәгатьчелек зур кызыксыну белән кабул итте.

Бүгенге көндә бу галимнәрнең шәкертләре аларның традицияләрен дәвам итәләр.

Г.Ф. Саттаровның шәкертләре ойконимия өлкәсендәге мәсьәләләрне тикшерүгә күп көч куялар. Шундыйлардан Р.И. Куряева «Тюркский пласт русской ойконимии Среднего Поволжья» (1992) дигән хезмәтен Урта Идел буе рус ойконимиясендәге төрки атамаларны, А.Ю. Филькова «Историко-лингвистический анализ полисонимов тюркского происхождения РСФСР» (1989) дигән хезмәтен төрки чыгышлы шәһәр исемнәрен өйрәнеп яздылар. 1998 елда Г.К. Һадиева, рус язу кенәгәләренә нигезләнеп, Казан ханлыгы чоры ойконимнарын тарихи-лингвистик яссылыкта өйрәнә һәм «Историко-лингвистический анализ ойконимии Казанского ханства» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклый. Ул «Ойконимы периода Казанского ханства (по писцовым книгам)» (2004)

дигән монография бастырып чыгара. З.Ф. Әхәтова тарафыннан Түбән Кама буе авыл атамалары буенча «Топонимия Нижнего Прикамья Татарстана» (1994), О.Р. Хисамов тарафыннан Көнбатыш Кама аръягы ойконимиясе буенча «Историко-лингвистический анализ ойконимии Западного Закамья Татарстана», Р.И. Хаҗиев Көньяк-көнчыгыш Кама аръягы ойконимиясе буенча «Историко-лингвистический анализ Юго-Восточного Закамья Татарстана» (2000), Ф.С. Сәлимҗанова Тау ягы ойконимиясе буенча «Историко-лингвистический анализ антропонимической системы Нагорной стороны Республики Татарстан» (2002), Р.К. Садыйкова Ульяновск өлкәсе ойконимнары буенча «Историко-лингвистический анализ тюрко-татарской топонимии Ульяновской области Российской Федерации» (2003) дигән темаларга кандидатлык диссертацияләре яклыйлар.

Ф.Г. Гарипова җитәкчелегендә И.Г. Әхмәтҗанов, IX–XVI йөз елъязмаларындагы төрки-татар географик атамаларын тарихи-лингвистик яссылыкта өйрәнеп, «Историко-лингвистическое исследование тюрко-татарских географических названий в русских летописях IX–XVI вв.» (2004) дигән темага фәнни хезмәт яза.

Алабуга өязе атамаларын өйрәнеп, А.К. Гәрәева «Историко-лингвистический анализ топонимов Елабужского уезда» (2004) дигән хезмәт яза.

Себер төрки ойконимиясе Х.Ч. Алишина, З.С. Камалетдинова, С.З. Рахимбакиев хезмәтләрендә тикшерелә.

Ә.Г. Кәримуллин, М.З. Зәкиев, Л.Ш. Арсланов, Н.Б. Борһанова, Д.Б. Рамазанова, Ф.Й. Йосыпов һ.б. галимнәрнең авыл атамаларын өйрәнүгә багышланган хезмәтләре бар.

Соңгы елларда Татарстан һәм татар халкы тарихын ачыклау эшчәнлегендә яңа мөмкинлекләр туды. Шул сәбәпле, төбәкләр тарихын ачыклау, атамаларны өйрәнү өлкәсенә тарихчыларның да игътибарлары артты. А.Х. Халиков, С.Х. Алишев, М.Г. Госманов, Р.Г. Фәхретдинов, И.Р. Таһиров, Д.М. Исхаков, Р.Ф. Галләмов, Р.Г. Насыйров һ.б.ның хезмәтләре зур әһәмияткә ия.

Төрки ономастикасына киң рәвештә якын килү XX гасырның 20 нче елларында башлана. Төрки ареалларның ономастикасы, шул исәптән ойконимикасы буенча язылган хезмәтләрдән Э.М. Мурзаев, Н.А. Баскаков, О.Т. Молчанова, А.К. Матвеев, А.Н. Кононов, В.М. Насилов, К.М. Мусаев, И.А. Воробьева, В.И. Абаев һ.б.

галимнәрнең фәнни басмаларын әйтеп үтәргә кирәк. Башкортстан ойконимиясе Т.М. Гарипов, А.А. Камалов, Ф.Г. Хисамитдинова хезмәтләрендә өйрәнелә. Казак топонимнарының структур типларына, ясалыш ысулларына, этимологияләренә караган хезмәтләр С.А. Амажолов, А.А. Абдрахманов, Т.Д. Жанузаков, А.Т. Кайдаров, Е.А. Керимбаев, Е. Койшыбаев, Г.К. Конкашбаев, Г.Б. Мадиева, Н.А. Прманова кебек галимнәр тарафыннан бастырыла. Үзбәкстаннан Х.Х. Хәсәнов, С.К. Караев һ.б. Урта гасыр топонимнарын тарихи-географик планда тикшерәләр. Азәрбайҗан топонимнарының кардәш телләр материаллары белән чагыштырып бирелгән җентекле лингвистик анализ Р.М. Юзбашев, С.М. Молла-Заде хезмәтләрендә чагыла. С. Атаниязов хезмәтләрендә Төрекмәнстан топонимиясе, К. Абдимуратов хезмәтләрендә каракалпакларның географик атамалары, Д. Исаева, К. Конкабаев хезмәтләрендә кыргыз атамаларының этимологиясе, лексик-семантик классификациясе, ясалыш үзенчәлекләре тикшерелә. Шулай итеп, төрки телләрнең ойконимикасы киң дәрәҗәдә өйрәнелгән, бик күп хезмәтләр басылып чыккан.

XX йөз урталарыннан төрки ойконимикасына багышланган җыентыклар басылды: «Топонимика Востока» (1962; 1964), «Языки и топонимия Сибири» (1970; 1972; 1976), «Диалекты и топонимы Поволжья» (1972; 1973), «Вопросы топоономастики», «Ономастика востока» (1980), «Ономастика Татарии (1989) һ.б.

1967 елдан ономатолог В.А. Никонов тырышлыгы белән «Идел буе ономастикасы» исемле конференцияләр үткәрелә башлый. Идел буеның Ульяновск (1967, 2017), Горький (1969), Уфа (1971, 2006), Саранск (1973), Пенза (1975), Волгоград (1989, 1995, 1998, 2002), Йошкар-Ола (2008), Казан (2010), Ярославль (2012), Тверь (2014), Арзамас (2016) шәһәрләрендә үткәрелгән әлеге конференцияләр ономастиканың топонимия, антропонимия, этнонимика, микротопонимика, зоонимия, космонимия һ.б. бүлекләренә кагылышлы төрле проблемаларны чишүгә, мәсьәләләрне ачыклауга юнәлдерелде. Шулай ук «Идел буе ономастикасы» конференцияләре төбәк халыкларының бер-берсенә тәэсир итеп яшәү шартларындагы үсешләрен, төрле лингвистик үзгәрешләрне, фән торышын ачыклауга гаять мөһим өлеш кертә.

Шулай итеп, ойконимнарга лингвистик, тарихи һәм географик хезмәтләрдә үзәк урын бирелүе күзәтелә. Төрле фән галимнәре

тырышлыгы белән ойконимика фәнни танып белү системасында үз урынын таба. Төрки-татар ойконимикасына караган күпсанлы хезмәтләр булуга карамастан, борынгы чорда барлыкка килгән ойконимик проблемаларны чишәр өчен, барлык географик атамаларны системалаштыру сорала.

### § 22. Ойконимик терминнар һәм аларның орфографиясе

Татар теленең ойконимик терминнары төзелеш-архитектура терминнарына якын торалар, чөнки ойконимия үзе кешеләрнең төзелеш-корылыш эшчәнлеге нәтиҗәсендә барлыкка килгән.

Торак пунктларның һәм аларны барлыкка китерүче корылмаларның төре, функцияләре, милли үзенчәлекләре халыкның хуҗалык һәм мәдәни тарихы, көнкүреш үзенчәлекләре, тормыш тәртибе белән тыгыз бәйләнгән. Шуңа күрә халыкларның төзелеш-архитектура тарихында этник, мәдәни һәм хуҗалык тарихы да тулы чагылыш таба (Саттаров, 1992: 104).

Төрки халыкларның моннан мең еллар элек күчмә тормыштан утрак тормышка күчүләре төрле шәһәр-калалар, авыллар, кальгалар, кышлаклар төзүдә бай тәҗрибә туплауга һәм камил осталыкка китергән. Х гасырда Болгар, Биләр, Сувар шәһәрләре Болгар дәүләтенең төп шәһәрләре булалар. Дәүләтнең төп халкы Идел һәм Кама кушылдыклары буенда урнашкан күпсанлы авылларда һәм бистәләрдә яшиләр.

Төрки халыкларның ойконимик терминнары Э.М. Мурзаев, Г.Ф. Саттаров, Н.Б. Борһанова, В.А. Бушаков, О.Т. Молчанова, Н.А. Прманова, А.Ю. Филькова, Ф.Г. Хисамитдинова, Г.К. Һадиева һ.б. галимнәрнең хезмәтләрендә урын алган.

Торак пунктларның барлык төрләрен (шәһәр, крепость, авыл, йорт, өй) җыйма рәвештә атау өчен ойконим термины кулланыла. Ойконимик терминнарга *балык, тура, кирмән, кар, чеп/чип/чит, бура, кала, кенд, ил, йорт, сала, өй, гел / гил / кил, ката/кәтә* лексемаларына нигезләнеп ясалган авыл атамалары керә.

Э.М. Мурзаев торак пункт типларын белдерә торган терминнардан ясалган атамаларны этномәдәни апеллятивлар дип атый (Мурзаев, 1996: 151).

Ойконимик терминнарның парадигматик рәте Татарстанның тарихи һәм хәзерге торак пункт атамаларында урын алган. Бу терминнар гади, кушма, тезмә исемнәр составында кулланылалар.

Үз вакытында Н.К. Дмитриев төрки телләрдәге шәһәр һәм авыл мәгънәсен белдерә торган барлык ойконимик терминнарның: *кала* (гарәп), *шехир* > *шехер* > *шахар* > *шар* (фарсы), якут телендә *куорат* сүзе рус теленнән «город», *аул* (монгол), кырым татар *кей/кой* «авыл» (фарсы), чуваш, татар *сала* «авыл» (хәзәр) башка телләрдән кабул ителүен, ягъни алынма сүзләр булуын билгеләгән иде (Дмитриев, 1962: 506).

Н.К. Дмитриев ясаган нәтиҗәләр дөреслеккә туры килә, ләкин конкрет төрки-татар тел материаллары, эзләнү нәтиҗәләре *балык* «шәһәр», *тура* «шәһәр», *кирмән* «шәһәр», «крепость», *ил* «авыл», *йорт* «авыл» һ.б. ойконимик терминнарның төрки чыгышлы булуларын күрсәтә.

Галимнәр фикеренчә, шәһәр мәгънәсен белдергән *кермен* сүзе көнбатыш ареалга хас була. Көнчыгышта борынгы төрки чордан ук билгеле *baluq, baliy, baliq* сүзе, ә үзәк районнардан көнбатышка кадәр сузылган территорияләрдә бүгенге көндә дә *корган* «крепость» сүзе кулланыла. (Сравнительно-историческая грамматика..., 2006: 438-454).

Түбәндә 1) «шәһәр», «крепость», «ныгытма»; 2) «авыл», «крепость», «ныгытма»; 3) «йорт», «торак» мәгънәләрендә кулланылышта йөргән ойконимик терминнарга һәм аларга нигезләнеп барлыкка килгән авыл исемнәренә анализ ясала һәм ойконимик терминнарның, авыл исемнәренең орфографиясе, транслитерациясе бирелә.

1. «Шәһәр», «крепость», «ныгытма» мәгънәсендә йөри торган ойконимик терминнар һәм алардан ясалган ойконимнар. Әлеге төркемгә *балык, тура, кирмән, кар, чеп/чип/чит, бура, кала, кенд* ойконимик терминнары керә.

Борынгы төрки телдә *балык* сүзе ике мәгънәгә ия омонимик сүз булган: «шәһәр» һәм «балык» (су җәнлеге) төшенчәләрен белдергән.

В.В. Бартольд *балык* сүзенең ике мәгънәсе дә бик борынгы төрки сүзләр булуын искәртә (Бартольд, 2002: 494). Э.В. Севортян *балык* сүзенең борынгы төрки телдә тагын «стена», «стена белән әйләндереп алынган шәһәр»; «крепость»; «балык» мәгънәләрендә йөрүен күрсәтә. Ул С.Е. Малов фикерен куәтләп, генезисы *бал* «балчык» тамырына кайтып кала дигән карашны алга сөрә (Севортян, 1978: 59–60).

Төньюкукка багышлап язылган борынгы төрки язма истәлектә *балык* сүзе «шәһәр» мәгънәсендә теркәлгән: *Santun balyg(g)a, talut uguzka, uc otuz balyg sydy. Usyn buntatu jurtda jatu galur arti* («Мин (гаскәрне) Шантунг шәһәренә һәм елгага кадәр алып бардым. Алар егерме өч шәһәрне җимерделәр һәм Усынбундат җирендә яшәп калдылар») (Малов, 1951: 62 (19)).

Э.М. Мурзаев сүзлегендә *балык* сүзе монгол телендәге *балгас* «шәһәр», тунгус-маньчжур телләрендәге *балаган* «торак», «шалаш», «йорт» сүзләре белән чагыштырыла (Малов, 1951: 62). Нәтиҗәдә, славян һәм төрки телләр белгече И.Г. Добродомов Себердә яшәүче руслар теленә *балаган* сүзе XVII йөз ахыры XVIII йөз башларында тунгус-маньчжур телләреннән алынган дип саный.

*Балык* «шәһәр» ойконимик термины, нигездә, тарихи топонимнарда сакланып калган. Уйгырлар үз шәһәрләрен *Besbalyg* «биш шәһәр», *Jengi Balyg* «яңа шәһәр» дип йөрткәннәр (Махпиров, 1990: 78). *Симезбалык, Арукбалык* – Төркестандагы борынгы шәһәрләр. *Бешбалык* орхон язмаларында теркәлгән. Пекин шәһәрен борынгы төркиләр *Ханбалык* дип атап йөрткәннәр.

Казан ханлыгы чорында Җөри юлы Тәмте елгасы буенда *Балыклы* авылы булуы билгеле. *«А от березы дорогою, что ездят из Балыклей деревни в деревню Кокчю»* (Писцовая книга, 1978, л. 99). *Балыклы* ойконимы «шәһәр», «крепость» мәгънәсен белдерә.

Татарстанның *Балык Бистәсе* районы исеме «шәһәр бистәсе» дигән мәгънәне белдерә, ягъни бу атамада шәһәр читләрен атау өчен кулланыла торган *бистә* термины урын алган. (Саттаров, 1998: 144). Татарстанның Кукмара һәм Теләче районнарында *Балыклы* дигән авыллар бар.

Идел-Кама болгарлары телендә «шәһәр, крепость, кальга» төшенчәсен белдерү өчен *кирмән* ойконимик термины кулланылган.

Урта гасырларда төрки халыклар Киев шәһәрен *Манкирмән* дип атап йөрткәннәр Болгарча, чувашча *ман*: 1) зур, олы; 2) бөек + болгарча *кирмән* «шәһәр, крепость». *Манкирмән* атамасы «бөек шәһәр» мәгънәсенә ия.

Идел–Кама Болгар дәүләтендә XIII йөздә барлыкка килгән шәһәрләр арасында *Кирмән (Кирмәнчек)* исемле шәһәр булган. Җөри юлында *Кирмән* авылы Казан ханлыгы чорында да торак пункт буларак яшәвен дәвам иткән. Тау ягында *Кермели* (Кирмәнле) исемле авыл булган. Элекке Лаеш өязенә (хәзерге Питрәч

районына) караган *Таукирмән* авылының Казан ханлыгы чорында булуы билгеле. Бу авыл *Ханкирмән* исемен дә йөрткән. Нугай юлында *Ташкирмән* исемле авыл булган (Чернышев, 2014: 292). Мамадыш районында *Кече Кирмән, Урта Кирмән* дигән татар авыллары һәм *Рус Кирмәне* авылы бар. Шушы авыллар яныннан агып уза торган елгачык *Кирмән* исемен йөртә.

*Кирмән* ойконимик термины Казан арты җирлегендәге берничә авыл атамасы составында урын ала һәм бу торак пунктларның байтагы болгарлар тарафыннан нигезләнүе турында ерак гасырлар аша хәбәр итеlә. Болгар кабер ташы язмалары һәм топонимик атамалар уртаклыгы борынгы заманнарда безнең территориядә яшәгән болгарларның телен, тарихын, этногенезын һәм аларның Казан татарларына нисбәтен ачыклауда зур әһәмияткә ия булып торалар. Казан арты җирлегендә 13 торак пунктта XIII–XIV йөзләргә караган болгар кабер ташы язмалары табылган. Аларның күбесе II стильгә карый, ягъни текстлары борынгы болгар телендә язылганнар. Һ.В. Йосыпов Мамадыш районы Татар Кирмәне авылы янындагы Кирмән шәһәрлегенең Ханнар зиратында 14 ташның борынгы болгар телендә язылуын хәбәр итә (Юсупов, 1960: 36). Болар арасында 1336, 1337–1338, 1352 елларга карый торган кабер ташлары бар.

В.В. Радлов сүзлегендә *кирмән* сүзе чуваш телендә *карман*, татар телендә *кирмән*, мари телендә *карман* «крепость» мәгънәсендә теркәлгән. Н.И. Ашмарин кыпчак телендәге *кармэн* «крепость» сүзеннән чувашлардагы *Карман, Кармантай* «крепость», «крепостьтай» мәҗүси исемнәре барлыкка килгән дип белдерә (Ашмарин, 1902: 108).

Кырым атамалары составында *кирмән* ойконимик термины булган: *Керменчек, Алма-Кермен, Бей-Кермен, Инкермен, Менгермен* дигән авыллар һәм *Керменчик* (Симферополь), *Эски-Кермен* кебек борынгы крепостьлар бар (Бушаков, 1985: 34). Төньяк Кавказда *Керман*, Болгариядә *Кермен,* Иранда *Кермен* һәм *Керманшаһ* дигән шәһәрләрнең булуы билгеле (Мурзаев, 1984: 302). Карачай-балкарларда Керман «крепость», осетиннарда Кермен-Чермен «крепость»исемнәре кулланылышта йөри (Справочник личных имен, 1979: 106, 688–689; Абаев, 1958: 593).

*Кирмән* ойконимик терминының мәгънәсе В.А. Бушаков, Ф.Г. Гарипова, Э.М. Мурзаев, Г.Ф. Саттаров, А.Ю. Филькова, Г.К. Һадиева хезмәтләрендә тикшерелә.

Ойконимик терминнарның кайберләре авыллар юкка чыккач, шушы төбәкнең халкы телендә җирле географик атама булып сакланып калганнар. Казан ханлыгы чорында Арча юлы Иске Казан шәһәре янында *Чепасна* дигән авыл булган. Бу авыл руслар тарафыннан җимерелгән һәм исәп кенәгәләрендә «бушлык» («пустошь») дип теркәлгән. Борынгы төрки сүзлектә *cit* сүзе «забор, стена» мәгънәсен белдерә. Кыргыз телендә *cit* «ныгытма», «саклану урыны», «качу урыны» мәгънәләренә ия (Русско-киргизский словарь, 1957: 891). Г.К. Һадиева карашынча, атама ике топокомпоненттан тора: *чеп/чип-чит* «ныгытма» + *пас/баш* «тау башын белдерә торган географик термин», ягъни «тау башындагы ныгытма». Төрки халыклар крепость һәм ныгытмаларын тау башына салганнар. Авылның урыны биеклектә урнашкан, җирле халык бу урынны *Җеп басма* дип йөртә (Хадиева, 2004: 81). Таулы Алтайда *Чеп-Туу* «ныгытмалы биек тау» топонимы бар (Молчанова, 1979: 338).

Топонимиядә төрки чыгышлы *тура* сүзе сакланган. Татарстанның Биектау районында *Иске Тура*, Яшел Үзән районында *Яңа Тура* дигән рус авыллары бар. Бу ойконимнарның асылында борынгы төрки *тура/тора* «ныгытма, крепость, шәһәр» ойконимик термины ята.

Борынгы төрки телдә *tura* «ныгытмалы торак», «крепость» мәгънәсен белдергән (ДТС, 1969: 587). Л.З. Будагов сүзлегендә *тура* «шәһәр» дигән мәгънәдә теркәлгән (Будагов, 1869: 387). Э.М. Мурзаев *тура* сүзенең түбәндәге мәгънәләрен күрсәтә: «шәһәр», «торак»; монгол телендә *тура* «крепость», «шәһәрчек»; бурят телендә «йорт», «бина», «шәһәр» (Мурзаев, 1984: 566).

О.Т. Молчанова Таулы Алтай топонимиясен тикшереп, *тура* терминының төрки телләрдәге кулланылышын чагыштыра: алтай телендә *тура* – «тукталу урыны», «торлак», «йорт», «ызба»; тува телендә *туруг* – «текә яр», «кыя»; якут телендә *туруүг таас хайа* – «отвесная скала»; борынгы төрки телдә *turug* – «таулардагы качу урыны»; башкорт телендә *торагъ* – «тукталу урыны»; *торлаг* – «торак»; кыргыз телендә *турак* – «яшәү урыны»; татар телендә *торак* – «торак», «фатир»; хакас телендә *тура* – «йорт», «ызба», иске хакас телендә – «шәһәр» (Молчанова, 1979: 100–101). Димәк, *тора* сүзенең генезисы гомумтөрки *тор~тору* «бер урында тору, яшәү; тормыш итү» тамырына барып тоташа.

Телебездә *тор* тамырыннан *торак, торлак, тормыш, торгызу* һ.б. сүзләр барлыкка килгән.

Татар теленең көнбатыш диалекты тобол сөйләшендә *тора* сүзе әле дә «шәһәр» мәгънәсен белдерә (Тумашева, 1992: 213).

Татарлар элек Төмән шәһәрен *Чимги-Тура*, алтайлар Бийск шәһәрен *Дьаш-Тура* дип йөрткәннәр, ә Таулы Алтай шәһәре *Ойрот-Тура* дип аталган була. Иске башкорт телендә *тура ~ тора* сүзе «крепость, шәһәрчек» мәгънәсен белдергән. Шуннан *Торатау// Тыратау* тавы исеме барлыкка килгән. 1574 елда нигезләнгән Уфа каласы башта *Туратау* һәм *Имән-кала* дип аталган. Казан ханлыгы чорында Алат юлында *Тура, Иске Тура* дигән авылларның булуы мәгълүм. *Тура* терминыннан ясалган географик атамалар Урал, Урта һәм Көнбатыш Себер территорияләрендә киң таралыш алган.

*Кар* топокомпоненты «шәһәр», «крепость», «авыл» мәгънәсенә ия атама *Шупашкар, Моркар, Муркар, Сыктывкар, Изкар, Кудымкар, Шурымкар* һ.б. көнчыгыш фин-угор халыклары шәһәр һәм авыллары атамалары составында урын ала.

Арча районындагы *Кышкар* авылы атамасы составында *кар* «шәһәр», «крепость» топокомпоненты урын ала, ягъни «кыш чыга торган торак пункт, шәһәр яки авыл» мәгънәсен белдерә. Алат юлындагы Кышкар авылының Казан ханлыгы чорында булуы тарихи чыганаклар буенча мәгълүм. *Кар* сүзенең килеп чыгышы турында төрле фикерләр бар. Г.Е. Корнилов, Б.А. Серебренников, Т.И. Тепляшина – төрки чыгышлы дип, ә Ф.И. Гордеев, В.Г. Егоров, Э.М. Мурзаев, Г.Ф. Саттаров, А.Ю. Филькова борынгы иран телләреннән килә дип саныйлар.

Татарстанның Зәй районында *Бура киртә* дигән татар, *Бура-Сарай* исемле рус, Азнакай районында *Буралы* дигән татар авылы бар. Г.Ф. Саттаров әлеге авыл атамалары составында урын алган *бура* ойконимик терминның нигезендә, хәзерге татар телендәге «өй, мунча һ.б. салу өчен бүрәнәдән дүрт почмаклы эшләнгән корылма» мәгънәсенә ия булмыйча, борынгы иран телләреннән үк килә торган *vara* «киртә»; «цитадель, кешеләр яши торган крепость, кальга» төшенчәсе ятуын билгели (Саттаров, 1998, 151). Шулай булганда, Татарстандагы әлеге авыллар иран телле борынгы скиф-сарматларга нисбәтле булып, беренчесенең атамасы – «крепость-киртә», икенчесенең – «крепость-сарай», өченчесенең – «крепость» мәгънәсен белдерә.

Топонимик әдәбиятка мөрәҗәгать итсәк, *кала* термины «нығытма; нығытылган урын, замок, шәһәр, авыл» мәгънәләренә ия. Әлеге лексик берәмлек Европа, Азия, Африка территорияләрендә киң таралыш тапкан. Галимнәр фикеренчә, *кала* термины бик борынгы чыгышка ия. Мәсәлән, А.З. Розенфальд карашынча, сүз чыгышы буенча, иран теленнән гарәп теленә кереп, гарәпләшкән формада кире фарсы һәм таҗик телләренә әйләнеп кайткан *калот* сүзенә барып тоташа (Розенфальд, 1951: 29).

Гарәп телендәге *кальга* «курган, крепость, нығытма, замок» ойконимик термины татар теленә, *кала* әйтелеше алып, «шәһәр» мәгънәсендә кабул ителгән. Хәзерге татар, казак (*кала*), чуваш (*хула*), мари (*ола*) телләрендә *кала* сүзе телдә нык урнашкан хәлдә «шәһәр» мәгънәсен белдереп килә.

Телләрнең бер-берсенә тәэсир итү күренеше буенча Х. Мамай шактый кызыклы мәгълүматлар китерә. Галим алан һәм каталон телләрендә *кала* сүзе кергән топонимнар арасына параллельләр үткәрә. Дәлил буларак, автор Пиреней ярымутравы топонимиясе эчендә каралган *кала* термины белән ясалган 17 атама тәкъдим итә. Аның карашынча, *кала* термины кайбер роман телләренә нәкъ менә төрки телләрдән үтеп кергән. Әлеге территориядә топонимнар составында кулланылган *кала* термины «порт» мәгънәсендә килә (Мамай, 2004: 60).

Татарстанның Саба районындагы *Калатау* авылы 1920 елларда нигезләнгән. Казан артындагы бер җыен бәйрәме *Калатау җыены* исемен йөрткән. Яңа Чишмә районының үзәге *Яңа Чишмә* авылын элек татарлар *Яңа Кала* дип атаганнар.

1925 елда Урта Азиянең Сәмәрканд шәһәре атамасына мөнәсәбәтле Әлмәт районында *Сәмәрканд* поселогы барлыкка килә. Аңа Кичүчат авылы кешеләре нигез сала. 1926 елда авылның халык саны – 92, 1938 елда – 121, 1949 елда – 121, 1958 елда – 64, 1970 елда – 39, 1979 елда – 36, 1989 елда – 7 кеше, ә 2002 елдан рәсми рәвештә яшәүчеләр калмый.

Борынгы төрки телдә *kand* «шәһәр» мәгънәсен белдергән, төркиләргә согдий теленнән кергән. *Кенд/кенд* термины Урта Азия, Казакстан, Кавказ, Синьцзян территорияләрендә киң таралган.

2. «Авыл», «крепость», «нығытма» мәгънәсендә йөри торган ойконимик терминнар һәм алардан ясалган ойконимнар. Бу төркемгә *ил, йорт, сала* керә.

Татарстанда исемнәре составында *иле* ойконимик термины булган авыллар шактый киң таралган: *Мулла Иле* (Яшел Үзән районы), *Чүриле* (Арча районы), *Кибәк иле* (Питрәч районы), *Янил* (Кукмара районы), *Чуваш Иле* (Биектау районы), *Кариле* (Балтач районы), *Кодаш Иле* (Питрәч районы) һ.б.

Борынгы төрки телдә ил «кабиләләр союзы», «кабиләләр берләшмәсе», «халык», «дәүләт» мәгънәләрендә кулланылган (ДТС, 1969: 168–169). Э.В. Севортян сүзлегендә *ил* сүзе «халык», «кабиләләр союзы», «ят кеше»; «дәүләт» (кыргыз, татар телләрендә); «авыл», (комык, карачай-балкар, чуваш); «ил» (казак, ногай, каракалпак, татар, башкорт, үзбәк); «хакимлек», «оҗмах», «гаскәр» мәгънәре бирелгән (Севортян, 1974: 340–342).

Кадыйр Гали бәк «Җәмигъ-әт-тәварих» (1602) дигән тарихи язмасында Казан ханлыгы чоры авыл исемнәрен «авыл» мәгънәсендә *ил* сүзе белән күрсәтә: *Солтан иле, Уймас иле, Кәче иле, Сәрдә иле, Чыпчык иле, Шабша иле, Вәнтә иле, Нурма иле, Шәехзадә иле, Карадәүләт иле, Хәерби иле, Тимерче иле* (Борынгы татар әдәбияты, 1963: 477). Татар телендә *авыл* сүзе соңрак активлашкан булырга тиеш, чөнки тарихи язмаларда һәм Казан ханлыгы чорындагы авыл атамалары составында бу ойконимик термин күзәтелми. *Ил* ойконимик термины «авыл» мәгънәсендә татар теленең урта һәм көнбатыш диалектында сакланып калган.

Татарстан ойконимнары составында *авыл* термины шактый урын ала: *Яңа авыл, Варклад авыл* (Әгерҗе районы), *Иске авыл* (Октябрь районы татар авылы, Әлки районы рус авылы), *Яңавыл* (Актаныш, Биектау, Буа районнары), *Югары авыл, Түбән авыл* (Мамадыш, Кукмара районнары). Пермь крае Барда районында авыл ойконимик термины кушылып ясалган татар авыллары атамасы дистәгә якын: *Байавыл, Бакчаавыл, Каенавыл, Тауавыл, Түбәнавыл, Ямантайавыл, Әрәмәавыл* һ.б.

Борынгы төрки телдә *агыл* сүзе «терлекләр өчен киртә абзар» мәгънәсен белдергән (ДТС, 1969: 18). Гомумтөрки *агыл, айыл, аwыл* «авыл» ойконимик терминының борынгы *агыл* «терлекләрне яисә аулап тотылган хайваннарны беркадәр вакыт ябып асрау өчен ясалган киртә, ихата, кура» сүзеннән ясалган булуы мәгълүм.

Башкорт ономасты Ф.Г. Хисамитдинова башкорт авыл атамаларын өйрәнгәннән соң, түбәндәге нәтиҗәгә килә: әлеге лексик берәмлек терлек асрау белән шөгыльләнүче күчмә халык яшәгән

урын атамаларына нигезләнеп барлыкка килә. Алга таба бу сүз ойконимик термин буларак кулланыла башлый (Хисамитдинова, 2017: 236).

Казак телендә *ауыл* терминының барлыкка килүен тикшеренүчеләр күп гасырлык традицияләргә корылган күчмә тормыш алып баруга һәм терлекчелек белән шөгыльләнүгә бәйләп карыйлар. Ойконимиядә әлеге термин мөстәкыйль кулланылышта очрамый диярлек. Ул бары тик кушма атамалар составында гына очрый. Бәйсезлек кабул иткәннән соң, әлеге терминның ойконимнар ясаудагы активлыгы арта. Шулай ук бу – республика тормышындагы милли кыйммәтләр, тел, тарих һәм мәдәнияткә булган карашларның үзгәрүенә китергән үзтәңгәлләштерү процессына, тарихи-җәмгыяви һәм мәдәни үзгәрешләргә дә бәйле (Прманова, 2011: 122).

Татарстанның Арча, Биектау, Кама Тамагы районнарында *Яңа Сала* дигән татар авыллары бар. Казан ханлыгы чорында Җөри юлында *Яңасала* авылы булган.

Топонимикада *сала* сүзенә ике төрле аңлатма бирелә: 1) татар теленә «авыл» мәгънәсенә ия булган *сала* сүзе борынгы рус телендәге *село* сүзеннән алынган; 2) гомумтөрки *салу* «кору» тамырыннан ясалган.

В.В. Радлов сүзлегендә *сала* сүзе рус телендәге «село» сүзеннән дип бирелә (Радлов, 1911: 349–350). М. Фасмер сүзлегендә сала «яши торган урын, йорт», «кыр, җир» борынгы славян теленә нисбәтле аңлатыла (Фасмер, 1987: 596).

Казан ханлыгы чоры язма истәлеге Сәхипгәрәй хан ярлыгында (1523) бу сүз *сала харҗы* «авыл салымы», Миңлегәрәй хан ярлыгында *Яңа сала*, Саадат-Гәрәй (1530) хан ярлыгында *Бога-Сала* рәвешле теркәлгән.

В.Г. Егоров фикеренчә, төрки *сала* сүзе хәзәрләрдән килеп кергән (Егоров, 1964: 176).

Географик атамаларда *йорт* ойконимик термины Идел буе, Казказ, Көньяк Урал, Көнбатыш Себер территорияләрендә таралыш алган. Төрки халыкларда *йорт* сүзе, борынгы заманнарда «күчеп йөри торган территория, тору урыны» төшенчәсен белдерү белән бергә, «ил, дәүләт» мәгънәсенә дә ия булган.

Борынгы төрки сүзлектә *jurt* сүзе «дом», «владение», «земля», «страна» мәгънәләре теркәлгән (ДТС, 1969: 282). Л.З. Будагов *йорт* сүзенең төрки телләрдәге «ил», «дәүләт», «яшәү урыны»,

«торлак», «стан», «лагерь», «халык» дигән мәгънәләрен күрсәтә (Будагов, 1871: 365).

А.Н. Кононов XIII йөздә Урта Азия һәм Иранда киң кулланылышта булган *jyrt* «ходить», «идти» сүзе *jyr-y-op-yjyry-jory* фигыленнән килеп чыккан дип саный. Шулай итеп, *jur-y + m* сүзенең беренчел мәгънәсе «йөрү», «күчеп йөрү», «күчеп йөрү урыны» булырга мөмкин (Кононов, 1958: 79).

Каюм Насыйри язмаларында иске татар телендә *йорт* сүзе «авыл, торак пункт» мәгънәсендә кулланылган: «Шырдан кыры элгәре Беловалга кырына тоташкан икән, дип сөйлиләр. Аннан соң, хәзер *Иске йорт* дип әйтәләр, Югары Шырдан кырында бер уйсу җир бар, шул җиргә ятып йоклап караганнар, аннан соң шул җиргә утырмакны мәслихәт күреп, шул алты кеше анда килеп утырганнар» (Насыйри, 1975: 14). Кайбер татар авылларының басу-кырында кайчандыр авыл булган урыннарны *иске йорт, йорт өсте* дип атау гадәте бар.

Татар әдәби телендә *йорт* ойконимик термины хәзер «авыл», «торак пункт» мәгънәсендә кулланылмый, ә «өй», «торак» төшенчәсен белдерә.

Казан ханлыгы чорында Җөри юлында *Иске Йорт* (бушлык, «пустошь») һәм *Иске Йорт* дигән авыллар булган (Чернышев, 2014: 286). Татарстанның Арча, Питрәч, Кукмара районнарында *Иске Йорт* дигән авыллар бар.

3. «Йорт», «торак» мәгънәсендә йөри торган ойконимик терминнар һәм алардан ясалган ойконимнар. Әлеге төркемгә *өй, гел/гил/кил, ката/кәтә* ойконимик терминнары керә.

Борынгы төрки телдә *ev* «торак» дигән мәгънә белдергән (ДТС, 1969: 162).

А.Н. Кононов төрки телләрнең тарихи фонетикасы нигезендә *oj – oj; yj – yj* < *об – ов* > *аб – ав* «өй»; чаг.: *суб – сув – суz – су (j) – су* мәгънәсеннән килеп чыккан, *об-ов* тамыры *оба* «юрта», «гаилә», «күчеп йөрү урыны» сүзләре белән тәңгәл килә, ди (Кононов, 1958: 79).

Төрки телләрдә «йорт», «торак» мәгънәсендә түбәндәге сүзләр кулланылышта йөри: *ev* (төрек, азәрбайҗан), *üj/öj* (төрек, комык, карачай-балкар, татар, башкорт, ногай, казак, каракалпак, кыргыз, үзбәк, уйгыр), *tam* (казак, кыргыз, каракалпак), *jurt/jort* (татар, башкорт, ногай), *žaj/ʒāj* (казак, каракалпак, төрекмән), *otaw/otag*

(казак, кыргхых, азәрбайҗан, төрекмән, ногай), *kijiz üj* (казак), *qara üj (*каракалпак, үзбәк, уйгыр, төрекмән), *alačyg* (татар, кыргыз, төрек, азәрбайҗан, комык), *qos (*каракалпак, кыргыз, казак, ногай, карачай-балкар, комык), *lašyg* (казак), *satyr (*татар, башкорт, казак, каракалпак, кыргыз), *terme* (ногай, комык) һ.б. (Сравнительно-историческая грамматика..., 2006: 461–466).

Татарстанда *өй* ойконимик терминына нигезләнеп, Арча районындагы *Өчиле*, Буа районындагы *Дүртөйле* авылларының исемнәре ясалган.

Татарстанның Лаеш районында *Сингел* дигән татар авылы урнашкан. Бу авылның Казан ханлыгы чорында булуы тарихи чыганаклар буенча билгеле (Чернышев, 2014: 291).

Чуваш галиме В.Г. Егоров, чуваш телендәге *кил* «йорт, өй» сүзенең хазарларның *Саркел* шәһәре исемендә саклаган, ди. Византия императоры Константин Багрянородныйның аны грек теленә «ак йорт» дип тәрҗемә итүен әйтә (Егоров, 1964: 112). Г.Ф. Саттаров чуваш галиме В.Г. Егоров фикерен куәтләп, *Сингел* авылы атамасында хазар реликты сакланган дигән караштa тора. Хазар, болгар, чуваш телләрендәге *çин ~ çене* – «яңа» + хазар-болгар, чуваш телләрендәге *гел ~ кел ~ кил* – «йорт», «өй» компонентларыннан гыйбарәт кушма төзелеш тәшкил итә һәм «яңа йорт, өй» дигән мәгънә белдерә (Саттаров, 1992: 142).

Әтнә районындагы *Өшкәтә* авылы Казан ханлыгы чорында булган.

*Ката/кәтә* термины Э.М. Мурзаев тарафыннан өйрәнелгән. Ул, А.И. Соболевский, Ф.Е. Корш, К. Риттер, В.И. Абаев, С.П. Толстой хезмәтләренә нигезләнеп, төрле тел төркемнәрендә (һинд-Европа, фин-угор, төрки, монгол) «торак», «йорт», «поселок», «шәһәр», «крепость», «сарай» мәгънәләрен белдергән терминнарны барлаган. Һинд-Европа: һинд *êanthf* «шәһәр стенасы», әфган *êandai* «шәһәр кварталы», *kedai* – «авыл», уйгыр *êant* «шәһәрчек», «поселок»; согди *êad, kand, knt, kt* «шәһәр»; фин-угор телләрендә: ханты *õot, xat*, венгр *haz*, фин *õota*, мордва *kud* «алачык»; төрки телләрдә: якут *хотон* «лев» (Мурзаев, 1984: 263–264).

Кушма төзелешле *Өшкәтә өш ~ өч + ката/кәтә* «ныгытма», «торак» компонентларыннан тора.

Шулай итеп, торак һәм яшәү урыннарының төрләре һәрдаим хәрәкәттә булып, халыкның төрле үсеш этаплары кичергән матди

һәм рухи кыйммәтләре кисешкән мөһим компонентларның берсе санала. Шунлыктан алда санап үтелгән терминнарны үз эченә алган торак пункт атамаларын без татар теленең лингвомәдәни феномены буларак карыйбыз. Бу очракта атамаларның халык тарихы, аның иҗтимагый-икътисади тормышы һәм этносның җәмгыяви оештырылу формасы да исәпкә алына.

Татар теле тарихында «шәһәр», «авыл», «йорт» төшенчәсен белдерүче ойконимик терминнар шактый күп була һәм алар, тарихның билгеле бер чорында кулланылышта йөреп, аерым тарихи-лингвистик сәбәпләр белән бәйләнешле рәвештә, бер-берсен эзлекле алмаштырганнар. Анализдан күренгәнчә, алар безнең регионның ойконимик берәмлекләре составында урын алып, бүгенге көнгә кадәр сакланып калганнар.

«Шәһәр», «ныгытма», «авыл», «яшәү урыны; торак урын» төшенчәләрен белдерү өчен кулланылган ойконимик терминнарны өйрәнү ойконимик модельләр, аларның структур төзелеше, терминнарның атамадагы урыны турында төгәл күзаллау булдырырга, төрки телләрнең үзара бәйләнешенә дәлил булырлык якын форма һәм археотипларны табарга, татар теленең бай лексикасын күз алдына китерергә, Татарстандагы авыл, шәһәр тибындагы бистә һәм шәһәрләрнең барлыкка килүен һәм үсешен тарихта чагылдырырга мөмкинлек бирә. Хәзерге татар телендә аерым бер төркем терминнар кулланылыштан төшеп калганнар, бер төркемнәре үзләренең беренчел мәгънәләрен югалтканнар, икенче бер төркем шул беренчел мәгънәсендә кулланылуларын дәвам итәләр.

Авыл атамалары составында кулланылышта йөргән оконимик терминнарны тикшерү татар халкының тарихын һәм этногенезын, туган телнең тарихи лексикологик үзенчәлекләрен һәм үсешен өйрәнүдә үзеннән зур фәнни өлеш кертә.

Соңгы елларда татар басма матбугаты битләрендә ойконимнарның дөрес язылышына, транслитерациясенә һәм тәрҗемәсенә аеруча зур игътибар бирелә башлады. Г. Саттаров, Ф. Гарипова, В. Имамов, Р. Мусабәкова, Г. Хаҗиева-Демирбаш, З. Вәлиәхмәтова, Р. Гыйлемханов һ.б.ның татар вакытлы матбугатында һәм фәнни җыентыкларда әлеге мәсьәләгә багышланган мәкаләләре басылып чыкты.

*Норлат – Нурлат, Корайван – Кер Хайван, Күн – Конь* кебек ойконимнар газета-журналларда барган дискуссияләрнең үзәгендә

торалар. Фикер төрлелеге еш кына ойконимнарның структур яктан дөрес аңлатылмавына кайтып кала. Татар телендәге атамаларны русча тәкъдим итү өчен уртак орфографиянең булмавы, рәсми белешмәлекләрнең, еш кына, дөрес җавап бирә алмавы, шулай ук, фикри каршылыкка китерергә мөмкин. Мәсәлән, «Населенные пункты Республики Татарстан» (1997) белешмә китабында Питрәч районы составына кергән *Күн* (төрки-татар *күн/һун* этноним) авыл атамасының рус варианты, транскрипциядә бирелергә тиеш булуга карамастан, рус теленә *Конь* «лошадь» дип тәрҗемә ителгән. Гарәп телендәге *нор/нур* «луч» һәм «дәүләт» тамырыннан ясалган *Норлат (Нурлат)* шәһәре атамасында да «ат» (*нурлы + ат*) мәгънәсе сиземләнә. Татар телендәге *яман* «дурной» һәм болгар компоненты *ширмә* «овраг» сүзләре кушылу нәтиҗәсендә барлыкка килгән *Ямаширмә* (Биектау районы) атамасы XX гасыр ахырларында *Яңаширмә* (татар телендә *яңа* + болгар телендә *ширмә* «елга») буларак тәкъдим ителде һәм рәсми документларда *Яңаширмә* дип теркәлде. Бүгенге көндә атама үзенең элекке тарихи әйтелешенә кайтты.

XVI гасырда патша хөкүмәтенең чит җирләрне басып алу сәясәте нәтиҗәсендә Казан ханлыгы дәүләт буларак яшәүдән туктый. Патша хөкүмәте татар җирләрен барлау максатыннан рус язу кенәгәләре булдыра. Әлеге язу кенәгәләренә авыл исемнәре дә теркәлә һәм татарлар яшәгән торак пунктларның атамалары рус исемнәре белән алмаштырыла башлый. Рус язу кенәгәләре буенча Казан ханлыгы чорының 700 авыл атамасы билгеле (Писцовая книга, 1978; Писцовая книга, 2001; Перечневая книга, 2004; Писцовое описание, 2006; Чернышев, 2014: 282–300). Руслар күп гасырлар дәвамында сакланып килгән татар авыл атамаларын рус теленең фонетикасына, сүз ясалыш законнарына яраклаштырып, төзелеш ягыннан зур үзгәрешләргә дучар итеп язалар. Үзгәртелгән атамалар акрынлап рәсми документларга, карталарга теркәлә бара.

Бүгенге көндә татар авыллары исемнәренең рус вариантлары катлаулы күренеш тәшкил итә. Хәтта бертөрле яңгырашлы татар авылы исемнәре язылышында да вариантлылык еш күзәтелә. Түбәндә «Населенные пункты Республики Татарстан» (1997) белешмә сүзлегендә бирелгән ойконимик терминнарның һәм татар авылы атамаларының татар, рус телендәге язылышларына тукталабыз.

Бер үк яңгыраштагы атамалар белешмәнең төрле битләрендә төрлечә язылганнар. Белешмәдә система, бертөрлелек юк.

Ойконимик терминнарның татарча язылышы һәм транслитерациясенә күзәтү ясыйк. *Авыл* ойконимик термины: Әгерҗе районында *Вәркләд **Авыл***, Буа районында *Яң**авыл***; *иле* ойконимик термины: Әлки районында *Татар Мулла **Иле***, шул ук атама икенче төрле язылышта Яшел Үзән районындагы *Муллаиле* авылы, Арча районында *иле* компонентлы ***Өчиле**, Яңа Чү**риле*** авыллары, Чүпрәле районында *Каз**ыле*** авылы.

Ойконимик терминнарның транслитерациясе: *Вәркләд **Авыл** – Варклед **аул*** (Әгерҗе районы), *Яңа **Авыл** – Новая **Деревня*** (Зәй районы), *Пулат **Авылы** – Булатово* (Яшел Үзән районы), ***Яңавыл – Янга-Аул*** (Буа районы), *Яңа **Авыл*** (Биектау районы); *Татар **Мулла Иле** – Татарское **Муллино*** (Әлки районы) *Өч**иле** – Уч**иле*** (Арча районы), ***Муллаиле – Молвино*** (Яшел Үзән районы), *Яңа Чү**риле** – Новое Чу**рилино*** (Арча районы), *Чуваш **Иле** – Чуваш**ли*** (Биектау районы), *Каз**ыле** – Каз**ыли*** (Чүпрәле районы), ***Тау Иле** – **Тавель*** (Түбән Кама районы), ***Кибәк Иле** – **Кобяково*** (Питрәч районы); *Алга **Көек** – Алга-**Куюк*** (Арча районы), ***Көек*** (Балтач); *Иске **Йорт** – Иске **Юрт*** (Арча, Кукмара районы), *Кече **Йорт** – Малые **Юрты*** (Яшел Үзән районы).

Географик терминнарның язылышы: Балык Бистәсе районында ***Кызыл Яр***, Чирмешәндә ***Кызылъяр*** авылы, Мөслим районында бер үк биттә ике язылышлы ***Кызыл Яр*** һәм ***Кызылъяр*** авыллары. *Күл* һәм *тамак* терминнарын эченә алган атамалар да төрлечә язылган. Аксубай районында *Камышлы **Күл***, Буада *Ак**күл***, Мамадыш районында *Көмеш **Күл;*** Сарман районында *Бал**тамак***, Ютазыда *Бәйрәкә **Тамак***, Кукмарада *Саз-**Тамак*** һ.б.

Бер үк атама ике төрле вариантта языла: *Әгерҗе – Агрыз, Агерзе*; *Балтач – Балтаси, Балтачево* һ.б.

Татар авылы атамаларына рус теле өчен хас булган *-овск, -евск, -ов(а), -ов(о), -ева(а), -ев(о), -анск, -инск, -енск, -ин(а), -ин(о)* суффикслары өстәлә. Мәсәлән: *Аккүз – Аккузово, Ахун – Ахуново, Бурсык – Барсуково, Аксубай – Аксубаево, Бикмураз – Бикмуразово, Буа – Буинск, Ямбулат – Ембулатово, Туйкә – Тойкино, Адай – Адаево, Шәпке – Шапкино, Кәче – Качелино, Актүбә – Актюбинский, Чынык – Чинниково, Уразай – Уразаево, Чат – Чатово, Чураево – Чирү, Тыңламас –Тыннамасово,*

*Юныс – Юнусово, Черемыш – Черемышево, Биләр – Билярск, Менделеевск* һ.б.

Сүз ахырында *-ы, -и* авазлары өстәлү: *Пимәр – Пимери, Көек – Куюки, Кибәч – Кибячи, Янсуар – Янцевары, Ачы – Ачи* һ.б.

Авыл атамалары, нигездә, рус теленә тәрҗемә итеп бирелми. Белешмәдә рус теленә тулаем тәрҗемә ителгән авыл исемнәре шактый: *Балык Бистәсе – Рыбная Слобода, Актау – Белая Гора, Кара Чишмә – Черный Ключ, Ык Тамагы – Икское Устье, Салкын Чишмә – Студёный Ключ, Яңа Суыксу – Новый Студенец, Салкын Алан – Холодная Поляна, Якты Күл – Светлое Озеро, Кара Күл – Черное Озеро, Кәкре Күл – Кривоозерки, Кызыл Яр – Красный Берег, Салкын Алан – Холодная Поляна, Нарат – Сосново, Өч нарат – Три сосны, Борчаклы Яз – Гороховое поле, Дүрт Өйле – Четыре Двора, Ташчишмә – Каменный Ключ* һ.б.

Татар авыллары атамаларына русча яңа исемнәр бирелгән очраклар: *Киекле – Бурметьево, Чәти – Верхний Китяк, Түбән Әрнәш – Тёплое Болото, Яңа Авыл – Берёзовая Грива, Алан – Пробуждение, Хансөяр – Хансверкино, Комазан Башы – Крещеная Ерыкса, Чия башы – Никифорово, Яуширмә – Кутлушкино, Абыз – Мингличёво, Үгез Куагы – Быковка* һ.б.

Тезмә атаманың бер компоненты тәрҗемә ителгән очраклар: *Югары Казаклар – Верхний Казаклар,* Татар Тансары – Татарский Тансар, *Яңа Имән – Новый Имян, Югары Богады – Верхние Бугады, Кече Акташ – Малый Акташ, Югары Казаклар – Верхний Казаклар, Урманасты Шынталасы – Подлесная Шентала, Яңа Такталы – Новая Тахтала, Олы Елово – Большое Елово, Олы Армалы – Большие Армалы* һ.б..

Татар телендәге авыл исемнәрен рус теленә кайсыдыр бер авазын төшереп калдырып ике төрле язылган очраклар: *Яңа Кызыл Яр – Кзыл Яр*, *Кызыл Яр – Кызылъяр, Кызыл Утар – Кзыл Утар, Кызыл Сукачы – Кзыл-Сукаче, Бакырчы – Бакрче, Кырынды – Крынды, Кышкар – Кшкар.*

Рус сүзләре һәм кушымчалары белән бирелгән авыл исемнәре: *Мортыш – Муртыш-Тамак, Гобәй – Губайдуловка, Чишмә – Хороший Ключ, Берлек – Берлек-Михайловка.*

Гади һәм тезмә исемнәрне яңгырашына туры китереп русча биргән очраклар шактый күп: *Таш билге – Тяжбердино, Алаба Күл – Алабакул, Чыты – Чита, Кычытканлы – Кичкальня, Тау*

*Иле – Тавель, Олы Имән – Улиманово, Әндерәш – Андрюш, Кибәк Иле – Кобяково, Оет – Уют, Җикәнле Күл – Зиканни-Куль, Хуҗа – Хузеево, Күн – Конь, Кичке Таң – Кичкетан.*

Транслитерацияләнгән атамалар: *Шикәрле Каен – Шикарле Каен, Салкын Чишмә – Салкын Чишма, Бакчасарай – Бакча-Сарай, Тәмле Чишмә – Тямле-Чишма, Иске Мунча – Иске-Мунча,Алан Җөри – Алан-Зире, Чукри Олан – Чукри-Аланово, Матмыр – Махмур, Чура батыр – Черебатырово, Исләйтар – Ислейтар* һ.б.

Шулай итеп, хәзерге татар авыл исемнәрен рус теленә тәрҗемә итүдә һәм транслитерация ясауда төрлелек һәм атамаларның язылыш-әйтелеше чыганак телдән бик нык аерылуы, хәтта русча бирелгән атамаларда мәгънәгә нык зыян килүе күзәтелә. Авыл атамаларының рус вариантындагы язылышларын тәртипкә китерәсе бар. Бу өлкәдә фәнни оешмалар максатчан эш алып барырга тиешләр.

Татарстан Республикасы авыл атамаларының дөрес язылышын һәм әйтелешен эшләү ономастика фәненең көн тәртибендә тора. Белешмәдә принципсызлык, ягъни система булмау күзгә ташлана. Авыл атамаларының дөрес язылышын тәэмин итәргә, халыкчан формаларын кире кайтарырга кирәк.

## § 23. Татар ойконимнарының этнолингвистик катламнары

Этнолингвистик катлам аерым бер халыкның озак вакытлар дәвамында бер территориядә яшәү нәтиҗәсендә барлыкка килгән ойконимнар җыелмасы буларак аңлашыла. Шуңа нисбәтле, топонимик тикшеренүләрнең иң әһәмиятле бурычларының берсе – теге яки бу телгә караган атамаларның таралыш чикләрен билгеләү. Аларны өйрәнү теге яки бу халыкның тарихи үткәндәге күченүләрен күзәтергә, халык миграциясен билгеләргә ярдәм итә.

Тарих һәм археология мәгълүматларына караганда, Урта Идел буе территорияләре төрле кабилә һәм халыклар алышыну процессын кичерә. Шунлыктан Татарстан ойконимиясе төрле дәрәҗәдәге борынгылык һәм чыгышы ягыннан төрлелеккә ия этнолингвистик катламнардан торган катлаулы тарихи өлкә буларак карала.

Татар ойконимнарының этнолингвистик катламы шактый күптөрле һәм чуар, чөнки «татар халкы һәм теле формалашуда Идел болгарлары төп роль уйнаса да, алар составына шулай ук

төрки телле печенеглар, кыпчаклар, мишәрләр, татар-монгол яулары белән килгән төркиләр, аз булса да монгол телле монголлар, угро-финнар һәм хәтта славяннар да төрлесе төрле дәрәҗәдә катнашканнар» (Зәкиев, 1977: 188). Әлеге халыклар гасырлар дәвамында бер-берсе белән төрле мөнәсәбәтләргә кереп, кайбер милли һәм телгә караган казанышларны уртаклашып яшәгәннәр, кайберләре үзара ассимиляцияләшкәннәр.

Татарстан ойконимиясе билгеле бер лингвистик һәм экстралингвистик факторлар тәэсире нәтиҗәсендә формалаша. Аерым бер катламга караган ойконимнар билгеле бер вакытта барлыкка килмәгәннәр. Тарих һәм башка фәннәр күрсәтүенчә, Татарстан территориясенә берничә гасыр дәвамында төрки телле кабилә һәм халыкларның килеп урнашуы билгеле. В.А. Никонов бу күренешкә мондый бәя бирә: «Фарсы телле топонимнар гасырлар дәвамында барлыкка киләләр, аларны уртак бер катлам буларак күз алдына китерү мөмкин түгел. Төрки дулкыннар да еш була. Беренчеләре дә, икенчеләре дә бер-берсе белән керешеп китмиләр» (Никонов, 1975: 104).

Г.Ф. Саттаров фикеренчә, топонимик чувашизмнар, башкортизмнар һ.б. топоизмнар теге яки бу халык белән күп гасырлар дәвамында күрше булып яшәү, аралашу җирлегендә генә барлыкка килмәгәннәр. Алар кайчандыр безнең регионда яки аның аерым төбәкләрендә теге яки бу кабилә-ыругның, халыкның яшәве, гомер итүләре җирлегендә туганнар. Әлеге кабиләләр, халыклар хәзерге Татарстан территориясендә яшәгән заманнарда төбәктәге географик объектларның байтагын үз телләренең атамалары белән атаганнар. Урта Идел–Кама территориясендә халык формалашу процессында татарлар бу җирлектә яшәгән кардәш һәм кардәш булмаган кабиләләрне үз этносларына катнаштырганнар, аларны акрынлап ассимиляцияләгәннәр. Татар халкы этносына катнашкан әлеге кабиләләрнең телләре белән мөнәсәбәтле географик атамалар, татарларның топонимиясенә кабул ителгән хәлдә, безнең көннәргәчә килеп җиткәннәр (Саттаров, 1973: 158–159). Шулай итеп, төрле кабилә һәм халыкларның гасырларга сузылган бер-берсенә тәэсире нәтиҗәсендә, чыгышы белән төрле башлангычларга караган татар ойконимиясе туплана. Татарстан территориянең этник тарихы турында бәян иткән мәгълүматларга нигезләнеп һәм лингвистик, этимологик анализлар ярдәме белән түбәндәге

этнолингвистик катламнар аерып чыгарыла: 1) фин-угор катламы; 2) иран катламы; 3) төрки катлам; 4) гарәби һәм фарсы телләренә нисбәтле ойконимнар; 5) монгол катламы.

Түбәндә кайсы этнолингвистик катламга керүләренә карап, ойконимнар системалаштырып бирелә.

Фин-угор катламы.

Идел буе территорияләре – фин-угор кабиләләренең беренче торган җирләре, тарихи ватаннары булып тора. Шуңа бәйле татар ойконимиясен формалаштыруда фин-угор кабиләләренең эзләре күзәтелә.

III–IV гасырларда фин-угор кабиләләре белән шактый дәрәҗәдә аралашкан беренче борынгы төрки кабиләләр Кама буйларының кайбер районнарында урнашып калалар һәм, өлешчә, Иделгә үтеп керәләр. Җирле халык мәдәниятендә борынгы төрки кабиләләр мәдәниятенә хас билгеләрнең килеп чыгуы шушы вакытка туры килә. VII гасыр азагы – VIII гасырда Урта Идел территориясенә төрки телле болгарлар көньяктан, Азов буе һәм Дон далаларыннан килеп утыралар һәм җирле кабиләләр белән күп төрле бәйләнешкә керәләр (Татарстан АССР тарихы, 1970: 35, 37).

Татар ойконимиясенең фин-угор телләренә нигезләнеп ясалган атамалары удмурт, мари, мордва телләренә нисбәтле барлыкка килгәннәр.

Удмуртларның *Варзи, Омга, Турья* «көртлек», «торна», *Бобья, Чабья* «бодай», *Чепья, Дурга* «кырый баз», *Курья* «култык», *Уча* «сандугач», *Кибья* «коңгыз» һ.б. кебек борынгы воршудлар кушамат-исемнәренә нигезләнеп Татарстанның Кама арьягы, Казан арты җирлегендә байтак кына татар авылларының атамалары барлыкка килгәннәр (Саттаров, 1973: 178). Мәсәлән: *Чәбия Чурчи* (Саба районы), *Яңа Чәбия* (Кукмара районы), *Иске Чәбия* (Мамадыш районы) *чабей-йа* «бодай»; *Көтек* (Арча районы), *Югары Көтек* (Кукмара районы) *кеттек* «челән»; *Түбән Оча, Яңа Оча* (Мамадыш районы), *Усы* (Актаныш районы) *уча* «сандугач» + *лы; Олы Кибәхуҗа, Югары Кибәхуҗа, Кече Кибәхуҗа* (Теләче районы) *кибья* «коңгыз» һ.б.

Удмурдларның воршуд исемнәренең (хатын-кыз линиясе буенча нәсел-ыру кушаматлары) саны чама белән җитмешкә җитә. Элекке заманнарда вотяклар булган удмуртларның бу кабилә һәм кавемнәргә бүленешенә, беренчеләрдән булып, удмуртларның

тарихын, көнкүреш үзенчәлекләрен һәм гореф-гадәтләрен өйрәнүче Г.Е. Верещагин, Б.Г. Гаврилов, Н.Г. Первухин, Г.Н. Потанин, И.Н. Смирнов, А.А. Спицын, М.Г. Худяков һ.б. галимнәр игътибар итәләр.

Кабилә эчендә борынгы удмуртлар, теге яки бу ыруг вәкиле булуларын искәртеп, үзләрен нәсел-ыру исеме белән (воршуд) атый торган булалар. Ыруг исеме һәм билгеле бер кавемгә карауны аңлау удмуртларда кияүгә чыккан хатын-кызның ялгызлык исеме формасында буыннан-буынга тапшырыла (удмуртларда хатын-кыз кияүгә чыкканчы гына шәхси исемгә ия була, кияүгә чыкканннан соң исә аны бары тик ыруг, воршуд исеме белән генә атап йөртә башлыйлар). Гадәттә ул нәсел илаһинең атамасы булып торган һәм буыннан буынга күчеп барган (Бушмакин, 1970: 168–169).

И.Н. Смирнов билгеләвенчә, удмуртлар кайда гына таралсалар да, алар «һәрвакыт бер-берсе арасында нинди дә булса бәйләнеш булган төркемнәр белән бергә урнашалар» (Смирнов, 1890: 27). Теге яки бу нәселгә караган удмуртлар кайда гына булсалар да, үзләрен ыруг исемнәре (воршуд) белән атауларын дәвам итәләр.

Бүгенге көндә удмуртлар тарафыннан кулланылган *пор* сүзе мари этнонимына карата кулланыла. Г.И. Тепляшина фаразлавынча, *пор* компонентлы географик атамаларны угор кабиләләре калдыра. *Пор* нигезле топонимнар очраган территорияләрдә кайчандыр мансилар яшәвен дә искәртү кирәк. Е.И. Ромбандеева фикеренчә, мансиның һәр кешесе бүгенгәчә үзләренең бабалары кайсы ыругка каравын төгәл белә. Удмуртлар *пор* сүзен мари этнонимы буларак кулланган очракта шуны ассызыклау мөһим: марилар, мансилар кебек үк, удмуртлар өчен чит кавем вәкилләре. Шунлыктан, мансиларның бер нәселен аңлату өчен кулланылган «пор» сүзе мариларга мөнәсәбәтле дә кулланыла башлый (Тепляшина, 1970: 263). Г.И. Тепляшина тикшеренүләрендә *пор* нигезе белән бәйле географик атамалар *-ым/-им* топоформантлы топонимнар белән туры килгән аерым бер ареалны тәшкил итүен әйтә (Тепляшина, 1969: 220). Галимә, тикшеренүенең нәтиҗәсе буларак, өйрәнелә торган территориясенең топонимиясендә угор кабиләләренең яшәү эзе чагылуын искәртә.

Татарстанда *Поршур* (Кукмара районы) авылы атамасы *пор* «мари этнонимы» + удмурт телендә *шур* «елга» мәгънәсен белдерә. Авыл Казан ханлыгы чорында булган (Чернышев, 1971: 191).

Удмурт апеллятив лексикасы һәм кушамат-исемнәренә нигезләнеп *Иске Муй* (Арча районы) *муй > му* «җир»; *Югары Пошалым, Түбән Пошалым, Урта Пошалым* (Арча районы) *пыш* «киндер», *пышалыны* «киндерле»; *Чырпы* (Лаеш районы ) *чырпы > шырпы* «тычкан» һ.б. авыл исемнәре барлыкка килгән.

Гидрографик терминга нигезләнеп *Шуран* (Лаеш, Мөслим районы), *Приют Шуран, Татар Шураны* (Мөслим районы) атамалары барлыкка килгән. Удмурт телендә *шур* «елга», «елгачык» + *-ан* борынгы төрки һәм төрки булмаган халыклар яшәгән территорияләрдә киң кулланыла торган борынгы кушымча.

*Пучы* (Актаныш районы) татар авылы атамасының нигезендә мари телендә «болан» мәгънәсен белдерә торган *пучы* кушаматы ята (Саттаров, 1973: 172). Кешенең хәрәкәтен, холкын яки башка берәр ягын боланга охшату җирлегендә метафорик образлы *Пучы* кушамат-исеме барлыкка килгән.

Борынгы мариларның бабаларын чирмешләр дип йөрткәннәр. Әлеге этнонимга нисбәтле *Чирмеш* (Питрәч районы) авылы исеме барлыкка килгән.

Л.Ш. Арсланов, Н.Б. Борһанова, Г.Ф. Саттаров *Субаш Аты, Югары Аты, Түбән Аты, Урта Аты* (Арча районы) авыллары исемен мари теле белән аңлаталар. Мари телендә *аты>ото* «алан», «кечкенә урман» мәгънәсен белдерә.

Татарстан ойконимиясендә мордва теленә нисбәтле ойконимнар күп түгел. *Мокшы* (Әтнә районы), *Яңа Мукшы, Иске Мукшы* (Аксубай районы) авыллары исемнәре мордваларның элекке атамасы *мукшы* этнонимы белән бәйле.

Шулай итеп, ойконимик фактлар борынгы заманнарда байтак кына фин-угор кабиләләренең болгар-татарлар составына кушылулары, аларның татар халкын этник яктан формалаштыруда бер компонент буларак катнашулары турында сөйли.

Иран катламы.

Татарстан территориясендә иран телләреннән кергән ойконимнарның булуы Идел һәм Урал буе территорияләренә савромат кабиләләрнең килеп урнашуы белән бәйле. Ойконимиядәге барлык иран телле реликтларны ачыклау һәм аларны анализлау аеруча катлаулы. Ул алдан әзерлек, үзенә генә хас методика булдыру таләп итә, чөнки күпчелек субстрат иран телләренә нисбәтле сүзләр, һичшиксез, берникадәр үзгәрешләр кичерәләр. Әлеге үзгәрешләр

башлангыч этапта фин-угор телләре йогынтысында булса, соңга таба алар төрки телләр тарафыннан үзгәрешкә дучар ителәләр.

Шул рәвешле, татар ойконимиясендәге иран телле атамаларны кире кагарга ярамаса да, бу проблема бүгенгәчә төгәл чишелешле түгел. Топонимиядә иран элементларын Ф.И. Гордеев, Г.Ф. Саттаров, Р.З. Шәкүров, Н.Д. Гарипова, Т.М. Гарипов, А.К. Матвеев, Җ.Г. Киекбаев һ.б өйрәнделәр. Иран реликты башкорт, фин-угор халыклары ойконимиясендә табыла.

Татар ойконимиясендә иран телләренә нисбәтле *кар* «шәһәр», «крепость» ойконимик термины *Кышкар* (Арча районы) авылы атамасында сакланган. *Кышкар* «кыш чыга торган торак пункт, шәһәр яки авыл» мәгънәсен белдерә. Бу хакта ойконимик терминнар бүлекчәсендә сүз алып бардык.

Әйбернең бер урында күп булуын, туплам җыелмасын белдерә торган *-сар/-сәр* кушымчасы, ягъни борынгы иран теленең реликты *Каенсар* (Балтач, Кукмара, Әтнә районнары), *Карамасар* (Апас районы) авыл атамалары составында очрый. *-сар/-сәр* реликты фарсы теле тәэсире кичергән үзбәк, уйгыр, казак, чуваш телләрендә очрый.

Г.Ф. Саттаров, *Кукмара* шәһәре һәм район атамасының борынгы иран (скиф-сармат) телләренә нисбәтле барлыкка килгән булуы бар, дип саный (Саттаров, 1998: 402). Борынгы иран телендә *kaufa* – «тау»; таҗик, фарсы, әфга телләрендә *koh/кyh* – «тау түбәсе, тау өсте».

Мари телчесе Ф.И. Гордеев мари этнонимын сарматизм дип саный. Идел буе фин халыклары атамалары составында урын алган *морт* сүзе борынгы иран теленнән кергән «кеше» сүзенә кайтып кала, дип карый (Гордеев, 1985: 94). Димәк, *Кукмара* ойконимы иран-сармат телендә «тау мари кеше» мәгънәсен белдерә.

*Байлангар* (Кукмара районы) исеме килеп чыгышы борынгы иран теленнән мари теленә алынган *ангыр* «ыргак, кармак» сүзенә бәйләп аңлатыла (Саттаров, 1998: 403). *Байлангар* атамасының асылында беренче компоненты төрки чыгышлы *бай* «күп, мул» сүзе, икенче компоненты сармат чыгышлы *ангыр* «ыргак, кармак» сүзе ята дип караганда, семантикасы «ыргак кебек кәкре чокыр-чакырга бай урын» төшенчәсен белдерә.

Шулай итеп, татар теленең борынгы иран теленә кайтып кала торган ойконимик атамалар борынгы мари теле аша килеп кергән

һәм Идел–Кама регионында барган бик борынгы тел контактларын чагылдыралар.

Төрки катлам.

Бүгенге көндә төрки ойконимия территориаль яктан киң таралыш алган, катлаулы структура һәм стратиграфиягә ия булган, лексик яктан бай системаны тәшкил итә. Татарстан ойконимиясендә иң күләмле булып төрки катлам тора. Ул берничә аскатламга (борынгы төрки, болгар, татар, чуваш, башкорт) бүленеп карала.

*Борынгы төрки аскатламы.*

Борынгы төрки ономастика субстрат, адстрат, алынма һәм телнең үз структур элементларының катлаулы үрелеп баруы шартларында формалаша. Әлеге процесс борынгы төркиләр тарафыннан үзләштерелгән мәдәни катламнарның төрлелегенә, буынара бәйләнеш һәм төркиләрнең дәүләт ясауда катнашкан иҗтимагый-сәяси системаларның үсеш-үзгәрешенә бәйле (Махпиров, 1990: 4–5).

Лаеш районында *Пәрәү* дигән татар авылы бар. Бу авылның Казан ханлыгы чорында булуы мәгълүм (Чернышев, 1971: 292). Борынгы заманнарда төрки халыкларда кыргый һәм йорт хайваннары балаларының атамалары булып йөри торган зоологик терминнарны, хайван балаларының кечкенә чагында сөйкемле, ягымлы, матур, уйнакчыл һәм зәвыклы булуларын күздә тотып, башлыча, ир балаларга исем итеп бирү гадәт-йоласы булган. *Пәрәү* авыл исеменең асылында *Пәрәү* «бозау» дигән борынгы төрки кеше исеме ята.

*Күгеш* (Яшел Үзән районы) дигән авыл исеме борынгы төрки-татар кеше исеменә нигезләнеп барлыкка килгән. Бу сүз полисемантик мәгънәгә ия. Аның килеп чыгышы: 1) *күк иш* > *күгеш, күк ише, изге җан*; 2) *ирекле, хөр иш (ярдәмче, бала)*; 3) *яшел иш, яшь иш (бала)*; 4) *күгү* «аккош» + *иш* «бала» рәвешле карала.

*Күгеш* исеме болгар-татарлардан мариларга да кергән (Черных, 1978: 70). Бу исемнән ясалган *Кугушев, Кугушин* фамилияләре татарларда һәм русларда да бар. Бу авылның Казан ханлыгы чорында булуы документаль мәгълүм.

*Чупай* (Мамадыш, Минзәлә, Әлмәт районнары) дигән атамасы борынгы төрки-татар *Чупай* исеменә барып тоташа. Борынгы төрки телдә *чап* сүзе *дан* мәгънәсенә ия булган, аңа *-ай* эндәшү-боеру кушымчасы ялганып *Чупай* исеме килеп чыккан

(Саттаров, 1998: 298). Казан татарлары арасында *Чупаев* фамилиясен йөртүчеләр бар.

Татар ойконимнары составында борынгы төрки этнонимнар, антропонимнар һәм географик терминнарга нигезләнеп ясалган атамалар күп. Алар турында сүз алдагы бүлектә алып барылачак.

*Болгар аскатламы.*

Болгарлар Урта Идел–Кама буенда, шактый зур территорияне биләп, VIII йөз башларыннан алып, якынча XVI гасырга кадәр, нигездә утрак тормышта күпсанлы авылларда һәм, байтагының исемнәре тарихи чыганакларда теркәлеп барганга, безгә билгеле шәһәрләрдә яшәгәннәр.

Тикшеренүләр күрсәткәнчә, күпчелек шәһәр һәм авыллар болгар атамаларын йөртәләр һәм, шул рәвешле, Идел–Кама ойконимиясендә аерым бер болгар катламы барлыкка китерәләр. Шулай да Идел-Кама болгарларының теле буенча мәгълүматларның чагыштырмача аз булуы әлеге сорауны бүгенгәчә ачык калдыра.

Г.Ф. Саттаров фикеренчә, субстрат болгар катламын өйрәнүдә һәм аңлатуда лингвистик ачкыч вазифасын түбәндәге төшенчәләр башкара:

1) гомумболгар теленнән калган билгеле булгаризмнар;

2) Идел–Кама–Урал регионының хәзерге төрки телләре (татар, чуваш, башкорт) диалектларында һәм сөйләшләрендә һәм башка төрки телләрдә (балкар, кумык, нугай, гагауз һ.б.) сакланып калган булгаризмнар;

3) урта гасыр башларында күрше славян (борынгы рус, болгар һ.б.) һәм фин-угор (венгр, мордва, удмурт, мари, коми һ.б.) телләре лексикасы тарафыннан кабул итеп алынган булгаризмнар;

4) XIII–XVII йөз эпитафикасында (Юсупов, 1960; Хакимзянов, 1978), Х. Мөслиминең «Тәварихы Болгария» китабында, татар шәҗәрәләрендә (Усманов, 1972; Ахметзянов, 1981) һ.б. чыганакларда бирелгән болгар-татар кеше исемнәре, кушамат, фамилиятәхәллүсләр, төрле терминнар, исем һәм атамалар (апеллятив һәм ономастик лексика);

5) Е.И. Чернышевның язу кенәгәләреннән алынган мәгълүматларга таянып төзелгән «Селения Казанского ханства» (1971) дигән мәкаләсендә тупланган авыл исемнәре;

6) борынгы татар-чуваш-башкорт телендәге кеше исемнәре һәм башка төрки телле халыклар лексикасындагы борынгы төрки чыгышлы антропонимнар;

7) «Борынгы төрки тел сүзлеге»ндә (1969) һәм башка алтай (монгол, тунгус-маньчжур) телләренең билгеле булган чагыштырма сүзлекләрендә теркәлгән апеллятив һәм ономастик лексика (Саттаров, 1989: 7).

Идел–Кама һәм Урал регионының хәзерге татар һәм башка төрки телләренең диалекталь фонетика, лексика һәм морфологиясе мәгълүматларына нигезләнеп, шулай ук алда күрсәтелгән лингвистик чыганакларда тупланган конкрет мәгълүматларны чагыштыру нәтиҗәсендә, Г.Ф. Саттаров тарафыннан болгар исемнәренә барып тоташкан 200 дән артык атама ачыклана. Әлеге атамалар Татарстан топонимиясендә болгар катламын тәшкил итәләр.

Татар теленең минзәлә сөйләшендә *күтер* географик термины «өсте үлән белән капланган күл», эчкен сөйләшендә «күл уртасындагы камышлык төпләрендә барлыкка килгән түмгәклек» төшенчәсен белдерә. Себер татарларында *күтер* сүзе саз үләненең бер төренә атама булып йөри. Чуваш телендә *күтер* – «саз».

Профессор Г.Ф. Саттаров карашынча, *Өтернәс* (Саба районы) авылы исемендәге *өтер* > *күтер* гидрографик терминының генезисы Идел-Кама болгарлары теленә барып тоташа (Саттаров, 1992: 200). Казан артында ярлары сазлыклы, баткаклы булганга, *Күтернәс* исемен йөртүче ике елга атамасы бар. *Күтернәс, Өтернәс* атамаларының болгар теленә нисбәтле булуын атамалар составында урын алган *нәс/инәс* «елгачык» географик термины да раслый. Казан артында *Чикәнәс, Сикәнәс* (Арча районы), Мамадыш районында *Сәкинәс, Югары Сәкинәс* дигән рус авыллары бар. Татар телендә *чак*, чуваш телендә *чике* сүзе «чик, кырый» төшенчәсен белдерә. Ф.Г. Гарипова Татарстан территориясендә Чик елгасы дип атала торган биш елга булуын күрсәтә (Гарипова, 1984: 130).

Составында *ширмә* «чокыр», елга» орогидрографик термины булган авыл атамаларының генезисы Идел-Кама болгарларына нисбәтле. *Карашырмә* (Саба районы), *Ямаширмә* (Биектау районы), *Орымширмә, Карашырмә* (Теләче районы), *Икширмә* (Саба районы), *Яуширмә* (Чистай районы) авыллары болгар чорында нигезләнгәннәр.

*Балтач* (Әгерҗе, Азнакай, Кама Тамагы районнары) авылы атамасы ике компоненттан – тамыры *балта* һәм *-ач* иркәләү-кечерәйтү кушымчасыннан тора. Болгар кабиләләрендә, мәҗүси ышанулардан чыгып, балаларга «кара көч»ләрне куркытырлык исемнәр бирелгән. *Балта* – әлеге көчләрне куркытырга сәләтле, каты, нык металл корал булып саналган. Шулай ук андый исемнәрне баланың таза, нык, көчле булуын теләп кушканнар. Болгар чорында, эпитафик мәгълүматлар күрсәткәнчә, *Балтач* исеме шактый таралыш алган булган (Юсупов, 1960: 108).

*Татар аскатламы.*

Татар теленә генә хас сүзләрне аеру шактый катлаулы, чөнки татар теле борынгы төрки телнең варисы булып тора һәм күп кенә сүз формаларын саклый. Кайбер галимнәр фикеренә таянып, башка төрки телләрдә чагылыш тапмаган атамаларны аерып чыгарып була.

«Сөзәк җир» төшенчәсен белдерүче җирле орографик терминга нигезләнеп, *Янтык* авылы атамасы барлыкка килгән. Лаеш районында *Татар Янтыгы* һәм *Рус Янтыгы* дип аталган авыллар бар.

*Кәкре елга* (Азнакай районы) авылы атамасының беренче компоненты татар телендә *кәкре* «*туры, төз булмаган, бөгелгән яки кәкрәйтелгән*» дигән мәгънәне аңлата (ТТАС, 2005: 289).

*Бүләк* (Азнакай районы) авылы атамасын татар аскатламы белән аңлатабыз. Татар теленең минзәлә, гәйнә сөйләшләрендә «әрәмәлек, вак урман» мәгънәсендә йөргән *бүләк* сүзе күптөрле татар ойконимнарының нигезендә ята. Г.Ф. Саттаров *бүләк* сүзен төрки телләрдәге *булак-болак* сүзләре белән бәйли. Шулай ук галим бүгенге көндә *чишмә* мәгънәсендә булган *бүләк* гидрографик терминының татарларда кулланылмавын искәртә, югыйсә башка төрки телләрдә әлеге термин киң кулланылышта йөри (Саттаров, 1992: 32).

Шулай ук *бүләк* терминын *бүлү-бүленү* сүзләре белән бәйләнештә аңлатып була. Татар һәм башкорт ойконимиясендә зур авылдан аерылып чыккан яңа авылларны *бүләк* термины ярдәмендә атау күренешләре еш очраган. Шулай итеп, «*бүләк*» авылларны башка авылларның *кисәк-бүлекләре* дип тә аңларга да мөмкин.

*Сарай-Чокырча, Чекурча* (Арча районы) авыллары исемнәре чокыр терминын белдерә. Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә *чокыр* «чокыр», «котловина», «впадина» мәгънәсен аңлата (ТТАС,

1981: 439), шуңа *-ча* кечерәйтү кушымчасы ялганып авыл исеме ясалган.

*Чалпы* (Азнакай районы) авылы исеме минзәлә сөйләшенә хас булган *җалпы* «иңкү, уйсу җир» терминының фонетик варианты *чалпы* сүзеннән барлыкка килгән.

*Башкорт аскатламы.*

Татарстан ойконимиясендә килеп чыгышлары белән башкорт теленә мөнәсәбәтле атамаларның урын алуы, безнең регионда башкорт кабиләләре күчеп йөрүләре, яшәүләре, кайбер төркемнәренең акрынлап утрак тормышка күчеп, аерым авылларны нигезләүләренә бәйләп аңлатып була.

Чүпрәле районындагы *Татар Төкесе*, Актаныш районындагы *Төке* авылы исемнәре составында урын алган *төкө* сүзе башкорт теленың Дим сөйләшендә «ташбаш», «комкорсак» (пескарь) мәгънәсен аңлата (Башкорт һөйләштәренең һүзлеге, 1979: 256).

Г.Ф. Саттаров Арча районында *Югары Мәтәскә, Түбән Мәтәскә*, Саба районында *Олы Мәтәскә, Югары Мәтәскә* дигән татар авыллары исемнәрен башкорт теленә мөнәсәбәтле аңлата (Саттаров, 1973: 166). *Мәтәскә* топокомпоненты башкорт теленең юрматы сөйләшендә «кәрлә» мәгънәсен белдерә (Башкорт һөйләштәренең һүзлеге, 1979: 169). Шушы сүзгә *-кәй* иркәләү-кечерәйтү кушымчасы ялганып, *мәтәскәй* формасы алган, *й* авазы төшеп калу юлы белән *мәтәскә* әйтелеше барлыкка килгән.

Казан артында башкорт этнонимына һәм башкорт теленә мөнәсәбәтле рәвештә барлыкка килгән ойконимнар бар. *Таузар* (Балтач районы) авылы (таузар башкортча әйтелеш), *Казак Үртәме, Үртәм* (Арча районы) авыллары (башкорт телендә үртәм «көек», «янык» мәгънәсен белдерә), *Карадуван* (Саба районы) авылы (карадуван башкорт этнонимы) авыллары исемнәре башкорт теленә мөнәсәбәтле барлыкка килгәннәр. Татарстанның Казан арты территориясендә урта гасырларда кайбер башкорт кабилә-ыругларының яшәвен тарихи, эпитафик һәм диалектологик чыганаклар раслый.

*Чуваш аскатламы.*

М.З. Зәкиев, үткәргән тикшеренүләре нәтиҗәсендә, чуваш теле, башка төрки телләр белән чагыштырганда, шактый аермалы төркем тәшкил итә, дигән фикергә килә. Болгарларның Идел буена килеп төпләнүләренә хәтле формалашып җиткән чуваш теле алга

таба башка күрше телләр, шул исәптән болгар, Казан татарлары һәм мишәрләр телләре белән, тыгыз мөнәсәбәттә торган. Күп гасырлар дәвамында барган әлеге аралашу Идел–Урал буе топонимиясенә дә, регион халыклары телләренә дә йогынты ясамыйча калмаган (Закиев, 1986: 90).

Азнакай районында атамасын чуваш теле материалы нигезендә аңлатырга мөмкин булган *Чәкән* авылы урнашкан. Болгар-татарларда кошларны тотемлаштыру, мәҗүси заманнарда аларның изгелегенә ышану булган. Шуңа нисбәтле кош исемнәре нигезендә кеше исемнәре дә барлыкка килгән. Чуваш телендә *чакан* буларак яңгыраган һәм *саескан* мәгънәсенә ия булган сүз татар телендә *чәкән* формасында сакланып калган (Саттаров, 1990: 32). Бүгенге чуваш теленә исә *саескан* сүзе *чакак* буларак тәрҗемә ителә

*Толкыяз* (Питрәч районы) авылы кушма төзелешле атама. Чуаш телендә *тула – талкы* «бодай» һәм татар телендә «дала, тигезлек, басу-кыр» мәгънәсендә йөргән *йаз* сүзенең генезисы борынгы төрки телдәге *йази* «степь, равнина» сүзенә кайтып кала (ДТС, 1969: 25).

Монгол катламы.

Идел–Урал территорияләренең озак вакыт дәвамында Алтын Урда дәүләте составында булуы сәбәпле, төбәктә монгол кавемнәренең күпләп яшәве табигый. Әлеге тарихи күренешләр топонимиядә чагылыш тапмый дип әйтеп булмый. Шул ук вакытта, монгол теленә нисбәтле сүзләрне ачыклау шактый авырлык тудыра, чөнки бу мәсьәләдә берникадәр буталчыклык тудыручы факторлар бар. Әлеге факторларга аваздаш, гомум алтай терминнарына кайткан сүзләр, шулай ук атама формалашуында монгол алынмаларының күп тапкыр фонетик үзгәрешләргә дучар булуы да карый. Шулай да, монгол теленә караган атамаларны аерып карыйк.

*Туктар Урдалысы* (Лениногорск районы) авылы (элеккеге исеме – *Урдалы*) атамасындага *урдалы* сүзе монгол телендә «хан сарае, зур тирмә, ихата» мәгънәләрен аңлаткан *ордо* сүзенә кайтып кала. *Урдалы* атамасы ике компоненттан: монгол сүзенең фонетик варианты булып торган *урда* сүзе һәм *-лы* ия булу кушымчасыннан тора. Шулай итеп, әлеге авыл атамасын да монгол катламына мөнәсәбәтле рәвештә тикшерергә мөмкин.

*Елга* – төрки-монгол термины. Термин Идел буе гидронимиясендә шактый киң таралган, Башкортстан территорияләрендә дә

киң кулланыла. Бу термин аерым агым суларны атау өчен кулланыла. Термин Россиянең киң территорияләрендә һәм чит илләрдә күзәтелә. Казакстанда *жилга (джилга)* – елгачык, Кыргызстанда – *жылга* – «русло», «ерганак», «ложбина» һ.б. Термин Көнбатыш Себер территориясендәге географик атамаларны барлыкка китерүдә актив катнашкан. Бу термин турында А.П. Дульзонның да фикерләре бар, ул мисал итеп Тоболдагы *йилга* формасын китерә (Дульзон, 1959: 18). М.Ф. Розен элек бу термин зур елгаларга да таралган дип әйтә: *Иртеш-Елга, Ом-Елга, Та-Елга (Тара)*. Бүгенге көндә ул кече елгалар исемендә сакланган, ди (Розен, 1970: 56). Термин барлык сүзлекләрдә теркәлгән. Татарстанда атамалары составында *елга* термины булган бик күп елга һәм авыл атамалары (мондый авыл атамалары елга исемнәренә мөнәсәбәтле рәвештә барлыкка килгән) бар. Мәсәлән, *Бурсык Елга, Олы Елга, Кече Елга, Зирекле Елга, Кара Елга, Карамалы Елга, Ташлы Елга, Үгез Елга, Куәтле Елга, Су Елга* һ.б.

Гарәп-фарсы телләренә нисбәтле гидронимнар.

Болгар халкы Ислам дине кабул итүеннән башлап, телгә күп кенә гарәп-фарсы алынмалары үтеп керүе күзәтелә. Татарлар, төрки исемнәре белән беррәттән, балаларына дин аша кергән исемнәр куша башлый. Татар ойконимнарының күпчелеге анторопонимнарга нигезләнгәнгә күрә, гарәп-фарсы катламы, башлыча, антропонимик ойконимнарда гәүдәләнә.

*Дусмәт* (Мамадыш районы) авылы атамасы *Дусмөхәммәт* исеменең фонетик тартылыш кичерүе, кыскаруы нәтиҗәсендә барлыкка килгән. *Дусмөхәммәт* исеме ике компоненттан тора. Атама нигезендә фарсы чыгышлы *дус* «дус, якын фикердәш, сердәш» + гарәби чыгышлы *Мөхәммәт* «макталган, данлыклы», «ислам диненә нигез салучы Мөхәммәт пәйгамбәрнең исеме» ята (Татар исемнәре ни сөйли, 1998: 98; 182).

*Ахун, Югары Гәрәй, Зөбәер, Иске Сәфәр* (Актаныш районы); *Муратовка* (Азнакай районы), *Абдул Салман, Татар Әхмәте* (Әлки районы); *Габдрахман, Мәмәт* (Әлмәт районы); *Әлмәндәр* (Апас районы); *Хәсәншәех* (Арча районы); *Бахтияр* (Әтнә районы); *Мортаза* (Баулы районы); *Әхмәт, Шигали* (Буа районы); *Нариман* (Югары Ослан районы); *Җәлил, Әлмәт* (Сарман районы); *Әбсәләм* (Ютазы районы), Мәмдәл (Биектау районы) һ.б. авыл исемнәре гарәп һәм фарсы чыгышлы кеше исемнәренә нигезләнеп барлыкка килгәннәр.

Рус теленә нисбәтле сүзләрдән ясалган ойконимнар

Татар теленә рус теле сүзләре IX гасырда ук керә башлый. Татарстан территориясендә рус теленә нисбәтле атамалар Казан ханлыгы яулап алынганнан соң күпләп барлыкка килә.

Рус теленә нисбәтле ойконимнарның күбесе антропонимнарга нигезләнеп барлыкка килгәннәр: *Александровка, Владимировка, Митрофановка* (Азнакай районы); *Алексеевка Емелькино, Новое Тимошкино, Сергеевский, Федоровка* (Аксубай районы); *Ивановский* (Алексеев районы); *Борискино* (Әлки районы); *Петровка* (Әлмәт районы) һ.б.

*Городок, починок, мунча (мовница)* сүзләре белән дә авыл исемнәре барлыкка килгәннәр: *Бишмунча* (Әлмәт районы) исемле татар авылы атамасы төрки-татар чыгышлы *биш* саны белән генезисы рус телендәге *мовница* сүзенә кайтып калган *мунча* компонентларын кушу нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Шулай ук *Починок Енаево* (Апас районы), *Починок Сосна* (Балтач районы), *Починок Кучук* (Кукмара районы), *Починок-Новоильяшево* (Тәтеш районы), *Починок-Поник* (Арча районы), *Городок* (Алексеев районы) һ.б. атамалар барлыкка килгән.

Апеллятив лексика һәм географик терминнарга бәйле атамалар: *Заречье, Первое Мая* (Азнакай районы); *Заря, Калиновка* (Аксубай районы); *Подлесный* (Бөгелмә, Лениногорск); *Полянка* (Әлмәт, Лаеш, Спасс, Балык Бистәсе районнары); *Зур Полянка* (Алексеев районы); *Березовая Грива* (Алексеев районы); *Березовка* (Әлмәт районы); *Лебяжье, Речное* (Алексеев районы); *Каменка* (Әлмәт, Биектау районнары) һ.б.

Татар ойконимиясендә аббревиатуралар белән исемләнгән торак пунктлар бар: *Агрокультура* (Чистай районы); *КИМ* (Спас районы) поселогы; *МЮД* (Международный юношеский день) поселогы (Аксубай районы); *Татцик* (Питрәч районы) поселогы.

Рус катламына караган татар авыллары исемнәре чукындыру сәясәте белән, я кайчандыр телгә үтеп кергән һәм фонетик яктан үзгәртелгән алынмалар, Октябрь инкыйлабыннан соң рус теленнән кергән сүзләр белән бәйле.

Шулай итеп, Татарстан ойконимиясе төрле катламнарга карый. Бу чуарлык катлаулы тарихи шартларда үсеш алуына, төрле чордагы халык күчешләренә, сәяси, мәдәни, милли үзгәрешләргә ишарә ясый. Гасырлар дәвамында әлеге территорияләрдә төрле

халык вәкилләре бер-берсе белән тыгыз мөнәсәбәттә торган, тел, милләт, көнкүреш үзенчәлекләре белән уртаклашкан һәм кешеләрнең тыгыз элемтәләре ойконимик атамаларда сакланган. Башка телләргә караган атамаларны барлау фин-угор, иран, төрки, гарәп, монгол, рус телле халыклар контактлары турындагы мәгълүматларны ачыкларга ярдәм итә.

## § 24. Татар ойконимнарын номинацияләү принциплары

Семантик яктан ойконимнар күпкырлы һәм катлаулы күренеш тәшкил итәләр. Ойконимның семантикасында атама бирелгән объект, сөйләүченең объектка карата мөнәсәбәте, ойконимның нигезен тәшкил иткән апеллятивның мәгънәсе һәм сөйләм вакытында әлеге сүзгә мөнәсәбәттә барлыкка килә торган ассоциацияләр турында мәгълүмат чагылыш таба.

Номинацияләү үзенчәлекләрен ачыклауда иң отышлы булып лексик-семантик классификация санала. Лексик-семантик классификацияне ясауда ономастика галимнәре түбәндәге мәсьәләләр чишүне максат итеп куялар: төрле типтагы географик объектларның төп номинация принциплары нәрсәдән гыйбарәт, атама сайлау барышында ойконимик объектларның кайсы үзенчәлекләре игътибарга алына, ойконимиядә атама буларак кайсы лексик элементлар ешрак куллана?

Галимнәрнең төрле территорияләрнең географик атамаларын тикшерүгә юл ачкан, лексик-семантик классификацияне барлыкка китерү мәсьәләсенә багышланган күп кенә хезмәтләре билгеле.

Төрки ойконимикада атамаларның лексик-семантик классификацияләрен төзү И.В. Дрон, Т.С. Жанузаков, Е.К. Койчубаев, Г.К. Корнилова, В.У. Махпиров, О.Т. Молчанова, Б.Х. Мусукаев, Л.А. Наханова, В.А. Никонов, В.Н. Попов, Н.А. Прманова, Г.Ф. Саттаров, А.Ю. Филькова, Р.З. Шакуров һ.б. хезмәтләрендә башкарылды. Классификацияләрнең күпчелеге төрки халыкларның эшчәнлек төрлелеген, тикшергән регионнарның физик-географик үзенчәлекләрен истә тотып эшләнелгән.

Аерым бер регион ойконимиясен тикшерүгә С. Атаниязов (Көньяк-көнчыгыш Төркмәнстан), К.К. Конкабаев (Көньяк Кыргызстан), С.З. Рахимбакиев (Көнбатыш Себер), Г.М. Ниязова (Төмән өлкәсе), Ф.Г. Хисамитдинова (Башкортстанның тарихи

атамалары), А.А. Камалов (Башкортстан), З.Ф. Әхәтова (Татарстанның Түбән Кама буе), Г.К. Һадиева (Казан ханлыгы чоры атамалары), Р.И. Хаҗиев (Көньяк-көнчыгыш Кама аръягы ойконимиясе), О.Р. Хисамов (Татарстанның Көнбатыш Кама аръягы) һ.б.ның хезмәтләре багышланган. Тикшерүчеләр нигезләрендә төрлечә якын килү принциплары яткан, бер-берсеннән аерыла торган классификацияләр тәкъдим итеlә. Мәсәлән, Көньяк Кыргызстан топонимнарын тикшерү барышында К.К. Конкабаев барлык географик атамаларны ике зур төркемгә бүлә:

1. Географик объектларның кеше эшчәнлегенә тыгыз бәйләнешен чагылдырган топонимнар: а) кыргызларның төп эшчәнлеге – терлекчелек турында мәгълүмат биргән географик атамалар; ә) кыргызларның кайчандыр күчмә тормыш истәлекләрен саклаган топонимнар; б) кыргызларның җир эшкәртүгә кагылышлы топонимнар; в) тормыш-көнкүреш, иҗтимагый мөнәсәбәтләрне чагылдыручы топонимнар; г) кыргызларның территориядә кеше яисә хайваннарның тән әгъзалары ярдәмендә ориентлашуы турында мәгълүмат биргән географик атамалар; д) аучылык турында мәгълүмат биргән топонимнар; е) этнотопонимнар; ж) кыргызларның совет чорындагы тормышларын чагылдыручы топонимнар.

2. Объектларның кешенең практик эшчәнлеге белән бәйләнешен чагылдыручы топонимнар: а) топонимия составында сыйфат сүз төркеме; ә) топонимия составында сан сүз төркеме (Конкабаев, 1980: 56).

А.Ю. Филькова Россия территориясендәге төрки чыгышлы полисонимнарны лексик-семантик классификация ярдәмендә түбәндәге ике зур төркемгә бүлә:

1. Төрле семантик спектрга ия булу нәтиҗәсендә, өстәмә эргогеографик, гидрографик, орографик төсмер белән баетылган номенклатур терминнар. Тикшерү барышында әлеге төркем түбәндәге төркемчәләргә бүленеп карала: 1) төрле типтагы торак пунктларны атаган географик терминнардан барлыкка килгән полисонимнар; 2) гидрографик терминнар нигезендә барлыкка килгән полисонимнар; 3) составында орографик терминнар булган полисонимнар; 4) геоботаник терминнар нигезендә барлыкка килгән топонимнар; 5) төрле типтагы биналарны аңлаткан терминнардан барлыкка килгән топонимнар; 6) халыкның типик көнкүреш үзенчәлекләрен чагылдырган топонимнар.

2. Антропонимик, этнонимик, топонимик терминологик характерда булмаган категорияләр тәэсирендә барлыкка килгән полисонимнар. Бу төркем түбәндәге төркемчәләргә бүленә: 1) антрополисонимнар; 2) этнополисонимнар; 3) гидрополисонимнар; 4) оронимополисонимнар; 5) фитонимополисонимнар; 6) хайван исемнәреннән барлыкка килгән полисонимнар (Филькова, 1989: 93).

XVI–XIX гасырларга караган башкорт ойконимиясен анализлау барышында, Ф.Г. Хисамитдинова ономастика буенча теоретикларның берсе булган А.В. Суперанская тәкъдим иткән топонигезләр тикшерү методын куллана. Әлеге ысулны кулланып тикшерү барышында атамалар составындагы топонигезләр аерып чыгарыла. Үз чиратында бу, беренчедән, ойконимнарның барлыкка килү чыганакларын, икенчедән, аларның төгәл семантик мотивацияләрен ачыкларга ярдәм итә. Шул ук вакытта анализ, билгеле бер вакыт аралыгы сүз ясалышы үзенчәлекләрен истә тотып, һәрбер чор өчен хас булган модельләрне аерып чыгаруны, атама бирү максатын, аның нинди юл үткәнен ачыклауны да күз алдында тота.

Башкортстан торак пунктларының атама нигезләре үзенчәлекләреннән чыгып, Ф.Г. Хисамитдинова ойконимнарны ике төп бүлеккә аера: 1) нигезендә уртаклык исемнәр, ягъни апеллятивлар яткан ойконимнар; 2) нигезендә ялгызлык исемнәре, ягъни онимнар яткан ойконимнар.

Алга таба апеллятив чыгышлы ойконимнар төркеме түбәндәге төркемчәләргә бүленә: 1) торак пункт терминнарыннан барлыкка килгән атамалар; 2) йорт һәм бина терминнарыннан барлыкка килгән атамалар. Ойконимнарның икенче – онимик чыгышлы төркеме түбәндәге төркемчәләргә бүленә: 1) этнонимнар нигезендә барлыкка килгән ойконимнар; 2) антропонимнар нигезендә барлыкка килгән ойконимнар; 3) топонимнар нигезендә барлыкка килгән ойконимнар (Хисамитдинова, 1981: 29-40).

Г.Ф. Саттаров, Татарстан Республикасы район һәм район үзәкләре атамаларын түбәндәге лексик-семантик төркемнәргә бүлеп тикшерә:

1) антропонимнарга (кеше исеме: кушамат, фамилия) нигезләнеп барлыкка килгән район һәм район үзәкләре атамалары; 2) елга атамаларына (гидронимнарга) нигезләнеп барлыкка килгән атамалар; 3) этнонимнардан (ыруг, кабилә, халык атамаларыннан)

ясалган район атамалары; 4) оронимик (тау-чокыр, үзәнлек-уйсулык, кыр-басу) географик номенклатура терминнарыннан ясалган атамалар; 5) ойконимик (торак пункт) номенклатура терминнарыннан ясалган район атамалары; 6) урнашу урынына, теге яки бу физик-географик объектның кайсы урынында урнашуына карап аталган район исемнәре; 7) гидрографик номенклатура терминнарыннан ясалган атамалар; 8) асылында чиркәү атамасы яткан район исеме; 9) символик атамадан гыйбарәт район исеме (Саттаров, 1984: 96).

Шулай итеп, топонимикада ойконимнарны анализлауның төрле семантик аспектлары яшәп килә, аларның һәрберсе билгеле бер өстенлекләргә ия.

Татарстан Республикасы татар авыллары атамаларын без ике лексик-семантик төркемгә һәм аларны төркемчәләргә бүлеп тикшердек:

1. Апеллятив лексика нигезендә барлыкка килгән атамалар. Әлеге төркемгә кергән авыл исемнәре, семантик үзенчәлекләренә карап, түбәндәге төркемчәләргә бүленә:

1) гидрографик номенклатура терминнарыннан ясалган атамалар;

2) оронимик терминнарга нигезләнеп барлыкка килгән атамалар;

3) фитонимик терминнар ярдәмендә ясалган атамалар;

4) зоонимик терминнар нигезендә барлыкка килгән атамалар;

5) географик объектның искелеген яки яңалыгын, урнашу урынын белдерүче сүзләрдән ясалган ойконимнар;

6) географик объектның төсен белдерүче сүзләрдән ясалган ойконимнар.

7) символик атамалардан гыйбарәт исемнәр.

2. Онимнар нигезендә барлыкка килгән атамалар. Бу төркемгә кергән атамалар түбәндәге төркемчәләргә бүленә:

1) антропонимнарга нигезләнеп барлыкка килгән атамалар;

2) этнонимнар нигезендә барлыкка килгән атамалар.

Түбәндә татар ойконимнарының лексик-семантик классификациясен карыйк.

1. Апеллятив лексика нигезендә барлыкка килгән атамалар. Апеллятив лексика үз эчендә түбәндәге төркемчәләргә бүленә:

1) *гидрографик номенклатура терминнарыннан ясалган атамалар.*

*Су* гидрографик термины борынгы төрки телдә 1) « су»; 2) «елга» төшенчәсен белдергән. Татарстан ойконимиясендә су термины «елга» мәгънәсендә актив лексик берәмлек булып тора: *Аксу* (Буа районы); *Карасу* (Аксубай районы) *кара* һәм *су* «җир астынннпн чыгучы су, елга»; *Суелга* авылы «елга» + «елга» (Мамадыш районы); *Иске Суыксу, Яңа Суыксу* (Буа районы), *Суксу, Ташсу* (Биектау районы); *Мари Суксыу, Татар Суксуы* (Актаныш районы); *Субаш* (Теләче районы), *Субаш Аты* (Арча районы), *Югары Субаш*, *Түбән Субаш* (Балтач районы).

Татар ойконимиясендә *су* термины *са/шу* фонетик вариантларында да очрый: *Чебакса* (Биектау районы) *чебак* «чабак» + *са/* су «елга»; *Югары Курса, Урта Курса, Түбән Курса, Смак Курса, Курса Почмак* (Арча районы) авыллары исемендәге *курса* сүзе *кур > курур* «корыр» + *са*; *Көек-Ерыкса* (Мамадыш районы); *Колбай-Мораса, Кече Колбай-Мораса* (Нурлат районы) монгол телендә *мораса* сүзе *мурэн > мора* «елга» + *са* «елга»; *Шуширмә* (Апас районы) *шу* «елга» + болгар телендә *ширмә* «елга», «чокыр» мәгънәсендә авыл атамалары барлыкка килгән.

Татар ойконимиясендә төрки-монгол телләре гидрографик *елга* номенклатурасы киң кулланылышта йөри. Элек *елга* сүзе бары уртача зурлыктагы агым суларны атау өчен файдаланылган. Хәзерге татар телендә исә ул зур һәм кечкенә елгаларга карата да кулланыла. Мәсәлән: Азнакай районында *Кәкре елга, Карамалы елга, Зирекле елга, Курай елга, Куәтле елга* дигән авыллары бар. *Кәкре елга* татар телендә *кәкре* «туры, төз булмаган, бөгелгән» дигән мәгънәдә (ТТАС, 2005: 289); *Карамалы елга, Зирекле елга* авыл исемнәре *карама* һәм *зирек* агачлары исемнәренә бәйле; *Курай елга* борынгы төрки телдә *курай > кагурай* «корыган сабак» сүзенә, *как* «коры, кипкән» тамырына кайтып кала (Әхмәтьянов, 2001: 123); *Куәтле елга* атамасы гарәп телендә *куәт* «*көч*», ягъни «*көчле елга*»; *Куш Елга* (Зәй районы); *Елгабаш, Ташъелга* (Мөслим районы); *Олы Елга* (Балык Бистәсе районы), *Үгез Елга* (Арча районы) борынгы төрки телдә *үгез > угуз* «елга» + *елга; Мөгезле Елга* (Әлмәт районы); *Якты Елга* (Буа районы); *Кара Елга* (Зәй, Кукмара районы); *Бурсык Елга* (Кукмара районы); Кече елга (Лаеш районы); *Су Елга* (Мамадыш районы), *Нарат Елга* (Чистай районы) һ.б.

Минзәлә сөйләшендә кыска елганы һәм инешне белдерү өчен *тукмак* һәм *чукмар* географик термины кулланыла (Саттаров, 1992: 20). Бу терминнар хуҗалык коралларын белдерә торган *тукмак* һәм *чукмар* сүзләренә нигезләнеп ясалган. Авыл атамалары составында бу сүзләрне күчерелмә мәгънәсендә (метафора) куллану күренеше ята. Мәсәлән: *Тукмак* (Лениногорск районында ике татар авылы бар), *Иске Тукмак, Яңа Тукмак, Тукмак* (Тукай районы), *Чукмарлы* (Сарман районы) авыллары.

*Тукмак* исемен йөрткән елгачыклар буена утырган авылларга *Тукмак* атамасы бирү башка төрки регионнарга да хас. Мәсәлән, Башкортстанда *Тукмакбаш, Тукмаккаран, Тукмаклы, Тукмар-Чишмә* дигән авыллар бар.

Татар телендә *кәкре, бөгелеш, бөгелмә* терминнары «елганың, юлның бөгелгән, борылыш ясаган урынын» белдерү өчен хезмәт итәләр (Саттаров, 1998: 44). Шуңа нисбәтле *Бөгелмә* елгасы исеменнән *Бөгелмә* шәһәре исеме ясалган. «Елга бөгелеше, борылышы» төшенчәсен белдерү өчен *уратма* җирле географик термины белән *Югары Уратма, Түбән Уратма* (Түбән Кама районы) барлыкка килгән.

Фарсы чыгышлы *чишмә* гидрографик терминына нисбәтле авыл атамалары: *Чишмә* (Әгерҗе, Мөслим, Нурлат, Актаныш районнары); *Чишмәбаш* (Актаныш, Кукмара районнары); *Акчишмә* (Әлмәт, Арча, Ютазы районнары).

Татар телендә киң кулланылышка ия булган *күл* «бөтен яктан да ярлар белән уратып алынган табигый сулык» гидрографик терминына нигезләнеп Татарстан ойконимиясендә байтак кына авыл исемнәре ясалган. Мәсәлән: *Аккүл-Буа* (Лениногорск районы), *Аккүл-Бигәнәй* (Саба районы), *Акса Күл* (Ютазы районы), *Каракүл Күл* (Биектау, Әлки, Минзәлә районнары); *Каенлы Күл*, *Камышлы Күл, Сасы Күл, Кәкре Күл* (Азнакай районы), *Каклы Күл* (Ютаза районы), *Көмеш Күл* (Мамадыш районы), *Табанлы Күл* (Актаныш районы), *Кушкүл* (Кайбыч районы), *Иске Баллы Күл, Яңа Баллы Күл* (Әлки районы), *Күлле Киме* (Әтнә районы), *Күл Черкен* (Буа районы), *Күлбаш* (Яшел Үзән районы), *Якты Күл* (Азнакай, Баулы районы) һ.б.

2) *оронимик терминнарга нигезләнеп барлыкка килгән атамалар* гадәттә территориянең нинди дә булса географик үзенчәлеген чагылдыра.

*Тау* орографик термины Татарстан ойконимиясендә киң кулланылышка ия. *Тау* терминына нисбәтле *Биектау* районы үзәге, *Биектау, Актау, Күктау, Печмәнтау, Кызыл Тау, Кала Тау, Кырынтау, Таузар, Тау Иле, Тау асты Байлар, Тау асты Тәкермән, Таулы Дөреш, Куштау, Яулаштау, Таулык, Таукирмән, Чияле Тау, Якты Тау* һ.б. авыллары барлыкка килгән.

Г.Ф. Саттаров, «Казан татарларының кан кардәш бабалары Идел–Кама болгарлары телендә *тау* орографик термины “тау” төшенчәсен белдерү белән бергә, күчерелмә мәгънәсендә, хәрби максатлардан чыгып, тау өстенә салынган кальга-крепостьне, ягъни кала-шәһәрне белдерү өчен дә хезмәт иткән булырга тиеш. Идел-Кама болгарларының *Җүкәтау, Тубылгытау* (Хәзер *Тубылгы Тау* авылы Чистай районында), *Чаллытау* (болгар телендә *чаллы* «ташлы» + *тау*) *Калатау, Сарытау* (Саратов) һ.б. кебек кальга-шәһәр атамалары шулай уйларга тулы мөмкинлек бирә», ди (Саттаров, 1998: 79).

Азнакай районындагы *Актүбә* торак пункты исеме *түбә* терминына нисбәтле барлыкка килгән. Урал татарлары һәм минзәлә сөйләшләрендә «тау башы»н, «тау түбәсе»н *түбә* сүзенә бәйле аңлаталар. *Ташлы түбә* (Азнакай районы) дигән авылның исеме борынгы төрки телдәге *таш* + *түбә*, ягъни «ташлы тау» дигән мәгънә белдерә.

*Ташкабак* (Югары Ослан районы) *таш* + *кабак* «елга буендагы биек ташлы тау» мәгънәсен аңлата.

Татар телендә «дала, тигезлек, басу-кыр» мәгънәсендә йөргән *йаз* сүзе кулланылган. Аның генезисы борынгы төрки телдәге *йази* «степь, равнина» сүзенә кайтып кала (ДТС, 1969: 25). Г.Ф. Саттаров, борынгы төрки *йази* сүзенең тамыры *яз* «җәй, язылдыр, җәелдер, киңәйт» фигыленә кайтып кала, ди (Саттаров, 1998: 54).

Татарстанда *йаз* терминына нисбәтле *Әйшияз* (Әтнә районы) гарәп теленнән кергән хатын-кыз исеме *Әйшә* > *Гайшә* «яшәүчән» + *йаз* «кыр-басу»; *Дөбъяз* (Биектау районы) *дөп/төп* «үзәк» + *йаз* «кыр-басу»; *Олыяз* (Биектау, Кукмара, Мамадыш, Саба районнары), *олы* «зур» + *йаз* «кыр-басу»; *Арпаяз* (Кукмара районы) *арпа* + *йаз* «кыр-басу»; *Толкияз* (Питрәч районы) чувашча *тула/талкы* «бодай» + *йаз* «кыр, басу»; *Атияз* (Алабуга районы) марича *аты* «куаклык, агачлык, урман» + *йаз* «кыр-басу»; *Язлы Арташ* (Саба районы) *язлы* «кырлы, басулы»; *Борчаклы Яз* (Теләче районы)

«борчак басуы, кыры»; *Солояз* (Бөгелмә районы) «солы басуы»; *Торнаяз* (Биектау районы) «торна басуы» дигән авыллар барлыкка килгән.

Урман эчендәге табигый ачык урын – аланга килеп утырып, нигезләнгән авылларга *алан* топонигезле исемнәр кушылган. Мәсәлән: *Алан* (Арча, Балтач, Мамадыш, Саба, Теләче, Түбән Кама районнары); *Алан-Елга, Йосыф Алан* (Саба районы); *Алан Җөри* (Теләче районы); *Алан-Полян* (Балык Бистәсе районы); *Алан-Бексер* (Биектау районы); *Зур Алан* (Әлки районы); *Рәхмәтулла Аланы* (Мамадыш районы) исемле байтак кына татар һәм рус авылларының исемнәре барлыкка килгән.

*Поташ Аланы* (Әлмәт районы) инглиз теленнән кергән *поташ* «үсемлекләр көленнән, калий тозларыннан торган селтеле каты ак матдә» (ТТАС, 2005: 424), ягъни «поташ минералы күп булган алан» дигән мәгънә белдерә.

3) *фитонимик терминнар ярдәмендә ясалган атамалар.*

Татарстан авыллары исемнәре фитонимик терминнарга – нинди дә булса үсемлек атамаларына нигезләнеп барлыкка килгәннәр. Авыл исеме территориядә күпләп үскән агачларга бәйле булырга мөмкин. Бу очракта, билгеле бер төбәктә теге яки бу әйбернең тупланганлыгын, күп булып үсүен, булуын, җыелмасын белдерә торган төрки-татар чыгышлы *-лык*, *-лы* (иран реликты *-сар/-сәр*) кушымчалары теге яки бу агач атамасына ялганып, шул төр агачның күп булып үсә торган урынын, җыелма төшенчәсен белдерә.

Агач һәм агачлыкларны белдерүче геоботаник терминнардан ясалган авыл исемнәре: *Түбән Чыршылы* (Лениногорск районы); *Юкәле авылы* (Әлмәт районы); *Таллы Бүләк авылы* (Азнакай районы) «*таллы әрәмәлек*»; *Зирекле* (Арча, Чистай районнары); *Зирекле Елга* (Азнакай районы); *Карагай* (Лениногорск районы); *Карамалы* (Азнакай, Әлки районнары); *Карамалы Елга* (Азнакай районы); *Олы Карамасар* (Апас районы); *Чыршы* (Алабуга, Биектау районнары); *Наратлы* (Азнакай, Әлмәт, Бөгелмә, Минзәлә районнары); *Наратлы Кичү* (Минзәлә районы); *Нарат* (Яшел Үзән районы); *Тубылгы Тау* (Яңа Чишмә районы); *Имәнкискә* (Лаеш районы) *имән* + *кискә* татар теленең урта диалектында *кискә* «киселгән урман урыны» (Татар теленең диалектологик сүзлеге, 1993: 174); *Печмәнтау* (Арча районы), *Солдат Писмәнкәсе* (Бөгелмә районы) минзәлә һәм казан арты сөйләшләрендә киселгән урман

урынын белдерү өчен *печмән/песмән* термины кулланылган; *Имәнле* (Мөслим районы); *Шикәрле Каен* (Минзәлә районы); *Кыр-Каен Түбә* (Актаныш районы); *Каенлы* (Түбән Кама районы); *Каенлык* (Актаныш, Кукмара районнары); *Каенсаз* (Мөслим районы); *Каенсар* (Арча, Әтнә, Балтач, Кукмара районнары); *Яңа Каенсар, Иске Каенсар* (Кукмара районы) һ.б.

Куаклыкны һәм аның төрләрен белдерүче геоботаник терминнардан ясалган авыл исемнәре: *Куакбаш, Иске Куак* (Лениногорск районы); *Кушкуак* (Чүпрәле районы); *Баланлы* (Азнакай, Буа, Бөгелмә, Мөслим районнары); *Балан Бүләк* (Азнакай районы); *Тойма* (Менделеевск районы) борынгы төрки телдә *тойма* «түбән урындагы чытырман, куелык» (Закиев, 1986: 34); *Шыгай* (Апас, Сарман районнары) гөлҗимешне сергач сөйләшендә *шыгай*, нократкистем һәм казан артының лаеш сөйләшендә *шыган* диләр; *Чиялек* (Актаныш районы); *Чиялетау* (Лениногорск районы); *Чия Түбә (Чияле)* (Мөслим районы) һ.б.

Иген-ашлык исемнәреннән ясалган геоботаник терминнардан ясалган авыл исемнәре: *Арпаяз* (Кукмара районы); *Иске Арыш, Яңа Арыш* (Балык Бистәсе р.); *Солыяз* (Бөгелмә р.) һ.б.

Үләннең төрләрен белдерүче терминнардан ясалган атамалар: *Киндерле* (Биектау районы); *Киндер Күл* (Кукмара районы); *Камышлы* (Азнакай, Кукмара районы); *Камышлы Күл* (Азнакай районы), *Камышинка* (Зәй районы); *Камыш* (Питрәч районы) һ.б.

Җимеш төрен белдерүче терминнан *Алмалы* (Арча, Зәй районнары); *Алма-Ата* (Ютазы районы) авыл исемнәре барлыкка килгән.

4) *зоонимик терминнар нигезендә барлыкка килгән атамалар.*

Фауна, ягъни хайваннар дөньясы, табигать, кеше, географик мохит белән тыгыз мөнәсәбәттә яши, боларның үзенчәлекле бер состав өлешен тәшкил итә. Шуңа күрә авыл атамаларының барлыкка килүе фаунага да бәйле. Татарстан территориясендә бу терминнарга нисбәтле авыл исемнәре артык күп түгел. Кайбер зоонимик терминнарга мөнәсәбәтле атамалар кеше исемнәре һәм этнонимнардан авыл исемнәренә күчнәннәр.

Татарстанда зоонимик терминнарга, ягъни хайван, балык исемнәренә бәйле рәвештә *Колын* (Актаныш районы); *Күк Тәкә* (Азнакай районы); *Борындык* (Кайбыч районы); *Илексез* (Сарман районы) *илек* «кыр кәҗәсе, урман кәҗәсе»; *Чебакса* (Биектау рай-

оны) *чебак/чабак* «вак балык» дигән авыл исемнәре бар. *Керкәле Тукмагы* (Лениногорск районы) авылы атамасының беренче компоненты *керкә* «форель» балыгы атамасына мөнәсәбәтле + *-ле* ия булу кушымчасы. Минзәлә сөйләшендә кыска елганы яки инешне белдерү өчен *тукмак* сүзе кулланыла. Бу атама керкәле балыгының күп булуына ишарә ясый. Биектау районында *Кондырлы* дигән инеш һәм татар авылы бар. Инештә *кондыр/кондыз* күп булганга, бабаларыбыз тарафыннан башта инешкә бирелгән, аның буенда барлыкка килгән авыл исеменә күчкән.

5) *географик объектның искелеген-яңалыгын, урнашу урынын белдерүче сүзләрдән ясалган ойконимнар.*

Географик объектның искелеге яки яңалыгы *иске – яңа* антонимик парлы сыйфатлары белән белдерелә.

Ойконимиядә торак пункт атамаларын беренчел (база, төп) итеп һәм яңаларга аерып карау кабул ителгән. Составында *иске* компоненты булган ойконимнарны беренчел (база, төп), ә *яңа* сүзе кергәннәрен яңа торак пунктлар дип атыйлар. Шулай ук яңа торак пункт барлыкка килгәнче, беренчел атама составында *иске* компонентының булмау мөмкинлеген дә искәртү кирәк. Әлеге компонент база атаманың яңасыннан аермасын күрсәтү өчен дә кертелә ала.

Авыл атамалары составында *иске – яңа* сүзләре еш очрый: *Иске Арыш – Яңа Арыш, Иске Шәйморза – Яңа Шәйморза, Иске Имән – Яңа Имән, Иске Әхмәт – Яңа Әхмәт, Иске Каразирек – Яңа Каразирек, Иске Шөгер –Яңа Шөгер, Иске Комазан – Яңа Комазан* һ.б.

Татарстанда *яңа* компонентлы168 атама, *иске* компонентлы 181 авыл исеме барлыкка килгән (Населенные пункты..., 1997: 339–344; 358–364).

*Баш, тамак* (анатомик) терминнары катнашып ясалган атамалар бу объектның икенче бер географик объектның (елганың, күлнең) башына, башланып киткән җиренә яки азагына, тамагына урнашуын белдерәләр.

Татарстан ойконимиясендә, географик объектның башланып киткән җиренә утыруыннан чыгып, «елга атамасы + *баш/башы* төзелмәсеннән гыйбарәт авыл исемнәре бар: *Куакбаш* (Лениногорск районы), *Мортышбаш* (Сарман районы), *Шушмабаш, Шурабаш, Симетбаш, Казанбаш, Ашабаш, Ашытбаш, Күпербаш, Сәрдәбаш, Орнашбаш* (Арча районы).

*Тамак* терминына нисбәтле: *Кама Тамагы* районы, *Сазтамак* (Кукмара районы), *Мортыш Тамак* (Сарман, Минзәлә районнары), *Бәйрәкәтамак* (Ютазы районы) авыл атамалары барлыкка килгәннәр.

Татар ойконимиясендә *югары, урта, түбән* компонентлы атамаларның булуын территориядә утрак тормыш алып баруга этәргеч булган эре су объектларының күплеге һәм, шул рәвешле, киңлекнең елга агымы юнәлеше буенча үзләштерелүенә бәйләп карыйбыз. Татарстан ойконимиясендә югары, урта, түбән урын рәвешләре катнашып күп кенә авыл атамалары барлыкка килгән: *Югары Аты – Урта Аты – Түбән Аты; Югары Сәрдә – Урта Сәрдә – Түбән Сәрдә; Югары Пошалым – Урта Пошалым – Түбән Пошалым, Югары Мәтәскә – Түбән Мәтәскә, Югары Әйшә – Түбән Әйшә, Югары Ат – Түбән Аты* һ.б.

Татарстанда *югары* сүзеннән – 97, *урта* сүзеннән – 34, *түбән* сүзеннән – 86 авыл атамасы барлыкка килгән (Населенные пункты..., 1997: 300–303, 336–338, 357–358).

*Олы – кече* антонимик терминнары белән *Олы Кавал – Кече Кавал, Олы Өтәк – Кече Өтәк, Олы Дүртиле – Кече Дүртиле, Олы Шәле – Кече Шәле, Олы Әтнә – Кече Әтнә* һ.б. авыл исемнәре барлыкка килгән. Олы сүзе белән 90 атама, кече сүзе белән 59 авыл атамасы барлыкка килгән (Населенные пункты..., 1997: 294–297, 328–330).

Парлары белән туры килми торган үзенчәлекле исемнәр тәшкил итүче атамалар бар: *Иске Кырлай – Кече Кырлай, Олы Мәңгәр – Кече Мәңгәр, Олы Мәтәскә – Югары Мәтәскә, Иске Муй – Кече Муй, Иске Шырдан – Олы Шырдан, Зур Елга – Елга, Иске Төбәк – Төбәк* һ.б.

6) *географик объектның төсен белдерүче сүзләрдән ясалган ойконимнар.*

Ялгызлык исемнәрендә кулланылган төсләр татар халкының дөньяга карашын, милли күзаллавын, мәдәни, мифик, иҗтимагый-тарихи һәм башка шартларның тәэсирен аеруча ачык чагылдыра.

Татар телендә, гомумән төрки телләрдә, ялгызлык атамаларын ясауда төс белдерә торган сүзләрдән иң активлары антонимик *ак* һәм *кара* сүзләре, алардан кала кызыл, сары, коңгырт, яшел, күк, зәңгәр сыйфат сүзләре урын ала. Барысы бергә ономастикада төсләр чагылышының тулы бер җыелмасын, үзенчәлеген барлыкка китерәләр.

Татарстанның авыл атамалары түбәндәге төсләр белдергән сүзләрдән барлыкка килгәннәр:

*Ак* сүзе: *Аккүл, Акмәчет, Аксай, Аксу, Актау, Актүбә, Акчишмә, Акъюл* – Татарстандагы авыл атамалары.

*Кара* сүзе, төсне белдерүдән тыш, күп кенә өстәмә мәгънәләргә дә ия. Байтак кына кеше исемнәре составындагы *кара* сүзе «муллык-байлык» теләүне чагылдыра дип карала. Г.Р. Галиуллина борынгы-төрки татар кеше исемнәрендә кара төснең «бөек, кодрәтле, көчле» кебек мәгънәләрне символлаштыруы турында яза (Галиуллина, 2008: 94).

Татарстанда исемнәре составында *кара* сүзе булган ике дистәдән артык авыл бар. Мәсәлән, *Карадуган, Кара Елга, Каракүл, Каракитә, Каратун, Кара Чишмә, Караширмә, Карашәм, Карача, Каратай, Каратал, Каратмән* һ.б.

*Күк* сүзе: *Күкчә* (Теләче районы), *Күкчә Бирәзә* (Арча районы), *Күкчишмә* (Мамадыш районы).

*Кызыл* сүзе белән *Кызылъяр* (Арча, Баулы, Балык Бистәсе, Түбән Кама, Чирмешән, Югары Ослан, Алабуга, Саба районнары), *Яңа Кызылъяр, Иске Кызылъяр* (Әгерҗе районы), *Кызылтау* (Апас районы), *Кызыл Мишә* (Саба районы), *Кызыл Чапчак* (Түбән Кама районы), *Кызыл Яшьләр* (Питрәч районы). *Кызыл Кичү* (Ютазы районы), *Кызыл басу* (Ютазы районы), *Кызыл Болгар* (Чистай, Биектау районы), *Кызыл Игенче* (Арча районы), *Кызыл Ил* (Лаеш районы), *Кызыл Көч* (Әлмәт районы), *Кызыл Күл* (Биектау районы), *Кызыл Таң* (Яшел Үзән районы), *Кызыл Төбәк* (Минзәлә районы), *Кызыл Уракчы* (Алексеев районы), *Кызыл Утар* (Әтнә районы), *Кызыл юл* (Зәй, Нурлат, Тукай районнары), *Кызыл Ялан* (Чистай районы), *Кызыл байрак* (Югары Ослан, Тукай районнары), *Кызыл Чишмә* (Чирмешән районы), *Кызыл бакча* (Сарман районы), *Кызыл Йолдыз* (Азнакай районы) һ.б. авыл исемнәре барлыкка килгән.

7) *символик атамадан гыйбарәт исемнәр.*

Билгеле булганча, XX гасыр башында Совет хакимияте урнашканнан соң Идел буе территорияләрендә 1918–1930 елларда массакүләм колхозлаштыру хәрәкәте бара. Күп кенә колхоз, совхозлар барлыкка килә. Төрле авыл кешеләре, яңа җирләргә күчеп, яңа торак пунктларын нигезләгәннәр. Әлеге торак пунктларының атамалары гадәттә идеологик фикерләүгә бәйле рәвештә кушыла торган булган.

Татарстанның күп кенә авыл исемнәре яңа, социалистик тормыш идеяләрен чагылдыра һәм совет символикасы белән бәйле рәвештә кушылган. Мондый сүзтезмәләрнең беренче компоненты булып *кызыл, якты, яшь, көчле, яңа, ирек, ирекле* сыйфатлары кулланыла. Мәсәлән, *Кызыл-көч* (Әлмәт районы); *Кызыл Юл* (Зәй, Нурлат, Тукай районнары); *Кызыл Игенче* (Арча районы); *Кызыл Ил* (Лаеш районы); *Кызыл Яшьләр* (Питрәч районы); *Кызыл Йолдыз* (Азнакай районы); *Кызыл Сукачы* (Азнакай районы) авыллары атамалары дәүләтнең кызыл әләме, революция төсе, йолдыз билгесе белән аваздаш. Татарстанның *Яңа Тормыш, Яңа Бүләк, Яңа Көн, Яңа Көч, Яңа Юл, Яңа Урал, Якты Көн, Якты Елга, Якты Тау, Якты Юл, Якты Ялан, Көчле Бүләк, Көчле Ирек, Ирек Таңы* һ.б. авылларының исемнәре күбесе колхозлашу чорында барлыкка килгәннәр.

*Таң, Ирек, Азат, Алга, Бакча, Берлек, Хөррият, Байрак, Мәйдан, Эшче, Ватан, Яшьләр, Ялкын, Алмалы, Ярдәм, Яңалиф, Гөлбакча* авыллары исемнәренең мәгънәви эчтәлекләре күмәклек сүзләрне ойконимлаштыру нәтиҗәсендә барлыкка килгән.

Беренче Май, капитализмны җиңүгә бәйле булган дәүләтнең рәсми бәйрәмнәре белән *Первое Мая*, *Победа*, *Октябрь* авыллары атамалары аваздаш.

Татарстанның көнчыгыш районнарындагы *Кызыл Бүләк, Яңа Бүләк, Көрәш Бүләк, Көчле Бүләк* авыл исемнәрендә *бүләк* сүзенең яңа төшенчә – социалистик инкыйлаб, юлбашчы, яңа җәмгыять, тормыш бүләге дигән мәгънә белдерүе сизелә.

Совет кешесенең тырышлыгы, эшчәнлеге, үрнәк булуына ишарә ясый торган *Тырыш* (Азнакай районы), *Үрнәк-Күмәк* (Лениногорск районы) авыллары атамалары барлыкка килгән. *Үрнәк-Күмәк* авылы атамасы күмәк хуҗалык күренешен чагылдырып кушылган исем санала.

2. Онимнар нигезендә барлыкка килгән атамалар. Бу төркем түбәндәге төркемчәләргә бүленә:

*1) антропонимнарга нигезләнеп барлыкка килгән атамалар.*

Татар ойконимнарының иң зур күпчелеге антропонимнарга нигезләнеп барлыкка килгәннәр. Кеше исемнәренең барлыкка килүе, үсеш-үзгәреше җәмгыятьнең социаль-тарихи һәм мәдәни-идеология эволюциясе, иҗтимагый-икътисади күренешләр белән тыгыз бәйләнгән.

Борынгы төрки чыгышлы кеше исемнәренең барлыкка килү мотив-чыганаклары болгар-татарларда балага исем кушу белән бәйләнешле шул чордагы борынгы ышануларга, йолаларга һәм традицияләргә нисбәтле булган.

Болгар-татарларда, эт культы, эт тотемына нисбәтле рәвештә һәм ир бала талымсыз, авыруларга бирешми торган булсын дигән теләктән чыгып, «эт» мәгънәсенә ия булган сүзләрне кеше исеме итеп бирү йоласы булган. Шушы йола аркасында борынгы телебездә «эт» төшенчәсен белдерә торган *көчек~коцок, канчык, әнчек, ногай, әнәк, әгер, йыт, барак, көпәк~күбәк* сүзләре кеше исеме булып та йөргәннәр. Татарстан Республикасының Кукмара һәм Әгерҗе районнарындагы *Көчек* дигән татар авыллары атамасының асылында да болгар-татарларның *Көчек* исеме ята. *Көчек* исеменнән Казан татарларында *Көчеков* фамилиясе ясалган.

Болгар-татарларда ир баланың кыю, батыр һәм җитез булуын теләп ау кошы атамасын исем итеп кушу йоласы булган. *Шоңкар* «лачынның бер төре» исеменең фонетик үзгәреш кичергән *шыңар* вариантыннан Татарстанның Саба районындагы *Олы Шыңар, Кече Шыңар* авылларының исемнәре барлыкка килгән.

Баш мәҗүси алла, тәңре яши торган урын – *күк* термины күк гөмбәзенең төсенә мөнәсәбәтле рәвештә барлыкка килгән.

*Күгеш* дигән борынгы-төрки-татар кеше исеме күп мәгънәле. Аның килеп чыгышы 1) *күк иш* > күгеш, күк ише, изге җан; 2) ирекле, хөр иш (ярдәмче, бала); 3) яшел иш, яшь иш (бала); 4) *күгү* («аккош») + *иш* («бала») рәвешле карала. Беренче мәгънәгә нисбәтле *Күгеш* (Яшел Үзән районы) дигән татар авылы исеме барлыкка килгән.

Ата-баба культы туганлык терминнарын яңа туган балага үзләрен генә исем итеп бирү яки, антрополексема булып, кушма төзелешле исем составында урын алу очракларында да чагылыш таба. Боларга төрки-татар чыгышлы ата һәм баба туганлык терминнарына һәм туганлыкны белдергән башка терминнарга нигезләнеп ясалган кеше исемнәре карый: *Атабай* исеме Татарстанның Лаеш һәм Кама Тамагы районнарындагы *Атабай* дигән татар авыллары атамасында сакланган. Лаеш районындагы Атабай авылының Казан ханлыгы чорында ук булуы документаль мәгълүм. Тау ягындагы *Азбаба* һәм *Албаба* авылларының Казан ханлыгы чорында булулары билгеле.

Саклау (профилактик) исеме сүзнең магик көченә ышанып, бала яныннан усал көчләрне куркытып качыру нияте белән кушылган борынгы исемнәргә карый. Әгерҗе районында *Саклау* авылы бар. Профилактик исемнәрнең бер төре тискәре мәгънәле сүзләргә нигезләнеп барлыкка килгән.

Борынгы заманнарда төрки халыклар, усал көчләрне, җен-пәриләрне куркыту, яңа туган сабый янына аларны якын җибәрмәү максатыннан чыгып, ир балаларга *Ачи (Ачы)* исеме биргәннәр. Республикабызның Саба районында *Ачы, Югары Ачы*, Түбән Кама районында *Ачи* дигән рус авыллары бар.

Татарларның борынгы кәсеп-һөнәрләре аучылык, терлекчелек һәм игенчелек булган. Балыкчылык кәсебенә нисбәтле рәвештә борынгы заманнарда ук *Балыкчы* исеме барлыкка килгән. Татарстанда Апас районында *Болын Балыкчы, Шәмбалыкчы* (Апас районы) дигән татар авыллары бар. Казан ханлыгы чорында Нугай юлы өстендә *Балыкчы* дигән татар авылы булган.

Игенчелек кәсеп-һөнәренә нисбәтле рәвештә *Сабанчы* (Әлмәт районы) *сабанчы* «сабан сөрүче»; *Бөрсет Сукачы* (Мамадыш районы), *Кызыл Сукачы* (Азнакай районы) *сукачы* «сука сукалаучы»; *Кызыл Уракчы* (Алексеев районы), *Уракчы* (Балык Бистәсе районы) *уракчы* «урак уручы»; *Югары Ындырчы* (Апас районы) «ындырда ашлык сугучы» кебек борынгы исемнәр барлыкка килгәннәр.

*2) этнонимнар нигезендә барлыкка килгән атамалар.*

Татарстан территориясендә күп төрле төрки һәм төрки булмаган кабилә, халыклар яшәгән һәм аларның байтагы ойконимнарда чагылыш тапканнар.

Мамадыш районында урнашкан *Югары Сон, Кече Сон, Урта Сон, Яңа Сон, Түбән Сон* авылларының этимологиясе *һун~сөн* этнонимына белән бәйле. Борынгы тарихи чыганакларда да ул *Сон* дип язылаа.

Һуннар-сөннәр, башка көчле төрки кабиләләр кебек үк, берничә мең еллар элек Евразиянең бик күп географик зоналарына таралып, башка кабиләләр белән аралашып яшәгәннәр. Беренче язмаларга алар б.э.к. II–III меңьеллыкларда *уну* исеме белән теркәлгәннәр.

Г.Ф. Саттаров *Күн* (Питрәч районы) авылының атамасын *һун* этнонимы белән бәйли (Саттаров, 1973: 93).

Тау ягындагы *Иске Бортас, Бортас* авыллары атамаларын *бортас* этнонимы белән аңлатабыз. Татарларның төп компоненты

булган болгарлар, анда катнашкан кыпчаклар һәм аларның гадәти төрки телле күршеләре тирәсендә *бортас* дигән кабилә берләшмәләре булган. Бортаслар тарихларын X йөздән алып XVII йөзгә кадәр күзәтеп була. Шуннан соң *бортас* сүзе этноним буларак югала, топонимикада гына сакланып кала (Попов, 1973: 112). Кыпчаклар килгәч, бортаслар Идел буеннан төрле урыннарга таралалар. Алар кыпчакларга, нугайларга, болгарларга, мишәрләргә кушылып китәләр.

Татарстанның Апас районында *Зур Болгаер, Кече Болгаер* авыллары, Лениногорск районында Болгар авылы бар. Әлеге атамаларны борынгы төрки болгар кабиләсе белән аңлатабыз.

Урта Идел буенда төзелгән Болгар дәүләте составындагы кабиләләр арасында болгарлар әйдәп баручылар булалар.

X йөз башында гарәп тарихчысы Ибне Рустә болгарларны өч төркемнән тора дип билгели: берсула, эсегел, болгар. Өчесенең дә тормышлары, көнкүрешләре бер үк дәрәҗәдә, ди (Хвольсон, 1868: 668). Болгар дәүләтендә суар, темтюз, сабакүл, бортас, башгард, һ.б. кабиләләр дә яши.

Г.Ф. Саттаров *болгар* этнонимын, *булуг-ар/булугар* төзелешен тәшкил итә һәм «булган ир, булган кеше, булдыклы кабилә, халык» мәгънәсен аңлата, ди. Галим борынгы төрки телдә *булуг* сүзенең 1) почмак, 2) дөнья кисәге, 3) край мәгънәләрен белдерүен һәм, *ң – г* тартыкларының тарихи күчеше закончалыгын күздә тотып, булгар-болгар этнонимы *булуң* «почмак, дөнья чиге, край» һәм *ар* «ир, ир кеше», шуннан «ил чигендәге, кырыендагы кабилә, халык» мәгънәсен аңлата һәм *булуңар – булугар – булгар – болгар* рәвешле фонетик үзгәреш кичергән дип карый (Саттаров, 1973: 143).

Шулай итеп, Татарстан ойконимнарының номинацияләү принциплары һәм аларны лексик-семантик яктан анализлау нәтиҗәләре географик атамаларның тарихи чыганак булып торуларын дәлилли. Торак пункт атамасын сайлау мәсьәләсе, тулысынча диярлек, атау мотивына тәэсир иткән экстралингвистик һәм тарихи сәбәпләргә бәйле.

Татар ойконимнарының күпчелеге антропонимнарга – кеше исемнәренә, кушаматларына, тотем атамаларына, нигезләнеп барлыкка килгән. Бу күренеш төбәк халкының үсеше, көнкүреше, гореф-гадәтләре, хуҗалык итү үзенчәлекле, башка халыклар белән булган мөнәсәбәтләре хакында фикер йөртүгә юл ача.

Тарихи халык күчешләре турында мәгълүматлар җиткергән этноойконимнар милли тарихны, төрки халыкларның этнографиясен өйрәнүдә файдалы мәгълүматлар чыганагы булып торалар.

Татарстан авылларының күпчелеге борынгы чорларда барлыкка килгәннәр. Моны археологик, тарихи материаллар раслый. Шулай ук колхозлашу елларында шактый авыллар нигезләнгән һәм бу авыллар статистик мәгълүматлар буенча бетеп бара.

## § 25. Татар ойконимнары төзелеш-ясалышында төп үзенчәлекләр

Сүз ясалышы һәм аның төзелешен анализлау географик атамаларны тикшерүнең мөһим аспектларыннан берсе санала, чөнки ойконимнарның төзелеш-ясалыш ысулларын тикшерү ономастика фәне өчен генә түгел, гомумән алганда, лингвистика өчен дә гаять зур әһәмияткә ия. Ойконимнарның ясалыш закончалыкларын билгеләү, аларның төп структур типларын күрсәтү географик атамаларның грамматик төзелешен, этимологиясен ачыкларга, чит телдән кергән ойконимнарны җирле атамалар составыннан аерып чыгарырга мөмкинлек бирә. Ойконимнарның төзелеш-ясалышын билгеләү ярдәмендә без атамаларны тикшерүне синхрон һәм диахроник аспектларда дәвам итә, ягъни чыганак-телне һәм атамаларның килеп чыгышын ачыклый алабыз.

Ономаст-галимнәр төрки ойконимнарның структур типларын тикшерүгә төрлечә якын киләләр. Төрки материалга нигезләнгән ойконимнарның классификациясе, беренче чиратта, нигез һәм сүз ясалышы модельләренә таянып башкарыла.

Географик атамалар телнең сүз ясалыш калыпларына нигезләнеп барлыкка киләләр, ләкин ялгызлык исемнәрнең ясалышында «барлык сүз ясалышы чаралары түгел, ә аерым бер җирлектә кабул ителә алган, катгый билгеләнгән калыплар гына кулланыла ала» (Суперанская, 1969: 89). Ойконимнарның ясалу ысуллары һәм чаралары һәр телдә гомуми кагыйдә-нормаларга буйсындырылган. Шулай итеп, татар ойконимнары татар теленең сүз ясалыш калыпларына нигезләнгән.

Төзелеш-ясалыш ягыннан төрки-татар ойконимнарын ике төркемгә бүлеп тикшердек:

1. Г а д и  о й к о н и м н а р. Гади ойконимнар а) тамыр һәм ә) ясалма төркемчәләргә бүленә.

2. Катлаулы төзелешле ойконимнар. Катлаулы төзелешле атамалар ике, өч һәм аннан артык нигездән торалар. Түбәндә әлеге төркемнәрне карап китик.

1. *Гади атамалар:*

1) *тамыр ойконимнар* кулланылышта еш очрый: *Ык* «елга» (Ютазы районы), *Йолдыз* (Азнакай, Югары Ослан районнары), *Түке* «ташбаш, комкорсак» (Актаныш районы)*, Тәмте* «төрки этноним *темтюзи*» (Теләче районы), *Ачы* (Теләче районы), *Батыр* (Аксубай районы), *Үби* «упкын» (Чүпрәле районы), *Чыршы* (Алабуга районы), *Байрак* (Зәй районы), *Үрнәк* (Яшел Үзән районы), *Чүти* «нур» (Кайбыч районы), *Алан* (Арча, Балтач районнары), *Ябалак* (Апас районы) һ.б.

Күпчелек гади ойконимнар тезмә ойконимнарның бер өлешен кыскарту нәтиҗәсендә барлыкка килгән трансформацияләү процессы нәтиҗәсе булып та тора. Әлеге ысул ярдәмендә ойконимик берәмлекләр беренчел мәгънәләрен югалта. Атама «составыннан исемнең исем буларак кулланылуына зыян китермәгән артык компонентларны юк итү исәбенә кыскартыла» (Суперанская 1972. 346). Мәсәлән: *Әйшә* < *Гайшәбикә* (гар. *Гайшә* «тере, яшәүчән» борынгы төрки-татар + *бикә* «хуҗа хатын; аксөяк хатын-кыз, ханым»); *Бишнә* < *Биек ышна* (төрки-татар *биек* + *ишнә/ышна* «урман чәчүлек өчен төпләнгән, әрчелгән җир, ышна»); *Мәмәт* < *Мөхәммәт* (гарәп «мактаулы, данлыклы; ислам диненә нигез салучы»); *Норлат* < *Нурдәүләт* (гарәп *нор/нур* «нур, яктылык, балкыш» + гарәп *дәүләт* «байлык»; «дәүләт»; «бәхет»); *Мамадыш* < *Мөхәммәтиш* (гарәп *Мөхәммәт* + борынгы төрки-татар *иш* «иптәш, юлдаш, дус»); *Шигали* < *Шаһгали* (фарс. *Шаһ* «хан, патша» + *гали* «бөек», «кыйммәтле») һ.б.;

2) *ясалма ойконимнар.* Татар телендә ойконимнарны ясауда кушымчалау ысулы өстенлек итә. Татар теле продуктив, төрле мәгънә һәм мәгънә төсмерләрен белдереп килә алган сүзләр ясау сәләтенә ия кушымчаларга бай. Әлеге аффиксларның бер өлеше татар ойконимнарын ясауда катнаша. Торак пункт исемнәр составында борынгы төрки телдә һәм иске татар телендә кулланылышта булган кушымчаларның да табылуы табигый күренеш.

Татар ойконимнарының зур күпчелеге тамыр яки нигез сүзгә сүз ясагыч кушымчалар кушылып ясалган.

Тюркологиядә *-чы/-че* кушымчасының килеп чыгышы турында төрле карашлар бар. Н.Ф. Катанов *-чы/-че* кушымчасын [*к*] авазы төшеп калып, *-чик* элементыннан барлыкка килгән, дип исәпли (Катанов, 1903: 172). Г.И. Рамстедт бу кушымчаны, кытай-корея телендәге *-ча* «кеше, зат, ир» сүзеннән килеп чыккан, ди (Рамстедт, 1957: 209). Ф.Ә. Ганиев бу фикернең дөреслеккә туры килүен һәм *-чы* кушымчасы исемнәрнең төрле лексик-семантик төркемнәренә, ягъни ялгызлык һәм уртаклык исемнәренә, конкрет һәм абстракт исемнәргә ялгана алуын белдерә (Ганиев, 2005: 72).

Бу кушымчаның ойконимнарда сүз ясагыч мәгънәсе – эш башкаручы затны белдерү, ул ясаучы нигез тәгъбир иткән корал белән эш итүче затны белдерә: *Бакыр**чы*** «бакыр җитештерүче» (Апас, Яшел Үзән, Тәтеш районнары), *Чир**үче*** иске тат. «гаскәр башлыгы» (Яшел Үзән районы), *Келән**че*** (Кама Тамагы районы), *Сабан**чы*** «җир сөрүче, сабанчы» (Әлмәт, Кукмара районы), *Тимер**че*** (Биектау районы), *Иген**че*** «иген үстерүче» (Мөслим, Тукай районнары), *Япан**чы*** (Әтнә районы), *Яңгыр**чы*** (Балтач районы), *Танга**чы*** (Лаеш районы), *Эш**че*** (Мамадыш районы), *Юкә**че*** (Мамадыш районы), *Телә**че*** (Теләче районы), *Яшә**үче*** (Чирмешән районы), *Урак**чы*** «урак уручы» (Балык Бистәсе, Чистай районнары), *Кибә**че*** «тимер күлмәкләр ясаучы» (Питрәч районы), *Тегермән**че*** (Минзәлә районы) һ.б.

Гомумтөрки *-лы/-ле* кушымчасы һәм аның *-ли/-лу, -ты/-ту, -ды/-ду/-ди* вариантлары ойконимнарда нәрсәнең дә булса җитештерелгән, урнашкан урынын яки предметның барлыгын, күплеген белдерә. Борынгы төрки язма истәлекләрдә *lig* формасында кулланыла (Севортян, 1966: 171–172). Л. Җәләй *-лы/-ле* кушымчасын, *-лык/-лек* кушымчасы белән уртак кушымча булган, ди (Җәләй, 2000: 76).

*-лы/-ле* ярдәмендә түбәндәге татар ойконимнары ясалган: *Балан**лы*** (Алексеев, Азнакай, Мөслим районнары), *Ирек**ле*** (Алексеев районы), *Зирек**ле*** (Алексеев, Яңа Чишмә районнары), *Юкә**ле*** (Әлмәт районы), *Камыш**лы*** (Алексеев, Кукмара районнары), *Карама**лы*** (Азнакай, Әлки районнары), *Камыл**лы*** (Кайбыч районы), *Карга**лы*** (Мамадыш, Чистай, Кайбыч районнары), *Чал**лы*** болг. *чал* «таш» + *-лы* (Кукмара, Кама Тамагы районнары), *Келәт**ле*** рус. *клеть* «кладовая» (Түбән Кама, Биектау районнары), *Шомырт**лы*** (Аксубай районы), *Таш**лы*** (Әгерҗе, Баулы районнары), *Кондыз**лы***

(Әгерҗе районы), *Кондыр**лы*** (Биектау районы), *Ирек**ле**, Камыш**лы**, Сар**лы*** «сазлы», *Үчәл**ле*** (Азнакай районы), *Такта**лы**, Сөнчә**ле*** (Аксубай районы), *Бака**лы*** (Баулы, Әлмәт районы), *Ирек**ле**, Нарат**лы*** (Бөгелмә, Әлмәт районнары), *Алма**лы*** (Арча, Зәй районнары), *Сугыш**лы*** (Бөгелмә районы), *Чыбык**лы*** (Зәй районы), *Балчык**лы*** (Кама Тамагы), *Балык**лы:*** «шәһәр» + *-ле* (Теләче, Кукмара районнары), *Бүкән**ле**, Дегет**ле***, (Мамадыш районы), *Чия**ле*** (Мөслим районы), *Чәчәк**ле*** (Спас районы), *Куак**лы**, Күпер**ле**, Чыршы**лы*** (Тукай районы), *Кычыткан**лы***, *Киек**ле*** (Нурлат районы) һ.б.

*-лы/-ле* кушымчасы һәм аның вариатив формалары булган *-ли/-лу, -ты/-ту, -ды/-ду/-ди* кушымчалары кергән атамалар, төркиләр яшәгән территорияләрдә генә түгел, борынгы заманнарда төрки халыклар яшәгән Кырым, Днепр һәм Дон буенда да теркәлгән. *-лы* кушымчасы һәм аның вариатив формаларының ойконимнар ясалышында катнашу дәрәҗәсе шактый зур. О.Т. Молчанова билгеләвенчә, әлеге аффикс Таулы Алтай ойконимнары ясалышында төп чара булып тора: 754 ясалма форманың 343 е составында әлеге кушымча бар (Молчанова, 1982: 125).

Ойконимнарны ясауда фарсы теленнән алынган *-сар/-сәр* кушымчасы катнаша. Кушымча шушы урында тупланып үскән аерым төр агачларның күп булып үсүен белдерә. Мәгънәви яктан кушымча татар телендәге *-лык/-лек* кушымчасы белән тәңгәл килә. *-сар/-сәр* аффиксы шулай ук, төрки телләр рәтендә булып, фарсы теле йогынтысына дучар булган үзбәк, уйгур, чуваш, казак телләрендә очрый. Мәсәлән, *Каен**сар*** авыллары Арча, Әтнә, Балтач, Кукмара районнарында, *Карама**сар*** Апас районында бар.

*-лык/-лек* кушымчасы нигездә үсемлек, агач һ.б. исемнәргә ялганып, тамырда күрсәтелгән предметларның җыелу, туплану урынын аерып күрсәтә. Татарстан ойконимиясендә *-лык/ -лек* кушымчасы нигездә ясалган түбәндәге ойконимнар бар: *Чия**лек*** (Аксубай районы), *Каен**лык*** (Аксубай, Кукмара районнары), *Нарат**лык*** (Арча, Биектау районнары), *Бер**лек*** «бердәмлек, көч» мәгънәсендә (Бөгелмә районы), *Корт**лык*** «умарта корты» (Кукмара районы), *Тегермән**лек*** (Мөслим районы), *Таш**лык*** (Түбән Кама районы), *Тау**лык*** (Тукай районы).

*-ан/-ән* кушымчалы ойконим һәм гидронимнар төрки һәм төрки булмаган халыклар яшәгән территорияләрдә киң таралыш алган. Күренекле татар ономасты Ф.Г. Гарипова билгеләвенчә,

«*-ан/-ән* кушымчасы ярдәмендә ясалган барлык гидроним һәм топонимнарның да мәгънәсен ачу бик авыр, чөнки алар бик борынгы заманнарда барлыкка килгәннәр» (Гарипова, 1998: 187).

*-ан* кушымчасы ярдәмендә Татарстанның башкаласы *Каз**ан*** шәһәренең исеме (Казан шәһәре атамасының килеп чыгышы турында 20 дән артык аңлатма бар) (Саттаров, 1984: 34–53), *Шур**ан*** удм. *шур* «елга» (Лаеш районы), *Куян [куй**ан**]* (Актаныш районы) һ.б. барлыкка килгәннәр.

Татар ойконимиясендә турыдан-туры антропонимиягә мөнәсәбәте булган *-ган* һәм *-мыш* кушымчалы авыл атамалары бар.

Татар телендә *-ган* кушымчалы фигыль III зат берлек санындагы нәтиҗәле үткән замандагы хикәя фигыль (мәсәлән, *ул бар**ган***) һәм үткән заман сыйфат фигыль формаларын (мәсәлән, *бар**ган** кеше*) белдерү функциясен үти. Бу исә, үз чиратында, фигыльгә туры килгән *Боер**ган**, Үт**әгән**, Тукта**ган**, Сора**ган*** һ.б. типтагы ялгызлык исемнәрдә чагыла. Башлангыч форма буларак *Ходай боерган*, *Ходай үтәгән*, *Үлем туктаган* мәгънәләрендә килгәнлектән, әлеге эллипсислы исемнәрне алда күрсәтелгән фигыль формаларыннан барлыкка килгән дип уйларга була. *Сатыл**ган**, Сора**ган**, Ишәй**гән*** исемнәре III зат берлек санындагы нәтиҗәле үткән замандагы хикәя фигыльдән ясалган булулары ачыклана һәм *Сатылган бала*, *Сораган бала*, *Ишәйгән бала* кебек мәгънәләргә ия булалар. *-ган* формалы фигыльгә нигезләнеп ясалган кеше исемнәре төрле дини йолалар, теләкләр белән мөнәсәбәтле рәвештә барлыкка килгәннәр. Тарихи ономастиконыбызда алар шактый актив кулланылышка ия булганнар (Саттаров, 2010: 25). Бу исемнәр татарларның тарихи антропонимиконында актив кулланылган. Алар антропоойконимнарга нигезләнеп барлыкка килгән авыл исемнәрендә бүгенге көнгә килеп җиткәннәр.

Иске татар телендә үткән заман сыйфат фигыль бүгенге татар әдәби теленә хас булмаган *-мыш* кушымчасы ярдәмендә ясалган. Мондый төр сыйфат фигыльләр нәтиҗәле үткән заман хикәя һәм форма ягыннан III зат берлектә *-мыш* кушымчалы үткән заман сыйфат фигыль белән тулысынча тәңгәл килгән фигыльләр ясау өчен җирлек булып торганнар. Н.Б. Борһанова фикеренчә, иске татар әдәби телендә актив кулланылган *-мыш* аффикслы сыйфат фигыль җанлы сөйләмгә хас түгел (бу тарихның алдагы чорларында ук шулай булган күрәсең). Диалектларда этимологияләре буенча

иске китап теле традицияләренә караган аерым бер гыйбарәләр генә сакланып калган: *картаймыш көн*, *салмыш баш* (Бурганова, 1982: 49). Э.В. Севортян, *-мыш* аффиксын анализлаганнан соң, әлеге аффикс ярдәмендә фигыльләрдән барлыкка килгән исемнәр угыз телләрендә һәм чуваш телендә таралган, дип белдерә (Севортян, 1966: 348).

*-мыш* һәм *-ган* кушымчалары ярдәмендә татар кеше исемнәренә нигезләнеп ясалган авыл исемнәре: *Әлдер**меш*** авылының исеме *Алдыр**мыш*** «алдырмыш бала» (Биектау районы), *Үтә**меш*** «үтәлгән» (Апас, Тәтеш районнары), *Сат**мыш*** «сатылган» (Апас районы), *Кара**мыш*** «туган бала» (Чирмешән районы), *Тукта**мыш*** «үлем яки туу туктамыш» (Биектау, Саба районнары), *Кат**мыш*** «ныгымыш бала» (Мамадыш, Мөслим районнары), *Ата**мыш*** «аталмыш бала» (Арча районы); *Актаныш* > *Аклан**мыш*** (Актаныш районы); *Үтә**гән*** (Әгерҗе районы), *Боер**ган*** (Буа, Тукай районнары), *Бас**кан*** (Мамадыш районы) һ.б. Түбән өлкәсе Табул районындагы бер татар авылы *Сатылган* (русча Медянка).

Тарихчы Һ.В. Йосыпов XIII–XVIII йөзләргә караган болгар кабер ташы язмаларында *Сатылмыш, Туктамыш, Чынмыш, Батамыш* һ.б. исемнәрнең урын алуы турында яза (Юсупов, 1960: 107–108).

Татар телендә беренче киләчәк заман сыйфат фигыльнең барлык формасы *-р* аффиксы, юклык формасы *-мас* кушымчасы ярдәмендә ясала. Әлеге сыйфат фигыль киләчәк заман хикәя фигыльнең нигезен тәшкил итә. Татарстанда урнашкан торак пунктлар атамаларының нигезендә *-р* һәм *-мас* кушымчалы борынгы төрки шәхси исемнәр табыла. Мәсәлән, *Баса**р*** «бала басар, ягъни күп бала атасы булыр, ишле гаиләле булыр» (Сарман районы), *Тукта**р*** «үлем яки туу туктар» (Әлмәт, Саба районнары), *Тыңла**мас*** (Актаныш районы). Хәзерге татар әдәби телендә, башкорт, казак, кыргыз, кумык, төрекмән, үзбәк һәм уйгыр телләреннән аермалы буларак, фигыльдән ясалган шәхси исемнәр чагыштырмача сирәк кулланыла. Алар, нигездә, антропоойконимнар составында сакланып калганнар.

Татар ойконимиясендә күплек сан күрсәткече булган *-лар/-ләр* кушымчасы ярдәмендә ясалган шактый авыл атамасы бар. Билгеле булганча, күплек сан кушымчасы борынгы төрки язма истәлекләрендә бары тик затны белдергән исемнәр белән кулланылган һәм

җыйма мәгънәдә килгән. Географик атамаларның күплек сан күрсәткечләре белән ярашуы төрки телләрдә Ф.Г. Гарипова, Т.Д.Жанузаков, С.М. Молла-заде, О.Т. Молчанова, Н.А. Прманова, Г.Ф. Саттаров һ.б. тарафыннан өйрәнелгән.

Татарстанда *-лар/-ләр* кушымчасына нигезләнеп барлыкка килгән авыл исемнәре: *Тау**лар*** (Балык Бистәсе, Тукай районнары), *Төрек**ләр*** «этноним» (Әтнә районы), *Казак**лар*** «йомышлы» (Арча, Теләче, Биектау, Тукай районнары), *Бай**лар*** «төрки-татар сословие титулы *бай»* (Әлмәт районы), *Морзалар* фарсы чыгышлы сословие титулы *морза/мирза* «аристократ» (Апас районы), *Яшьләр* (Сарман районы) һ.б.

Иркәләү-кечерәйтү мәгънәсен белдергән *-ча/-чә* кушымчасы ярдәмендә *Чекур**ча*** төрки-тат. *чекур/чокыр* «чокыр» (Арча районы); *Ар**ча*** районы исеменнән төрки-тат. *ар/ор/ур* «биеклек» + *-ча* атамалары барлыкка килгән.

*-выч/-веч* кушымчасы фигыль нигезенә ялгана һәм, генетик яктан *-ыч* кушымчасы белән бәйле булып, «нигездә күрсәтелгән хәрәкәтнең урынын белдерә. Бу кушымча ярдәмендә *Кушла**выч*** төрки-татар *кушла/кышла* «кыш чыгу, кышлау» (Арча районы) мәгънәсен аңлаткан атама барлыкка килгән.

*-чык/-чек* кушымчасы исем сүз төркеменә ялганып кечерәйтү мәгънәсен бирә. Татар ойконимнарыннан *Колчык* (Апас районы) төрки-татар *кол/кул* «кечкенә чокыр, ерым, ерынты» атамасы барлыкка килгән.

Анализ нәтиҗәләре күрсәтүенчә, төрки-татар ойконимиясендә *-лы/-ле, -чы/-че* кушымчаларының атамалар составында күп кулланылуы ачыкланды.

Тарихи ойконимиядә фигыль сүз төркеменә *-ган, -мыш* һәм *-р* кушымчалары ярдәмендә кеше исемнәренә нигезләнеп барлыкка килгән ойконимнар булуы ачыкланды. Татарстан Республикасы территориясендә сакланып калган антропоойконимнардан чыгып, мондый исемнәрнең иске татар телендә шактый актив кулланылышы турында фикер йөртергә була.

2. Катлаулы төзелешле ойконимнар. Татар телендә яңа сүзләр ясау аффикслар ярдәмендә генә түгел, сүзләрне кушу юлы белән дә башкарыла. Ф.Ә. Ганиев билгеләвенчә, төрки телләрнең агглютинативлыгы төрки телләрнең абсолют сыйфаты буларак тәкъдим ителә. Телче галимнәр еш кына төрки телләрнең анали-

тиклык сыйфатын игътибарсыз калдыралар. Ул исә телнең грамматик төзелешендә һәм сүз ясалыш системасында әһәмиятле роль башкара. Татар теленең яртыдан артык өлеше аналитик төр буларак тәкъдим ителә, һәм күп кенә грамматик мәгънәләр аналитик формалар аша белдереләләр. Телнең әлеге торышы нәкъ менә шуның белән раслана (Ганиев, 1974: 8).

Гади ойконимнардан аермалы буларак, катлаулы төзелешле һәр атама нигезендә аерым бер географик объект, билгеле бер киңлек эчтәлеге ята. Телдә яшәп килгән географик терминнар, төрле семантикалы лексик берәмлекләр буларак, географик объектларны белдерүдә актив катнашалар. Мәсәлән, ойконимнарда *су, баш, түбән, югары, яңа, иске, иле* һ.б. терминнар актив. Әлеге лексик берәмлекләр шул рәвешле үзләре белдергән мәгънә белән берлектә ойконимнар ясауның мөһим чараларының берсенә әвереләләр. Географик терминнар атамалар составында киләләр. Терминнар индикатор ролен башкаралар.

Синтаксик яктан якын килгәндә, катлаулы төзелешле төрки ойконимнарда һәрвакыт ике компонент аерып чыгарыла: аергыч һәм аерылмыш. Икенче компонент, ягъни аерылмыш – төп ияртүче компонент, беренчесе – аергыч – ияртүче компонент буларак аңлашыла. Катлаулы төзелешле ойконимнарда географик номенклатур термин төп компонент буларак тәкъдим ителә. Катлаулы ойконимнарның әлеге компоненты һәрвакыт исем сүз төркемендәге лексик берәмлек белән белдерелә.

Ойконимнар ясауда беренче һәм икенче төр изафә бәйләнеше аерып чыгарыла. Изафә бәйләнеше төрки телләрнең үзенчәлекле билгеләреннән берсе санала. Ике нигезнең кушылуы һәм морфологик күрсәткечләрдән азат изафә бәйләнешенең беренче кушымчасыз төренә таянып ясалган сүзләр аергыч + аерылмыш калыбына салыналар.

Исемнең исемне янәшә тору чарасы аша ияртүеннән ясалган, изафә бәйләнешенең беренче тибына нигезләнгән ойконимнар бер типологик система тәшкил итәләр. Бу очракта географик объект төгәл термин белән, ә аның төп билгесе объектның характеристикасын тулыландырган бүтән исемнәр белән белдерелә.

Татарстандагы авыл исемнәре арасында бу төр атамалар түбәндәгеләр: *Толкыяз* (Питрәч районы); *Кушелга* (Зәй районы); *Актанышбаш, Илтимер, Чишмәбаш* (Актаныш районы); *Бакчасарай*

(Әлмәт, Тукай районнары); *Зәйчишмә* (Әлмәт районы); *Ашытбаш, Күпербаш, Кышкар, Казанбаш, Сәрдәбаш, Симетбаш, Печмәнтау, Шушмабаш* (Арча районы); *Ташчишмә* (Әтнә районы); *Кенәбаш, Нурмабаш* (Балтач районы); *Солояз* (Бөгелмә районы); *Сарсаз* (Буа районы); *Ташкабак* (Югары Ослан районы); *Айбаш, Ташсу, Торнаяз, Чебакса* (Биектау районы); *Арпаяз, Сазтамак, Чишмәбаш* (Кукмара районы); *Ташкирмән* (Лаеш районы); *Куакбаш, Юлтимер* (Сарман, Лениногорск районнары); *Елгабаш* (Мөслим районы); *Аркатау* (Питрәч районы); *Калатау, Мишәбаш* (Саба районы); *Байрәкәтамак, Димтамак* (Ютазы районы); *Шуширмә* (Кайбыч районы); *Кушкуак* (Чүпрәле районы); *Суелга* (Мамадыш районы); *Субаш* (Теләче районы) һ.б.

Изафә бәйләнешенең беренче тибына нигезләнгән атамалар башка төрки җирлекләрдә дә еш очрый. Топонимистлар казак, азәрбайҗан, шор, Таулы Алтай географик атамаларның шактые бу төр изафәгә нигезләнеп ясалган ди.

Хәзерге төрки телләрдә изафә бәйләнешенең икенче төре аеруча киң таралыш тапкан. Иң мөһим төркем – баш килештәге ияргүче сүз + III зат тартым кушымчасы алган ияртүче сүз. Изафә бәйләнешенең икенче төрендә компонентларның катгый янәшәлеге зур әһәмияткә ия. Изафә бәйләнешенең икенче төре компонентлары, нигездә, катгый рәвештә янәшәлек саклыйлар. Аларны аерган очракта, бәйләнеш югала. Мондый ойконимның атау өлеше бер һәм берничә сүздән торырга, җанлы сөйләмдә кулланылганда, тартым аффиксына ия булган ияртүче сүздән башка да килергә мөмкин. Нәтиҗәдә, бер сүздән торган гади ойконим барлыкка килә. Атау өлеше ике яисә берничә сүздән торган очракта исә, ойконим тезмә ялгызлык исемнәр рәтендә саналуын дәвам итә.

Татар ойконимиясендә исемнең исемгә янәшә тору һәм тартым кушымчасы аша иярүеннән ясалган, ягъни изафә бәйләнешенең икенче тибына нигезләнгән ойконимнар шактый күп. Мәсәлән: *Мулла Иле* (Әлки, Яшел Үзән районнары), *Чура Иле* (Арча районы), *Чуваш Иле* (Биектау районы), *Ык Тамагы* (Менделеевск районы), *Каз Иле* (Тукай районы), *Тау Иле* (Мамадыш, Яшел Үзән), *Татар Баганасы* (Чистай районы), *Татар Янтыгы, Татар Кабаны* (Лаеш районы).

Сыйфат, сүзтезмә һәм җөмләдә үзенең төп атрибутив вазифасын башкарып килгәндә, һәрвакыт ияртүче сүзгә мөнәсәбәтле пре-

позициядә тора, ягъни ияртүче сүзгә кадәр килә. Сыйфат шулай ук, исем сүз төркеменә күчеп, предметлашкан билгене дә белдереп килергә мөмкин. Бу очракта сыйфат исемгә хас синтаксик функцияләрне башкара һәм исемнең форма ясагыч кушымчаларын кабул итә.

Төрки топонимиядә беренче өлеше сыйфат белән белдерелгән ике һәм өч компонентлы атамалар төркеме яши. Әлеге атамалар рельеф үзенчәлекләре, төсләр сыйфатламасы, тышкы табигате кебек төшенчәләр аша белдерелгән географик объект билгеләрен белдерәләр. Еш кына ойконимиядә *олы – кече, югары – түбән* кебек каршы куюлар очрый.

Татар ойконимиясендә ике компонентлы авыл атамалары арасында лексик мәгънәсенә бәйле рәвештә сыйфат исемне төрле яктан характерлый:

а) төсе буенча: *Аксу* (Буа районы), *Ак Чишмә* (Әлмәт, Арча, Ютазы районы), *Ак Бүре* (Яңа Чишмә районы), *Аккүл* (Лениногорск районы), *Акбаш* (Бөгелмә, Ютазы районы), *Аксай* (Бөгелмә районы), *Каракүл* (Әлки районы), *Кызыл Күл* (Биектау районы), *Каратай* (Арча районы), *Салкын Чишмә* (Минзәлә районы), *Карашәм* (Яшел Үзән);

ә) авылның урнашу урыны буенча: *Югары Арбаш – Түбән Арбаш, Югары Казаклар – Түбән Казаклар* (Кукмара районы); *Түбән Оры – Югары Оры Югары Курса – Урта Курса – Түбән Курса* (Арча районы);

б) объектның сыйфаты буенча: *Яңа Мусабай* (Тукай районы), *Иске Масра, Яңа Әтнә* (Арча районы), *Иске Икширмә* (Саба районы);

в) күләме/зурлыгы буенча: *Олы Бисәр, Олы Тархан, Зур Әтрәч, Олы Шәмәк* (Тәтеш районы); *Кече Урыссу* (Ютазы районы); *Олы Бисәр, Олы Тархан, Зур Әтрәч, Олы Шәмәк* (Тәтеш районы).

Иярүче кисәге ясалма сыйфатлар белән белдерелгән атамалар: *Каенлы елга, Таллы Буләк* (Азнакай районы), *Зирекле Каран, Таллы Күл* (Баулы районы), *Ташлы Елга* (Кукмара районы), *Буралы Чишмә* (Сарман районы).

Иярүче компоненты сан белән белдерелгән ойконимнар. Исем һәм сан арасындагы бәйләнешне тәэмин итүче мөһим һәм катгый таләп ителгән чара – лексик компонентларның үзара янәшәлеге. Мондый бәйләнеш Татарстанның түбәндәге

ойконимнарында чагылыш таба: *Бишбатман* (Яшел Үзән), *Бишмунча* (Әлмәт районы), *Кырык Садак* (Буа районы), *Өчиле* (Арча районы), *Дүрт Мунча* (Зәй районы).

Якут топонимиясендә саннар сирәк кулланыла, тәртип саннары кергән атамалар очрамый (Гриценко, 1968: 12). Шуның белән беррәттән, күрше территориядә урнашкан шор һәм алтай топонимнарында алар шактый еш күзәтелә (Бонюхов, 1972; Молчанова, 1979).

Ияргүче кисәге төрле фигыль формаларына нигезләнгән ойконимнар.

Исем сүзтезмәләрдән торган географик атамаларда фигыльнең исемгә мәгънәви буйсынуы күзәтелә. Бу очракта исем белән фигыльнең янәшәлеге мәҗбүри шарт булып тора һәм сыйфат фигыльләрнең аффикслары алар арасында бәйләнеш булдыруда гаять зур роль уйный (Зәкиев, 1995: 197; Гарипова, 1991: 101).

Татарстан ойконимиясендә предикатив мөнәсәбәтләргә (ия + хәбәр) нигезләнгән фигыльле конструкцияләр очрый: *Янгелде*, *Тәүгелде* (Апас районы), *Ямбакты* (Тәтеш районы), *Колабирде* (Кайбыч районы), *Уразбахты* (Мамадыш районы), *Алабирде* (Тәтеш районы), *Иштуган – иш* «иш, дус» + *туган* (Кукмара районы), *Хансөяр* (Баулы районы).

«Фигыль + исем» конструкциясенә нигезләнгән ойконимнар: *Килдураз* (Апас районы), *Килдеш* (Тәтеш районы), *Бирдебәк* (Балык Бистәсе), *Килдебәк* (Саба районы)

«Сыйфат + фигыль + *-ган*» конструкциясенә нигезләнеп ясалган ойконимнар: ***Байтуган*** (Әгерҗе районы), ***Салтыган*** (Кайбыч, Кама Тамагы районнары)

Топонимиядә фигыльле конструкцияләр күренеше төрки телләрнең үзенчәлеге булып тора. Төрки халыкларда фигыль формалы топонимнарга М.А. Абдрахманов, Ф.Г. Гарипова, Г.И. Донидзе, Дж. Карамышева, Җ.Г. Киекбаев, Г.Ф. Саттаров, О.А. Султаняев һ.б. игътибар бирәләр. Төрле фигыль формаларына нигезләнеп топонимнарның шактый күп һәм типларының төрле булуларын Г.И. Донидзе төрки топонимиягә хас үзенчәлек дип атый һәм мондый топонимнарның махсус тикшерү берәмлеге булып торырга тиешлегенә басым ясый.

Татар ойконимиясендә кушма ойконимнарның трансформацияләнү күренеше еш очрый. Кушма ойконимнарның күп кенә

лексик формалары вакытлар узу белән үзгәрәләр: *Абҗабар* > *Габделҗаббар* (Арча районы); *Абде*> *Габдулла* (Теләче районы); *Әйшә* > *Гайшәбикә* (Яшел Үзән, Биектау районнары); *Бишнә* > *Биек ышна* (Яшел Үзән); *Мәмәт* > *Мөхәммәт* (Лаеш районы); *Нурлат* > *Нурдәүләт* (шәһәр, район); *Мамадыш* > *Мөхәммәтиш* (район); *Шигали* > *Шаһгали* (Биектау, Буа районнары); *Борнак*> *Борыны ак* (Балтач районы) һ.б.

Шулай итеп, татар ойконимнары структур яктан гади һәм катлаулы төрләргә аерылалар. Катлаулы төзелешле ойконимнарның күпчелек өлеше изафә бәйләнешенең икенче төренә нигезләнеп ясалган. Исем, сыйфат, сан сүз төркемнәре, фигыльнең үткән заманы кулланылышта аергыч буларак йөри.

Ойконимнарның төзелешен тикшерү торак пункт атамаларын барлыкка китерүдә катнашкан топоформантларны билгеләргә, топонигез составын ачыкларга, татар ойконимнарын башка төрки телле халыкларның ойконимнары белән чагыштырырга ярдәм итә.

## ТАТАР ОРОНИМИКАСЫ

### § 26. Татар оронимикасын өйрәнү тарихы

Ороним (грек. *ὄρος – тау*, *ὄνομα – исем, атама*) – топонимның бер төре, җир өстенең барлык төр (уңай һәм кире) ландшафт, рельеф атамалары. Оронимика – топонимиканың оронимнарны, аларның барлыкка килү закончалыкларын, үсеш һәм яшәү рәвешләрен өйрәнә торган тармагы. Оронимия – оронимнар җыелмасы (Подольская, 1988: 104, 105).

Бүгенге ономастика фәнендә иң актив өйрәнелгән һәм өйрәнелүен дәвам иткән тармак булып топонимика тора. Республикадагы һәм аннан читтә булган төрле төбәктәге татар топонимиясе тел тарихы, диалектология, когнитив һ.б. яссылыкта монографик планда өйрәнелеп кандидатлык һәм докторлык диссертацияләре яклана, аерып китаплар, сүзлекләр дөнья күрә. Шулай булуга карамастан, татар топонимиясендә әле аз өйрәнелгән юнәлешләр дә шактый. Оронимия шундыйларның берсе.

Оронимиягә караган кайбер материаллар икенче Камчатка экспедициясе (1733–1743) һәм Академик экспедиция (1768–1774) вакытында туплана башлый. Н.П. Рычков та үзенең «Журнал или

дневные путешестивия... по разным провинциям Российского государства в 1769 и 1770 гг.» дигән хезмәтендә төрки-татар атамаларын китерә.

Күп кенә макрооронимнар XIX–XX гасырларда рус сәяхәтчеләренең Себер, Урта һәм Үзәк Азиягә ясаган географик, картографик экспедиция нәтиҗәләрендә күренә. Атаклы рус географы П.П. Семенов 1856–1857 елларда Тянь-Шань тауларына экспедециясе вакытында Или елгасы аръягындагы таулар тезмәсен *Алатау* исеме белән атый. А.П. Федченко (1844–1873) Урта Азиягә сәяхәте вакытында ачкан тау тезмәләрен *Төркестан, Алай арты, Зәраушан* исемнәре белән бирә (Поспелов, 2002: 35). Мондый экспедицияләр вакытында оронимнар җирле халык телендәге сакланган атама белән теркәлгәннәр. Бары тик географик объектның атамасы булмаган очракта гына сәяхәтче-галим исеме белән аталган. Гадәттә, документаль рәвештә теркәлү, өйрәнү нигездә макрооронимнарга хас. Тарихта үзенең тирән эзен саклаган милләт буларак, татар теленә нисбәтле барлыкка килгән оронимнарның географиясе хәзерге Татарстан Республикасы белән генә чикләнми. Себердә һәм Урта Азиядә, Кавказда төрки-татар орографик терминнар киң таралыш алган.

Төрки-татар орографик терминнары рус ономастикасында да шактый чагылыш таба. Мәсәлән: *буерак, яр, яруга, яндова* (Добродомов, 1974.) Рус телендәге *мыс* орографик термины килеп чыгышы ягыннан борынгы төрки телдәге *tијиz – мөгез* сүзенә нисбәтле. Бу хакта XVI–XVII гасыр рус язмаларында шактый тәфсилле язылган (Барандеев, 2012: 142).

Татар телендәге *үзән* орографик термины да XVI–XVII гасыр рус язмаларында урын алган. Әлеге термин «Книга Большому Чертежу» (1627) дигән хезмәттә Иделнең түбәнге агымы бассейнын тасвирлаганда кулланыла. (Книга Большому Чертежу, 1950: 143–144.)

Гомумән, татар оронимиясе күбрәк микротопонимнар составында урын ала. Макрооронимнар аз күләмдә кулланыла. Көньяк Себернең таулы ягы, Кемерово өлкәсе һәм Хакасия Республикасындагы тау тезмәсе *Кузнецкий Алатау* дип атала. Тау түбәсендәге ак кар, соры гранит, кара-кучкыл таш өемнәре, таудагы агачлар аны ала итеп күрсәтә. Тауның исеме шуңа нисбәтле барлыкка килгән. Анда яшәүче җирле халыкны, XVI–XVIII гасырда, руслар, Кузнецк татарлары дип йөрткәннәр (Поспелов, 2002: 154). *Урал-*

*тау* атамасы Башкортстан һәм Чиләбе өлкәләре буйлап ике мең километрга сузылган тезмәне үз эченә ала һәм гомумиләштерүче атама булып тора. «Книга Большому Чертежу» (1627) дигән хезмәттә ул *Аралтова* яки *Оралова гора* буларак телгә алына. В.Н. Татищев 1736 елда Европаны Азиядән бүлеп торучы тау тезмәсе татарча *Урал*, ә рус телендә *Пояс* дип аталганын яза. XVIII гасырның икенче яртысында Пояс атамасы кулланылыштан төшеп кала һәм Урал, Урал таулары дип кенә атала башлый (Поспелов, 2002: 266). Татар телендәге *үзән* орографик термины да XVI–XVII гасыр рус язмаларында урын алган. Әлеге термин шул ук хезмәттә Иделнең түбәнге агымы бассейнын тасвирлаганда кулланыла (Книга Большому Чертежу, 1950: 143–144.)

Топонимик мәгълүматлар, шул исәптән татар оронимнары турында XVIII гасыр ахыры – XIX гасыр башында Н.И. Ашмарин, Н.И. Золотницкий, Н.А. Износков, Һ.В. Йосыпов, А.П. Ковалевский, В.К. Магницкий. Шиһабетдин Мәрҗани, К.Г. Насыйри, Ризаэддин Фәхреддинов, С.М. Шпилевский һ.б. язып чыгалар. Билгеле рус галимнәре Н.Ф. Катанов, В.В. Радлов, совет чорында ономатологлар Н.А. Баскаков, Г.И. Донидзе, Э.М. Мурзаев, Н.А.Никонов, Б.А. Серебренников, А.В. Суперанская, Е.М. Поспеловлар үзләренең хезмәтләрендә төрки-татар чыгышлы оронимнарга күзәтү ясыйлар. 1969 елда Мәскәүдә «Оронимика» фәнни мәкаләләр җыентыгы басылып чыга.

Чуваш ономатологлары Н.А. Ашмарин, Г.Е. Корнилов, мари галимнәре С.И. Галкин, Ф.Г. Гордеев, А.Н. Куклин, удмуртлардан М.Г. Атамановлар үзләренең хезмәтләрендә төрки-татар оронимнарына да игътибар бирәләр. Башкорт топонимистлары әлеге юнәлештә актив эш алып баралар. Җ.Г. Киекбаев, А.А. Камалов, Р.Г. Кузеев, Р.З. Шәкүров, М.Г. Усманова һ.б.ның хезмәтләрендә оронимнарга игътибар бирелә. Н.А. Ласынова «Көньяк-көнчыгыш Башкортстан оронимиясе» (2004) дигән кандидатлык диссертациясендә оронимнарга системалы анализ ясый.

Төрки-татар чыгышлы оронимнар Урта Себер, Алтай территорияләре буенча А.П. Дульзон, О.Т. Молчанова, Кабарда-Балкар топонимиясендә Б.Х. Мусукаев, М.А. Хабичев, Грузия буенча М.К. Гаджихалилов һ.б. хезмәтләрендә анализлана. Р.Д. Сунчугашев «Хакасия оронимиясе» (1999) дигән кандидатлык диссертациясе яклый.

Оронимик материаллар, үзләре аерым сүзлекләр буларак, басылып чыкмасалар да, түбәндәге топонимик сүзлекләрдә зур урын алып торалар: Г.К. Конкашпаевның «Словарь казахских географических названий» (1963), В.А. Никоновның «Краткий топонимический словарь» (1966), Г.Ф. Саттаровның «Җирле географик атамалар сүзлекчәсе» (1968), Ю.И. Боченкованың «Словарь географических терминов и других слов встречающихся в топонимии Горно-Алт. авт. области» (1969), Дж.Н. Коков, С.О. Шахмурзаевларның «Балкарский топонимический словарь» (1970), Е. Койчубаевның «Краткий толковый словарь топонимов Казахстана» (1974), О.Т. Молчанованың «Топонимический словарь Горного Алтая» (1979), «Башкорт топонимнары һүзлеге» (1980), Ф.Г. Гарипованың «Татарстан микротопонимнары сүзлеге» (1992, 1993), Р.Ш. Шаһиевның «Нефть төбәге микротопонимнары сүзлеге» (2008) һ.б.ларда.

Төрки-татар топонимиясе мәсьәләләрен Р.Х. Субаева (1963, 1964) ике теллелек яссылыгында өйрәнә. Татар оронимиясен өйрәнүгә Ф.Г. Гарипова зур өлеш кертә. «Татарстан АССРның елга, күл, юл, тау урман атамалары сөйләм телендә» (1982) дигән мәкаләсендә ул оронимнарга аерым күзәтү ясый.

Татар топонимиясе, шул исәптән оронимия мәсьәләләре, беренче тапкыр 1960 еллар башында төрки-татар ономастика мәктәбенә нигез салган профессор Г.Ф. Саттаров тарафыннан өйрәнелә башлый. Топонимиягә караган «Мәктәптә туган як ономастикасы» (1984), «Атамалар дөньясына сәяхәт» (1992), «Татар топонимиясе» (1998) татар орографик терминнарын һәм орнимиясен өйрәнүдә фундаменталь хезмәтләр булып торалар. «Татар топонимиясе»ндә оронимия мәсьәләләрен яктырткан «Татар теленең орографик терминнары һәм терминологиясе» дигән аерым бүлек бар. Анда орографик терминнар өч төркемгә бүлеп карала:

1. Таулы, калкулыклы җир өстен белдерүче орографик терминнар: *тау, уба, байрак~бөерек, кәңгелде, чкрә, тау кабагы, ау кашы үр, каш, калатау, йылгайак, кырач, түбә, калкулык, чалкулык, чагу, мар, түмгәләк, шәймек, дүмбскә, тиңгәк, вал (уал), чырда, атау* һ.б.;

2. Тигез җир өстенә караган орографик терминнар: *кыр, басу, болын, юша, печәнлек, көтүлек, туплавык, урман, куак, яньк җир, юл, сукмак, чирәмлек, комлы җир, алан, кәс, балчык, пычрак, кола җалан, шалка, төзем җир* һ.б.;

3. Түбән, чокырлы, иңкү, уйсу урыннарны белдерү өчен хезмәт итә торган җирле орографик терминнар: *ерганак, ермак, канау, ор, чокыр, чогыр, уй, яр, йарлавык, җам. баз~базы, сикелтә, түбән җир, иңкү җир, уйсулык, уентык, иңкел, сыза, уйвас, сыгым, яптынка, астыр, җәмәлкә, ерымцак, кагылма, җалпу, җир, иң җир, индерә* һ.б. (Саттаров, 1998:75).

Биш дистәдән артык яшь галим, Г.Ф. Саттаров җитәкчелегендә, ономастикадан кандидатлык һәм докторлык диссертациясе яклады. Шуларның егермегә якыны топонимиягә караган хезмәтләр. Е.Б. Акиндиков (1992), З.Ф. Әхәтова (1994), Ш.Ш. Тулегенова (1995), Н.А. Прманова (1997), Г.К. Закирова (1998), Х.Ч. Алишина (1999), Р.И. Хаҗиев (2000), О.Р. Хисамов (2001), Р.Ш. Шаһиев (2001), Р.К. Садыкова (2003) һ.б.ның хезмәтләрендә, өлешчә, төрки-татар оронимиясе мәсьәләләре кузгатыла.

## § 27. Татар оронимнарының этнолингвистик катламнары

Татар теленең җирле географик терминнарының, гомумән географик терминологиясенең формалашуын һәм үсешен татар теленең формалашуы һәм үсешеннән аерып карарга ярамый. Телебезнең тармак лексикасын тәшкил итүче терминологик лексиканың, шул исәптән географик терминологиянең, формалашуы һәм үсеше гомумтатар теле лексик хәзинәсенең формалашуы һәм үсеш процессы һәм тарихы белән турыдан-туры тыгыз рәвештә бәйләнгән.

Татар оронимиясе системасында төрле тарихи чорларга һәм катламнарга караган атамаларны очратабыз. Чөнки оронимнар үзләрен тудырган халыклар тарихы белән тыгыз бәйләнештә үсәләр, билгеле бер тарихи чорларда барлыкка килеп, конкрет тарихи вакыйгаларга, аерым алганда, тел, мәдәният, икътисади бәйләнешләргә, халыкның күчеп утыруларына һәм башка күренешләргә мөнәсәбәтле рәвештә яшәеш алалар.

Татар оронимнары, этнолингвистик яктан караганда, бик үзенчәлекле. Ул халыкның килеп урнашу тарихы, илдәге сәясәт һәм икътисади мөмкинлекләр белән тыгыз бәйләнгән. Географик атамалар берьюлы барлыкка килми. Гадәттә аларның чишмә башы төрле чорларга һәм төрле телләргә барып тоташа, чөнки янәшә яшәгән төрле милләт вәкилләре гасырлар дәвамында аралашып яши.

Оронимик материалларга нигезләнеп, халыклар һәм аларның телләре бәйләнешен өйрәнү, үткәндәге этник элементларны ачыклау да әһәмияткә ия.

Җирле халык телендә яшәп килүче күп кенә географик атамалар аерым төбәкләргә күчеп килүчеләр, яисә чиктәш төбәкләрдә яшәүчеләр теленә ныклап кереп киткән.

Татар оронимнарының, этнолингвистик яссылыктан чыгып бәяләгәндә, Урал-Алтай, Алтай телләре гомумилегенә караган, фин-угор, иран, төрки-татар, монгол, гарәп-фарсы һәм рус телләренә нисбәтле атамалар булуы күзәтелә.

Топостратиграфик үзенчәлекләрне өйрәнеп, Г.Ф. Саттаров иң борынгы катламнарның Урал-Алтай телләре гомумилегенә каравын искәртә (Саттаров, 1998: 349). Төрки телләр, шул исәптән татар теле, үз чиратында, монгол, тунгус-маньчжур телләре белән бергә, алтай телләре туганлыгына (гомумилегенә) карый. Урал-Алтай теориясе буенча Алтай телләре гомумилеге тагын да зуррак, борынгырак тел гомумилеген – Урал-Алтай телләре туганлыгын тәшкил итә (Саттаров, 1998: 348). М.З. Зәкиев тә: «“Урал-Алтай теориясе” (уралоалтаистика) Алтай телләренең туганлыгын гына танып калмый, аларга бер тамырдан ясалган телләр сыйфатында, Урал (угро-фин һәм самодий) телләрен дә өсти. Бу турыда шактый бәхәсләр булса да, аны нигездә танылган караш дип санарга була», – дип яза ул (Зәкиев, 1977: 22).

Әлеге этнолингвистик катламнар тулы бер эзлекле оронимик системаны тәшкил итәләр, татар халкы һәм татар теле тарихын өйрәнүдә үзләреннән зур өлеш кертәләр.

Урал-Алтай гомумилегенә нисбәтле катлам.

Татар теленең борынгы заманнарга, борынгы тел туганлыгына (бу очракта Урал-Алтай телләре гомумилегенә) барып тоташа торган географик терминнарын табу һәм барлау шактый кыен. Чөнки бу мәсьәлә, тарихи-чагыштырма метод кулланып, Урал һәм Алтай телләре географик терминнарын җентекле итеп махсус өйрәнү, анализлауны сорый (Саттаров, 1992: 169). Г.Ф. Саттаров, үзенең күп еллар дәвамындагы күзәтү һәм өйрәнүләреннән чыгып, гомумтелдәге *алан,* урта диалектның казан арты сөйләшендәге *лап* («тигез җир») орографик терминнарын Урал-Алтай телләре туганлыгына кертә (Саттаров, 1998: 350).

Татар телендәге «урман эчендәге агачсыз, ачык урын» мәгънәсенә ия *алан* (ТТАС, т. 1, 1977: 44) орографик терминын

Г.Ф. Саттаров һәм Э.В. Севортян чыгышы ягыннан Урал-Алтай телләренә бәйләп карыйлар. *Алан* – татар теленең *бөре, минз., кмшл., оренб.* сөйләшләрендә, башк. *аклан* (ТТДС, 1969: 29), төрек. *алан*, төркм., казак, к.калп. *алаң,* тува *аланды*, якут *алы*: алтай *йалан*, тат. диал. *җалан,* шор *чалан* һ.б. (Саттаров, 1998: 352).

Э.В. Севортян *алан ~ алаң* сүзенең килеп чыгышын «ачык, киң» мәгънәсен белдерә торган *а: л ~ а: ла* тамырына кайтарып калдыра (Севортян, 1974: 135).

Тунгус-маньчжур телләре төркемнәренә керә торган эвенк телендә *авлан ~ аулан* – 1) алан, болын, тигез җир, 2) сирәк урман, 3) урмансыз ачык урын; эвен телендә *авлон (~ аулан)* – 1) алан, тигезлек, 2) урмансыз тундра, 3) урмансыз ачык урын; орок телендә *авла(н) ~ аула(н)* – 1) болын, алан, тигезлек, 2) урмансыз ачык урын (Сравнительный словарь тунгусо-маньчжурских языков, 1975, т. 1, 1977, т. 2). Чаг.: монгол һәм бурят телләрендә *аглак* – 1) кул тимәгән урын, 2) ерак аулак урын; татар телендә *аулак* – 1) тыныч, кеше йөрми торган, кешесез, 2) кешесез тыныч урын һ.б.

Татар теленең *аклан, алан, ялан (йалан)* орографик терминнары катнашып түбәндәге оронимнар ясалган: *Аклан тавы* (Югары Мактама авылы, Әлмәт районы), *Бояр йорты акланы* (Бикморас авылы, Әлмәт районы), *Дөя суйган алан* (Карабаш эшчеләр бистәсе, Бөгелмә районы), *Олы аклан* (Мәмәт авылы, Әлмәт районы), *Дәү алан* (Тайсуган авылы, Әлмәт районы), *Кызлар акланы* (Самарканд авылы, Әлмәт районы), *Сарут аланы* (Сәпәй авылы, Азнакай районы), *Чатлык яланы* (Исергәп авылы, Баулы районы), *Түгәрәк ялан* (Уразай авылы, Азнакай районы) һ.б.

*Кыр ягы* – урын атамасы (Бишмунча авылы, Әлмәт районы). *Бикбакул кыры*, *Банкир кыры* – басу атамалары (Урмышлы авылы, Лениногорск районы), *Йомран кыры* – кыр атамасы (Карамалы Елга авылы, Азнакай районы), *Олы кыр* – басу атамасы (Иске Байсар авылы, Азнакай районы) оронимнары составында урын алган кыр – 1) «урмансыз тигезлек. Зур тигез ачык мәйдан»; 2) «иген игү өчен эшкәртелә торган җир мәйданы, басу» (ТТАС, т. 2, 1979: 223–224) орографик терминының генезисы да Урал-Алтай уртаклыгына барып тоташа.

Монгол телләрендә: монг. *кира* – «тау сырты», *хяр* – «калкулык сырты»; бурят. *хяра* – «тау сырты»; халха монг. *кэр, хәэр* – «басу, ачык кыр», «дала» һ.б.

Тунгус-маньчжур телләрендә: эвенк. *кира* – 1) әйбер кырые, яны, 2) өслек, йөз, чик, кырый, 3) кабырга, чит; эвен. *къирън* – 1) чик, ян, 2) кырый, 3) кабырга, почмак, чат, 4) тау сырты; ороч. *кија (кира);* удей. *кија (кира)* – «кырый, яр»; ороч. *kiјадума* – кырыйдагы, азаккы; орок. *кира* – 1) әйбернең кырые, кыры, 2) яр; маньчжур. *хирга* ~ *хирха* «ут чыгару өчен чакма» (кремень) һ.б. (Саттаров, 1998: 353).

Фин-угор телләрендә: удм. *кыр* – «дала, ачык урын»; мари *курык*, мари диал. *кырык;* коми *кыр* – «үр, калкулык», «биек булмаган тау», «кыялы яр»; *кырт* – «кыя»; *кырем* – «чокыр»; «текә ярлы упкын», *кыркети* – «бик текә яр»; фин. *horkea* «биеклек, калкулык»; эстон. *kuruk* – «кечкенә үр, калкулык»; саам. *кыры* – «зур булмаган түгәрәк калкулык»; *курро* – «тау сырты»; гомумпермь телендә *kur* – «тау» (Мурзаев, 1984: 327–328).

Мисаллардан күренгәнчә, татар орогорафик терминнары һәм атамалары арасында Урал-Алтай телләре кардәшлегенә нисбәтләре дә урын алган.

Фин-угор катламы үз эчендә берничә аскатламга бүленә. Алар түбәндәгеләр:

*1. Мари аскатламы.* Кама буенда мариларның күренә башлавы турындагы беренче мәгълүматлар XV–XVI гасырларга карый. Алар турында елъязмаларда, ярлыкларда искә алына (Сепеев, 1975: 5). Марилар, татар, башкорт, рус, удмурт һәм чувашлар озак дәверләр дәвамында бергә яшиләр, моны топонимик чыганаклар да раслый. Мәсәлән: *Мари межасы* (Симәк авылы, Мөслим районы) – ызан исеме, *Мари тавы* (Тат. Бүләре авылы, Мөслим районы) атамаларының нигезендә мари этнонимы ята. Шушы ук этнонимны белдерүче чирмеш этнонимы белән ясалган оронимнар да очрый. *Чирмеш тавы* (Каташ-Каран авылы, Сарман районы), *Чирмеш буе* – урын атамасы (Мортышбаш авылы, Сарман районы).

Күргәнебезчә, хәзерге мариларның бабалары (чирмешләр) татар оронимиясендә шактый эз калдырганнар.

*2. Мордва аскатламы.* Урта Идел һәм Кама буйларында болгарлар белән бергә борынгы чуваш, удмурт, мари, башкорт һәм башка кабиләләр, халыклар белән мордва халкы да гомер иткән. Борынгы чыганакларда мордвалар турында беренче тапкыр б.э.ның VI гасырында телгә алына (Хасанов, 1977: 296–302).

Татар оронимнары составында, нигездә, мордваларның *мукшы* этнонимы чагылыш таба: *Мукшы акланы* (Бәкер авылы, Лениногорск районы), *Мукшы басуы* (Кәләй авылы, Әлмәт районы) һ.б. Татар оронимнары составында *мукшы* этнонимының очравы, аларның татар халкы белән тыгыз бәйләнештә яшәүләрен дәлилләүче мисал.

Иран катламы. Географик атамаларның иран катламы Урта Иделнең бик зур регионын үз эченә ала һәм бу әлеге территориягә борынгы савроматларның, алардан соң алан һәм сармат кабиләләренең килүе белән бәйләнгән. Иран катламы татар оронимнары составында борынгы катламнардан санала.

III–IV гасырлардан башлап, беренче меңьеллыкның ахырына кадәр Идел–Кама буйларына төрки телдә сөйләшүче кабиләләрнең зур-зур төркемнәре берничә тапкыр үтеп керә. III–IV гасырларда фин-угор кабиләләре белән шактый дәрәҗәдә аралашкан беренче төрки кабиләләр Кама буйларының кайбер районнарында урнашып калалар һәм, өлешчә, Иделгә үтеп керәләр.

Идел–Урал буйларында б.э.га кадәр дә, аннан соң да фин-угорларның булуын бер галим дә инкяр итми, ләкин күпләр аларның яшәү урыннарын Урта Иделнең урманлы зонасы белән чиклиләр, көньякның урмансыз зонасында, б.э.ның IV йөзендә һуннар килгәнче, фин-угорлар белән янәшә иран телле кабиләләр яшәгән дип уйлыйлар. Ә кайбер тарихчылар, Урта Иделдә (шулай ук Түбән Иделдә, Каспий тирәләрендә, Төньяк Кавказда, Кара диңгезнең төньягында) иранлылар үзләре генә яшәгәннәр, бу регионнарда иранча сөйләшү генә яңгыраган, диләр (Федоров..., 1978: 6).

М.З. Зәкиев исә «бу фикерләр дөреслеккә туры килсә, Идел-Уралда бары фин-угор һәм иран топонимнары гына өстенлек итәр иде. Ләкин фин-угор топонимнары бары Идел–Уралның урманлы зонасында гына күпләп очрый, иран топонимнары Идел–Уралда гомумән булмаган диярлек, ә төрки топонимнар тулып ята», – дип яза (Зәкиев, 1998: 44).

Шулай итеп, борынгы чорларда Евразия далаларында һәм Идел–Кама буйларында иран, фин-угор, төрки кабиләләр катнашында катлаулы тарихи-этнолингвистик процесслар барган.

Урал, Идел буе топонимиясендә, шул исәптән оронимиядә иран катламы булу, телче галимнәр арасында фикер каршылыгы тудыра. М.Г. Атаманов, Т.Н. Гарипова, Н.Д. Гарипова, Ф.Н. Гордеев, Г.Ф. Саттаров, Р.З. Шәкүров һ.б. галимнәр әлеге катламның

барлыгын расласалар, Ф.Г. Гарипова, М.З. Зәкиевләр бу фикер белән килешмиләр.

Н.Д. Гарипова һәм Т.М. Гарипов «су үтми торган тукымадан яки тиредән җиргә утыртылган казыкларга тарттырып ясалган, вакытлы рәвештә ышыклану, тору өчен хезмәт итә торган корылма; кояштан яки яңгырдан саклану өчен ясалган япма» (ТТАС, т. 3, 1981: 413) мәгънәсенә ия *чатыр* сүзенең генезисын иран теленә бәйләп аңлаталар. *Чәтр/зонт(ик)* – чатыр, шатер (Гарипова, Гарипов, 1964: 185). Г. Дёрфер рус һәм башка славян телләрендәге *шатёр* «палатка» сүзенең килеп чыгышын Идел болгарлары телендәге *satir* сүзенә кайтып кала дип карый (Doerfer, 1967: 20). Венгр телендә бу сүз *sator* («палатка») формасында кулланыла (Аракин, 1984: 20). Татар микротопонимнары арасында *чатыр* ойконимик термины белән ясалган *Чатыр тавы* (Азнакай шәһәре, Митрәй, Уразай авыллары, Азнакай районы), *Чатыр чокыры* – чокыр атамасы (Татар Димескәе авылы, Бөгелмә районы) кебек оронимнар бар.

Терлекчелек төп кәсеп-шөгыль булган күчмә тормыш шартларында болгар-татарлар (V–XII йөзләр) һәм ут күрше канкардәш башкорт кабиләләре (VI–XVIII йөзләр) аз һәм җиңел материалдан тиз корырга мөмкин булган гади торакларда – чатыр, куыш, шалаш һ.б.да яшәгәннәр (Саттаров, 1992: 139). Димәк, *чатыр* сүзенең борынгы бабаларыбызга иран телләреннән килеп керүе гаҗәп түгел.

Татар оронимиясендә иран катламының да урын алуы, иран телле скиф-сармат һәм скиф-алан кабиләләренең Идел–Кама буйларына үтеп керүенә бәйле һәм Идел–Кама һәм Урал регионында барган бик борынгы тел контактларын чагылдыралар.

Төрки-татар катламы. Безнең эраның беренче гасырларында Көньяк Урал һәм Көнбатыш Себер далаларында Себернең җирле угор-төрки кабиләләре белән кушылган төрки телле һуннар туплана башлый. Инде б.э.ның IV гасырларына, төбәк һуннар биләмәсенә әйләнә. Пьянобор кабиләләре үзләренең гомер иткән җирләрен ташлап көнбатышка, Нократ, Идел буйларына китә башлыйлар. Яңа кабиләләрнең Кама буйларына һәм Иделгә үтеп керүләре IV гасыр азакларында көчәя. Һуннар 375 елда Иделне кичеп чыгып, Көнчыгыш Европа далаларын яулап алалар (История Татарской АССР, 1980:12). Җирле халыкның беркадәр өлеше күченеп килгән кабиләләр эчендә әкренләп югала башлый.

Һуннардан соң Ык белән Идел арасы далаларына VI–VIII йөзләрдә Төрки каганнары хуҗа булалар (Әхмәтҗанов, 1999: 13). Күп кенә галимнәр бу тирәләрнең төркиләшүен бары Төньяк Кавказдан болгарлар килүгә генә бәйлиләр, иртәрәк төркиләшә башлау турындагы фикерләрне төрле дәлилләр белән юкка чыгарырга тырышалар. А.Х. Халиковның Урта Идел һәм Урал буйлары болгарларга чаклы ук төркиләшә башлаган дигән фикерләренә А.П. Смирнов һәм Г.Е. Кәримовлар каршы чыгалар (Зәкиев, 1977: 77).

Тарих бернәрсәне дә читләтеп үтми һәм ул төрки-татар топонимиясенең формалашуына да тәэсир итми калмаган. Хәзерге төрки оронимия территориаль яктан киң таралыш алган, катлаулы төзелешле, лексик асылы төрле булган, стратиграфик яктан тирән һәм озак вакытлар дәвамында төрле этник факторлар тәэсирендә формалашкан үзенчәлекле типологик система тәшкил итә.

Татар оронимикасында төрки-татар катламы иң саллысы санала. Төрки-татар этнолингвистик катламын берничә төркемчәгә (аскатламга) бүлеп өйрәнергә мөмкин: 1) борынгы төрки; 2) болгар; 3) иске татар; 4) башкорт; 5) чуваш; 6) яңа татар.

*Борынгы төрки аскатламы.* Борынгы төрки топонимия – нигездә субстрат топонимнарны үз эченә алган җирле географик атамалар катламының катлаулы структур-типологик төзелешен тәшкил итүче система.

Татар оронимиясендә борынгы төрки телләргә нисбәтле булган, безнең көннәргә кадәр килеп җиткән һәм хәзерге төрки телләрдә, шул исәптән татар телендә, аның диалектларында сакланып калган атамалар аз түгел.

Татар теле тарихында «дала», «тигезлек», «басу-кыр» мәгънәсендә йөргән *йаз* орографик термины да кулланыла. Аның генезисы борынгы төрки телдәге *jazi* «дала», «тигезлек» сүзенә (ДТС, 1969: 25) кайтып кала.

Татар телендәге *яссы* сүзенең килеп чыгышы да борынгы төрки телдәге *jazi* «дала, тигезлек» сүзенә барып тоташа. Чагыштыр: азәрб. *jасты* «яссы»; башкорт. *яссы;* кырг. *җазы ~ җазык*: 1) тигез, яссы; 2) тигезлек, киңлек; к-калп. *җазыкъ*: 1) тигезлек, үзәнлек, 2) таралган, җәелгән; хакас. *чазы*: 1) кыр, 2) дала (Саттаров, 1992: 58–59). *Яссы болын* – Азнакай районы Кәтем авылындагы болын атамасы.

*Йаз* орографик терминының Татарстан һәм Башкортстан топонимиясендә «кыр-басу, дала, тигезлек, алан» мәгънәсен белдергән хәлдә саклануы игътибарны үзенә җәлеп итә.

Татар оронимиясендә киң урын алган *баш* анатомик термины үзенең тамырлары белән борынгы төрки телгә карый. Борынгы төрки телдә *baš* – 1) баш, түбә; 2) башлык; 3) башланып киткән урын һ.б. (ДТС, 1969: 86).

*Баш* анатомик термины түбәндәге татар оронимнары составында урын алган. *Болан баш буе* – кыр исеме, *Болан баш тавы* (Салих авылы, Баулы районы), *Печмән баш чокыры* (Мәмәт авылы, Әлмәт районы), *Пич башы тавы* (Кичүчат, Сәмәрканд авыллары, Әлмәт районы) һ.б.

*Каш, кашлаг* топонимик аппеллятивы оронимик термин буларак кулланыла. *Кашлак* (Яңа Кәшер авылы, Әлмәт районы). Борынгы төрки телдә *Qasll* «кырый, чит, каш, чик», *jar gasi* «яр кырые» (ДТС, 1969: 431). Татар теленең бөре, минзәлә, гәйнә сөйләшләрендә *каш* – калку җир, калкулык, кашлак; тау ягы, кама тамагы сөйләшләрендә *каш башы* – тау түбәсе, тау башы, калкулык өсте (ДС, 1958: 78; ТТДС, 1969: 198).

Борынгы төрки-татар *кол ~ кул* анатомик термины белән татар топонимиясендә орографик һәм гидрографик терминнарны күзәтергә мөмкин. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *кул* – «инешле ерынты, сулы сыза» (ТТАС, т. 2, 1979: 187), «су ага торган чокыр, кушылдык, тармак» мәгънәсендә. В.В. Радлов сүзлегендә *кол ~ кул* терминының таранчы һәм чыгтай телләрендә «елга юлын» белдерүе күрсәтелә. Керәшен татарлары сөйләшендә *кул* – «чокыр» (Баязитова, 1973: 209). Урта диалектның гәйнә, ккрасноуфим сөйләшләрендә *кул* һәм *кулара* – «ике тау арасындагы үзән» (ТТДС, 1969: 209).

Башкорт теленең караизел сөйләшендә *кулат, кул* – «уйсулык, уйсу җир, тар сай чокыр» (Башкорт һөйләштәренең һүзлеге, т. 2, 1970: 147). *Абагалы кул чокыры, Бүре кулы – урманлы чокыр* (Октябрь Бүләге авылы, Азнакай районы), *Ишлекәй кулы* – урын исеме (Акбаш авылы, Ютазы районы), *Карагаш кулы* – кечкенә тау арасы (Исергәп авылы, Баулы районы; Митрәй авылы, Азнакай районы), *Караңгы кул* – урын атамасы (Кәрәкәшле авылы, Ютазы районы), *Караңгы кул арасы* – чокыр атамасы, *Хөсәен кул арасы* (Кичүчат авылы, Әлмәт районы) һ.б.

Генезисы белән борынгы төрки телгә мөнәсәбәтле *яр ~ ярган* топонимик терминнары белән *Яргак* – урын атамасы (Кичүчат авылы, Әлмәт районы), *Кара яр* – яр атамасы (Чуар Абдул авылы, Азнакай районы), *Кызылъяр* – урын атамасы (Бишмунча, Кама Елга авыллары, Әлмәт районы; Кирлегәч авылы, Лениногорск районы), тау атамасы (Урсалбаш авылы, Әлмәт районы).

Татар телендәге *яр* гидрографик термины күбрәк төс белдерүче сыйфатлар белән ачыкланып килә. Төрки телләрдә *яру, яр (йар), йарык* орографик номенклатура термины «җир эченә уеп керү», «җирне казып керү», «җирне казу, чокырайту» төшенчәсен белдерә (Саттаров, 1992: 99). *Яр* – татар теленең кузн., хвл., чист. сөйләшләрендә «чокыр». Минзәлә сөйләшенең мөслим-актаныш урынчалыгында вак-вак киртләч ярлардан гыйбарәт булган урынны *ярлавык*, зәй керәшеннәре сөйләшендә *җаргыч* дип йөртәләр. *Җаргак* – нгб. керәшеннәрендә кибә торган елга (ТТДС, 1969: 567).

Татар телендә «җир өстенең һәр яктан текә, биегәеп, күтәрелеп торган шактый зур урын» төшенчәсен белдерә торган *тау* сүзе шулай ук борынгы төрки телдән үк килә торган географик термин һәм беркадәр үзгә фонетик яңгыраш алган хәлдә барлык төрки телләрдә дә урын ала: бор. төрки телдә *tay*; азәрб. *даг*, кырым тат. *дагъ*, төрекмән *дааг*, төрек *dag*, алтай *туу*, кыргыз *тоо*, казак, башкорт, к-калп. *тау*, тува *даг*, үзб. *тогъ*, уйгыр, хакас, шор, чулым тат. *тагъ*, якут. *тыа*, чув. *тав* һ.б. (Саттаров, 1998: 376). *Тау* орографик термины белән *Уралтау, Алатау, Текә тау* (Кәтем, Чуар Абдул авыллары, Азнакай районы), *Тау ягы* – урын атамасы (Бишмунча, Кичүчат авыллары, Әлмәт районы), *Ала тау* (Миңлебай авылы, Әлмәт районы), *Ачы тау* (Сугышлы авылы, Лениногорск районы), *Алып тавы* (Тайсуган авылы, Әлмәт районы), *Әхмәт тавы* (Кирлегәч авылы, Лениногорск районы), *Бүре тавы* (Колшәрип авылы, Әлмәт районы; Тимәш авылы, Лениногорск районы), *Бәләкәй тау* (Мәмәт авылы, Әлмәт районы), *Урыс тавы, Кылыч тау, Сәлимә тау* (Кичүчат авылы, Әлмәт районы) һ.б. оронимнар бар.

Татар телендә, башлыча, кешенең ис сизү һәм үпкәгә һава үткәрү, сулыш алу органы атамасы булып кулланыла торган *борын* анатомик терминына нигезләнеп, аның гәүдәнең алга чыгып торган орган булуына охшатып, ягъни метофорик юл белән, тауның алга чыгып торган өлешен белдерү өчен *борын* («мыс») географик термины барлыкка килгән. Алда әйтеп үтелгәнчә, ул килеп чы-

гышы белән борынгы төрки телдәге «мөгез» сүзенә килеп тоташа. *Ташлы борын* – тау атамасы, *Ташлы борын тугае* – шул тау буендагы тугай Әлмәт районы Кичүчат авылындагы оронимнар. *Борынчак* – Әлмәт районы Сөләй авылындагы борын кебек аерылып, чыгып торган басу атамасы.

*Борын* сүзе барлык төрки телләрдә дә анатомик һәм географик төшенчәләрне белдерә: борынгы төрки телдә *burun* – 1) нос, 2) мыс, выступ; *tay burni* «выступ горы»; төрек, кырым тат., кумык, балкар, төрекмән, уйгыр, үзбәкләрдә *бурун;* ногай *бурын*, казак, кыргыз, якут, себ. тат. *мурун;* башкорт. *морон;* алтай, хакас *мурун;* тува *мурну* – 1) борын («нос»), 2) күчерелмә мәгънәдә борын («мыс»). Б. Мункачи, Ю. Немет, Г. Рамстедт, Э. Севортян һ.б. *burun* (борын) сүзенең асылында *bura ~ bur* – «иснәү» фигыле ята дип карыйлар (Севортян, 1978: 269–270). Борынгы төрки телдә *bur*- 1) пахнуть, благоухать; *jipar burdi* «мускус блогоухал»; 2) испаряться: *suv burdi* «вода испарялась» (ДТС, 1969: 125).

*Болгар аскатламы.* Болгар теле – таралган уйгыр, борынгы төрки һәм өлешчә төрки булмаган ыру һәм кабиләләрдән оешкан, Идел һәм Кама буендагы дәүләт халкының борынгы теле (Баскаков, 1969: 233).

Идел буе Болгар дәүләте составына кергән кабиләләр барысы да бериш булмаганнардыр, «ләкин шунысы бәхәссез, бу союз барлыкка килгәндә берләшмә ниндидер якынлыкка, кардәшлеккә нигезләнгән булган. Бик ихтимал, бу якынлык бер үк телнең, барыннан да бигрәк төркинең якын шиваләрендә чагылгандыр» (Генинг, Халиков, 1964: 130).

Болгар теле истәлекләре аерым сүзләрдә һәм күпчелек ялгызлык исемнәрендә сакланып калган. Татар теленә болгар теленең тәэсире зур була. Чөнки «татар сөйләм теле болгар һәм кыпчак кабиләләре телләренең үзара йогынтысы нәтиҗәсендә барлыкка килә» (Баскаков, 1969: 288).

Татар топонимиясендә болгар катламын өйрәнү белән М.З. Зәкиев, Г.Ф. Саттаров, Ф.Г. Гарипова, Р.Г. Әхмәтҗанов шөгыльләнәләр.

*Инеш* – гидрографик һәм оронимик термин буларак йөри. Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә «кечкенә, сай һәм тар елгачык» мәгънәсендә теркәлгән (ТТАС, т. 1, 1977: 394). Татарстанда һәм Татарстаннан читтәге башка өлкәләрдә дә *инеш* сүзе кергән мик-

ротопонимнар күзәтелә: *Инеш урамы* – урам (Иске Мәстән, Урт. Тәрәшкә, Кулат авыллары, Ульяновск өлкәсе), *Инеш урманы* (Усть-Кулатка, Кулат авыллары, Ульяновск өлкәсе), *Инеш сазы* (Мочалей, Похвистнево авыллары, Самара өлкәсе), һ.б. (Гарипова, 1998: 90). Борынгы төрки телдә «спуск», «низина, долина» (ДТС, 1969: 174). Татар телендәге *инеш* «елгачык», иңкел, иңкеш «түбән җир», иңкү, иңкүлек; кыргыз – *еңку;* башкорт – *иңкеү;* нугай *еңгез* «сөзәк, кыек» сүзләренең асылында «иңкү, җиргә батып, иңеп керү» төшенчәсен белдерә торган гомумтөрки *иң* тамыры ята. Татар теленең каз. ар.-лш., каз. ар.-крш. сөйләшләрендә *иңеш* – «инеш» (речка) (ТТДС, 1969: 156). В.В Радловта «киң елгачык» (Радлов, т. 1, кис. 2: 1445). Г.Ф. Саттаров: «Инеш гидрографик термины татар теленә болгар теленнән күчкән мирас. Бу гидрографик термин башка төрки телләрдә урын алмый», – дип яза (Саттаров, 1998: 382).

«Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *атау* – «утрау (ТТАС, т. 1, 1977: 82), һәр ягыннан су уратып алган коры җир» (ТТАС, т. 3, 1981: 322) дип бирелә. Г.Ф. Саттаров фикеренчә, калкулыкны белдерүче *атау* орографик термины чыгышы белән болгар-татар теленә карый (Саттаров, 1992: 192). *Атау* орографик термины белән түбәндәге оронимнар ясалган. *Атау болыны* (Тайсуган авылы, Әлмәт районы), *Атау су буе*, (Урсалбаш авылы, Әлмәт районы), *Атау* – урын атамасы (Яңа Кәшер авылы, Әлмәт районы), *Кече атау* – тау атамасы (Салагыш авылы, Әгерҗе районы). Зәй керәшеннәрендә, казан арты, бөре, минзәлә, гайнә сөйләшләрендә атау «калкулык, кашлак (холм, пригорок, возвышенность)» мәгънәсендә йөри (ТТДС, 1969, 52: 198). Лаеш сөйләшендә *атау* «калку җирдәге куаклык»ны белдерә (ТТДС, 1969: 52).

Болгар бабаларыбызда да чокырны һәм елгачыкны *ширмә ~ җырма ~ сырма* дип атаганнар (Саттаров, 1992: 91; 1998: 125). Чокырлы, батынкы урынны белдерүче *сырма* җирле орографик термины чуваш телендә «чокыр», «елга» мәгънәсендә кулланыла Г.В. Егоров бу сүзнең килеп чыгышын *сыр*- «размывать» тамырына кайтарып калдыра: уйг. *яр* , төрекм., кырг. *җар,* казак. *җырма*, азәрб. *ярган* «чокыр», «раскалывать» һәм *җыр* «прорывать»тан, – дип карый (Егоров, 1964: 226).

Татар оронимнары арасында составында *ор, ур* топокомпонентлары булганнары да бар. *Ургалак чокыры* (Урсалбаш авылы, Әлмәт

районы), *Ургалак аланы* (Әлкәй авылы, Азнакай районы). Татар әдәби телендә *ур* – 1) «дошманнан саклану өчен, шәһәр һәм крепость тирәли койма урынына казылып ясалган ныгытма, траншея һәм вал»; 2) «текә ярлы коры елга, тирән чокыр» (ТТАС, т. 2, 1979: 310). Алабуга керәшеннәре сөйләшендә *ур* – «текә ярлы сусыз коры елга» (ТТДС, 1969: 455). Башкорт телендә *ур* «чокыр» (Гарипова, 1975: 190). Г.Ф.Саттаров *ур* сүзен болгар телендәге *var (вар ~ ар)* «елга» сүзенә бәйләп аңлата (Саттаров, 1973: 126; 1989: 9).

В.А. Никонов фикеренчә, Оренбург, Орск атамаларының нигезендә төркиләрдә «чокыр»ны белдерүче *ор* сүзе ята (Никонов, 1966: 312-313). *Ургалак чокыры*, *Ургалак аланы* атамалары да *ур* «елга, елгачык» + *-гыл* (исемгә кушылып сыйфат ясаучы кушымча) + *-ак* (сыйфат белән характерлана дигән мәгънәне белдерә) (Татар грамматикасы, т. 1, 1998: 395, Ганиев, 2000: 186) рәвешле ясалган.

Чуваш телендә *вар ~ варан ~ асан* сүзләре бүгенге көндә «чокыр, үзән, сыза, уйсулык, иңкүлек, коры чокыр, елга юлы», чув. диал. «елгачык» мәгънәләрендә кулланыла (Нестеров, 1981: 296). Хакас. *ор* «казу, чоку». Төрекмәннәрдә һәм М. Кашгари сүзлегендә *уры/уру* «ашлык саклау өчен ясалган чокыр», кырг., к.-калп. *ор* «озын чокыр, канау, чокыр» (Саттаров, 1989:10). «Канау-крепость валы», «чокыр» һәм «туфрак өеме» *ор* сүзенең төп мәгънәләреннән санала (Севортян, 1974: 467). Иске мари телендә *ор* – «крепость, ныгытма» (Марийско-русский словарь, 1966: 389).

Алда китерелгән географик атамалар мисалыннан чыгып һәм башка чыганакларга нигезләнеп, Г.Ф. Саттаров болгар-татар һәм башка төрки телләрдә кулланылган *уар ~ ор ~ ур* сүзенең төп ике мәгънәдә кулланылуына басым ясый: 1) елга, елгачык; текә ярлы елга; тирән чокыр, канау; 2) кырыена туфрак өеп ясалган тирән канау, туфрак өеме, ныгытма, крепость (Саттаров, 1989: 11).

Югарыда күрсәтелгәннәргә нигезләнеп, без составына *ур* гидрографик термины кергән татар оронимнарын болгар теленә һәм гомумтөрки *ор ~ ур* географик номенклатура терминына нисбәтле дип карыйбыз.

Шулай итеп, китерелгән мисаллар оронимнар составында сакланып калган болгар аскатламының гомумтөрки телгә нигезләнгәнен күрсәтә.

*Иске татар аскатламы*. Иске татар әдәби теле XV йөздә Казан ханлыгында татар халкы белән бергә формалаша. Татар

халкы, электән үк язу куллану традициясе булган кабиләләрдән оешканлыктан, башта ук язма әдәби телгә ия була. Бу иске татар әдәби теле дә гомуми уртак иске төрки телне гомумхалык сөйләмә теленә билгеле дәрәҗәдә якынайту нәтиҗәсендә барлыкка килә.

Иске татар әдәби теле болгар-татарлар арасында гына түгел, хәтта башкорт һәм казакларның элгәрләре тарафыннан да актив кулланыла (Баскаков, 1973: 143).

«Языки мира. Тюркские языки» дигән энциклопедик басмада, төрки гаиләдә борынгы 15 һәм хәзерге вакытта яши торган 39 телнең язма тарихы V–VI, VIII–IX, X–XII йөзләрдә башлануы, XII–XIII гасырдан язма истәлегенең язылу датасы билгеле булган иске язулы (старописьменные) телләр дигәндә, азәрбайҗан, төрек, төрекмән, уйгур, үзбәк телләре белән рәттән, татар теле дә истә тотыла (Языки мира..., 1997: 160, 395, 413, 427, 438, 358).

Татар оронимиясендә иске татар теленә нисбәтле топонимнар сакланып калган.

Иске татар телендәге *чагыл* – «тау» мәгънәсенә ия җирле орографик терминга нигезләнеп регионда байтак кына оронимнар барлыкка килгән. Мәсәлән: *Чагыл* – тау атамасы (Кичүчат авылы, Әлмәт районы), *Чагыл тавы* (Кама Исмәгыйль авылы, Әлмәт районы), *Биек чагыл* – тау атамасы (Сәпәй авылы, Азнакай районы), *Биек чагыл таулары* (Тат. Кандызы авылы, Баулы районы), *Торна чагылы* (Кәрәкәшле авылы, Ютазы районы). Күп очракта җирле орографик атамалар иске татар *чагыл* «тау» + татар *тау* конструкциясен тәшкил итәләр. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *чагыл* – «калкулык; кояш нурлары төшә торган тау бите» (ТТАС, т. 3, 1981: 398). *Чагыл, чагу, чалкый, чалкулык* орографик терминнары минзәлә сөйләшендә калку җирне, калкулыкны белдерә.

Урманда агач төпләреннән чистартылган ачыклык зәй керәшеннәре сөйләшендә *әрчү* термины белән атап йөртелә (ТТДС, 1969: 517). «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *әрчү* «агач-куакларны тамырлары белән куптарып, берәр нинди урынны чистарту» (ТТАС, т. 3, 1981: 685) дип бирелә. *Әрчү* орографик термины белән *Бәләкәй әрчү* – ачыклык урын (Олы Урыссу, Ютазы районы) һ.б. оронимнар ясалган.

*Барлак* – урын атамасы (Кичү авылы, Әлмәт районы). Тау ягы тархан сөйләшендә «яткын җир» (залежная земля) ягъни,

кыр-басуның төре *барлак* орографик термины белән белдерелә (ТТДС, 1969: 70). Кичү ныгытмасын төзүдә катнашкан Тау ягының Тархан кешеләреннән хәзерге рус авылы булган Кичүдә (Әлмәт районы) җирле *барлак* термины урнашып кала һәм шул мәгънәсендә кулланыла.

Типтәр телендә *печмән* – «агачлары киселгән урман аланы» (Әфләтунов, 1961: 165). Татар телендә актив кулланыла торган пычак, пычкы, печњ, почмак, печән сүзләренең тамыры – *пыч ~ поч*. Иске татар телендә актив кулланылган *печмән* сүзе типтәрләр сөйләшендә сакланып калган. Г.Ф. Саттаров исә – «межа, ызан» дип аңлата (Саттаров, 1984: 75). *Печмән* (Письмянка) елгасы – Бәләбәй районында, Өсән елгасының уң кушылдыгы. Элекке вакытларда *Песмән-Каран,* хәзер *Писмән* дип йөртелүче елга. Калтай районында *Печмән-Тау* авылы бар. *Печмән* берәмлеге татар теленнән мари теленә дә үтеп кергән. Болын марилары телендә *пысман* «җир кисәге, полоса, межа» төшенчәсендә кулланыла (МРС, 1956: 488). Тау ягы марилары сөйләшендә дә *пысман~песман* шул ук мәгънәдә йөри (Марийско-русский словарь, 1956: 493).

Татар әдәби телендә «ташкын яки яңгыр суы белән юылып, ашалып ясалган тирән булмаган сулы яки сусыз чокыр» төшенчәсен белдерүче *ерганак* (ТТАС, т. 1, 1977: 333) термины урынына татар теленең минзәлә сөйләшендә *йырач~ирәч* термины кулланыла (Саттаров, 1992: 89). *Ирәч* орографик термины белән Кама аръягы регионында түбәндәге микротопонимнар ясалган. *Ирәч басуы* (Әлкәй авылы, Азнакай районы), *Ирәч яланы, Ирәч прахуды* (Урсалбаш авылы, Әлмәт районы) һ.б.

Монгол катламы. Идел буе Болгар дәүләтендә халыкның тыныч кына көн күрүе, мәдәни һәм икътисад үсеше монгол басып алучыларының һөҗүме нәтиҗәсендә юкка чыгарыла. 1236 елда монголлар Болгар җирләрен басып алсалар да, халкын буйсындыра алмыйлар.

Монгол телле халыклар белән аралашып яшәү Идел буе төрки теленә дә тәэсир итмичә калмый.

Монгол телендә *ово* «ялгыз таучык, калкулык, ташлар өеме, чик буе билгесе», башкорт. *уба* «кабер калкулыгы», «калкулык өстендәге үрләр», татар теленең камышлы һәм нагайбәк сөйләшләрендә *уба* «кечкенә калкулык», себер татарларында «калкулык», «биек җир», минзәлә һәм оренбург сөйләшләрендә «җиргә казып

ясалган чокыр, җәнлек оясы» (ТТДС, 1969: 451). *Уба* диал. (Тумашева, 1992: 162, 224; ТТДС, 1969: 451) *ӧбӧ, убы* «(насыпной) холмик; яма, нора», (ДС II: 203) «логово» > удм. (Насибуллин: 142) *убо* «түтәл», мар. (Исанбаев, 1978: 25) *вова, воба* «баз, өн» һ.б. гом. кыпч., к. кр.-тат. (Будагов I: 107) *оба* «очлы түбәле һәм әйләнәсе чирек чакрымнан бер чакрымга кадәр булган калкулык – ул аерым урын яисә авыл билгесе булучан» < монг., маньч. һ.б. *обо, оба* (> каз., к.-калп., к.-балк., кырг. *оба, обо,* хак. *обаа,* тув. *оваа*), бур. *обоо, обоон,* яз. монг. *oбиγan* һ.б. «уба». Чаг.: тибет. *огбон* «гыйбадәт кылу һәм табыну тавы». Аерым тауларга – убаларга табыну һәм шул тауга гыйбадәтханә ясау киң таралган булган; тау булмаганда ясалма тау ясаганнар. Кара: Традиционная культура народов Центральной Азии 1986: 74–84; 112–131 (Л.Л. Абаев һәм Е.А. Окладников мәкаләләре) (Әхмәтьянов, 2015: 337).

*Бүре убасы чокыры* (Сәпәй авылы, Азнакай районы) оронимы да монгол генезислы *уба* орографик термины һәм *бүре* зоологик терминнары бергә килеп «бүре чокыры + чокыр» төзелмәсенә ия булган сүзтезмә. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *уба* орографик терминының тискәре рельефны (чокырны) белдерүче атама булуы да, уңай рельефны (калкулыкны) белдерүче атама булуы да теркәлгән (ТТАС, т. 3, 1981: 293). Башкортстанда *уба* «калкулык» орографик терминына нигезләнеп ясалган топонимнар бар. *Убатау* – Аургазы һәм Дәүләкән районнарындагы тау исеме һ.б. *Уба* < *убы* сүзенә күп топонимистлар У*фа* ~ *Уфы* ~ *Өфе* елга һәм шәһәр исемен баглыйлар (Әхмәтьянов, 2015: 337). Р. Фәхреддин: «Уба. Бу башкортлар сүзе булып, биек урын белән бәйле булмыш. Уфа шәһәре биек урында утырганы мәгълүм», – дип яза (Фәхреддин, 1893, т. 9: 259).

Татар теленең камышлы, бөре, минзәлә һәм гәйнә сөйләшләрендә *чаган* сүзе «өрәңге» агачын аңлата (ТТДС, 1969: 47). Монгол телендә *цагаан/чагаан* – 1) ак; 2) өрәңге, бурят телендә *сагаа(н)* – «ак», *сагаан үлтэнэг* – «өрәңге». Татар теленә *чаган* сүзе монгол теленнән кергән дип санала (Фасеев, 1969: 189). Татар оронимиясендә *чаган* фитонимик термины белән *Чаганлык чокыры* (Кичүчат авылы, Әлмәт районы), *Чаганлык тавы* (Бикморас авылы, Әлмәт районы) җирле географик объект атамалары барлыкка килгән.

«Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *өрәңге* – киртле киң яфраклы агач; чаган, диелгән (ТТАС, т. 3, 1981: 706). Уйг. *ерән,*

*үрәнги*, чув. *верене* «клен». Болар монгол телендәге *өрәң, үрәңхи* «ак, аксыл», борынгы монгол һәм төркидәге үрүң «ак», сүзенә нисбәтле барлыкка килгәннәр. *Өрәңгеле тау* (Сәпәй авылы, Азнакай районы), *Өрәңгеле түбә* – тау атамасы (Урсай авылы, Азнакай районы) һ.б.

Татар теленең лексик составында монгол катламының билгеле күләмдә урын алуы һәм оронимик системада аз булуы, төрки-татарларның монголлар белән күп гасырлар дәвамында, этногенетик якка караганда, сәүдә. иҗтимагый-тарихи җирлектә аралашуы нәтиҗәсе булып тора.

Гарәп-фарсы алынмалары урын алган оронимнар. Тормыш-көнкүрешнең төрле тармакларына караган күп кенә гарәп-фарсы алынмалары татар телендә географик терминнар һәм җирле географик объект атамалары буларак та киң кулланылышка кереп китә.

Гарәп телендәге *кальга* «курган, крепость, ныгытма, замок» ойконимик термины, болгар-татар теленә, *кала* әйтелеше алып, «шәһәр» мәгънәсендә кабул ителгән (Саттаров, 1992: 117). *Кала* ойконимик термины *Калалы тау* (Бишмунча авылы, Әлмәт районы), *Кала тавы* – тау исеме (Яңа Сәет, Түреш авыллары, Мөслим районы), *Кала тау* (Катыш Каран авылы, Сарман районы) оронимнары составында урын алган.

Гарәп телендә «үлгәннәрне күмү урыны, каберлек» төшенчәсенә ия *зиярәт* сүзе (ГТРАС, т. 1, 1993: 132), ойконимик термин буларак, *Зират башы* – урын атамасы (Кичүчат авылы, Әлмәт районы), *Зират тавы* (Бикморас, Түбән Мактама авыллары, Әлмәт районы), *Зират үре* (Шарлама авылы, Әлмәт районы), *Зират чокыры* (Иске Минзәләбаш, Иске Кәшер, Кормаш, Күктау авыллары, Сарман районы) җирле географик объект атамаларында урын алган.

*Мәчет тавы* (Кирлегәч авылы, Лениногорск районы; Үчәлле авылы, Азнакай районы), *Мәчет чокыры* (Уразай авылы, Азнакай районы) җирле географик объект атамалары составында «мөселманнарда: намаз укый, гыйбадәт кыла торган йорт» төшенчәсенә ия мәчет сүзе урын алган. *Мәчет* ойконимик терминының нигезендә гарәп телендәге *мәсҗид* сүзе ята.

*Мулла бакчасы* (Кама Елга авылы, Әлмәт районы), *Мулла кулы таулары* (Туйкә авылы, Азнакай районы) микрооронимнарында

генезислары гарәп теленә нисбәтле, «укымышлы кеше, өйрәтүче, укытучы, дингә өндәүче» мәгънәсенә ия *мелла ~ мулла* рухани дәрәҗәсен аңлатучы сүз ята.

Сәүдә һәм юл йөрү белән бәйле, гарәби чыгышлы *мал* – «байлык (терлек, акча һәм кулдагы булган нәрсәләр)», *кәрван* – «юлчылар, мал йөртүчеләр төркеме», *хәзинә* – «казна, дәүләт, байлык; акча һәм байлыклар саклану урыны; хәзинә, җиргә күмелгән акча» мәгънәләрендәге сүзләр регионадагы *Мал буе* – болын исеме (Урманай авылы, Азнакай районы), *Мал йөрәге чокыры* (Урсалбаш авылы, Әлмәт районы), *Кәрванбикә тавы* (Татар Димскәе авылы, Бөгелмә районы), *Хәзинәле тау* (Кама Елга авылы, Әлмәт районы) җирле оронимик объект атамаларында урын алганнар.

Күп гасырлар буе татар теленә керә барган гарәп һәм фарсы алынмалары татар теленең актив лексикасында гына түгел, оронимикасында да шактый зур урын биләп тора.

С л а в я н  (р у с)  к а т л а м ы. Тарих дәвамында татар теленә, рус теленнән һәм аның аша Көнбатыш Европа телләреннән байтак кына географик терминнар һәм аларга нигезләнеп ясалган географик атамалар да кулланылышка алына (Саттаров, 1998: 409).

Славян (рус) чыгышлы оронимнарны, татарлар яшәгән җирлектә булуларыннан чыгып, алынма атамалар буларак карыйбыз. Мәсәлән, *Кордон ~ Кардун* – урын атамасы (Мәмәт авылы, Әлмәт районы). Рус. *кордон* – 1) «юлны саклап торучылар яки чик сакчылары отряды»; 2) «чик буе сакчылары, урман каравылчылары һ.б.ш. торган, яшәгән урын» мәгънәләренә ия (РТС, 1991: 299). *Проход ~ Прахут* – урын атамасы (Урсалбаш авылы, Әлмәт районы). Рус. *проход* – «юл, үтеп йөрү юлы, үтә торган юл» төшенчәләрен белдерә (РТС, 1991: 500). Ике тау арасын белдерүче *Кулча* (Исергәп авылы, Баулы районы) орографик объект атамасы рус телендә *кольцо* – «боҗра, алка» ны белдерә.

Әлеге катламга караган татар оронимнарының зур күпчелеген гибрид, ягъни катнаш топонимнар тәшкил итә. *Дегетле баз* – чокыр атамасы (Туйкә авылы, Азнакай районы), рус. *дёготь; Завод тавы* (Кирлегәч авылы, Лениногорск районы) һ.б.ны мисалга китерергә мөмкин.

Элекке заманда татар авылларының җирләре рус боярлары кулында булганлыктан, татар авылларында *бояр* сословие титулы һәм *поп* рухани терминнары белән ясалган оронимнар еш

очрый. *Бояр болыны* (Урдала авылы, Лениногорск районы), *Бояр сырты* – тау исеме (Мәмәт авылы, Әлмәт районы), *Бояр тавы* (Исергәп авылы, Баулы районы), *Бояр йорты акланы* (Бикморас авылы, Әлмәт районы), *Поп малае чокыры* (Кичүчат авылы, Әлмәт районы). Әлеге оронимнарда географик объектның кемгә нисбәтле булуы конкретлаштырылса, *урыс, марҗа* этнонимнары гомумилек төсмерен бирәләр. *Урыс тавы*, (Кичүчат авылы, Әлмәт районы), *Урыслар каршысы* – кисендек атамасы (Кәрәкәшле авылы, Ютазы районы), *Марҗа тавы* (Әлкәй авылы, Азнакай районы).

Рус теленнән татар оронимиясенә кергән лексемаларның кулланылыш диапозоны шактый киң. Оронимнар составында урын алган рус сүзләренең бер өлеше татар теле закончалыкларына буйсындырылып үзгәреш кичергән, ә бер өлеше чыганак телдәгечә сакланган. Татар оронимиясендә рус катламы, нигездә, гибрид атамаларны тәшкил итә.

Тарихи шартлар, халыкның миграциясе, сугышлар, сәүдә һәм икътисади бәйләнешләр татар оронимиясендә Урал-Алтай гомумилегенә, Алтай телләренә нисбәтле фин-угор, иран, төрки-татар, монгол, гарәп-фарсы һәм славян (рус) катламнарын аерып карау мөмкинлеген бирә. Тикшеренүләр татар оронимиясенең иң борынгы этнолингвистик катламын чыгышлары Урал-Алтай һәм Алтай телләре туганлыгына нигезләнгән атамалар һәм терминнар тәшкил итүен күрсәтә. Татар оронимнарының барлыкка килү мәсьәләләрен караганда Урал-Алтай, Алтай телләре гомумилеге исә төрки монгол, тунгус-маньчжур телләре өчен уртак булган, борынгыдан килә торган гомумтел һәм орографик терминнарны үз эченә ала.

Фин-угор катламы татар оронимиясендә мари һәм мордва халыклары тарафыннан барлыкка китерелгән. Иран, монгол катламнары аз өйрәнелгәннәрдән санала. Гарәп-фарсы теленә нисбәтле географик объект атамалары, терминнары татар оронимиясендә алынмалар буларак карала. Рус катламы иң яшь, иң өске катлам булып исәпләнә.

Татар оронимнарының зур күпчелеге төрки-татар чыгышлы. Борынгы төрки, болгар, иске татар аскатламнары төрки-татар катламын барлыкка китерүдә база хезмәтен үтиләр.

## § 28. Татар оронимнарын номинацияләү принциплары

Татар оронимнары атамаларның тәртипсез җыелмасы түгел. Алар барлыкка килүнең ныклы сәбәпләре үзенең номинацияләү һәм мотивлаштыру принциплары булган бөтен бер тулы системаны тәшкил итәләр. Татар оронимнары, нигездә, микротопонимнар составында урын алганлыктан, алар күп очракта микротопоним буларак карап тикшерелә.

Төрки телләр материалына нигезләнеп үткәрелгән семантик төркемләүләр А. Абдрахманов, З.Ф. Әхәтова, Ф.Г. Гарипова, Ф.К. Гриценко, И.В. Дрон, А.А. Камалов, Е.К. Койчобаев, О.Т. Молчанова, Б.Х. Мусукаев, В.Н. Попова, Г.Ф. Саттаров, О. Султаньяев, М.Г. Усманова, А.Ю. Филькова, О.Р. Хисамов, Ф.Г. Хисамитдинова, Р.Ш. Шаһиев һ.б. галимнәрнең хезмәтләрендә урын алган.

Ономастик эзләнүләрнең башка юнәлешләре кебек үк, ялгызлык исемнәрне төркемләүнең дә үзенең фәнни нигезләнгән тарихы бар. Е.М. Черниховская, ономастика тарихында, классификация мәсьәләләренең билгеле бер урын тотуына басым ясап, дистә еллар дәвамында топонимистлар алдында ономастик материалларның бирелешен ничек итеп яхшырак төзү, топонимнарны, антропонимнарны һ.б.ны классификацияләү мәсьәләләре торуы хакында яза (Черниховская, 1970: 65).

Лексик-семантик төркемнәргә бүлеп анализлау – географик атамаларны өйрәнүнең иң киң таралган ысулы. А.А. Камалов исәпләвенчә, классификация теге яки бу тел топонимиясенең барлык төркемнәрен үз эченә алырга, һәм алар семантик яктан түгел, ә атау характерыннан чыгып төркемләнергә тиеш (Камалов, 1994: 27). Шул принцип нигезендә А.А. Камалов топонимнарны өч төркемгә бүлә:

1. Географик объектның билгеләрен белдерүче атамалар;
2. Объектның бер-берсенә мөнәсәбәтләрен белдерүче атамалар;
3. Кеше һәм җәмгыять арасындагы мөнәсәбәтләргә нисбәтле атамалар.

Г.Ф. Саттаров үзенең «Татар топонимиясе» исемле фундаменталь монографик хезмәтендә топонимнарны 1) татар теленең җирле географик терминнарына һәм 2) апеллятив лексикадан ясалган топонимнарга бүлеп анализлый (Саттаров, 1998: 74–337). Н.А. Ласынова башкорт оронимиясе буенча язган «Көньяк-көнчыгыш

Башкортстан оронимиясе» (2004) дигән кандидатлык диссертациясендә, О.Т. Молчанова, Р.Д. Сунчугашев, А.А. Камалов, Р.З. Шәкүров һ.б. хезмәтләренә таянып, оронимнарны ике зур төркемгә бүлә: 1) объектның табигый үзенчәлекләрен чагылдырган оронимнар; 2) кешенең дөньяны кабул итү һәм хуҗалык итү ысулына нисбәтле барлыкка килгән оронимнар. Аларның һәр икесен берничә төркемчәгә бүлә (Ласынова, 2004: 8).

Әлбәттә, әлеге төр төркемләүләр тотрыклы һәм топонимика фәнендә ныклы урын алганнар. Оронимнарны классик рәвештә төркемләгәндә әлеге калып шактый отышлы санала һәм ул атамаларның экстралингвистик табигатен ачарга ярдәм итә.

Югарыда санап киткән галимнәрнең хезмәтләренә таянып, татар оронимнарын ике зур төркемгә бүләбез: 1) объектның табигый үзенчәлекләрен чагылдырган оронимнар; 2) кешенең дөньяны кабул итүенә һәм хуҗалык итү ысулына нисбәтле барлыкка килгән оронимнар.

Объектның табигый үзенчәлекләрен чагылдырган оронимнар. Әлеге төркемгә караган оронимнарга атама бирүнең нигезендә кеше белән бәйле булмаган объектның табигый үзенчәлекләре ята. Оронимнар географик объектның төрле үзенчәлекләрен чагылдыралар. Аларны, үз чиратында түбәндәге төркемчеләргә аерабыз:

1. Төскә нисбәтле оронимнар;

2. Орообъектның үлчәмен, формасын, өлешен, күләмен, табигый климатик үзенчәлекләрен белдергән оронимнар;

3. Оронимнарда казылма байлыклар турындагы мәгълүматларның чагылышы;

4. Объектның башка бер объектка нисбәтле урнашуын белдергән, ориентир вазифасын башкаручы сүзләр кергән атамалар;

5. Сан белән белдерелгән оронимнар;

6. Фитонимик һәм зоонимик терминнар ярдәмендә ясалган атамалар.

*Төскә нисбәтле оронимнар* нигездә туфрак катламының, ятмаларның төсенә һәм андагы үсемлекләр дөньясына, аларның төсенә бәйле. Акбалчык чокыры (Түреш авылы, Мөслим районы), Акйар (Кече Рәс авылы, Биектау районы; Зур Күккүз авылы, Апас районы), *Актау* (Кичүчат, Чупай, Колшәрип, Миңнебай авыллары, Әлмәт районы; Дүсем авылы, Сарман районы), *Алатау, Каратау*

(Кәкре Елга авылы, Азнакай районы) *Кара яр, Зәңгәр тау* (Салих авылы, Баулы районы), *Сары тау* (Шөгер авылы, Лениногорск районы) һ.б.

Әлбәттә, төс белдерә торган аппеллятивларның барысы да оронимнарның туфрак, тау-таш катламының төсенә яисә анда үскән флорага бәйле түгел. Кара, ак, кызыл кебек төсләр башка мәгънәдә дә килергә мөмкин. Ак төс – яктылык, чисталык, башка төрки халыклардагы кебек үк яшәү, бәхет төсе, мәңгелек символы. Мәҗүсилек чорында борынгы төрки халыклар ак һәм кара сүзләренең магик көче бар дип ышанганнар. Ак төсне көн, кояш символы, ә кара төсне төн, җир, туфрак символы итеп караганнар (Тань Аошуан, 2004: 240). Кызыл төс исә, күчерелмә мәгънәдә сәясәт белән бәйләнгән. *Кызылтау* (Әгерҗе, Әсәй, Мәлбагыш авыллары, Азнакай районы), *Кызыл ялан* (Ләшәү Тамак авыыл, Сарман районы) һ.б.

*Орообъектның үлчәмен, формасын, өлешен, күләмен, табигый климатик үзенчәлекләрен белдергән оронимнар* гадәттә антонимик парларны тәшкил итәләр. *Бәләкәй тау – Олы тау* (Мәмәт авылы, Әлмәт районы), *Бәләкәй чакыр – Олы чокыр* (Урсалбаш авылы, Әлмәт районы), *Биек тау* (Кичүчат, Иске Иштирәк, Чүти авыллары, Лениногорск районы), *Биек чагыл* (Сәпәй авылы, Азнакай районы), *Биек чагыл таулары* (Татар Кандызы авылы, Баулы *районы), Озын үр* (Таллы Бүләк авылы, Азнакай районы), *Озын тау* (Әгерҗе авылы, Азнакай районы), *Озын сырт* (Әсәй авылы, Азнакай районы), *Кече тау* (Салагыш авылы, Әгерҗе районы), *Кечкенә тау* (Исергәп авылы, Баулы районы), *Зур аклан* (Урдала авылы, Лениногрск районы) һ.б.

Объектның формасына карап метафорик юл белән ясалган оронимнарны да шушы төркемгә кертеп карыйбыз. Алар нигездә хуҗалык кирәк-яракларына, кеше яки хайван әгъзаларына охшатып аталганнар: *Мич башы тавы, Кылыч тау, Ташлы борын* (Кичүчат авылы, Әлмәт районы) һ.б.

Бер төркем оронимнар географик объектның формасын, күләмен, өлешен, халәтен белдерүче сүзләрдән ясалганнар: *Кысык тавы* (Сәмәрканд авылы, Әлмәт районы), *Өзек арасы, Сай чокыр – Тирән чокыр* (Кичүчат авылы, Әлмәт районы), *Кырынтау* (Иске Иштирәк, Кирлегәч авыллары, Лениногорск районы), *Текә тау* (Татар Кандызы авылы, Баулы районы), *Очлы түбә* (Карамалы авылы, Азнакай районы) һ.б.

Татар оронимнары составында климат үзенчәлекләрен белдергән атамалар, әллә ни күп булмасалар да, очрый. Мәсәлән, *Җылы чокыр* (Нәдер, Югары Мактама авыллары, Әлмәт районы), *Салкын түбә* (Карамалы авылы, Азнакай районы), *Кайнар тау* (Түбән Ләшәү авылы, Сарман районы) һ.б. Хәтта, уңай рельефны белдерүче атама составында тискәре рельефны белдергән *чокыр* термины да урын ала. *Җылы чокыр* – тау атамасы (Тайсуган авылы, Әлмәт районы).

*Оронимнарда казылма байлыклар турындагы мәгълүматларның чагылышы. Акбур чыккан тау* (Сарабиккол авылы, Лениногорск районы), *Акбур чокыры* (Үчәлле авылы, Азнакай районы), *Акбурлы тау* (Туктар Урдаласы авылы, Лениногорск районы), *Бакыр базы калкулыгы, Ак балчык базы* (Кәләй авылы, Әлмәт районы), *Бакыр казнасы* (Кәрәкәшле авылы, Ютазы районы), *Бакыр тавы* (Исергәп авылы, Баулы районы; Сарайлы авылы, Сарман районы), *Дегет базы* (Нәдер авылы, Әлмәт районы), *Дегет чокыры* (Урсалбаш авылы, Әлмәт районы), *Дегетле базы* (Туйкә авылы, Азнакай районы) һ.б.

*Объектның башка бер объектка нисбәтле урнашуын белдергән, ориентир вазифасын башкаручы сүзләр кергән атамалар* шактый күпчелекне алып торалар. *Аргы наратлы тау – Бирге наратлы тау* (Туктар Урдаласы авылы, Лениногорск районы), *Аргы очлы түбә – Бирге олы түбә – Урта очлы түбә* (Чупай авылы, Әлмәт районы), *Аргы чөмәк тау – Бирге чөмәк тау* (Урсалбаш авылы, Әлмәт районы), *Якын тау* (Васильевка авылы, Әлмәт районы) һ.б. Аларның күбесе антонимик парларны тәшкил итәләр.

Шулай ук, орообъектның юнәлешен ачыклау максатыннан, аның кайсы торак пунктка нисбәтле булуын белдереп, ориентир сыйфатында ойконимнар да килә. Мәсәлән: *Нәдер тавы* (Түбән Мактама авылы, Әлмәт районы), *Тархан үре* (Буралы авылы, Азнакай районы) һ.б.

*Сан белән белдерелгән оронимнар* географик объектның санын гына түгел, ә аның урнашу тәртибен дә белдерәләр. *Биштау* (Бишмунча авылы, Әлмәт районы), *Ике тау арасы* (Кичүчат авылы, Әлмәт районы), *Ике яр арасы* (Васильевка авылы, Әлмәт районы), *Беренче чокыр, Икенче чокыр, Өченче чокыр, Дүртенче чокыр* (Иске Актүбә бистәсе, Азнакай районы) һ.б. Оронимнар составында килгән саннар географик объектта урнашкан баш-

ка предмет яки затның санын да күрсәтеп килергә мөмкин: *Биш каен калкулыгы* (Яшәр авылы, Бөгелмә районы), *Алты каен яланы* (Дүсем авылы, Сарман *районы), Ике каен тавы* (Югары Чыршылы авылы, Лениногорск районы), *Кырык кәҗә тавы* (Сарлы авылы, Азнакай районы) һ.б.

*Фитонимик һәм зоонимик терминнар ярдәмендә ясалган атамалар* татар оронимиясенең шактый өлешен тәшкил итәләр. Флорага һәм фаунага кагылышлы мәгълүматлар географик реалийны сурәтләп бирүче иң әһәмиятле чыганаклар булып торалар. Әлеге төркемгә караган географик объект атамаларында регионның тере табигый байлыклары тулысы белән чагылыш таба. Һәм алар табигатьнең бүгенге торышын, халәтен генә түгел, ә үткәнен дә тулы чагылдыралар.

Географик объект атамаларын түбәндәге геоботаник терминнарына нисбәтле оронимнарга һәм зоологик терминнарга нисбәтле оронимнарга бүлеп карыйбыз:

*а) фитонимик терминнарга нисбәтле оронимнар.* Билгеле бер урында теге яки бу төр агачның, үләннең күп булуын, тупланганлыгын, җыелмасын белдерә торган *-лык/-лек, -лы/-ле* кушымчалы сүзләр күп кенә оронимнар составында урын алганнар: *Алмагачлык үре* (Мәмдәл авылы, Азнакай районы), *Баланлы алан* (Баланлы Бүләк авылы, Азнакай районы), *Карагай тавы* (Сугышлы авылы, Лениногорск районы), *Наратлы тау* (Әгерҗе, Мәнәвез авыллары, Азнакай районы; Сугышлы, Шөгер авыллары, Лениногорск районы), *Усаклы түбә* (Яңа Шалты авылы, Баулы районы) һ.б.

Агачлар һәм куаклар бик куе булып, ботакланып-тармакланып үскән урманны белдерүче *чытыр* (ТТАС, т. 3, 1981: 463) термины белән ясалган оронимнар: *Чытыр арасы* – урман арасындагы чокыр, *Чытыр тугае* (Кичүчат авылы, Әлмәт районы) һ.б.

Кыргый үлән исеменә нисбәтле оронимнар: *Абагалы кул чокыры* (Октябрь Бүләге авылы, Азнакай районы), *Бөтнек тавы* (Шөгер авылы, Лениногорск районы), *Тигәнәк чокыры* (Миңлебай авылы, Әлмәт районы) һ.б.;

*ә) зоологик терминнардан ясалган оронимнар.* Татар теленең зоологик терминнарыннан ясалган географик атамаларны Г.Ф. Саттаров алты төркемчәгә аера (Саттаров, 1998: 247). Без дә татар оронимнарын төркемләгәндә шуңа таянабыз.

Кыргый хайван-җәнлекләр исемнәреннән ясалган оронимнар: *Аю сөйрәгән чокыр, Суырлы тау* (Мәмәт авылы, Әлмәт районы), *Бүре тавы* (Колшәрип авылы, Әлмәт районы), *Куян болынлыгы* (Сөендек авылы, Азнакай районы), *Төлке чокыры* (Чалпы авылы, Азнакай районы), *Мал йөрәге чокыры* (Урсалбаш авылы, Әлмәт районы) һ.б.

Киек кошлар исемнәренә нисбәтле оронимнар: *Бөҗыр аланы* (Сәпәй, Туйкә авыллары, Азнакай районы), *Бөркет тавы* (Бишмунча, Нәдер, Тайсуган авыллары, Әлмәт районы; Шөгер авылы, Лениногорск районы), *Карлыгач чокыры* (Тайсуган авылы, Әлмәт районы), *Ябалактау* – тау атамасы (Кама Исмәгыйль авылы, Әлмәт районы) һ.б.

Җир-су хайваннары исемнәреннән ясалган оронимнар: *Елан чокыры* (Сула авылы, Бөгелмә районы) һ.б.

Кешенең дөньяны кабул итүенә һәм хуҗалык итү ысулына нисбәтле барлыкка килгән оронимнар. Һәр номинатив берәмлек атама бирүче хакында мәгълүмат саклый, һәр атама, үз тарихы белән бергә, атама бирүченең кемлеге турында да сөйли. Атама, милли топонимиканың фәнни һәм теоретик нигезе буларак, кеше, аның фикер йөртүе белән бәйләнгән. Ономастик дөнья сурәтендә исем-атама биргән һәр этносның, һәр кешенең, хуҗалык итү ысулы белән бергә, рухи сыйфатлары гамәлгә аша, чагылыш таба, реальләшә. Оронимнарда чагылыш тапкан сәнгатитарихи мәгълүматлар берьяклы гына түгел. Алар үзара берничә блокны берләштерәләр: халык тарихы, иҗтимагый тормыш, халыкның матди байлыгы, рухи дөньясы турында мәгълүмат бирәләр.

Әлеге төркемгә караган оронимнарны классик тәртиптә берничә төркемчәгә аерырга мөмкин:

*1. Антропонимнарга нисбәтле оронимнар.* Антропооронимнар яки антропонимнарга нигезләнеп ясалган географик объект атамалары антропонимик берәмлекләрнең (кеше исемнәре, кушаматлар, фамилияләр, отчестволар) топонимик берәмлекләргә күчүе нәтиҗәсендә барлыкка килә. Кеше һәрвакыт табигать белән бербөтен булып яшәгән. Башка төр топонимик берәмлекләрдән аермалы буларак, оронимнар составында урын алган антропонимнар андагы вакыйга белән бәйле кешенең исемен саклый. Тормышкөнкүреш өчен артык уңай булмаган тау-чокыр исемнәрендә, гадәттә, ул фаҗигале язмышлы затны теркәп калдыра: *Зәйнәп чо-*

*кыры* (Октябрь авылы, Мөслим районы), *Гарифулла чокыры* (Кормаш авылы, Сарман районы), *Җәләй тавы* (Чупай авылы, Әлмәт районы), *Шәрифә болыны* (Яшәр авылы, Бөгелмә районы) һ.б.

Татарларда кешегә фамилия белән мөрәҗәгать итү, нигездә, Октябрь инкыйлабыннан соң гына күзәтелә башлый. Шуңа да, фамилиягә нигезләнгән татар оронимнары күп түгел. Мәсәлән: *Мурзин чокыры* (Салкын Чишмә авылы, Бөгелмә районы), *Варварин чокыры, Варварин тавы* (Дәүләт авылы, Әлмәт районы). Антропооронимнарда татар кеше исемнәре, нигездә, кыскартылмыйча тулы килеш кулланыла.

*2. Этнонимнарга нисбәтле оронимнар.* Асылында нинди дә булса этник төркемне (ыру, кабилә, милләт һ.б.ны) белдерүче сүзләр – этноним урын алган оронимнар татар атамалары арасында еш очрый. Этнооронимнарның барлыкка килүләре бик борынгы заманнарга барып тоташа һәм, башка топонимик берәмлекләр кебек үк, башка этносларның татарлар белән уртак эш-гамәлләр алып баруын, аларның миграциясен, үзара мөнәсәбәтләрен ассызыклый. Мәсәлән, *Урыс тавы* (Кәүҗияк авылы, Сарман районы), *Мукшы чокыры* (Чүти авылы, Лениногорск районы), *Марҗа тавы* (Әлкәй авылы, Азнакай районы), *Чегән чокыры* (Миңнебай авылы, Әлмәт районы), *Чирмеш түбәсе* (Күктәкә авылы, Азнакай районы) һ.б.

*3. Туганлык терминнарына һәм сословие титулларына нисбәтле оронимнар.* Туганлык терминнары катнашып ясалган атамалар, нигездә, ниндидер бер вакыйга, халыкның ул географик объект белән бәйле мөнәсәбәтенә нисбәтле туа. Татар оронимиясендә татар әдәби телендәге туганлык терминнары белән түбәндәге оронимнар барлыкка килгәннәр: *Бәбәй чокыры* (Нәдер авылы, Әлмәт районы), *Кызлар акланы* (Сәмәрканд авылы, Әлмәт районы), *Кызлар тавы* (Кәтем, Сукаеш авыллары, Сарман районы), *Хатынташ тавы* (Иске Урыссу авылы, Ютазы районы), *Ирләр калкулыгы* (Югары Чыршылы авылы, Лениногорск районы), Бабай атавы (Шәрләрәмә авылы, Сарман районы) һ.б.

Төрки-татар, гарәп-фарсы чыгышлы сословие титуллары түбәндәге атамалар составында урын алганнар: *Мулла кулы таулары* (Туйкә авылы, Азнакай районы; Тайсуган авылы, Әлмәт районы), *Абыстай* («мулла, мөәзин хатыны») *аланлыгы, Ахун* («остаз, мөселманнарда өлкән рухани») *чокыры* (Карагай авылы,

Лениногорск районы), *Хуҗа* («милек иясе, өйрәтүче, әфәнде») *чокыры* (Бишмунча авылы, Әлмәт районы) һ.б.

Рус теленнән кергән сословие титуллары белән *Справник тавы* (Бәйрәкәтамак, Иске Урыссу авыллары, Ютазы районы), *Поп малае чокыры* (Кичүчат авылы, Әлмәт районы) һ.б. атамалар ясалган.

*4. Хезмәт кораллары, тормыш-көнкүреш әйберләре һәм шулар белән бәйле кәсеп-һөнәргә нисбәтле оронимнар.* Татар халкының күптәннән утрак тормыш белән яшәве, игенчелек, терлекчелек һ.б. кәсеп-һөнәр белән шөгыльләнүләре оронимнарда чагылыш тапкан. *Каравыл тавы* – тау атамасы (Иске Урыссу авылы, Ютазы районы; Татар Кандызы авылы, Баулы районы), *Базар чокыры* (Яңа Кәшер авылы, Әлмәт районы), *Тегермән тавы* (Яңа Имән авылы, Сарман районы), *Умарталык акланы* (Мәнәвез авылы, Азнакай районы) һ.б.

Хезмәт кораллары, тормыш-көнкүреш әйберләре атамаларына нисбәтле оронимнар: *Балталы тугае* (Кирлегәч авылы, Лениногорск районы), *Кибән тавы* (Яңа Шалты авылы, Баулы районы), *Көл тавы* (Иске Каразирек авылы, Ютазы районы), *Сәке чокыры* (Сарабиккол авылы, Лениногорск районы), *Терекөмеш тавы* (Иске Иштирәк авылы, Лениногорск районы) һ.б.

*Дегет кайнаткан чокыр* (Үзбәк авылы, Лениногорск районы), *Таш кискән тау* (Сөләй авылы, Әлмәт районы), *Акбур чыккан тау* (Сарабиккол авылы, Лениногорск районы), *Янган тау* (Миңлебай авылы, Әлмәт районы) һ.б. оронимнар шул урында булган эш-вакыйгаларны чагылдыралар.

*5. Шул урында булган вакыйга, гореф-гадәт, йола, дин белән бәйле терминнарга нисбәтле һәм эмоциональ бәяләү сыйфатларын белдерелгән оронимнар.* Татар халкы гасырлар буе яшәп килгән гореф-гадәтләренә, ышану-инануларына, диненә зур хөрмәт саклап яшәгән. Үз җаны аша уздырган вакыйгалар, аларга булган мөнәсәбәте, бәясе, хис-кичерешләре географик объект атамаларында да чагылыш таба: *Җыен тавы* (Күктәкә авылы, Азнакай районы), *Сабан туе болыны* (Дүсем авылы, Сарман районы), *Изгеләр зираты* (Кичүчат, Югары Мактама авыллары, Әлмәт районы; Кирлегәч, Урмышлы авыллары, Лениногорск районы), *Гает аланлыгы* (Митрәй авылы, Азнакай районы), *Җомга каберлеге* (Тымытык авылы, Азнакай районы) һ.б.

Мифологик терминнар түбәндәге оронимнар составында урын алган: *Мәчкәй тавы* (Кичүчат авылы, Әлмәт районы), *Җен*

*чокыры* (Кирлегәч авылы, Лениногорск районы; Мәмәт авылы, Әлмәт районы), *Җенле тау* (Түреш авылы, Мөслим районы; Яшәр авылы, Бөгелмә районы), *Пәриле чокыр* (Актүбә эшчеләр бистәсе, Азнакай районы) һ.б.

*6. Охшату-чагыштыру аша исемләнгән (метофорик) атамалар.* Татар оронимиясендә теге яки бу географик объектның кеше яки хайван әгъзасы, тормыш-көнкүреш әйбере һ.б. белән форма охшашлыгы нигезендә күп кенә метофорик географик атамалар барлыкка килгәннәр.

Кешенең табигатьне үзләштерүе, үзенең әгъзасы аша барган. Шуңа да, табигатьтә географик объект атамаларында кеше әгъзасы исемнәре урын алган. Мисал өчен, кайберләренә тукталып үтик: *Борынчак* – борын кебек аерылып, чыгып торган басу атамасы (Сөләй авылы, Әлмәт районы), *Йөрәк тавы* – йөрәк формасындагы тау атамасы (Мәсгут авылы, Азнакай районы), *Ташлы борын* – борын кебек алга чыгып торган калкулык атамасы, *Тукмак кул тавы* (Кичүчат авылы, Әлмәт районы).

Географик объектның формасын тормыш-көнкүреш әйберләренә охшатып аталган оронимнарга *Калалы тау* – зур-зур ташлары калкып торган тау атамасы (Бишмунча авылы, Әлмәт районы), *Кылыч тау* (Бишмунча, Кичүчат авыллары, Әлмәт районы; Бәйрәкә авылы, Ютазы районы; Бәкер, Туктар Урдаласы авыллары, Лениногорск районы; Карамалы авылы, Азнакай районы), *Көймә тавы* (Кызылъяр авылы, Баулы районы), *Көянтә тау* (Урсалбаш авылы, Әлмәт районы), *Пич башы тавы* (Кичүчат, Сәмәрканд авыллары, Әлмәт районы), *Күчкемә тавы* (Татар Кандызы авылы, Баулы районы). Татар теленең минз., бөре сөйләшләрендә көймә – *кәмә* дип атала (ДС, 1958: 98). Ә яңгыр яки кар суы ташкыны каз.ар.-крш., зәй-крш. сөйләшендә *күч* дип йөртелә (ТТДС, 1969: 287). Ягъни, тау үзенең формасы белән ташуны кичә торган көймәгә охшаган.

*7. Топонимик советизмнар*, ягъни Октябрь инкыйлабы һәм аннан соңгы тормыш-көнкүреш вакыйгалары белән бәйле атамалар ойконимнар составында яхшы ук урын алсалар да, оронимнарда әллә ни күп түгел: *План тавы* (Кәкре Елга авылы, Азнакай районы), *Беренче Май акланы, Динамо чокыры* (Таллы Бүләк авылы, Азнакай районы) һ.б.

Соңгы вакытта телне кеше, аның фикерләве, дөньяны кабул итүе белән бәйләп өйрәнә торган когнитив юнәлеш тел гыйлеменең

төрле тармакларына үтеп керде. Үзенең ныклы нигезе булган ономастика тармагы да бу агымнан читтә калмады. Беренче карашка, ономастика фәненең әлеге юнәлешкә кереп китүе башкаларга яки заманга ияреpгә тырышу булып күренсә дә, нигездә ул ономастика фәненең киләчәген билгели.

Һәрбер милләтнең менталитеты төркем сыйфатына ия һәм бу сыйфат кешеләр тарафыннан үзе яшәгән тирәлекне аңлап, шунда яшәп формалаша. Ә ментальлек исә, халык үзенең асылы дип санаган милли тел, милли традицияләр, милли яшәү рәвеше, милли мәдәният, халыкның тапкырлыгы, зирәклеге тәэсирендә барлыкка килә.

Номинациянең үсеш юллары һәм юнәлешләре, нигездә, бөтен милләтләр өчен уртак булса да, аермалы яклары да шактый. Атама тик торганнан гына барлыкка килми. Аның өчен географик объектның атама алырга хаҗәте булу кирәк. Һәр атаманың беренчел мотивировкасы була. Һәм ул, яшәве, кулланышы дәвамында акрынлап юкка чыга. Гадәттә, исем-атама сөйләмдә, аралашу нәтиҗәсендә охшату-чагыштыруга нигезләнеп барлыкка килә һәм алар атама бирүченең үзләренә генә билгеле була. Гамәлдә йөреп, вакыт иләге аша узганнан соң, ул телдә берегеп кала.

Топонимияне, шул исәптән оронимияне когнитив юнәлештә билгеле бер семантик кыр буларак концептларга туплап карау әлеге атамаларны бирүче халыкның телдәге дөнья сурәтен ачыкларга ярдәм итә.

Оронимнар кешенең дөнья турындагы белемнәрен бер системага сала. Аның дөньяга карашын формалаштыруда иң актив элементларның берсе булып тора. Алар географик чынбарлыкның, реалийларның кеше аңындагы беренчел чагылышы. Һәр атама үз тарихы белән бергә атама бирүченең кемлеге турында да сөйли. Атама – милли дөнья сурәтенең иң асыл сыйфаты. В.И. Постовалова әйткәнчә, ул «үзендә тудыручының сыйфатларын саклап килә» (Постовалова, 1998: 48).

Ономастик берәмлекләрне, шул исәптән оронимнарны лингвокогнитив яктан анализлау әле башлангыч дәрәҗәдә генә. Шулай да, әлеге юнәлештә эшләүче Е.Л. Березович, Г.Р. Галиуллина, Н.Д. Голев, М.В. Голомидова, Л.М. Дмитриева, М.Э. Рут, В.И. Супруннарны атап үтү урынлы булыр.

Когнитив лингвистика тел күренешләрен антропоцентрик (үзәгендә кеше торган) күзлектән өйрәнергә мөмкинлек бирә, тел формалары нигезендә ятучы белемнәрнең когнитив структурасын күрергә ярдәм итә. Тел берәмлекләренең эшчәнлеген ментальь процесслар күзлегеннән чыгып аңлату, менталитет һәм чынбарлык фактларына реакция үзенчәлекләрен, сөйләм коммуникациясе кагыйдәләрен, дөньяны күзаллау кыйммәтләрен исәпкә алып, оронимиянең туу һәм юк ителү стратегиясен ачыклау мөмкинлеге бирә.

Когнитив семантика концепциясендә мәгънә – ул менталь феномен. Һәм ул, абстракт символларга гына кайтарылып калдырылмыйча, ничек бар шулай өйрәнелергә тиеш, дигән караш төп урынны алып тора.

Оронимнарның, нигездә, төгәл авторы юк, ул халыкныкы. Аның авторы бер милләт яки билгеле бер төбәк халкы. Шул халык географик чынбарлыкка атама биргәндә үзен «таба» һәм, киресенчә, үзенең уй-фикерләрен, хис-кичерешләрен чагылдырган үз милли дөньясын, шул дөньяда үзен күрсәтә (Бабенко, 2004: 97).

Шулай итеп, ороним ике яклы була: бер яктан, географик объект атамасы үзенә исем биргән милләтнең йөзен күрсәтә, икенче яктан, объектив чынбарлыкны, дөнья сурәтен яктырта.

Оронимиянең мәгънә ягын ачыклау өчен семантик кыр термины кулланыла. Семантик кырны тикшергәндә исә, «кеше», «вакыт», «кыр-мохит» төшенчәләреннән башка мөмкин түгел. Чөнки атама антропоүзәк сыйфатка ия. Алда әйтелгәнчә, исематаманы кеше ягъни билгеле бер халык вәкиле бирә. Һәм ул милләтнең рухи дөньясын, тел үзенчәлеген, фикерләү рәвешен чагылдыра. Й.Л. Вайсгербер сүзләре белән әйтсәк, «милләтнең бөтен әйтергә теләгәне, фикерләү чаралары теленә салынган» (Вайсгербер, 2004: 105). Алар реаль чынбарлык турында мәгълүмат кына биреп калмыйлар, ә кешенең катлаулы хисләр дөньясын, кәефен, омтылышларын күрсәтәләр (Храпченко, 1982: 328).

Когнитив лингвистиканың төп төшенчәләренең берсе – кешенең телдә чагылдырылган әйләнә-тирә дөнья объектлары һәм күренешләре турындагы менталь күзаллауларның билгеле бер җыелмасы, шулай ук үзе турындагы күзаллаулар җыелмасы булган «концепт» термины. Концепт терминын шәрехләүдә фикер каршылыклары булса да (Җамалетдинов, 2006: 90–93), күп кенә галимнәр тарафыннан әйтелгән төп фикерне җыйнап күрсәтергә

мөмкин. Концепт – чынбарлык күренешләренең, объектларының билгеле бер телдә сөйләшүчеләрнең милли үзенчәлекләренә бәйле рәвештә тудырылган символик сурәтенең телдәге чагылышы, прагматиклашкан семантик берәмлеге.

Е.Л. Березович фикеренчә, топонимнарга, шул исәптән оронимнарга, концептуаль анализ ясау аларның семантик кыры оешуның эчке закончалыкларына игътибар итәргә мөмкинлек бирә (Березович, 1997:24).

Татар оронимнарын номинацияләү принципларын когнитив яссылыкта карап концептуаль анализ ясаганда, беренче катлам итеп микротопонимик модельләрне билгеләү тора. Оронимик модель булып охшаш сыйфатларга, бер типтагы билгеләргә ия булган географик объект атамалары санала (Березович, 1997: 27).

Тематик яктан охшаш оронимик модельләрне семантик кыр барлыкка китерә. Татар оронимнарын ун концептка бүлеп карарга мөмкин. Һәр концепт үз эчендә берничә семантик кырга, ә алар үз чиратында модельләргә бүленә.

Без, Е.Л. Березович, М.Э. Рут, В.И. Супруннарның хезмәтләренә таянып, когнитив яссылыкта түбәндәге номинацияләү принципларын тәкъдим итәбез.

1. «Кеше» концепты.

1.1. *«Ир-ат» семантик кыры.* Аның иң киң таралган моделе булып антропоним + объект тора: *Абуталип түбәсе* (Мәсгут авылы, Азнакай районы), *Әмин тавы* (Урманай авылы, Азнакай районы), *Гарифулла чокыры* (Кормаш авылы, Сарман районы), *Вәли тугае* (Кичүчат авылы, Әлмәт районы), *Пите тугае* (Кәләй авылы, Әлмәт районы), *Мурзин чокыры* (Салкын Чишмә авылы, Бөгелмә районы) һ.б.

Әлеге семантик кырны тагын берничә модельгә – кушаматларга, фамилияләргә таркатырга мөмкин. Әлеге төр бүленеш нинди форманың киңрәк таралышын ачыкларга мөмкинлек бирә. Антропонимнарга нигезләнгән татар оронимнарында тулы ир-ат исеме зур күпчелекне тәшкил итә.

1.2. *«Хатын-кыз» семантик кыры*нда киң таралган берничә модель аерыла. Модель 1. Антропоним + объект: *Сәлимә тау* (Кичүчат авылы, Әлмәт районы), *Зифа яланы* (Урсалбаш авылы, Әлмәт районы), *Сәмига тавы* (Мәнәвез авылы, Азнакай районы), *Гөләй яланы* (Әлкәй авылы, Азнакай районы) һ.б. Модель 2. *Кар-*

*чык, әби* + объект: *Карчыклар чокыры* (Шыгай авылы, Сарман районы), *Әби тавы* (Керәшен Сәрдәсе авылы, Питрәч районы) һ.б. Модель 3. *Кыз* + объект: *Кызлар басуы* (Актүбә эшчеләр бистәсе, Азнакай районы), *Кыз кала асты сырты* (Яңа Ибрай авылы, Аксубай районы), *Кыз кала асты* (Янтык авылы, Балык Бистәсе районы), *Кыз тугае* (Шәрләрәмә авылы, Сарман районы), *Кызлар дугае* (Иске Мичән авылы, Саба районы) һ.б.

«Хатын-кыз» семантик кырында антропооронимнар күбрәк тигез рельеф белән бәйле атамаларда урын ала. Кире һәм уңай рельефны атаганда антропонимнар аз кулланыла.

1.3. *«Этнос» семантик кыры.* Модель 1. Төрки этноним + объект: *Типтәр басуы* (Сәпәй авылы, Азнакай районы), *Башкорт тугае* (Бишмунча авылы, Әлмәт районы), *Мишәр тавы* (Ләшәү Тамак авылы, Сарман районы), *Чуваш сырты* (Чупай авылы, Әлмәт районы), *Нугай казындылары* (Үчәлле авылы, Азнакай районы) һ.б. Модель 2. Төрки булмаган этноним + объект: *Мукшы чокыры* (Чүти авылы, Лениногорск районы) *Чегән тавы* (Октябрь Бүләк авылы, Азнакай районы), *Урыс тавы* (Кичүчат авылы, Әлмәт районы), *Ар тавы* (Кенәбаш авылы, Балтач районы) һ.б.

1.4. *«Кеше әгъзалары, органнары» семантик кыры.* Модель 1. Анатомик термин + объект: *Саз башы тугае* (Сарлы авылы, Азнакай районы), *Озынкул тавы* (Юг. Чыршылы авылы, Лениногорск районы), *Олы борын аланы* (Карабаш эшчеләр бистәсе, Бөгелмә районы), *Чырай түбәсе* (Октябрь Бүләге авылы, Азнакай районы), *Күт бите* (Иске Кәшер авылы, Сарман районы), *Ботлык* – җир һәм тау атамасы (Олы Салтык авылы, Кама Тамагы районы), *Буксә печәнлеге* (Пүскән авылы, Балтач районы), *Хаҗи бот арасы* (Әлге авылы, Кукмара районы) һ.б.

2. «Гаилә» концепты.

2.1. *«Ана» семантик кыры.* Модель 1. Туганлык термины + объект: *Әсәй аланы* (Әсәй авылы, Азнакай районы), *Хатынташ тавы* (Урыссу авылы, Ютазы районы), *Әби чирәме* (Янурыс авылы, Сарман районы) һ.б.

2.2. *«Ата» семантик кыры.* Модель 1. Туганлык термины + объект: *Ирләр калкулыгы* (Югары Чыршылы авылы, Лениногорск районы), *Бабай атавы* (Шәрләрәмә авылы, Сарман районы; Туктар Урдаласы авылы, Лениногорск районы), *Баба тавы* (Танай Турай авылы, Апас районы) һ.б.

3. «Йорт, каралты-кура» концепты.

3.1. *«Йортның өлешләре» семантик кыры.* Модель 1. Йорт өлешләре + объект: *Олы таш мич тавы* (Әгерҗе авылы, Азнакай районы), *Пич башы тавы* (Кичүчат авылы, Әлмәт районы; Татар Янтыгы авылы, Лаеш районы) һ.б.

3.2. *«Йорт җиһазы һәм кирәк-яраклары» семантик кыры.* Модель 1. Йорт кирәк-ярагы + объект: *Әрҗәле тау* (Кама Исмәгыйль авылы, Әлмәт районы), *Чүлмәк тау* (Борнак авылы, Балтач районы) һ.б. *Сәке чокыры* (Сарабиккол авылы, Лениногорск районы), *Ястык тау* (Кили авылы, Балтач районы) һ.б.

3.3. *«Ризыклар» семантик кыры. Балагач чокыры* (Чупай авылы, Әлмәт районы), *Майлы беләк* (Урмышлы авылы, Лениногорск районы), *Әпәй тавы* (Кирлегәч авылы, Лениногорск районы; Иске Татар Кармәте авылы, Аксубай районы), *Бәрәңге тау* (Көек авылы, Балтач районы), *Чумар тавы* (Бәзәкә авылы, Алабуга районы) һ.б.

3.4. *«Кием» семантик кыры.* Модель 1. Баш киеме + объект: *Бүрекле тау* (Исергәп авылы, Баулы районы), *Бүрекле тугай* (Түбән Мактама авылы, Әлмәт районы). Модель 2. Аяк киеме + объект: *Чабата тавы* (Әҗмәр авылы, Спас районы). Модель 3. Өс киеме + объект: *Ыштансыз тау* (Юлбат авылы, Саба районы), *Ыштан балагы болыны* (Салагыш авылы, Әгерҗе районы) һ.б.

3.5. *«Хуҗалык кирәк-яраклары» семантик кыры.* Модель 1. Каралты-кура кирәкләре + объект: *Киртәле тау* (Әгерҗе авылы, Азнакай районы), *Киртәлек сырты* (Тат. Димскәе авылы, Бөгелмә районы), *Кунача тавы* (Кама Елга авылы, Әлмәт районы), *Чатра чокыры* (Татар Кандызы авылы, Баулы районы), *Читән тавы* (Салагыш авылы, Әгерҗе районы); Модель 2. Эш кораллары + объект: *Балталы тугае* (Кирлегәч авылы, Лениногорск районы), *Сабан тугае* (Җәнәй авылы, Саба районы), *Сиксән балта аланы* (Олы Бәрәзә авылы, Әтнә районы), *Беләүле тау* (Тайсуган авылы, Әлмәт районы) һ.б.

3.6. *«Йорт хайваннары һәм кошлары» семантик кыры.* Модель 1. Эре терлек + объект: *Сары айгыр тавы* (Тымытык авылы, Азнакай районы), *Сары айгыр түбәсе* (Чупай авылы, Әлмәт районы), *Атлар тугае* (Федотовка авылы, Лениногорск районы), *Сыер тавы* (Сөләй авылы, Әлмәт районы) һ.б. Модель 2. Вак терлек + объект: *Тәкә тавы* (Шөгер авылы, Лениногорск районы), *Кәҗә чокыры* (Шарлама авылы, Әлмәт районы) һ.б. Модель 3. Терлек

+ объект: *Мал йөрәге чокыры* (Урсалбаш авылы, Әлмәт районы), *Мал тавы* (Югары Әлки авылы, Әлки районы) һ.б. Модель 4. Йорт хайваны + объект: *Этаскан үр* (Кама Исмәгыйль авылы, Әлмәт районы), *Эт атавы* (Баскан авылы, Мамадыш районы) һ.б. Модель 5. Йорт кошы + объект: *Каз болыны* (Түбән Мактама авылы, Әлмәт районы), *Әтәч тавы* (Кирлегәч авылы, Лениногорск районы) һ.б.

3.7. *«Бакча культуралары» семантик кыры.* Модель 1. Яшелчә + объект: *Шалкан аланы* (Сарлы авылы, Азнакай районы), *Шалкан чокыры* (Иске Кәшер авылы, Сарман районы), *Кыяр тавы* (Кәкре Елга авылы, Азнакай районы) һ.б. Модель 2. Яшелчәлек + объект *Яшелчә болыны* (Татар Кандызы авылы, Баулы районы), *Яшелчә тавы* (Әнәк авылы, Актаныш районы) һ.б. Модель 3. Җиләк-җимеш + объект: *Алма тавы* (Сөләй авылы, Әлмәт районы), *Чия тау* (Тимәш авылы, Лениногорск районы) һ.б.

4. «Авыл» концепты.

4.1. *«Корылма» семантик кыры.* Модель 1. Хуҗалык корылмалары + объект: *Мунча түбәсе* (Миңнебай авылы, Әлмәт районы), *Ташкеләт чокыры* (Тайсуган авылы, Әлмәт районы) һ.б. Модель 2. Хуҗалыктан читтәге корылмалар + объект: *Тегермән чокыры* (Кичүчат авылы, Әлмәт районы), *Тегермән тау* (Олыяз авылы, Мамадыш районы), *Чатыртау* (Азнакай районы), *Сарай тавы* (Кунып авылы, Балтач районы), *Утар чокыры* (Әшнәк авылы, Алексеев районы), *Чүннек аланы* (Сикертән авылы, Арча районы) һ.б.

5. «Кыр-басу» концепты.

5.1. *«Басу» семантик кыры.* Модель 1. Объект + объект: *Кибән тавы* (Яңа Шалты, Баулы районы; Дүсем, Ләшәү Тамак авыллары, Сарман районы), *Кыр төбәк* (Түбән Мактама авылы, Әлмәт районы), *Әвен базы* (Кече Әтрәч авылы, Тәтеш районы), *Әвен тау асты болыны* (Олы Шыңар авылы, Саба районы) һ.б.

6. «Әйләнә-тирә табигать» концепты.

6.1. *«Кыргый җәнлекләр» семантик кыры.* Модель 1. Кыргый җәнлекләр + объект: *Бүре базы* (Карамалы, Туйкә авыллары, Азнакай районы; Азалак, Саклау авыллары, Сарман районы), *Бүре калкулыгы* (Мәндәй авылы, Азнакай районы), *Бүре убасы чокыры* (Сәпәй авылы, Азнакай районы), *Аю чокыры* (Яшьләр авылы, Сарман районы), *Куян аланы* (Югары Чыршылы авылы, Лениногорск районы), *Төлке тавы* (Иске Кәшер авылы, Сарман районы).

Модель 2. Кимерүчеләр + объект: *Бурсык итәге* (Кичүчат авылы, Әлмәт районы), *Сорка аланы* (Югары Чыршылы авылы, Лениногорск районы) һ.б.

6.2. *«Кыргый кошлар» семантик кыры.* Модель 1. Кешеләргә якын + объект: *Торна тугае кыры* (Шарлама, Әлмәт районы), *Торна чагылы* (Каракашлы авылы, Ютазы районы), *Карлыгач чокыры* (Тайсуган авылы, Әлмәт районы).һ.б. Модель 2. Кешедән ераклашкан + объект: *Ябалак тавы* (Иске Кәшер авылы, Сарман районы), *Бөркет тавы* (Мәсәгут авылы, Азнакай районы), *Чәүкә тавы* (Нөркәй авылы, Сарман районы), *Песнәк тавы* (Татар Кандызы авылы, Баулы районы).

6.3. *«Сөйрәлүчеләр һәм балыклар» семантик кыры*. Модель 1. Сөйрәлүчеләр + объект: *Бака тамагы болыны* (Туктар Урдаласы авылы, Лениногорск районы), *Елан тавы* (Чалпы авылы, Азнакай районы), *Елан чокыры* (Сула авылы, Бөгелмә районы) һ.б.

6.4. *«Үсемлекләр» семантик кыры.* Модель 1. Ашарга яраклы үсемлекләр + объект: *Балтырган тавы арасы* (Әгерҗе авылы, Азнакай районы), *Бөрлегән болыны* (Елгабаш авылы, Мөслим районы), *Кычыткан чокыры* (Иске Мнзәләбаш авылы, Сарман районы), *Кымызлык чокыры* (Чупай авылы, Әлмәт районы). Модель 2. Дару үләннәре + объект: *Бөтнек тавы* (Шөгер авылы, Лениногорск районы), *Мәтрүшкә аланы* (Явлаштау авылы, Саба районы); Модель 3. Хуҗалык материалы вазифасындагы үсемлек + объект: *Җитен атавы* (Урсалбаш авылы, Әлмәт районы), *Мүк өсте акланы* (Тукт.Урдала авылы, Лениногорск районы), *Мүк тавы* (Кама Елга авылы, Әлмәт районы). Модель 4. Чүп үләне + объект: *Алабута яланы* (Тымытык авылы, Азнакай районы), *Сарут аланы* (Сәпәй авылы, Азнакай районы), *Тигәнәк чокыры* (Миңлебай авылы, Әлмәт районы; Чалпы авылы, Азнакай районы) һ.б.

6.5. *«Казылма байлыклар» семантик кыры*. Модель 1. Файдалы казылмалар + объект: *Дегет базы* (Чупай авылы, Әлмәт районы), *Дегет чокыры* (Урсалбаш авылы, Әлмәт районы), *Бакыр шахтасы* (Нөркәй авылы, Сарман районы), *Бакыр базы* (Ләшәү Тамак авылы, Сарман районы), *Известь тавы* (Уразай авылы, Азнакай районы) һ.б.

7. «Тышкы дөнья» концепты.

7.1. *«Сословие» семантик кыры.* Модель 1. Социаль статус + объект: *Бояр болыны* (Тукт. Урдала авылы, Лениногорск районы),

*Бояр сырты* (Мәмәт авылы, Әлмәт районы), *Байлар базы* (Карабаш эшчеләр бистәсе, Бөгелмә районы), *Алпавыт тау башы* (Иске Салман авылы, Әлки районы), *Кенәз аланы* (Урман асты Шонталысы авылы, Алексеев районы) һ.б.

7.2. *«Сугыш» семантик кыры.* Модель 1. Сугышчы + объект: *Солдат печмәне чокыры* (Солдат Печмәне авылы, Бөгелмә районы), *Солдат чалуы* (Тау иле авылы, Яшел Үзән районы), *Солдатлар кыегы* (Мазиково авылы, Апас районы). Модель 2. Корал + объект: *Кылыч тау* (Кичүчат авылы, Әлмәт районы; Бәкер авылы, Лениногорск районы), *Уклы тау* (Кама Исмәгыйль авылы, Әлмәт районы) һ.б.

7.3. *«Тарих» семантик кыры.* Модель. 1. Тарихи шәхес + объект: *Сталин чокыры* (Елхово авылы, Әлмәт районы), *Пугач путбалы* (Бәкер авылы, Лениногорск районы), *Пугачау тавы* (Катыш Каран авылы, Сарман районы), *Чапай тавы* (Олы Бәрәзә авылы, Әтнә районы). Модель 2. Социалистик җәмгыять» + объект: *Коммунизм тавы* (Бишмунча авылы, Әлмәт районы), *Лагерь акланы* (Мәнәвез авылы, Азнакай районы) һ.б.

7.4. *«Сәүдә» семантик кыры.* Модель. 1. Объект + объект: *Базар чокыры* (Яңа Кәшер авылы, Әлмәт районы), *Базар тавы* (Тау иле авылы, Яшел Үзән районы), *Мөгаҗи тавы* (Сөләй авылы, Әлмәт районы). Модель 2. Акча + объект: *Хәзинәле тау* (Кама Елга авылы, Әлмәт районы), *Тәңкә тавы* (Пшәңгәр авылы, Балтач районы) һ.б.

7.5. *«Сәнгать, фольклор» семантик кыры.* Модель 1. Мифик образ + объект: *Җен чокыры* (Колшәрип, Мәмәт авыллары, Әлмәт районы), *Пәриле тау* (Яңа Шалты авылы, Баулы районы), *Пәриле чокыр* (Актүбә эшчеләр бистәсе, Азнакай районы), *Мәчкәй тавы* (Кичүчат авылы, Әлмәт районы), *Пәриле каен төбе* (Иске Рәҗәп авылы, Спас районы). *Шайтан чокыры* (Зур Күккүз авылы, Апас районы), *Шүрәле атавы* (Олы Урсак авылы, Кайбыч районы); Модель 2. Йола, бәйрәм + объект: *Сабан туе тавы* (Сәпәй авылы, Азнакай районы), *Җыен тавы* (Күктәкә авылы, Азнакай районы) һ.б.

7.6. *«Дин» семантик кыры.* Модель 1. Объект + объект: *Мәчет тавы* (Үчәлле авылы, Азнакай районы; Кирлегәч авылы, Лениногорск районы) һ.б. Модель. 2. Дини титул + объект: *Мулла аланы* (Күктау авылы, Сарман районы), *Ахун чокыры* (Карагай

авылы, Лениногорск районы), *Мөәзин чокыры* (Әҗмәр авылы, Спас районы), *Мөәзин акланы* (Иске Карамалы авылы, Мөслим районы) һ.б.

7.7. *«Бина» семантик кыры.* Модель 1. Объект + объект: *Клуб тавы, Мәктәп тавы* (Карамалы авылы, Сарман районы), *Завод тавы* (Кирлегәч авылы, Лениногорск районы; Явлаштау авылы, Саба районы), *Завод өсте* (Япанчы авылы, Әтнә районы). *Завод үзәне* (Ор авылы, Балтач районы).

7.8. *«Һөнәр, хезмәт төре» семантик кыры.* Модель 1. Һөнәр + объект *Капитан тавы* (Кама Исмәгыйль авылы, Әлмәт районы), *Справник тавы* (Бәйрәкәтамак авылы, Ютазы районы), *Тимерче тавы* (Күн авылы, Питрәч районы), *Урманчы болыны* (Көек авылы, Саба районы). *Ындырчы тавы* (Болын Балыкчы авылы, Апас районы), *Контуктор чокыры* (Уразбахты авылы, Мамадыш районы). Әлеге төр объектлар хуҗалык итү, ниндидер бер һөнәр, кәсеп белән шөгыльләнү өчен уңайлы түгел. Шунлыктан, оронимнарда очраган хезмәт төре сирәк таралган һөнәрләрне күрсәтә.

8. «Сан» концепты.

8.1. *«Сан» семантик кыры.* Модель 1. Микъдар саны + объект: *Биш каен калкулыгы* (Яшәр авылы, Бөгелмә районы), *Биштау* (Бишмунча авылы, Әлмәт районы), *Ике каен тавы* (Югары Чыршылы авылы, Лениногорск районы), *Ике тау арасы* (Каенлык авылы, Буа районы). Модель 2. Тәртип саны + объект: *Икенче чокыр* (Актүбә эшчеләр бистәсе, Азнакай районы), *Бишенче Әхмәр тавы* (Чураш авылы, Сарман районы). Модель 3. *Куш, пар* лексемасы + объект: *Куштау* (Айбаш авылы, Биектау районы; Сәпәй авылы, Азнакай районы), *Куштау өсте* (Кызыл Мишә авылы, Саба районы), *Пар болын* (Олы Шыңар авылы, Саба районы) һ.б.

9. «Төс» концепты.

9.1. «*Төс» семантик кыры.* Модель 1. Төс + объект: *Акйар* (Кече Рәс авылы, Биектау районы), *Кашка тау* (Бәркәтә авылы, Чирмешән районы), *Каратау* (Иске Иштирәк авылы, Лениногорск районы), *Кара чокыр* (Иске Байсар авылы, Актаныш районы), *Зәңгәр тау* (Салих авылы, Баулы районы), *Кызыл тау* (Шарлама авылы, Әлмәт районы; Ахун авылы, Актаныш районы), *Кызыл яр* (Елхово авылы, Әлмәт районы; Иске Икшермә авылы, Саба районы), *Сары тау* (Шөгер, Керкәле авыллары, Лениногорск районы), *Сары кыек* (Олы Шыңар авылы, Саба районы) һ.б.

Татар оронимнарын дөнья күренеше белән бәйләп, ягъни когнитив юнәлештә өйрәнү, шул яссылыкта классификацияләү халыкның дөньяны кабул итүенең, фикерләү үзенчәлекләренең, күп гасырлар дәвамында формалашкан милли традицияләрнең телдә чагылышын күрсәтә.

Татар оронимиясендә зур күпчелекне «Тышкы дөнья» концепты алып тора. Ул үз эченә сигез семантик кырны берләштерә. Орообъектларга атама бирүдә кешенең тышкы дөньяны танып белүе күзәтелә. «Йорт, каралты-кура» концепты татар халкының утрак тормыш алып баручы милләт икәнен ачыклый. Әлеге концепт кешенең географик объектларны үзенең йорты, яшәве, көнкүреше аша кабул итүен ассызыклый. Монда ризык та, кием-салым да, йорт кирәк-ярагы һ.б. чагылыш таба. Дөньяны табигать аша кабул итүенең үзенчәлекле ягы булып «әйләнә-тирә табигать» концепты тора.

«Кеше» концепты, семантик кыр ягыннан төрлелеге белән алда әйтелгәннәрдән калышса да, күләм ягыннан иң бае. Әлеге яссылыкта төркемләгәндә татар халкының ир-атка ил тоткасы итеп хөрмәт белән каравын, хатын-кыз исемнәренең тигез һәм тискәре рельефны белдергән орообъект атамаларында күбрәк кулланылуын күрәбез. Алар, нигездә, трагик язмышлар белән бәйле. Туганлык терминнарын караганда өстенлек хатын-кызларга бирелә.

Концептуаль яссылыкта оронимнар аша дөньяны күзаллау – ул акыл эшчәнлеге продукты, фикер йөртүнең, чынбарлыкның һәм дөнья турындагы фикерләрнең чагылышы буларак, телнең үзара тәэсир итешүе. Бу өлкәдәге эзләнүләрнең нәтиҗәләрен гомумиләштереп, оронимнар ярдәмендә дөньяны күзаллауны тел чаралары ярдәмендә системалаштырылган әйләнә-тирә дөнья турындагы белемнәр дияргә мөмкин.

## § 29. Татар оронимнары төзелеш-ясалышында төп үзенчәлекләр

Татар оронимнары, ялгызлык исемнәрдән, бигрәк уртаклык исемнәргә якын тора. Шуңа да, аларның төзелеш-ясалыш үзенчәлекләрен тикшергәндә, күмәклек исемнәре өчен кулланыла торган калыпларга нигезләнәбез.

Оронимнарны төзелеш һәм ясалыш ягыннан өйрәнү-анализлау топонимик, шул исәптән оронимик тикшеренүләрнең аерылгысыз өлеше.

Аерым җирлекләргә, төрле телләргә караган оронимнарның төзелеш үзенчәлекләрен, формаларын тикшерү өчен төрле алымнар кулланыла.Төрки чыгышлы географик атамаларның төзелеш-ясалыш үзенчәлекләре С. Атаныязов (1990), А.А. Бонюхов (1972), Ф.Г. Гарипова (2004), Т.Д. Джанузаков (1976), А.А. Камалов (1994), Е.К. Койчубаев (1967), Г.Е. Корнилов (1972), С.М. Молла-заде (1978), О.Т. Молчанова (1983), Б.Х. Мусукаев (1980), Г.Ф. Саттаров (1998), Р.Х. Субаева (1964), Ф.Г. Хисамитдинова (1991), Р.З. Шәкүров (1973) һ.б. хезмәтләрендә яктыртыла.

Татар телендә географик объект атамаларының төзелеш-ясалыш үзенчәлекләре мәсьәләсен, беренчеләрдән булып, Г.Ф. Саттаров күтәреп чыга. Ул топонимнарны өч төркемгә бүлә: 1) ияртүче һәм ияртүче кисәкләр төзелешен тәшкил итә торган атамалар; 2) ияртүче кисәктән башка кулланыла торган топонимнар; 3) исем + фигыль төзелмәсеннән гыйбарәт атамалар (Саттаров, 1966).

Б.Х. Мусукаев Кабарда-Балкар Республикасының Баксам һәм Чегем топонимнарын өйрәнеп, аларны 1) гади, 2) катлаулы, 3) тезмә төзелешлеләргә бүлеп карый (Мускаев, 1980).

Төрки тел белемендә географик атамаларны төркемләүдә төрле карашлар бар. Галимнәрнең хезмәтләрендә төрле принциплар кулланып тикшерү күзәтелә.

Гомумән алганда, татар оронимнары төзелеш ягыннан татар теленең сүз ясалыш калыпларына нигезләнгән. Шуларга таянып, оронимнарны 1) гади, 2) кушма, 3) тезмә төзелешлеләргә бүләбез. Үз чиратында алар берничә төркемчәгә аерылалар.

Гади оронимнар дип, бер генә сүздән торган һәм кушымчалары булмаган оронимнарга әйтәләр. Алар үзләре *тамыр* һәм *ясалма* төрләргә бүленә.

*Тамыр оронимнар* дип, нигезләре тамыр белән тәңгәл килгән оронимнар атала. Аларның составын морфемаларга бүләргә мөмкин түгел. Күпчелеге исем сүз төркеменә карыйлар. Нигездә алар географик терминнардан ясалган: *Барлак* – урын атамасы (Кичү авылы, Әлмәт районы), *Чагыл* – тау атамасы, *Шарлык* – калкулык атамасы, *Төбәк* – урын атамасы (Кичүчат авылы, Әлмәт районы), *Түбә* – калкулык атамасы (Урмышлы авылы, Лениногорск районы), *Прахут* («проход») – урын атамасы (Урсалбаш авылы, Әлмәт районы), *Алан* – алан атамасы (Кече Болгаер авылы, Апас районы;

Кече Тормы авылы, Тәтеш районы), *Болын* (Пүскән авылы, Балтач районы) һ.б.

Тикшеренүләр күрсәткәнчә, тамыр оронимнар арасында сыйфат сүз төркеменә караганнары күренми.

*Ясалма оронимнар* дип, атамаларның кушымчалар алу ярдәмендә ясалышына әйтәләр.

Татар телендә, һинд-Европа телләреннән аермалы буларак, сүзләр префикслар белән түгел, сүз ясагыч кушымчалар белән ясалалар. Оронимиядәге бу төр сүз ясалышы бөтен төрки телләргә дә хас күренеш (Атаниязов, 1966: 11; Абдимуратов, 1966: 7; Камалов, 1969; Бонюхов, 1972; Исаев, 1972; Шәкүров, 1973: 18; Алиев, 1975: 5).

Оронимнарның ясалыш ысуллары күмәклек исемнәреннән әллә ни аерылмый. Тик шунысы бар, күмәклек сүзләрдән аермалы буларак, оронимнар ясауда аларның кайберләре генә кулланыла. Шуларның иң активларына тукталып үтик:

*-лык, -лек* кушымчасы ясаучы нигез белдергән предметларның күп үскән яки күп булган, саклanган яки ташланган урынны белдерүче географик объект атамаларын ясый: *Таш**лык*** – урын атамасы (Кирлегәч авылы, Лениногорск районы), *Шар**лык*** – тирә ягы сазлы калкулык (Кичүчат авылы, Әлмәт районы), *Сырт**лык*** (Ямурза авылы, Әгерҗе районы) һ.б.

Э.В. Севортян *-лык* кушымчасының, якут теленнән кала, башка барлык төрки телләрдә сүз ясау өчен еш кулланылуын яза (Севортян, 1966: 20). Нугай, каракалпак, уйгыр, иске үзбәк, башкорт, кумык, азәрбайҗан, төрек, төрекмән һ.б. төрки телләрдә *-лык/-лек* тамырда күрсәтелгән предметның бер урында күп булуын белдерә. Н.З. Гаджиева һәм Б.А. Серебренниковлар да бу кушымчаның җыелма күплекне белдерүе хакында язалар (Гаджиева, Серебренников, 1974, №1: 10). Н.К. Дмитриев исә, *-лык* кушымчасының төрки телләрдә генә түгел, ә монгол телләрендә дә урын алуын әйтә (Дмитриев, 1948: 72).

Н.А. Баскаков аны мөстәкыйль сүзгә кайтарып калдыра: «Төрки *luk-lük,* мөгаен, яңа уйгыр һәм башка телләрдә очрый торган тулы, күп дигән мәгънәдәге *lik* сүзе белән бәйләнгән» дип яза (Баскаков, 1951: 216). Әлеге фикергә Д.Г. Тумашева да кушыла (Тумашева, 1964). Ф.Ә. Ганиев, Н.А. Баскаков фикере дөреслеккә туры килә, дип саный (Ганиев, 2000: 50).

*-лау/-ләү, -ау/-әү* кушымчалары белән ясалган җирле географик объект атамалары: *Утыр* + *-ау* > *Утрау* – кыр атамасы (Урмышлы авылы, Лениногорск районы), *Җәй* + *-ләү* > *Җәйләү* – урын атамасы (Яңа Кәшер авылы, Әлмәт районы).

Кушма оронимнар.

Татар телендә кушма исемнәр өч төрле ысул белән ясалалар: нигезләр (сүзләр) кушылу, сүзтезмәләрнең кушма сүзгә әйләнүе, сүзтезмәләрнең кушымча алып кушма сүзгә күчүе (Татар грамматикасы, т. 1, 2015: 268).

Кушма төзелешле оронимнарның икенче компоненты гадәттә географик термин була. Кушма микротопонимнарны кайсы сүз төркеменә карауларыннан чыгып, төрле типларга (модельләргә) аерып карыйбыз. Татар оронимнары I төр изафә бәйләнешен тәшкил итәләр.

Кушма төзелешле оронимнар арасында сыйфат + исем тибы иң продуктивы: *Актау* – тау атамасы (Бишмунча, Кичүчат, Колшәрип авыллары, Әлмәт районы), *Биектау* – тау атамасы (Кичүчат авылы, Әлмәт районы; Чүти, Иске Иштирәк авыллары, Лениногорск районы), *Кызылтау* – тау атамасы (Әгерҗе, Әсәй авыллары, Азнакай районы; Акбаш авылы, Ютазы районы), *Кызылъяр* – урын атамасы (Бишмунча, Кама Елга авыллары, Әлмәт районы), тау атамасы (Урсалбаш авылы, Әлмәт районы), *Кырынтау* – тау исеме (Иске Шөгер, Кирлегәч авыллары, Лениногорск районы), *Куштау* – тау атамасы (Сәпәй авылы, Азнакай районы) һ.б.

Тезмә оронимнар.

Тезмә оронимнар морфологик билгеләре буенча ике, өч, дүрт һәм сирәк кенә биш компонентлыга бүленәләр.

Татар телендә кушма сүзләрнең байтак өлешен тезмә сүзләр тәшкил итә. Тезмә сүзләр үзләренең структурасы ягыннан ике төргә бүленә: 1) компонентлары икенче изафә мөнәсәбәте нигезендә кушылып ясалган тезмә исемнәр; 2) компонентлары комплетив бәйләнештә булган, исем белән фигыль кушылып ясалган тезмә фигыльләр; 3) компонентлары комплетив бәйләнештә булган ике фигыльнең (тулы мәгънәле һәм модификацияләүче фигыльнең) кушылуыннан ясалган тезмә фигыльләр (Татар грамматикасы, т. 1, 2015: 206–207). Әлеге юл белән ясалган татар оронимнары төбәкләрнең физик-географик үзенчәлекләрен,

объектның билгеле бер шәхескә, вакыйгага теге яки бу мөнәсәбәттә булуын тулы һәм ачык итеп күзалларга ярдәм итәләр. Иярүче кисәк булып исем, сыйфат, фигыль, сан, рәвеш һ.б. сүз төркемнәре килә. Ияртүче кисәк вазифасын географик термин үти.

Тезмә сүз һәм тезмә терминнар, исемләү-атау функциясен (номинация) үти торган катлаулы лексик берәмлек буларак, бер-берсенә бик охшаш. Тезмә сүзләр – телдә күптәнге катлау, тезмә терминнар исә, яңарак катлау булганга, әле лексик яктан тотрыкланып җитмәгәннәр. Әмма тышкы күренешләре ничек кенә булмасын, тезмә сүз һәм тезмә терминнар, бербөтен предмет һәм төшенчәләрне атау максаты белән, башта ук катлаулы лексик берәмлек буларак төзеләләр һәм ирекле синтаксик сүз тезмәләреннән дә, тотрыклы фразеологик тәгъбирләрдән дә нык аерылалар (Саттаров, 1998: 346).

Хәзер ике, өч, дүрт һәм биш компонентлы тезмә оронимнарга киңрәк тукталыйк.

*Ике компонентлы оронимнар.* Татар телендә атрибутив бәйләнештәге компонентлар тезелеп шактый гына оронимнар ясалган. Атрибутив бәйләнештә булган тезмә оронимнарның беренче компоненты булып мөстәкыйль сүз төркемнәренә караган сүзләр килә. Ике компонент та төрле ясагыч кушымча алырга мөмкин.

Ике компонентлы тезмә оронимнар берничә морфологик төргә аерыла:

Исем + исем тибындагы атамалар. Бу тип үзе ике төргә бүленә: а) III төр изафә бәйләнешендәге ике компоненты да исем сүзтөркеме булган аергыч + аерылмыш конструкциясеннән гыйбарәт кушымчасыз тезмә оронимнар; ә) II төр изафә бәйләнешендәге кушымчалы тезмә оронимнар;

*Кушымчасыз тезмә оронимнар.* Кушымчасыз тезмә оронимнарны объектның географик үзенчәлекләрен ачыклаучы иярүче кисәкләренә карап төрле тематик төркемчәләргә аерырга мөмкин. Мондый төркемләү Ф.Г. Гарипова (1994), М.Г. Усманова (1994) хезмәтләрендә дә чагылыш тапкан.

Оронимның беренче компоненты географик объектның кемгә дә булса мөнәсәбәтле булуын белдерүче антропоним: *Сәвәләй тау* (Кама Исмәгыйль, Нәдер авыллары, Әлмәт районы), *Сәлимә тау* (Кичүчат авылы, Әлмәт районы) һ.б.

Ияртүче кисәге үсемлек, кош-корт, хайван исемнәре, ияртүчесе – номенклатура термины: *Чия тау* (Иске Иштирәк, Тимәш авыллары, Лениногорск районы; Әлкәй авылы, Азнакай районы), *Суыр тау* (Урсалбаш авылы, Әлмәт районы) һ.б.

*Кушымчалы тезмә оронимнар.* Кушымчалы тезмә оронимнар исем + исем конструкциясе белән ясалганнар. Кушымчаның беренче яки икенче компонентка ялгануына карап, ике компонентлы тезмә оронимнар ике төркемгә бүленә, ягъни II һәм III төр изафә бәйләнешле төркемнәргә.

II төр изафә бәйлнешендәге тезмә оронимнарны үз эчендә ике төркемчәгә бүләргә мөмкин. Беренче төркемчәгә ияртүче кисәге булып ялгызлык исемнәр килгән атамалар керә:

а) кеше исемнәре белән: *Газулла тавы* (Кичүчат авылы, Әлмәт районы), *Әхмәт тавы* (Кирлегәч авылы, Лениногорск районы), *Җәләй тавы* (Чупай авылы, Әлмәт районы), *Мөрдәкәй тавы* (Уразай авылы, Азнакай районы) һ.б.

ә) фамилияләргә нисбәтле: *Варварин тавы, Варварин чокыры* (Дәүләт авылы, Әлмәт районы), *Кугиев аланы* (Сәпәй авылы, Азнакай районы), *Вәлишин түбәсе* (Салкын Чишмә авылы, Бөгелмә районы) һ.б.

Ияртүче компонент күмәклек исемнәрне тәшкил итүче тезмә оронимнарны икенче төркемчәгә кертәбез. Тематик яктан әлеге төркемчәгә түбәндәге атамалар керә:

а) үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы: *Карагай тавы* (Сугышлы авылы, Лениногорск районы), *Буләк тавы* (Сөләй авылы, Әлмәт районы; Мортаза авылы, Баулы районы), *Тигәнәк чокыры* (Миңлебай авылы, Әлмәт районы), *Үгез тугае* – болын атамасы (Зәй-Каратай авылы, Лениногорск районы) һ.б.

ә) казылма байлыклар: *Бакыр базы* (Мәмәт, ЮгарыМактама авыллары, Әлмәт районы) һ.б.

б) этнонимнар: *Урыс тавы* (Кичүчат авылы, Әлмәт районы), *Нугай казындылары* (Үчәлле авылы, Азнакай районы) һ.б.

II төр изафә бәйләнешендәге ике составлы тезмә оронимнарның үзенчәлеге шунда, икенче компонентта кемгә яки нәрсәгә дә булса караганлыкны белдерүче *-ы, -е* кушымчасы сакланган хәлдә, беренче компоненттагы *-ның, -нең* иялек килеше кушымчасы төшеп кала. Топонимик мәгълүматлар бу тип ясалышның соңгырак чорга каравын әйтәләр (Ахатова, 1994: 158).

III төр изафә бәйләнешендәге ике составлы тезмә оронимнарда сыйфат + исем конструкцияле атамалар зур күпчелекне тәшкил итә. Кушымчаларның булу-булмавына карап, без аларны ике төркемчәгә, төп һәм ясалма сыйфатлыга бүләбез.

Ике компонентлы тезмә оронимнарда иярүче кисәк булып килгән төп сыйфатлар географик объектның төрле билгеләрен белдереп киләләр:

а) төсен: *Кара яр* – яр атамасы (Чуар Абдул авылы, Азнакай районы), *Ала тау* (Миңлебай авылы, Әлмәт районы), *Зәңгәр тау* (Салих авылы, Баулы районы), *Сары тау* (Шөгер авылы, Лениногорск районы) һ.б.;

ә) формасын, күләмен: *Текә тау* (Кәтем, Чуар Абдул авыллары, Азнакай районы), *Бәләкәй ачы* – урын атамасы (Яңа Кәшер авылы, Әлмәт районы), *Кыска кул* – чокыр атамасы (Сарлы авылы, Азнакай районы) һ.б.;

б) температурасын, исен, тәмен: *Җылы чокыр* (Югары Мактама авылы, Әлмәт районы), *Салкын түбә* – тау атамасы (Карамалы авылы, Азнакай районы) һ.б.

Иярүче кисәк исемгә *-лы/-ле* кушымчасы ялганып ясалган оронимнар: *Баллы буе* (Рангазар авылы, Сарман районы), *Агачлы кул* – ике тау арасы (Зәй-Каратай авылы, Лениногорск районы), *Беләүле тау* (Тайсуган авылы, Әлмәт районы), *Бурлы тау* (Сарабиккол авылы, Лениногорск районы) һ.б.

*Иярүче кисәге фигыль формаларына нигезләнгән оронимнар.* Фигыль формалы географик атамалар А. Битанова, Ф. Гарипова, Г. Донидзе, Җ. Киекбаев, О. Молчанова, Г. Саттаров, О. Султаньяев хезмәтләрендә беркадәр өйрәнелгән. В. Никонов та славян топонимиясенә хас булмаган фигыль формалы тезмә топонимнарның төрки топонимиядә урын алуын яза (Никонов, 1969: 29).

Иярүче кисәк фигыль формаларына нигезләнгән атамалар өч һәм аннан күбрәк компонентлы оронимнарда еш күзәтелә, ә ике компонентлылар арасында сирәк очрый. *Казыган тау* (Тайсуган авылы, Әлмәт районы), *Янган тау* (Миңлебай авылы, Әлмәт районы) тезмә оронимнарының иярүче кисәге үткән заман сыйфат фигыльнең ***-ган*** формасына нигезләнеп ясалган.

Өч компонентлы тезмә оронимнар. Өч компонентлы атамалар да, ике компонентлылар кебек үк, структуралары ягыннан ике кисәккә – иярүче һәм ияртүче кисәккә бүленәләр. Монда

ияручe кисәк үзе ике компоненттан тора һәм бербөтен синтаксик берәмлек була, ә бер компонентлысы ияртүче кисәк вазифасын үти.

Өч компонентлы тезмә оронимнарны берничә морфологик типларга бүлеп тикшерергә мөмкин:

«Исем + исем + исем»нән гыйбарәт тезмә атамалар: *Арка бүләк болыны* (Бәйрәкә авылы, Ютазы районы), *Авыл очы болыны* (Өшәр авылы, Актаныш районы), *Әби патша тавы* (Салауз-Мухан авылы, Мөслим районы), *Болан баш тавы* (Салих авылы, Баулы районы), *Елан елга чокыры* (Нөркәй авылы, Сарман районы), *Ибрай чишмәсе тавы* (Яңа Кәшер авылы, Әлмәт районы) һ.б.

«Сыйфат + исем + исем»нән гыйбарәт тезмә атамалар: *Баллы күл тавы* (Мәмәт авылы, Әлмәт районы), *Иске авыл урыны* – урын атамасы (Бәкер авылы, Лениногорск районы), *Даулы җир түбәсе* (Мәнәвез авылы, Азнакай районы), *Кырган чишмә тавы* (Татар Кандызы авылы, Баулы районы), *Караңгы кул арасы* (Кичүчат авылы, Әлмәт районы) һ.б. Күп очракта мондый ясалышта ике географик термин урын ала.

«Сан + исем + исем»нән ясалган тезмә атамалар: *Ике тау арасы* – чокыр атамасы (Кичүчат авылы, Әлмәт районы), *Биш туган кыры* (Елховой авылы, Әлмәт районы), *Кырык кәҗә тавы* (Сарлы авылы, Азнакай районы) һ.б.

«Исем + сыйфат фигыль + исем» (географик термин): *Аю сөйрәгән чокыр, Сыер яткан чокыр* (Мәмәт авылы, Әлмәт районы), *Дөя суйган алан* (Карабаш эшчеләр бистәсе, Бөгелмә районы), *Төлке чапкан алан* (Әлкәй авылы, Азнакай районы), *Таш кискән тау* (Сөләй авылы, Әлмәт районы), *Дегет кайнаткан чокыр* (Үзбәк авылы, Лениногорск районы), *Акбур чыккан тау* (Сарабиккол авылы, Лениногорск районы).

*Дүрт компонентлы тезмә оронимнар.* Дүрт компонентлы тезмә оронимнар әллә ни күп түгел. Әлеге атамалар исем, сыйфат, фигыль сүз төркемнәре катнашып ясалганнар.

«Сыйфат + исем + исем + исем»: *Олы таш мич тавы* (Әгерҗе авылы, Азнакай районы), *Ак балчык базы өсте* (Әлмәндәр авылы, Апас районы), *Тишек бит таш тавы* (Бәйрәкә авылы, Ютазы районы), *Коры күпер тау башы* (Кара Чишмә авылы, Чирмешән районы) һ.б.

«Исем + фигыль + сыйфат фигыль + исем»: *Ат чаба торган тау* (Яңа Шалты авылы, Баулы районы), *Кызлар уйный торган*

*чокыр* (Татар Кандызы авылы, Баулы районы), *Кызлар уйный торган сырт* (Иске Имән авылы, Сарман районы) һ.б.

*Биш компонентлы тезмә микротопонимнар.* Татар оронимиясендә биш компонентлы атамалар юк дәрәҗәсендә. Без бары тик *Каршы уен була торган җир* – урын атамасы (Тимәш авылы, Лениногорск районы), *Алып бабай чабата каккан тау* (Бакырчы авылы, Яшел Үзән районы; Биектау авылы, Балык Бистәсе районы; Катмыш авылы, Мамадыш районы), *Бирге тәкә чала торган төш* (Әлмәндәр авылы, Апас районы) оронимнарын гына билгели алабыз. Мондый төр берәмлекләр телдә бик аз кулланыла. Кеше объектларга атама биргәндә, һәрвакыт кыскалыкка омтылган, аның иң характерлы ягын чагылдырырга тырышкан. Биш компонентлы оронимнарның санаулы гына булуын шуның белән аңлатырга мөмкин.

Нәтиҗә ясап шуны әйтергә була, оронимнарының зур күпчелеген төрле структур модельләргә нигезләнеп ясалган ике компонентлы атамалар тәшкил итә. Синтаксик яктан исә, II төр изафә бәйләнеш өстенлек алган.

Оронимар, башка төр ономастик берәмлекләрдән үзенең баерак булуы һәм чынбарлыкны төгәлрәк чагылдыруы белән белән аерылып тора. Чөнки ул, нигездә, табигый юл белән формалаша һәм ориентирны гына күрсәтмичә, билгеле бер дәрәҗәдә эстетик функция дә башкара. Тел, милләт тарихын ачыклауга бәяләп бетергесез зур өлеш кертә.

## ТАТАР УРБАНОНИМИКАСЫ

### § 30. Урбанонимика фәненә билгеләмә

Топонимиканың урам исемнәрен өйрәнә торган бүлеге *урбанонимика* дип атала. XX йөз урталарыннан *урбанонимика* тел белгечләренең игътибар үзәгендә була.

XX йөзнең икенче яртысында илкүләм тарихны, шулай ук аерым өлкәләрнең тарихын, мәдәниятен тикшерү активлаша һәм галимнәрнең аерым урам атамаларын өйрәнүгә дә игътибарларын арттыра. Төрле елларда Г.П. Бондарук, И.Д. Воронин, М.В. Горбаневский, К.С. Горбачевич, Ю.К. Ефремов, А.М. Мезенко, Э.М. Мурзаев, В.П. Нерознак, В.А. Никонов, Н.В. Подольская,

Е.М. Поспелов, Г.П. Смолицкая, Н.С. Студенов, А.В. Суперанская һ.б. галимнәр тарафыннан адреслы объектларның барлыкка килүләре һәм мәгънә белдерүләренә караган актуаль проблемалар күтәрелә башлый һәм фәнни хезмәтләр языла.

Шушы чорда шәһәр объектлары арасындагы бәйләнешләрне ачыклауга һәм системага салуга юнәлгән типологияләр барлыкка килә. Еш кына әлеге типологияләр топонимия белән тыгыз бәйләнештә тора. Шуннан чыгып, галимнәр, аерым бер территориянең топонимнарын чагылдырган мәгълүматларга таянып, классификация төзүне башкаралар. Әлеге бурыч шәһәр эчендәге объектларны төрләргә бүлү белән генә чикләнми: галимнәр шулай ук атамаларның барлыкка килү, алмашыну, үсеш процессларын да тикшерәләр, тарихи-мәдәни мирасны саклауга юнәлгән сүзлекләр, юл күрсәткечләр, карталар һ.б. төзиләр. Шулай итеп, тел галимнәре топонимнар системасын өйрәнүгә структур якын килүләр һәм аңа хас сыйфатларны, аерым алганда, территориаль беркетелү, аерым объектның үзенчәлекләрен һ.б.ны билгеләп үтәләр.

1960 елларда бу юнәлештәге эзләнүләр шактый күзәтелсә, 70 нче елларда урбанонимнарны өйрәнү эше берникадәр тынып кала. Әлеге чорга караган хезмәтләрнең берсе – Н.В. Подольскаяның «Урбанонимия центральных областей РСФСР» дигән мәкаләсе. Галимә беренчеләрдән булып Россиянең Европа өлешенә кергән шәһәрләрнең урбанонимнарын чагыштырма планда өйрәнә һәм системалаштыра (Подольская, 1974: 123–129).

1985 елда Мәскәү шәһәре урбанонимнарына багышланган «Географические названия в Москве» дигән җыентык дөнья күрә. Бу җыентыкта төп урынны А.В. Суперанскаяның мәкаләсе алып тора. Галимә урбанонимнарның, башка географик атамалардан аермалы буларак, махсус катлам тәшкил итүен ассызыклый. А.В. Суперанская билгеләвенчә, «шәһәр эчендәге бөтен объектлар кеше тарафыннан барлыкка китерелгән. Шуңа күрә кешенең бу территориягә бәйле башкарылган эшчәнлеге әлеге процесска турыдан-туры тәэсир итә. Нәтиҗәдә урбанонимнар, топонимнар белән чагыштырганда, башка принципка нигезләнеп барлыкка килә һәм бик шартлы рәвештә генә топонимнар белән берләштерелергә мөмкин» (Суперанская, 1985: 161). Галимә урбанонимнарны урам, мәйдан, бина һәм шәһәр эчендәге башка объект атамаларының бердәмлеге, дип билгели (шунда ук: 72).

Югарыда әйтеп кителгән тикшеренүләргә карамастан, Россия урбанонимнары системасына хас үзенчәлекләрне ачыклауга багышланган беренче хезмәт 1994 елда М.В. Горбаневский тарафыннан языла. М.В. Горбаневский «Русская городская топонимия: Проблемы историко-культурного изучения и современного лексикографического описания» дигән докторлык диссертациясендә Россиянең Европа өлешендә урнашкан 30 дан артык зур һәм кечкенә шәһәр урбанонимиясен тикшерә. Ил үзәгендә урнашкан шәһәр топонимнарын анализлау нәтиҗәсендә, автор урбанонимнарның төп ясалыш модельләрен ачыклый (Горбаневский, 1994: 432).

Шулай да әлеге хезмәт кенә урбанонимиканың барлык проблемаларын да чишә алмый. Фәндә ачыкланмаган мәсьәләләрнең берсе – шәһәр атамалары типологиясенең үзгәреп торуы. Шәһәрләр киңәйгән, үскән саен яңа урам исемнәре барлыкка килә һәм төрле тарихи, сәяси максатларга бәйле бер атама икенчесенә үзгәртелә.

Р.В. Разумов рус шәһәрләре урбаноним системаларының XVIII–XX гасырлар дәверендә үзгәреш тарихларын өйрәнә. Аның «Система урбанонимов русского провинциального города конца XVIII–XX веков: на примере Костромы, Рыбинска и Ярославля» дигән кандидатлык диссертациясендә күпчелек рус шәһәрләрендә урын алган топонигезләр ачыклана. Автор шәһәр атамаларының лексик-семантик яктан кичергән эволюцияләрен тасвирлый, урбанонимнарның төрле дәверләрдә таралыш тапкан типларын тикшерә һәм аларны җәмгыятьтә барган социаль-сәяси процесслар күзлегеннән чыгып аңлата (Разумов, 2003: 293).

Соңгы елларда безнең илебездә шәһәр топонимиясен тикшерүгә игътибар үсә бара. Мәскәү, Санкт-Петербург, Калуга, Кострома, Тамбов, Ульяновск һ.б. шәһәрләрнең топонимиясен, урам исемнәрен, башка географик объектларының атамаларын тикшерүгә багышланган фәнни хезмәтләр барлыкка килде, аларның кайберләренең топонимиясен өйрәнүгә караган кандидатлык диссертацияләре язылды. Мәсәлән: И.Б. Горланова «Топонимия города Костромы (структура, семантика и функционирование в синхронно-диахронном аспекте)» (2006), Г.П. Смолицкая «Названия московских улиц» (2006), Н.Ю. Забелин «Московская городская топонимия структурно-семантический анализ топонимической

системы» (2007), А.Ю. Асанов «Урбанонимия города Тамбова в лингвокогнитивном аспекте» (2014) һ.б.

Татар урбанонимиясе мәсьәләсенә килгәндә, аның милли тарих белән тыгыз бәйләнештә торуын ассызыклау кирәк. Бүгенге көндә борынгы татар шәһәрләре атамаларына караган мәгълүмат сакланмаган, дип әйтеп була. Урбанонимнар җәмгыятьнең сәяси, социаль, икътисади, мәдәни сфералар белән тыгыз бәйләнештә торып, әлеге сфералардагы яңарышларны чагылдырып торучы элементлар булганга күрә, аларны телнең һәрдаим үзгәрешләр кичерә торган өлкәсе итеп билгеләргә мөмкин. Мәсәлән, тарихи вакыйгаларга нисбәтле, борынгы татар шәһәрләре булган Казан, Алат, Арча, Лаеш, Тәтеш шәһәрләрендә элеккеге татар атамалары чагылмый диярлек.

Бүгенге көндә Татарстанның Казан, Алабуга, Азнакай, Бөгелмә, Яшел Үзән, Яр Чаллы, Чистай һ.б. шәһәрләре урбанонимиясен өйрәнүгә багышланган махсус монографик хезмәтләр юк. Хәзерге чорда Татарстан Республикасының шәһәр топонимнары икетеллелек шартларында тикшерелергә тиеш, шул ук вакытта төрле шәһәрләргә караган урбанонимнарның бер үк лексик-семантик материалга нигезләнгәне күзәтелә.

Татарстан шәһәрләре урбанонимиясендә бер үк төрле атаманың кабатланып килүе еш күзәтелә. Шуңа нисбәтле, без эшебездә татар урбанонимиясен Казан шәһәре мисалында тикшерергә булдык. Беренчедән, язу кенәгәләрендә, тарихи документларда Казан шәһәренең кайбер урбанонимнары теркәлеп калган. Икенчедән, башкала шәһәрнең атамалар системасы, провинциаль шәһәрләр белән чагыштырганда, иң зур үсешкә ия булып тора. Урбанимик даирәнең формалашу концепциясе югары дәрәҗәдә эшкәртелгән булганга күрә, башкаланың атамалар системасы башка шәһәрләр өчен онимик терминнар чыганагы булып хезмәт итә.

Казанның урам исемнәрен, аларның урнашу тәртибе һәм урыны күрсәтелгән хезмәтләрнең эчтәлекләре һәм жанрларына карап, Г.Ф. Саттаров, өчкә аерып карый:

1. Казан шәһәре тарихын өйрәнү белән мөнәсәбәтле рәвештә аның урамнары турында беркадәр сүз алып барылган тарихи очерклар.

2. Казан буенча юл күрсәткечләр.

3. Казанның кайбер урам яки башка объектларының исемнәренә лингвистик күзәтүләр ясалган мәкаләләр (Саттаров, 1971: 47).

Гомумән, Казан шәһәренә багышлап, күпсанлы тарихи очерклар, китаплар язылган. Платон Заринский «Очерки древней Казани» дигән хезмәтендә Казанның шәһәр топонимиясе, төзелү урыны турында яза. Бу хезмәтендә автор XVI йөзнең икенче яртысындагы Казанның топографиясен тасвирлый, шәһәрнең кайбер географик объектларының исемнәренә туктала. Кремль янындагы тирән чокырның ни өчен *Таҗик чокыры* дип аталуы турында яза. Черек күлнең суы агып чыкмавы, аңа Таҗик чокырыннан һәм борынгы корылма булган сәүдәгәрләр мунчасыннан пычрак юынтык сулар агып төшү нәтиҗәсендә барлыкка килүен әйтә. XVI йөздә Болак мул сулы булган. Ул, ике тармакка аерылып, Казансу елгасына койган. Көнчыгыш тармагы Казансуга Кремль янында, ә көнбатыш тармагы тимер юл вокзалыннан ары тоташкан. Көнбатыш тармакны *Черек Болак* дип атап йөрткәннәр (Заринский, 1877: 220).

Н.А. Спасскийның «Очерки по родиноведению. Казанская губерния» дигән хезмәтендә Казан шәһәре һәм аның урамнарының тарихын яктыртуга зур урын бирелә. Автор Казанның күп кенә урамнары, бистәләре, мәйданнары һәм башка объектларының исемнәрен атый, аларның кайсы гасырда һәм ни сәбәпле барлыкка килүләрен тасвирлый. XX гасыр башында Казанда барлыгы 230 урам булып, аларның гомуми озынлыгы 122 чакрымга җитүен ассызыклый (Спасский, 1910: 245).

Тарихчы Н.Ф. Калинин 1929 елда басылган «Казань XVIII века» дигән мәкаләсендә Казан топографиясен шактый тулы итеп тасвирлый. XVIII йөздә Казанның элекке чикләреннән чыгып үсүе, шәһәр читендә бистәләр барлыкка килү, Болак елгасының сәүдә алып бару өчен зур әһәмияткә ия булуы, анда Иделдән суднолар керүе турында яза. XVIII гасырда Казан урамнарының урнашу тәртибе хәзерге урамнардан үзгә булган. Шәһәр үзәгендә бер ноктадан чыккан дугасыман һәм туры урамнар (мәсәлән, *Проломный, Владимир, Воскресенский урамнары* һ.б.) булганнар (Калинин, 1929: 119–130).

XIX йөзнең икенче яртысында һәм XX йөздә Казан өчен байтак юл күрсәткечләр һәм адрес мәгълүматлары күрсәтелгән китаплар басыла. Алар арасында А.С. Дубровинның «Указатель города Казани и достопримечательностей с кратким очерком древностей Казанской губернии» (1890), П.А. Верещагинның «Указатель

достопримечательностей города Казани» (1895), Н.П. Загоскинның «Спутник по Казани» (1895), М.В. Казанскийның «Путеводитель по Казани» (1899), Ш.К. Шаһидуллинның «Идел нәһерендә юлдаш» (1908), Е.Г. Бушканецның берничә юл күрсәткече: «Город Казань. Краткий путеводитель для путешествующих по Волге» (1954), «Исторические памятники Казани. Краткий путеводитель-справочник для туриста» (1959), «Казань. Путеводитель» (1961), «Казань – путеводитель» (1964); А.И. Григорьевның «Казанский Кремль. Краткий путеводитель» (1959), Т.С. Бобченко, А.В. Гарзавина, К.Р. Синицыналарның «Казань: Путеводитель» (1970), В.В. Кузьмин, Ю.И. Смыков, А.Х. Халиковларның «Казань – путеводитель» (1977) һ.б. хезмәтләр бар. С.М. Шпилевскийның «Указатель исторических достопримечательностей г. Казани» (1873), Н.Я. Агафоновның «Историческая объяснительная записка наименований казанских улиц» (1899), К.Г. Козьминның «Адресная книжка г.Казани» (1906), П. Васильевның «Календарь – указатель города Казани на 1882 год» (1881), Н.Г. Шебуев редакциясендә «Вся Казань. Адресная и справочная книга» (1899), «Адресная книга города Казани на 1906 год» (1906) дигән адрес күрсәткечләр һәм белешмә китаплар басылып чыга.

Т.С. Бобченко, А.В. Гарзавина, К.Р. Синицына авторлыгында чыккан «Казань: Путеводитель» (1970) юл күрсәткечендә хәзерге Казан урамнарының һәм мәйданнарының урнашу тәртибе, төзелеш үзенчәлекләре, аларда булып узган тарихи вакыйгалар, истәлекле урыннар, зур корылмалар, архитектура кыйммәтенә ия булган аерым биналар турында сүз алып барыла.

1977 елда В.В. Кузьмин, Ю.И. Смыков һәм А.Х. Халиковларның «Казань – путеводитель» дигән юл күрсәткече басыла. Бу Казанга багышланган юл күрсәткечләрнең иң тулысы һәм эзлеклесе. Анда Казан турындагы гомуми мәгълүматларга урын бирелә. Керештә Казанның салыну тарихы, исеменең килеп чыгышы, төзелеш тарихы турында сүз алып барыла. Казан тарихының мөһим даталары урнаштырыла. Юл күрсәткечтә төп урынны «Шәһәрне карау программасы һәм аның маршрутлары» алып тора.

В.И. Белокопытов һәм Н.Я. Шевченконың «Их именем названы улицы Казани» дигән хезмәте Казан урамнары турында бай материал тупланган хезмәтләрнең берсе булып санала. Авторлар Казанда яшәгән һәм эшләгән бик күп революционерлар, Комму-

нистлар партиясе, Совет дәүләте эшлеклеләре, атаклы галимнәр, язучылар, гражданнар сугышы һәм Бөек Ватан сугышы геройларының исемнәрен йөрткән урамнар турында мәгълүмат бирәләр. Хезмәттә Казанның теге яки бу урамының ни өчен билгеле бер шәхес исем-фамилиясе белән аталуы әйтелә һәм алар турында шактый тулы биографик белешмә бирелә. Хезмәттә 1230 күренекле шәхеснең исем-фамилиясен йөртүче урамнар турында сүз алып барыла (Белокопытов, 1973: 527).

Казанның кайбер урам исемнәре һәм башка топонимнарга лингвистик анализ ясалган хезмәтләрдән тәүгесе итеп доцент С.А. Мартьянованың «Лексика писцовых книг города Казани XVI–XVII вв.» исемле мәкаләсен күрсәтергә мөмкин. Әлеге мәкаләдә автор Казан шәһәренең борынгы топонимиясен ике этнолингвистик катламга: 1) рус теленә алынган татар атамаларына һәм 2) рус теленең үз исемнәренә бүлеп карый (Мартьянова, 1952: 110–115).

XVI–XVII йөзләрдә басылган язу кенәгәләрендәге топонимнар, урам һәм бистә исемнәрен С.М. Мартьянова лексик-семантик яктан 5 төркемгә бүлә: 1) эпитеттан торган урам исемнәре: *Большая, Прямая, Мокрая, Новая, Проломная;* 2) беренче күчеп килүчеләрнең туган шәһәрләренең исеме бирелгән урамнар: *Вологда, Псков, Тула;* 3) сәнәгать һәм сәүдә оешмалары яки һөнәр атамалары бирелгән урамнар: *Гостиный, Пушкарская, Ямская, Банная, Пивоваренная;* 4) чиркәү терминологиясенә (башлыча чиркәү исемнәренә) нигезләнгән урам һәм бистә исемнәре: *Воскресенская, Воздвиженская, Дмитриевская, Преображенская, Спасс, Федоровская, Вишняковская (Николы Вишнего)*; 5) кеше исем-фамилияләре бирелгән тыкрык исемнәре: *Щекушин тыкрыгы, Терехов тыкрыгы* һ.б.

Г.Ф. Саттаровның «Ни өчен шулай аталган? Татарстан топонимнары» дигән хезмәтендә урам исемнәрен өйрәнү торышы, аларның элекке һәм хәзерге исемнәре, урам исемнәрен алмаштыру-яңарту, язуда дөрес чагылдыру проблемалары күтәрелә. Шулай итеп, профессор Г.Ф. Саттаров беренчеләрдән булып татар урбанонимикасын тикшерә (Саттаров, 1971: 47–79). Шуңа нисбәтле, галим татар топонимикасы фәненең урбанонимика бүлегенең нигез ташларын сала.

1993 елда Г.Ф. Саттаров «Башкалабыз атамаларына – милли рух» дигән мәкаләсендә урам атамаларында милли рухыбыз һәм

йөзебез чагылмавы, татар урамнары исемнәренең бик азы татарча булуы, аларга татар халкына мөнәсәбәте булган күренекле шәхесләребезнең исемнәрен куярга кирәклеге мәсьәләсен күтәрә (Саттаров, 1993: 164–168).

Архитектор В.П. Остроумовның «Казань. Очерки по истории города и его архитектуры» дигән хезмәтендә татар бистәләренең һәм урамнарының тарихи планировкасы һәм кайберләренең исемнәренең килеп чыгышы турында сүз алып барыла. Мәсәлән, XVII йөздә кирпеч сугучылар яшәгән бистә *Кирпеч бистәсе* (хәзерге *Бутлеров* һәм Санкт-*Петербург* урамнары башланып киткән урында булган) дип аталган. Хәзерге *Пушкин* һәм *Жуковский* урамнары арасында матур калку урында барлыкка килгән бистә *Кызыл бистә (Красная слобода)* исемен йөрткән (Остроумов, 1978: 76).

К.Ф. Әмировның «Казань: где эта улица, где этот дом?» дигән белешмә китабында Казан шәһәре урамнары турында шактый тулы тарихи-лингвистик мәгълүматлар бирелә (Амиров, 1995).

Хәзерге татар теле белемендә татар урбанонимнарының аерым аспектлары Р.М. Әмированың «Казан шәһәре татар эргонимиясе» (2013), А.Ә. Гафурованың «Специфика функционирования ономастической лексики в татарских и англоязычных рекламных текстах» (2012), Г.К. Һадиеваның «Урбанонимия города Казани» (2012), Э.Ю. Галиеваның «Особенности лексико-морфологических групп урбанонимов города Бугульма» (2013), М.Ф Низамова һәм Д.А. Сәлимоваларның «Структурно-семантические характеристики урбанонимов (на материале онимов города Елабуги)» (http://econf.rae.ru/article/6387) хезмәтләрендә чагылыш таба.

Бүгенге көндә вакытлы матбугатта татар урбанонимнары проблемасына багышланган мәкаләләр бастырыла, массакүләм мәгълүмат чараларында топонимнарны тәрҗемә итү, аларны алмаштыру, тарихи атамаларны кайтару проблемалары күтәрелә.

Лингвистлар һәм фәлсәфәчеләр фикеренчә, тел берәмлекләрендә гасырлар дәвамында җәмгыять эволюциясе нәтиҗәсендә формалашып килгән милли психология, менталитет һәм милли үзаң чагылыш таба. Татар урбанонимнарының килеп чыгышы тарихы шуның белән тыгыз бәйле. Татарстан Республикасы урбанонимиясенең күпчелеген рус атамалары тәшкил итсә дә, шуның белән бергә, татар халкы бары тик үз милләтенә генә хас бул-

ган үзенчәлекләрне дә урбанонимнарга күчергән. Бу аңлашыла да: урам исемнәре җирле халыкның дөньяны күзаллавына, аның гадәт-йолаларына, тарихына бәйле.

Россия тарихына бәйле рәвештә, татар урбанонимиясен, без, түбәндәге тарихи чорларга бүлеп карыйбыз: 1) инкыйлабка кадәрге чорда барлыкка килгән урбанонимия; 2) совет чоры урбанонимиясе; 3) хәзерге чор урбанонимиясе (1990 еллардан бүгенге көнгә кадәрге чор). Түбәндә һәрбер дәвернең үзенчәлекләрен карап китик һәм татар урбанонимиясенең үсеш тарихына күзәтү ясыйк.

1) Инкыйлабка кадәрге чорда барлыкка килгән урбанонимия. Борынгы Казан шәһәренә Идел Болгарстаны чорында нигез салына. XV йөздә шәһәр Казан ханлыгы башкаласына әйләнә (Фахрутдинов, 2015: 120). Казан шәһәре халкын, башлыча, болгар-татарлар һәм башка җирле халык вәкилләре тәшкил иткән. 1552 елда Казан ханлыгы рус дәүләтенә кушылгач, җимерелгән шәһәр торгызыла. Казан Кремленең чикләре киңәйтелә, яңа бистәләр төзелә. Татарлар шәһәр эченнән куылгач, шәһәргә руслар күченеп яши. Казан шәһәре дә рус шәһәрләре сыйфатларын чагылдыра башлый: борылмалы урамнар, тупиклы тыкрыклар, күпсанлы ерымнар барлыкка килә. Казан шәһәренең язу кенәгәсендә кайбер урам һәм тыкрык исемнәре *Тау өсте, Тау асты, Ерым арты, Ярык өсте* дип теркәлгәннәр. Кабан күленең сул яры буенда *Татар бистәсе* була.

XVIII гасыр урталарына кадәр Казан ирекле рәвештә төзелүен дәвам итә. Ләкин Санкт-Петербургта оештырылган төзелеш Комиссиясе Казанны, башка 200 шәһәр белән беррәттән, регуляр план буенча төзелергә тиешле шәһәрләр исемлегенә кертә (http://uag.kzn.ru/history/generalnyj_plan/xviii/). Шулай итеп, 1767 елдан башлап, Казанда архитектор В.И. Кафтырев шәһәр планы төзү эшен башлап җибәрә. Аның проектлары буенча Казанда дистәләгән торак, административ һәм дини биналар төзелә.

Бу вакытта Казан составына 9 зур урам, 170 кече урам белән тыкрык, 10 мәйдан, 8 бистә кергән. Үзгәрешләр, башлыча, үзәк районнар эчендә башкарыла – шәһәр читендәге төзелеш һаман да ирекле характерга ия була.

Казан урамнары веер һәм турыпочмак системасында төзелә. Үзәк нокта булып Кремль санала, Кремльдән *Проломная, Вос-*

*кресенская, Арская* урамнары сузылып китә. Төзелешнең башка юнәлешен билгеләүче булып *Болак* белән *Кабан күле* тора. Аларга параллель рәвештә *Вознесенская, Московская, Екатерининская* урамнары урнаша.

1815 һәм 1842 еллардагы янгыннардан соң шәһәр үзәгендә таш биналар төзелеше активлаша. *Пләтән, Әмәт, Савин, Калуга, Игумново* исемле чиктәш авыллар шәһәр бистәләре статусына керә. *Проломная, Георгиевская, Петропавловская, Гостинодворская, Воскресенская* урамнарына таш түшәлә.

Бу чорда чиркәү һәм монастырь исеме белән аталган урам исемнәре күп була: *Воскресенский, Спас, Георгиевский, Петропавел, Вознесенский* урам һәм тыкрыклары; *Преображенский, Архиепископ, Федоровский, Архангель, Пләтән* бистәләре (соңгы икесе XVII йөздә шул исемдәге монастырьларга караган авыллар булганнар). XIX йөздә бу бистә һәм авыллар шәһәр эчендә калганнар, ә исемнәре урамнарга күчкән.

1899 елда гына шәһәр думасы утырышында шәһәр башлыгы С.В. Дьяченко урам исемнәрен алмаштыру мәсьәләсен күтәрә. Моның проектын төзү Казан тарихчысы Н.Я. Агафоновка тапшырыла. Ул шул ук елны үзенең проектын тәкъдим итә (Агафонов, 1899). Бу проектның зур гына кимчелекләре була. Н.Я. Агафонов Казан урамнары исемнәрен алмаштыру мәсьәләсендә, югары катлау вәкиле буларак, үз сыйныфы мәнфәгатьләреннән чыгып эш итә. Ул, беренче чиратта, патшалар (*Александр II, Николай, Екатерина* урамнары), эре түрәләр, дворяннар (кенәз *Курбский*, подполковник *И.И. Михельсон*), Казан чиновниклары һәм дворяннары (*М.А. Ахматов, И.С. Жарков, Ф.Н.Хворов*) һәм бай сәүдәгәрләр (*Г.Д. Чепарин, В.П. Ложкин*) исем-фамилияләрен Казан урамнарына бирүне күздә тота. Шул ук вакытта Н.Я. Агафонов проектының заманы өчен уңай, прогрессив яклары да бар. Автор күп кенә урамнарга атаклы язучылар, галимнәр, мәгариф һәм мәдәният эшлеклеләренең исемнәрен бирергә кирәк дип карый. Казанның аерым урамнарының исемнәрен *Л.Н. Толстой, А.С. Пушкин, С.Т. Аксаков, Г.Р. Державин, К. Фукс, А.М. Бутлеров*, татар галимнәреннән *Хәлфиннар* һ.б. хөрмәтенә алар исеме белән алмаштырырга тәкъдим итә. Ул елларда ук бөек рус язучылары *Л.Н. Толстой, А.С. Пушкин* исемнәре бирелгән урамнар бүген дә шулай аталалар (Саттаров, 1971: 72–73).

XX йөз башларында дәвалау, сәүдә, сәнәгать оешмалары исемнәрен алган *Госпитальная, Газовая, Заводская, Кузнечная, Горшечная, Бойничная, Толчок* урамнары, *Тулуповка, Рыбноряд* мәйданнары, географик үзенчәлекләренә нисбәтле *Подлужная*, *Заречная*, *Луговая* урамнары барлыкка килә.

1914 елда Казанның яңа планы төзелүе сәбәпле, дистәләгән урам исемнәрен алмаштыруны күздә тоткан карар чыгарыла. Үзгәрешләр иң беренче чиратта яңгырашы күңелгә ятмаган атамаларга кагыла: мәсәлән, *Кошачий* һәм *Собачий* тыкрыклары үзгәртелә, *Юшков* тыкрыгы *Некрасов* урамына әверелә.

2) Совет чоры урбанонимиясе. Совет чорында татар урбанонимиясе тарихының яңа дәвере башлана. 1920 елның 25 нче июнендә Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелә. Шәһәр торгызыла, халык саны арта башлый. Бөек Ватан сугышына кадәр Казан индустриаль үзәккә әверелә. Моңа нисбәтле, *Дементьева, Техническая* һ.б. индустриаль урамнар калкып чыга.

Россиянең башка шәһәрләре кебек үк, Казан да 1917 елның инкыйлабыннан соң шактый урам исемнәрен алмаштыра. Хакимият алмашыну белән шәһәр урбанонимия тарихының яңа дәвере башлана. Идеологиягә нисбәтле исемнәр барлыка килә башлый: *Восстание*, *Маркс*, *Энгельс, Ленин* урамнары һ.б. Октябрь инкыйлабыннан соң илебездә булган зур үзгәрешләр йогынтысында барлыкка килгән һәм шул елларның рухын җиткергән урбанонимнар саны шактый: *Совет, Пролетар, Кызыл Октябрь, Пионерлар урамнары* һ.б Шулай ук патша хакимиятенә каршы чыгучыларның исемнәре калкып чыга: *Разин, Пугачев* урамнары.

1950 еллардан башлап, татар урамнарына Бөек Ватан сугышы геройлары, сәнгать, әдәбият эшлеклеләре, галимнәрнең исемнәре бирелә. Алар арасында татар фамилияләре дә еш очрый. Мәсәлән, *Хөсәен Ямашев, Гадел Кутуй, Салих Сәйдәшев, Әмирхан Еники, Һади Такташ* урамнары.

XX йөзнең 60 нчы елларында илдә барган прогрессив үзгәрешләр нәтиҗәсендә Космоска беренче космонавт чыгару куанычын уртаклашу һәм хөрмәт белдерү йөзеннән татар халкы урамнарына *Гагарин, Космонавтлар, Академик Королев* һ.б. исемнәр бирелә. Илдә барган сәнәгать революциясе дулкынында *Мотор, Водоканал, Индустрия, Завод* урамнары исемнәре калкып чыга.

Совет заманы урбанонимиясе алдагы чор традицияләрен дәвам итә, кайбер урам исемнәре географик объектларга нигезләнеп исемләнә: *Озерная, Дачная* урамнары; кеше һөнәре исемен йөрткән урам исемнәре барлыкка килә: *Химиклар, Журналистлар, Мехчылар* урамнары.

3) Хәзерге чор урбанонимиясе. Татар урбанонимиясенең хәзерге чоры, иң беренче чиратта тарихи атамаларның яңадан кайтуы белән характерлана. *Кәҗә бистәсе станциясе, Сукно бистәсе, Ташаяк урамы* атамалары барлыкка килде.

XXI йөз башларында кайбер урбанонимнар башка исемнәргә үзгәртелә. Мәсәлән, *Земляничная 3-я – Рәхим Саттар, Владимирская 2-я – Коновалов, Шатурская* урамының бер өлеше – *Симонов, Портовая* урамының бер өлеше – *Девятаев, Татцик – Мәсгут Латыйпов, Лесопарковая* урамының бер өлеше – *Алтынов, Совхозная – Сафин, Союзная 4-я – Әнвәр Кәримов, 50 лет Октября – Академик Кирпичников, Сакко и Ванцетти – Рөстәм Яхин, Тукай тыкрыгы – Михаил Худяков, Ухтомского – Борһан Шаһиди, Школьный тыкрыгы – Катановский тыкрыгы, Революция – Нәкый Исәнбәт, Калинин* урамының бер өлеше – *Әмирхан Еники, Володарского – Гаяз Исхакый, Кирпично-Заводская – Һади Атласи, Ново-Кремлевская – Ташаяк, Армавирская 2-я – Муса Бигиев, Карл Либкнехт – Алафузов, Проходная – Сардар Вәисов, Забайкальская – Галимҗан Баруди, Ярмарочная площадь – Меңьеллык мәйданы, Нариманов* урамының бер өлеше – *Сара Садыйкова, Трубная – Гомәр Гали, Набережная – Азатлык* һ.б. Күргәнебезчә, татар урбанонимиясе системасында татарның күренекле шәхесләренең исемнәре мәңгеләштерелә, милли исемнәребез бирелгән урамнар саны арта. Шул ук вакытта, урам исемнәрен алмаштыру – тирәнтен уйлап эш итүне сорый торган җаваплы һәм мөһим эш булып санала.

Татарстанның хәзерге чорында барлыкка килгән яңа атамаларын урам исемнәрен башкага алмаштыру нәтиҗәсендә генә барлыкка килгән дип әйтеп булмый, чөнки шәһәр һәм авылларда яңа төзелгән урамнар барлыкка килә. Бу аларның киңәю күрсәткече булып тора.

Гомумән, Татарстан Республикасында яңа барлыкка килгән урамнарга татар халкының күренекле җәмәгать эшлеклеләре, язучылары, мәдәният һәм фән хезмәткәрләренең исемнәре бирү күпләрдә канәгатьлек хисе уятты.

## § 31. Урбанонимнарның орфографиясе һәм транслитерация мәсьәләсе

Татар урбанонимнарының язылышы һәм рус телендә бирелеше актуаль мәсьәләләрдән санала. Ономастиканың башка төр берәмлекләрендәге кебек үк, биредә дә шактый авырлыклар күзгә ташлана. Урам исемнәре – милли телнең яшәеше, функциональ мөмкинлекләрен күрсәтә торган билге, шунлыктан аларда сүзләрнең бирелеше төгәл, тел нормаларына туры килгән булуы зарур. Бу өлкәдә аерым кабул ителгән закон һәм кагыйдәләр урамнарга исем бирү, аларның язылышы кебек аспектларны да үзәккә алалар. Мисал өчен, Татарстан Республикасында Топонимия комиссиясе эшли. Әлеге комиссия урам исемнәрен биргәндә түбәндәгеләрне исәпкә алуны ассызыклый.

Атама сайлау вакытында аның төгәл, гади, кыска һәм истә калырлык булуына игътибар итәргә һәм ике төрле аңларга мөмкин исемнәрдән ваз кичәргә кирәк. Урам, мәйдан һәм халык яшәгән башка территорияләрнең атамалары Татарстан Республикасының дәүләт телләрендә бирелә һәм тәрҗемә ителми. Географик объектның исемен рәсмиләштергәндә, Татарстан Республикасы дәүләт телләренең географик амтамаларны куллану кагыйдәләрен һәм гадәтләрен саклаган норматив язылыш формалары билгеләнергә тиеш (http://www.kzn.ru/node/32147 Официальный портал органов местного самоуправления города Казань).

Урам атамаларын бер телдән икенче телгә тәрҗемә итү мәсьәләсенә килгәндә, Комиссия атаманың оригинал телендә бирелешен теркәп кую ягында тора. Урбанонимнарны рус теленнән татар теленә һәм татар теленнән рус теленә күчерү вакытында, аффикслар үзгәртү яисә ирекле тәрҗемәдән башка механик транслитерация кулланыла (http://www.kzn.ru/node/32147 Официальный портал органов местного самоуправления города Казань). Шулай итеп, *Зур Кызыл урамы* түгел, бәлки *Большая Красная урамы* формасы дөрес булып санала. Шулай ук, документларда буталчык җибәрмәү максатыннан, *Үзәк урам* урынына *Центральная* урбанонимы кулланылырга тиеш.

Татар урбанонимнарының икетеллелек шартларында өч ысул ярдәмендә бирелеше таралган 1) тәрҗемә; 2) транслитерация; 3) катнаш ысул.

Тәрҗемә ысулына килгәндә, ул 1990–2000 елларда киң таралышка ия булган. Уртаклык исеме белән мотивлашкан рус телендәге шәһәр атамаларының мәгънәләре татар теленә турыдан-туры тәрҗемә ителгән. Мәсәлән: улица *Дубравная – Имәнлек* урамы, улица *Родины – Ватан* урамы. Бүгенге көндә әлеге ысул кулланылмый, чөнки урам исемнәре тәрҗемә итеп бирелми. Шул ук вакытта, Реестрда кайбер атамаларның рус һәм татар формалары яшәве дәвам итә: улица *Победы – Җиңү* урамы; улица *Связистов – Элемтәчеләр* урамы; улица *Слободская – Бистә* урамы; улица *Приволжская – Идел буе* урамы; площадь *Свободы – Ирек* мәйданы; улица *Серп и Молот – Урак һәм Чүкеч* урамы; улица *Современников – Замандашлар* урамы; улица *Строителей – Төзүчеләр* урамы; улица *Трудящихся – Хезмәтчәннәр* урамы; площадь *Тысячелетия – Меңьеллык* мәйданы һ.б.

Топонимнар нигезендә барлыкка килгән урбанонимнарның телдә кабул ителгән тәрҗемә варианты булса, шуның ярдәмендә бирелә: *Тюлячинская – Теләче* урамы; *Тюменская – Төмән* урамы; *Услонская – Ослан* урамы; *Ферганская – Фирганә* урамы; *Челябинская – Чиләбе* урамы.

Транслитерация ысулы бер телнең язылышын икенче телнең аналог хәрефләре ярдәмендә күрсәтүгә нигезләнә. Бүгенге көндә күпчелек очракта әлеге ысул кулланыла – урам атамалары тәрҗемә ителми. Урбанонимнарның язылышлары, оригиналдагы аффикслары сакланган килеш, икенче тел материалы белән бирелә: улица *Кунче – Күнче* урамы; улица *Малая Дорожная – Малая Дорожная* урамы; улица *Эмет – Өмет* урамы; улица *Свободная – Свободная* урамы; улица *Яшьлек – Яшьлек* урамы.

Әлеге ысулдан файдаланганда, кайбер татар авазларының рус телендә бирелү юллары истә тотыла.

Мәсәлән, татар теленең [ә] авазы рус телендә *э, а, я* хәрефләре белән бирелә: ***Бә**хетле* урамы – улица ***Бэ**хетле*; *М**ә**ңгелек* урамы – улица *М**я**нгелек*; *Үрм**ә**ле* урамы – улица *Урм**а**ле* (http://www.kzn.ru/node/32147 – Официальный портал органов местного самоуправления города Казань).

[ө] авазы *е, и, ы, э* хәрефләре ярдәмендә күрсәтелә: *С**ө**енеч* урамы – улица *С**и**енеч*; *Яшь К**ө**ч* урамы – улица *Яшь К**ы**ч*; ***Ө**мет* урамы – улица ***Э**мет*; *К**ө**меш* урамы – улица *К**е**меш*.

Калган татар авазлары күпчелек очракта түбәндәгечә бирелә:

[ж] авазы *ж* хәрефе белән: ***Җ**имешле* урамы – улица ***Ж**имешле*.

[ң] авазы *н* хәрефе белән: *У**ң**ыш* урамы – улица *У**н**ыш*.

[һ] авазы *х* хәрефе белән: ***Һ**ади Атласи* урамы – улица ***Х**ади Атласи; **Һ**ади Такташ* урамы – улица ***Х**ади Такташа*.

[ү] авазы *у* хәрефе белән бирелә: ***Ү**зәнле* урамы – улица ***У**зянле*; *Үрмәле* урамы – улица ***У**рм**а**ле.*

Атаманы к а т н а ш ы с у л белән биргәндә, аның бер өлеше – оригинал телдә, икенчесе – кабул ителгән тәрҗемә формасында килә.

Урам-юллар челтәренә караган объектлар тәрҗемә итеп бирелә: *улица – урам*, *переулок – тыкрык*, *проезд – юл*, *площадь – мәйдан, слобода – бистә*. Алынма булып торган сүзләр тәрҗемә ителми: *Проспект Ибрагимова – Ибраһимов проспекты*; *Аракчинское шоссе – Аракчино шоссесы*; *Оренбургский тракт – Оренбург тракты*.

Составларында сан булган атамалар да өлешчә тәрҗемә ителә*: 5-я Давликеевская – 5 нче Дәүләки* урамы; *8-я Залесная – 8 нче Залесная* урамы һ.б.

Шулай ук урбанонимнар составында булган *поперечно-*, *большая*, *малая*, *старая*, *право-*, *лево-* компонентлары кайбер очракларда тәрҗемә ителә: *Поперечно-Азинская – Аркылы Азино* урамы (ләкин *Поперечно-Боевая – Поперечно-Боевая* урамы); *Большая Мухаметшина – Зур Мөхәммәтшин* урамы (ләкин *Большая Заречная – Большая Заречная* урамы); *Малая Армавирская – Кече Армавир* урамы (ләкин улица *Малая – Малая* урамы); *Старо-Аметьевская – Иске Әмәт* урамы (ләкин улица *Старая – Старая* урамы), *Право-булачная – Уңъяк Болак* урамы, *Лево-Булачная – Сулъяк болак* урамы һ.б.

Икетеллелек шартларында һәр телнең орфографик нормаларының үтәлүен тикшереп торучы органнар булуы зарур. Бүгенге көндә Казан аншлагларында шактый орфографик хаталар күзәтелә, кайберләрендә атамалар татар телендә бирелми (http: //m.prokazan.ru/news/view/118306). Моны берничә сәбәп белән аңлатып була: 1) аншлагларны урнаштырганчы, аларның паспортларын тикшерүче органнар булмавы; 2) аншлагларны махсус лицензиясез оешмалар тарафыннан чыгару мөмкинлеге; 3) урам атамаларының татар телендә грамоталы бирелешенең Интернет челтәрендә, хәтта Шәһәр үзидарә органнары сайтында һәм Реестрда булмавы.

Шулай итеп, урам атамаларының дөрес язылышы өчен җаваплы органнар билгеләү, ике телнең орфографик нормаларын саклаган Реестрны Интернет челтәрендә урнаштыру проблеманың чишелеше булырга мөмкин.

## § 32. Урбанонимнарны номинацияләү принциплары

Татар урбанонимнары татар халкының тормыш-көнкүреше, мәдәни үзенчәлеге, милли йөзе, милли рухы, тарихи вакыйгалары турында мәгълүматлар саклыйлар.

Урам исемнәрен тикшергәндә, галимнәр төрле классификацияләргә мөрәҗәгать итәләр. Күпчелек очракларда урбанонимнарны лексик-семантик яктан тикшерәләр. Урбанонимика яшь фән булганга күрә, урам атамаларын төркемләүгә багышланган хезмәтләр саны күп түгел, һәм булган классификацияләр, вакытлар үтү белән, үстерүгә һәм тармакландыруга мохтаҗ. Топонимикада урбанонимнарны төркемләүдә кулланылган классификацияләргә күзәтү ясыйк.

А.М. Селищев «Из старой и новой топонимии» дигән хезмәтендә урбанонимнарныж лексик-семантик яктан бүленеш принципларын тасвирлый. Автор топонимнарны элекке (инкыйлабка кадәрге) һәм яңа (совет чоры) бүленешен билгели. Инкыйлабка кадәрге урбанонимиянең түбәндәге типларын бүлеп чыгара:

1) кеше исемнәреннән яки кушаматларыннан барлыкка килгән атамалар;

2) һөнәр белән бәйле атамалар;

3) кешенең социаль дәрәҗәсе, җәмгыятьтә тоткан урыны буенча барлыкка килгән атамалар;

4) администрация һәм хакимият белән бәйле атамалар;

5) этник характерны чагылдыручы атамалар;

6) ландшафт һәм төзелеш үзенчәлеген билгеләгән атамалар;

7) абстракт мәгънәгә ия атамалар;

8) культ объектлары (Селищев, 1968: 46).

Совет чоры топонимиясенә классификация биргәндә, автор бүлекләрне хакимияткә бәйле тематика ягыннан чыгып билгели. Әлеге бүленеш XX йөзнең 20–30 нчы еллары топонимиясен киң планда тикшерергә мөмкинлек бирә. Шулай да, топонимика фәне үсеше белән, урам исемнәрен тагын да тирәнрәк планда тикшерү ихтыяҗы барлыкка килә.

1964 елда А.В. Суперанская «Применение метода лингвистической статистики к изучению топонимической системы города Москвы» дигән мәкаләсендә структур якын килү принцибының әһәмиятен ассызыклап, урбанонимнарның 12 лексик-семантик тибын аерып күрсәтә. Алар түбәндәге күренешләр белән бәйле рәвештә барлыкка килә:

1) аерым шәхес исеменә бәйле атамалар;

2) аерым бер төркемне атаган исем белән бәйле атамалар *(шоссе Энтузиастов);*

3) торак пунктлар атамалары;

4) ясалма объектлар;

5) табигый топонимия;

6) физик-географик объектлар;

7) чиркәү исемнәре;

8) урнашу;

9) тышкы кыяфәт яки тәэсир;

10) исем яки куллану;

11) кабатланган урамнар;

12) символик атамалар (Суперанская, 1964: 121).

Р.В. Разумов «Система урбанонимов русского провинциального города конца XVIII–XX веков: на примере Костромы, Рыбинска и Ярославля» дигән хезмәтендә урбононимнарны ялгызлык яки уртаклык исемнәргә нигезләнүенә карап төркемли.

*Ялгызлык исемнәре* белән мотивлашкан атамаларны галим түбәндәге төрләргә бүлеп карый:

1) антропонимнарга нисбәтле урбанонимнар;

2) топонимнарга нисбәтле урбанонимнар;

3) экклезионимнарга нисбәтле урбанонимнар;

4) эргонимнарга нисбәтле урбанонимнар;

5) башка урбанонимнарнарга нисбәтле урбанонимнар.

*Уртаклык исемнәре* белән мотивлашкан урбанонимнарны төркемләгәндә, Р.В. Разумов сүзнең мөстәкыйль семантик нигезен күздә тотып эшли. Моннан чыгып, ул түбәндәге төркемнәрне аерып чыгара:

1) объектның табигый үзенчәлекләрен чагылдырган урбанонимнар;

2) объектның кеше эшчәнлеге белән бәйле үзенчәлекләрен чагылдырган урбанонимнар;

3) җәмгыятьнең идеологик карашларын чагылдырган урбанонимнар (Разумов, 2003: 76).

Топонимиядә лексик-семантик классификацияләрнең саны шактый булуга карамастан, алар арасында урбанонимнарны системалаштыруга яраклы якын килүләр аз. Моның сәбәбе, алда әйтеп кителгәнчә, кеше эшчәнлегенең урбанонимнарга турыдан-туры тәэсир итү мөмкинлеге белән аңлатыла. Табигый объект атамаларын аерым бер кеше ихтыяры белән сайлап яки алыштырып булмый. Урбанонимнар исә социаль үзгәрешләр, җәмгыять ихтыяҗы белән тыгыз бәйләнештә тора. Шуңа күрә, урбанонимнар шәһәр топонимиясен максатчан анализлау нәтиҗәсендә туган классификацияләр нигезендә генә, яисә төрле төр топонимнарны тикшерүгә җайлаштырылган универсаль схемалар ярдәмендә генә тикшерелергә мөмкин.

Татарстан Республикасы урбанонимнарының лексик-семантик яктан төркемнәргә бүленешен тәкъдим итәбез.

*Ялгызлык исемнәре* белән мотивлашкан атамаларны түбәндәге төркемнәргә бүлдек:

1) антропонимнарга нисбәтле урбанонимнар:

а) революционерлар, Бөек Ватан сугышы, Советлар Союзы геройлары исемнәренә нисбәтле урбанонимнар: *Петров, Бабушкин, Петр Алексеев, Мулланур Вахитов, Сәетгалиев, Зоя Космодемьянская, Александр Васильченко, Әнвәр Кәримов, Әхмәтхан Солтан, Виктор Сажинов, Галләм Морзаханов, Дмитрий Строганов, Җәлилчеләр урамы, Сабир Әхтәмов, Петр Полушкин, Рәхим Саттар, Семен Коновалов, Мәгубә Сыртланова* урамнары;

ә) пролетариат, юлбашчы исемнәренә нисбәтле урбанонимнар: *Карл Маркс, Фридрих Энгельс, Ильич* (В.И. Ленинга багышлап аталган) урамнары;

б) рус һәм халыкара эшчеләр хәрәкәтенең күренекле вәкилләре исемнәренә нисбәтле урбанонимнар: *Крупская, Клара Цеткин, Тельман, Бауман, Киров, Патрис Лумумба* урамнары;

в) космонавтиканың теоретиклары һәм практиклары, космонавт исемнәренә нисбәтле урбанонимнар: *Юрий Гагарин, Комаров, академик Королев, Циолковский, Чкалов* урамнары;

г) галимнәр, фән эшлеклеләре, күренекле татар мәгърифәтчеләре исемнәренә нисбәтле урбанонимнар: *Арбузов, Лобачев-*

*ский, профессор Котельниковлар, Петр Витер, Фәйзрахман Юнысов, Каюм Насыйри, Шиһабетдин Мәрҗани* урамнары;

д) татар язучылары, шагыйрьләре исемнәренә нисбәтле урбанонимнар: *Мөхәммәдьяр*, *Дәрдемәнд, Ризаэддин Фәхретдин, Габдулла Тукай, Галиәсгар Камал, Гаяз Исхакый, Шәриф Камал, Һади Такташ, Шамил Усманов, Гадел Кутуй, Нәкый Исәнбәт, Хәсән Туфан, Әмирхан Еники, Гомәр Бәширов, Нурихан Фәттах, Туфан Миңнуллин, Аяз Гыйләҗев* урамнары*, Фатыйх Әмирхан* проспекты;

е) артистлар, композиторлар, җырчылар, мәдәният эшлеклеләре исемнәренә нисбәтле урбанонимнар: *Салих Сәйдәшев, Рөстәм Яхин, Сара Садыйкова, Александр Ключарев, Зифа Басыйрова, Натан Рахлин, Нияз Даутов, Фәхри Насретдинов, Айрат Арсланов, Хәйдәр Бигичев, Айдаров, Әбҗәлилов* урамнары;

ж) җәмәгать эшлеклеләре, педагоглар, сәясәтчеләр исемнәренә нисбәтле урбанонимнар: *Борһан Шаһиди, Габдрахман Рафиков, Галимҗан Баруди, Җамал Вәлиди, Йосыф Акчурин, Сәрдар Вәисов, Шакирҗан Таһиров, Һади Атласи* урамнары;

җ) спортсменнар исемнәренә нисбәтле урбанонимнар (әлеге бүленешкә караган урбанонимнар соңгы елларда гына барлыкка килде): *Александр Курынов, Рәшит Нәҗметдинов* урамнары.

з) медицина эшлеклеләре исемнәренә нисбәтле урбанонимнар: *Алексей Казымбәк, Андрей Адо, Салих Корбангалиев* урамнары.

и) архитекторлар исемнәренә нисбәтле урбанонимнар: *Мөнир Агишев, Михаил Коринфский* урамнары.

к) рус һәм башка кардәш халыкларның язучылары, композиторлары, рәссамнары исемнәре белән*: Мамин-Сибиряк, Салтыков-Щедрин, Пушкин, Гоголь, Горький, Толстой, Аксаков, Пришвин, Гайдар, Вероника Тушнова, Евгений Баратынский, Николай Заболоцкий, Руставели, Абай Кунанбай, Алишер Нәваи*, *Чыңгыз Айтматов*, *Глинка, Бородин, Чайковский*, *Айвазовский, Шишкин, Левитан, Верещагин* урамнары.

2) географик атамаларга һәм географик терминнарга нисбәтле барлыкка килгән урбанонимнар:

а) ойконимнардан (якын тирәдәге торак пункт исеменнән, яки Татарстан территориясендә урнашкан объект атамасыннан) ясалган: *1 нче Уракчы* урамы – *1-я Аракчинская* (XVI–XVII гасырларда бу урында Уракчы исемле татар авылы урнашкан була), *Берсут*

(Мамадыш районы *Берсут* бистәсе исеменнән, Кама елгасы ярында урнашкан);

ә) полисонимнарга нисбәтле: *Архангельск, Әстерхан* тыкрыклары, *Ашхабад, Витебск, Кисловодск, Петербург, Уфа, Алабуга, Бөгелмә* урамнары;

б) гидронимнардан барлыкка килгән урбанонимнар: *Алдан* (Якутиядәге Алдан-Лена елгасының уң култыгы исеменнән), *1-Аральск, 2-Аральск* (Үзбәкстандагы Аральск диңгезе исеменнән), *Уңъяк Болак, Сулъяк Болак*, *Елга арты*, *Чишмәле* урамнары;

в) оронимнарга нисбәтле урбанонимнар: *Алтай урамы* (Алтай таулары атамасыннан), *Кавказ урамы* (Кавказ таулары атамасыннан);

г) башка урбанонимнардан барлыкка килгән урам исемнәре: *Арбат* урамы (Мәскәү шәһәрендәге шул исемле урам атамасы) һ.б.

*Уртаклык исемнәре* белән мотивлашкан атамаларны түбәндәге төркемнәргә бүлдек:

1) абстракт төшенчәләр һәм сыйфатлар нигезендә барлыкка килгән урбанонимнар: *Баллы, Тамчы, Татулык, Тормыш, Тынлык, Хезмәт юлы Ямьле, Илһам, Сафлык, Иминлек, Тынычлык, Шатлык, Гүзәл, Нәфис, Нурлы, Безоблачная, Васильковая, Веселая, Волшебная, Единение, Жемчужная, Живописная, Звездопадная, Знатная, Красивая, Лирическая, Надежда, Небесная, Поднебесная, Серебряная, Стройная* урамнары; *Әкият, Дивный, Загадочный, Мизгел, Раздольный, Укромный* тыкрыклары;

2) физик-географик үзенчәлекләренә бәйле рәвештә барлыкка килгән, ягъни объектның зурлыгы, конфигурациясе, барлыкка килүенә ишарә ясаган атамалар: *Тар урам, Таш урам, Ташлык* тыкрыгы, *Аулак урам, Грунт урам*; *Зур Шоссе урам, Яңа бистә, Иске бистә, Яңа урам, Иске урам;*

3) географик урнашуга бәйле рәвештә исемләнгән урбанонимнар: *Дальний* тыкрыгы, *Заозерная*, *Заречье* урамнары, *Тоташ* тыкрыгы, *Кремль яр буе, Приозерная* урамнары;

4) коры җир объектлары белән бәйле урбанонимнар:

а) пространствога мөнәсәбәтле: *Бакча*, *Кыр* урамнары;

ә) объектка мөнәсәбәтле: *Мәктәп*, *Базар*, *Интернат*, *Завод* урамнары;

б) табыш объектлары белән бәйле: *Алебастр*, *Торф* урамнары;

5) флорага бәйле, ягъни үсемлек атамаларына нисбәтле урбанонимнар: *Бакча, Алматау, Балантау, Баланлык, Имәнле, Ландыш, Миләш, Таллык, Усак*, *Каен*, *Сирень, Наратлык, Алчәчәк, Гөлбакча, Васильковая* урамнары*; Армут, Лавровый* тыкрыклары;

6) төсләр белән бәйле урбанонимнар: *Кызыл, Кызыл Татарстан, Кызыл Армия, Кызыл Яр* (инкыйлабның бөеклеген символлаштыручы атамалар), *Ак Чулпан, Ак каен* (нәфислекне символлаштыру), *Яшел* (яшьлек символы – күбесенчә яшьләр торган урам) урамнары;

7) татар халкының һөнәрчелеге белән бәйле булган урбанонимнар: *Сафьян урамы* (урам XVIII–XIX гасырларда күннән татар халык аяк киеме эшләүчеләр бистәсендә урнашкан. Чүәкләр өчен иң яхшы материал дип сафьян исәпләнгән)*, Күнче* (бу атама да борынгыдан сакланып килә: урам XVIII–XIX гасырларда күннән ясалган татар халык аяк киеме эшләп чыгаручы осталар бистәсендә урнашкан);

8) ел фасылларына бәйле: *Апрель, Май, Җәйге* урамнары;

9) ассоциатив күзаллауларга нигезләнгән урбанонимнар: *Якты, Ирек мәйданы, Ирекле, Кояшлы* урамнары;

10) җитештерү өлкәсе белән бәйле атамалар: *Эш, Инженер, Колхоз* урамнары;

11) җәмгыятьтә билгеле вакыйгалар, атамаларга бәйле кушылган исемнәр: *Ак чәчәкләр* урамы, *Гаилә* тыкрыгы, *Сабантуй* урамы, *Универсиада* проспекты;

12) иҗтимагый-сәяси карашлар белән бәйле: *Совет, Кызыл Октябрь, Пролетар, Пионер* урамнары;

13) бәйрәм, юбилей еллары белән бәйле: *Җиңүнең 40 еллыгы, Беренче Март, Сигезенче Март, Октябрьнең 50 еллыгы* урамнары, *Беренче Май* тыкрыгы, *Беренче Май* мәйданы;

Татар урбанонимнарын формалаштыруда катнашкан төп билгеләр үзгәреп торганга, бүгенге көндә аларның төрлелеге күзәтелә. Әлеге билгеләрне тарихи аспект белән мөнәсәбәттә тикшереп, татар урбанонимиясенең үзенчәлекләрен билгеләү мөһим. Шул ук вакытта югарыда әйтеп кителгән физик-географик, флора, фауна, эмоциональ, темпораль, төсләр белән бәйле булган урбанонимнар төрки урбанонимия системалары өчен универсаль булып тора. Шуның белән бергә, урам атамалары барлыкка килү процессы теләсә кайсы халыкның дөнья күзаллавы белән бәйле. Урбанонимнар, ачык лексик системаны тәшкил иткәнгә күрә, билгеле бер

вакытта үзгәрергә яисә юкка чыгарга мөмкин. Урбанонимика фәненең бурычы урам исемнәрен тарихи чыганак буларак куллану, урбанонимнар ярдәмендә халыкның көнкүрешен, яшәешен, социаль һәм сәяси мөнәсәбәтләр үсешен ачыклап, әлеге белемне алдагы буыннарга җиткерүдән гыйбарәт.

Соңгы ике дистә ел дәвамында барлыкка килгән яңа урбанонимнарның 42% ы ялгызлык исемнәре нигезендә формалашкан, 58% ы нигезендә уртаклык исеме ята. Ялгызлык исемнәре белән мотивлашкан атамалар, башлыча, антропонимнарга нигезләнеп барлыкка килгәннәр.

Шулай итеп, Татарстан Республикасы урам исемнәрен лексик-семантик яктан тикшерү татар халкының тормыш-көнкүреше, икътисады, мәдәнияте, милли составы, тарихи-инкыйлаби вакыйгалары, атаклы кешеләре белән танышырга, татар халкы тарихын, билгеле бер территориянең ландшафт үзенчәлекләрен өйрәнергә булыша.

## § 33. Татар урбанонимнары төзелеш-ясалышында төп үзенчәлекләр

Татар урбанонимнарының ясалышы моңа кадәр махсус өйрәнелмәде. Тикшерүләр күрсәткәнчә, урбанонимнар башка төр ялгызлык исемнәренә хас үзенчәлекләр нигезендә ясалалар. Составлары ягыннан татар телендә аларның түбәндәге төрләре күзәтелә.

*Ялгызлык исеме* ярдәмендә барлыкка килгән атамалар күпчелек очракта икенче төр изафә бәйләнеше белән барлыкка килә: *Әбүбәкер Терегулов* урамы; *Әгерҗе* урамы; *Әмәт* тыкрыгы; *Бакый Урманче* урамы; *Фатыйх Әмирхан* проспекты һ.б.

Нигезендә *уртаклык исемнәре* яткан атамалар түбәндәгечә формалаша:

1. Гади урбанонимнар. Алар үз чиратында түбәндәге төрләргә бүленәләр:

а) тамыр атамалар: *Алан, Бәйрәм, Иман, Ирек, Карлыгач, Лачын, Ләйсән, Миләш, Намус, Нәүрүз, , Таң, Тугай, Тулпар, Тургай, Тылсым, Хыял, Чаткы, Чәчәк, Шәфкать, Өмет, Энҗе, Юкә, Яз* урамнары;

ә) кушымчалар ярдәмендә ясалган урбанонимнар:

*-лык* кушымчасы ярдәмендә барлыкка килгән урбанонимнар: *Изгелек, Батырлык, Агачлык, Аланлык, Бердәмлек, Дуслык, Кардәшлек; Мәңгелек, Таллык, Туганлык, Шатлык* урамнары;

*-чы/-че* кушымчасы ярдәмендә барлыкка килгән урбанонимнар: *Игенче, Күнче, Уракчы* урамнары;

*-дәш/-тәш* кушымчасы ярдәмендә барлыкка килгән урбанонимнар: *Сердәш, Юлдаш* урамнары;

*-ар/-әр* кушымчасы ярдәмендә барлыкка килгән урбанонимнар: *Болгар* урамы;

*-лар/-ләр* күплек кушымчасы яңа сүз ясамый, ләкин географик атамалар составында еш очрый торган кушымча булып тора: *Дуслар, Качаклар, Яшьләр* урамнары.

2. Катлаулы төзелешле – ике тамыр ярдәмендә барлыкка килгән урбанонимнар. Алар үз чиратында түбәндәге төрләргә бүленәләр:

а) *кушма төзелешле* урбанонимнар: *Айнур, Акъяр, Акташ, Алмагач, Алматау, Алмачуар, Алчәчәк, Асылъяр, Байтирәк, Балачак, Каенсар, Казансу, Каратау, Күлбаш, Кызылтау, Наратбаш, Ташлыяр* урамнары;

ә) *тезмә атамалар: Алтын Балык, Су Анасы, Казан Яшьләре, Ак Каен, Кызыл Яр, Тар Урам, Тау Буе, Юл Урам, Эш Урам, Яшь Көч* урамнары.

*Сыйфатлар* нигезендә формалашкан *гади* атамалар:

*Тамыр* сүзләр: *Аяз, Аулак, Гүзәл, Зифа, Иркен, Көмеш, Матур, Нәфис, Саф, Тансык, Тигез, Тыныч, Туры, Таныш, Уртак, Юмарт, Якты, Якын, Яшел* урамнары.

Кушымча ярдәмендә ясалган атамалар:

*-лы/-ле* кушымчасы ярдәмендә ясалган атамалар: *Данлы, Алмалы, Бәхетле, Серле, Бакчалы, Җиләкле, Җимешле, Затлы, Зирекле, Йолдызлы, Игелекле, Икмәкле, Имәнле, Каенлы, Камышлы, Кардәшлек, Кояшлы, Күлле, Миләшле, Назлы, Нурлы, Сазлы, Таулы, Ташлы, Үзәнле, Үрмәле, Урманлы, Чирәмле, Чияле, Яфраклы* урамнары.

Шулай итеп, татар урбанонимнары ясалышы, башлыча, телдәге сүз ясалыш модельләренең иң активлары ярдәмендә башкарыла. Татар урбанонимнарының күпчелеге икенче төр изафә бәйләнеше белән барлыкка килгән һәм атамалар ясалышында *-лы/-ле* кушымчасы иң актив кушымча булып тора.

# ТАТАР ЭРГОНИМИКАСЫ

## § 34. Эргонимика фәненә гомуми билгеләмә

XX–XXI гасырларда Россиядә барган иҗтимагый үзгәрешләр, икътисадның яңа үсеш юллары төрле өлкәләрдә оешма һәм предприятиеләрнең күпләп барлыкка килүенә китерде. Боларның һәрберсенең, үз чиратында, атамасы булу таләп ителә.

Тел белемендә оешма атамалары белән кызыксыну инде шактый тарихка ия. Ватан ономастика фәнендә беренче тапкыр бу төр берәмлекләр турында әлеге фәннең теоретик тәгълиматын эшләүгә зур өлеш керткән А.В. Суперанская 1973 елда басылган «Общая теория имени собственного» хезмәтендә предприятие, учреждение, берләшмә, оешма атамалары хакында мәгълүмат бирә, әмма әлеге төр атамаларны эргоним дип түгел, ялгызлык исемнәр буларак кына телгә ала (Суперанская, 1973: 194).

1988 елда ономастик терминология буенча нәшер ителгән беренче «Словарь русской ономастической терминологии» сүзлегендә Н.В. Подольская *эргоним* термины турында мәгълүмат бирә: «Эргоним – эшлекле оешмаларны, предприятеләрне, учреждениеләрне, корпорацияләрне, түгәрәкләрне атый торган ялгызлык исемнәре» (Подольская, 1988: 151).

Эргонимнарны монографик яссылыкта өйрәнгән хезмәтләрдә (И.В. Крюкова, Т.П. Романова, Т.В. Шмелева һ.б.), беренче чиратта, әлеге билгеләмәгә таянып эш итү күзгә ташлана.

Бүгенге көндә ономастика фәнендә *эргоним* термины югарыда аталган хезмәттәгечә кабул ителгән, эргонимия дип эргонимнар җыелмасын, эргонимика термины исә шул төрдәге ялгызлык исемнәрен өйрәнә торган фәнне атау өчен кулланыла.

Шулай итеп, рус тел белемендә эргонимнарны тикшерә башлау узган гасырның 60–70 нче елларына туры килә. Бу төр ялгызлык исемнәргә Б.З. Букчина, Г.А. Золотова, С.А. Копорский, М.Н. Морозова, С. Роспонд, В.Д. Беленькая, С.М. Зинин, А.В. Барандеев, В.Д. Бондалетов, Е.Л. Березович игътибар итә.

Алга таба эргонимнар барлыкка килүнең лингвистик факторлары, оешма яисә предприятиегә исем сайлауга тәэсир итә торган экстралингвистик шартлар өйрәнелә. Мәсәлән, Л.М. Щетинин эргонимнарның, иң элек, эстетик функциясенә игътибар итә, ул кунакханә, кинотеатр, кафе, остаханәләргә «*Сияние*», «*Лагуна*», «*Звезда*» кебек матур яңгырашлы исемнәр бирелүен күрсәтә (Щетинин, 1968: 7–8).

Бүгенге көндә тел белемендә эргонимнар берничә яссылыкта тикшерелгән. Аерым алганда, эргонимнарның лексик-семантик үзенчәлекләрен тикшереп С.А. Копорский кинотеатрларга бирелә торган исемнәрнең нигезендә тарихи, мифологик һәм, өлешчә, географик лексика ятуын исбатлый (Копорский, 1969: 65).

Эргонимнарны тарихи яссылыкта тикшергән хезмәтләрне дә күрсәтү зарур. Мәсәлән, Ю.А. Карпенко эргонимнарны тарихка бәйләп тикшерергә омтылган, ул хәтта эргоним термины урынына «эргонизм» терминын тәкъдим итә (Карпенко, 1984: 8). Аңлашылганча, автор әлеге терминны тел белемендә киң кулланыла торган диалектизм, жаргонизм, архаизм, окказионализм кебек терминнар моделендә ясаган булса кирәк, әмма *эргонизм* термины киң кулланылышка кереп китә алмый.

Е.С. Отин хезмәтләрендә дә эргонимик лексика тарихи яссылыктан чыгып тикшерелә. Автор тикшерү объекты итеп 1917 елгы инкыйлабка кадәр һәм аннан соң да булган сәнәгать оешмаларын, акционерлык җәмгыятьләрен, фирмаларны ала (Отин, 1993: 84).

Шулай ук чит илләрдә кулланылышта йөргән эргонимнарны тасвирлама һәм чагыштырма планда тикшерү юнәлешендә дә хезмәтләр бар. А.В. Беспалова инглиз телендә кулланылган эргонимнарны тикшерү объекты итеп ала, Л.В. Дубровина Бөекбритания һәм АКШтагы медицина эргонимнарын (Дубровина, 1988), Е.Г. Микина француз эргонимиясенең формалашу этапларын тикшерә (Микина, 1986). Фам Вонг Фонг Россия һәм Вьетнамда кулланылган эргонимнарның барлыкка килү үзенчәлекләрен чагыштырып тикшерә (Фам Вонг Фонг, 2009: 44).

XX гасырның 90 нчы елларында фәндә эргонимнарны аерым өлкәләргә бәйләп тикшерә торган *төбәк эргонимикасы* формалаша. Бу өлкәдә Ижау шәһәре эргонимнарын тикшергән Н.А. Прокуровская (Прокуровская, 1996), Омск шәһәренең ойкодомонимнарын тикшергән И.А. Астафьева (Астафьева, 1996: 7), Уфа шәһәрендә кулланылышта йөргән эргонимнарны тикшергән А.М. Емельянова (Емельянова, 2007), хәзерге Казан шәһәре татар эргонимнарын өйрәнгән Р.М. Әмирова (Әмирова, 2013) һ.б.ның хезмәтләре игътибарга лаек.

Эргонимнарны лексик-семантик юнәлештән чыгып тикшергән Н.А. Янко-Триницкой мондый төр ялгызлык исемнәрне өч төркемгә бүлә. Беренче төркемгә уртаклык исемнең мәгънәсе сакланган атамалар кертелә. Икенче төркемдәге ялгызлык исемнәр аерым образлар, уңай күзаллаулар тудыра торган лексикадан ясалган. Өченче төркем, башлыча, сан белән бәйле атамалардан гыйбарәт (Янко-Триницкий, 1997).

М.Я. Крючкова күп компонентлы эргонимнарны нормативлык яссылыгыннан чыгып тикшерә, эргонимнарны дөрес язу кагыйдәләрен камилләштерә, ялгызлык исемнәрнең уртаклык исемнәрдән аермалы якларын билгели, күп компонентлы эргонимнарның ясалыш һәм мәгънәви үзенчәлекләрен анализлый, семантик төркемнәрен күрсәтә (Крючкова, 2003).

Эргонимнарны прагматик аспектта тикшерү Н.В. Шимкевичның «Русская коммерческая эргонимия: прагматический и лингвокультурный аспекты» (2002), М.Е. Новичихинаның «Коммерческая номинация» (2002), И.В. Крюкованың «Рекламное имя: от изобретения до прецедентное» (2004), Е.А. Трюфонованың «Названия деловых объектов: семантика, прагматика, поэтика» (2006) хезмәтләрендә күзәтелә.

Эргонимнарны социолингвистик яссылыктан чыгып тикшергән галимнәргә М.В. Китайгородская, И.В. Крыкова (2005), А.М. Емельянова (2007), Н.В. Носенко (2007), А.Р. Тураеваны (2012) кертергә кирәк.

Эргонимнарны функцияләреннән чыгып анализлау юнәлешендә Т.П. Романова хезмәтләре зур игътибарга лаек. Автор, Л.Г. Михайловская (1971), Н.Д. Голев (1980), М.Э. Рут (1992) хезмәтләренә таянып, эргонимнарның төп номинатив, информатив һәм рекламалау функцияләрен аерып күрсәтә.

Соңгы берничә дистә елда төрки тел белемендә дә эргонимнарны тикшерү шактый активлашты. Аерым алганда, О.А. Донскова Түбән Идел буе һәм Көнбатыш Казакстанда кулланылышта йөргән эргонимик берәмлекләрне тикшерә. Галимнең хезмәтендә эргонимнарның кулланылу вакыты инкыйлабка кадәрге, совет дәвере, XXI гасыр башы кебек чорларга бүленеп, аларның үсеш-үзгәреш процессы эзлекле рәвештә бирелә (Донскова, 2004).

Казак теленә караган эргонимнарны тикшерүче – Г.Б. Мадиева. Ул үзенең «Ономастическое пространство современного Казахстана: структура, семантика, прецедентность, лемматизация» дигән хезмәтендә казак телендә кулланылышта йөргән ялгызлык исемнәренең ономастик мохитен анализлый (Мадеева, 2005).

А.М. Емельянова Уфа шәһәрендә кулланылышта йөргән барлык, шул исәптән милли эргонимнарның да кулланылыш үзенчәлекләрен социолингвистик һәм прагмалингвистик яссылыкта тикшерә. Автор билгеле бер төбәк эргонимнарының семантик, сүзьясалыш, кулланылыш үзенчәлекләрен тикшерү белән бергә, аларны риторика позициясеннән чыгып та бәяли (Емельянова, 2007).

Татар теле гыйлемендә эргонимнарны тикшерү соңгы елларда гына башланды, гәрчә эргонимика хакында Г.Ф. Саттаровның 1970 елда басылган «Этапы развития и очередные задачи татарской ономастики» хезмәтендә үк мәгълүмат бирелсә дә. Галим биредә, иң элек, ономастиканың ялгызлык исемнәрне тикшерә торган барлык тармакларны да берләштерә торган фән булуына басым ясый һәм, топонимика, антропонимика, этнонимика, космонимика, поэтик ономастика кебек тармаклар белән беррәттән, кибет, кафе, оешма атамаларын тикшерү белән шөгыльләнә торган яңа бер тармагы булуын искәртә (Саттаров, 1970: 31).

Рус филологиясендә дә бары тик 1960–1970 елларда гына чын-чынлап сүз алып барыла башлаган оешма, кибет, кафе һ.б.ның атамалары, аларның ономастиканың бер тармагын тәшкил итүе хакындагы карашлар татар тел гыйлемендә дә XX гасырның 70 нче елларында ук телгә алына. Димәк, татар ономастикасы фәне шул елларда ук инде чагыштырмача алда булып саналган рус ономастикасы белән янәшә атлаган, барлык фәнни казанышлардан хәбәрдар булган.

Татар теле белемендә эргонимнарның ясалу ысулын, килеп чыгышларын, мәгънә үзенчәлекләрен лингвистик, ягъни тел

яссылыгында Р.М. Әмирова (Әмирова, 2013) тикшерә. Бу төр онимнарны яктырткан фәнни хезмәтләргә Г.Р. Галиуллина (Галиуллина, 2008: 95–99), О.Р. Хисамов (Хисамов, 2010: 251), И.М. Низамов (Низамов, 2008: 135), А.Ә. Гафурова (2012) һ.б. тикшеренүләрен кертеп карарга кирәк.

Эргонимик лексика, башка төр ономастик берәмлекләрдән аермалы буларак, ономастик кырның периферия өлкәсенә урнашкан (Супрун, 2000: 17). Шунлыктан үзенең семантик табигатендә күмәклек сүзләргә хас үзенчәлекләрне дә берләштерә. Эргонимнарга хас тагын бер үзенчәлек – ул да булса, аларның составы үзгәреп, яңарып торучанлыгы. Ономастик катламнардан бары тик эргонимнар гына диярлек, телдә озак яшәмәскә, кулланылыштан төшеп калырга, югалырга мөмкин. Бу, беренче чиратта, экстралингвистик факторларга бәйле, ягъни оешма, предприятие эшләүдән туктаса, аның атамасы да юкка чыга, онытыла.

Эргонимнар чынбарлыкның аерым предметларын конкрет атау өчен хезмәт итә һәм бертөрле предметлар арасыннан берсен аерып алып атый, әмма атый торган предметның һәм объектның үзенчәлекләрен, сыйфатларын белдерми. Аларда төшенчә белән турыдан-туры бәйләнеш юк. Эргоним, нигездә, объект өчен «элмә такта» буларак кына хезмәт итә. Шул ук вакытта төп денотат белән ассоциация дә тудыра.

Эргонимнар составына, ялгызлык исемнәренә хас булганча, теләсә кайсы сүз төркеменә караган лексема, хәтта бәйлек тә керергә мөмкин. Эргонимнар ялгызлык исемнәренең барлык функцияләрен башкара, әмма аларның үзләренә генә хас функцияләре дә бар (Әмирова, 2013: 43–48).

Шулардан түбәндәге функцияләре аерып күрсәтергә кирәк:

1) *номинатив, ягъни атау функциясе.* Һәрбер эргоним аерып атый торган исемгә ия була. Адресат яисә клиент оешманы исеменә карап танып белергә (идентификацияләргә) һәм башка күп сандагы төрдәшләреннән аера алырга тиеш. Мәсәлән, *Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы, Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы,* «*Метроэлектротранс*» *оешмасы, Казан шәһәре прокуратурасы, Муса Җәлил исемендәге Опера һәм балет театры,* «*Әкият*» *курчак театры* һ.б. Әлеге объектларның нинди хезмәт күрсәтүләре, нәрсә белән шөгыльләнүләре исемнәрендә үк чагылыш таба. Шунысын да

искәртергә кирәк: мондый үзенчәлек күбрәк дәүләт оешмаларына хас.

2) *мәгълүмати функция.* Һәрбер атама билгеле бер мәгълүматка ия. Эргонимнар түбәндәге мәгълүмат турында хәбәр итәләр:

а) объектның үзенчәлеге, ягъни нинди хезмәт күрсәтелүе яисә товар ассортименты турында. Мәсәлән: *«Чәй йорты»* кафесы, *«Сәүдә дөньясы», «Сәүдәгәр»* кибетләре һ.б. Кайбер очракта хезмәт күрсәтү яисә сату объекты турыдан-туры күрсәтелергә дә мөмкин: *«Киемнәр», «Аяк киеме», «Ашамлыклар»* кибетләре һ.б. Сату объекты шулай ук метафорик, метонимик, ассоциатив рәвештә ишарә ителергә дә мөмкин;

ә) атамада адресат, клиентның кем булырга тиешлеге дә чагылыш табарга мөмкин. Мәсәлән: *«Ханум», «Оста»* кибетләре, *«Батыр»* спорт комплексы һ.б.;

б) хезмәт күрсәтүнең яисә товарның субъектын билгеләү аша сату-алуның, хезмәт күрсәтүнең объектын белдерергә мөмкин. Мәсәлән, *«Адвокат»* юридик фирмасы, *«Тешләр», «Күзләр», «Ак теш»* клиникалары һ.б. Товарның ясалу урынын билгели торган атамалар да була. Мәсәлән, *«Татарстан сөте»* холдинг компаниясе, *«Питрәч», «Актаныш», «Чистай»* кибетләре.

3) *рекламалау функциясе.* Эргонимнарның бу функциясе, нигездә, коммерция оешмаларына карый. Гадәттә, дәүләт оешмаларына мондый функция башкару хас түгел. Мәсәлән: *«Казан дәүләт медицина университеты», «Идел буе районының халыкны эш белән тәэмин итү үзәге»* һ.б. атамалар, нигездә, мәгълүмати функция башкара.

4) *эстетик функция.* Гадәттә, мондый функцияне кибет, кунакханә, ресторан, кафе, матурлык салоннары атамалары башкара. Мәсәлән, *«Алтынчәч»* чәчтарашханәсе, *«Акчарлак»* рестораны, *«Яшьлек»* сәүдә йорты, *«Аяз күк», «Ләззәт»* кибетләре, *«Мөслимә»* кием тегү салоны һ.б. Күргәнебезчә, мондый атамалар кешегә уңай тәэсир итеп, аның ассоциатив уйларын, күзаллавын уятырга сәләтле.

5) *мемориаль функция.* Мондый төр эргонимнарда оешма җитәкчеләре, тарихи шәхесләрнең исемнәре һ.б чагылыш табарга мөмкин. Мәсәлән: *«Илгизәр Самакаевның сәнгать галереясы», «Нуруллин М.Р.»* азык-төлек кибете. Бу җәһәттән, дәүләт оешмалары, уку йортлары, мәчетләр тарихи шәхесләрнең исемнәрен

йөртүләре белән игътибарга лаек. Мәсәлән, *Әл-Мәрҗәни, Кол Шәриф* мәчетләре, *Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры, М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры, С. Сәйдәшев исемендәге дәүләт зур концерт залы* һ.б.

6) *милекне саклау функциясе рос-, тат-, русь-* кебек элементлар ялганган эргонимнарда ачык күренә. Бу элементлар әлеге оешмаларның дәүләт структурасы белән бәйле булуына ишарә итә, ягъни потенциаль клиентта үзенә карата ышаныч уята. Мәсәлән: *«Роспроект»* оешмасы, *«Кара алтын»* банкы, *«Татэнерго», «Татгидромаш», «Татгаз», «Татметалл»* оешмалары һ.б.

Эргонимнар ялгызлык исемнәренең барлык функцияләрен башкара, әмма, алардан тыш, бу төр ономастик берәмлекләр номинатив, мәгълүмати, рекламалау, мемориаль, эстетик һәм милекне саклау функцияләренә дә ия.

Татар эргонимиясе күп гасырлар дәвамында төрле сәяси, мәдәни, лингвистик һәм экстралингвистик факторлар йогынтысында формалаша. Хәзерге татар ономастика фәнендә бу төр берәмлекләрне өйрәнүнең әһәмияте һәм зарурилыгы алыштыргысыз. Чөнки аларны тикшерү телнең хәзерге торышын, алдагы үсеш юнәлрешләрен билгеләүдә зур роль уйный.

## § 35. Эргонимнарның генетик катламнары

Ономастик лексиканың кайсы гына төрен алсак та, аларның һәрберсе үзендә халык тарихын, милләт язмышын, мәдәни бәйләнешләрне чагылдыра. Бу күзлектән караганда, эргонимнар аеруча үзенчәлекле. Иҗтимагый тормышта, җәмгыятьтә барган һәр вакыйга, һәр күренеш күпчелек очракта эргонимда чагылыш таба. Шәһәр, бистә, авыл лингвомәдәниятенең төп берәмлеге булганлыктан, телара, милләтара бәйләнешләр, иң элек, эргонимнарда күзәтелә һәм аларның составында да урын ала. Шуңа бәйле эргонимнар килеп чыгышлары ягыннан төрле телләргә барып тоташа. Эргонимнар өлкәсендәге күзәтүләр күрсәткәнчә, халыкара лексикага нигезләнеп ясалган эргонимнар кулланылыш ешлыгы ягыннан шактый актив. Соңгы берничә дистә ел эчендә илдә барган сәяси-иҗтимагый тормыш белән бәйле рәвештә, татар эргонимиясенең зур үзгәреш кичерүе күзәтелә. Халкыбызның гадәт-йола, карашларын чагылдыра алган, матур яңгырашка, тирән мәгъ-

нәгә ия эргонимнар барлыкка килә. Рус яисә халыкара сүзләргә нигезләнеп ясалган атамалар белән беррәттән, халкыбызның һәм башка төрки телләрнең милли мәдәниятенә, традицияләренә, милли үзенчәлекләренә нигезләнгән эргонимнар барлыкка килә. Хәзерге татар эргонимик даирәсендә кулланылышта йөргән эргонимнарны килеп чыгышлары ягыннан берничә төргә бүлеп карарга мөмкин:

Төрки-татар сүзләренә нигезләнеп ясалган эргонимнар. Бу төр берәмлекләрдә халкыбыз тарихы, мәдәнияте, гореф-гадәтләре, уй-хыяллары, күзаллаулары чагылыш таба.

XX гасыр ахырларында дәүләтчелекнең торгызылуы һәм милли идеологиянең яңаруы татар халкының мәдәни тормышына да үтеп керә. Галимнәр фикеренчә, милли сәясәт өлкәсендәге яңарыш, мәдәни кыйммәтләрнең артуы, диннең иҗтимагый тормышка кабат әйләнеп кайтуы – бу процессларның барысы да татарның милли үзаңына һәм нәтиҗәдә ономастика тармагында да тәэсир итә (Галиуллина, 2008: 191).

Шундый милли атамалар арасында *Сөембикә* исеме нигезендә ясалганнары еш очрый. Мәсәлән, *«Сөембикә» кафесы, «Сөембикә» кием-салым сату ноктасы, «Сөембикә» сувенирлар кибете* һ.б. Сөембикә – халкыбыз тарихында тирән эз калдырган, фаҗигале язмышка ия ханбикә. «Казан ханнарының исемнәре онытылдыгы хәлдә, Сөен-бикә исеме онытылмады. Ул үзе күңелләрдә калдыгы кеби, аның исеме дә телләрдә калды», – дип яза ханбикә турында тарихчы Һади Атласый (Атласи, 1992: 182). Сөмбикә бүгенге көндә милләт аңында азатлык, ирек символы рәвешендә күзаллана. Татар халкы өчен бу эргоним чын милли атама буларак кабул ителә.

Милли эргонимнар арасында халкыбыз тарихында тирән эз калдырган *Болгар, Биләр* атамалары ярдәмендә ясалганнары да еш кулланыла. Тарихчылар *болгар* сүзен этник төркем, дәүләт белән бәйлиләр, шәһәр атамасы буларак та карыйлар. Мәгълүм булганча, X–XII гасырларда Идел буенда Бөек Болгар дәүләте яши. Аның башкаласы итеп Идел һәм Кама кушылган җирдә урнашкан Болгар шәһәре сайлана. Бу шәһәр чын мәгънәсендә мәдәни, иҗтимагый-сәяси үзәк була. Бөек Болгар дәүләтенең төп халкы болгарлар дип аталуы мәгълүм, ягъни татар халкының тамырлары нәкъ менә шушы Болгар дәүләтенә, болгар этник төркеменә барып тоташа (Фәхретдинов, 1995: 72). *Болгар*

атамасы халкыбызның тарихи хәтере өчен зур кыйммәткә ия. Казан шәһәрендә *болгар* сүзе катнашында ясалган эргонимнарны да күпләп очратырга мөмкин. Мәсәлән: *«Болгар» кунаханәсе, «Болгар» рестораны, «Болгар» ял итү комплексы, «БулгарГео» геодезия һәм картография оешмасы, «Булгар-синтез» полиэтилен җитештерү оешмасы, «Булгар Банк» банкы, «Болгар-Арыш», «Болгар-Медиа» оешмалары* һ.б.

Идел буе Болгар дәүләтендә икенче мәдәни үзәк булып саналган шәһәрләрнең берсе – Биләр (Фәхретдинов, 1995: 77). Бүгенге көндә дә Биләр шәһәре урнашкан урын тарихи ядкяр булып санала. Татар эргонимнары арасында да *Биләр* топонимы катнашында барлыкка килгәннәре еш күзәтелә: *«Биләр» кафесы, «Биләр» азык-төлек кибете, «Биләр» рестораны* һ.б.

Татар халкының борынгы ышануларына, мифик карашларына, борынгы Тәңречелек чорына барып тоташа торган атамалар арасында *Ак бүре* катнашында ясалганнары аерым урын алып тора. Мәсәлән, *«Ак Бүре» кафесы, «Ак бүре» спорт комплексы* һ.б. Ак бүре образы аеруча халык авыз иҗатында тулы чагылыш таба. Ф.И. Урманчиев фикеренә караганда, фольклор материаллары татарларның борынгы тотемы Ак бүре булуын исбатлый (Урманчиев, 1994: 97).

Г.Ф. Саттаров антропонимикада *бүре* сүзе белән бәйле исем-фамилияләрнең килеп чыгышын борынгы бабаларыбызның тотемистик ышануларына бәйләп аңлата (Саттаров, 1990: 16). Бу хакта Г. Дәүләтшин да «Бүре сүзе борынгы төркиләрдә кеше исемнәре ясалышында киң кулланылган. Моны аеруча затлы нәселдән чыккан кеше исемнәрендә күреп була», – дип яза (Дәүләтшин, 1999: 65).

Г.Р. Галиуллина шушы компонент кергән кеше исемнәренең, күптән инде кулланылыштан төшеп калса да, башка төр ономастик берәмлекләрдә, мәсәлән, эргонимнарда актив булуына басым ясый. Галимә фикеренчә, бу факт тәңречелек чорына барып тоташа торган борынгы йола, гореф-гадәтләрнең халкыбыз хәтерендә әле дә саклануын күрсәтә (Галиуллина, 2008: 57).

*«Юргак» кафесы, «Тулпар» спорт комплексы, «Тулпар-сервиз» оешмасы, «Тулпар» аэроклубы, «Тулпар» бәйрәм оештыру оешма*лары атамалары – татар халкына гына хас милли эргонимнар. Тарихтан, гореф-гадәтләрдән, халык авыз иҗатыннан күренгәнчә,

юргак, чабыш атлары милләтебез тормышының аерылгысыз өлешен тәшкил итә. Бу хакта хәтта XIX гасырда Казан татарларының тормышын шактый тәфсилле тасвирлаган, көнкүреш, этнографик һәм мәдәни үзенчәлекләрен мөмкин кадәр тулы чагылдырырга тырышкан Карл Фукс үзенең хезмәтендә татарларның ат ялатуларын искәртеп уза (Фукс, 1991: 37–40).

Төрки-татар чыгышлы милли атамалар рәтенә *«Өчпочмак», «Кыстыбый» кафеларының* атамаларын да кертү зарур. Өчпочмак, кыстыбый – татар халыкының чын милли ризыгы булып санала. Шуңа да әлеге ризык атамалары, нигездә, кафе эргонимнарын ясауда катнаша.

Татар халкының милли бәйрәме – сабантуй. Бүгенге көндә сабантуй милләтнең олы бәйрәме булып санала. Шушы сүз нигезендә ясалган *«Сабантуй» кафесы* эргонимы татар халкының мәдәниятен, гореф-гадәт, йолаларын чагылдыручы атама буларак күзаллана.

Милли эргонимнардан тагын *«Алтынай» кибете* атамасын китерергә мөмкин. Милли атамаларның һәрберсе татар халкының мифик, мәдәни, этнографик күзаллауларын чагылдыра, тарихи хәтерен яңарта.

Гарәп һәм фарсы телләреннән кергән сүзләргә нигезләнеп ясалган эргонимнар. Татар эргонимик системасында гарәп һәм фарсы телләреннән кергән берәмлекләр киң кулланыла.

Татар халкының гасырлар дәвамында хәтерендә йөрткән, яраткан геройлары, милли образларының тагын берсе – *Хуҗа Насретдин*. Бу образ татар халкына XVI–XVIII гасырларда ук Көнчыгыш халыкларыннан килеп керә. Һәр халык әлеге образга үз традицияләрен бирергә омтыла. Татар халкының Хуҗа Насретдины җор телле, тапкыр, зирәк булуы белән аерылып тора һәм гасырлар дәвамында телдән-телгә күчеп йөри, мәзәкләре сөйләнә, хәтта эргоним ролендә дә кулланыла: *«Хуҗа Насретдин» кафесы*.

Югарыда аталган телләрдән кергән эргонимнарга *«Милли» кибете, «Милли китап» нәшрияте* атамаларын китерергә мөмкин.

Гарәп һәм фарсы телләреннән кергән сүзләргә нигезләнеп ясалган эргонимнарның күпчелеген ислам дине белән бәйле эргонимнар тәшкил итә. Галимнәр ислам диненең татар халкының көнкүрешенә генә түгел, ә ономастиконына да үтеп керүенә

игътибар итәләр. Мәсәлән, Г.Ф. Саттаров ислам диненең антропоникага үтеп керүе хакында болай ди: «Ислам дине татар тормышының бөтен икътисади һәм идеологик даирәләрен үз йогынтысында тоткан һәм, әлбәттә, кеше исемнәре системасына да көчле тәэсир ясаган» (Саттаров, 1989: 137). Г.Р. Галиуллина да бу хакта үзенең хезмәтләрендә искәртә. Галим фикеренчә, төрки-татар рухи мәдәниятенең бер өлешен тәшкил итә торган ислам дине антропонимик системаның үсешендә зур роль уйнаган. Ислам дине тәэсирендә төрки-татар антропонимик системасы яңа үсеш этабына керә (Галиуллина, 2008: 111). Бу үзенчәлек антропонимик системага гына түгел, татар эргонимиясенә дә хас. Аеруча XX гасыр ахырында илдә барган иҗтимагый үзгәрешләр, дин һәм сүз ирегe игълан ителү нәтиҗәсендә эргонимик системада да мөселманлык, ислам дине кануннары белән бәйле эргонимнар барлыкка килде. Мәсәлән, ирләр кием-салымы сата торган *«Адәм»* кибетенең атамасы Коръән сүрәләренә, Мөхәммәд пәйгамбәрнең хәдисләренә, атабыз Адәм, анабыз Һәва дигән ышануларга барып тоташа (Мәхмүтов, 1995: 29).

Ислам дине белән бәйле эргонимнар, бер яктан, халкыбызның дини гореф-гадәтләре, ышанулары хакында бәян итсә, икенче яктан, бу эргонимнар татар халкының ислам дөньясы белән булган бәйләнышлары «чагылдырган тел фактлары булып та торалар. Мәсәлән, кафе, кибет, медицина үзәкләре, дини оешмаларның атамалары булып хезмәт иткән *«Хәләл», «Йасин», «Әлкәүсәр», «Зәкать», «Корбан»* эргонимнары актив кулланыла торган берәмлекләрдән санала. Күп кенә кибет, кафеларның, хәләл азык-төлек стандарты буенча комитет атамасы буларак билгеле *хәләл* сүзе гарәп теленнән алынган һәм ул ислам кануннары нигезендә әзерләнгән ризык, ислам дине тарафыннан рөхсәт ителә торган эш-шөгыль мәгънәсендә аңлашыла. Мөселман халкы өчен *хәләл* (حلال) лексемасы Коръән кануннарына, мөселман гореф-гадәтләренә туры китереп, шулар нигезендә әзерләнгән азык-төлекне белдерү өчен файдаланыла торган төп берәмлеккә әверелеп бара. Мәсәлән: *«Хәләл ит», «Хәләл ризык», «Хәләл азык-төлек», «Әл-хәләл» кибетләре* һ.б.

Медицина үзәкләренең атамасы буларак кулланыла торган *«Йасин»* эргонимы да Коръән сүрәләренә нигезләнеп барлыкка килгән. Ул Коръәндәге 36 нчы сүрәнең башында торган «йа син»

(آ ثِين) дигән гарәп хәрефләреннән килеп чыккан. Мөхәммәд пәйгамбәр хәдисләренә караганда, «Йа син» сүрәсе Коръәннең йөрәген, үзәген тәшкил итә. Бу сүрәне, гадәттә, кешеләрнең физик һәм рухи газапларын җиңеләйтү өчен талисман итеп тә йөрткәннәр, бу сүрә аларны төрле авырлыклардан, золымнардан саклый дип ышанганнар.

Коръән белән бәйле эргонимнарның тагын берсе – *«Әл-Кәүсәр» кафесы* атамасы. Бу эргоним мөселман кешесенә Коръәндәге 108 нче сүрә исеме буларак мәгълүм. Гарәп теленнән алынган бу лексема ислам динендә җәннәт чишмәсенең исемен аңлата. *Кәүсәр* лексемасы татарларда шактый актив һәм борынгыдан ук кулланыла. Ономастикада ул антропоним буларак файдаланыла башлый. Галимнәр аның ир балаларга да, кыз балаларга да исем итеп бирелүенә игътибар итәләр. Әмма ул антропонимиядә *Әл-кәүсәр* дип түгел, ә *Кәүсәр* формасында кулланыла (Саттаров, 1998: 152). XX гасырның ахырларыннан башлап, без аны кеше исемнәре рәтендә генә түгел, татар эргонимиясе составында да күрәбез.

Дини оешмаларның, берләшмәләрнең атамалары да зур мәгънә салынган гарәп сүзләренә нигезләнгән. Мәсәлән, Татарстан мөселманнарының диния нәзарәте каршында *«Зәкать»* фонды оешкан, дини берләшмәләрдән *«Корбан» комплексы, «Идел-хаҗ»* һ.б. эшли.

Халкыбыз тормышында ислам диненең, Коръән сүрәләренең, Мөхәммәд пәйгамбәр хәдисләренең йогынтысын күрсәткән эргонимнарның тагын бер төре кеше исемнәре белән бәйле. Антропонимнар нигезендә ясалган эргонимнар күпчелекне алып тора. Ләкин аларның бары берничәсе генә ислам диненә барып тоташа. Болар – *«Айшә», «Мөслимә» кибетләре, «Фатыйма» кунакханәсе һәм хатын-кызларга психологик ярдәм күрсәтү оешмасы, «Рәшидә» Коръән өйрәнү буенча уку-укыту үзәге.*

Ислам динен кабул иткән кеше ислам терминологиясе буенча *мөслим (мөслимә)*дип атала. Татар антропонимикасы законнары нигезендә, байтак кына хатын-кыз исемнәре ир-ат исемнәренә *-а/-ә* кушымчалары өстәлү нәтиҗәсендә барлыкка килә (Галиуллина, 2008: 247). Шул нигездә ясалган *Мөслимә* антропонимы татар халкында чисталык, сафлыкны гәүдәләндерә торган образ булып та йөри.

Шулай ук кеше исемнәренә нигезләнеп ясалган эргонимнардан *«Госмания»* урта белем бирә торган ислам мәктәбе, *«Фарук»* һәм *«Ризван»* мәдрәсәләре, *«Габдесамат»* дини берләшмәсе, *«Йосыф»* ирләр чәчтарашханәсе атамаларын китерергә мөмкин.

Шәрык дөньясы белән бәйле эргонимнарның бер төркеме кеше исемнәренә нигезләнеп ясалган. Урта Азия илләрендә киң кулланыла торган антропонимнардан саналган *Нагмир, Сәид, Әсхәр, Мостаф* исемнәре эргоним ролен үти: *«Нагмир» сәүдә комплексы, «Әль-Сәид» күчемсез милек агентлыгы, «Әсхәр» гараж кооперативы, «Мостаф» төзелеш-проектлау оешмасы*, *«Асмар» азык-төлек кибете, «Рамсар» азык-төлек кибете «Бахир азык-төлек кибете, «Раузан» азык-төлек кибете, «Сурахан» азык-төлек кибете, «Халва», «Кебеб Хаус», «Султан-Кебаб» кафелар*ы һ.б.

Кайбер очракта эргоним буларак кулланыла торган антропоним янына татар һәм башка төрки халыкларда сословие термины буларак кулланылган сүзләр дә килергә мөмкин. Мәсәлән, *«Давид бәк» кунакханәсе*.

Югарыда саналган атамаларда, бер яктан, халкыбызның милли үзаңы, дини ышанулары, икенчедән, ислам дине кануннары нигезендә яшәү рәвеше, шуңа омтылышы чагылыш таба. Шунысын да искәртергә кирәк, дин, Коръән белән бәйле мондый атамалар бары тик XX гасыр ахырларында гына, илдә барган зур иҗтимагый үзгәрешләр нәтиҗәсендә генә, кулланылышка кереп китә һәм активлаша.

Рус яисә халыкара сүзләргә нигезләнеп ясалган эргонимнар татар теле җирлегендә бик актив кулланылышта йөри. Күпсанлы рус атамаларына нигезләнеп ясалган эргонимнарга Россиянең барлык төбәкләрендә кулланылышта йөргән *«Магнит», «Эссен», «Лента», «Пятерочка» кибетләр челтәрләре*, *«Олигарх» төзелеш материаллары кибете, «Магнат» азык-төлек кибете, «Меценатъ» рестораны, «Лидер» төзелеш оешмасы, «Премьер» стоматология кабинеты, «Давыдов» кибете, «Гармония» медицина диагностикасы үзәге, «Третий глаз» стоматология үзәкләре, «Лебедкин» кафесы, «Туманов» оешмасы, «Дантист» стоматология кабинеты, «Эколог» оешмасы, «Коммерсант» сәүдә оешмасы, «Юрист» юридик оешмасы, «Альянс» төзелеш фирмасы, «Легион» компьютер клубы, «Лига» тәрәзә җитештерү оешмасы, «Союз» аудисалоны* һ.б. атамаларны кертергә була.

XX гасыр ахырларында киң кулланыла башлаган эргонимнарның икенче бер төркемендә Европа цивилизациясе чагылыш таба. Теге яки бу оешманың, күп очракта кибетләрнең, Европа тәҗрибәсенә нигезләнүенә, яисә Көнбатыштан китерелгән товарлар белән сату итүенә аның чыганак телдәгечә язылган исемнәре – эргонимнары да ишарә итә. Мондый очракларда, еш кына товар тамгасы, яисә шул товарны эшләп чыгарган оешма исеме шул кибетнең атамасы буларак та кулланыла. Аеруча машина маркалары, товар атамалары, ягъни прагматонимнар эргоним ролендә еш күзәтелә. Мәсәлән, *«Adidas», «Dayly», «Grostyle», «Honda», «Hyundai», «Nokia», «Siemenes»* һ.б. кибетләрнең атамалары ролен кием-салым, машина, көнкүреш техникасы маркалары башкара.

Шунысы игътибарга лаек, инглиз, немец, итальян һ.б. телләрдә язылган эргонимнар үзләренең мәгънә үзенчәлекләре ягыннан да аерыла. Аларда Көнбатыш илләренең халыкларына хас булган юмор, сентиментализм, конкретлык чагылыш таба. Мондый төр эргонимнар, Көнчыгыш илләрдән кергән төрләренә караганда, бик үзенчәлекле, мәгънәви яктан гаять бай. Аларда дөнья әдәбияты да, кино-театрлар да, миф-легендалар да, Европа халкының дөньяга карашы, аны кабул итүе – барысы да урын ала. Мәсәлән, *«Вантаа»* (Финляндиядәге шәһәр) *сәүдә ноктасы, «Милан»* (Италиядәге шәһәр) *кафесы, «Фронда»* (XVII гасырда Франциядә булган иҗтимагый-сәяси компания) *сәүдә ноктасы*, *«Графиня»* (граф нәселеннән булган хатын-кызларга олылап эндәшү сүзе) *косметика салоны*, *«Мондиал»* (фран. «югары дәрәҗәдәге») *кибете*, *«Джон Сильвер» кафесы, «Наполеон» фирмасы, «Дали» компаниясе, «Робинзон» кафе-бары, «Мона Лиза» массаж ясау клиникасы* һ.б. Бу эргонимнарның барысы да, башлыча, латин графикасында, инглиз теленә яраклаштырып язылган. Гомумән, инглиз теле, потенциаль клиентларны җәлеп итү максатыннан, эргонимнар составында, рекламада бик актив кулланыла. Клиент латин графикасында язылган эргонимнарны, гадәттә, теге яки бу кибет, сәүдә үзәге тәкъдим итә торган товарның югары сыйфатлы, модалы, заманча һәм Европадан кертелгәнлеген күрсәтә торган билге рәвешендә кабул итә.

Башка телләрдән кергән алынмаларга нигезләнеп барлыкка килгән эргонимнар.

Татар теле җирлегендә, югарыда саналган чыганак телләрдән кала, башка телләрдән (мәсәлән:, төрек, үзбәк, япон, кытай һ.б. дан) кергән берәмлекләр дә кулланыла. Мисал өчен, аерым ил, дәүләт, милләт исемнәре дә эргоним ясауда катнашырга мөмкин: *«Turkish airlines», «Әфганистан бердәмлеге» Татарстан Республикасы төбәкара иҗтимагый оешмасы, «Туркистан» кафесы, «Азәрбайҗан» Татарстан Республикасы милли-мәдәни автономиясе, «Үзбекистан һава юллары» авиаоешмасы, «Үзбәк ашлары» кафесы, «Төрек ашлары» кафесы, «Малабар» һинд халыклары ашлары рестораны* һ.б.

Соңгы елларда Көнчыгышның иң алга киткән илләреннән саналган Япония белән Кытайның милли ризыкларын тәкъдим иткән ресторан, бар, кафе һәм башка көнкүреш хезмәте күрсәтә торган оешмаларның да күпләп ачылуы күзәтелә. Мәсәлән, *«Мацури» рестораны, «Канпай» рестораны, «Китай-авто» автомобиль детальләре сатучы кибет, «Таобао» интернет-кибете, «Чжуд-Ши КЗН» медицина үзәге, «Лаоши» кытай телен укыту мәктәбе* атамаларында Кытай халкының милли үзенчәлекләре урын ала.

Галимнәр тарафыннан Япония алга киткән ил итеп кенә түгел, ә һәркайда үзенең индивидуаль йөзен саклап кала ала торган көчле дәүләт буларак бәяләнә (Крыкова, 2007: 78). Бу сыйфат әлеге оешма, ресторан, кафеларның япон халкына хас стильдә төзелүендә генә түгел, ә аларның атамаларында да чагылыш таба. Мәсәлән: *«Японка» кибете, «Япончик» суши-бары, «Япошка» суши-бары, «Гейша» кафесы, «Самурай» рестораны, «UNIQLO» киемнәр кибете, «Японский дворик» суши-бары, «Мегуми» кибетләр челтәре, «Japan koni» автосервизы, «Японские кондиционеры» Япониядә эшләнгән кондиционерлар сату компаниясе* һ.б.

Әлеге саналган оешмаларның эшчәнлеге теге яки бу яклап эргонимнарда чагылыш тапкан милләт белән бәйле. Алар шул милләтнең ашын-сыен тәкъдим итәләр, яки шул илләрдә чыгарылган товарларга ремонт ясау, кирәк-ярак сату белән шөгыльләнәләр. Әлеге эргонимнар Татарстан Республикасының күпмилләтле булуын күрсәтә, алар шәрык илләренең милләте, гореф-гадәте, этнографик күзаллаулары һәм ономастик байлыгы турында шактый тулы мәгълүмат бирә, татар халкының башка төрки һәм Көнчыгыш илләре белән рухи уртаклыгына да ишарә итә.

Татар эргонимнары илдәге һәрбер сәяси-иҗтимагый вакыйгаларны, күпмилләтле республиканың мәдәни-рухи тормышын, дини гореф-гадәтләрен, милли йолаларын чагылдыра алуы ягыннан зур әһәмияткә ия ономастик берәмлек булып тора.

## § 36. Татар эргонимнарын номинацияләү принциплары

Тел белемендә ялгызлык исемнәренең һәрбер төренең үзенә генә хас төркемләү үзенчәлекләре бар. Татар эргонимик берәмлекләрен төркемләүдә М.В. Китайгородская (2003) классификациясе нигез итеп алына һәм ике төркем аерыла: мотивлашкан һәм мотивлашмаган эргонимнар.

Мотивлашкан эргонимнарга атама белән ул белдергән оешма, яисә оешманың берәр үзенчәлеге, сыйфаты арасындагы мәгънә бәйләнеше булган атамалар кертелә. Ягъни оешманы атау өчен аның берәр төп билгесе яисә башкарган шөгыле, эшләп чыгарган продукциясе нигез итеп алына (Китайгородская, 2003: 138). Мотивлашкан эргонимнарның түбәндәге төркемчәләрен күрсәтергә мөмкин:

1. Объектның пространстводагы урыны белән бәйле эргонимнар: *«Казан» милли мәдәни үзәге, «Мөслим икмәге» икмәк кибете, «Казан» сәяхәтләр бюросы, «Казан» такси хезмәте күрсәтү оешмасы, «Казан» күчемсез милек үзәге, «Казан» ат-спорт клубы, «Әлмәт хәбәрләре» муниципаль газета редакциясе, «Яр Чаллы» балалар һәм яшүсмерләр спорт мәктәбе, «Казан» телерадиокомпаниясе, «Каравай» кибете* (Каравай бистәсендә урнашкан), *«Яңа бистә»* (Яңа бистәдә урнашкан), *«Тукай-сервиз» оешмасы* (Г. Тукай урамында урнашкан), *«Яшь көч» кибете* (Яшь көч урамында урнашкан) һ.б.

Кайбер төр эргонимнарда объектның адресы чагылыш таба. Мәсәлән, *«Чехова 31» кибете* (Чехов урамы, 31 нче йортта урнашкан), *«Арбузова 5» кафесы* (Арбузов урамы, 5 нче йортта урнашкан) һ.б., ә менә *Чехов базары, Даурия базары* кебек сәүдә үзәкләренең атамаларында урам исеме дә, тукталыш атамасы да чагылыш таба.

Шулай ук кибет, сәүдә нокталарының атамалары тукталыш исеменә нисбәтле барлыкка килергә мөмкин. Мәсәлән: *«Чишмәле» кибете* («Чишмәле» тукталышында урнашкан), *Кол Гали сәүдә*

*ноктасы* (Кол Гали тукталышында урнашкан), *«Океан» торак-коммуналь хезмәтен күрсәтү оешмасы* (Океан тукталышында урнашкан) һ.б.

2. Объектның эшчәнлеге белән бәйле эргонимнар. Бу төр эргонимнар төп урынны биләп тора һәм номинаторлар тарафыннан актив файдаланыла. Мәсәлән: *«Сөт», «Аш-су», «Балык», «Икмәк», «Чәчәкләр», «Аяк киеме», «Ризык», «Бүләкләр», «Башлык» кибетләре* кебек эргонимнар клиентка кирәкле мәгълүматны турыдан-туры җиткерү максатыннан кулланыла. Алар барлык төр кибет, оешма, учреждение, предприятиеләрне атау өчен кулланылырга мөмкин. Мәсәлән: *«Төзелеш» оешмасы, «Трикотаж» кибете, «Алтын» кибете, «Металл» металл эшләнмәләре җитештерү оешмасы, «Спорт» спорт кибете, «Ак таш» юл плиткасы җәя торган оешма* һ.б. Мондый төр эргонимнар оешма, кибет турында тулы мәгълүмат та бирергә, шул ук вакытта бер генә төр товарны атарга да мөмкин.

Соңгы елларда объектны турыдан-туры атый торган эргонимнар арасында тезмә һәм парлы сүзләр нигезендә барлыкка килгәннәре еш кулланыла башлады. Мәсәлән: *«Аяк киемнәре» кибете, «Шкаф-купе» оешмасы, «Азык-төлек» кибете, «Аракы-шәраб» кибете, «Хуҗалык товарлары» кибете, «Җиләк-җимеш, яшелчә» сәүдә ноктасы, «Хәләл ризык» ашамлыклар кибете* һ.б. Номинаторлар оешма, кибет, андагы ассортимент хакында мөмкин булган кадәр төгәлрәк мәгълүмат бирергә тырыша.

Дәүләт, хөкүмәт структурасына караган оешмаларның атамалары да, нигездә, учреждение хакында турыдан-туры мәгълүмат бирүгә корылган була, мәсәлән: *Татарстан Республикасы дәүләт торак инспекциясе, Татарстан Республикасының Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты каршындагы төзелеш, транспорт, элемтә, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыгы аппараты идарәсе* һ.б. Шулай ук мәктәп, уку йортлары, клиника, хастаханә, музей, китапханә, балалар бакчалары һәм башка төрле бюджет оешмаларының эргонимнары да, башлыча, шушы оешма хакында турыдан-туры мәгълүмат бирә, аны тулысынча атый. Бу очракта да, гадәттә, сүз-тезмәләр кулланыла: *Татарстан Республикасы яшьләр оешмалары советы, Казан шәһәре психоневрология интернаты, Республика клиник хастаханәсе, Казан шәһәренең 131 нче номерлы физика-*

*математика лицее, Казан радиомеханика колледжы, Татарстан Республикасы һәм татар халкының дәүләтчелек музее, Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең күргәзмәләр залы, Казан ипподромы* һ.б.

Объектның эшчәнлеге белән бәйле эргонимнарның берничә төре бар:

а) объектның эшчәнлеге хакында турыдан-туры мәгълүмат бирә торган эргонимнар: *«Сөт», «Аш-су», «Балык», «Икмәк», «Чәчәкләр», «Аяк киеме», «Ризык», «Бүләкләр», «Башлык» кибетләре, «Спорт» спорт кибете* һ.б.;

ә) объектның эшчәнлеген күзаллауларга нигезләнеп атый торган эргонимнар: *«Татлы» кибете, «Тәмле» кафесы, «Снайпер» корал сату кибете, «Мәгариф» нәшрияты, «Фән» нәшрияты, «Яналиф» нәшрияты* һ.б.;

б) төрле фәнни терминнарга нигезләнгән эргонимнар: *«Вектор» җитештерү предприятиесе, «Резонанс» касса аппаратларын сату оешмасы, «Полимер» оешмасы, «Фотон» аппаратура җитештерү предприятиесе* һ.б.;

в) һөнәр атамалары белән мотивлашкан эргонимнар: *«Дантист» стоматология кабинеты, «Эколог» оешмасы, «Коммерсант» сәүдә оешмасы, «Юрист» юридик оешмасы* һ.б.

3. Объектны кеше исем-фамилияләренә нигезләнеп атау. Элеге эргонимнарның берничә төре бар:

а) хатын-кыз исемнәренең эргоним буларак кулланылуы. Аның үз үзенчәлекләре бар. Мәсәлән, чәчтарашханә, кафе, зур булмаган кибет, сәүдә нокталарына атама итеп, нигездә, хатын-кыз исемнәре куела: *«Сара», «Энҗе», «Айгөл», «Алсу», «Аида», «Лира», «Луиза», «Роза», «Регина»* һ.б. чәчтарашханәләре; *«Лилия», «Дәлия», «Таңсылу», «Зөһрә», «Ләйсән», «Гөлнара», «Гүзәл»* һ.б. ашамлыклар кибете, *«Регина», «Резеда», «Роза»* кафелары һ.б. Барыннан да бигрәк, хатын-кыз исемнәре, чәчтарашханә, косметология салоннарының атамаларында очрый, чөнки әлеге оешмалар, беренчедән, күпчелек очракта хатын-кызларга хезмәт күрсәтә. Икенчедән, галимнәр фикеренчә, матур яңгырашлы, тирән мәгънәле хатын-кыз исеменә нигезләнеп ясалган эргонимнар потенциаль клиентны үзенә җәлеп итеп тора һәм кешенең хәтерендә дә тиз кала (Китайгородская, 2003: 130). Эргоним сыйфатында татар хатын-кыз исемнәренең дә, рус һәм башка алынма антропонимнарның да киң кулланылуы күзәтелә;

ә) ир-ат исемнәре күп очракта оешма, ресторан атамаларында нигез ролен башкара. Мәсәлән:*«Тимерхан» рестораны, «Айзат» автомобиль сервизы оешмасы, «Әмир» куркынычсызлык хезмәте күрсәтү оешмасы, «Әхмәтхан» җиһазлар сату оешмасы, «Азамат» автомобиль сервисы оешмасы, «Әмин» товар җитештерү оешмасы, «Салават» хәйрия фонды, «Солтан» туристлык агентлыгы, «Әмир» җиһаз җитештерү оешмасы, «Бәхтияр» кибете, «Рәйхан» автомобильләр сервизы, «Шамил» кафесы, «Марсель» ашамлыклар кибете,* һ.б. Галимнәр фикеренчә, ир-ат исеменә нигезләнеп ясалган эргонимнар кешеләрдә оешмага карата ышаныч уята (Китайгородская, 2003: 35), чөнки ир-ат исеме үзенең семантикасы белән ныклык, батырлык, көч, ышаныч мәгънәләренә ия, ә хатын-кыз исемнәре матурлык, сафлык, нәзакәтлелек символы буларак гәүдәләнә (Вәлиева, 2007: 66);

б) милли-дини исемнәргә нигезләнеп ясалган эргонимнар. Әлеге эргонимнар оешманың атамасы хакында мәгълүмат биреп кенә калмый, клиентта шул оешма яки кибеткә карата билгеле бер мөнәсәбәт урнаштыруга да ярдәм итә. Мәсәлән, мөселман кешесенең мөселман исемнәре белән аталган оешма-кибетләргә карата шактый ук уңай мөнәсәбәттә торуы мәгълүм: *«Галия» уку-укыту үзәге, «Мөслимә» кием-салым кибете, «Фатыйха» автомәктәбе һәм «Фатыйма» кунакханәсе, рестораны, психологик ярдәм күрсәтү үзәге, «Мостафа» архитектура һәм төзелеш проектлары оешмасы, «Йосыф» ирләр чәчтарашханәсе* һ.б. Мөселман исеме белән аталган оешмаларның бер өлеше ислам дине белән турыдан-туры бәйле: *«Габдесамат» дини берләшмәсе, «Госмания» урта белем бирә торган ислам мәктәбе* һ.б.

Кеше исемнәренә нигезләнеп ясалган эргонимнар кулланылышы шул оешма хуҗасының исеменә яисә башка төрле туганлык мөнәсәбәтләренең чагылыш табуына бәйләп тә аңлатыла. Матур яңгырашка ия һәм сирәк кулланыла торган, стилистик яктан аерылып торган исемнәрнең эргоним ролендә килү очраклары гына бу атаманың мотивлашкан булу-булмавын шик астына ала. Биредә мисал итеп, *«Гөлкәй», «Таңсылу», «Таңсу» кафеларының* атамаларын китерергә мөмкин. Фәнни мәгълүматларга караганда, *Гөлкәй, Таңсылу, Таңсу* исемнәре XX гасырда Казан шәһәрендә бик сирәк очрый (Галиуллина, 2008: 315–330). Саналган исемнәр татар халык авыз иҗатында – әкиятләрдә, җырларда чагылыш таба,

классик әдәбиятта уңай образларны гәүдәләндерү максатыннан кулланыла (Зиннатуллина, 2005: 77). Шуңа күрә аларның эргоним ролендә кулланылуын бары тик татар халкының эстетик-мәдәни күзаллауларына таянып кына аңлатырга мөмкин;

в) фамилия һәм ата исемнәренә нигезләнеп ясалган атамалар. Әлеге төр эргонимнар чагыштырмача сирәк очрый. Мәсәлән: *«Халич» бары, «Ибрагимыч» сәүдә склады, «Лебедкин» кафесы, «Туманов» оешмасы* һ.б. Мисаллардан күренгәнчә, татар эргонимнары арасында фамилиягә һәм ата исемнәренә нигезләнеп ясалганнары бөтенләй диярлек кулланылмый. Гомумән, татар халкына элек-электән бер-берсенә исем белән эндәшкән яисә *абый, апа, эне, сеңел* кебек туганлык мөнәсәбәтен белдерә торган, *әфәнде, туташ, ханым* кебек олылап эндәшә торган сүзләрне кулланырга тырышкан. Татар халкында фамилия яисә *-ович/-евич* кушымчалары өстәлгән ата исеме белән эндәшү, русларга караганда, чагыштырмача соң кулланылышка керә. Аңа кадәр татар халкында *фәлән кешенең улы/углы* формасында эндәшү кабул ителгән була (Мазитова, 1986: 31). Татар эргонимиясендә дә фамилия яисә ата исемнәре атама ясауда сирәк файдаланыла.

Кеше исеме яисә фамилиясенә нигезләнеп ясалган эргонимнарның кайберләре антропонимнарга *«тур», «К», «+»* кебек элементлар өстәлү нигезендә барлыкка килгән. Мәсәлән: *«Регина – тур» оешмасы, «Диана и К» фирмасы, «Дилә – тур» туристлык агентлыгы, «Айзат +» оешмасы* һ.б.

4. Объектны образлы күзаллауларга таянып атаучы эргонимнар: *«Хәзинә» күргәзмәләр залы, «Ватан» йортлар төзү оешмасы, «Сандугач» иҗат клубы, «Ялкын» газлаштыру оешмасы, «Ял» кунакханәсе, «Ак йорт» күчемсез милек агентлыгы, «Алтын иген» икмәк кибете, «Бәйрәм» бәйрәмнәр оештыру үзәге, «Төзелеш» төзелеш оешмасы, «Саулык» даруханә, «Стиль» чәчтарашханәсе, «Курай» радиосы, «Йомшак алтын» сәнгать эшләнмәләрен ясау һәм сату оешмасы, «Сабантуй» кафесы, «Кырлай ял паркы* һ.б. Бу эргонимнарда татар халкының мәдәни күзаллаулары, милли-этнографик үзенчәлекләре, көнкүреше, тарихи хәтере чагылыш таба.

Мотивлашкан эргонимнарның һәркайсы билгеле бер максат белән барлыкка килгән. Алар арасында объект, аның урнашкан урыны (*«Яңа бистә»* кибете, *«Тукай-севриз»* оешмасы һ.б.), эшчәнлеге (*«Чәчәкләр», «Башлык»* кибетләре, «*Төзелеш*» оешмасы һ.б.)

белән турыдан-туры бәйләнештә торганнары да, кеше исем-фамилияләренә нигезләнеп атаганнары да, образлы күзаллауларга гына нигезләнеп атаганнары да *(«Татлык»* кибете, *«Фән»* нәшрияты» һ.б.) бар.

Мотивлашмаган эргонимнарга оешма белән аның атамасы арасында турыдан-туры бәйләнеш булмаган онимнар кертелә.

1**.** Кешене, затны белдерә торган, төрле яклап атый, бәяли торган сүзләр нигезендә ясалган эргонимнар: *«Әфәнде» тегү салоны, «Каган» куркынычсызлык хезмәте оешмасы, «Хан» азык-төлек кибете, «Эшкуар» эксперт оешмасы, «Олигарх» төзелеш материаллары кибете, «Магнат» азык-төлек кибете, «Меценатъ» рестораны, «Лидер» төзелеш оешмасы, «Премьер» стоматология кабинеты* һ.б.

2. Үсемлек, җир-су хайваннары, кош-корт атамаларына нигезләнеп ясалган эргонимнар: *«Ак барс» хоккей клубы*, *«Юлбарыс» җиңел автомобильләр сервизы, «Фил» студиясе, «Тулпар» иминият компаниясе, «Аю» агрофирмасы, «Арслан» автомобильләр сервизы, «Бүре» кафесы, «Аю» автомобиль югыч, «Керпе» азык-төлек кибете, «Торна» азык-төлек кибете, «Аккош» төзелеш материаллары кибете, «Акчарлак» рестораны, Сандугач» балалар һәм яшүсмерләр клубы, «Байгыш» азык-төлек кибете, «Тургай» рестораны, «Бөркет» алюминий конструкцияләр җитештерү оешмасы* һ.б.

3. Географик терминнарга, табигать күренешләренә нигезләнеп барлыкка килгән атамалар: *«Таш» төзелеш оешмасы, «Салават күпере» иҗат берләшмәсе, «Тугай» азык-төлек кибете, «Төньяк балкышы» кибете, «Алан» кибете, «Кич» кибете, «Давыл» кафесы, «Дулкын» кафесы* һ.б.

4. Мифик геройларның исемнәренә, мифик образларга нигезләнгән эргонимнар: *«Ак бүре» спорт комплексы, «Тулпар» иминиятләштерү компаниясе, «Тулпар Эйр» авикомпаниясе, «Тулпар» аэроклубы; «Зилант» банкетлар залы, «Зилант» бильярд клубы, «Зилант» интернет-кибете* һ.б.

5. Тарихи шәхесләрненең исемнәрен нигез итеп алган эргонимнар: *«Чынгызхан» автомобильләр юуу оешмасы, «Тамерлан» куркынычсызлык хезмәте оешмасы, «Сөембикә» кафесы, «Сәйдәш» мәдәният йорты* һ.б.

6. Космонимик һәм астрономик атамаларга нигезләнгән эргонимнар: *«Кояш» кием-салым кибете, «Йолдыз» азык-төлек кибете, «Ай» автомобиль сервизы, «Чулпан» автомибильләр гараж-кооперативы, «Аяз күк» кафесы* һ.б.

7**.** Вакыт, чор, ел фасылларына мөнәсәбәтле сүзләр нигезендә барлыкка килгән эргонимнар: *«Таң» нәшрияты, «Кич» кафесы, «Заман» төзелеш материаллары кибете, «Март» медицина үзәге, «Апрель» кунакханә җиһазларын сату оешмасы, «Май» чәчтарашханәсе, «Август» көчемсез милек агентлыгы, «Октябрь» нәшрияты, «Декабрь» төзелеш оешмасы, «Яз» кафесы* һ.б.

8**.** Семантикасында уңай төшенчә яткан абстракт сүзләргә нигезләнеп ясалган эргонимнар: *«Файда» автомобильләр кирәк-ярагы сату кибете, «Савап плюс» автомобильләр кирәк-ярагы сату кибете, «Бәхетле» супермаркетлар челтәре, «Саулык» даруханәсе, «Хөррият» даруханәсе, «Шәфкать» хәйрия җәмгыяте, «Казаныш» икенчел чималны эшкәртү оешмасы, «Гармония» медицина диагностикасы үзәге, «Тылсым» кием-салым тегү оешмасы, «Намус» автомәктәбе* һ.б.

Татар эргонимиясе үзенең үзенчәлекле, бай булуы белән аерылып тора. Оешма-учреждение атамаларының авторлары күптөрле принциплардан чыгып эш итәләр. Кайбер эргонимнарда оешма-предприятиенең эшчәнлеге тулысынча чагылыш таба, кайбер эргонимнарны, оешманы эшчәнлеге белән генә түгел, хезмәт күрсәтү төре, товар ассортименты белән дә бәйләп булмый. Номинатор кибеткә яисә оешмага образлы күзаллау нигезендә генә дә исем бирергә яки матур яңгырашка ия сүзне эргоним итеп кулланырга да мөмкин. Шуңа күрә атама ролендә кулланылган сүзләрнең гаять чуар булуы күренә. Эргонимнарның лексик-тематик төркемнәрендә бу бик тулы чагылыш таба.

## § 37. Татар эргонимнары төзелеш-ясалышында төп үзенчәлекләр

Татар эргонимнары, башка төр ономастик берәмлекләргә хас төзелеш-ясалыш принциплары нигиезендә барлыкка киләләр. Н.В. Подольская хезмәтләрендә ялгызлык исемнәренең сүзьясалыш үзенчәлекләре ике төп төркемгә – семантик һәм грамматик төрләргә аерып бирелә (Подольская, 1990: 43). Эргонимнарның сүзьясалыш үзенчәлекләрен тикшергән башка хезмәтләр белән

чагыштырганда, Н.В. Подольская бүленеше төгәл ачыкланган һәм бәхәс уятмый торган бүленешләрдән санала. Татар эргонимнарының да ясалышын Н.В. Подольскаяның әлеге төркемләвенә нигезләнеп һәм татар теленең сүзьясалыш үзенчәлекләрен дә исәпкә алып, *семантик* һәм *грамматик* онимлашуга бүлеп карарга кирәк.

Семантик ысул. Бу очракта тел берәмлекләре әзер килеш эргонимга күчә. Семантик ысул нигезендә ясалган татар эргонимнарын берничә төргә бүленә:

*Лексик-семантик ысул.* Бу очракта сүзнең киңәюе нәтиҗәсендә бер үк сүз төркеме эчендә яңа сүз барлыкка килә. Үз чиратында бу ысул белән ясалган татар эргонимнары түбәндәге төрләргә аерыла:

1) метонимик онимлашу эргонимик системада киң таралган ысул санала. Татар тел белемендә бу термин, иң элек, Х.Р. Курбатов, В.Х. Хаков хезмәтләрендә чагылыш таба. Тел белемендә кулланылышта йөргән традицион билгеләмәдә: «Предметның үзен әйтү урынына аның берәр билгесен белдерү, яисә аны ачыклап килгән сүзне генә атау» диелә (Хаков, 1999: 60). Г.И. Берестнев үзенең когнитив семантика буенча язылган хезмәтләрендә метонимиянең ике төрен аерып күрсәтә: а) когнитив метонимия (образлы фикерләү); ә) тел метонимиясе (атау) (Берестнев, 2005: 123–124).

Эргонимик лексика тел метонимиясе нигезендә барлыкка килә. Исем сайлаганда метонимик күчешкә таянучы авторлар, гадәттә, объект белән аның исеме арасында ниндидер бәйләнеш булдырырга, кулланучыга тиз аңлашыла торган исемнәр бирергә тырышалар. Мәсәлән: *«Ак теш» стоматология хезмәте күрсәтүче оешма, «Ак таш» юл плиткасы җәя торган оешма, «Барс Авто» автомобильләр сату салоны* һ.б.

*«Өчпочмак» кафесы, «Икмәк» кибете, «Сөт» кибете, «Хәләл ит» кибете, «Катык» кулинария кибетләр челтәре* һ.б. эргонимнарда тәкъдим ителә торган продукция эргонимда тулысынча яисә өлешчә чагылыш таба.

Шулай ук метонимик онимлашу нигезендә ясалган эргонимнарда товарның, хезмәт күрсәтүнең субъекты яисә адресаты чагылыш табарга мөмкин. Мәсәлә: *«Юрист», «Бакчачы», «Ветеран»* кибетләре, *«Тәмле тамак»* кафесы.

Метонимик онимлашуның беренчел образ нигезендә ясалган төрен балалар бакчалары, балалар кирәк-ярагын сата торган

кибетләр, балалар кафелары һ.б. атамаларында очрый (Носенко, 2007: 75). Мәсәлән: *«Әкият», «Ромашка» исемендәге балалар бакчалары, «Кояш», «Җиләк», «Алма» кибетләренең* атамалары шундыйлардан;

2) метафорик онимлашу. Татар теле белемендә метафорага мондый билгеләмә бирелә: «Метафора (грек. *metaphora* – күчеш) бер предмет атамасын билгеле бер төс, форма, урнашуы һ.б. ягыннан охшашлык нигезендә икенче бер предметка күчерү дигәнне аңлата» (Татар лексикологиясе, т. 1, 2015: 109).

Соңгы елларда метафора, стилистик чара булудан бигрәк, когнитив лингвистика кысаларында тикшерелә (Арутюнова, 1990: 5–32; Караулов, 1987: 68; Кубрякова, 1987: 93–94 һ.б.). Кеше метафораны үзенең уй-фикерләрен җиткерүдә генә кулланып калмый, ә алар ярдәмендә уйлый, дөньяны танып белә. Эргоним-метафора клиентны уйларга, төрле күренешләрне каршы куеп, чагыштырып карарга, уртак һәм аермалы якларын табарга, нәтиҗәдә шушы атама белән килешергә я килешмәскә этәрә, чөнки, галимнәр фикеренчә, метафорик күчеш нигезендә эргонимнар ясалганда, метафораның мәгълүмати, эмоциональ-бәяләү функцияләре кулланыла һәм бу үзенчәлек, үз чиратында, клиентның, сатып алучының күзаллауларына тәэсир итә. Мәсәлән: *«Тулпар» авиаоешмасы*. Алда әйтелгәнчә, татар халкының тормышы элек-электән атлар белән бәйле, аннары тулпар тизлек символы да булып тора. Газ үткәрү кирәк-ярагын сата торган кибетнең *«Ялкын»* дип аталуы да бик урынлы. *«Сыйфат»* эргонимына ия кунакханә исә күз алдына югары дәрәҗәдә хезмәт күрсәтелә, клиентта ышаныч тудыра торган оешма буларак килеп баса. *«Рухият» нәшрияты* да татар кешесе аңында мәдәният, татар рухы белән бәйле күзаллауларга барып тоташа;

3) метафорик-метонимик онимлашу юлы белән ясалган эргонимның мәгънәсендә метафора һәм метонимия берләшә. Мәсәлән: *«Ак йорт» төзелеш оешмасының* атамасында *ак* сыйфаты эргонимның мәгънәсен тагын да киңәйтеп, образлырак итә. *Ак* сыйфаты татар кешесе өчен аклык-сафлык билгесе булып йөри. Ханлыклар чорында билгеле бер статуска ия кешеләр ак йортларда яшәгәннәр. Бу аларның бай, затлы нәселдән булуы турында сөйләгән. Димәк, әлеге эргоним бу оешманың югары сыйфатлы йортлар төзүенә ишарә итә.

*«Ханбикә» матурлык салонының* атамасы мәгънәсендә метафора һәм метонимия берләшә. Салонның хатын-кызларга юллануы метонимиягә ишәрә булса, хатын-кызларны ханбикәләр кебек затлы, чибәр итү максатыннан бар нәрсә дә эшләнүе хакында сөйләве метафора икәнен күрсәтә.

Метафорик-метонимик онимлашу юлы белән ясалган эргонимга *«Сердәш» яшьләргә һәм балаларга психологик-педагогик ярдәм күрсәтү оешмасы* атамасы да керә. Яшьләр, яшүсмерләр һәм балалар өчен психологик ярдәм даими кирәк. Шуңа да яшьләргә һәм балаларга психологик-педагогик ярдәм күрсәтү оешмасының «Сердәш» дип аталуы һич гаҗәп түгел, киресенчә, исеме җисеменә якын килә һәм клиентта оешмага карата ышаныч уята.

*Башка төр ялгызлык исемнең эргонимга күчүе, ягъни трансонимлашу ысулы* белән ясалган эргонимнар түбәндәге төркемнәргә бүленә:

1. *Антропонимнан эргоним ясалу* төренә кеше исемнәре, фамилияләре, мифонимнар, әдәби геройлар, тарихи шәхесләр, күренекле кешеләрнең исемнәреннән эргонимнар ясалу кертелә.Мәсәлән: *«Рәйхан» автомобильләр сервисы, «Лилия» чәчтарашханәсе, «Хуҗа Насретдин» кафесы, «Наполеон» фирмасы, «Авиценна» медицина үзәге, «Алмаз» туристлык агентлыгы, «Арслан» кибете* һ.б.

2. *Топонимнан эргоним ясалу* ысулы берничә төргә бүленә:

а) годонимнан, ягъни шәһәрнең проспект, урам, тыкрык, бульвар атамаларыннан (*«Бистә» азык-төлек кибете, «Тукай» автомобильләр сервизы* һ.б.);

ә) гидронимнан (*«Аккош күле» ял итү үзәге, «Черек күл» ял итү паркы, «Шушма» рестораны* һ.б.);

б) микротопонимнан (*«Татарстан» кунакханәсе, «Биләр» рестораны* һ.б.) эргонимнар барлыкка килү.

3. *Астроним һәм космонимга нигезләнеп яңа эргонимнар* ясалу. Мәсәлән: *«Йолдыз» бар-кафесы, «Ай» кибете, «Юпитер» күчемсез милек агентлыгы* һ.б.

Трансонимлашу ярдәмендә эргонимнар ясалышы да ике төргә – *гади* һәм *метафорик* төркемнәргә бүлеп карала. Гади трансонимлашу ул метонимик трансонимлашу. Мәсәлән: *«Казан» кунакханәсе, «Әлфия» рестораны* һ.б.

Метафорик трансонимлашу дигәндә, аллюзив (аллюзия – сәнгатькә, әдәби әсәрләргә ишарә итү) метафора нигезендә

аллюзив эргонимнар барлыкка килү күз алдында тотыла. Әмма фактик материалдан күренгәнчә, безнең очракта эргонимнарда метафора белән метонимия синкретизмы урын ала, ягъни атамада предприятиенең ниндидер бер сыйфаты да чагылыш таба. Мәсәлән: *«Батыр» татарча көрәш буенча спорт үзәге, «Чебурашка» азык-төлек кибете* һ.б. Мисаллардан күренгәчә, әлеге эргонимнарда әкият геройлары исемнәре чагылыш тапса да, алар балалар иҗаты белән шөгыльләнә, яисә балалар кирәк-ярагын сата торган оешма-кибетләр түгел. Бу – аллюзив эргонимнарны башка эргонимнардан аера торган төп үзенчәлек.

Татар эргонимнарының грамматик онимлашу нигезендә ясалышы синтаксик, лексик-грамматик һәм сүз-тезмәләр лексикалашу ысулларына бүленә.

1. *Эргонимнарның синтаксик ысул, ягъни сүз кушылу ысулы белән ясалышы.* Сүзләр кушылып ясалган эргонимнар дигәндә, галимнәр тезмә, кушма һәм аббревиатур эргонимнарны күз алдында тоталар (Носенко, 2007: 88).

Татар теле белемендә галимнәр сүзләр кушу, ягъни синтаксик ысул белән *кушма, тезмә, парлы* һәм *кыскартылма* сүзләр ясалуын ассызыклыйлар (Ганиев, 2005: 40–48; Хисамова, 2006: 36):

1) кушма эргонимнар. Кушма эргонимнарның төп өлеше морфема-префикс ялгану нигезендә ясалган. Иң актив морфема-префиксларга *авто-, авиа-, агро-, видео-, евро-* кебек алынма берәмлекләрне китерергә мөмкин. Мәсәлән: *«Автомаркет», «Автокомфорт» кибетләре; «Автобюро», «Автоконфискат» автосалоннары; «Автоклуб» клубы; «Автомакияж» оешмалары* һ.б.; *«Авиагаз», «Авиамотор» оешмалары; «Авиатор» кунакханәсе* һ.б.

Кайбер очракларда өч компонент кушылу нигезендә ясалган эргонимнар да күзәтелә: *«Элитмоторосгрупп» оешмасы, «Автоспорттюнинг» агентлыгы, «Growmединфосервис» оешмасы* һ.б. Ике компонентлы кушма сүзләр дә, өч компоненттан торганнары да, нигездә, рус һәм Европа телләреннән кергән алынма сүзләргә нигезләнеп ясала;

2) парлы эргонимнар. Парлы эргонимнар дигәндә, үзара тезүле юл белән бәйләнгән, тигез хокуклы булган ике компоненттан торган атамалар күздә тотыла (Ганиев, 2010: 480). Парлы эргонимнарның бер төркеме үзара синоним булган компонентлар ярдәмендә оешкан: *«Караван-сарай» кибете, «Аракы – шәраб» кибете* һ.б.

Кайбер очракта икенче компонент оешманың шөгыленә, хезмәт күрсәтү төренә ишарә итәргә мөмкин. Мәсәлән: *«Элемтә-инвест» инвестиция компаниясе, «Алан-аш» кафесы, «Нур-медиа» студиясе* һ.б.

Әлеге төр кушма эргонимнарның кайберләре ялгызлык исем катнашында да ясала: *«Айназ-сервис» оешмасы, «Болгар-Арыш» авыл хуҗалыгы оешмасы, «Идел-пресс» типографиясе*, *«Булгар-синтез» полиэтилен җитештерү оешмасы*, *«Мәгариф-Тур» туристлык агентлыгы, «Барс-Авто» автомобиль салоны* һ.б.;

3) тезмә эргонимнар. Кагыйдә буларак тезмә сүзләр, гадәттә, ирекле сүзтезмәләр калыбы буенча ясала (Ганиев, 2005: 47; Хисамова, 2006: 111). Бу үзенчәлек шулай ук эргонимнарда да чагылыш таба. Тезмә эргонимнарның төрләре түбәндәгеләр:

а) сыйфат + исем калыбында ясалган тезмә исемнәр: *«Бай альянс», «Яшь көч», «Яңа бистә», «Аяз күк», «Юмарт абзый»* һ.б. Бу төр тезмә кушма эргонимнар ясауда аеруча *ак, кара, алтын* кебек сыйфатлар өстенлек итә: *«Ак Байтал», «Ак бит», «Ак бүре», «Кара Алтын», «Кара йолдыз», «Алтын тал», «Алтын ай», «Алтын иген»* һ.б.;

ә) II төр изафә бәйләнеше нигезендә ясалган тезмә исемнәр: *«Арыш мае», «Төньяк балкышы», «Өмет утлары», «Татар радиосы», «Курай радиосы», «Кояш нуры»* һ.б.;

4) кыскартылма (аббревиатур) эргонимнар. Татар теле белемендә аббревиация ысулы галимнәр тарафыннан сүзләр ясалуның бер чарасы буларак карала (Ганиев, 2005: 47). Чыннан да, аббревиация эргонимнар ясалышында мөстәкыйль чара буларак кулланыла. Аббревиация ысулы нигезендә ясалган эргонимнарның төрләре түбәндәгеләр:

а) хәреф аббревиатуралары: *«КФУ» (Казан федераль университеты), «ЧМУ» (Чистай медицина училищесы), «МПК» (Минзәлә педагогия көллияте)* һ.б.;

ә) иҗектән торган кыскартылма эргонимнар: *«Татком» төзелеш оешмасы, «ТатХимПрод» оешмасы, «Таттехмедфарм» оешмасы* һ.б.;

б) катнаш тип: сүзләрнең беренче иҗекләреннән һәм беренче хәрефләреннән торган эргонимнар: *«Радим» (Радик + Марат), «РифЭль» (Риф + Эльвира), «ЛиЛу» (Лилия + Луиза) кибетләре* һ.б.; беренче сүзнең беренче иҗегеннән, икенче сүз тулысын-

ча кергән эргонимнар: *«Татпроект» оешмасы, «Татнефть» компаниясе, «Казиндустрия» оешмасы* һ.б.

2. *Эргонимнарның лексик-грамматик ысул белән ясалышы.* Лексик-грамматик ысул белән сүз ясалышы татар телендә шактый киң таралган. Галимнәр бу ысул белән сүз ясалышын түбәндәгечә билгелиләр: «Саф яки грамматик формантлар алган нигезләрнең башка сүз төркеменә күчү юлы белән яңа сүзләр ясалу лексик-грамматик ысулны тәшкил итә» (Ганиев, 1998: 224). Татар тел белемендә әлеге чараны атау өчен морфологик-синтаксик ысул дигән термин да кулланыла: «Бер сүз төркеменең нигез хәлдә яки нинди дә булса грамматик формада икенче сүз төркеменә күчүе морфологик-синтаксик ысул белән сүз ясалышы дип атала» (Хисамова, 2006: 44).

Лексик-грамматик ысул белән ясалган эргонимнарның түбәндәге төрләрен күрсәтергә мөмкин:

1) сыйфаттан исемгә күчеп субстантивацияләшеп барлыкка килгән эргонимнар: *«Бәхетле» сәүдә челтәре, «Тәмле» кондитер оешмасы, «Татлы» кибете, «Бай» видеостудиясе, «Милли» кафесы* һ.б.

2) рәвештән исемгә күчеп субстантивацияләшеп барлыкка килгән эргонимнар: *«Алга» дизайн-студиясе, «Югарыда» кафесы* һ.б.

3. *Эргонимнарның сүзтезмәләр лексикалашу ысулы ярдәмендә ясалышы.*

Оешма атамалары, аеруча дәүләт төзелешенә караган атамалар арасында да әлеге юл белән ясалган эргонимнар шактый еш очрый (Ганиев, 1998: 307; Тимерханов, 2005: 157–160). Мондый эргонимнарда, гадәттә, компонентлар саны чагыштырмача күп була, әмма барлык компонентлар да ияртүче сүзгә бәйлелеген саклый. Мәсәлән: *дәүләт советы – дәүләт советы комиссиясе, хокук идарәсе – хокук идарәсе бүлекчәсе* һ.б. Арада бик күп компонентлардан торган эргонимнар да очрый. Аларда төп сүзгә бәйлелек саклана: *Җәмәгатьчелек белән элемтә һәм милләтара мөнәсәбәтләр бүлеге, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре даими комиссиясе* һ.б. Мисаллардан күренгәнчә, әлеге төр тезмә эргонимнар бюджет оешмаларының атамаларында күзәтелә. Коммерция оешмаларның исемнәре бер-ике, сирәк кенә өч компоненттан тора.

Иң беренчеләрдән булып, атрибутив һәм комплетив төрләргә караган сүзтезмәләрнең лексикалашуы күзәтелә. Биредә татар теленең үз сүзләре дә, гарәп-фарсы һәм рус теле аша Европа телләреннән кергән алынма берәмлекләр дә актив катнаша. Мәсәлән: *Нотариаль контора, Федераль җыен, Структур бүлекчә, Даими комиссия* һ.б. Сүзтезмәләр лексикалашу ысулы ярдәмендә ясалган эргонимнар арасында «исем + тартым категориясендәге исем» төре буенча барлыкка килгәннәре актив кулланыла: *Мәгариф учреждениесе, Казначылык департаменты, Дәүләт Советы, Министрлар кабинеты, Президент аппараты, Матбугат үзәге, Иминлек хезмәте* һ.б.

Шулай ук өч лексик берәмлектән торган эргонимнар да чагыштырмача еш очрый. Алар гадәттә «исем + III зат тартым категориясендәге исем + III зат тартым категориясендәге исем» төре нигезендә ясалалар. Мәсәлән: *Дәүләт иминлеге комитеты, Дәүләт идарәсе органы, Һөнәр берлеге комитеты, Хокук идарәсе бүлекчәсе* һ.б.

Сүзтезмәләр лексикалашу ысулы ярдәмендә барлыкка килгән эргонимнарның бер төркеме «сыйфат + исем + III зат тартым категориясендәге исем» төре нигезендә ясалган. Мәсәлән: *Кыйммәтле кәгазьләр базары, Социаль тәэминат министрлыгы, Матди ярдәм бүлекчәсе* һ.б.

III төр изафә формасы нигезендә ясалган эргонимнар да чагыштырмача еш күзәтелә, ләкин алар күпчелек очракта сыйфат һәм исем сүз төркемнәренә караган лексик берәмлекләр белән катлауландырылган булалар. Шуңа да карамастан, аларда мәгънә бөтенлеге саклана. Мәсәлән: *Судның күчмә сессиясе, Контроль-ревизия идарәсенең баш контролер-ревизоры аппараты, Дәүләт Советының закон чыгару комитеты, Хуҗалык хезмәте күрсәтү предприятиесенең тәэминат бүлекчәсе* һ.б.

Ономатолог галимнәрдән Н.В. Носенко тезмә онимнар рәтенә кертеп карала торган тагын бер төрле эргонимнарны аерып карый (Носенко, 2007: 219). Боларга *«Булат позис» сакчыллык оешмасы, «Айнур и К» төзелеш оешмасы* кебек атамалар кертелә.

Сүзтезмәләр лексикалашу нигезендә ясалган эргонимнар дәүләт төзелешенә караган оешмаларның атамалары буларак шактый актив кулланыла. Шунлыктан бу ысул эргонимнар ясалышы да чагыштырмача продуктив санала.

Шулай итеп, татар телендә кулланыла торган эргонимнарның ясалышында төрле ысуллар һәм чаралар катнаша, төрле чыганакларга караган тел берәмлекләренең бер эргоним составында килүе белән алар татар теленең сүз ясалыш мөмкинлекләрен киңәйтәләр.

## § 38. Татар эргонимнарының орфографиясе һәм транслитерация мәсьәләсе

Татар җәмгыяте XX гасыр ахыры – XXI гасыр башларында көчле икътисади үсеш чоры кичерә. Илдә барган иҗтимагый-икътисади үзгәрешләр эргонимнар формалашу, барлыкка килү яисә юкка чыгу процессына да тәэсир итә. 1992 елда «Татарстан халыклары телләре турында»гы Закон кабул ителә, 1994 елда аны гамәлгә ашыру буенча дәүләт программасы раслана. Бу процесслар эргонимикада да чагылыш таба: бик күп яңа атамалар уйлап табу, булганнарын тәрҗемә итү мәсьәләсе күтәрелә.

Икетеллелек турындагы канунның таләпләрен тормышка ашыру максатыннан, татар теленең лексик байлыгы яңа сүзләр, яңа терминнарга байый һәм аларның күбесе эргонимнар составына килеп керә. Байтак кына лексик берәмлекләр яңа мәгънә алып кулланыла башлый. Мәсәлән, *Дәүләт Думасы, Аксакаллар шурасы, Корылтай* кебек эргонимнар шушы сүзләрнең яңа сәяси мәгънә алулары нигезендә барлыкка килә. *«Иттифак» милли бәйсезлек партиясе, «Ислам» партиясе, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе, «Азатлык» радиостанциясе, Татар иҗтимагый үзәге* кебек эргонимнар шушы яңарыш чорында атама буларак кулланылышка кереп китә.

Татар теленең дәүләт теле дәрәҗәсенә күтәрелүе нәтиҗәсендә, моңа кадәр бернинди каршылыксыз кулланыла торган байтак кына сүзләр эргонимнар составында үзләренең татарча парлары белән алмашына: *санаторий – шифаханә, больница – хастаханә, аптека – даруханә, столовая – ашханә, администрация – хакимият, делегация – вәкиллек, коммерция – сәүдә, колледж – көллият, страхование – иминият, культура – мәдәният, класс – сыйныф, студент – талиб, врач – табиб* һ.б. Мәсәлән, *«Сәламәт» даруханәсе, Республика клиник хастаханәсе, «Ак Барс Мед» иминият компаниясе* һ.б.

XX гасыр башында актив кулланылып, телдән төшеп калган һәм бүгенге көндә кабат кулланылышка кертелгән бу төр лексик

берәмлекләрне – фәндә «кире кайтарылган» лексика дип атау кабул ителгән (Тимерханов 2005: 165). Әлеге мәсьәләне өйрәнүгә И.М. Низамов, М.З. Зәкиев, Ф.Ә. Ганиев, Ф.М. Хисамова, Ф.С. Сафиуллина, Г.Ф. Саттаров, Р.Г. Йосыпов, М.Б. Хәйруллин һ.б. хезмәтләрендә шактый киң урын бирелә. Татар эргонимнарында яңадан кулланыла башлаган лексик берәмлекләрнең түбәндәге төрләрен күрсәтергә мөмкин:

а) фән, мәгариф, мәдәният белән бәйле төшенчәләрне атаган лексика: *мәдәният, мәгариф, мәгърифәт, көллият, мәдрәсә, мөхәррир, нәшрият* һ.б.;

ә) дәүләт төзелеше, идарә итү эшләре, сәүдә белән бәйле лексика: *вәкаләт, идарә, хакимият, ширкәт, фирка, хөкүмәт, җәмгыять, сыйныф, фәрман, рәис, милек, ришвәт, мөсафир, мөсафирханә, кәрван, вәкил, инкыйлаб* һ.б.;

б) медицина, хәрби, хокук төшенчәләрен белдерүче лексика: *табип, хаким, хөкем, хокук, солых* һ.б.;

в) дини лексика: *гыйбадәтханә, диния нәзарәте, хәйрия, мәхәллә, хаҗ* һ.б.

Кушымчалар, яисә мөстәкыйль лексик берәмлекләр ялгану юлы белән барлыкка килгән яңа сүзләр дә эргонимнар составына кереп китә. Мәсәлән, *-и/-ый* кушымчалары *дәүләти, икътисадый, иҗтимагый, мәдәни, сәяси, хосусый, җинаяти* һ.б. сүзләр составында урын ала һәм яңа эргонимнар барлыкка китерүгә хезмәт итә: *«Россиянең татар авыллары» бөтенроссия иҗтимагый оешмасы, «Сиони» грузин милли-мәдәни автономиясе.*

Эргонимнар арасында *-ханә* компоненты катнашында ясалган атамалар активлаша: *чәчтарашханә, гыйбадәтханә, чәркәханә, шәрабханә, хастаханә* һ.б.: *«Татарстан» кунакханәсе, «Май» чәчтарашханәсе, «Галәм» гыйбадәтханәсе.* Арада актив кулланылышка кереп китә алмаган сүзләр дә бар: *саклауханә (склад), тамгаханә (таможня), эшханә (предприятие)* һ.б. Кайбер очракта *-ханә* компоненты мөстәкыйль сүз буларак та кулланыла*: оста ханәсе, сәнгать ханәсе, кер юу ханәсе, җәмәгать кабул итү ханәсе* һ.б. Дөрес, галимнәр фикеренчә, *-ханә* компонентын, мөстәкыйль сүз булудан бигрәк, сүз ясалышында актив катнаша торган чара буларак кабул итү фәнни яктан дөресрәк санала (Тимерханов, 2005: 172).

Кире кайтарылган лексика арасында рус һәм Европа алынмалары да бар. Кайчандыр архаизмнар буларак кабул ителгән *дума,*

*коллегия, департамент, губерна, юстиция, палата, миграция* һ.б. лексик берәмлекләр бүген дәүләт, хөкүмәт оешмалары белән бәйле эргонимнар составында шактый еш очрый: *Дәүләт Думасы, Татарстан Республикасы судьяларының квалификация коллегиясе, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы дәүләт хезмәткәрләре эшләре департаменты, Татарстан Республикасы Теркәү палатасы, Татарстан Республикасы Федераль миграция хезмәте идарәсе, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы* һ.б.

«Татарстан Республикасы халыклары телләре турында»гы закон кабул ителгәннән соң, оешма атамаларының ике телдә дә язылуы катгый таләп ителә башлады. Бу күренеш бюджет оешмаларының атамаларында аеруча ачык чагылыш таба. Әлеге төр эргонимнарда, кагыйдә буларак, ике компонент та күпчелек очракта татарчага тәрҗемә ителә, татар телендә языла, яисә денотат гомум кулланылышта йөри торган халыкара сүз белән бирелә. Шунысын да искәртергә кирәк, татарча эргонимнарда беренче компонент, ягъни аерып атаучы компонент, еш кына, денотатны ачыклап килә, ә денонат, кагыйдә буларак, тартым кушымчасы ала, мәсәлән: *Сәламәтләндерү һәм спорт үзәге, Татарстан Республикасы Татарстан халыклары ассамблеясы, Марсель Сәлимҗанов исемендәге актерлар йорты, Республика балалар китапханәсе, Татарстан китап нәшрияты, Татарстан Республикасы Мәгариф министрлыгы, Казан шәһәре Идел буе районы мәгариф бүлеге*, *Балалар һәм яшьләр иҗат үзәге, Татарстан Республикасы Дәүләт музее* һ.б.

Коммерция оешмаларының атамаларында ике компонентның да татар телендә булуы чагыштырмача сирәк күзәтелә. Кайбер очракта беренче кисәге, ягъни ялгызлык исеме татарча булып та, денотат русча бирелергә мөмкин. Мәсәлән: *«Кояш» фирменный магазин, «Акташ» продукты, «Саулык» аптека, сеть кафе «Алан аш», «Катык» сеть магазинов кулинарии, кафе «Сөембикә», «Файда» сеть магазинов* һ.б.

Эргонимнар – телнең, аның сүзлек байлыгының җәмгыять тормышына турыдан-туры бәйле булган, шуңа күрә дә даими үзгәреп, камилләшеп бара торган өлкәсе. Җәмгыятьтәге икътисади, фәнни-техник, сәяси, иҗтимагый яңалык-үзгәрешләр нәтиҗәсендә яңадан-яңа оешмалар, шул нигездә яңа эргонимнар барлыкка килә. Эргонимнарда, аеруча татар телендәге атамаларда икетеллелек,

аерып әйткәндә, механик рәвештә сүздән-сүзгә тәрҗемә итү, кальканаштыру белән бәйле байтак кына хаталар күзәтелә.

Атамаларда түбәндәге төгәлсезлекләрне күзәтергә мөмкин:

1. Орфографик хаталар. Элмә такталарда татар теленең үзенчәлекле хәрефләрен хаталы язу очраклары шактый күп. Татар алфавитында, рус алфавитыннан аермалы буларак, татар теленә генә хас алты хәреф бар: *ә, ө, ү, җ, ң, һ*. Русчадан татарчага тәрҗемә иткәндә, бу хәрефләрне, еш кына, рус хәрефләре белән алыштыралар:

а) рус теленнән аермалы буларак, татар теленә генә хас *ә* хәрефенең *а, е* яисә э хәрефләре белән язылуын күрсәтергә мөмкин. Мәсәлән: *Татарстан Республикасында Федераль Миграция хезм**э**те идар**э**се Казан ш**э**һ**э**ренд**э**ге бүлегене**н** Авиат**о**зелеш районындагы бүлекч**э**се.* Дөрес варианты – *Татарстан Республикасындагы Федераль Миграция хезмәте идарәсе Казан шәһәрендәге бүлегенең Авиатөзелеш районындагы бүлекчәсе; Россия Федерациясенең С**э**л**ә**м**э**тлек саклау һ**е**м медицина промышленносте министрлыгы.* Дөрес варианты – *Россия Федерациясенең Сәламәтлек саклау һәм медицина промышленносте министрлыгы*; *«Айсберг» иҗтимагый-әхлакый үз**е**ге*. Дөрес варианты – *«Айсберг» иҗтимагый-әхлакый үзәге; Кулинария «Мил**э**ш».* Дөрес варианты – *«Миләш» кулинариясе; ООО «Р**э**йхан».* Дөрес варианты – *«Рәйхан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте; «Ад**э**м» кием-салым кибете.* Дөрес варианты – *«Адәм» кием-салым кибете* һ.б.

Күпчелек очракта ***ә*** хәрефе урынына башка сузык авазларны язу белән бәйле хаталар татар әдәби һәм сөйләм телендә ныклап үзләшкән гарәп-фарсы алынмалары язылышында китә. Мондый хата-төгәлсезлекләр сингармонизм законына буйсынмаган сүзләрдә күренә: *Россия Федерациясе М**а**гариф һәм фән министрлыгы «ТИСБИ» ид**ә**р**ә** академиясе.* Дөрес варианты – *Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы «ТИСБИ» идарә академиясе; «С**э**лам**э**тлек» даруханәсе.* Дөрес варианты – *«Сәламәтлек» даруханәсе; «Ш**а**рык» кибете*. Дөрес варианты – *«Шәрык» кибете* һ.б.

Аеруча *-ханә* лексемасының язылышы күпчелек очракта хата белән бирелә: *дарух**ә**нә – даруханә, ч**а**йхан**а** – чәйханә, ашхан**э** - ашханә* һ.б.

Киресенчә, *а* авазы урынына *ә* язылу да күзәтелә: *Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты ГХАТ идарәсе мәгълүм**ә**т*

*һәм документ биру бүлеге*. Дөрес варианты – *Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты ГХАТ идарәсе мәгълүмат һәм документ биру бүлеге;*

ә) татар теленә хас иренләшкән *ү* авазының *у* хәрефе белән бирелүе: *Социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча д*ә***у***ләт учреждениесе региональ б***у***леге*. Дөрес варианты – *Социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча дәүләт учреждениесе региональ бүлеге; Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы Казан шәһәре хакимияте мәгариф идарәсе Совет районы мәгариф б***у***леге 11 нче татар гимназиясе*. Дөрес варианты – *Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы Казан шәһәре хакимияте мәгариф идарәсе Совет районы мәгариф бүлеге 11 нче татар гимназиясе; С*ә***у***дә йорты «Корзинка»*. Дөрес варианты – *«Корзинка» сәүдә йорты; «Ак б***у***ре» спорт комплексы*. Дөрес варианты – *«Ак бүре» спорт комплексы; «Аяз к***у***к» кафесы*. Дөрес варианты – *«Аяз күк» кафесы; «***Саудагер***»* сәүдә комплексы. Дөрес варианты – *«Сәүдәгәр»* сәүдә комплексы һ.б.

Атна көннәрен күрсәткәндә татар телендә кулланылышта йөри торган сузык авазлар урынына рус хәрефләрен язу*: д***у***ш***э***мбе, п***э***н***җи***шембе, шимб***е***, якш***е***мбе яисә дүш***э***мб***э***, сиш***э***мбе, ч***э***рш***э***мбе, п***э***нҗеш***э***мбе,* ***ж****омга, шимб***э**. Дөрес варианты – *дүшәмбе, сишәмбе, чәршәмбе, пәнҗешәмбе, җомга, шимбә, якшәмбе;*

б) татар теленә хас иренләшкән *ө* авазының *о*, хәтта *ә* белән бирелеше шулай ук зур хаталардан санала: *«Т***о***ньяк балкышы» сәүдә ноктасы*. Дөрес варианты – *«Төньяк балкышы» сәүдә ноктасы; «Айг***ә***ль» кибете*. Дөрес варианты – *«Айгөл» кибете* һ.б.;

в) тартык авазларны белдергән хәрефләргә бәйле төгәлсезлекләр дә татар сүзләрен аңламау, аларның язылыш кагыйдәләрен белмәү нигезендә яисә игътибарсызлык аркасында килеп чыга. Мәсәлән: *«Эн***ж***е» кибете*. Дөрес варианты – *«Энҗе» кибете; «Я***н***а бистә» кибете*. Дөрес варианты – *«Яңа бистә» кибете* һ.б.;

г) алынма сүзләрнең кушымчаларында хаталар китү: *Татарстан Республикасының Казан шәһәре Вахитов район***е** *буенча Россия Федерациясе пенсия фондының идарәсе*. Дөрес вариант – *Россия Федерациясе пенсия фондының Татарстан Республикасының Казан шәһәре Вахитов районындагы идарәсе;*

д) график принципның бозылуы: *Татарстан Республикасы «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Җир*

*һәм милек мөнәсәбәтләре комитеты» муниципаль учреждени**я**се.* Дөрес варианты – *Татарстан Республикасы «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Җир һәм милек мөнәсәбәтләре комитеты» муниципаль учреждениесе; «Элеком» предприяти**я**се.* Дөрес варианты – *«Элеком» предприятиесе; «Татинвест» предприяти**я**се*. Дөрес варианты – *«Татинвест» предприятиесе* һ.б.;

е) саннарның язылышы белән бәйле хаталар. Татар тел белемендә саннар һәм алар янында килгән кушымчаларның язылышын тарихи-традицион принципка нигезләнеп аңлаталар: «Тарихи-традицион принципның саклануын цифрлар, төрле шартлы билгеләр соңында килгән кушымчаларның сызыкча аша түгел, бәлки аерым язылуында, ул кагыйдәнең гарәп имлясыннан алып, яңалиф орфографиясенә һәм аның аша рус графикасы нигезендәге яңа орфографиягә дә үтеп керүендә күрәбез: *6 шар алма, 18 нче йорт, 11 нән 15 нә кадәр* һ.б.» (Татар грамматикасы, т. 1, 2015: 74). Бу кагыйдә башка галимнәр таарафыннан да раслана: «Цифрлар белән күрсәтелгән саннарның дөрес язылышы» турындагы кагыйдәдә болай диелә: «Гарәп цифрлары тәртип саны кушымчасыннан беразаерыбрак языла: 5 нче сыйныф, 11 нче трамвай» (Сафиуллина, Зәкиев, 1994: 225).

Элмә такталарда *нчы, нче* кушымчалары күп төрле вариантта языла: *Казан шәһәре Авиатөзелеше районының **168нче** урта гомуми белем бирү мәктәбе*. Дөрес варианты – *Казан шәһәре Авиатөзелеше районының 168 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе; Сәламәтлек саклау муниципаль учреждениесе «**11нче** номерлы шәһәр шифаханәсе»*. Дөрес варианты – *Сәламәтлек саклау муниципаль учреждениесе «11 нче номерлы шәһәр шифаханәсе».*

2. Грамматик (морфологик) формалар бозылу. Эргонимнарда күзәтелгән бу төр ялгышларның күбесе ике тел белән эш итүче каләм ияләренең, татар һәм рус телләренең берәрсенә генә карый торган грамматик үзенчәлекләрне белеп, күреп бетермичә, рус теленә хас формаларны автоматик рәвештә туган телгә күчереп куюлары аркасында барлыкка килә (Юсупов, 1996: 73).

Грамматик формаларның бозылуы түбәндәге очракларда киң таралган:

а) килеш кушымчаларының дөрес тәрҗемә ителмәве, урынсыз кулланылуы: *Государственное образовательное учреждение дополнительного профессионального образования – Һөнәр буенча өстәмә*

*белем бирү**нең** дәүләт мәгариф учреждениесе*. Дөрес варианты – *Өстәмә һөнәри белем бирү (буенча) дәүләт мәгариф учреждениесе; Организатор пассажирских перевозок муниципальное унитарное предприятие – Пассажирлар**ны** йөртүне оештыручы муниципаль* ***унитар предприятиесе.*** Дөрес варианты – *Пассажирлар йөртүне оештыручы муниципаль унитар предприятие; Татарстан Республикасы Эчке эшләр идарәсе карамагын **дагы** Дербышки милиция бүлеге*. Дөрес варианты – *Татарстан Республикасы Эчке эшләр идарәсе карамагындагы Дербышки милиция бүлеге;*

ә) сыйфат ясаучы кушымчаларның дөрес кулланылмавы. Ф.Ә. Ганиев фикеренчә, татар телендә *-аль, -ль, -ив, -он, -ар, -ый, -и* һ.б. сыйфат ясаучы алынма кушымчалар бар. Ләкин, фактлар күрсәткәнчә, югарыда китерелгән кушымчалар татар теленең үз сүзләре нигезендә сыйфатлар ясамыйлар. Бу кушымчалар башка телләрдән үзләренең ясаучы нигезләре белән бергә алынганнар. Шул кушымчалар белән килгән барлык сыйфатлар чыганак телдә ул телнең сүзьясалыш закончалыклары нигезендә һәм структур үзенчәлекләренә нигезләнеп ясалганнар. Татар телендә ул алынма сыйфатларның кушымчалары я бөтенләй алып ташлана, я кыскартыла: *революционный – революцион, объективный – объектив, экспериментальный – эксперименталь* һ.б. (Татар грамматикасы, т. 1, 1998: 403). Бу эргонимнар өлкәсендә дә күзәтелә. Мәсәлән: *Республиканский центр молодежных, инновационных и профилактических программ Республика яшьләр инновацио**нн** һәм профилактик программалар үзәге*. Дөрес варианты – *Республика яшьләр инновацион һәм профилактик программалар үзәге; Казанский энергетический техникум – Казан энергети**к** техникумы*. Дөрес варианты – *Казан энергетика техникумы;*

б) хәл фигыль, сыйфат фигыль формаларының, фигыль юнәлешләренең дөрес тәрҗемә ителмәве: *Казан шәһәре Вахитов районы 82 нче номерлы аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнеп гомуми белем бирү мәктәбе* рәвешендә язылган элмә такталарны күзәтергә мөмкин. Мисалдан күренгәнчә, бу эргоним аңлаешсызлык тудыра. Беренчедән, *82 нче номерлы аерым фәннәр* дип аңларга урын калдырылган. Икенчедән, *өйрәнеп* фигыле дөрес формада кулланылмаган, чөнки бу сүзтезмәне *«мәктәп аерым фәннәрне башта үзе өйрәнә, аннары укучыга белем бирә»* мәгънәсендә дә аңларга мөмкин;

в) атамаларда эргонимның аерып атый торган компоненты белән денотат грамматик яктан үзара ярашмаган булырга мөмкин, ягъни денотат өлешендәге тартым кушымчасы төшереп калдырыла. Мәсәлән: *«Дус» кибет*. Дөрес варианты – *«Дус» кибете*; *«Биләр» ресторан.* Дөрес варианты – *«Биләр» рестораны; «Зәм-зәм» кафе.* Дөрес варинаты – *«Зәм-зәм» кафесы; «Әкият» кафе*. Дөрес варианты – *«Әкият» кафесы* һ.б.

3. Стилистик хаталар. Җөмләдә бертөрле сүзләрнең, охшаш сүзләрнең, шулай ук бертөрле кушымчаларның кабатланып килүен, кайбер сүзләрнең урынсызга кулланылуын һәм, киресенчә, интонациянең бөтенлеге, шомалыгы өчен кайбер әһәмиятле сүзләрнең җитмәвен, кайберләренең исә үз мәгънәсендә кулланылмавын, сөйләмдә сүзләрнең урнашу тәртибе бозылуын стилистик хаталарга кертеп карыйлар (Юсупов, 2008: 201). Атамаларда күзәтелә торган стилистик төгәлсезлекләрдән түбәндәгеләр күрсәтелә:

а) логик басымны дөрес күрсәтмәү, ягъни логик эзлеклелекнең юклыгы. Мәсәлән: *Главное управление федеральной регистрационной службы по Республике Татарстан.* Татарча тәрҗемәсендә логик эзлеклелек сакланмаган*: Татарстан Республикасы буенча федераль теркәү хезмәтенең баш идарәсе.* Дөрес варианты: *Федераль теркәү хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча баш идарәсе.*

Мондый төр төгәлсезлек *Сәүдә йорты «Корзинка», Минимаркет «Хәләл ризык», Сәүдә рәте «Анфилада», Ресторан «Катык»,* Кафе *«Юргак»* кебек эргонимнарда да күзәтелә;

ә) бер үк кушымчаның кабатланып кулланылуы: *Татарстан Республикасы**ның** Халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау минстрлыгы**ның** Казан шәһәре муниципаль учреждениесендәге социаль яклау идарәсе**нең** Авиатөзелеш районы социаль яклау бүлеге.* Дөрес варианты – *Татарстан Республикасы Халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы Казан шәһәре муниципаль учреждениесендәге социаль яклау идарәсенең Авиатөзелеш районы социаль яклау бүлеге;*

б) сүзләрнең синоним, антоним парларын дөрес сайламау: *Документларны **бирү** үзәге.* Дөрес варианты – *Документларны тапшыру үзәге; Татарстан Республикасының кулланучылар хокукларын **саклау** җәмгыяте.* Дөрес варианты – *Татарстан Республикасының кулланучылар хокукларын яклау җәмгыяте* һ.б.;

в) калькалаштыру: ***по – буенча*** тәңгәллекләре. Татар телендә *буенча* бәйлеге, еш кына, урынсыз кулланыла. Практикада *по – буенча* тәңгәллеге, тулаем әйткәндә, *по* предлогының татар теленә интерференциясе чагылыш таба (Юсупов, 2008: 169).

Безнең фикеребезчә, *по* предлогы, *буенча* бәйлегеннән тыш, күп төрле башка чаралар ярдәмендә дә белдерелә ала. Мәсәлән: *МЧС РТ Управление по делам ГО и ЧС г. Казани – Казан шәһәренең гражданлык оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр* ***буенча*** *идарәсе.* Кулайрак вариант – *Казан шәһәренең гражданлык оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр идарәсе;*

г) татар теленең үз сүзләрен кулланмыйча, рус сүзләреннән файдалану: *Республиканская стоматологическая поликлиника – Республика стоматология* ***поликлиникасы.*** Дөрес варианты – *Республика стоматология шифаханәсе; Центр занятости населения Приволжского района –* ***Приволжский*** *районының халыкны эш белән тәэмин итү үзәге*. Дөрес варианты – *Идел буе районының халыкны эш белән тәэмин итү үзәге;*

д) тәрҗемәнең тулы булмавы. Рус телендә конкрет мәгънәдәге бер генә лексик берәмлек белән белдерелә торган төшенчәләр татар телендә сүзтезмә яисә парлы сүзләр ярдәмендә бирелергә мөмкин (Юсупов, 2008: 78). Телләргә хас бу үзенчәлекне аңлап, тиешле дәрәҗәдә тәрҗемә итмәү стилистик хаталарга китерә. Мәсәлән: *Продукты – Азык.* Дөрес варинаты – *Ашамлыклар, яисә азык-төлек; Товары для дома – Йорт кирәге*. Дөрес варинты – *Йорт кирәк-яраклары, Фрукты – Җиләк.* Дөрес варинты – *Җиләк-җимеш* һ.б.

Шулай итеп, оешма атамаларында күзәтелә торган хаталарның төп өлеше дөрес тәрҗемә итмәү нәтиҗәсендә барлыкка килә. Тәрҗемәнең дөрес булмавы күпсанлы орфографик, грамматик һәм стилистик хаталарга китерә. Татар авазларының дөрес язылмавы, килеш кушымчаларының тиешенчә булмавы, җөмлә тәртибендә эзлеклелек югалу – оешма атамаларында иң күп очрый торган хаталардан санала.

## ТАТАР ЭТНОНИМИКАСЫ

### § 39. Этнонимика фәненә гомуми билгеләмә

Этноним – этник төркемнәр, кабилә, халык һәм аның аерым өлешләренең атамасы. Аларны өйрәнә торган ономастика тармагы этнонимика (борынгы грек телендә *εθνος* – халык, кабилә һәм *δνομα* – атама, исем) дип атала. Этнонимика фәне лингвистик, этнографик, тарихи тикшеренүләрдә гаять әһәмиятле роль уйный. Әлеге фәннең казанышлары атамаларның барлыкка килү тарихын өйрәнүдә, тел тарихының борынгы катламнарын торгызуда, этник төркемнәрнең, кабилә һәм халыкның үсеш тенденцияләрен, таралыш һәм миграцион күчешләрен, башка кабиләләр һәм халыклар белән катнашу һәм үзара тәэсир итү үзенчәлекләрен ачыклауда әһәмиятле. Этнонимика этнос атамаларын өйрәнеп кенә калмый, бәлки тарихи вакыйгаларны реконструкцияләүдә дә үз өлешен кертә, чөнки этнонимнарда халыкның борынгы үткәне сакланып кала, шулай ук тарихи аренадан юкка чыккан халыкларның тарихы да этнонимнарда сакланып калырга мөмкин.

Этнонимнарның берничә төре аерыла: *макроэтнонимнар* дип зур төркем этнос һәм этник төркем атамаларын атыйлар, еш кына бу термин артык киң мәгънәдә кулланылып, генетик яктан төрле этносларны берләштереп атау өчен кулланылырга мөмкин (мәсәлән: руслар, гарәпләр, кытайлар, татарлар, башкортлар); *микроэтноним* атамасы исә зур булмаган этник төркемнәрене атау өчен кулланыла (мәсәлән: кыпчаклар, керәшеннәр, типтәрләр, мишәрләр) (Татар энциклопедиясе, т. 6, 2014: 468).

Этнонимнар составындагы халык һәм кабиләләрнең үзатамаларын белдерү өчен *автоэтноним* термины кулланыла. Гадәттә,

бу төр этнонимнар «кеше», «ир» төшенчәләре белән бәйле була. Төрки телләрдә ул *«ир» («ар», «эр»)* сүзенә төрле элементлар кушылып ясала: *суар* (су – эр) – су кешесе; *сарир* (сары – ир) – сары кеше; *акацир* (акац – ир) – урман кешесе һ.б. (Татар энциклопедиясе, т. 6, 2014: 468).

Башка халыклар тарафыннан бирелгән атамаларны исә *аллоэтноним* термины белән атап йөртәләр. Мәсәлән, алманнар үзләрен *Deutschen*, фин халкының исә *suomalainen* дип йөртәләр. Мари халкы бөтен болгарларны *суас* дип, руслар исә *ас (яс)* дип атап йөрткәннәр.

Нигездә, этнонимнар этнос яшәгән ил яки төбәк атамасы белән тәңгәл килә. Әгәр ил яки төбәк атамасы этнонимнан барлыкка килсә, бу төр туры тәңгәллек дип атала. Мәсәлән: *греклар – Греция, чехлар – Чехия, марилар – Марий Эл, татарлар – Татарстан* һ.б. Кайбер очракларда, киресенчә, ил исеме этноним вазифасын да үтәргә мөмкин, мәсәлән, А*мерика – американнар.*

Этнонимнарга якын торган берәмлекләрдән төрле типтагы топонимнардан ясалган һәм аерым төбәк вәкилләрен атый торган берәмлекләрне билгеләү кирәк. Бу төр лексика вазифасын этнохоронимнар, ягъни зур регионда яки шәһәрдә яшәүче кешеләрне берләштеп атый торган сүзләр (*европалы, кавказлы, африкалы*, *азияле*, *казанлы, мәскәүле* һ.б.); шулай ук аерым төркемнәрнең тарих дәвамында формалашкан рәсми булмаган кушаматлары (*казаклар, чирмешләр* һ.б.) керә.

Этнонимнарга якын берәмлекләр булып, шулай ук лингвонимнар – теге яки бу этник төркемнәрнең теле һәм диалектлары тора. Аларның түбәндәге типларын аералар: 1) зур гаилә телләренең атамалары (Урал-Алтай телләре, Алтай телләре); 2) зур тел төркемнәренең атамалары (төрки телләр, славян телләре); 3) этноним белән тәңгәл килгән телләр (татар теле, башкорт теле, мари теле һ.б.); 4) диалект төркемнәре яки диалект атамалары (мишәр диалекты, нократ сөйләше).

Этнонимика фәнендә бу төр берәмлекләрне этноним буларак карау-карамау мәсьәләсе тынып тормый, чөнки алар арасында нейтраль берәмлекләр белән бергә, кушамат буларак кулланыла торган һәм үзендә кушаматка хас түбәнсетү кебек эмоциональ-экспрессив мәгънәгә ия булганнары да очрый.

Этноним эчтәлеге этнонимны йөрткән халык белән бер үк булмаска мөмкин. Тарих фәнендә *татар* этнонимының хәзерге татар халкы белән тәңгәл булмавын күрсәткән материаллар билгеле. Этнонимның эчтәлеге үзгәрешсез тормый, этнонимның тышкы формасы үзгәрмәсә дә, һәрвакытта да ул бер үк объектны атамаска мөмкин. Мисал өчен, VII гасырда Балкан ярымутравына күчеп килгән төрки телле болгар кабиләсе көньяк славяннар белән катнашып югалса да, этноним әлеге территориядә берегеп калып, шул территориядәге халыкны атый башлый, шул рәвешле алар Идел буе болгарлары һәм Кавказ балкарлары белән бер үк этнонимны йөртәләр (Этнонимы, 1970: 9).

Аерым очракларда теге яки бу территорияне басып алучы халык, кабилә атамасы территориягә берегеп калып, алдагы буыннарга күчә. Мисал өчен монгол яуларыннан соң Идел буенда, Урта Азиядә һәм башка территорияләрдә теркәлеп калган татар, мангыт, барлас, кунград һ.б. этнонимнарны атарга була.

Этнонимның эчтәлеге объектка бәйсез дә үзгәрергә мөмкин. Моның өчен объектның этник составы үзгәрү мөһим түгел, бәлки этнонимны кулланучыларның этник күзаллаулары үзгәреш кичерү дә җитә. Мәсәлән, Октябрь инкыйлабына кадәр Россиядә *кыргыз* этнонимы казакларны, аерым очракларда төрекмәннәрне атау өчен кулланылган, ә кыргызларның үзләрен исә *каракыргызлар* дип йөрткәннәр (https://ru.wikipedia.org). Руслар XVIII гасырга кадәр көнчыгыш халыкларын гомуми *татар* этнонимы белән атаганнар.

Шулай итеп, этноним һәм аның объекты тәңгәл килмәскә мөмкин, тарихның аерым этапларында этнонимның бер этник объектны атау, икенче этапларда аның объекты үзгәрү очраклары да бар. Нәтиҗәдә этнонимның өч мәгънәви аспекты аерыла: этнонимга кадәрге мәгънә, аны этимологик мәгънә дип тә атыйлар, әлеге мәгънә тулысынча яки өлешчә югалырга мөмкин; этнонимик мәгънә, ягъни этнонимның реаль эчтәлеге, этник объект белән турыдан-туры бәйләнеше; этнонимнан соң барлыкка килгән мәгънәсе, сирәк булса да бу төр мәгънә дә очрый.

Этнонимнарны өйрәнүдә аерым кыенлык тудырган аспект булып бер үк этнонимның төрле халыкны атавы яки бер үк халыкны атау өчен берничә этноним кулланылуы тора.

Төрки этнонимнарны анализлау барышында уртак морфологик структурага ия булган берничә зур төркем этноним аерыла.

Беренче чиратта, *-ар* кушымчасына тәмамланган этнонимнар: *татар, хазар, булгар (болгар, балкар, малкар), авар (абар, апар), мажар (мадьяр, мишар), кангар (кен ~ер), сувар (субар), кажар (кеджер, качар, гаджар), кабар* һ.б. (Еремеев, 1970: 133). Югарыда әйтелгәнчә, *-ар* компоненты «кеше», «ир» мәгънәләрен белдерә.

Икенче зур төркем төрки этнонимнар *-ак, -әк, -ык, -ик, -ук, -үк, -к* кушымчаларына тәмамлана, килеп чыгышлары ягыннан алар беренче төркемдә күрсәтелгән төрдән соңрак барлыкка килгән дип санала ( Еремеев, 1970: 134). Әлеге төркемгә *казак, кумык, кыпчак, бәҗәнәк (бедженек, печенег), кайык, кынык, кырык (кызык), чарук, емек, уграк (играк), юрук, калтак, фарсак (варсак), сарык, барак* һ.б. керә.

Өченче зур төркем *-ман/-мән* кушымчасы булу белән характерлана: *төрекмән, куман, караман, акман, сарман, чуман, бисәрмән* һ.б.

Төрки, шул исәптән татар этнонимиясенә караган мәгълүматлар бик борынгы чорларга барып тоташа. Аларга алдагы параграфларда кайбер этнонимнарның этимологиясен анализлаганда киңрәк тукталырбыз. Шулай да төрки халыкларның ономастикасын өйрәнүдә зур роль уйнаган Мәхмүт Кашгариның «Диване лөгатет-төрк» хезмәтен атау зарур. Шул чорда яшәгән кабиләләр атамаларын, тарихын, аларның тел үзенчәлекләрен туплаган әлеге хезмәт төрки этнонимияне өйрәнүдә гаять әһәмиятле чыганак санала. Гарәп телендә язылган бу хезмәт, асылда, татарларның этногенезын өйрәнүдә беренче талпыныш булып тора. Татарларны М. Кашгари төрки кабиләләр рәтенә кертә. Аның болгарлар турындагы фикерләре дә кызыклы. Болгарлар һәм суварлар Византия тирәсендә яшәгән печенеглар белән янәшә яшиләр, телләре – төрки тел, әмма кушымчалары кыскартылган, ди ул (Кашгарлы, 1992, т. I: 30).

Татарларның этник тамырларын билгеләүдә беренче талпынышлар төрки шәҗәрәләрдә дә күзәтелде. Мисал өчен, XIV гасырның танылган фарсы тарихчысы Рәшидеддиннең «Җәмигъ әт-тәварих» хезмәтен атарга кирәк. Галим фикеренчә, борынгы заманнарда татарлар Хитай чикләрендә яшәгәннәр һәм Хитай императорына ясак түләгәннәр (Рашид-ад-дин, 1952: 101).

Мондый төр чыганаклар исәбенә Хива ханы Абел-Гази Баһадурхан тарафыннан язылган «Шәҗәрәи төркия»не дә кертеп

карыйбыз. Биредә татарларның килеп чыгышы Аланча ханның игезәк уллары Татар һәм Монгол белән бәйләп аңлатыла (Абуль-Гази, 1906: 33). Соңрак чорларда да шәҗәрәләрдә аерым бер этносның килеп чыгышын шәхесләр, ханнар яки изгеләр белән бәйләп карау традициясе дәвам итә. Бу традиция XIX–XX гасыр чикләрендә язылган татарга кагылышлы хезмәтләрдә дә күзәтелә.

Россиядә беренче этногенетик эзләнүләр белән Петр I чакыруы буенча килгән чит ил галимнәре, соңрак Рус Фәннәр Академиясе шөгыльләнә.

XVIII гасыр дәвамында Академия Идел буена, Себер һәм Кавказга рус булмаган халыкларны өйрәнү буенча берничә фәнни экспедиция оештыра. Әлеге экспедицияләр нәтиҗәсендә зур күләмле лингвистик, этнографик, топонимик, тарихи һәм географик материал туплана һәм эшкәртелә. Бу чордагы тикшеренүләрдә татар этнонимы киң мәгънәдә, ягъни көнчыгышта яшәүче рус булмаган халыкларның күпчелеген атау өчен кулланыла.

XIX гасырда Россиядә татар этнонимының семантикасы тараеп, Идел–Урал территориясендәге татарларны, Кырым татарларын, Литва татарларын атау өчен кулланыла башлый. Шушы чорда татар этнонимы һәм татар этносының тәңгәл булмавын күрсәткән материаллар күренә башлый. Идел–Урал татарларының антропологик билгеләре, этнологик үзенчәлекләре, мифологик күзаллаулары белән монголлардан аерылып торуларын, Идел буе Болгар дәүләте составындагы төркиләр белән охшашлыкларын билгеләү юнәлешендә эш башлана. Татар тарихын өйрәнүчеләр Идел буе татарларының, этнос буларак, Идел буе болгарларының варислары булуын, ә татар этнонимының монгол-татарлар белән соңрак дәверләрдә килүен билгелиләр. Гомумән, татар халкының этногенезы буенча хәзерге фәнни хезмәтләрдә берничә теория бар, шулардан түбәндәге өчесе җентекләп тәфсилләнгән: төрки-татар теориясе; болгар-татар теориясе; татар-монгол теориясе. Әлеге хезмәттә аларны ачыклау максаты куелмаганлыктан, аерым тукталмыйбыз.

Татар этнонимика фәне хәзерге көндә дә ачык өйрәнелгән дип әйтеп булмый, гәрчә теле яки бу этнонимга бәйле мәгълүматлар тарихчылар, тел тарихчылары, ономатологларның хезмәтләрендә бирелсә дә. Махсус хезмәтләрдән тел һәм тарих галиме М.З. Зәкиевнең «Происхождение тюрков и татар» (2003), «Türklerin ve

Tatarların kökeni» (2006) китапларында бик күп ономастик берәмлекләргә, шул исәптән этнонимнарга да этимологик анализ бирелгән. Авторның «История татарского народа (этнические корни, формирование и развитие)» (2008) һәм «Татар халкы тарихы (этник тамырлары, оешуы һәм киләчәге)» (2008) дигән китапларында этнонимнарга, топонимнарга этимологик анализ тагын да тулырак һәм системалырак эшләнгән. Мондый анализ лингвистик археология дигән фәнни юнәлешкә кадәр үстерелгән.

## § 40. Этнонимнарның этимологиясе

Этнонимнарның этимологиясе белгечләрне генә түгел, киң катлам кешеләрне дә һәрдаим кызыксындырып тора. Шунлыктан этнонимнарның килеп чыгышын ачыкларга омтылышларны да еш очратабыз. Мондый кызыксынулар нигезендә башка телләрдән охшаш сүзләр эзләү һәм алар белән уртаклык табарга омтылулар да күзәтелә, шунлыктан, этнонимнарның килеп чыгышын аңлаткан фәнни хезмәтләр белән бергә, чынбарлыкка туры килмәгән фикерләрне алга сөргән материалларны да күрәбез. Гомумән, ономастик материалның килеп чыгышын аңлаткан субъектив фикерләр шактый таралыш тапкан. Әйтергә кирәк, антропоним һәм топонимнарның килеп чыгышын билгеләү ономастика фәнендә билгеле бер тәртипкә салынган дип исәпләнсә, этнонимнарның килеп чыгышын аңлатуда төрлелек һәм принципларның эшләнеп җитмәве шактый күзгә ташлана. Татар халкына мөнәсәбәтле этнонимнарны аңлатуда да мондый төр үзенчәлек бар.

Хәзерге татарларның этник тамырлары шактый тирәндә ята. Татарларның Идел–Уралда үз төрки регионнары булган. Аларның *болгар* дигән төркеме, мишәрчә (огузча) сөйләүчеләрне берләштереп, Болгар дәүләтен төзегән. Урта диалектта (кыпчакча) сөйләүчеләре, *кусян/косан* (ак сөннәр/ак һуннар) исемен алып, Косан илен барлыкка китергәннәр. Соңыннан болгар (мишәрләр) косан төркемнәре берләшеп, бер халык төзегәннәр, алар *болгар* һәм *косан* атамаларын дәвам итмичә, XX гасыр башында гына *татар* исемен кабул иткәннәр, ә *татар* дип аталган башка төркиләр, Октябрь инкыйлабыннан соң республикаларын төзү барышында *татар* исеменнән баш тартып, үзләренең борынгы чын исемнәрен кайтарганнар.

Безгә мәгълүм булганча, тарихта төркиләрнең исемнәре шактый еш алмашынып тора, ләкин төрки кабиләләр нинди генә

гомуми исем йөртсәләр дә, нигездә шул килеш сакланып калалар, бары бераз үсүгә, камилләшүгә генә дучар булалар.

Тарихка нык мәгълүм булган беренче төрки исем – *киммер,* моннан соң *сака/сак, скиде (скиф), сармат, алан (ас), һун, авар, төрки, хазар, бәҗәнәк, кыпчак* һ. б. исемнәргә алмашыналар, чөнки хакимият башында гел бер кабилә, бер халык кына утыра алмый, төрле чорда төрлесе өстенлек ала. Халыкның алмашынмыйча, бары аның этнонимының гына алмашынып торуын – *скиф* этнонимының *сарматка, сармат* атамасының *аланга, алан* исеменең *һунга, һун* атамасының *кыпчакка* һ. б. шундый алмашынып торуын XIX йөздә П.Ф. Сум да исбатлаган (Сум, 1846: 15).

Соңгы елларда тарихчылар төркинең Европадагы тарихын кыскарту юлына бастылар һәм бернинди исбатлаусыз *киммер, скиф, сармат, алан* этнонимнары иран теллеләрне белдерә дип раслый башладылар. Шуның өчен без, төрки этник тамырларын ачу омтылышы белән, *киммер, скиф, сармат, алан* исемнәре астында мәгълүм булган халыкларның да нигездә шул ук төрки булуларына аерым тукталырга булдык.

Скифлар (киммер, скиф, сармат) турындагы иң тулы мәгълүматлар безгә антик дөнья тарихыннан килә. Б.э.к. V йөздә яшәгән Геродот б.э.к. VIII–V йөзләр тарихы турында тугыз язма калдыра. Алар барысы бергә «Тарих» исеме астында дөнья күрәләр һәм шуннан соң Геродотны тарих фәненең атасы дип атый башлыйлар. Борынгы грекча язылган башка хезмәтләрдә дә скифлар турында үз чоры өчен җентекле генә материаллар бар. Бу яктан аеруча Гиппократ (б.э.к. V–IV йөзләр), Ксенофонт (б.э.к. V–IV йөзләр), Полибий (б.э.к. II йөз), Страбон (б.э.к. I йөз), Птолемей (б.э. II йөзе) һ.б.ның язмалары әһәмиятле. Бу хезмәтләрдә *скиде (скылы)* дип йөртелгән халыкларны руслар *скиф* дип алганнар. Көнбатыш фәнендә – *скит,* төрекләрдә – *искит* этнонимы ике мәгънәдә кулланыла (тар һәм киң мәгънәләрдә). Тар мәгънәдә ул конкрет бер кабилә яки халыкны атый, киң мәгънәдә Скиде конфедерациясенә кергән барлык халыкларны да эченә ала. Моны күз алдына китерү өчен, *рус* этнонимының бары рус милләтен генә дә, чит илләрдә исә Россиядәге барлык халыкларны да атауны хәтерләргә кирәк.

Киң мәгънәсендә кулланып, борынгылар скифлар арасында күп халыкларны күрсәтәләр. *Скиде* дигән халыкларны грек чы-

ганаклары дүрт төргә бүлә: 1) патша скифлары, 2) җир сөрүче скифлар, 3) игенче скифлар һәм 4) күчмә скифлар.

Скифларны төрле халык төрлечә атый, чөнки бер халык икенчесенә исемне күрше кабилә атамасы белән куша. Греклар Скиф конфедерациясенә кергән халыкларны *скиде* дип атаганнар. Фарсылар аларны *сака/сак* дип йөрткәннәр, чөнки алар күршесендә скифларның *сака* дигән өлеше яшәгән. Ә төп скифлар – патша скифлары – үзләрен *сколот* дип йөрткәннәр, бу – «патша скифлары» дигән сүз, ди Геродот (Геродот, 1972, 4 китап: 5–7 абзац). Геродот скифлар арасында бераз гына башкачарак сөйләшүче *савраматларны* да күрсәтә (шунда ук, 4 китап: 117 абзац). Менә шул савраматлар соңрак, ягъни б.э.к. III һәм б.э.ның III йөзләре арасында *сармат* исеме белән хакимлек итүчеләр булып саналалар. Б.э.к. I йөзләрдә сарматлар арасында *алан (ас)* дигән кабиләләр өстенлек алу өчен көрәш башлыйлар.

Скифлар турында шактый төгәл мәгълүматларны без фарсы чыганакларыннан да таба алабыз. Бу турыда төп фарсы чыганагы – б.э.к. VI–V йөзләр арасында яшәгән Иран патшасы Дарий I гә багышланган кыяташ язмалары. Ул борынгы фарсыча Накши-Рустем һәм Бехистун тарлавыкларындагы кыяларга чокып язылган. Анда скифлар *сака* дип бирелә һәм алар *тиграхауда сакалары* (очлы башлык кигән сакалар), *хаумаварга сакалары* (Геродотта болары амюргий скидлары дип бирелә), *тиай-парадарая* (диңгез арты) *сакалары, тиай-пара-сугда* (согдылар артындагы) *сакалар* дигән төрләргә бүлеп күрсәтеләләр.

Ксеркс (б.э.к. V йөз) дигән патшага багышланган фарсыча язмаларда да сакалар *хаумаварга, тиграхауда* һәм *скудра* дигән төрләргә бүлеп бирелә. *Скудра* сүзе *Ичкудра, Чкудра* формаларында да очрый. Скудра сакалары Кара диңгезнең төньягындагы диңгез арты скифларына (сакаларына) туры килсә кирәк.

Б.э.к. VII йөздә язылган Ассирия чыганакларында күбрәк *киммерләр (гиммер)* һәм *ашгузалар* турында сүз алып барыла. Шул чорлардагы чөй язуларга караганда, Ассирия чыганакларындагы *ашгузы/ишгузылар* грек чыганакларындагы скифларга туры килә (Durmuş, 1993: 26).

Скиф-сакалар турында мәгълүматлар кытай чыганакларында да бар. Анда алар нигездә *сай* дип укылалар, шул ук вакытта аларны *сцу/су/са'и/ссе/се* дип уку мөмкинлеге дә бар. Борынгы

кытай кульъязмаларында аны *сак* дип язу да очрый. Димәк, кытайча *саи* Урта Азия җирләрендә бик борынгыдан яшәгән *сакалар-скифларны* белдерә. Кытайлар Көнбатыш Төркестандагы сакаларны *саи-ванг* дип, ягъни *патша сакалары* дип атыйлар (Durmuş, 1993: 27–28).

Язма чыганакларны һәм археологик материалларны анализлау нәтиҗәсендә, галимнәр скифлар (сакалар, ишгузалар) яшәгән җирләрне, ягъни Дунайдан алып Көнбатыш Кытайгача һәм Синьцзянга кадәр булган җирләрне өч регионга бүлеп карыйлар.

*Беренче регион* – Кытай чикләреннән алып Каспий диңгезенә кадәр булган җирләр. Монда *тиграхауда* һәм *хаумаварга* дигән скифлар яши. Кайбер грек чыганакларында бу регион халкын *массагетлар* дип тә атыйлар. Монда тагын Фирганә тирәләрендә Согдиана артында яшәүче сакалар да аерып күрсәтелә.

*Икенче регион* – Каспийдан алып Дунай буйларына кадәр булган территорияне эченә ала. Монда диңгез арты скифлары яши. Геродот бу скифларны җир сөрүче, иген игүче скифлар, патша скифлары, таврлар, меланхленнар дигән төрләргә бүлә. Болар барысы да скиф диалектларында сөйләшкәннәр.

*Өченче регион* – Алгы Азия һәм Кече Азия. Монда скифлар, Геродот әйтмешли, киммерләрне куа китеп килеп керәләр. Бу скифлар Мисыр, Сүрия һәм Палестинага килеп җитәләр, ләкин археологик казылмалар аларның, нигездә, Көнчыгыш Анатолиядә төпләнеп яшәүләрен күрсәтә (Durmuş, 1993: 37).

Шулай итеп язма чыганакларда скифларның (*сака, ишгуза, сармат*, *киммерләрнең*) яшәү урыннары һәм аерым төрләре шактый җентекле күрсәтелә.

Без әле генә скиф-сарматлар тарихының беренче эзләрен эченә алган борынгы грек, фарсы, Ассирия һәм Кытай чыганакларының булуы турында сүз алып бардык. Рәсми тарих фәнендә бу этнонимнар белән йөртелгән халыклар иран (төгәлрәк әйтсәк: осетин) телле булганнар дигән фикер өстенлек алса да, башка төрле карашларның булуын да әйтергә кирәк.

XVII йөзнең икенче яртысында борынгы грек чыганаклары белән рус галимнәре дә кызыксына башлый. «Тарих атасы» дип йөртелгән Геродотның язмаларын башта немецчәдән русчага, соңрак турыдан-туры грекчадан тәрҗемә итүчеләр күренә. Геродот язмалары белән Андрей Лызлов кызыксына. Ул, рус һәм Көнбатыш

тарихи чыганакларын өйрәнү өстенә, Көнчыгыш белән дә якыннан таныша. Төрки дөньясын яхшы белә, 1692 елда «Скифская история» дигән хезмәтен төгәлли, ул башта кулъязма хәлендә күбәйтелә, соңрак русның җәмәгать эшлеклесе һәм язучысы Н.И. Новиков тарафыннан 1776 елда – өлешчә, ә 1787 елда тулысынча китап итеп бастырыла. А. Лызлов, скифларны өйрәнеп, аларны төрки-татарларга китереп бәйли, хезмәтенең беренче бүлегендә төрки-татарларны турыдан-туры скифлардан чыккан халык дип билгели. Башка бүлекләрендә ул *скиф* сүзен аз куллана, аларны *төрки-татар* (татары-турки) дип атап эш итә (Лызлов, 1787).

XVIII йөз башында скиф-сарматлар мәсьәләсе башкаларны да җәлеп итә башлый. Славян тарихы белән кызыксынган Петр I Вена шәһәрендә яшәүче Г.В. Лейбницның славян тарихы белән шөгыльләнүен сорый. Петр I нең теләген яхшы төшенгән автор 1708 елда җибәрелгән хатында болай яза: «Сарматларны мин славяннар дип уйлыйм: *славян* сүзе туганчы, аларны *сармат* дип атаганнар», – ди (Лейбниц, 1873: 211).

Соңрак скиф-сармат проблемасына Германиядән Петербург Академиясенә чакырылган Готлиб Зигфрид Байер мөрәҗәгать итә. Аныңча, скифлар Азиядән килгән халык, ә славян җирле, шуңа күрә скиф славян була алмый, ул фин, лив, я эст булырга тиеш (Нейхардт, 1982: 12).

XVIII йөз уртасында скиф-сарматларны өйрәнү эшенә рус тарихчысы В.Н. Татищев килеп кушыла. *Скиф* сүзе белән күп халыкларны атаганнар, ди ул, славяннарны, сарматларны, төркиләрне, монголларны, хәтта немецләрне, фарсыларны һәм кытайларны да. X йөздә халыклар турында төгәлрәк мәгълүматлар алына башлагач, *скиф* исемен сирәк кулланалар, ләкин элек яшәгән халыклар юкка чыкмыйлар, яшәүләрен дәвам итәләр. Бу халыкларны гомумән атау өчен XIII йөздән *скиф* урынына *татар дигән* исем киң таралыш ала (Татищев, 1962: 232–233).

XVIII йөз ахырында атаклы тарихчы Н.М. Карамзин: Геродот заманында барлык Евразия халыклары скиф дип аталган, дигән фикергә килә (Карамзин, 1988: 5).

XIX йөздә Геродот язганнарны археологик материаллар да раслый. Тарих фәненә башка грек чыганаклары да кертелә. Гомумән, борынгы тарихны объектив һәм белеп өйрәнү өчен шартлар туа.

Казан һәм Вильна университетларында да эшләгән, академик Э.И. Эйхвальд, Геродот хезмәтләрен өйрәнеп, 1838 елда славян, фин, төрки, монгол халыкларының тарихын яза. Ул тагын да дөрес һәм төгәл фикер әйтә. Аныңча, скиф бер генә халык түгел, элек скиф территориясендә нинди халыклар яшәгән булса, хәзер дә алар үз урыннарында яшәүләрен дәвам итәләр (Эйхвальд, 1838: XXVII).

Күп халыкларның этногенезы белән шөгыльләнгән П.Ф. Сум, скифлар, сарматлар һәм аланнар төрки булганнар, алардан һуннар һәм башка төркиләр формалашкан, *сармат* этнонимы да төрки сүздән – *сары* сүзеннән ясалган, ди (Сум, 1848: 3, 15).

XIX йөзнең беренче яртысында немец тарихчысы Б.Г. Нибур, скифларны монгол булганнар, ди, һәм *монгол* исеме мәгънәсенә төркиләрне дә кертеп карый (Niebuhr, 1847).

XIX йөзнең икенче яртысында А.Д. Мордтман Лейпцигта чөй язулар турында бер китап чыгара, һәм шунда скифларның төркичә сөйләшкән булуларын исбатлый. Ләкин аныңча, бу төрки тел скиф чорында Урал-Алтай берлегеннән аерылып чыгу чорын кичергән (Mordtmann, 1870: 66–77).

Тюрколог булмаган галимнәрнең скифны төркигә тиңләве XX йөзгә чыккач та очрый әле. Мәсәлән, 1904 елда О. Франке Үзәк Азия скифлары һәм төркиләре турында сөйли торган кытайча чыганакларга багышланган немецчә хезмәт бастыра һәм анда Үзәк Азия скифларын, төрки булганнар, дип раслый (Durmuş, 1993: 17).

1837 елда К. Цейсс скиф тарихын өйрәнүдә яңа юнәлеш башлап җибәрә. Үзенең Мюнхенда чыккан хезмәтендә ул, беренче буларак, скифларны иран телле булганнар дип белдерә. Бу фикерен ул скиф һәм иранлылар арасындагы дин охшашлыгы белән исбатларга омтыла (Доватур, 1982: 47). Ләкин шулай ук немец тарихчысы К. Нойманн 1855 елда, К. Цейсс фикеренә каршы килеп, дин һәм тел фактларыннан чыгып, скифларны – төрки, ә сарматларны славян булганнар, дип яза (шунда ук: 50).

XIX йөзнең 60 нчы елларында К. Мюлленхофф скиф-осетин теориясенә нигез сала, скиф-сарматлардан калган сүзләрне бары иран теленнән чыгып кына анализлый, төрки, монгол, славян телләренә мөрәҗәгать итми һәм, нәтиҗәдә, скифлар осетин булганнар, алар скиф чорында төньяктарак яшәгәннәр, ди (Доватур, 1982: 53).

К. Мюлленхоффтан соң скиф-иран-осетин теориясе белән күпләр шөгыльләнә башлый, аны яклаучылар арта тора.

Скиф материалларын үз күзе белән күреп, аларны үзе тикшереп караган тюркологлар барысы да скифлар составында төркиләрнең төп роль уйнавын этнологик, мифологик, лингвистик, археологик мәгълүматлар белән дәлилләп күрсәтәләр.

Венгр тюркологы Геза Куун бик күп кире кагылмаслык фактлар белән скиф-сарматларның төрки булуларынраслый (Kuun, 1981: LVII–LVIII).

Скифлар, саклар, сарматларның төркилеге мәсьәләсенә Хәсән Гата әл-Габәши дә шактый ышанычлы дәлилләр китерә. Ул үзенең 1909 елда Уфада басылган төрки кавемнәрнең тарихын җентекләп тикшерүгә багышланган китабында бу мәсьәләне хәл ителгән дип саный (Габәши, 1909: 54).

Һади Атласи үзенең 1911 елда чыккан «Себер тарихы» әсәрендә болай яза: «Юнан голямасының Скифия дип атадыклары урыннар төрки халыкның утрагы булган Төркестан, ягъни иранилар тарафыннан Туран исеме бирелгән өлкәдер» (Атласи, 1993: 21).

Садри Максуди Арсал, борынгы дәүләт һәм хокуклар тарихын җентекләп өйрәнгәндә, табигый рәвештә скифның этник үзенчәлекләре мәсьәләсенә килеп керә һәм, үз чорының иң тирән белемле галиме буларак, борынгы чыганакларны җентекләп тикшереп, скифларның төркилеген исбат итә (Zeki Velidi, 1930: 8).

Зәки Вәлиди Туган да, рус һәм Көнбатыш галимнәре скиф-иран берлеген яклауларына карамастан, үзе тапкан дәлилләргә таянып, скифларның, һичшиксез, төрки булуларын әйтә (Вәлиди, 1981: 34).

Тарих фәнендә скиф-сака-сармат иран телле халык дип танылгач, СССРдагы тюркологлар бу мәсьәләгә гомумән кагылмаска тырышалар. Шулай да фактик материал скиф-сакаларны төркидән бөтенләй аерырга мөмкинлек бирми. Мәсәлән, казак галимнәре скиф-сакаларны казакларның борынгы бабалары итәрәк өйрәнүне алга сөрәләр (Аманжолов, 1971; Акишев, 1978).

1975 елда Олжас Сулейменов үзенең «Аз и Я» дигән китабында, скифларга кадәр берничә мең ел элек яшәгән шумерларны да, скифларны дә төркиләр булырга тиеш, дигән фикерне әйтә (Сулейменов, 1975: 269–270). Аның идеяләрен татарларда Әбрар Кәримуллин күтәреп алды. Ике елдан соң М.З. Зәкиев төрки-татар

теле һәм халкы тарихы буенча китап чыгарып, скифларның, сарматларның, кушаннарның, тохарларның, үсүннәрнең төрки булуларын төрле яклап исбатларга тырышты (Закиев, 1977: 27–44).

1986 елда Кавказ галимнәреннән И.М. Мизиев, 1993 елда шул ук И.М. Мизиев белән К.Т. Лайпанов скиф-сармат-аланнарның төрки булуларын барлык этногенетик дәлилләр белән ныгыттылар.

1993 елда Төркиядә Илһами Дурмуш барлык этногенетик мәгълүматларны туплап, скифлар турында махсус монография язып чыгарды. «Skitler (Sakalar)» дигән бу китапта скифлар арасында төркиләрнең төп роль уйнаулары дәлилләр белән исбатлана.

1995 елда М.З. Зәкиевнең «Этнические корни татарского народа» һәм «Аланы: кто они?» дигән ике фәнни тикшерү нәтиҗәләре басылды (Закиев, 1995: 12–57).

Соңгы елларда скиф-иран теориясенең ялгышларын ачып биреп, скиф-төрки концепциясенең дөреслеген күрсәткән материалларның өр-яңалары да күренә башлады. Боларның иң күренеклеләреннән Азәрбайҗан галиме Фиридун Агасыоглуның скифларны төрки дип раслаган эшен күрсәтергә кирәк (Фиридун Агасыоглу, 2000: 77–133).

Скифларны төрки телле булган дип исбатлаган тагын бер күренекле хезмәт рус телендә Нью-Йоркта 2002 елда чыкты. Ул – азәрбайҗан галиме Заур Гасановның «Царские скифы (этноязыковая идентификация «царских скифов» и древних огузов)» дигән китабы. Автор биредә патша скифларының барлыкка килүләрен һәм күчеп йөрүләрен төрки-огузларның «Огуз-намә»сендәге хәлләр белән тиңләштерә, патша скифлары аллалары җыелмасын төркиләрнең тәңречелегенә охшата, Геродотның скифлар риваятендәге «сукырлар уллары» турында әйтелгәннәрне төркиләрнең «Кероглы» (сукыр улы) дастанында тасвирлаган вакыйгалар белән параллель куя. Болар патша скифларының чыннан да төрки элгәрләре икәнлегенә шик калдырмый.

Скифлар арасында төп урынны төркиләр алып торган дип исбатларга тырышучы тюркологлар белән янәшә, скиф-иран теориясен генә яклаучылар да булды. Мәсәлән, башкорт галимнәре Т.М. Гарипов белән Р.Г. Кузеев, Идел–Уралдагы скиф-сарматлар иран телле булган дигән фикерне хуплап, бу регионда иран тамырлы топонимнар эзләделәр. Аларча, мәсәлән, *сэрмэсэн, сэрмэт, аблай, абрай, капа, капкан, капка, капсык, сак, сакмар, киртә* һ.б.

сүзләр Идел–Уралда иранлылардан калганнар (Гарипов, Кузеев, 1988: 15).

Нәтиҗә ясап әйткәндә, скиф-иран, скиф-төрки мәсьәләләрен бары лингвистик юл белән генә хәл итеп булмый, аны барлык этногенетик мәгълүматлар синтезы гына дөрес хәл итә ала.

Төрки этнонимиясендә урын алган башка берәмлекләргә дә күзәтү ясыйк.

1. Иң актив беренчел этноним – ул *ар/әр/ир* ‘ирләр, кешеләр’ мәгънәсен бирә. Хәзерге чорда *ар* беренчел этнонимы үзе генә кулланылмый, төрле аергычлар белән икенчел этноним төзүдә ул бик актив: *хаз-ар, су-ар, тау-ар(тавр), шум-ер, булг-ар, тат-ар* һ.б.

2. *Ас* этнонимы иң борынгылардан санала, ул ялгыз килеш төрле кабиләләрне һәм халыкларны атау өчен кулланылган. Аның *йәс/йәш* вариантлары кайбер төрки телләрдә ‘яшь кеше’ мәгънәсен бирә. Нугай һәм караим телләрендә *йас/йәш* ‘ул, огул’ мәгънәсендә аңлашыла. Идел буе болгарларында да *ас* кабиләләре күренекле урын алып торган. Марилар элек тә, хәзер дә болгар-татарларны *суас* (ягъни *су аслары)* дип атаганнар һәм атыйлар. Алар чувашларны *суасламари* дип йөртәләр.

Тарихта аслар һәрчак аланнар белән янәшә искә алыналар. Хәзерге көндә төрки этнонимы *ас/алан* бернинди нигезсез иран телле осетиннарга каратыла. *Ас* этнонимының төрки булуын *ас* сүзеннән ясалган этнонимнарның төркиләрдә күп очравы раслый: *карагас (керек ас), кыргыз (кырык ас), каңгалас (каңгалы ас* ягъни *хакаслар), кангарас, хакас, бортас, апас, суас, ос, уз, ош, төлөс, сары ас, огуз (ок + ас), гагауз* һ. б.

3. *Сак/сака* этнонимының төрки сүз булуы кире кагылмаслык итеп исбатланган. *Сак/сака/сой* ‘балалар, бала-сага, ыру, кабилә’ мәгънәләрендә йөртелгән. Якутлар үзләрен *саха* дип атыйлар, хакасларда *сага* дигән нәселләр бар, *хакас* этнонимы үзе дә *сака + ас (һака + ас=һакас)* этнонимнарыннан тора. *Казак* этнонимы да *ко-сак* ‘ак саклар’ әйтеменнән ясалган, *кыпчак* сүзе дә шул ук *ку + сак* ‘ак саклар’ сүзенең диалекталь әйтелешеннән барлыкка килгән. *Сак* этнонимы төрле диалектларда *һак, зак, дак, сой* формаларында да әйтелә торган булган.

4. *Сөн/һөн/хун* дигән беренчел этноним төрле фонетик чолганышта төрле вариантларда әйтелә: *сан/зян/зан/йан/җан/жан/шан/чан/чын* һ. б. Мәсәлән, *жужан/сусан, кусан/косан/казан, сянби*

‘сөнгә тартым байлар’. *Сөн/һөн/хун* кабиләләренең борынгы иң ачык эзләре Идел–Уралдагы Сөн дигән елга һәм авыл исемнәрендә сакланган. *Чаллы* этнонимы да шул ук этнонимга барып тоташа булса кирәк: *сүнле/сөнле/чөнле/ченле/ челле/ чаллы.*

5. *Ок* этнонимының мәгънәсе – ‘кабилә’. *Онок* этнонимын кытайлар *ун оклар* дип тәрҗемә иткәннәр (Kafesoglu, 1992: 156). *Комык* этнонимы да *ок* этнонимына нигезләнеп ясалган. *Комык* сүзе *ку-мән-ок* (*мән* тамыры да – этноним) өлешләреннән торган булса кирәк. *Огуз* этнонимы *ок* һәм *ас (уз)* өлешләреннән тора: *ок-ас > ок-уз > огуз, огур* сүзе исә беренчел *ок-ир* этнонимнарыннан ясалган: *ок-ир > окур > огур.*

6. Беренчел этноним буларак *бай* сүзенең төрле вариантлары кулланыла: *бәк/май/бик/бей/би/пи*. Мисаллар: *каспи* ‘кыя байлары’, *аргиппи* – ‘аргы пи, еректагы байлар’, *нагайбәк, биләр, бараба* ‘бары байлар’, *койбалы* ‘куй-бей-ле’, *майсагет/массагет* ‘бай саклы’ һ.б.

7. *Мән/мин/ми* сүзе дә беренчел этноним буларак кулланылган дип әйтә алабыз. Хәзер ул икенчел этнонимнарда очрый: *төркмән, куман, куманды, кубанды, караман, саралымин, сарыман* (*сарман*), *миде* (*Мидия*) һ.б. *Куман* этнонимы Көнбатышта *кыпчак* этнонимын алмаштырып йөргән, нәкъ менә Көнбатышта кулланылганлыктан, *куман* сүзендәге *ман* өлешен герман телләрендәге *ман* ‘кеше’ сүзе белән бәйләп караганнар.

8. Беренчел этнонимнар арасында без *каң/канг* сүзен дә очратабыз. Борынгы төрки телдә ул ‘бабайның бабасы’ мәгънәсендә кулланылган. Иранлылар хорезмлыларны *каңха* дип атаганнар. Монда *-ха* – иранча күплек кушымчасы, *каң* – ‘бабайлар’ мәгънәсендә. Шумерларның үзатамасы *каңгар* булган, ул *каң + ар* этнонимнарыннан тора. Фарсыларда атлы почтальонны *ангареон* дип атаганнар, ди Геродот (VIII, 98). Бу сүз, билгеле инде, кангардагы [к] авазы әйтелмәү аркасында ясалган. Бәҗәнәкләрнең үзатамасы *кангар* булган.

9. Төркиләрдә *кижи/кеше* сүзе дә этноним буларак кулланылган, кытайларда бу этноним *кюше* формасында әйтелгән. Ул *ку/ко* ‘аксыл’ мәгънәсендә борынгы сүз белән дә бергә йөргән: *кукижи* ‘аксыл йөзле кешеләр’; кытайлар үз күршеләренең берсен (төркиләрне) *туциши* дип атаганнар. *Ту/тау* аергычы *кеше* этнонимын ачыклаган, *туциши/тукижи* ‘тау кешеләре’ була. *Майма кижи* ‘вак

балык ашаучылар’, *алтай кижи, чуй кижи, казан кешесе, сөнкиши, туба кижи, куманды кижи, шор кижи, түргеши* кебек этнонимнарның булуы *кеше* сүзенең, еш кына, этноним булып кулланылуын да күрсәтә.

10. Урта Азиядәге *парды*/*парты* һәм аларның Кама буендагы кардәшләрен атый торган *барды* этнонимы *-лы*/*-ды*/*-ты* кушымчасы ярдәмендә ясалган. Бу этнонимның нигезендә *бар*/*пар* сүзе ята. Огуз телләрендә *барлы*/*варлы* хәзер дә ‘байлыгы бар, бай’ мәгънәсендә кулланыла. Күренекле тюрколог А.Н. Самойлович, ‘бай’ мәгънәсен белдерү өчен, төркиләрдә иң элек *бар, барлы* сүзләре кулланылган, соңрак *бай*/*би*/*бәк* сүзе барлыкка килгән, дигән фикер әйтә (Самойлович, 1936, 2005: 291–330). *Парды* этнонимы Пермь краендагы торак пункт атамасында сакланып калган.

11. *Сармат* этнонимы да *сарма* сүзенә *-лы*/*-ты*/*-т* кушымчасы кушылып ясалган булса кирәк. *Сармат* – ‘сармалы кешеләр’ дигән сүз. Ә *сарма* – ул төркиләрдә, ашамлык яки кымыз тутырып, атның ике ягына асылындырып йөртү өчен эшләнгән тире капчык.

12. *Сак* этнонимына кушылган *-дык*/*-дак*/*-ды* кушымчалары шулай ук яңа этноним ясауда катнашканнар: *сак-ды > согды, сак-дык > согдак.* Боларны һинд-Европа галимнәре, ясалма рәвештә, иран телле дип санаганнар, һәм аларны иран телле дип тикшерү гадәткә кергән. Ләкин алар – төрки этнонимнар.

13. *Остяк*/*иштәк* этнонимының язмышы бер катлы гына түгел. Пермь краенда *Ос* шәһәре бар, анда аслар яшәгәннәр. Аслар арасында *остяк (остык)* дип аталганнары да булган. Алар үзләренең *ас* үк түгел, ләкин асларга якынлыкларын аңлаганнар һәм үзләрен *ас* + *лы* / *ас* + *лык* / *астык* дип атаганнар. Рус сәяхәтчеләре аны *остяк* дип йөрткәннәр, ләкин, ялгышып, аның белән ханты-мансиларны да атаганнар. Ләкин *аслык/остяк/иштяк* дип татарларның һәм башкортларның аерым төркемнәре атала. Кайбер галимнәр ханты-манси телендә Обь елгасы *Ас* дип атала, ә *ях* ‘халык’ дигән сүз, шуларны бергә кушкач *осях* хасил була, бу ‘Ос/Обь кешеләре’ дигән сүз була дип уйлаганнар (Попов, 1973: 148), ләкин бу очраклы туры килү. *Остяк* дип татарлар һәм башкортларның аерым төркемнәре аталган, ул этноним *ос* + *тык* / *ос* + *тяк* өлешләреннән тора.

14. Б.э.к. III меңьеллыкта Тигр һәм Евфрат елгаларының югары агымы тирәләрендә *субар* дигән кабиләләр яшәгәнлеге

мәгълүм. Бу – ике сүздән: *суб* һәм *ар* сүзләреннән ясалган этноним. *Суб* – төркичә *су* сүзенең тулы формасы, *ар/ир/эр* – ‘кеше, ир кеше’ мәгънәсендә кулланыла, ул б.э.к. II–I меңьеллыкларда үзе генә бер төрки кабиләнең этнонимы булган. Бу этнонимны йөртүчеләр ишәйгәч, алар башка җирләргә күчеп китә, яңа җирдә аларның тормышы су-елга белән бәйләнгән булса, аларга гади генә *ар* яки *ир* димиләр, башкалардан аеру өчен *субар* (су кешеләре) диләр. Субарларны төрле кабиләләр үз диалектларындагыча итеп атый башлыйлар: мәсәлән, *субар/сабар/сабир/ сибир.*

15. Борынгы төркиләрдә *ок* (кабилә, ыру) этнонимы да булган, ул *ар/ир* яки *ас* этнонимы белән бергә кушма этноним ясаган: *ок-ар* һәм *ок-ас.* Боларда беренче (о) авазы икенче иҗектәге (а) авазын иренләштереп (у) га күчергән, (к) ике сузык арасында яңгыраулашкан: *окар>огур, окас>огус>огуз.*

Якын туган һәм ерак туган телләрдә очрый торган уртак сүзләрне һәр очракта да алынма дип булмый. Андый сүз, иң борынгы нигез телдә үк туып, соңрак бу нигез телдән аерылып чыккан барлык телләрдә дә очрарга мөмкин.

### § 41. *Казан* атамасының этимологиясе

Татар тел һәм тарих фәннәрендә этимологик яктан бик җентеклеп тикшерелгән сүз *Казан* атамасы дисәк, һич тә ялгыш булмас. *Казан* топонимының этимологиясе өстендә бик күп һәвәскәрләр һәм галимнәр шөгыльләнгәннәр, аны халык этимологиясе белән аңлату да бик иртә башланган.

Һәвәскәрләр *Казан* атамасы аш пешерә торган *казан* исеменнән алынган дип уйлаганнар. Бу фикерне раслау өчен, төрле риваятьләр уйлап чыгарганнар: янәсе елгада аш пешерә торган казанны юганда, ул суга төшеп киткән, шуңа күрә бу елганы *Казан* дип атаганнар. Елга исеменнән аның янында оешкан торак җиренә дә *Казан* дип исем кушканнар. Бу – *Казан* сүзенең этимологиясе турында иң күп таралган легенда.

*Казан* – (аш пешерү коралы) *казу* сүзеннән ясалган булса кирәк: *казыган/казан.* Бу мәгънәдәге *казан* сүзе төркиләрдә еш кулланыла дип уйлыйлар: *Газандаг* ‘Казан кебек тау’, *Газандәре* ‘Казан мәгарәсе’, *Газанкөл* ‘Казан күле’, *Газанбулаг* ‘Казан чишмәсе’ (Амирова, 1992: 7). *Казанчы* ‘казан төзәтүче’ топонимы Башкортстанда (Саттаров, 1985: 37) һәм Азәрбайҗанда очрый (Гейбуллаев, 1986: 36).

*Казан* атамасының килеп чыгышын аңлаткан карашларга тукталып үтик.

Иң беренче булып, *Казан* шәһәрен *каз* кабиләләре салган дигән караш урын алды. Әле XX йөзнең 70 нче еллар башында ук бу фикерне тарихчылар да, лингвистлар да уңай каршыладылар (Зәкиев, 1977: 39). *Казан* каз кабиләсе исеменнән һәм урын белдерә торган *-ан* кушылмасыннан тора дип уйладылар. Тик соңрак *каз* дигән кабиләнең чыннан да булуын һәм яшәгәнлеген исбат итә алмадылар. Бу төр аңлату халык этимологиясенә якын булып калды.

Г.Ф. Саттаров, *казан* сүзе суның елга төбен *казыган* (огузча әйтсәк, *казан*) дигәннән килә, дип аңлатты (Саттаров, 1985: 41).

1975 елда чуваш лингвисты В.Л. Егоровның «О времени возникновения Казани» дигән мәкаләсе дөнья күрде. Бу мәкаләдә автор Болгар дәүләтендә *Хасан/Хәсән* дигән хан булуын исбатларга алына, үзенчә исбатлый да, Казанның 1370 елда шул хан тарафыннан салынганлыгын күрсәтә, шәһәр үзенең төзүчесе исеме белән Хасан дип аталган дигән нәтиҗәгә килә. Хасан исеме, әкренләп, Казан формасын алган (Егоров, 1975: 86).

Бу фикергә Р.Г. Әхмәтьянов каршы чыга. Үзенең «О топониме *Казань* (по поводу статьи В.Л. Егорова «О времени возникновения г. Казани")» дигән мәкаләсендә шундый фикер әйтә: елга исеме шәһәр исеменнән була алмый, шәһәр исеме генә елга исеменнән килә ала, Хәсән дигән ханның булуы да исбат ителмәгән, шуңа күрә *Казан* атамасы *Хасан* хан исеменнән була алмый, ди ул (Ахметьянов, 1975: 133–136).

Чуваш галиме В.Л. Егоровның фикеренә таянып, Казан атамасының этимологиясенә күренекле топонимист Э.М. Мурзаев аңлатма бирергә тырыша. Ул В.Л. Егоровның, И.Г. Добродомовның, В.А. Кучкинның *Казан* атамасы *Хасан* исеме үзгәрүдән туган дигән фикерләрен яклавын белдерә. *Казан* атамасының нигезендә Идел буе халыклары *Хусан, Хасан, Азан, Озан, Ожанг, Кузон* дип әйтә торган *Хасан* исеме ята, дип белдерә ул (Мурзаев, 1982: 80).

А.Х. Халиков, Казан шәһәре, бигрәк тә Сөембикә манарасы, сиздермичә генә дошман килмәсен дип, якын-тирәне күзәтү хезмәтен үтәгән, шуңа күрә *Казан* атамасы *күзаң* (ягъни күзәтү, аң булып тору) сүзенә кайтып кала, дип аңлатты.

Р. Ногмани, *Казан* атамасын *каз* һәм *-ан* өлешләреннән тора дип раслап, күптән әйтелгән фикерне яңадан терелтә. Системалылыкка

мисал итеп, ул тагын *Кашан, Кабан, Ослан, Чирмешән, Хәзрән, Хорәсән* сүзләрен китерә. Болардагы -*ан* өлеше ‘урын, як’ мәгънәсен бирә ди һәм дәвам итә: *Казан* – каз ягы, *Кашан* – каш ягы, *Чирмешән* – чирмеш ягы, *Кабан* – каба ягы, ягъни киң як, *Ослан* – ыслы як, Хорасан – Хорас (кояш алласы) ягы һ.б. (Ногмани, 1990).

*Казан* топонимы *казан* дигән халык исеменнән, ягъни этнонимнан килә дигән дөрес караш та күптән урнашкан. Татар галимнәреннән бу фикерне, беренчеләрдән булып, Һ.В. Йосыпов язып чыккан. Ул *казан* сүзенең, беренче чиратта, төркмәннәр арасында этноним буларак кулланылуын исәпкә алган, ул сүзнең башкортларда ыру атамасы булуын күргән. Ул, *Казан* этнонимын йөртүчеләр Болгар дәүләтендәге Казан кенәзлеге халкының нигезен тәшкил иткән, дигән нәтиҗәгә килгән (Юсупов, 1971: 229–230).

Азәрбайҗан галиме Г.А. Гейбуллаев та *Казан* топонимының этноним булуын күрсәткән. «Азәрбайҗанда бер болгар кабиләсенең *казан* дигән этнонимы да бар, – ди ул, – этнонимнан калган *Казан* топонимы Кавказда, Украинада, Башкортстанда, Төркмәнстанда, Көнбатыш Себердә, Иранда, Төркиядә дә бар. XII гасыр чыганагында Әрмәнстанда бер *Казан* крепосте телгә алына» (Гейбуллаев, 1986: 35–36). Ләкин *казан* этнонимының этимологиясен ачу барыбер әле проблема булып кала биргән.

Шулай итеп, *казан* дигән лексик берәмлек күп мәгънәле сүз, ул бер-берсенә бик аз бәйләнгән берничә сүзгә килеп тоташа: 1) *казан* – аш пешерү коралы, 2) *казан* – дан *казан*, 3) *Казан* – кеше исеме, 4) *Казан* – шәһәр исеме, 5) *Казан* – елга исеме, 6) *казан* – халык, этнос исеме.

Төркиләргә типик булган этнонимнар ясалышы системасын өйрәнү барышында, без *казан* сүзенең фонетик вариантлары төрле чорларда төрле регионнарда кулланылу үзенчәлекләрен чагылдырган материаллар тупладык. Аларны төркичә кушма сүзләр ясалу системасына салып тикшергәч, *Казан* сүзенең этимологиясе үзеннән-үзе аңлашыла.

*Казан* атамасы русларның Львов елъязмасында һәм В.Н. Татищев хезмәтләрендә *Кусян* дигән вариантта бирелгән. Идел буе халыкларында аның *Хусян/Кусян/Кузон* дигән варианты сакланган.

Менә шул фактлардан чыгып, без *кусян/кусөн/кусан* сүзендәге *ку/кыу* өлешен аерып алдык, ул борынгы төркичә ‘ак/аксыл’ дигән мәгънәдә кулланылган. Нинди дә булса бер сүзнең аергычы

булып килгәндә, *ку/кыу* лексемасы, үзенең ‘ак’ дигән мәгънәсен дә югалтып, аерылмышка ялганып киткән, шуның аркасында формасын да төрлечә үзгәрткән: 1) Урта Азиядә ул *ку* килеш сакланган: *куман/куса/кушан*, 2) Казакстанда, Идел–Уралда *ко* формасын алган: *косан, косак, коман,* 3) *кыусак* этнонимында ул *кыф/кып* булып үзгәргән: *кыфсак/кыфчак,* соңрак *кыпчак*, 4) бик борынгы чорда башына кар яткан кыя тауларны (иске төркичә кыя тау *кәс* дип йөртелгән; *кыя* сүзе дә *кәс* сүзе дә *кыю/кисү* сүзеннән ясалган) *кыраукас* яисә *кыукас* дип аталганнар, *кыукас* лексемасы *кафкас* формасын алган, болгар-татарда ул *каф тавы* дип атала. Димәк, бу очракта *кыу/ку* сүзе *каф* булып киткән.

*Кусан/косан* сүзендәге *сан* өлешен, нинди тарихи факттан чыгып, *сөн/сүн* этнонимының үзгәргән варианты дип карадык соң? Ни өчен *кусан/косан* сүзе ‘ак сөн’ мәгънәсен бирә дигән фикергә килдек? Сәбәбе шунда: *кусан /кушан* (русча хезмәтләрдә аның *кушан* формасы гына кабул ителгән) сүзенең ‘ак сөн’ булуы русча язылган тарихи хезмәтләргә теркәлеп калмаган диярлек, шулай да кусаннарның дәвамы булган *эфталитларны* параллель рәвештә *ак сөннәр/ак хуннар* дип атап йөртү гадәти күренешкә әйләнгән. Димәк, эфталитларның элгәрләре булган кусаннар да ак сөннәр булганнар, аның өстенә *кусан/кушан/косан* сүзе этимологик яктан да *ак сөннәр* дигән сүз була (Закиев, 1998: 110). 1980 еллар ахырында безнең бу фикерне шикләнмәслек итеп раслаган чыганак табылды: *кусан/кушан* исемен йөртүчеләрне Византиянең VI гасырда яшәгән язучысы Прокопий Кесарийский ‘аксыл сары сөннәр’ икәнлеген теркәп калдырган (Прокопий Кесарийский, 1876, Г. Дистунис аңлатмасында).

Кусаннар бик борынгы заманнарда ук Идел–Уралда да, Урта Азиядә дә яшәгәннәр булса кирәк, бу кабиләләрнең үзара аралашуы өчен уңайлы су юлы да булган: Урал, Идел, Каспий. Шулай да бу кабиләләр *кусан* исемен Идел–Уралда алганнардыр, чөнки *ку-сан* ‘ак сөн’ булу өчен, аларның төньяк киңлекләрендә яшәүләре кирәк. Урта Азиядә дә аларның ак тәнле булулары галимнәрне бераз гаҗәпләндергән. Урта Азияне өйрәнгән галим Г.Е. Грумм-Гржимайло да үзенең «Белокурая раса в Средней Азии» дигән мәкаләсендә *өсөн/усунь, асиан/кусан* һәм *хагяс (сак/һакас)* кабиләләре, Урта Азиядәге башка төркиләрдән аермалы буларак, зәңгәр (яшел) күзле һәм аксыл (сары) чәчле булганнар ди, һәм моның гадәти булмаган хәл икәнен дә төшенә (Грумм-Гржимайло, 1998, изд. 1909: 342).

Тарих фәнендә Урта Азия кусаннары ныграк өйрәнелгән. Шундый мәгълүмат сакланган: кусаннар б.э.к. II гасырда, *өсөннәр (усуньнар)* белән бергә, Урта Азиягә төньяктан килгәннәр (История таджикского народа, 1965: 309) һәм *тохарлар* белән бергәләп, Грек-Бактр дәүләтен җимергәннәр, бактрларны А. Македонский китереп утырткан греклардан азат иткәннәр. Димәк, кусаннар/кушаннар Идел–Уралда да, Урта Азиядә дә яшәгәннәр. Фирганә янында бу *кусаннар/кушаннар* төзегән шәһәр *Касан* дип исемләнгән, аның янында *Касансай,* безнеңчә әйтсәк, *Касансу* елгасы ага.

Менә шундый фактларны бергә туплап карагач, без Идел буендагы *Косан/Кошан* шәһәрен *кусан/кушан* кабиләләре төзәгән дигән нәтиҗәгә килдек. Кайбер галимнәр *кушаннар* иран телле кабилә ич, ягъни Казан шәһәрен иран телле халыклар төзегән булып чыга, дип, каршы килделәр.

Мондый сорауларга түбәндәгечә җавап бирү кирәк: беренчедән, *косан* – төрки сүз, димәк, аның иран телле халыкны атавы мөмкин түгел, икенчедән, *косан/кусан/кушан* кабиләләре *үсүн/өсөн* (*ас-сөн*), *тохар* (*даг-ар* ‘тау кешеләре’) һәм *алан/ас* кабиләләре белән бер үк халык булганнар, бер телдә сөйләшкәннәр (Бартольд, 1963: 175–176; Будагов, 1947: 44). Тохарларның, алан-асларның, өсөннәрнең (ас-сөннәрнең) төрки булулары турындагы фикер соңгы елларда шик тудырмый. Яһүдиләр б.э.к. үк һәм хәзер дә төркиләрне *тохар/дагар* дип атаганнар һәм атыйлар, күп очракта *дагар* сүзенә үзләренең *-ма* дигән күплек кушымчасын кушып, төркине *дагарма* диләр.

Шулай итеп Казан шәһәре үзен төзегән халыкларның исеме белән *кусан/косан/козан* дип аталган. Шәһәрнең, авылларның үзен төзүче халык исеме белән аталышы еш очрый: *Суар, Биләр, Аслы, Косан.*

Тикшеренүләр күрсәткәнчә, *кусаннар/косаннар* Урта Идел, Түбән Кама тирәләрендә бик борынгыдан төпләнгәннәр. Алар ак расага караган халык булган (*кусан* – ‘ак сөннәр’).

Нәтиҗә ясап әйткәндә, биредә без *Казан* атамасының килеп чыгышын төрки этноним белән бәйләп анализладык һәм әлеге фикерне тарихи материаллар да раслый.

# ТАТАР ОНОМАСТИКАСЫНЫҢ БАШКА ТАРМАКЛАРЫ

## ТАТАР КОСМОНИМИКАСЫ

### § 42. Космонимика фәненә гомуми билгеләмә

Ономастика фәнендә күк йөзе һәм андагы җисемнәрнең атамаларын өйрәнә торган юнәлешне билгеләү өчен *космонимика һәм астронимика* терминнары кулланыла. Әлеге ике термин кайбер хезмәтләрдә мәгънә ягыннан тәңгәл итеп күрсәтелсә дә, сүзлекләрдә аларның аерымлануы күзгә чалына (Бондалетов, 1983: 224). Мәсәлән, Н.В. Подольскаяның «Словарь русской ономастической терминологии» хезмәтендә мондый билгеләмә бирелә:

Космоним – оним төре. Космик киңлек зонасын, галактиканы, йолдызлар системасын (йолдызлыкларны) атаган ялгызлык исеме. Мәсәлән: *Зур Магеллан Болыты* (Большое Магелланово Облако), *Җидегән йолдызлыгы* (Большая Медведица), *Бөркет йолдызлыгы* (Созвездие Орла), *Волопас йолдызлыгы* (Созвездие Волопаса), *Кыз йолдызлыгы* (Созвездие Девы), *Орион йолдызлыгы* (Созвездие Ориона) һ.б.

Астроним – оним төре. Аерым торган күк җисеменең, шул исәптән йолдыз, планета, койрыклы йолдыз (комета), астероид (планетоид) атамасын белдергән ялгызлык исеме. Мәсәлән: *Кояш, Ай, Җир, Меркурий, Тимер Казык йолдызы, Чулпан йолдыз (Венера), Марс, Вега, Эрос, Цецера; Энке, Фая, Галлея койрыклы йолдызлары* (кометалары) (Подольская, 1978: 199).

Шул рәвешле, астронимика (бор. грек. *ἀστήρ* – йолдыз + *ὄνομα* – атама) аерым күк җисемнәрен, ягъни йолдыз, планета һәм

аларның иярченнәрен, комета, метеорит һәм метеорит агымнарын, астероидларны атау өчен кулланылган ялгызлык исемнәрен өйрәнә торган тармак, ә космонимика (бор. грек. *κόσμος* – дөнья, галәм + *ὄνομα* – атама) кеше күзенә космик киңлек зонасында аерым төркем булып күренгән йолдызлыклар һәм аларның өлешләрен, галактикаларның атамаларын өйрәнә торган тармак буларак билгеләнә. А.В. Суперанская «космоним» терминын «үз эченә галактика, йолдызлар җыелмасы, томанлыклар, йолдызлыкларны җыйган термин» дип атый (Суперанская, 1973: 188). Астронимга ул күк җисемнәре – аерым бер йолдыз, планета, астероид, комета атамаларын кертә.

Астронимик терминнар космик киңлектәге җисем атамаларының бер өлешен тәшкил иткәнгә күрә, күк җисеме атамаларын өйрәнә торган тармакны, гомумиләштереп, *космонимика* дип атау дөресрәк булыр иде.

Шул ук вакытта космонимика кысаларында астротопонимика юнәлеше дә аерылып карала. *Астротопонимика* – планеталар, аларның иярченнәре һәм астероидлар өслегендәге объект атамаларын өйрәнә торган тармак. Бу атамаларның күбесе мемориаль сыйфатта булып, күренекле шәхес исемнәре белән аталган (мәсәлән, Меркурий өслегендәге эре кратерлар *Гомер, Гёте, Шекспир, Рафаэль, Достоевский, Толстой, Бетховен* исемнәрен алган). Бу атамалар халыкара астрономик оешма тарафыннан раслана һәм планеталар номенклатурасына кертелә. Астротопонимнар аерым планета, иярчен яки астероидка карата, шул җисем исеме белән бәйле рәвештә ачыклана (мәсәлән, селеноним – Җир иярчене Ай өслегендәге, марсионим – Марс өслегендәге, меркурионим – Меркурий планетасы өслегендәге объектларның атамасы).

Билгеле булганча, ономастик берәмлекләр төрле халыкларның иң беренчел яшәү урынын һәм күченү процессларын, үзара мәдәни һәм икътисади, сәяси элемтәләрен, иң борынгы тел халәтен һәм диалект үзенчәлекләрен билгеләргә ярдәм итә. Шул исәптән, космонимик терминнар да, әлеге максатка бәйле рәвештә, борынгы кешеләрнең дөнья һәм галәм төзелеше турында иң беренчел күзаллауларын, көнкүрешен, фәлсәфәсен, мифологиясен һәм халык авыз иҗатын өйрәнүдә әһәмиятле чыганакларның берсе булып тора. Космонимик берәмлекләрдә тел барлыкка килгән һәм яңа атамалар кулланышка кергән борынгы чорлардагы күк йөзенең төзелеше,

планета һәм йолдызларның Җир планетасына мөнәсәбәтле урыны турында мәгълүматлар әлегә кадәр яңартылмаган. Мәсәлән, безнең эрага кадәр йөз мең еллар элек борынгы халыклар күк йөзендә сурәте аюга охшаган йолдызлар җыелмасы күргән һәм шуңа күрә бу йолдызлыкны Аю йолдызлыгы дип атаган. Сиксән мең еллар элек йолдызларның хәрәкәте нәтиҗәсендә бу сурәт үзгәрә башлаган, әмма Аю йолдызлыгы атамасы бүгенге көнгә кадәр кайбер телләрдә сакланып калган. Димәк, б.э.к. йөз мең еллар элек нигез баба телдә (ностратик телдә) инде *аю* сүзе булган. (Карпенко, 1981: 184). Бу мәгълүмат исә тел тарихын, телләрнең килеп чыгышының хронологик чикләрен шактый үзгәртә (С.А. Старостин, А.А. Зализняк телләрнең праностратик халәтен б.э.к. 20–23 мең еллар элек дип билгелиләр) (Старостин, 207: 779). Төрки халыклар исә әлеге йолдызлыкны Җидегән йолдыз дип атаган.

Икенче яктан, космонимик терминнарда халыкларның үзара сәяси, мәдәни, икъдисади элемтәләре дә ачык чагыла. Еш кына беренчел атамалар югалып, алар урынына чит телләрдән килеп кергән алынма сүзләр кулланыла башлый. Бу күренеш аеруча Идел буенда ислам дине таралган (X гасыр) һәм Европа фәннәре тәэсир иткән чорда (XIX–XX гасырлар) чагылыш таба. Татар теленә гарәп теле яисә рус теле аша латин теленнән алынган атамалар килеп керә, дәреслекләрдә урын ала. Мәсәлән, Чулпан (гар. Зөһрә) йолдызны атаган *Венера* сүзе, Зөхәл (гар.) атамасын алыштырган *Сатурн* сүзе иҗтимагый процесслар нигезендә телдә барган күренешләрне ачык сурәтли.

Астрономия, фән буларак, бик борынгы – беренче астрономик күзәтүләр б.э.к. II меңьеллыкларда яшәгән шумер-аккадлы Вавилон дәүләтендә үк барлыкка килгән. Борынгы Кытайда исә аннан да элегрәк – б.э.к. III меңьеллыкта ук император сараенда астроном вазифасы булган, легендалар б.э.к. 2137 елда кояш тотылуны алдан әйтеп бирә алмаган ике астрономның үтерелүе турында хәбәр итәләр (https://ru.wikipedia.org/wiki/История_астрономии). Борынгы Мисырда, борынгы Грециядә, Һиндстанда, инклар һәм майя цивилизацияләрендә – һәрберсендә күк җисемнәре турында тупланган белемнәр язу (кодлар) барлыкка килгәннән соң, теркәлгән. Шул рәвешле, космонимик атамалар борынгы заманнардан бирле сөйләмә һәм язма формада үсеп-үзгәреп, камилләшеп, безнең чорга килеп җиткәннәр һәм дөнья телләрендә төрле стильләрдә актив

кулланылалар. Һичшиксез, һәрбер астроном үзенә кадәр булган белемнәр белән танышкан, аларны үзенең эшчәнлегендә кулланган.

Лингвистик аспекттан караганда татар космонимикасы – ономастика фәнендә аз өйрәнелгән өлкәләрнең берсе. Күк җисемнәре атамалары борынгы төрки язма истәлекләрдә үк (Орхон-Енисей язмаларында, «Котадгу белег», «Диване лөгатет-төрк», «Кыйссаи Йосыф» һ.б. әсәрләрдә) теркәлеп калган. Шул вакытлардан алып, бүгенге көнгә кадәр йолдызлы күк галим, шагыйрь һәм язучыларның, ягъни телне статик һәм динамик халәтендә кулланучыларның игътибарын үзенә җәлеп итә. Татар телендә бу атамаларны лингвистик яктан өйрәнү, төркемләү, башка төрки телләрдәге кебек үк, бары XX гасырның икенче яртысында гына башлана һәм шактый сүлпән бара. Монда, аларны фәнни әйләнешкә кертеп җибәрүдә татар халкының бөек мәгърифәтчесе Каюм Насыйриның роле зур икәнен әйтеп үтәргә кирәк (Насыйри, 1975: 8). XX гасырның икенче яртысында (60 нчы елларда) бер үк вакытта диярлек, казак, татар, башкорт, чуваш телендәге космонимнарны өйрәнгән мәкаләләр дөнья күрә (Ю. Немет, Т. Дж. Джанузаков, В.А. Никонов, Н.Х. Максютова, Д.К. Нуржанова, М.Н. Юхма, Г.Х. Әхәтов һ.б. хезмәтләре). Биредә «Идел буе ономастикасы» дип аталган конференция материалларын атап үтү зарур: 1973 елда Уфа шәһәрендә басылып чыккан «III Идел буе ономастикасы» конференциясе материалларында В.А. Никоновның «Идел буе космонимиясе» һәм Н.Х. Максютованың «Башкорт космонимиясе» дип аталган шактый саллы мәкаләләре дөнья күрә (Ономастика, 1973: 373–382). Бу – космонимиканы ономастика фәне кысаларында өйрәнүнең башлангычы гына була әле. 1974 елда Татарстан Мәгариф министрлыгы раславы нигезендә Мәхмүд Галеев һәм Адлер Тимергалин тарафыннан русча-татарча астрономия терминнары сүзлеге басыла (Галеев, 1971: 3). Бу хезмәтнең ономастика фәне өчен дә әһәмияте бик зур, чөнки анда планета, йолдыз атамаларының борынгы исемнәре дә күрсәтелгән. «Татарча астронимия терминнары да шактый эшләнгән, ләкин астрономия терминнары моңа кадәр эзлекле бер системага салынмаган, атама сүзләр чагыштырылмаган һәм бергә тупланмаган, ягъни таркау хәлдә иде. Шуның аркасында терминнарны дөрес кулланмау очраклары да бар, матбугатта аерым атамаларның төрле вариантлары һәм синонимнары йөри, кайбер очракларда исә тел хәзинәсендә электән булган

сүз онытылып, бер дә кирәксезгә ясалма терминнар кулланыла. Хәлбуки, төрки телләрдә, гарәп теле йогынтысында, борынгыдан ук фәнни астрономик терминнар эшләнгән булган. Аларның байтагы, соңыннан интернациональ характер алып, барлык телләрнең терминологик байлыгына әверелгән (мәсәлән: *Альголь, Алькор, Альмукантарат, Бетельгейзе, зенит, надир* һ.б.). Шул ук вакытта җанлы телдә байтак кына йолдызларның һәм йолдызлыкларның үз исемнәре булган (*Көянтә – Орион, Иләк – Плеяда, Акбүзат һәм Күкбүзат йолдызлары, Әвернә – Лебедь* кебекләр). Төзүчеләр бу атамаларны сүзлеккә кертергә тырыштылар», – дип яза авторлар (Галеев, 1974: 4).

Татар телендәге космонимнарны өйрәнүгә диалектолог галимнәр дә аерым өлеш кертә. Диалекталь лексиканы өйрәнгәндә, йолдызлы күк йөзен тасвирлаган кайбер атамалар Г.Х. Әхәтов, Р.Г. Әхмәтьянов, Р.С. Барсукова, Ф.С. Баязитова, Ф.Г. Гарипова, Л.Т Мәхмүтова, И.С. Насипов, Д.Р. Рамазанова, З.Р. Садыйкова, Д.Г. Тумашева, Т.Х. Хәйретдинова, Ф.Й. Йосыпов, Э.Х. Кадирова һ.б. хезмәтләрендә дә чагылыш таба.

Татар халкының антропонимик системасында космонимик күзаллаулар белән бәйле кеше исемнәренең кулланышы Г.Р. Галиуллина мәкаләсендә җентекле яктыртыла (Галиуллина, 2008: 197–204). *Кояш, көн, ярук, таң, тәңре* һ.б.ш. космонимик лексемаларның татар антропонимикасында гасырлар дәвамында сакланган үз урыны барлыгын искәртеп, галимә бүгенге көндә дә әлеге лексемалардан *кояш* һәм *таң* компонентларының татар исемнәрендә кулланылганын билгели.

Күк йөзенә мөнәсәбәтле лексемаларның урта гасыр язма истәлекләрендә кулланылыш үзенчәлекләрен исә Э.Х. Кадирова мәкаләсендә күрергә мөмкин (Кадирова, 2010: 334–336). Галимә бу лексемалар арасында кайберләренең төрки мифологиягә бәйле булуын искәртә (мәсәлән, «Хөсрәү вә Ширин» поэмасында Мәррихның (Марсның) Мәликәнең башкаларны тар-мар итүенә күктән шатлануы күренеше). Автор күзәтүендә й*олдызлык* мәгънәсендә килгән «бурҗ», «бурҗис» сүзенең кулланылышы да үзенчәлекле.

Россия Фәннәр академиясенең Тел белеме институты тарафыннан чыгарылган «Төрки телләрнең чагыштырма-тарихи грамматикасы. Лексика» (2001), «Төрки телләрнең чагыштырма-тарихи грамматикасы. Баба төрки-нигез тел. Тел мәгълүматлары буенча

баба төрки этносның дөнья картинасы» (2006) дип аталган академик хезмәтләрдә борынгы төрки халыкларның күк йөзе, күк җисемнәре һәм күренешләре турындагы күзаллауларына аерым бүлекчә багышланган (Сравнительно..., 2001: 50–67; Сравнительно..., 2006: 326–352). Биредә төрки телләрдәге кайбер космонимик атамалар тарихи планда яктыртыла.

Күк йөзендәге кеше күзе күрә алган алты меңгә якын йолдыз арасыннан фәкать ике йөз җитмеш бише генә исем-атама йөртә. 1922 елда Халыкара Астрономия Берлегенең *(Международный астрономический союз (МАС))* I съезды уздырыла. Әлеге корылтайда күк йөзе сферасы 88 йолдызлыкка бүленеп, фәнни әйләнешкә кертелә һәм яңа ачылган күк җисемнәренә исем яки номерлар бирү җайга салына.

Шул рәвешле, космонимик лексиканы өйрәнү татар теленең сүзлек составын барлау максатыннан гына түгел, гомумән, татар халкының дөнья һәм галәм төзелеше турында иң беренчел күзаллауларын, көнкүрешен, фәлсәфәсен, мифологиясен һәм халык авыз иҗатын өйрәнү өчен дә әһәмиятле юнәлешләрнең берсе булып тора. Шул ук вакытта космонимик терминология – ономастика фәне өчен дә кыйммәтле чыганакларның берсе, чөнки күк йөзендәге җисем атамалары, ялгызлык исемнәре буларак, телдәге онимлаштыру күренешенең иң борынгы закончалыкларын ачарга ярдәм итә.

## § 43. Татар телендә космонимик лексиканың үсеш тарихы

Кешелек тарихы зур үсеш юлы кичкән. Билгеле булганча, дөньяны танып-белү тәҗрибә аша бара, бу тәҗрибә буыннан буынга тел ярдәмендә тапшырыла килгән. Бик борынгы заманнардан ук кешеләр йолдызлы күкне күзәткәннәр, аны аңларга, тасвирларга тырышканнар, күк йөзе һәм галәм турында йөзләрчә ел бөртекләп җыелган белемнәрне тормыш-көнкүрештә кулланырга омтылганнар. Йолдызлы күк кешегә илһам чыганагы буларак та, гамәли ихтыяҗларны канәгатьләндерү чарасы буларак та хезмәт иткән. Кешеләр йолдызларның, кояш һәм айның күк йөзендәге торышы-хәрәкәтенә карап, урман-кырларда, иксез-чиксез сахра киңлекләрендә адашмаска, юл табарга һәм аны билгеләргә өйрәнгәннәр, һава торышын алдан әйтеп бирүне җайга салганнар, диңгез киңлекләрендә иркен йөзәргә мөмкинлек булдырганнар, яңа илләр,

материклар ачканнар. Күкне илаһилаштыру, аны аллалар белән бәйләү һәм кешенең тормышына, язмышына йолдызларның йогынты ясавы турындагы белемнәр бик борынгы чорларда ук барлыкка килгән һәм бүгенге көнгә кадәр халык аңында сакланган. Димәк, йолдызлы күк турындагы белемнәрнең кешелек тарихында иң борынгылардан булуы, бу белемне барлыкка китергән лексик байлыкның телнең иң тәүге катламнарына каравы бәхәссез.

Тәүлек барышында көн һәм төн алышынуы белән бәйле астрономик күренеш тереклек ияләренең яшәү закончалыкларын билгеләп, шуңа күрә борынгы кешеләр, иң беренче чиратта, кояшның яки айның горизонттан күтәрелү биеклегеннән чыгып, вакытны билгеләргә өйрәнгәннәр, вакыт белән нәкъ шушы аллалар – Кояш һәм Ай идарә итә дип уйлаганнар. Борынгы төркиләр иртән Кояшны сәламләү, кич белән Айны каршылау өчен аерым догалар-ялварулар әйткәннәр. Шунысы кызыклы: изге кояшка карата табу сүзләр гамәлдә булган, мәсәлән, «кояш батты» дип әйтү тыелган, «кояш баеды» дип әйтергә рөхсәт ителгән (Сравнительно..., 2006: 333).

Төрки космонимиканың үсеш тарихы бик борынгы чорларга – Алтай һәм Урал-Алтай тел бердәмлеге чорына ук барып тоташкан булуы мөмкин, чөнки аерым космонимик берәмлекләрнең урталыгы күзгә ташлана. Мәсәлән, *күк, тәңир* (төрки) – *тэнгэр* (монгол) – *ку* (япон) – *кава* (мари) һ.б. Шулай да күпчелек төрки космонимнар борынгы төрки чорга карый. Галәм һәм аның төзелеше турындагы уртак күзаллаулар системасы булу төрки халыклар арасында уртак космонимик катлам барлыкка китергән. Язма рәвештә теркәлеп калган иң борынгы космонимик берәмлекләр рун язулы Орхон-Енисей истәлекләрендә очрый (Древнетюркская..., 1993: 176; Малов, 2012: 93).

Күк җисемнәре атамалары XI гасыр истәлеге Йосыф Баласагунның «Котадгу белег» (Баласагунский, 1983), Әхмәт Югнәкинең «Һибәт-ел хәкаикъ» (Бертельс, 1945: 22), кытай теленнән борынгы уйгыр теленә тәрҗемә ителгән «Алтын йарук» (Малов, 1951: 145) әсәрләрендә дә сакланып калган. Татар халкының күренекле язучысы, галиме Адлер Тимергалин күрсәтүенчә, «Котадгу белег»тә башлангыч астрономик белемнәр бирелә, зодиак йолдызлыклары һәм планеталар телгә алына. «Автор *(Й. Баласагунлы)* Сатурн планетасының ул вакытларда билгеле булган башка планеталардан ераграк урнашканлыгын әйтә. Ул йолдызлар түгәрәк

буенча хәрәкәт итәләр, кайчагында бер-берсе белән көрәшкә ташланалар һәм җиңелгән йолдыз күктән атылып төшә, дип исәпли. Автор Айның тулган чагы аның Кояшка каршы вакытка туры килүен дә белә» (Тимергалин, 2007).

Төрки халыкларның гореф-гадәтләре, тел үрнәкләре тупланган җыентык – Мәхмүт Кашгариның «Диване лөгатет-төрк» әсәре дә ономастика фәне өчен кыйммәтле чыганакларның берсе булып тора (Кашгари, 1960; 1961; 1963). Әлеге язмаларда тупланган тел байлыгы борынгы төрки сүзлектә чагылыш тапкан (ДТС, 1969). Сүзлек VII–XIII гасырларда язылган төрки язма истәлекләрнең лексик байлыгын – 20 000 сүз һәм сүзтезмәне үз эченә ала. Шулар арасында космонимнар аеруча игътибарга лаек, чөнки алар төрки халыкларның галәм төзелешенә бәйле борынгы ышануларын, йолаларын чагылдыралар. Сүзлектәге космонимнарны казак теленә мөнәсәбәттә тикшергән галимнәр Р.А. Авакова, Ж.Г. Нукежанова *ай, йолдыз, күн (кояш), Барша, Мүштәри, Каракуш, Сүнбелә, Үлкәр, Йетигән, Тимирказык, Бакырсокым*, *Кызыл йолдыз, Алтын йулдыз, Йыгаш йулдуз, Сув йулдыз, Сәбит йулдыз* һ.б. космонимнарны күрсәтәләр (Авакова, 2013: 49).

А.Х. Нуриева тарафыннан төзелгән «Тарихи грамматика» әсбабында «Китаб әт-төхфәт үз-үзәкийә...» сүзлегеннән (XIV гасыр) түбәндәге күк җисемнәре санала: Ай *(Луна)*, Айдын, Айдынлык *(лунный свет)*, тулун ай *(полнолуние)*, Ак айгыр *(Сириус)*, Арык так *(Близнецы)*, Йәтикәр вә Үлкәр *(Стожары)*, Йашык йамлы *(Канопус, Солнце)*, Кыйыр, кыр күк *(небо)*, көн/көнәш *(Солнце)*, Сибәк / Тимер Казык *(Полярная звезда)*, Чулпан *(звезда)*, Икки бүзат *(название звезды)* һ.б. (Нуриева, 1982: 8).

Идел буе Болгар дәүләте чорында (X–XIII гасырлар) астрономия фәненең аеруча алга киткәнлеге билгеле. Әлеге чорда ислам дине Идел буена үтеп кереп, дин белгечләре дин календаренә туры килгән ритуал гореф-гадәтләрнең төгәл үтәлүен күзәтеп торырга тиеш булганнар. Идел буендагы география һәм климат шартлары исә (вакытның кәгъбә вакытына туры килмәве, җәйге төннәрнең кыска, кышкы төннәрнең озын булуы, төрле ел фасылларына туры килгән ураза көннәрен төгәл билгеләмәү, биш вакыт намазның дин кушкан вакытта үтәлмәве һ.б.) дин үсешендә шактый катлаулылык тудырган. Бу үзенчәлекләрне ачыклау өчен хәтта гарәп илләреннән дә сәяхәтчеләр килгән (мәсәлән, Ибне Батута). Бу чорда вакытны

вертикаль (текә) утыртылган казыкның күләгәсенә һәм күктәге Кояшның биеклегенә, ә төннәрен Зур Җидегән йолдызлыгының торышына карап чамалаганнар. Шул ук вакытта Көнчыгыш мәдәнияте Идел буена астрономия, йолдыз багу, йолдызга карап фал ачу, язмышны әйтеп бирү кебек һөнәрләрне дә алып килә. Көнчыгыш гарәп илләрендә XI–XVI гасырлар астрономия фәненең чәчәк ату чоры буларак билгеле (Насыйр әд-дин әт-Туси, Котб әд-дин әш-Ширази, Мөаййад әд-дин әл-Урди, Мөхәммәд бине әш-Шатир, Җәмшид Гыйяс әд-дин әл-Каши, Галәветдин Гали бине Мөхәммәд әл-Кошчы һ.б. атаклы астрономнарның яшәгәнлеге фәнгә мәгълүм). Болгар ханнарының әлеге белгечләрне Көнчыгыш илләреннән махсус чакыруын яисә җирле шәкертләрне укырга җибәргән булуы мөмкин. Һәрхәлдә, тарихчы галим Г.М. Дәүләтшин күрсәткәнчә, Болгар шәһәренең үз астрономнары булган (Давлетшин, 2015: 76). Болгар дәүләте Батый хан тарафыннан җимерелеп, бераздан яңадан торгызылгач та, астрономнарның Болгар шәһәрендә яшәгәнлекләре билгеле. Шундыйларның берсе – Болгар җәмигъ мәчетендә вакыт бүлүче – әлфәләки (фәләк – гар. *язмыш*) – вазифасындагы астроном Мәсгуди әл-Болгари булган. Ул Болгар шәһәреннән 700 чакрымда торып, астролябия, квадрант, секстант кебек приборлар кулланган һәм төн озынлыгын, намаз һәм ураза вакытларын билгеләгән. Бу турыда күренекле гарәп галиме, географ, тарихчы Ибне Фадлаллах әл-Гомәри (1301–1349) язып калдырган (Давлетшин, 2015: 78).

Урта гасырларда (монгол яуларыннан соң) язылган әсәрләрнең (Котбның «Хөсрәү вә Ширин», Харәзминең «Мәхәббәтнамә», Мәхмүд Болгариның «Нәһҗел-фәрадис» һ.б.) телендә дә космонимнар кулланыла, әмма галәм җисемнәрен күбрәк гарәп-фарсы алынмалары белән белдерү өстенлек итә, төрки эквивалентларының әдәби телдән төшеп калу процессы күзәтелә. Әлеге чорда иҗат ителгән әсәрләр арасында Сәйф Сараиның «Сөһәйл вә Гөлдерсен» әсәрен күрсәтү урынлы. Бу әсәрдә

*Сөһәйлни күрдейү әйләнди бер тик,*
*Көнәш гирдиндә йүргән мисле йер тик.*

Хәзерге телдә:

*Сөһәйлне күргәч әйләнде бер тапкыр,*
*Кояш тирәсендә йөргән әйтерсең җир кебек.*

дигән юллар, галимнәр билгеләвенчә, Җирнең Кояш тирәсендә әйләнүен төркиләрнең Европада Николай Коперник фаразлавына караганда, йөз елга алданрак белүләрен күрсәтә.

Э.Х. Кадирова күрсәтүенчә, урта гасыр язма истәлекләрендә *Кояш, Ай, Зөһрә (Чулпан) йолдыз, Иләк йолдыз, Өлкәр, Җидегән йолдыз, Казык йолдыз* һ.б. атамалар иске төрки язма истәлекләр телендә еш кулланыла, кайберләре кешенең тышкы гүзәллеген сурәтләү чаралары составында актив килә, планета исемнәре гарәп телендә бирелә (Кадирова, 2010, 334–336).

Кызганыч ки, XVI гасырда ислам илләрендә дә астрономия фәне үсүдән туктый. Бу чорда Казан ханлыгы Рус дәүләте тарафыннан яулап алына һәм җирле мәдәният үсәр өчен шулай ук шартлар юкка чыга. Бары XIX гасырда гына татар телендәге фән үсә башлый, әмма астрономиягә караган төрки атамалар урынына традицион рәвештә гарәп теле берәмлекләре кулланыла яисә рус теле аша һинд-Европа (латин) телләреннән алына.

Совет елларында (1932 елдан башлап) космонимик терминнарны үзенә туплаган астрономия фәне мәгариф системасында мәҗбүри укытыла торган фәннәр исемлегендә иде. Милли мәктәпләрдә астрономия фәне татар телендә укытылып килде (атамаларның да татарча кулланылышы күздә тотылды). 1993 елда исә бу фән мәҗбүри укыту исемлегеннән алынды, аерым мәктәпләрдә генә факультатив дәрес яки түгәрәк рәвешендә алып барылды. 2017 елда астрономия фәне яңадан мәҗбүри укытыла торган фәннәр исемлегенә кертелсә дә, егерме елга сузылган бушлык нәтиҗәсендә, татар телендәге астротерминологик база югалу алдында калды. Бүгенге көндә татар әдәби телендәге космонимик терминнар нигездә рус теле аша һинд-Европа телләреннән алына һәм татар теленең алынма лексик фондына карый, аерым очракларда рус теле сүзләре татарчага тәрҗемә итеп бирелә.

Космонимик лексика татар халык иҗатында, легенда-мифларда, җырларда, мәкаль-әйтемнәрдә сакланып калган. Әлеге тармакны җентекле өйрәнүче галим М.Х. Бакиров, еш кына, үзенең хезмәтләрендә космонимик катламның шактый үзенчәлекле булуы турында яза: «Космогоник легендаларда сүз дөньяның, тереклек бишеге булган җирнең, күк һәм күк җисемнәренең ничек барлыкка килүе турында бара. Аерым алганда, безнең бабаларыбызга җирнең барлыкка килүе хакында Себер ягында таралган борынгы

космогоник легенда билгеле булган. Анда болай диелә: «Элекке заманнарда дөнья тоташ судан гына торган. Кешеләр әле булмаган. Суда балыклар һәм су кошлары гына яшәгәннәр. Шунда бер үрдәк, су төбенә чумып, борыны белән бер кисәк балчык алып чыккан. Бу зурайган һәм шуннан җир хасил булган, ди» (Татар халык иҗаты. Риваятьләр..., 1987: 232). Икенче бер легенда буенча, җир үгез мөгезендә тора, үгез исә иксез-чиксез суда йөзеп йөрүче Кер-балык өстендә, дип фараз ителә. Җир тетрәүләре шул үгез башын як-якка чайкаудан хасыйл була имеш.

Янә килеп, халык аңында шулай ук күк белән җирнең кайчандыр үзара тоташкан-кушылган булуы турындагы борынгы мифологик ышануга нигезләнүче легенда да сакланып калган. Анда күк йөзе, бер ананың пычранган бала чүпрәген (варианты: баланың йомшак җирен сөрткән учма саламын) күк белән җир арасына кыстырып куюына гарьләнеп, югарыга менеп киткән, диелә. Җир белән күкнең аерылуы бик самими рәвештә тасвирланса да, берничә урында язып алынган әлеге текстта, асылда, дөнья мифологиясе белән уртак мотив турында сүз бара» (Бакиров, 2007: 70).

Тарихчы, язучы Мурад Аджи фикеренчә, төрки космонимика халыкларның яшәү рәвешендә дә чагыла. Төркиләр изге торак (храм) төзегәндә, анда берничә катлам-ярусны билгелиләр: караңгы төсләр Топрак йолдыз *(Сатурн)*, кызгылт-сары төс – Йыгач *(агач)* йолдыз *(Юпитер)*, кан төсендәге кызыл катлам – Ут йолдыз *(Марс)* турында сөйли. Иң югарыда кояш кебек якты төсле Алтын йолдыз *(Венера)* урнашкан (Аджи, 2005:12).

Шул рәвешле, күчмә тормыш алып барган төркиләрнең күк җисемнәренә аеруча игътибарлы булулары ачыклана. Сакланып калган иң борынгы төрки язма истәлекләрдә – б.э.ның VI–VII гасырларына караган руник Орхон-Енисей язмаларында ук космонимик терминнарның кулланылуы мәгълүм. Бу лексик байлык төркиләргә илһам чыганагы буларак та, гамәли ихтыяҗларны канәгатьләндерү чарасы (ориентир һәм сынамышлар) буларак та хезмәт иткән. Утрак тормышка күчкәч, кайбер халыкларда, шул исәптән татарларда да, күп кенә космонимик терминнар халык хәтереннән җуелган яисә әдәби телдә аларны алынма сүзләр алыштырган.

## § 44. Татар телендә космонимнарны төркемләү

Космонимнарны төркемләү мәсьәләсе тел белемендә бүгенге көнгә кадәр житәрлек күләмдә эшләнмәгән. Аерым хезмәтләрдә генә бу мәсьәлә яктыртыла һәм, нигездә, сүзлек байлыгын төркемләүдәге тематик классификация файдаланыла. Мәсәлән, К.Г. Ароновның казак теле космонимнарын өйрәнүгә багышланган фәнни хезмәтендә әлеге принципка таянып, җиде төркем аерыла: 1) аерым йолдызларга караган космонимнар; 2) йолдызлыкларга караган космонимнар; 3) йолдыз төркемнәренә караган космонимнар; 4) зодиак йолдызлыкларына караган космонимнар; 5) кояш системасы күк җисемнәренә караган космонимнар; 6) комета һәм метеорларга караган космонимнар; 7) космос һәм галактикага караган космонимнар (Аронов, 1992: 7). Бүленештән күренгәнчә, телдәге космонимик рәт тулы булган очракта, бу классификация универсаль, әмма барлык телләргә дә бер дәрәҗәдә туры килеп бетми, чөнки кайбер төркем космонимнарның атамасы телдә бөтенләй булмаска да мөмкин.

Рус теле белеме һәм ономастика өлкәсендә эзләнүләр алып барган галим Г.Ю. Сызранова космик онимнарны космоним һәм астроним дигән ике төркемгә бүлеп өйрәнергә тәкъдим итә (Сызранова, 2013: 171). Астронимнар – күк йөзендәге аерым планета һәм йолдыз атамалары. Калган барлык галәм җисемнәре космоним буларак төркемләнә. Мондый бүленеш шулай ук космонимнарны төрле аспектларда өйрәнүне чикли.

Башка хезмәтләрдә (М.Э. Рут (1987), В.А. Никонов (1973), Ю.Г. Карпенко (1981) һ.б.) космонимнарны төркемләүнең лексик-семантик модельләре яки номинацияләү принциплары буенча төркемләү чагылса да, тулы классификация очрамый.

Шул рәвешле, татар теле космонимнарын төркемләү бүгенге көндә дә татар ономастикасы фәне алдында торган бурычларның берсе булып кала.

Әлеге хезмәттә космонимнарны төркемләүгә без ике аспекттан чыгып якын киләбез. Беренчесе – генетик классификация, ягъни космонимик онимнарны килеп чыгышы ягыннан төркемләү. Лингвистика фәнендә әлеге аспект төп, нигез алымнарның берсе булып тора. Икенче аспект – лексик-тематик классификация. Биредә казак теле космонимикасын этнолингвистик яссылыкта өй-

рәнгән галим К.Г. Ароновның тематик төркемнәре нигезендә татар телендә булган космонимнарны билгеләү күздә тотыла.

Киләчәк хезмәтләрдә чагыштырмалы ысул нигезендә Идел буе телләре (төрки, славян һәм фин-угор) һәм Идел буе төрки телләре (татар, башкорт, чуваш) өчен уртак космонимнарны өйрәнү, тарихи-чагыштырмалы ысул ярдәмендә космонимнарның хронологик куллану чикләрен ачыклау, этнолингвистик эзләнүләр дә кызыклы нәтиҗәләр бирергә мөмкин.

Космонимнар арасында бик борынгы һәм чагыштырмача яңа атамаларны аерып карау мөһим. Борынгы атамалар, нигездә, телескоп барлыкка килгәнчегә кадәр булган чорда, ягъни кешенең табигый күз күреме җитәрлек дәрәҗәдә ачык күргән күк җисемнәрен атыйлар. Аларны икенче төрле «халык космонимнары» дип тә йөртәләр. Халык мондый космонимнарга охшату-чагыштыру нигезендә ясалган метафоралар ярдәмендә исем биргән (*Әвернә йолдызлыгы, Чүмеч йолдыз, Акбүзат* һ.б.). Аерым халык космонимнары, астрономия фәне тарафыннан теркәлеп, фәнни кулланышка кереп киткән. Яңа барлыкка килгән лексик атамалар арасында күбрәк ай яки планета өслеге белән бәйле атамалар урын ала, йолдыз яки йолдызлык, галактика атамаларын хәзерге астрономия фәнендә хәрефләр һәм идентификацион номер белән күрсәтү гадәткә кергән.

I. Генетик классификация.

Татар телендә кулланылган астрономик терминнарны *килеп чыгышы ягыннан* өч зур төркемгә бүлеп каралырга мөмкин: 1) төрки-татар чыгышлы космонимнар; 2) гарәп теленнән кергән алынма космонимнар; 3) рус теле аша һинд-Европа (грек, латин) телләреннән кергән алынма космонимнар.

1. *Төрки-татар чыгышлы космонимнар.*

Алда әйтелгәнчә, күк җисемнәрен, аларның торышын өйрәнү борынгы кешегә суда һәм коры җирдә вакыт-пространствода юнәлеш табарга мөмкинлек биргән. Борынгы космонимик атамаларның эзе гасырлар тирәнлегенә төшеп югала, аларның кайсы гасырда барлыкка килгәнен әйтүе шактый кыен. Бик күп космонимик атамаларның башка телләрдән тәрҗемә итеп алынуы да мәгълүм, шуңа күрә, еш кына, космонимнарның генетик чыганагын билгеләгәндә, без бары тик лингвистик аспектны күздә тотабыз, этник-мифологик аңлатмалар бу очракта үз-үзләрен акламый.

Хәзерге татар телендә саф төрки чыгышлы космонимнар сан ягыннан күп түгел. Бу – татарларның шактый күптәннән утрак тормышка күчүе сәбәпле, күк җисемнәренең борынгы атамалары телдән югалу белән аңлатыла булса кирәк. Утрак тормышка соңрак күчкән башка төрки халыкларда (мәсәлән, казак, башкорт халыкларында) космонимик атамалар шактый яхшы сакланган: «Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков: Лексика» хезмәтендә дә космонимик атамаларның күбесе казак теле мисалында бирелгән (Сравнительно..., 2001: 50–67). «Татар теленең зур диалектолик сүзлеге»ндә дә (2006) күк җисеме атамалары сирәк очрый, шулай да без аларны К. Насыйри, Н. Исәнбәт кебек галимнәрнең хезмәтләрендә, алар тарафыннан туплап калдырылган халык авыз иҗаты әсәрләрендә күрә алабыз.

Төрки космонимнарны өйрәнгән вакытта, планета, иярчен яки йолдыз тибындагы аерым җисемне белдермәгән, әмма галәм турында нигез күзаллаулар барлыкка китергән атамаларны да өйрәнү зарур.

Алар арасында *күк/*kök* атамасы игътибарны үзенә җәлеп итә. Шунысын әйтергә кирәк: хәзерге төрки телләрдә күк *(небо)* төшенчәсен белдергән сигез лексема кулланыла: 1) көнчыгыш ареалда (алт., тув., хак., шор., уйг. телләрендә) *teŋir* сүзе; 2) кыпчак-угыз-карлук (тат., башк., каз., ккалп., кырг., ком., ног., әзерб., төрек, төркм., үзб., уйг. телләре) ареалын барлыкка китергән *kök* сүзе; 3) борынгы төрки язмалардагы *qalyq*, 4) *ewren* сүзләре; 5) якут телендәге *xallān* сүзе; 6) чуваш телендәге *tüpe* (< töbe) сүзе; 7) тат., каз., ккалп., кырг., төркм., үзб., уйг. иске әдәби телләрендәге *asman/aspan* сүзе; 8. гарәп теленнән алынган *säma* сүзе (Сравнительно..., 2006: 329). Татар телендә әлеге атамалардан *kök* сүзе «күк йөзе *(небо)*» мәгънәсендә, *täŋre* сүзе «күк *(небо)*» мәгънәсен югалтып, Аллаһ мәгънәсендә куллана; иске татар әдәби телендә һәм диалектларда *asman* сүзе «күк йөзе (небо)» мәгънәсендә сакланган.

*Kök* сүзенең беренчел этимологиясе ачыкланмаган дип карала, әмма бу атаманы Һинд-Европа телләре белән чагыштырма рәвештә өйрәнү кызыклы нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә: төрки телләрдә дә, һинд-европа телләрендәге *sky* (күк) сүзе кебек үк, әлеге тамыр «каплау, ябу, тышчалык» мәгънәсен биргән сүзләрдә очрый. Мәсәлән, *kö-n «тире, күн»* гәүдәне каплап алган тышчалык; *kö-m «күмү, каплап кую»; kö-läm «күләм»; kö-bik «күбек»;*

*kö-läŋge «күләгә»* һ.б. Төрки телләрдә шул ук борынгы тамыр *кояш* мәгънәсендә килгән *kön* (*kö-n*) сүзендә дә күзәтелә (ДТС, 1969: 326).

Борынгы төрки синкретизм (бер үк тамырда исем, фигыль, сыйфат мәгънәләре бирегү) күренешенә бәйле рәвештә, *kök* атамасында төс белдерү үзенчәлеге дә сакланган. Татар телендә әлеге тамырда зәңгәрсу һәм соры төсләрне белдерү очрый. *Күгелҗем, күксел, күксү, күгәрек* сүзләрендә әлеге төсләр чагылыш тапкан.

Поэтик татар телендә *күк* сүзе, күплек санда килеп, Аллаһ, югары көч мәгънәсендә дә кулланыла ала: *Күкләрдән иңгән язмыш (Р. Йосыпова)*; *Мин күкләрдән сине сорап алдым (җыр)*. Шулай ук халык авыз иҗатында, борынгы мәкаль-әйтемнәрдә сакланып калган: *Күккә сагурса йүзгә түшүр (Күккә төкерсә, йөзгә төшәр), Күкнең баскычы юк* һ.б.

*Тәңре/*täŋre* сүзе борынгы төрки язмаларда ике мәгънәдә – күк һәм күк Алласы мәгънәсендә кулланылган: 1) *Üzä kök täŋri asra yağïz yer qïlïntuqda ikin ara kisi oğlï qïlïnmïs* (Күлтәгин язмасы, б.э. 732 ел). *Өскә күк Алласы, аска коңгырт-кара җир кылынганда, ике арага кеше баласы кылынган (барлыкка килгән)*. 2) *jẹrni kökni jaraţqan* (Мәхмүд Кашгари, «Диване лөгатет-төрк», 1073 ел) *Җирне, күкне яралткан (барлыкка китергән)*. Билгеле булганча, әлеге атама Алла сүзенә синоним рәвешендә хәзерге татар телендә дә кулланыла: *Татар иле! Тәңре бүләге син!* (Ф. Низамова). Нәкый ага Исәнбәт туплаган мәкальләр арасында *«Тәңрегә әйткән, кирәмәткә биргән», «Тәкәнең мөгезе Тәңрегә җиткәнен кем күргән?», «Мечкәй – Тәңренең убыры»* вариантлары очрый (Исәнбәт, 2010: 762). *Тәңре* сүзенең татар телендә антропоним буларак та кушма исемнәрнең ясалышында кулланылуы мәгълүм (Галиуллина, 2008: 198).

*Асман/*astan* сүзендә борынгы төрки халыкларның күзаллаулары чагылыш тапкан: **as* – җир өстенә асылып куелган; *as+ым* (синкретик сыйфатлы исем фигыльдән ясалган) + *ан* (ас(ы)ман – исемләшкән сыйфат фигыль) = *асылган* мәгънәсен белдерә. *Асман* сүзе «күк йөзе» мәгънәсендә татар теленең көнбатыш диалектында (тубыл-иртыш сөйләшендә) бүгенге көнгә кадәр актив кулланыла (Татар..., 2009: 58), әдәби телдә исә ул, китап сүзе буларак, XX гасырга кадәр актив булган.

*Йолдыз/*julduz* термины гомумтөрки телдән үк килә һәм төрле фонетик вариантларда барлык төрки телләрдә дә диярлек кулланыла. Этимологиясе «ялтырау» мәгънәсенә барып тоташа. Еш кына төрки телләрдә ул, антропоним буларак, хатын-кыз яисә ир-атка бирелгән (Галиуллина, 2009: 19). Шунысы кызыклы: борынгы чорда халыклар күк йөзе җисемнәрен аерым йолдызлыкларга, галактикаларга *(галактика* – бор. грек. *γάλα, γάλακτος сөт, Сөт юлы* – «Млечный Путь») берләштереп атамаганнар, шуңа күрә йолдызлыклар да, галактикалар да, гомуми рәвештә, «йолдыз» дип аталган.

Шул рәвешле, татар телендә кулланылган *kök, täŋri, asman, joldız* сүзләре борынгы төрки катламнан ук килгән космонимик сүз байлыгын тәшкил итәләр.

Төрки чыгышлы йолдыз һәм йолдызлык атамаларыннан хәзерге татар телендә *Ай, Кояш, Киек Каз юлы, Җидегән (Етегән) йолдыз, Чүмеч йолдыз, Тустаган йолдыз, Тимер Казык йолдыз, Котып йолдыз, Күкбүзат йолдыз, Акбүзат йолдыз, Өлкәр йолдыз, Иләк йолдыз, Көянтә йолдыз, Чулпан йолдыз, Зөһрә йолдыз, Таң йолдызы, Шәфәкъ йолдызы, Кызыл йолдыз* атамалары кулланыла.

*Ай* – Җир планетасының бердәнбер табигый иярченен атау өчен кулланылган лексик берәмлек. *Ай* лексемасы борынгы төрки нигез баба телдән үк килә, рун язулы борынгы текстларда язма рәвештә теркәлеп калган һәм төрки халыклар өчен уртак. 30–31 көнгә тигез булган (һиҗри тәкъвимдәге бер айда 29–30 көн) вакыт берәмлеген атау өчен дә файдаланылган. Матур әдәбият һәм фольклор әсәрләрендә матурлык, гүзәллек символы буларак кулланылган, *ай* лексемасы кергән сурәтләү чаралары телдә бик популяр булган. «Татар халык авыз иҗаты. Мәкальләр һәм әйтемнәр» хезмәтендә *Ай* атамасы белән бәйле иллегә якын мәкаль-әйтемнәр, сынамышлар тупланган: *Ай тулса, йолдызлар сыегая; Айга күлмәк киермиләр; Бер күктә ике Ай булмас; Ай утырып туса, аяз була* һ.б. (Татар халык авыз иҗаты. Мәкальләр..., 1987: 39).

*Кояш* – Җир планетасына иң якын йолдыз атамасы. Аның тирәсендә бу системаның башка объектлары – планеталар һәм аларның иярченнәре, кәрлә планеталар һәм аларның иярченнәре, астероидлар, метеороидлар, кометалар һәм галәми тузан әйләнә. *Кояш* сүзенең борынгы вариантлары *kün, künäş, qujaş* булган дип карала (ДТС, 1969: 326, 327, 464). Борынгы төрки тамырда *көю*

(яну – гореть) мәгънәсе ачыклана. Шулай ук төрки-татар язма әдәби истәлекләрендә, борынгы мәкаль-әйтемнәрдә сакланып калган: *Күнгә баксаң, көз камар (Кояшка карасаң, күз камашыр)* һ.б.

Татар әдәбиятының чишмә башы булган «Кыйссаи Йосыф» әсәрендә (Кол Гали, XIII гасыр) ай һәм кояш лексемалары күк җисеме атамасы буларак та, сурәтләү чарасы буларак та кулланыла: «Дугар күн, тулун ай, онбир йулдуз Дүшим ичрә сәҗдә кыйлды бәңа дүб-дүз» *(Туар кояш, тулган ай, унбер йолдыз Төшемдә сәҗдә кылды миңа тәгаен)*, «Тулун ай дип балкыр иди аның йүзи» *(Тулган ай кебек балкый иде аның йөзе)*, «Биңзе нуры күнәш кеби балкыр имди» *(Йөзенең нуры кояш кебек балкый инде)*.

*Киек Каз юлы* атамасы (рус. *Млечный Путь*) космонимик лексемалар арасында иң борынгылардан санала. Шунысы кызыклы: төрле халыклар әлеге галактиканы төрлечә атаганнар, бу атамалар халыкларның кәнкүреше, күзаллаулары белән бәйле. Мәсәлән, Идел буенда яшәгән татар, башкорт, мари телләрендә әлеге галактика мәгънәсе буенча «киек каз яки каз юлы» дип аталса, мукшы, эрзя телләрендә «торна юлы яки кош юлы» дип исемләнгән. Ханты һәм мансилар исә аңа «чаңгы юлы», Урта Азиядә «салам карагы юлы», Венгриядә яки Молдовиядә «чегән юлы» мәгънәсендә атама биргәннәр (Абдуллина, 2014: 1141).

*Җидегән (Етегән) йолдыз* (рус. *Большая Медведица*) космонимы шулай ук күп кенә төрки халыклар өчен уртак, борынгы атамаларның берсе булып тора. Җиде йолдыз җирдән караганда тоткалы чүмечкә охшаган сурәт барлыкка китерәләр, шуңа күрә кайбер халыкларда аның бер варианты буларак, *Чүмеч йолдыз* һәм *Тустаган йолдыз* атамалары да кулланыла. Җидегән йолдызлыгы ике өлешкә – Зур һәм Кече Җидегәнгә бүленә.

*Зур Җидегән йолдызлыгы* – гади күзгә яхшы күренгән зур, якты җиде йолдыздан тора. Башка халыкларда бу йолдызлыкны Зур Аю (лат. *Ursa Major,* гар. *Әд-дөбб әл-әкбәр,* рус. *Большая Медведица*) дип атыйлар. Клавдий Птолемейның б.э.ның 140 елларында төзелгән «Альмагест» йолдыз каталогына кертелгән. Әл-Бируни үзенең 1030 елда тәмамланган «Мәсгуд канунында» Птолемейның бор. грек. *άρκτος μεγάλη* исемен гарәп теленә «Әддөбб әл-әкбәр» сүзләре белән тәрҗемә иткән. Татар халкы иске төрки-татар әдәби телендә йолдызлыкның Дөббеләкбәр гарәп атамасын да кулланган.

*Кече Җидегән йолдызлыгы (Кече Аю, лат. Ursa Minor)* – күк йөзенең төньяк ярымшарындагы котып янында урнашкан йолдызлык. Аңа гади күз белән күренә торган кырыклап йолдыз керә. Кече Җидегән йолдызлыгында Тимерказыктан 1° ераклыкта Җир шарының төньяк котыбы урнашкан. Кече Җидегән төркеменнән берничә йолдызның төрки-татар чыгышлы атамалары билгеле:

α – *Тимерказык (Котып йолдызы)*. Клавдий Птолемей аны «койрык очындагы йолдыз» *(Аюның койрык очындагы)* дип атаган. Әл-Бируни «койрыкның очы» һәм «җәди әл-кыйбла» – «кыйбланың кәҗә бәтие» дип атый. Хәзерге гар. телендә «нәҗм әш-шималь» – Төньяк йолдызы дип исемләнә.

β – *Акбүзат* (Кәүкәб, гар. *әл-кәүкәб әш-шимали* – «төньяк йолдыз»; рус. *Кохаб*), Б.э.к. 1900 елдан б.э.ның 500 елына кадәр бу йолдыз күк йөзенең төньяк котыбына иң якын йолдыз булган һәм котып йолдызы сыйфатында йөргән. Бу үзенчәлек аның гарәп исемендә сурәтләнгән.

γ – *Күкбүзат* (гар. *фәркад* – «бозау», рус. *Феркад*). Клавдий Птолемей аны «киләсе якның төньяк йолдызы» дип биргән. Әл-Бируни «Мәсгуд канунында» аны «икедән төньяктагы» дип атый.

Тимерказык (Котып йолдызы) төрки халыкларда күккә кагылган «тимер казык» итеп күз алдына китерелгән һәм аның янындагы ике йолдыз шул казыкка бәйләп куелган Акбүзат һәм Күкбүзат дип исемләнгән тайлар буларак күзалланган. Тимерказык хәрәкәт итми һәм һәм һәрвакыт Төньяк котып ягын күрсәтә, шуңа күрә ул бик борынгы заманнардан бирле юл-сәфәр йөрүчеләр өчен ышанычлы табигый ориентир буларак хезмәт иткән. Х. Мәхмүтов тарафыннан китерелгән (Н. Исәнбәттән алынган) бер риваятьтә *Тимерказык, Акбүзат* һәм *Күкбүзат йолдызлары* турында болай диелә: «Акбүзат һәм Күкбүзат – Тимерказык (Котып) йолдызы тирәли әйләнүче ике йолдызның исеме (Беренчесе – шактый якты, икенчесе, аның белән чагыштырганда, тоныграк булып күренә). Бер легендада сөйләнгәнчә, берсе ак, икенчесе күк ике атны тимер казыкка бәйләп куйганнар имеш. Шул казык тирәсеннән китә алмыйча утлап йөргәндә, аларны җиде карак (Җидегән йолдыз) урлап китәргә ниятләгән. Болар Акбүзат һәм Күкбүзат артыннан әй чабалар, әй чабалар, әмма куып җитә алмыйлар, ди» (Татар халык иҗаты. Мәкальләр..., 1987: 525).

Татар халык авыз иҗатында әлеге йолдызлар атамасы чагылган табышмак һәм әйтемнәр сакланып калган:

*Казыкка бәйләнгән ике атым дулый, дуласа да бер тирәдән китә алмый* (табышмак: *Тимерказык, Акбүзат, Күкбүзат йолдызлары*).

*Акбүзат йолдыз, Күкбүзат йолдыз, Тимерказык бер ялгыз* (әйтем).

*Тимерказыкны Акбүзат куа, Акбүзатны Күкбүзат куа* (әйтем).

*Ала таң, бола таң, Тимерказык олатаң* (олы атаң)(әйтем).

*Күк атасы – Тимерказык* (әйтем).

*Җидегән йолдыз җиде, имеш, Җиде санасаң, савап, имеш* (әйтем).

*Җидегән йолдыз – җиде кубыз* (әйтем).

*Җидегән йолдыз җиде әйләнә, Тимерказык урынында* (әйтем).

*Җидегән йолдызның койрыгы таңга сызылыр* (әйтем).

*Җидегән йолдыз карсу булып күренсә, яңгыр булыр* (сынамыш).

*Өлкәр йолдызы* Сәвер *(Үгезбозау)* йолдызлыгында урнашкан йолдызлыкларның берсе (рус. *Плеяды*). Атамасы күп кенә төрки телләрдә таралган, борынгы атама булып тора. Өлкәр, башлыча, татар әдәби телендә кулланыла торган атама, халыкның сөйләмә телендә *Иләк йолдыз* термины ешрак очрый. Г.Р. Абдуллина фикеренчә, *Өлкәр* атамасы «өлкән» мәгънәсен белдерә, башкорт телендә аның *Сыңғы, Сыңға йондоҙ* (бөҗрасыман йолдыз) атамалары бар (Абдуллина, 2016: 297). *Өлкәр* сүзе кайчандыр телдә *иләү (өләк/иләк)* мәгънәсе белән бәйле булырга мөмкин, чөнки әлеге йолдызлыктагы йолдызлар, иләктән сибелгән кебек, таралып урнашканнар. Шулай ук бу сүзнең ‘тишек’ мәгънәсе билгеле (Карпенко, 1981: 52). Телдә бу йолдызлык атамасы кергән әйтем-сынамышлар да сакланып калган:

*Өлкәр батты – җир катты* (сынамыш).

*Өлкәр җиргә төшкәндә, сыер суга төшәр* (сынамыш).

*Өлкәрле айның бары кыш* (әйтем).

*Көянтә йолдыз* (рус. *Орион*) иске төрки-татар язма истәлекләрендә гарәп теленнән алынган *Җәүза* һәм *Җәббар* сүзләре белән аталган. Татар телендәге атамасы охшашлык нигезендә ясалган метафораны тәшкил итә (әлеге йолдызлыктагы унбер йолдыз күктә көянтә рәвешендә күренә). Көянтә йолдыз турында берничә табышмак сакланып калган:

*Биш кыз бер көянтә күтәргән, Төн буена су ташый* (табышмак).

*Алты кыз һәр төн саен Көянтәләп су китерә, Унбер егет, бергә җыелып, Читтән күзләп төн кичерә* (табышмак).

*Чулпан йолдыз, Зөһрә йолдыз, Таң йолдызы, Шәфәкъ йолдызы* – Венера (лат. *Venus*) планетасын атый торган атамалар. Төрки халыкларда әлеге атама белән бәйле легендалар шактый, планета өслегендә күренгән тапларны халык көянтә аскан кызга охшатып, халык авыз иҗаты әсәрләре (табышмаклар, әйтем-мәкальләр, үги кыз әкияте, Зөһрә кыз әкияте һ.б.) уйлап чыгарган.

*Кызыл йолдыз* – Марс планетасы атамасы. Өслегендә күп булган тимер оксиды Марска кызгылт төсмер бирә, шуңа күрә аны «Кызыл планета», «Кызыл йолдыз» дип атаганнар. Иске төрки-татар язма истәлекләрендә гарәп теленнән алынган *Мәррих* атамасы очрый.

Югарыда язылганнардан чыгып, шуны әйтергә мөмкин: татар телендә төрки чыгышлы космонимнар күп түгел. Бу – татар халкының шактый борынгыдан утрак тормышка күчеп, ориентир өчен әһәмиятле булган йолдыз атамаларының халык хәтереннән әкренләп югалуы белән бәйле булса кирәк. Шуңа карамастан, халык аңында бүгенге көндә дә күк йөзендә күзәтелгән төп космонимик җисемнәрнең атамалары саклана, алар фольклор әсәрләрендә, матур әдәбиятта, халыкның җанлы сөйләмә телендә кулланылуларын дәвам итәләр.

2. *Гарәп теленнән кергән алынма космонимнар.*

Хәзерге вакытта Россия халыклары куллана торган календарь системасы татарларда XIX гасырның икенче яртысында гына ныклап урнаша. Аңа кадәр кулланылган зодиакаль календарь гарәп теленнән алынган йолдызлык исемнәренә корылган булган. Татарлар «Фәкать игенчелек эшләре өчен, кояш хисабы белән яз башыннан башлап, “хәмәл, сәвер, җәүза, саратан, әсәд, сөнбөлә, мизан, гакърәб, кавыс, җәди, дәлү, хут” дип, гарәби исемнәр кулланалар», – дип яза Шиһабетдин Мәрҗани «Мостафад әл-әхбар фи әхвәли Казан вә Болгар...» әсәрендә (http://kitap.net.ru/marjani1.php). Шушы ук сүзләрне Нәкый Исәнбәтнең «Татар халык мәкальләре» җыентыгында да күрәбез: «...язма календарьда ай исемнәре түбәндәгечә: 1. Дәлү (чиләк) – гыйнвар; 2. Хут (балык) – февраль; 3. Хәмәл (кузы) – март; 4. Сәвер (үгез) – апрель; 5. (Җәүза) – май; 6. Сәрәтан (кысла) – июнь; 7. Әсәд (арыслан) – Июль; 8. Сөн-

белә (сөнбел чәчле кыз) – август; 9. Мизан (бизмән) – сентябрь; 10. Гакрәб (чаян) – октябрь; 11. Кавәс (җәя) – ноябрь; 12. Җәди (кәҗә бәрәне, ылак) – декабрь (Исәнбәт, 2010: 288). Шул рәвешле, вакытны санаганда да төрки бабаларыбыз унике зодиакаль йолдызлык исемнәренә корылган гарәп чыгышлы ай исемнәреннән файдаланган.

Алда әйтелгәнчә, көнчыгыш гарәп илләрендә XI–XVI гасырлар астрономия фәненең чәчәк ату чоры буларак билгеле, төрки халыклар исә ислам дине аркылы Көнчыгыш мәдәнияте казанышларын үзләренә кабул итеп алганнар. Шул исәптән, фәнни әйләнешкә гарәп теле космонимнарының да үтеп керүе барган. Идел буенда астрономия буенча язылган фәнни трактатларда, Каюм Насыйри, Шиһабетдин Мәрҗани кебек олы галимнәрнең хезмәтләрендә гарәп теле терминнары һәм космонимик берәмлекләр урын алган, шуңа күрә аларны өйрәнү зарур. Гарәп космонимнары төрки халыкларга гына түгел, Европа телләренә дә үтеп кергәннәр һәм урнашып калганнар. Дөньяви астрономия фәнендә термин буларак кулланыла торган күп кенә атамаларның нигезендә гарәп сүзләре ята. Төрки халыкларда кулланылган кайбер йолдызлык һәм аларга караган гарәпчә чыгышлы йолдыз исемнәре (әлеге исемлекне төзегәндә «Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге» һәм «Википедия» энциклопедиясе материаллары файдаланылды):

Гарәби чыгышлы йолдыз атамалары:

*Зур Җидегән* йолдызлыгындагы җиде йолдызның да гарәпчә исемнәре кулланылган: α йолдызы – *Дубхе* (*дөбб* – «аю», гар. *каһил әд-дөбб* – «аюның аркасы»); β – *Мәрәк* (гар. «корсак»; рус. *Мерак*); γ – *Фәкда* («бот», гар. «аюның боты»); δ – *Мәгъриз* (гар. «койрык башы»; рус. *Мегрец*); ε – *Әлҗун* (гар. «кара ат»; рус. *Алиот*); ζ – *Мизар* (гар. «алъяпкыч», рус. *Мицар*); η – *Бәнәтнаш* яки *Әлкаид* (гар. «яслатучылар (кыз елатучылар) башлыгы»).

*Орион* (Көянтә, гар. *Җаббар*) йолдызлыгына караган гарәп чыгышлы атамалар: α – *Бителҗәүза* (гар. *ибт әл-җәүза'* – «Бәйленең култык асты», монда «Бәйле» астында Орион күздә тотыла; рус. *Бетельгейзе*); β – *Риҗел* (гар. *риҗл әл-җәббар* – «Орионның аягы»; рус. *Ригель*); δ – *Минтака* (гар. *минтақа* – «билбау»); ζ – *Әлнитак* (гар. *ән-нитақ* – «кушак»; рус. *Альнитак*); Минтака һәм Әлнитак йолдызлары «Орион билбавы»н тәшкил итә;

ε – *Әл-низам* (гар. *ән-низам* – «энҗе җебе»; рус. Альнилам), κ – Сәеф (гар. *сәеф* – «кылыч», Орионның кылычы күздә тотыла; рус. *Саиф*).

*Мизан* (Үлчәү) йолдызлыгына (гар. «үлчәү»; лат. *Libra*) караган гарәп чыгышлы атамалар: α – *Зөбәнел-Җәнүби* (гар. «көньяк кыскыч»); β – *Зөбәнел-Шимали* (гар. «төньяк кыскыч»); γ – *Зөбәнел-Гакрәп* (гар. «чаян кыскычы»).

*Дәлү* (Сукояр) йолдызлыгы (гар. *әд-дәлү* «чиләк»; лат. *Aquarius*): α – *Сәгыделмәлик* яки *Сәгыделмөлек* (гар. *сә‘д әл-мәлик* – «патшаның бәхетлелеге» яки сә‘д әл-мөлк «илнең бәхетлелеге»; рус. *Садальмелик*); β – *Сәгыделсогуд* (гар. *сә‘д әл-со‘уд* – «бәхетлекнең бәхетлелеге»); δ – *Сак* (гар. *әс-сак* – «балтыр», әл-Бируни бу йолдызны «уң балтырда икенчедән көньяктагы» дип атаган; рус. *Скат*).

*Сәвер* (Үгезбозау) йолдызлыгы (гар. *әҫ-ҫәвр* – «үгез»; лат. *Taurus*): α – *Әлдәбәран* (гар. *әд-дәбәран* – «иярүче», «Гиадалар артыннан иярүче» күздә тотыла, шулай ук йолдызны Үгезнең күзе (лат. *Oculus Tauri̅*) дип тә атаганнар; рус. *Альдебаран*); β – *Әлнәтых* (гар. *ән-нәтх* – «чик», «мөгезләрнең чиге» күздә тотыла).

*Әсәт* (Арыслан) йолдызлыгы (гар. *әл-’әсәд* – «арыслан»; лат. *Leo*), аңа караган гарәп чыгышлы йолдыз атамалары: β – *Дәнәбәл* (гар. *ҙәнәб әл-’әсәд* – «Арыслан койрыгы»); γ – *Әлҗәбһә* (гар. *әл-җәбһәһ, җәбһәт әл-’әсәд* – «Арыслан маңгае», әмма чынлыкта «Арыслан ялы» булып тора; рус. *Альгиеба*); δ – *Зоһер* (гар. *зоһер әл-’әсәд* – «Арыслан биле», шулай ук *Зосма* – бор. грек. «билбау»); ε – *Әлҗәнүби* (гар. р*ә’с әл-’әсәд әл-җәнүби* – «Арыслан башының көньяктагы йолдызы»); ζ – *Әлзафирә* (гар. *әз-зәфирәһ*); η – *Әл Җәбһә* (гар. әл-җәбһәһ); θ – (гар. *әл-хорт*); κ – (гар. *минхир әл-’әсәд* – «Арыслан борыны»); Әсәт λ – Әлтараф (гар. әт-тарф – «күренеш»); μ – *Рәэсәләс* (яки *Әлшимали,* гар. *рә’с әл-’әсәд әш-шимали* – «Арыслан башының төньяктагы йолдызы»).

*Зур эт* (Кәлб-әл-әкбәр) йолдызлыгына караган гарәп чыгышлы йолдыз атамалары: β – *Мирзам* (гар. *мирзам* – «өндәүче» яки *мурзим* – «бәй», рус. *Мирцам*); γ – *Мөхлифәйн* (гар. *мөхлифәйн* «этнең күзе», рус. *Мулифен*); δ – *Вәзен* (гар. *вәзн* – «авырлык», рус. *Везен*); ε – *Газараэ* (гар. *әл-‘әҙара’* – «гыйффәтле кызлар», рус. *Адара*); ζ – *Фуруд* (гар. *фуруд* – «ялгыз», «аерылган»); η – *Әлгазраэ* (гар. *әл-‘әҙра* – «гыйффәтле кыз», рус. *Алудра*).

*Кефей* йолдызлыгына караган гарәп чыгышлы йолдыз атамалары: α – *Әлзирамин* (гар. *әз-зира‘ әл-йәмин* – «уң кул»); β – *Әлфирк* (гар. *әл-фирқ, әл-фирқәһ* – «өер»); γ – *Әлрагый* (гар. *әр-ра‘и* – «көтүче»); δ – *Әлрәдиф* (гар. *әр-рәдиф* – «ияреп баручы»).

*Персей* йолдызлыгына караган гарәп чыгышлы йолдыз атамалары: α – *Мирфәкъ* (гар. *әл-мирфәқ* – «терсәк», «Персейның терсәге» күздә тотыла; рус. *Мирфак*); β – *Әлгул* (гар. *рә’с әл-гул* – «Горгонаның башы» ; рус. *Альголь*);

Гарәби чыгышлы йолдызлык атамалары:

*Әлтаир* йолдызлыгы (гар. *ән-нәср* әт-та’ир) «очучы каракош»; *Җәди* йолдызлыгы (гар. *әл-җәди* «кәҗә бәтие»; шулай ук *Кәҗәмөгез* йолдызлыгы; лат. *Capricornus*); *Җәүза* йолдызлыгы (гарәп. «бәйле»; шулай ук *Игезәкләр* йолдызлыгы; лат. *Gemini*); *Гакрәп* йолдызлыгы (гар. *әл-‘әқрәб* – «чаян»; шулай ук *Чаян* йолдызлыгы; лат. *Scorpius*); *Саратан* йолдызлыгы (гар. *әс-сәрәтан* – «кысла»; шулай ук *Кысла* йолдызлыгы; лат. *Cancer*); *Кавәс* йолдызлыгы (гар. *әл-қәўәс* – «җәя»; шулай ук Укчы йолдызлыгы; лат. *Sagittarius*); *Хут* йолдызлыгы (гар. «зур балык»; шулай ук Балыклар йолдызлыгы; лат. *Pisces*); *Хәмәл* йолдызлыгы (гар. *әл-хәмәл* «бәрән»; шулай ук Кучкар йолдызлыгы; лат. Aries); *Сөмбелә* йолдызлыгы (гар. *сөнбелә* – «башак»; шулай ук Кыз йолдызлыгы; лат. *Virgo*); *Әлтаир* (гар. ән-нәср әт-та’ир – «очучы каракош»; Еланлы Кеше β – Кәлбелрагый (гар. *кәлб әр-ра‘и* – «көтүче эте»); *Әлгазраэ* («Гыйффәтле Кызлар») йолдызлар төркеме.

Шул рәвешле, иске татар теленең фәнни стилендә кулланылган гарәп чыгышлы космонимик атамалар сан ягыннан шактый күп. Алар бүгенге көндә махсус өйрәнүне, системалаштыруны таләп итә.

3. *Рус теле аша һинд-Европа (грек, латин) телләреннән кергән алынма космонимнар.*

Хәзерге чорда дөнья телләренең күпчелегендә фәнни стильдә латин теле терминнары кулланыла, шуңа күрә космонимик атамаларның да шактый өлеше латин нигезле. Шунысын да ассызыклау мөһим: йолдызлык атамаларының күбесе рус теленә Европа телләреннән тәрҗемә итеп алынганнар, XX гасырда исә, астрономия фәнен мәктәпләрдә татарча укыту ихтыяҗы килеп тугач, бу исемнәр рус теленнән татар теленә тәрҗемә ителгәннәр һәм фәнни әйләнешкә тәрҗемә формада кергәннәр. Мәсәлән, *Почмаклык* (Наугольник), *Рәссам* (Живописец), *Вероника чәче* (Волосы

Вероники) һ.б. Шул ук вакытта Европа телләрендә гарәп теленнән алынган атамалар кулланылган, рус теленә алар фонетик яктан җайлаштырып кабул ителгәннәр, ә татар теленә рус телендә әйтелгәнчә кереп киткән: *Бетельгейзе* – Орион йолдызлыгының α йолдызы, Мирзам – Зур эт йолдызлыгының β йолдызы, *Альдебаран* – Үгезбозау йолдызының сары α йолдызы, Мицар – Зур Җидегән йолдызлыгының ζ йолдызы, *Вега* – Лира йолдызлыгының α йолдызы һ.б. Бу атамаларның гарәп теленеке булуы, беренче карашка, сизелми дә (мәсәлән, *Факт* йолдызының исеме гарәп теленең *Фахита* сүзеннән алынган, *Фомальгаут* – гар. *Фум аль хут* (балык авызы) һ.б.).

Шул ук вакытта татар әдәби теленә рус-Европа телләре аша *латин нигезле* космонимнар да алынган. Аларның кайберләрен күрсәтеп үтәргә мөмкин:

*Альциона* – Иләк йолдызлыгындагы γ йолдызы. Йолдызның исеме мифологик Плеядаларның (Иләк йолдызлыгы) берсе – *Алкиона* (мифологик Атланта һәм Плеона исемле аллаларның кызы, Посейдонның сөеклесе) исеменнән алынган.

*Антарес* – Чаян йолдызлыгының α йолдызы. «Антарес» сүзе грек теленең *ανταρης* «Ареска (Марска) каршы» мәгънәсендәге сүздән алынган. Бу йолдыз кызыл төстә булуы белән Марс планетасына охшаган. Гарәп телендә исә ул «Чаян йөрәге» мәгънәсендәге *Кальб-аль-Әкраб* исемен йөртә.

*Арктур* – Үгез көтүчесе йолдызлыгындагы α йолдызы. Борынгы грек телендәге *Ἀρκτοῦρος* < *ἄρκτου οὖρος* «Аю сакчысы» мәгънәсендәге сүздән алынган. Легенда буенча, Зевс тарафыннан күккә Гера аюга әверелдергән әнисе нимфа Каллистоны сакларга куелган. Гарәп телендә кулланылган *Харис-ас-сама'э* атамасында да «күк сакчысы» мәгънәсе бар.

*Беллатрикс* – Орион йолдызлыгының γ йолдызы. *Беллатрикс* (лат. *Bellātrix*) – латин теленә «сугышчы хатын-кыз», «амазонка» буларак гарәп теленең *әл-нәҗид* – «яулап алучы» сүзеннән тәрҗемә итеп алынган.

*Капелла* – Йөкче йолдызлыгының α йолдызы. *Капелла* сүзе латин телендә «кәҗә» дигәнне аңлата. Ул Амалфея исемле кәҗәне гәүдәләндергән. Юпитерны имезеп үстергән бу кәҗәнең мөгезе мифологиядә «Муллык мөгезе» («Рог изобилия») буларак танылган.

*Плейона* – Үгезбозау йолдызлыгындагы γ йолдызы. Атлант исемле титанның хатыны, алардан җиде гүзәл Плеядалар туган.

*Сириус* – Зур эт йолдызлыгындагы α йолдызы. Атамасы грек теленең *sirius –Σείριος* («якты», «ялтыравыклы») сүзеннән килә. Орион яки Икарий исемле мифологик затларның сакчы эте. Зур Эт йолдызлыгындагы Процион һәм Сириус йолдызларын ике эт итеп күзаллаганнар. Латин телендә дә шул ук атама (*Canicula* – «кечкенә эт» дигәнне аңлата). Бу йолдыз җәйге чиллә башлангач күк йөзендә иртәнге якта күренә башлый, шуңа күрә бу вакытны «каникул көннәре» дип атаганнар.

*Целено* (Келенó) – Үгезбозау йолдызлыгындагы α йолдызы. Борынгы грек телендәге Κελαινώ – караңгылык, кара мәгънәсендәге сүздән алынган. Атлант һәм Плейонадан туган кыз исеме, Посейдонның тагы бер сөеклесе.

*Центавр Альфасы* – Центавр йолдызлыгы α йолдызы, *Центавр Проксимасы* – Центавр йолдызлыгының α йолдызы. Цента́вр или Кента́вр (лат. Centaurus) – бу йолдызлар Хирон исемле үтә акыллы һәм зирәк мифологик затны (кентаврны), Кронос һәм нимфа Филираның улын гәүдәләндерәләр.

*Электра* – Үгезбозау йолдызлыгындагы α йолдызы. Эле́ктра (борынгы грек. Ἠλέκτρα) – грек мифологиясендәге Агамемнон и Клитемнестраның кызы, грек трагедияләрендәге героиня исеме белән аталган.

Шунысы кызыклы: космонимнар арасында грек һәм латин нигезле атамалар күп түгел. Күпчелек атамалар, алда әйтелгәнчә, тәрҗемә итеп алынганнар.

II. Лексик-тематик классификация.

Космонимнарны лексик-тематик яктан төркемләү алымнары татар теле белемендә эшләнелмәгән, әмма башка телләрдә кайбер эзләнүләр бар (К.Г. Аронов (1992), М.Э. Рут (1987) һ.б.). Әлеге классификация казак телендә кулланылган космонимнарны өйрәнгән галим К.Г. Аронов хезмәтенә таянып төзелде (Аронов, 1992: 7). Ул түбәндәге төркемнәрне билгели:

1) аерым йолдыз исемнәрен белдергән космонимнар;
2) йолдызлык исемнәрен белдергән космонимнар;
3) йолдыз төркемнәрен белдергән космонимнар;
4) зодиак йолдызлыкларын белдергән космонимнар;

5) кояш системасында урнашкан күк җисемнәрен белдергән космонимнар;

6) комета һәм метеорларны белдергән космонимнар;

7) космос һәм галактиканы белдергән космонимнар.

Бу классификациягә татар теле материалына бәйле рәвештә кайбер үзгәрешләр кертү сорала. Икенче һәм өченче пунктларны берләштереп, планета яки иярчен өслегендә урнашкан топонимик материалны аерым төркем итеп формалаштырырга мөмкин дип саныйбыз. Шул рәвешле, татар телендә кулланышта йөргән космонимнарның җиде лексик-тематик төркемен аерабыз[1]:

1. *Аерым йолдыз исемнәрен белдергән космонимнар: Акбүзат* – Зур Җидегән йолдызлыгының γ йолдызы, *Аламак* – Андромеда йолдызлыгындагы γ йолдызы, *Алараф* – Кыз йолдызлыгындагы β йолдызы, *Алголь* – Персей йолдызлыгындагы β куш йолдызы, *Алиот* – Җидегән йолдызлыгындагы έ йолдызы, *Альбирео* – Аккош йолдызлыгының γ йолдызы, *Альгена* – Игезәкләр йолдызлыгының γ йолдызы, *Альгениб* – Пегас йолдызлыгының γ йолдызы, *Альгиеба* – Арыслан йолдызлыгының γ йолдызы, *Альдебаран* – Үгезбозау йолдызлыгының сары α йолдызы, *Альдерамин* – Цефей йолдызлыгының α йолдызы, *Алькор* – Зур Җидегән йолдызлыгы β куш йолдызы сыңары, *Альрами* – Укчы йолдызлыгының α йолдызы, *Альтаир* – Каракош йолдызлыгының α йолдызы, *Альфард* – Гидра йолдызлыгының α йолдызы, *Альциона* – Иләк йолдызлыгындагы γ йолдызы, *Антарес* – Чаян йолдызлыгының α йолдызы, *Арктур* – Үгез көтүчесе йолдызлыгындагы α йолдызы, *Ахернар* – Эридан йолдызлыгының α йолдызы, *Беллатрикс* – Орион йолдызлыгының γ йолдызы, *Бенетнаш* – Зур Җидегән йолдызлыгының η йолдызы, *Бетельгейзе* – Орион йолдызлыгының α йолдызы, *Вега* – Лира йолдызлыгының α йолдызы, *Гемма* – Төньяк Таҗ йолдызлыгының α йолдызы, *Денеб* – Аккош йолдызлыгының α йолдызы, *Денебола* – Арслан йолдызлыгының β йолдызы, *Дубхе* – Зур Җидегән йолдызлыгының α йолдызы, *Канопус* – Киль йолдызлыгының α йолдызы, *Капелла* – Йөкче йолдызлыгының α йолдызы, *Күкбүзат* – Кече Җидегән йолдызлыгының έ йолдызы, *Маркаб* – Пегас йолдызлыгының α йолдызы, *Мегрец* – Зур

[1] Космонимик атамалар «Русча-татарча астрономик сүзлек» (1974) материалларына нигезләнеп бирелә.

Җидегән йолдызлыгының δ йолдызы, *Мерак* – Зур Җидегән йолдызлыгының β йолдызы, *Меропа* – Үгезбозау йолдызлыгындагы α йолдыз, *Мира* (Гаҗәп йолдыз) – Кит йолдызлыгындагы үзгәрүчән йолдыз, *Мирах* – Андромеда йолдызлыгының β йолдызы, *Мирзам* – Зур эт йолдызлыгының β йолдызы, *Мирфак* – Персей йолдызлыгының α йолдызы, *Мицар* – Зур Җидегән йолдызлыгының ζ йолдызы, *Нат* – Үгезбозау йолдызлыгының β йолдызы, *Плейона* – Үгезбозау йолдызлыгындагы γ йолдызы, *Рас Агетти* – Геркулес йолдызлыгындагы α йолдызы, *Рас Альхаге* – Еланлы йолдызлыгындагы α йолдызы, *Регул* – Арслан йолдызлыгындагы α йолдызы, *Ригель* – Көянтә йолдызлыгындагы β йолдызы, *Сириус* – Зур Эт йолдызлыгындагы α йолдызы, *Сиррах* – Андромеда йолдызлыгындагы α йолдызы, *Спика* – Кыз йолдызлыгындагы α йолдызы, *Тимерказык* – Кече Җидегән йолдызлыгының α йолдызы, *Тубан* – Аждаһа йолдызлыгындагы α йолдызы, *Факт* – Күгәрчен йолдызлыгындагы α йолдызы, *Фекда* – Зур Җидегән йолдызлыгындагы γ йолдызы, *Фомальгаут* – Көньяк Балык йолдызлыгындагы α йолдызы, *Хәмәл* – Кучкар йолдызлыгындагы α йолдызы, *Целено* – Үгезбозау йолдызлыгындагы α йолдызы, *Центавр Альфасы* – Центавр йолдызлыгы α йолдызы, *Центавр Проксимасы* – Центавр йолдызлыгының α йолдызы, *Шаф* – Кассиопея йолдызлыгындагы β йолдызы, *Шеат* – Акбүзат йолдызлыгындагы β йолдызы, *Шедир* – Кассиопея йолдызлыгындагы α йолдызы, *Электра* – Үгезбозау йолдызлыгындагы α йолдызы.

2. *Йолдызлык исемнәрен белдергән космонимнар: Аждаһа, Аккош, Алтын Балык, Андромеда, Андромеда томанлыгы, Арго корабле, Арыслан, Ау этләре, Балыклар, Бүре, Вероника чәче, Геркулес, Гидра, Дельфин, Елан, Еланлы, Әвернә, Жираф, Зур Җидегән, Зур Магеллан Болыты, Зур эт, Игезәкләр, Иләк (Өлкәр), Индус, Йөкче, Калкан, Каракош, Кассиопея, Квадрант, Кече Җидегән, Кече Магеллан Болыты, Кечкенә Арыслан, Кечкенә ат, Кечкенә эт, Кәҗәмөгез, Кәлтә, Киль, Кискеч, Кит, Козгын, Колын, Корбан, Корма, Көньяк Балыгы, Көньяк, Гидра, Көньяк өчпочмагы, Көньяк Таҗы, Көньяк Хач, Көянтә, Кучкар, Куян, Күгәрчен, Кыз, Лира, Микроскоп, Мич, Насос, Октан, Очар Балык, Өчпочмак, Персей, Почмаклык, Рәссам, Секстант, Селәүсен, Сәгать, Скульптор, Сукояр, Сыңармөгез, Табак, Тавис, Телескоп, Торна, Төлке, Төньяк Таҗ, Тукан, Тулпар, Ук, Укчы, Үгез көтүчесе, Үгезбозау,*

*Үлчәү, Феникс, Хамелеон, Центавр, Цефей, Циркуль, Чаян, Чебен, Челтәр, Эридан, Юпитер, Ясле, Яссы Тау.*

3. *Зодиак йолдызлыкларын белдергән космонимнар.* Зодиак йолдызлыклары (лат. *ζωδιακός* – «җәнлек») – Кояшның йолдызлар арасында күренмә бер еллык хәрәкәте (эклиптика) буйлап урнашкан 12 йолдызлык (Галиев, 1973: 22). Иске төрки-татар әдәби телендә кулланылган элеккеге атамалары түбәндәгечә булган: *Хәмәл* (♈), *Сәвер* (♉), *Җәүза* (♊), *Саратан* (♋), *Әсәт* (♌), *Сөмбелә* (♍), *Мизан* (♎), *Гакрәп* (♏), *Кавәс* (♐), *Җәди* (♑), *Дәлү* (♒), *Хут* (♓).

Хәзерге татар телендә исә әлеге атамаларның рус теленнән тәрҗемә вариантлары кулланыла: *Кучкар, Үгезбозау, Игезәкләр, Кысла, Арыслан, Кыз, Үлчәү, Чаян, Укчы, Кәҗәмөгез, Сукояр, Балыклар.*

4. *Кояш системасында урнашкан күк җисемнәрен белдергән космонимнар: Планета* (грек. *πλανήτης* – «илгизәр») – йолдыз яки йолдыз калдыгы тирәсендә әйләнгән күк җисеме. Борынгы чорда кешеләр күк йөзендә ялтырап күренгән планеталарны да йолдыз дип уйлаганнар, шуңа күрә аларга «йолдыз» дип исем биргәннәр (мәсәлән, *Зөһрә йолдыз, Топрак йолдыз, Кызыл йолдыз* һ.б.). Кояш системасында, Халыкара астрономия берлеге билгеләмәсе буенча, сигез планета бар: Кояштан ераклашу тәртибендә дүрт җирсыман – *Меркурий, Венера (Чулпан, Зөһрә), Җир, Марс*; дүрт зур планета – *Юпитер, Сатурн, Уран* һәм *Нептун* планеталары күрсәтелә. Шулай ук, ким дигәндә, биш кәрлә планета барлыгы билгеләнә: *Плутон* (2006 елга кадәр тугызынчы планета дип исәпләнде), *Макемаке, Хаумеа, Эрида* һәм *Церера*. Меркурий һәм Венерадан тыш, һәрбер планета тирәсендә, ким дигәндә, бер иярчен әйләнә (https://tt.wikipedia.org/wiki/Планета).

Иске төрки-татар телендә кайбер планеталарның гарәпчә исеме дә кулланылган: *Мәррих* (Марс), *Мөштәри* (Юпитер), *Гатарид* (Меркурий), *Зөхәл* (Сатурн), *Зөһрә* (Венера).

Планеталарның иярченнәре дә мәгълүм: *Ариэль* – Уран планетасының иярчене, *Аурора* – Юпитер планетасының иярчене атамасы, *Гиперион* – Сатурн планетасының иярчене атамасы, *Деймос* – Марс планетасының кечкенә иярчене атамасы, *Диана* – Сатурн планетасының иярчене атамасы, *Ио* – Юпитер планетасының иярчене атамасы, *Каллисто* – Юпитер планетасының иярчене атамасы, *Мимас* – Сатурн планетасының иярчене атамасы, *Миранда* –

Уран планетасының иярчене атамасы, *Нереида* – Нептун планетасының иярчене атамасы, *Оберон* – Уран планетасының иярчене атамасы, *Рея* – Сатурн планетасының иярчене атамасы, *Тефия* – Сатурн планетасының иярчене атамасы, *Титан* – Сатурн планетасының иярчене атамасы, *Титания* – Уран планетасының иярчене атамасы, *Тритон* – Нептун планетасының иярчене атамасы, *Умбриэль* – Уран планетасының иярчене атамасы, *Феба* – Сатурн планетасының иярчене атамасы, *Фемида* – Сатурн планетасының иярчене атамасы, *Фетида* – Сатурн планетасының иярчене атамасы, *Фобос* – Марс планетасының иярчене атамасы, *Энцелад* – Сатурн планетасының иярчене атамасы, *Япет* – Сатурн планетасының иярчене атамасы.

Күренгәнчә, бу атамалар арасында төрки чыгышлылары юк. Шулай да татар халкы өчен сөенечле мәгълүматны әйтү зарур: 2010 елда Халыкара Астрономия Берлеге тарафыннан Кояш системасындагы 48631 номерлы кече планетага (Җирдән 250 млн. км ераклыкта, диаметры – 3 км) Хәсән Туфан («Hasantufan») исемен бирү турында карар кабул ителде. Әлеге планетаны 1995 елның 26 сентябрендә Казан дәүләт университеты обсерваториясендә үзешчән астроном Тимур Валерьевич Крячко ачкан. Шагыйрьләрдән кече планета исемнәренә лаек булган Анна Ахматова, Иосиф Бродскийны атарга мөмкин. Кояш системасында халыкара рәсми кабул ителгән татарча исемле кече планетаның булуы – татар халкы өчен зур горурлык.

5. *Комета, астероид һәм метеоритларны белдергән космонимнар.* Комета (бор. грек. *κομήτης, komḗtēs* – «чәчле») – Кояш тирәли әйләнгән, якты томан белән өртүле, үзәге һәм койрык сыман якты полосасы булган күк җисеме; койрыклы йолдыз. Татар телендә кометалар исем белән аталмаган, астрономия фәнендә аларны, гадәттә, астроном-галим исеме белән атаганнар (*Галлей кометасы, Энке кометасы* һ.б.). 1994 елда Халыкара астрономия берлеге кометаларны атау өчен яңа система кабул итә. Әлеге системада кометаларны билгеләүдә саннар һәм хәрефләр кулланыла, астероидлар өчен дә шундый ук классификация гамәлдә йөри. Астероидлар – Кояш системасына кергән, чагыштырмача зур булмаган космик җисемнәр. Алар Кояш тирәли әйләнәләр, формалары симметрик түгел, диаметрлары бердән алып 1000 км.га кадәр була, атмосферасыз, ләкин иярченнәре булырга мөмкин.

Кояш системасында түбәндәге астероидлар күзәтелә: *Икар, Ирида, Нестор, Паллада, Патрокл, Приам, Симеиза, Фигнерия, Эрот, Этра, Юнона* һ.б.

Метеорит – эре күк җисеменең өстенә галәмнән очып килеп төшкән физик җисем, эрерәкләре *болид* дип аталган. Шулай ук татар телендә метеорит исемнәре юк, гадәттә, алар кайда төшсәләр, шул урын исеме белән аталганнар (мәсәлән, *Тунгус, Үргәнеч, Стәрлетамак метеоритлары* һ.б.). «1937 елның сентябрендә Мөслим районы үзәгеннән 18 километр ераклыктагы Каенсаз авылы кешеләре авылдан 300 метрлап читтә, кечкенә урман эченә, көчле күкрәү авазлары белән һаваны ярып, якты эз калдырып, утлы шарлар рәвешендәге метеорлар төшүен күрәләр. Колхозчылар Шәйгардан Мәрданов, Мәүлидә Бәдриева һ. б. аларның төшкән урыныннан ерак булмыйлар. Көчле һава дулкыны Мәүлидәне хәтта аяктан да ега. Бу хакта тиз арада Мәскәүгә хәбәр ителә. 18 сентябрьдә СССР Фәннәр Академиясеннән килгән галимнәр фәнни-тикшерү эшләрен башлап җибәрәләр, метеорит төшкән урыннар җентекләп өйрәнелә. Иң зур метеорит кисәге табылган чокырның киңлеге 110, озынлыгы 150, тирәнлеге 100 сантиметр була, метеоритның авырлыгы исә 102,5 килограмм тәшкил иткән. Ул Фәннәр Академиясе метеоритлар комитеты каталогында «Каенсаз – 1090» исеме белән теркәлә һәм шунда саклауга куела» – дип яза тарихчы Ә. Әхмәтгалиев (Әхмәтгалиев, 2004).

6. *Космос һәм галактиканы белдергән космонимнар.* Космос (грекча *κόσμος* – «тәртип», «гүзәллек») – «дөнья, галәм, матди дөнья» дигәнне аңлата. Татар телендә бу төшенчәне аңлату өчен гарәп теленнән алынган *галәм* һәм төрки *аҗун* сүзләре кулланылган.

*Галәм* гадәттә бар булган һәрнәрсәне – матдә һәм энергия, планеталар, йолдызлар, галактикалар һәм галактикаара бушлыкның барлык эчтәлеген үзенә ала. *Галәм (аҗун)* сүзенә билгеләмә бирү шактый кыен һәм күптөрле, ул татар телендә кулланыла торган *космос*, *дөнья* һәм *табигать* сүзләре белән мәгънәдәш булып килә ала. Барлыкка килүен Зур шартлау белән бәйләп аңлаткан теорияләр дә, күпгаләмлелек теорияләре дә фәндә бүгенге көнгә кадәр яши. Борынгы төркиләрнең галәм төзелешен аңлаткан үзенчәлекле ышанулары булган, бу ышанулар нигезендә дөньяның өч өлештән – югары, урта һәм аскы өлешләрдән торуы тас-

вирланган. Космос югары өлешне тәшкил иткән, кешеләр күк җисемнәренә табынганнар, йолдыз һәм йолдызлыкларны аерып, аларга атама биргәннәр. Әлбәттә, галактика турында күзаллаулар төрки халыкларга фән аша соңгы гасырларда, телескоп барлыкка килгәч үтеп кергән. Татар телендә төрки чыгышлы бердәнбер галактика исеме кулланыла: бу – Киек Каз юлы *(Саман, Салам юлы)*, ягъни Кояш системасы урнашкан үзебезнең галактика. Башка галактика атамалары (мәсәлән, *Көнбагыш галактикасы, Зур һәм Кече Магеллан Болыты, Боде*, *Рәссамчы (Көмеш тәңкә), Өчпочмак, Мейола, Хог, Чоңгыл, Антенна, Орчык, Тычкан, Сигара, Арба тәгәрмәче, Чукмарбаш, Сомбреро, Фейерверк, Каракүз (Йокыга талган Гүзәл), Әйләнмә* һ.б. галактикалар). Бу космонимнарның кайберләре (*Мейола, Хог*) аларны ачкан астроном фамилиясе белән аталса, башкалары охшатуга нигезләнгән метафора ярдәмендә исемләнгән.

Галимнәр әйтүенчә, галәмдә егерме триллионнан артык галактика булырга мөмкин, Җир шарыннан гади күз белән аларның өчесен генә *Зур һәм Кече Магеллан Болытын, Андромеда томанлыгын* гына күреп була. Галактика исемнәре татар телендә алынма исем буларак яисә рус теленнән тәрҗемә ителгән формада кулланылалар.

7. *Астротопонимик берәмлекләр.* Астротопонимика – планеталар, аларның иярченнәре һәм астероидлар өслегендәге объект атамаларын өйрәнә торган тармак. Астротопонимнар аерым планета, иярчен яки астероидка карасa, шул җисем исеме белән бәйле рәвештә ачыклана (мәсәлән, селеноним – Җир иярчене Ай өслегендәге, марсионим – Марс өслегендәге, меркурионим – Меркурий планетасы өслегендәге объектларның атамасы). Биредә шуларның кайберләрен карап китәрбез.

Ай өслеге атамалары – селенимнар: *Салават күпере култыгы* (Залив радуги); *Чык култыгы* (Залив Росы); *Урта култык* (Срединный залив); *Карпат таулары; Дымлы диңгез* (Море влажности); *Дулкыннар диңгезе* (Море воли); *Көнчыгыш диңгезе* (Море восточное); *Яңгырлар диңгезе* (Море дождей); *Кырый диңгез* (Море краевое); *Хәвефле диңгез* (Море опасностей); *Хыял диңгезе* (Море мечты); *Тыныч диңгез* (Море мирное); *Мәскәү диңгезе* (Море Москвы); *Яңа диңгез* (Море новое); *Болытлар диңгезе* (Море облаков); *Пар диңгезе* (Море паров); *Күбек диңгезе* (Море пены); *Уңыш*

*диңгезе* (Море плодородия); *Тынлык диңгезе* (Море спокойствия); *Суык диңгезе* (Море холода); *Аязлык диңгезе* (Море Ясности); *Әҗәл күле* (Озеро смерти); *Төшләр күле* (Озеро сновидений); *Давыллар океаны* (Океан бурь) һ.б.

*Марс* өслеге атамалары – марсионимнар: *Амазония тигезлеге* (Равнина Амазония), *Тиррен диңгезе* (Тирренское Море), *Олимп платосы* (Плато Олимп), *Елисей платосы* (Елисейское Плато), *Кече Сырт* (Малый Сырт), *Зеферия тигезлеге* (Равнина Зеферия), *Эолия тигезлеге* (Равнина Эолия), *Азания тигезлеге* (Равнина Азания), *Сиреналар диңгезе* (Море Сирен), *Аокий култыгы* (Аокийский Залив); *Гордий төене* (Гордиев Узел), *Атлантида, Улисса бугазы* (Пролив Улисса), *Антей каналы* (Канал Антей), *Феникс күле* (Озеро Феникса), *Харон өч юл чаты* (Трёхпутье Харона) һ.б.

## § 45. Космонимнар төзелеш-ясалышында төп үзенчәлекләр

Кайбер тикшеренүләрдә төрки телләрдәге космонимнарга этимологик анализ ясалса да, төрки ономастика фәнендә аларны структур планда системалы өйрәнүләр алып барылмаган.

Космонимнарның ясалышы үзенчәлекле, чөнки аларның күбесе предметларны туры мәгънәсендә атамыйлар, ә охшашлыкка нигезләнгән күчерелмә мәгънә – метафоралаштыру ярдәмендә барлыкка килгәннәр. Димәк, төп номинация принципы – метафоралаштыру (Рут, 1970: 106). Номинацияләнү процессы да шартлы – аерым бер пространство һәм вакыт аралыгында гына номинатив мәгънә белән предметлык төшенчәсе туры килә ала. Мәсәлән, күк йөзендә аерым бер дәвердә һәм урында кеше чүмечкә (башка халыкларда – аюга) охшаган йолдызлык сурәтен күрә һәм аны *Чүмеч йолдыз (Аю йолдыз)* дип атый. Алда әйтелгәнчә, йөз мең еллар элек исә бу йолдызларның торышы башкача булган һәм кеше аларны башка сурәттә күргән. Халык космонимнарында күмәклек исемнәренең онимлашу процессы күзәтелә, ә һинд-Европа телләреннән алынган космонимнар мифологик ялгызлык исемнәре җирлегендә барлыкка килгәннәр (мәсәлән, *Беллатрикс, Кассиопея, Венера, Марс* һ.б.). Эстон телендәге космонимнарны тикшергән галим П.К. Прюллер күрсәтүенчә, «Эстон күк йөзеннән безгә крестьянның авыл хуҗалыгы белән бәйле тормыш-көнкүреше карап

тора» (Прюллер, 1966: 155). Моны төрки халыклар турында да әйтергә була: халык космонимнары төрки халыкларның тормыш-көнкүрешен чагылдырган, шуңа күрә без күк йөзендә тимер казыкка бәйләнгән бүз атларны, чүмеч (тустаган), иләк һ.б. йолдызларны күрәбез. Димәк, халык космонимнарының номинацияләнү процессы турыдан-туры халыкның яшәү рәвеше белән бәйле.

Рус телендәге космик объектларның семантик модельләре нигезен, Ю.А. Карпенко фикеренчә, түбәндәге ялгызлык исемнәре тәшкил итә:

1) мәҗүси аллалар һәм алиһәләр исеме (*Астрея, Юнона, Амур*);

2) хатын-кыз исемнәре (*Надежда, Мариэтта*);

3) астрономнарның яки күренекле шәхесләрнең исем-фамилияләре (*Галилео, Вольфиана*): ир-ат фамилияләре (*Ульянов, Коперник, Жуков, Орлов*); хатын-кыз фамилияләре (*Кеннония, Яхонтовия*);

4) топонимнар (*Европа, Россия*);

5) төрле абстракт и күмәклек исемнәр (*касә, арыслан, юл, салам* һ.б.) (Карпенко, 1981: 4–14)

Төрки телләрдә исә бу бүленеш рус теле аша һинд-Европа телләреннән кергән алынмаларга һәм тәрҗемә ителгән калька космонимнарга туры килә. Алар татар халкының үз тарихын чагылдырмыйлар. Хәзерге татар телендә кулланылган халык космонимнарын аерып карасак, аларның семантик модельләре түбәндәге нигездә барлыкка килгән:

1) хайван-җәнлекләр, кош атамаларына нигезләнеп барлыкка килгән космонимнар (*Киек Каз юлы; Акбүзат, Күкбүзат йолдызлары*);

2) халыкның тормыш-көнкүреш предметларына, корал атамаларына нигезләнеп барлыкка килгән атамалар (*Тимер Казык, Чүмеч, Тустаган, Көянтә, Иләк йолдызлар*);

3) хатын-кыз исеменә нигезләнеп барлыкка килгән атама (*Зөһрә йолдыз*);

4) Төс яки процесс мәгънәсенә нигезләнеп барлыкка килгән атамалар (*Алтын Казык, Кызыл йолдыз, Ай, Кояш* һ.б.);

5) вакыт мәгънәсенә нигезләнеп барлыкка килгән атамалар (*Таң йолдызы, Шәфәкъ йолдызы*);

6) санга нигезләнгән атама *(Җидегән/Етегән);*

7) күк йөзендәге урынына бәйле рәвештә барлыкка килгән атама *(Котып йолдызы)*.

Бүленештән күренгәнчә, халык космонимнары арасында тормыш-көнкүреш предметларына, корал исемнәренә нигезләнеп барлыкка килгән атамалар күпчелекне тәшкил итә. Киләчәк хезмәтләрдә бу бүленеш диалект материалларын теркәп, шулар нигезендә ачыклап бетерүне сорый.

Составы ягыннан телдә кулланылган космонимнарны (алынма һәм тәрҗемә вариантларны кертеп) ике төркемгә бүлеп карарга мөмкин:

1) бер компонентлы (бер сүздән торган) космонимнар: *Җир, Марс, Ай, Кояш, Әвернә, Аждаһа, Бүре, Елан* һ.б.

2) ике яки берничә сүздән торган космонимнар: *Ау этләре, Вероника чәче, Киек каз юлы, Арго корабле, Андромеда томанлыгы, Зур Магеллан болыты, Зур эт* һ.б.

Космонимнарның күпчелеге бер компонентлы гына. Ике яки берничә (өч) сүздән торган космонимнар сирәгрәк очрый, алар, күбесенчә, татар теленә тәрҗемә ителгән атамаларда яки астротопонимик берәмлекләрдә күзәтелә.

Хәзерге татар әдәби телендәге космонимнарның ясалышы татар теленең сүзъясалыш закончалыкларына бәйле рәвештә түбәндәгечә нормалашкан.

1) *тамыр космонимнар*: *Бүре, Арыслан, Кояш, Ай, Җир, Сатурн, Елан, Жираф* һ.б.;

2) *кушма космонимнар: Акбүзат* (ак + бүз + ат), *Күкбүзат* (күк + бүз + ат), *Үгезбозау* (үгез + бозау), *Кәҗәмөгез* (кәҗә + мөгез), *Сукояр* (су + кояр), *Каракош* (кара + кош), *Өчпочмак* (өч + почмак), *Сыңармөгез* (сыңар + мөгез), *Тимерказык* (тимер+ + казык), *Аккош* (ак + кош) һ.б.;

3) *тезмә космонимнар*: *Киек каз юлы, Алтын балык, Андромеда томанлыгы, Арго корабле, Ат башы томанлыгы, Вероника чәче, Зур Магеллан болыты, Зур эт, Иләк йолдыз, Көньяк балыгы, Көньяк Гидра, Көньяк өчпочмагы, Крабсыман томанлык, Очар балык, Үгез көтүчесе, Центавр Альфасы* һ.б.

Әлеге космонимнар *исем* + *исем* конструкциясенең беренче һәм икенче изафә төрләре нигезендә ясалганнар. 1 нче төр: *Алтын балык, Иләк йолдыз, Көньяк Гидра* һ.б.; 2 нче төр: *Киек каз юлы,*

*Андромеда томанлыгы, Арго корабле, Ат башы томанлыгы, Вероника чәче* һ.б. Шул ук вакытта *сыйфат+исем* конструкциясе дә урын ала: *Зур эт, Крабсыман томанлык, Очар балык* һ.б.;

4) *Кушымчалау ысулы белән* ясалган космонимнар: *Еланлы, Укчы, Почмаклык, Йөкче.*

Бу төр космонимнар сирәк күзәтелә. Мисаллардан күренгәнчә, ясалма космонимнарның барлыкка килүендә *нигез + чы/че (Укчы, Йөкче); нигез + лы/ле (Еланлы); нигез + лык/лек (Почмаклык)* модельләре катнаша.

Лексик-семантик ысул белән космонимнар ясалуында алынмалык ысулын күрсәтергә мөмкин. Хәзерге татар әдәби телендәге космонимнар арасында рус теле аша һинд-Европа телләреннән кабул ителгән космонимнар күпчелекне тәшкил итә. Төрки чыгышлы космонимнар бик сирәк кулланыла, бу – татар телендәге космонимик берәмлекләрнең җитәрлек күләмдә тупланылмавы һәм өйрәнелмәве белән дә бәйләп аңлатыла булса кирәк.

Шул рәвешле, космонимнарның төзелеш-ясалышында түбәндәге үзенчәлекләрне күзәтергә мөмкин:

1. Космонимнарның күпчелеге охшашлыкка нигезләнгән метафоралар ярдәмендә номинацияләнү процессын кичергәннәр. Халык космонимнарының нигезендә тормыш-көнкүреш кирәк-яраклары урын алса, башка телләрдән алынган космонимнарга мифологик номинацияләнү хас.

2. Космонимнарның күпчелеге бер компонентлы (бер сүздән торган) атамалар.

3. Тамыр космонимнар күпчелекне тәшкил итә. Кушымчалау ысулы белән ясалган космонимнар сирәк кулланыла.

4. Хәзерге татар әдәби телендәге космонимнар арасында рус теле аша һинд-Европа телләреннән кабул ителгән космонимнар күпчелекне тәшкил итә.

Шулай итеп**,** йолдызлы күк йөзе борынгы чорлардан алып, хәзерге көнгә кадәр кешеләрнең игътибарын үзенә җәлеп итә. Фәнни-техник алгарыш заманында йолдызлар һәм башка космик объектлар үзләренең беренчел функцияләрен – юл күрсәтү, вакыт билгеләү һәм һава торышын фаразлау өчен кулланышларын югалтып, әдәби-эстетик функциядә – әдәби һәм сәнгати сурәт ясау өчен кулланылалар. Хәзерге телләрнең күбесендә, шул исәптән татар телендә дә, космик объектларның беренчел вазифалары югалу

сәбәпле, аларның онимлашкан атамалары халык хәтереннән җуела, шуңа күрә аларны туплау һәм өйрәнү киләчәк буыннарга тел мирасы калдыру өчен дә бик әһәмиятле.

Татар әдәби телендәге космонимикага караган материалны өйрәнү барышында түбәндәге үзенчәлекләр ачыкланды:

1. Ономастика фәне кысаларында барлыкка килгән күк җисеме атамаларын өйрәнү юнәлеше – татар теле белеме өчен чагыштырмача яшь һәм өйрәнелмәгән өлкәләрнең берсе. Рус ономастика фәнендә дә бу юнәлешне *космонимика* яисә *астронимика* дигән терминнар белән атау мәсьәләсе тулысынча хәл ителмәгән. Әлеге хезмәттә *космонимика* термины нигез итеп алынды.

2. Космонимик терминнар борынгы кешеләрнең дөнья һәм галәм төзелеше турында иң беренчел күзаллауларын, көнкүрешен, фәлсәфәсен, мифологиясен һәм халык авыз иҗатын өйрәнүдә әһәмиятле чыганакларның берсе булып тора. Кызганыч ки, татар телендәге космонимик терминнар җитәрлек дәрәҗәдә өйрәнелмәгән. Бу уңайдан күк җисемнәрен өйрәнүгә омтылыш буларак, аерым мәкаләләр дөнья күрсә дә, татар теленең гомумхалык сөйләмендә, диалектларында, борынгы һәм иске язма истәлекләрендә кулланылган космонимик атамалар исемлеге тулы күләмдә тупланмаган һәм системалаштырылмаган. Димәк, әлеге юнәлештә эзләнүләр алып бару киләчәк эше булып кала.

3. Хәзерге татар әдәби телендә саф төрки чыгышлы, татар халкына караган космонимнар сан ягыннан күп түгел. Бу – татарларның шактый күптәннән утрак тормышка күчү сәбәпле, күк җисемнәренең борынгы атамалары телдән югалуы белән аңлатыла булса кирәк. Шуңа карамастан, халык аңында бүгенге көндә дә күк йөзендә күзәтелгән төп космонимик җисемнәрнең атамалары саклана, алар фольклор әсәрләрендә, матур әдәбиятта, халыкның җанлы сөйләмә телендә кулланылуларын дәвам итәләр.

4. Әлеге хезмәттә космонимнарны төркемләү генетик һәм лексик-тематик классификация принципларын кулланып башкарылды. Туплау өчен материал М. Галеев һәм А. Тимергалин тарафыннан эшләнгән «Русча-татарча астрономия терминнары сүзлеге»ннән алынды. Генетик яктан космонимнар арасында 1) сан ягыннан аз булган төрки чыгышлы. 2) ислам дине кабул ителгәннән соң, гасырлар дәвамында Көнчыгыш мәдәнияте һәм фәне йогынтысы шартларында Идел буена үтеп кергән гарәп-фарсы алынмалары

һәм 3) күпчелекне тәшкил иткән, рус теле аша һинд-Европа телләреннән кергән космонимнар каралды. Лексик-тематик яктан космонимнар, галим К.Г. Аронов классификациясенә нигезләнеп, җиде төркемгә аерылды: 1) аерым йолдыз исемнәрен белдергән космонимнар; 2) йолдызлык исемнәрен һәм йолдыз төркемнәрен белдергән космонимнар; 3) зодиак йолдызлыкларын белдергән космонимнар; 4) Кояш системасында урнашкан күк җисемнәрен белдергән космонимнар; 5) комета, астероид һәм метеоритларны белдергән космонимнар; 6) космос һәм галактиканы белдергән космонимнар; 7) астротопонимик берәмлекләр. Бу төркемнәр арасында күпчелекне аерым йолдыз исемнәрен белдергән космонимнар алып тора.

5. Төрки-татар чыгышлы космонимнарның ясалышы хәзерге татар әдәби теле сүзьясалышы кануннарына нигезләнеп формалашкан. Космонимнар арасында тамыр сүзләр күпчелекне тәшкил итә, кушымча ярдәмендә ясалган төр иң аз санлы булып тора. Хәзерге татар космонимикасы рус теле аша һинд-Европа телләреннән кергән алынма лексика һәм рус теленнән тәрҗемә итү хисабына байый.

Космонимик лексиканы өйрәнү хәзерге телне өйрәнү өчен дә, тел тарихы юнәлеше өчен дә әһәмиятле, чөнки күк җисемнәрен белдергән кайбер атамалар кешелек тарафыннан үзләштерелгән иң борынгы сүзләр булырга мөмкин. Киләчәк хезмәтләрдә чагыштырмалы ысул нигезендә Идел буе телләре (төрки, славян һәм фин-угор) һәм Идел буе төрки телләре (татар, башкорт, чуваш) өчен уртак космонимнарны өйрәнү, тарихи-чагыштырмалы ысул ярдәмендә космонимнарның хронологик кулланылу чикләрен ачыклау, этнолингвистик эзләнүләр дә кызыклы нәтиҗәләр бирергә мөмкин.

## ТАТАР ЗООНИМИКАСЫ

### § 46. Татар зоонимикасына гомуми билгеләмә

З о о н и м и к а – ономастиканың хайван һәм кош-корт кушаматларын, ягъни зоонимнарны өйрәнә торган тармагы (Саттар-Мулилле, 1994: 4). Грек теленнән кергән *зooним* (грек. *ζῷον* – хайван һәм *ὄνομα* – исем, ат) сүзе хайваннарның (кыргый һәм йорт хайваннарының) исеме, кушаматы дигәнне белдерә. *Зоонимика* терминын зоонимия белән бутарга ярамый. Зоонимия хайван атамалары (*сыер, сарык, эт, песи, куян* һ.б.) җыелмасы ул.

*Зооним* термины беренче тапкыр тел белемендә 1960 еллардан соң А.В. Суперанская һәм П.П. Чучка хезмәтләрендә күренә башлый (Суперанская, 1965: 35; Чучка, 1964: 61–63). Әлеге терминны бер төркем галимнәр (Миронюк, 1987: 4, Подольская, 1978: 58–59, Шевчик, 2011: 9, Юсифов, 1985: 10) хайван атамаларын, икенчеләре (Поротников, 1972: 210, Рядченко, 1988: 90) хайван кушаматларын белдерү өчен файдалана. Зооним термины ике мәгънәдә дә кулланыла ала дигән фикерне яклаучылар да (Леви-Стросс, 1983: 3; Юсифов, 1985: 8), буталыш китмәсен өчен башка терминнар кертергә кирәк дигән фикердә торучылар да (Кацитадзе, 1985: 11; Морковкин, 1983: 56) бар.

«Зооним ул – хайваннарның, шул исәптән, аларның зоология бакчаларындагы төрләренең, йорт хайваннарының, циркта «эшләүче», сакта торучы, тәҗрибә өчен тотылучы яисә кыргый хайваннарның исеме, кушаматы» дигән билгеләмә киң таралган булса да (Подольская, 1978: 58-59), күп кенә телләрдә бүгенге көнгә кадәр зооним термины ике мәгънәдә: хайван атамалары җыелмасы (*төлке, кәҗә, дуңгыз, аю, сыер, эт һ.б.*) һәм әлеге хайваннарның кушаматлары (*Акбай, Алмачуар, Рекс, Актырнак, Джек һ.б.*) буларак кулланыла килә.

Ономастиканың башка тармаклары белән чагыштырганда, зоонимика бик аз өйрәнелгәннәрдән санала. Галимнәр моны зоонимнарның рәсми документларда сирәк очракта гына теркәлүе һәм йорт хайванына хуҗасы биргән исемнең дә, ул үлгәч, юкка чыгуы, онытылуы белән аңлаталар.

Зоонимика буенча язылган беренче хезмәтләрдән танылган тюрколог Н.К. Дмитриевның «Собачьи клички у башкир» (1928) мәкаләсен атарга була. Ул, СССР Фәннәр академиясе оештырган лингвистика-фольклор экспедициясе материалларына нигезләнеп, эт кушаматларын анализлауга багышланган.

1961 елда В. Ташицкий «Ономастиканы өйрәнүче галим үзенең тикшеренүләрендә хайван кушаматларына тукталмыйча берничек тә үтеп китә алмый» дигән булган (Ташицкий, 1961: 3). Тик, шулай да, зоонимияне әле бүгенге көндә дә тиешле дәрәҗәдә өйрәнелгән дия алмыйбыз. Тикшеренүләрнең күбесе, нигездә, зоонимик материалны күпмедер дәрәҗәдә лингвистик яктан яктырткан мәкаләләрдән гыйбарәт. Мәсәлән, П.Т. Поротниковның «Из Уральской зоонимии» (1972) хезмәтендә, исеменнән үк күренгәнчә,

Урал якларында – Свердловск өлкәсенең Талицк районында очрый торган зоонимнарга күзәтү ясала. Автор ат, сыер, сарык, дуңгыз, кәҗә, эт, песи һәм тавыклар, казлар, үрдәкләрне атау өчен кулланыла торган кушаматларны анализлый һәм йорт хайваннарының, нигездә, һәрберсенең үзенә генә хас аерым исеме булуына, ә йорт кошларына сирәк очракта гына кушамат бирелүенә игътибар итә. П.Т. Поротников фикеренчә, беренчеләренең, һичшиксез, индивидуаль кушаматы булырга тиеш, ә менә икенчеләренеке алай ук мөһим түгел. Автор моны тавык, каз, үрдәк кебек йорт кошларын, гадәттә, аерым-аерым түгел, ә барысын бергә чакыру белән аңлата (Поротников, 1972: 210–218). А.А. Смирновның «Из зоонимии Горьковской области» мәкаләсе җирле зоонимнарны тел ягыннан тикшерүгә багышланган (Смирнов, 1971: 299–302). Н.Г.Дубованың «Некоторые особенности кличек охотничьих собак» мәкаләсе алардан беркадәр аерылып тора (Дубова, 1980: 145–149). Биредә рус телендәге ау этләренең кушаматлары һәм аларның классификациясе китерелә. Мәкаләдә эт кушаматларына карата, ул вакытлар өчен яңалык буларак, *киноним* термины кулланылган. Әлеге термин моңа охшаш башка фәнни хезмәтләрдә очраса да, телгә актив рәвештә кереп китә алмады. Бу уңайдан, тел белгече Н.Г. Рядченконың фикерендә дә мантыйк бар кебек. Һәрбер хайван кушаматы өчен аерым термин уйлап табу һәм куллану кирәк түгелдер дигән фикер яклы ул. Бүгенге көн күзлегеннән караганда да, галимнәргә таныш әлеге *киноним, иппоним, фелионим* кебек терминнарны киң катлам укучылар белмәскә мөмкин. Зоонимнарга А.В. Суперанская да шактый киң туктала. Аның «Общая теория имени собственного» (1973) китабында һәм аннан соңрак басылган хезмәтләрендә хайван кушаматлары хакындагы кызыклы эзләнүләре урын алган. Н.Г. Рядченко «Зоонимия как особый класс ономастической лексики» мәкаләсендә, шулай ук, хайван кушаматларының бик аз өйрәнелүен, өйрәнелгәннәренең дә төрки телләр материалына нигезләнгән булуын ассызыклый. Ул үзе туплаган рус зоонимнарының номинация принципларын билгели, теге яки бу кушаматның нинди билгеләргә карап бирелүен ачыклый (Рядченко, 1988: 88–96).

Әмма барлык зоонимнарны туплап, аларны фәнни яктан анализлау озак еллар дәвамында актуаль булып кала килгән. 1989 елда «Ономастическая лексикография» хезмәтендә В.Э. Сталмане

хайван кушаматларының бик аз өйрәнелүе һәм сүзлекләрдә гомумән диярлек теркәлмәве турында яза. Тулы зоонимикон булдырыр өчен башта аерым бер җирлектә кулланыла торган ареаль зоонимнарны теркәгән кечкенә зоонимик сүзлекләр төзү кирәк дигән фикерне яклый автор (Сталмане, 1989: 90).

XX гасыр ахыры – XIX гасыр башында зоонимнарга карата кызыксыну аеруча артты. Тел белгечләренең зоонимикага күзәтү ясаган мәкаләләре генә түгел, гади халыкның үз этләре, песиләре һ.б.ның кушаматлары турындагы күзәтүләре дә басыла башлады.

Ономастикага кагылышлы башка тел берәмлекләре белән чагыштырганда, татар телендә хайван кушаматлары бик актив кулланылышта. Зоонимнарны көндәлек тормышта һәм радио-телевидение, театр һ.б.да һәрдаим ишетәбез, әдәби әсәрләрдә, вакытлы матбугатта еш очратабыз. Башлангыч сыйныфларда ук, исемне үткәндә, кулга ияләштерелгән хайваннарга кушамат бирелүе хакында аңлатыла, аларны баш хәрефтән язарга кирәклеге искәртелә (Татар теле, 2017: 12), югары сыйныфларда һәм уку йортларында ономастиканың хайван кушаматларын өйрәнә торган тармагы – зоонимика турында мәгълүмат бирелә һ.б. (Татар теле, 2013: 79). Ләкин, дистә еллар дәвамында актив кулланылышта булсалар да, татар телендә хайван кушаматларын җентекләп өйрәнү һәм анализлауга багышланган фәнни хезмәтләр юк дәрәҗәсендә. Татар зоонимнарына, нигездә, тел белеме һәм ономастика юнәлешендәге хезмәтләрдә генә күпмедер дәрәҗәдә урын бирелә.

Эт, песи, сыер, ат һ.б. йорт хайваннарының исемнәренә багышланган мәкаләләр арасында күпчелекне ат кушаматлары турындагылары тәшкил итә. Мәсәлән, бу хакта Р.Г. Әхмәтьяновның 1975 елда «Некоторые названия лошадей в татарском языке», 1988 елда «Общая лексика материальной культуры народов Среднего Поволжья» һ.б. мәкаләләре дөнья күрә. 2008 елда Г.А. Исхакова «О названиях мастей лошадей в татарском языке» мәкаләсендә атларның төсләрен белдерә торган сүзләрне тикшерә. Әлеге сүзләрнең кайберләре ат кушаматлары составында да кулланыла.

1994 елда Г.Ф. Саттаровның «Татарстан хәбәрләре» газетасында басылган «Татар зоонимиясе (кече туганнарыбызның исемнәре)» мәкаләсендәге мәгълүматлар шактый кызыклы. Автор теге яки бу җан иясен белдерә торган ялгызлык исем-атамасына тарихи

милли лексик хәзинә бирәмлеге һәм милли сүз байлыгын тәшкил итүче кыйммәтле мирас итеп карый. Г.Ф. Саттаров, халкыбызның йорт хайваннарын һәм кош-кортларны кече туганнарыбыз дип атавы, аларның этләргә, песиләргә, атларга, сыерларга һ.б.га булган яратуын белдерә, дип, ассызыклый (Саттар-Мулилле, 1994: 4).

Кешеләрнең, кабилә-кавем, халыкларның инану-ышанулярын, фольклор-әдәбиятын, тормыш-көнкүрешләрен, яшәү рәвешләрен формалаштыру һәм үстерүдә хайваннар дөньясының йогынтысы бик зур булуын галим төрлечә раслый. Аның борынгы бабаларыбызның хайваннарга карата мөнәсәбәте һәм әлеге мөнәсәбәтнең исемнәргә күчүе турындагы күзәтүләреннән чыгып китерелгән мисаллары ономастика фәне өчен бик әһәмиятле. Бүгенге көндә, нигездә, кеше исемнәренең хайван кушаматлары булып йөрүенә игътибар итәбез. Ә тарихка кагылышлы материаллар һәм нигезле дәлилләр, киресенчә, иң элек хайван кушаматларының кеше исемнәренә күчүе хакында сөйли. Бу, әлбәттә, кайбер болгар кабиләләренең үз чыгышларын эт, бүре, барс һ.б. хайваннар белән бәйләүләреннән чыгып аңлатыла. Борынгы төрки кавем-халыкларда эт культы булу, төрки халыкларның этне яман көчләрдән саклый торган изге хайван итеп санаулары, аңа зур хөрмәт күрсәтүләре билгеле. «Болгар-татарларда ир бала талымсыз, авыруларга бирешми торган булсын дигән теләктән чыгып, я булмаса, эт елында туган ир балаларга “эт” мәгънәсенә ия булган сүзләрне кеше исеме итеп бирү йоласы булган. Шушы йола аркасында борынгы телебездә *эт* төшенчәсен белдергән *көчек – коцок, канчык, әнчек, ногай, әнәк, әгер, йыт, барак, көпәк – күбәк* сүзләре кеше исеме (зооантропоним) булып та йөргәннәр» (Саттар-Мулилле, 1994: 3). Бер-берсенә синоним булган *Көчек, Барак, Әнчек* исемнәре исем-фамилияләрдә сакланып калган һәм аларның кайберләре әле дә кулланыла. «Борынгы һәм иске татар телендә *Этбай, Эткол, Эткөчек, Этҗимас* («эт ашамас»), *Эткенә* һ.б. кебек кеше исемнәре кулланылышта йөргән» (шунда ук: 4).

Фән телендә *кош-корт, хайван кушаматлары* дигән рәсми термин булса да, җанлы сөйләм телендә татарларның ат кушаматы, сыер кушаматы һ.б. дип түгел, ә ат исеме, сыер исеме, эт исеме дип сөйләшүен күздә тотып, Г.Ф. Саттаров дә «татар телендә дүрт аяклы дусларыбыз турында сүз алып барганда, кешегә карата кулланыла торган исем терминын куллану дөрес һәм урынлы

булыр», – ди (Саттар-Мулилле, 1994: 4). Галим фикеренчә, бу – кешенең әлеге хайваннарны якын итүен, үз итүен күрсәтә.

З.Ф. Миргалимованың «Названия млекопитающих в татарском литературном языке» хезмәтендә кайбер хайваннарның атамасына кагылышлы мәгълүматлар табарга була (Миргалимова, 2007: 3–22).

«Сарман ягы – нурлы як» исемле сайтта урнаштырылган «Сарман районы атамалары» дигән мәкаләдә үз якларында кулланыла торган этноним, гидроним, топоним, космоним, ороним, эргоним, ойконим һ.б.ш. белән беррәттән, кайбер зоонимнарга да мисаллар китерелә. Бу районда хайваннарга кушамат аларның аерым бер үзенчәлекләре, төсләре һ.б. буенча бирелгән (*Актүш, Акбай, Сарбай, Алабай* – этләр, *Чуаркай* – тавык, *Иркә, Шомырт* – сыерлар һ.б.). Мәкаләдән күренгәнчә, җирле зоонимнарны *Мурка, Шарик, Чарли, Рекс* һ.б. кебек алынма кушаматлар һәм сериал геройларның исемнәре (*Марианна, Лорена, Мендисобаль*) чуарлый (http://sarmanyaq.ucoz.ru/load/sarman_rajony_atamalary/1-1-0-1).

А. Гәрәеваның «Клички домашних животных в английском, русском и татарском языках» мәкаләсендә дә актив кулланылышта булган кушаматларга мисаллар китерелгән (Гареева, 2015: 19).

Әлбәттә, бүгенге көн өчен болар гына бик аз. Башка телләрдә һәрбер йорт хайванының кушаматларын аерым-аерым җыеп, туплап өйрәнгән, анализлаган хезмәтләр бар. Мәсәлән, Е.В. Гусеваның «Социально-культурные факторы номинации (на материале современных городских зоонимов)» (2005), О.П. Дмитриеваның «Ономастическое пространство Россошанского района Воронежской области» (2009) диссертацияләре һәм А.А. Пашкевичның «Особенности кличек животных как именных классов» (2006), Е.А. Цыпанованың «Клички собак в коми языке» (2010), У.М. Трофимованың, М Трофимованың «О некоторых принципах наименования животных (на материале кличек кошек и собак г. Бийска)» (2011), Ю.И. Чайкина, Е.Н. Варникованың «Антропозоонимы» (2012), О.А. Великанованың «Современные сельские зоонимы» (2012) мәкаләләре шундыйлардан.

Бу хезмәт әлегә кадәр булган бушлыкны тутырып, алга таба тикшеренүләр алып бару һәм татар телендәге барлык зоонимнарны туплап анализлау өчен җирлек булыр дип өметләнәбез.

## § 47. Татар телендә зоонимнарны төркемләү

Ономастика, дөресрәге, аның зоонимика дигән бүлеге кешеләрнең үз хайваннарына исем биргәндә нәрсәгә игътибар итүләрен өйрәнә. Кушамат, беренче чиратта, аны уйлап табучының аң-белем дәрәҗәсенә, интеллектына, фантазиясенә, кызыксынуларына, хайваннарның кайда яшәвенә дә бәйле. Мәсәлән, цирктагы өйрәтелгән хайваннарга яңгырашлы, матур исемнәр бирәләр. Ау вакытында тиз генә чакырып алырга уңайлы булсын өчен, ау этләренә кыска, җитди кушаматлар бирелә. Мәсәлән: *Аврора, Герда, Хазар, Туман, Фрида* һ.б. Песиләргә – нәфис, ягымлы, назлы, сыерларга уңайлы, истә кала торган һ.б. исемнәр бирергә тырыша халык. Йорт хайваннарын гаилә әгъзасы кебек кабул итеп, яратып, назлап аларны хәтта берничә исем белән дә атарга мөмкиннәр. Мәсәлән, хуҗасының кәефенә карап, бер үк песи *Йомшак*, яисә *Йомшаккай, Йомшагым* да була ала.

Төрле тел культуралары арасында гына түгел, бер үк тел культурасы эчендә дә зоонимиканы аерым төркемнәргә бүлеп карарга мөмкин. Мәсәлән, шәһәр зоонимикасы, авыл зоонимикасы, заманча зоонимика, элеккеге, ягъни тарихи зоонимика һ.б. Авыл зоонимикасы шәһәрнекеннән гади, халыкчан булуы белән аерыла (мәсәлән: *Актырнак, Актәпи, Тузик, Барсик*). Бүгенге зоонимика элеккегедән заманча һәм ниндидер дәрәҗәдә халыкара булуы белән игътибарны җәлеп итә (*Рекс, Джек, Граф, Крис, Фрида*). Гади халык хайван исемнәренең гадәти, традицион, киң таралыш алганын сайларга яратса, шәһәр кешеләре этләрен, песиләрен теге яки бу кешегә, персонажга һ.б.га бәйләп атарга һәм оригиналь исемнәр сайларга тырышалар.

Димәк әле зоонимнар йорт хайваннарының токымына карап та аерыла. Мәсәлән, овчарка кебек этләрнең исемнәре дә үзләренә туры килеп, көчле, дәрәҗәле, затлы булуларын белгертеп торырга тиеш дип санала (*Амур, Алмаз, Армани* һ.б.). Кайбер илләрдә (мәсәлән, Англиядә) токымлы этләргә исем кушканда берничә кагыйдәне истә тоталар: яңа туган эт баласының исемендә ул яши торган питомникның исемен чагылдырырга, ата, аналарының исемнәренә тематик яктан бәйләнешле булган яки шул исемнәрнең беренче хәрефенә башланган кушамат уйларга тырышалар (Пашкевич, 2006: 63).

Токымлы атларга да исемне очраклы рәвештә генә кушмыйлар. Мәсәлән, инглизләр элек-электән колынның исемендә атасының һәм анасының исемнәрендәге хәрефләрне, иҗекләрне чагылдырырга яисә бу исемнәр арасында ассоциатив бәйләнеш булдырырга тырышалар (Пашкевич, 2006: 63). Анасының исемендәге беренче хәрефкә башланган яисә атасы һәм анасы исемнәренең иҗекләреннән ясалган зоонимнар татарларда да очрый. Мәсәлән, атасының исеме *Верный*, анасыныкы *Назлы* булып, алардан туган атка *Весна* дип исем бирелгән. Атларга исем кушканда яңгырашлы, матур исемнәр уйлап табарга тырышу аларның чабышларда катнашуы белән, токымлы атларга мөнәсәбәтнең һәм игътибарның югары булуы белән аңлатыла. Кайбер хуҗалыкларда йорт хайваннарын алар туган ай исемендәге хәрефкә башланган кушамат белән атау киң таралган (мәсәлән, мартта туганнар «М» хәрефенә, августта туганнар «А» хәрефенә). Эт үрчетүдә, эт күргәзмәләрендәге халыкара традицияләр һәм этләрнең төрле максатлардан чыгып кулланылуы (ау этләре, йорт этләре, бүлмә этләре һ.б.) да үзенчәлекле мотивлаштыру билгеләре, милли үзенчәлекләре булган исемнәр системасын барлыкка китергән.

Мотивациясенә карап, зоонимнарны төп ике зур төркемгә: хайваннарны характерлый торган һәм ирекле (бу очракта: бернигә дә нигезләнмәгән, ошаганга күрә генә кушылган) кушаматлар була (Пашкевич, 2006: 63). Моннан тыш, зоонимнарны, кулланылыш өлкәсенә карап, рәсми (ягъни, паспортында язылганча) һәм рәсми булмаган (эндәшкәндә, чакырганда кулланыла торган) төрләренә дә аерып була (Суперанская, 1973: 180). Кушамат бирелү ешлыгыннан чыгып, Д.И. Ермолович хайваннарны, иң беренче чиратта, йорт хайваннарына (эт, песи һ.б.) һәм малларга (сыер, бозау, үгез, ат, колын, кәҗә һ.б.) аерып карый. Нигездә, шуларына кушамат бирелә. Шул ук вакытта, автор җәмгыять өчен әһәмияте булган башка хайваннарга (мәсәлән, зоопаркларда һәм циркләрдагы җәнлекләргә һ.б.) да исем бирелергә мөмкинлеген искәртә (Ермолович, 200: 113).

Чыганак тел буенча татар зоонимнарын алты төркемгә аерып була:

1) төрки-татар зоонимнары. Алар татар телендә генә түгел, башка төрки телләрдә дә кулланыла торган төрки нигездән ясал-

ган. Мәсәлән: *Илбарс, Сөенеч*, *Сарбай*, *Карлыгач, Сарыкай, Борнак, Сарытай, Кашкар, Идел, Илкәй, Сагынбай* һ.б.;

2) татар теленең үз зоонимнары: *Сылу*, *Көрәнкашка, Сарыбикә, Сандугач, Сылукай, Елгыр, Сандугачсылу* һ.б.;

3) рус теленнән кергән зоонимнар. Телебездә руслардан кергән хайван атамалары аеруча күп. Ат исемнәрендә – *Юпитер, Краснуха, Сивка, Ветерянка* һ.б. Сыер исемнәрендә – *Зорька, Зойка, Бурка* һ.б. шундыйлар. *Тузик, Пират, Лайка, Барбос, Снежок, Дружок* кебек эт исемнәре дә һәркайсыбызга таныш. Бу мисаллар татарларның үз хайваннарына руслар һ.б. халыклар яратып куша торган атамаларны бик теләп бирүләре хакында сөйли;

4) Европа телләреннән кергән зоонимнар: *Джек, Тэдди, Майкл, Мадонна, Лорена* һ.б.;

5) гарәп теленнән кергән зоонимнар: *Салават, Фатыйма, Сайфия, Тансык, Талия, Ләйлә* һ.б.;

6) фарсы теленнән кергән зоонимнар: *Наза, Миян, Биллүр, Гөлбану, Гөлзар* һ.б. Мисаллардан күренгәнчә, гарәп һәм фарсы теленнән кергән хайван кушаматларының күбесе антропозоонимнардан гыйбарәт.

Соңгы елларда, кызганычка каршы, чын татар исемнәренә караганда, рус һәм рус теле аша чит телләрдән кергән кушаматларга өстенлек бирелә. Бу җәһәттән, Адлер Тимергалин да бик дөрес күзәтү ясаган: *«Акбай, Сарбай, Дүрткүз, Актырнак, хәтта Такташның Караборыны кебек матур-матур эт исемнәре безгә артык гадәти булып тоелган күрәсең. Жюль Вернның «Серле утрау» романы татар телендә өч китап булып басылып чыккач, Азат Музгаркасын андагы акыллы эт исеме белән Топ дип атап маташкан иде дә, Музгаркабыз яңа исемне колагына да элмәде, хәтта холыксызланды, шулай Музгарка көенчә калды»* (А. Тимергалин). Шунысын да искәртик, әлеге кушаматлар аерым бер билгеләргә карап түгел, ә бары тик гадәтләнгән исем, җайлы, җиңел исем булулары өчен бирелгән. Ә уйлап кушылган очракта, исем нигездә, хайваннарның төсенә яки күзгә ташланып торган аерым билгесенә, холкына, берәр әгъзасының үзенчәлегенә (төс буенча, ниндидер билге, тамга буенча, мәсәлән) һ.б.га карап бирелә.

Зоонимнар барлыкка килүдә төп модельләр һәм чыганаклар дип Д.И. Ермолович түбәндәгеләрне атый:

1) күпчелек антропонимнар;

2) аерым очракларда гына, сирәк кулланыла торган антропонимнар (танылган кешеләрнең исем-фамилияләре, әдәби әсәрләрдән алынган атамалар һ.б.);

3) топонимнар һәм астронимнар;

4) төрле товарлар, җитештерелгән әйбер атамалары (Капучино, Кэдбери) һ.б.;

5) уртаклык исемнәр һәм хайваннарны характерлый торган башка сүзләр, гыйбарәләр (*Верный, Буян*) (Ермолович, 2001: 113–114).

Хайван кушаматларының мотивлаштыру билгеләре төрле булырга мөмкин. Мәсәлән, атларга кушамат биргәндә түбәндәгеләргә игътибар ителә:

1) хайваннарың төсе;

2) кул-аякларының төсе яки башка үзенчәлеге;

3) күз тирәсендәге төс, билге;

4) хайванның үлчәме белән бәйле үзенчәлекләр;

5) хайванның холкы (Пашкевич, 2006: 63).

Эт һәм песи кушаматлары барлыкка килүдә 1) кеше исемнәре (шул исәптән, танылган кешеләрнең яки сериаллардан, әдәби әсәрләрдән алынган исемнәр), 2) хайваннарның тышкы билгеләре (төс, форма, үлчәм) аеруча зур йогынты ясый. Моннан тыш, кушаматка:

1) типиклык, гадәтилек;

2) оригинальлек;

3) аерым бер хәрефләргә башлану;

4) хайваннарың үз-үзен тотышына, холкына бәйле булу (Трофимова, 2011: 550–551) хас.

Тупланган материалны анализлау татар телендә зоонимнар ясалышында чыганакларның һәм мотивлаштыручы билгеләрнең шактый күп булуын күрсәтте. Без аларны түбәндәге төркемнәргә аерып чыгардык:

1. Кеше исемнәреннән – антропонимнардан ясалган зооним, ягъни антропозооним. Бүгенге көндә йорт хайваннарына исем бирүдә иң киң таралган һәм җайлы юл – кеше исемнәре кушу. Мәсәлән, *Мәликә, Фатыйма, Солтан, Дания*, *Зәйнәп, Зөләйха, Джек, Ральф* һ.б. Кайбер илләрдә хайваннарны кеше исемнәре белән атарга ярамый. Элек Россиядә дә йорт хайваннарына кеше исеме бирү тыелган булган. Бу җәһәттән, В.И. Дальның «этне кеше исеме белән чакыру гөнаһ иде» дигән сүзләре дә бар (Рядченко, 1994: 80). Бүгенге көндә, киресенчә, Көнбатыш мәдә-

ниятләрендә дә, Россиядә дә антропоним-зоонимнар бик киң таралган күренеш.

Татарлар куллана торган антропозоонимнарны дүрт төркемгә бүлеп карап була.

1) Төрки-татар антропоним – зоонимнары *(Акбай, Сарбай, Мыраубикә, Сарыкай, Сарытай, Күгәрчен, Карабаш, Карабай, Тулпар): Нәни **Сарбай** да, бу ишегалдында үзенең бик кирәкле зат икәнен танып, апалары янында бутала* (А. Хәсәнов). *Ошамаска, кәнфит бит ул, диеп, көчекнең башыннан назлап сыйпады, ә **Акбай** шатлыгыннан күзләрен ялтыратып кызый тирәсендә бөтерелде* (Н. Каштанов).

2) Гарәп-фарсы антропоним – зоонимнары (*Фатыйма, Солтан, Ясмин, Гайшә, Дания, Нурлы, Туфан*): *Тәрәзә төбендә битен юып маташкан соры песи – **Фатыйма**, сикереп төшеп, Бикмүш бабайны гадәтенчә мыраулап каршы алды* (Г. Гобәй). ***Солтан** кушаматлы кавказ овчаркасы моңарчы тугры эт булган, беркайчан да беркемгә дә ташланмаган* («Татарстан яшьләре»).

3) Рус антропоним – зоонимнары (*Анфиса, Мурзик, Октябрина, Дружок, Красотка, Снежок, Дружок, Мишка, Шарик, Жулик, Лапа, Бим, Рада* һ.б.): ***Дружок** әле дә исән һәм ил чиген әле дә шулай сизгер саклый икән* (А. Алиш). *Бу – **Мурзик** түгел, икенче бер мәче баласы иде* (Т. Кәримов). *Ул **Красотка** исемле сыер кайда булган?* (Т. Гыйззәт).

4) Чит телдән кергән антропоним – зоонимнар (*Фиалка, Сэм, Джек*): *Минем янга да **Джек** кушаматлы бер эт китердеме?* (М. Мәһдиев). *Өченче ел рәттән әлеге мактаулы исемне **Сэм** кушаматлы эт яулый икән* («Татарстан яшьләре»). Россиядә чит ил антропонимнарын хайван кушаматлары буларак куллану бик актив. Мәсәлән: *Джерри, Джек, Барби, Том, Ральф*. Зоопарклардагы һәм цирклардагы хайваннарга да, гадәттә, чит ил сүз-атамалары кушыла.

Кеше исемнәреннән тыш, сирәк очракта хәтта фамилияләрнең дә кушаматка әйләнү очраклары бар. Мәсәлән, Вахитов фамилияле кешенең атына да *Вахитов* дигән кушамат такканнар һ.б. *Вахитов кушаматлы бу ат иясенә охшаса да охшар икән, бигрәк тыныч, сабыр инде* («Ватаным Татарстан»).

2. Төс белән бәйле кушаматлар. Хайваннарның төсенә карап бирелгән зоонимнар татар телендә аеруча актив. Алар үзләре ике төркемчәгә аерыла:

1) хайванның төсе буенча (*Ак песи, Аппак, Сорый Җирәнкәй, Каймак, Шайтан, Алмачуар, Сарбай һ.б.*);

2) хайваннарның билгеле бер әгъзасының, урынының төсе буенча (*Актырнак, Караколак, Акмуен* һ.б.) *Эт түгел, **Актырнак**! – дидем, эт һәм Актырнагыбызның бер үк нәрсә булуларын аңларга да теләмичә* (Ф. Яхин). *Өйдән чыгуга ук күрше йорт артында яшәүче **Аккүз** исемле эт койрыгын болгап каршы ала, аннары юл читендәге миләш куагы, ботак-кулларын сузып, матур теләкләр теләп озата...* («Сабантуй»). Йорт хайваннарының төсе белән бәйле исемнәр электән үк киң таралган була. Зоонимнарның теләсә кайсы төркемендә дә диярлек төсне белдерүдән барлыкка килгән атамалар күпләп ясалган. Иң кызыгы, төс турыдан-туры гына түгел, ә метафора ярдәмендә дә белдерелә ала. Мәсәлән, ак төстәге песи балаларына – *Каймак*, кап-кара песиләргә *Шайтан* һ.б. исемнәр кушу очрый. Мондый мисаллар халыкның ономастика юнәлешендәге иҗат мөмкинлекләрен, фантазиясен күрсәтә.

Бүгенге көндә койрык *(Аккойрык, Каракойрык),* муен *(Акмуен),* аяк, тырнак *(Актырнак),* күз *(Аккүз, Каракүз, Алакүз),* тояк *(Актояк),* баш, маңгай *(Акмаңгай),* мөгез *(Карамөгез)*, борын *(Акборын, Караборын)*, түш *(Актүш, Каратүш),* колак *(Акколак)* һ.б. әгъзаларының төсләре буенча бирелгән кушаматлар аеруча активлардан санала*: **Акколак** дигән песи өй түбәсенә менеп кояшта кызынып ятарга бик ярата икән* (Ф. Яруллин). *Минем дустым **Актырнак** әллә нинди нәселле эт тә түгел иде ул безнең **Актырнак**, ләкин үз нәселдәшләреннән аерылып торган, гаҗәеп кызык гадәтләре бар иде аның* (Г. Рәхим). Сирәк кенә сырт *(Карасырт, Аксырт),* табан *(Актабан),* тамак *(Актамак)* һ.б. төсенә бәйле зоонимнар да очрап куя.

Ә менә *җирән, коба, кола, туры, тимеркүк, чуар, алмачуар* кебек төс белдерүче сыйфатлар хәзерге татар телендә, нигездә, ат һәм сыер төсләрен белдерү өчен генә кулланылалар. «...сыйфатларның кайберләре хәтта билгеле предметларга гына береккән булалар, мәсәлән, *җирән кола, тимеркүк, алмачуар* кебек сыйфатлар ат җенесенең (елкы) төсен белдерүгә генә хас сыйфатлар булып торалар», – дип яза күренекле телче В.Н. Хангилдин (Татар теле грамматикасы, 1959: 92). *Җирәнкүк, Җирәнкашка, Турыайгыр, Җирәнбия, Колатана, Колакай* кебек матур зоонимнарыбыз моңа

мисал булып тора: *Мин Тулпарга атланган, Аксирак* ***Җирәнкашка*** *белән, Фәрит Таштоякка атланган* (Р. Батулла).

3. Аерылып торган билгеләрне күздә тотып кушылган исемнәр. Күзгә бәрелеп торган ниндидер билгесенә, тамгасына карап бирелгән зоонимнар аеруча песи, сыер, ат кушаматларында еш очрый. Мисал өчен, маңгаенда ак яки башка төстәге билгеләре булган сыерларга, бозауларга *Йолдыз, Йолдызкай* дигән исем бирәләр. *Тишекколак* исемле сыерның колак үзенчәлекләре дә аның кушаматында чагылган һ.б. *Йолдыз* зоонимы астроним буларак башка төркемчәдә дә карала.

4. Хайваннар чыгарган тавышка бәйле кушаматлар. Бу төркемдә песиләргә бирелгән исемнәр өстенлек итә. Мәсәлән: *Мияубикә, Мияукай, Мурзик, Мырау, Мыраубатыр, Мыраубикә, Мырый* һ.б. *Әй,* ***Мыраубикә****, Эт белән эт булма* (Т. Миңнуллин). *Тычкан баласы ни күзләре белән күрсен, баскыч башында, бабайның ертык катасын кигән килеш, ата мәче* ***Мырый*** *йоклап ята икән* (Р. Батулла). *Бу –* ***Мурзик*** *түгел, икенче бер мәче баласы иде* (Т. Кәримов).

5. Башка характерлы билгеләре буенча бирелгән кушаматлар. Алар, гадәттә, йорт хайваннарын сыйфатлый торган сүзләрдән ясала: *йомшак, матур, тиктормас* һ.б. Мисал өчен, *Йомшак, Йомшаккай, Кечкенә, Матур, Тәмлетамак, Тиктормас, Шапшак* исемле песиләрнең исеме дә җисеменә туры килгән очракта, аларның ниндирәк булуларын күзаллау авыр түгелдер. *Таныш булыгыз, мин бу йортта дөнья күрүче мәче –* ***Тәмлетамак*** (Т. Миңнуллин). ***Йомшаккай*** *мияулап җибәргән* (З. Хөснияр). *Ул да булмады, Шамилнең каршында торган өйдән куян кызы* ***Йомшаккай****, бүре малае Сорыбай, төлке кызы Хәйлүш, аю малае Әюп һәм шүрәле малае Шүркә килеп чыктылар* (Н. Хәлилова). *Чабыш, Юртак* исемле атларның исемнәре дә аларның нинди булуын күздә тотып кушылган.

6. Әдәби әсәр геройлары, кино һәм мультфильм персонажлары исеменнән ясалган зоонимнар: *Маркиз, Леопольд, Матроскин, Мохтар, Мила*, *Пират*, *Рекс, Тимон, Том, Шарик*. Сериаллар, чынлап та, хайван атамаларының үзгәреш кичерүенә нык йогынты ясый. Сериаллардагы күп кенә геройларның исемнәрен яңа туган бозау, бәрәннәргә кушу гадәте 1990 еллар тирәсендә сизелә башлады. Нәтиҗәдә, *Марианна,*

*Лорена, Эстер, Мендисобаль* кушаматлы йорт хайваннарыбыз ишәеп китте.

Поэтик зоонимиягә, ягъни, әдәби әсәрләрдә кулланылган хайван кушаматларына бик күп мисал китерергә булыр иде. *Песиебез хәзер өч ... Агына исем – **Аппак**, Кара колакка – **Шапшак*** (Р. Харис). *Урман эченә керүгә үк ат, алгы аякларын каты терәп, кинәт туктады, **Сыртак** ат башы аша тәкмәрли язды, ул **Елтыртайның** муенын кочаклап, чырае белән ат ялына батып керде* (Р. Батулла). ***Барый** кушаматлы песи койма башында утыра иде* (З. Хөснияр). – *Шул сәгатьтән алып, әлеге килбәтсез эт малаена шушы сүз ябышты да калды: – **Тырнак**!* (М. Хәсәнов).

7. Топонимнардан ясалган зоонимнар: *Чита, Балкан, Аляска, Амазонка, Амур, Байкал, Дунай, Урал, Эльба* һ.б.: *Безнең беренче атыбыз **Байкал** исемле бик әйбәт малкай иде, аннан соңгы атларга да аның хөрмәтенә шул ук исемне куштык* («Казан утлары»). ***Аляска** имеш. Шундый сыер исеме буламы инде? Беткәнме әллә Розалар, Малиналар?* («Ялкын»).

8. Астронимнардан ясалган зоонимнар: *Йолдыз, Айбикә, Йолдызкай, Кояш, Марс, Юпитер*. Алар арасында аеруча киң таралганы – сыерларга кушыла торган *Йолдыз* исеме. Мәсәлән: *Ат караучы Ислам абый **Йолдыз** кушаматлы атка печән ашата* («Татар теле»). *Сүз уңаеннан «**Йолдыз**» кушаматлы бахбай да бер атнадан Дон Урай авылы янында табылган* («Шәһри Казан»).

9. Хайван, кош-корт һәм бөҗәк исемнәреннән ясалган зоонимнар: *Карлыгач* (сыер, ат)*, Бөркет, Карчыга* (сыер, песи)*, Чыпчык* (сыер)*, Акчарлак, Күгәрчен* (сыер, бозау)*, Былбыл* (сыер), *Сандугач* (сыер), *Чайка* (сыер), *Күбәләк* (бозау, сыер) һ.б. Бу зоонимнарны, гадәттә, төрле хайваннарга кушалар. Мәсәлән, *Карлыгач* кушаматлы сыерлар да, атлар да бар: *Киерелеп суккан саен бичара **Карлыгач** бөтен гәүдәсе белән калтыранып куя, өттереп алган авыртуга түзә алмыйча, урыныннан кузгалырга теләп, тартылып карый, ләкин күпме тырышса да, арбаны урыныннан кузгата алмый иде* (Г. Галиев). *Сыерларына Йолдыз, Зур бүләк, Яшь бүләк, **Карлыгач** дип кенә эндәшә Гөлчәчәк апа* («Туган як»).

10. Үсемлек, җиләк-җимеш атамаларыннан ясалган зоонимнар: *Малина*, *Ромашка, Күкчәчәк, Җимеш, Роза, Лилия, Ләлә, Астра,* Ясмин, *Кашкарый*, *Резеда*, *Шомырт*, *Мандарин*, *Пальма* кебек исемнәр күбесенчә сыерларга, бозауларга кушыла.

11. Хайванның туу вакыты белән бәйле кушаматлар. Бу төр кушаматлар аеруча бозауларда еш очрый. Гадәттә, ул кушаматлар хайваннарның туган ае (*Марта, Августина, Октябрина*), ел фасылы (*Весна, Язгөлем*), көне (*Суббота, Субботка*) белән бәйле. *Бу «графикны» бер генә нәсел сыеры да бозмаган икән, шуңа күрә исемнәре дә* ***Марта*** *икән* (Р. Гаязетдин). *Әнә шул ялгыз көннәрнең берсендә ул фатирына «**Марта»ны** – йомшак борынлы, сөйкемле карашлы, кәкре тәпиле бер көчекне алып кайтты* (Н. Акмал).

12. Кешеләрнең титул һәм дәрәҗәләрен билгели торган сүзләр ярдәмендә ясалган зоонимнар: *Хан, Солтан, Король, Ханбикә, Маркиза, Граф, Маркиз, Барон, Лорд* һ.б. Мәсәлән, *Бүгенге көндә Вахитовларның 23 баш мөгезле эре терлеге, 20 тавыклары, 8 баш умарталары,* ***Барон*** *исемле этләре һәм песиләре* ***Маркиза*** *бар* («Якты юл»). ***Лорд*** *исемле эт белән* ***Барон*** *исемле песине хуҗа бер үк көнне кала базарыннан, байтак кына акча түләп, сатып алып кайткан* («Көмеш кыңгырау»). *Этебез* ***Граф*** *та безнең янда йөгереп йөри, әйтерсең миңа капканы шайбадан сакларга булыша* (С.Мамаджанов).

13. Асылташлар исеменнән ясалган зоонимнар: *Аметист, Опал, Алмаз, Рубин* һ.б. экзотик кушаматлар. *Алмазына атланып авылдан чыгып бара иде инде әткәй* («Казан утлары»).

14. Табигать күренешләре белән бәйле зоонимнар: *Туфан*, *Тамчы*, *Буран, Яшен, Болыт***.** *Нәсимә апа сыерына Болыт дип исем кушты бу юлы* («Сөембикә»). *Сабантуйда Туфанымның беренче килүендә һичнинди шигем юк иде* (Г. Галиев).

15. Холык буенча: *Буян, Ангел, Ласка, Лада* һ.б.

Шәхси хуҗалыклардагы хайван кушаматлары белән күмәк хуҗалыклардагы, ягъни, фермалардагы малларга бирелгән исемнәр арасында да аерма була. Кайвакытта шәхси хуҗалыклардагы сыер, бозау исемнәре кабатланырга да мөмкин. Шулай ук, ике күршенең дә сыеры бер үк исемле булырга, яки хуҗалыктагы һәр туган бозауга бер үк исем кушарга мөмкиннәр. Ә менә күмәк хуҗалыкларда, буталыш китмәсен өчен, һәр сыерга аерым исем бирергә тырышалар. Шуңа, башка исемнәрне кабатламас өчен, халкыбыз шактый оригиналь кушаматлар уйлап табарга мәҗбүр. Бу очракта нәкъ менә сериал геройларының исемнәре (*Эстер, Марианна*), музыкаль корал исемнәре (*Гитара, Скрипка*), географик атамалар (*Алтай, Аляска, Чита*) ярдәмгә килә дә инде.

Зур көтүләр булып яши торган хайваннарга (мәсәлән, сарыкларга) һәм кошларга исем бирелми. Күмәк хуҗалыкларда аларга номер сугалар, шәхси хуҗалыкларда аерым очракларда гына исем белән дәшәләр.

Хайван кушаматларының мотивлашу дәрәҗәсе төрлечә. Гадәттә, аларны чынлап та мотивлашкан һәм символик рәвештә генә мотивлашкан (ягъни мотивлашкан төрдән мотивлашмаган төргә күчештә булган) кушаматларга бүлеп карап була. Мотивлашкан кушаматларга теге яки бу билгеләренә карап кушылган исемнәр (*Актырнак* – ак тәпиле эт, *Шайтан* – кара төсле песи һ.б.) керә. Мотивларын югалткан кушаматлар да булырга мөмкин. Теге яки бу билгесенә нисбәтле яки теләк рәвешендә кушылган исемнәр дә бу категориягә керә (*Җитез, Матур, Йомшаккай*).

Төс, холык, аерылып торган билгеләргә яисә тавышка карап кушылган зоонимнар мотивлашкан төркемне тәшкил итә. Мотивлашмаган кушаматларга: 1) антропозоонимнар *(Роза, Зина, Динә, Мәликә; Вахитов; Сабитов; Кәбировна, Ивановна);* 2) экзотик исемнәр һәм әдәби әсәрләрдән алынган исемнәр *(Эстер, Марианна);* 3) китаплардан, кинофильмнардан алынган исемнәр *(Мохтар, Стрелка);* 5) топозоонимнар, астрозоонимнар *(Амазонка, Эльба, Амур, Байкал, Марс, Урал)* керә.

Гадәттә, хайван кушаматлары булып:

1) ялгызлык исемнәр: *Роза, Зина, Динә, Сабитов* һ.б.;

2) уртаклык исемнәр: *Скрипка, Малина* һ.б.;

3) сыйфатлар: *Матур, Йомшак, Аппак, Шапшак, Тиктормас* һ.б. кулланыла.

Стандартка әйләнеп, артык популярлашып киткән зоонимнар да, бердәнбер, бик сирәк кенә кулланыла торган кушаматлар да бар. Соңгылары әдәби әсәрләрдә очрый. Мәсәлән: *Нуяк, Сыртак, Шапшак, Эльба, Лунтик* һ.б.

Татарлар куша торган зоонимнарның күбесе, нигездә, әлеге төркемнәргә сыеп беткән. Теге яки бу билгеләрен уйлап тормыйча, исем ошаган өчен генә кушылганнары да бик күп.

Моннан тыш, зоонимнарга мода да була ала. Мәсәлән, XVIII гасырда Россиядә француз исемнәре белән мавыгу сизелгән. Рус дворяннары француз теленнән кергән кеше исемнәрен бик күп кушканнар. Соңрак алар эт, песи исемнәренә дә күчкән. *Фидо (Фиделька), Мими (Мимишка), Зизи (Зизишка)* һ.б. (Епишкин,

2010: 449). Тик гади халык аларны бик кулланмаган. XIX гасырда исә рус аристократлары Франциядән түгел, ә Британиядән үрнәк ала башлыйлар. *Джек, Джим, Тэдди, Бобби, Тоби, Диана* кебек исемнәр шул вакытларда кереп калган. Татарларда еш кулланыла торган *Бобик, Тобик, Тузик* һәм *Трезор* кебек популяр кушаматлар да безгә Англиядән кергәннәр (шунда ук: 442).

Соңрак, киресенчә, чит илләрдә рус исемнәренә мода башлана. АКШта, мәсәлән, *Саша, Борис, Сергей, Дмитрий, Игорь, Люба, Надя, Кира* кебек исемнәр кушалар. Рус антропонимнарының да күбесе зооним булып киткән (Кторова, 1990: 50).

Эт, песи, ат, сыер, бозау, кәҗә һ.б. йорт хайваннарының исемнәреннән тыш, зоопарклардагы, циркълардагы җәнлекләрнең атамалары, өй шартларында, читлектә тәрбияләнүче экзотик хайваннарның, кошларның кушаматлары да игътибар үзәгеннән читтә калырга тиеш түгел. Тик, кызганычка каршы, тутый кошларның, әрлән, диңгез дуңгызчыгы һ.б. кебек хайваннарның күбесенә татарча түгел, ә рус яки чит телдән кергән заманча исемнәр бирелә, шуңа күрә, татар зоонимикасы кысаларында аларның күбесен тикшерүдә катнаштырып булмый. Мәсәлән, тутый кошларга, гадәттә, *Кеша, Гоша, Чика, Рио* исемнәре. Әрләннәрне *Лунтик, Дима, Муза, Джон* дип атаучылар бар.

Димәк, татар зоонимикасы дигәндә, игътибар үзәгендә иң элек эт, песи, сыер, ат кушаматлары тора. Аларның күпчелеге хайваннарның төсенә, холкына, теге яки бу гадәтләренә карап кушылган. Моннан тыш, татар халкы яраткан йорт хайваннарына кушамат биргәндә кеше исемнәрен дә бик яратып куллана.

## § 48. Зоонимнар төзелеш-ясалышында төп үзенчәлекләр

Татар телендә кулланыла торган хайван кушаматларын ясалма һәм ясалма булмаган төрләргә аерып карарга мөмкин.

Ясалма кушаматларга кушымчалы атамалар һәм кушма атамаларның барлык төрләре, ә ясалма булмаганнарына тамыр кушаматлар һәм телнең хәзерге чорында нигезен морфемик кисәкләргә, ягъни тамыр һәм кушымчага таркатып карап булмый торган, тамырлашкан кушаматлар керә. Татар зоонимнары арасында тамыр яки тамырлашкан сүзләрдән гыйбарәт кушаматлар бик күп түгел. Мәсәлән: *Иркә, Роза, Матур, Алмаз, Йомшак, Тырнак, Барый* һ.б.

Ф.С. Фәсиев туган телгә нигезләп яңа терминнар ясауның биш төрле ысулын аерып чыгара. Болар:

1) семантик ысул;

2) фонетик ысул;

3) морфологик ысул;

4) синтаксик ысул;

5) кушма сүзләрне кыскарту, ягъни, аббревиатура (Фасеев, 1969: 125).

Татар телендә сүзьясалышын өйрәнгән Ф.Ә. Ганиев түбәндәге ысулларны күрсәтә:

1) фонетик ысул;

2) кушымчалау ысулы;

3) сүзләр кушылу;

4) сүзтезмәнең кушма сүзгә күчүе;

5) сүзтезмәнең кушымча алып кушма сүзгә күчүе;

6) конверсия (лексик-грамматик ысул);

7) лексик-семантик ысул;

8) аббревиация (кыскартылмалар ясалышы) һ.б.

Автор фикеренчә, кушымчалау, сүзләр кушылу, сүзтезмәнең кушма сүзгә күчү ысуллары иң продуктив ысуллар булып тора. Конверсия һәм лексик-семантик ысуллар ул кадәр үк продуктив түгелләр (Ганиев, 2000: 14).

Әлеге классификация зоонимнарга карата да кулланыла ала, әмма кушаматлар ясалуда аларның кайберләре генә, башлыча беренче ике ысул продуктив. Әлеге ысулларга аерып тукталып, аларны мисаллар ярдәмендә карап үтәрбез.

**Кушымчалау ысулы**

1. *Нигез + -кай/-кәй кушымчасы белән ясалган кушаматлар.* Аларның үзләрен өч төркемгә бүлеп була:

а) сыйфат + *-кай/-кәй* кушымчасы: *Алакай* (сыер), *Җирәнкәй* (песи, сыер), *Каракай* (сыер), *Көрәнкәй* (песи), *Назлыкай* (песи), *Сарыкай* (ат, песи), *Чуаркай* (тавык), *Сорыкай* (песи), *Колакай* (сыер) һ.б.;

ә) исем + *-кай/-кәй* кушымчасы: *Йолдызкай* (песи) һ.б.;

б) аваз ияртеме + *-кай* кушымчасы: *Мияукай* (песи) һ.б.

2. *Нигез + -й кушымчасы белән ясалган кушаматлар.* Бу төркемдәге кушамат сыйфат нигезгә кушымча ялганып ясалган: *Сорый* (песи) һ.б.

3. *Нигез + -лач, -ләч кушымчасы белән ясалган кушаматлар.* Әлеге төркемдәге зоонимнар сыйфат һәм исем нигезләрдән ясалган: *Аклач, Сөтләч* (сыер исемнәре) һ.б.

4. *Нигез + -ым/-м кушымчасы белән ясалган кушаматлар.* Әлеге ысул белән ясалган зоонимнарны үзләрен ике төркемчәгә аерып була:

а) сыйфат + *-ым/-м кушымчасы: Йомшагым* (песи), *Кечкенәм* (бозау), *Сөйкемлем* (песи) һ.б.;

ә) исем+исем + *-ым/-м кушымчасы*: *Язгөлем* (сыер) һ.б.

**Нигезләр кушылу**

Ясалышы буенча икенче зур төркемне кушма зоонимнар тәшкил итә. Билгеле булганча, татар телендә кушма сүзләр өч ысул белән ясала: 1) нигезләр кушылу; 2) сүзтезмәнең кушма сүзгә күчүе; 3) сүзтезмәнең кушымча алып, кушма сүзгә күчүе (Татар грамматикасы, т. 1, 2015: 192).

Кушма зоонимнарның күбесе ике сүз (нигез) кушылудан барлыкка килгән һәм алар арасында исем белән сыйфат яисә ике сыйфат кушылып ясалганнары күбрәк. Мәсәлән:

1. *сыйфат+исем тибында ясалган зоонимнар: Акмаңгай* (сыер, эт), *Акмуен* (эт), *Бүзтана* (сыер), *Бүзат* (ат), *Тишекколак* (сыер), *Тәмлетамак* (песи), *Сыңарколак* (эт), *Елтыртай* (ат). Аларның күпчелеген төсне белдерә торган сыйфатлар ярдәмендә ясалган кушаматлар тәшкил итә. Аерым-аерым карыйк:

а) *ак* компоненты + хайваннарның теге яки бу әгъзасын, гәүдәсенең билгеле бер урынын һ.б. белдергән сүзләр кушылып ясалган: *Акмыек*, *Акмаңгай* һ.б.;

ә) *ак* компоненты + хайваннарның холкын, үз-үзен тотышын белдергән сыйфатлар кушылып ясалган: *Акнаян, Акшаян* һ.б.;

б) *бүз* компоненты + хайваннарны белдерүче атама (*тана, ат, сыер*) кушылып ясалган: *Бүзтана, Бүзат* һ.б.;

в) *кара* компоненты + хайваннарны белдерүче атама кушылып ясалган: *Караайгыр, Карабайтал, Карабия.* Болар барысы да атны белдерүче сүзләр: *айгыр* (ата җенестәге печтерелмәгән ат), *байтал* (яшь бия, өч яшьлек бия), *бия* (ана җенестәге ат). *Кара* компонентына себер диалектларында песине белдерә торган *мешәк* сүзе кушылып ясалган *Карамешәк* кушаматы да әлеге төркемдә карала;

г) *сары* компоненты + исем: *Сарыбикә* (песи), *Сарытай* (ат) һ.б.;

д) *коба* компоненты + хайваннарны белдерүче атама (*үгез, сыер*) *Кобасыер, Кобаүгез* һ.б.;

е) *кола* компоненты + хайваннарны белдерүче атама (*бия, айгыр, тана*) *Колабия, Колайгыр, Колатана* һ.б.;

ё) *җирән* компоненты + хайваннарны белдерүче атама (*бия, кашка*) *Җирәнкашка*, *Җирәнбия* һ.б.;

ж) *коңгыр* компоненты + хайваннарны белдерүче атама (*бия, ат, байтал*): *Коңгырбайтал, Коңгырат, Коңгырбия, Кыңгырбозау, Кыңгырсыер* һ.б.;

ж) *кызыл* компоненты + хайваннарны белдерүче атама (*сыер, тана*): *Кызылсыер, Кызылтана* һ.б.

Мисаллардан күренгәнчә, төс белән бәйле зоонимнарның күбесе *ак* сыйфаты ярдәмендә ясалган һәм мондый типтагы зоонимнар төрле төр хайваннарга бирелгән исемнәрдә дә диярлек очрый. Мәсәлән, песи кушаматларында: (*Акпеси, Акбикәч, Акйомшак, Аккерфек*); ат кушаматларында (*Акалаша, Акбайтал, Акбәкәл, Акбия, Акбүз, Акбүзат, Аккашка*); эт кушаматларында (*Акбай, Акбарс, Акборын, Аккойрык*); сыер кушаматларында (*Акбаш, Акколак*) һ.б.

2. *Исем + исем тибында ясалган зоонимнар: Мөгезбай* (бозау, үгез) һ.б.

3. *Сыйфат + сыйфат тибында ясалган зоонимнар: Карайомшак* (песи), *Көрәнала* (сыер) һ.б.

4. *Аваз ияртеме + исем тибында ясалган зоонимнар: Мияубикә, Мияуҗан* (песи кушаматлары) һ.б.

5. *Сан + исем тибында ясалган зоонимнар: Дүрткүз* (эт кушаматы).

6. *Исем + фигыль тибында ясалган зоонимнар: Йортсаклар* (эт кушаматы).

Хайван кушаматлары арасында ике нигез кушылып, аваз төшеп калу нәтиҗәсендә барлыкка килгән кушма зоонимнар да очрый. Алар бүгенге көндә бер сүз кебек кабул ителә. Мәсәлән, *Сарбай* (сары + бай), *Муйнак* (муены ак), *Борнак* (борыны ак) кебек эт кушаматлары һәм *Алат* (ала + ат) – ат кушаматы һ.б.

**Конверсия ысулы**

Саф яки грамматик формантлар алган нигезләрнең башка сүз төркеменә күчү юлы белән яңа сүзләр ясалу конверсия ысулының нигезен тәшкил итә (Татар грамматикасы, т. 1, 2015: 197).

Бу ысул белән ясалган зоонимнар бер сүз төркеменнән икенче сүз төркеменә күчкән дигән сүз. Атама, структур морфологик яктан нинди булуына карамастан, һәрвакыт конкрет предметны, әйберне яки исемләшкән эш-хәрәкәтне, процессны белдереп килә, ягъни, һәрчак исем сүз төркеменә караган була, исемләшкән хәлдә генә термин функциясен башкара, килеш, сан, тартым һ.б. белән төрләнә ала. Зоонимнарның конверсия ысулы белән барлыкка килгәннәре бик күп түгел. Мондый кушаматлар, нигездә, сыйфатның конверсияләнеп исем функциясенә күчү юлы белән ясалган. Мәсәлән: *Качкын* (сыер, бозау), *Тиктормас* (песи), *Сабыр* (сыер, бозау), *Җитез* (песи), *Назлы* (ат, песи, сыер), *Наян* (песи), *Кечкенә* (песи), *Матур* (песи, сыер) *Күгелҗем* (сыер), *Нурлы* (сыер, ат), *Мукләк* (сыер), *Шаян* (песи), *Шапшак* (песи), *Шәмәхә* (песи), *Аппак* (песи) һ.б. Мисаллардан күренгәнчә, йорт хайваннарының төсен, холкын, үз-үзен тотышын, тышкы кыяфәтен белдерә торган сыйфатлар, конверсияләнеп, зооним булып киткәннәр.

Ике сүзнең бер-берсенә иярүеннән һәм буйсынуыннан, икенче төрле әйткәндә, ияртүле бәйләнешкә керүеннән кушма зоонимнарның тагын бер төре – тезмә кушаматлар ясалган. Алар чагыштырмача аз һәм бик сирәк кулланыла. Очраганнары *сыйфат + исем* тибында ясалган. Мәсәлән, *Зур бүләк* (сыер), *Очлы колак* (песи), *Яшь бүләк* (сыер). *Сыерларына Йолдыз, **Зур бүләк, Яшь бүләк**, Карлыгач дип кенә эндәшә Гөлчәчәк апа* («Туган як»).

Татар телендә кушма сүзләр кушылу юлы белән генә түгел, бәлки сүзтезмәләрнең лексикалашуы, сүзтезмәнең кушма сүзгә әйләнүе юлы белән дә хасил булалар. Ф.Ә. Ганиев фикеренчә, сүзтезмәнең лексикалашу юлы белән барлыкка килгән кушма сүз, сүзьясалыш ысулы ягыннан түгел, төзелеше ягыннан кушма сүз булып тора, чөнки мондый сүзләрнең нинди ысул белән хасил булуын билгеләве шактый кыен (Ганиев, 2000: 104). Зоонимнар арасында да очрый андый мисаллар. Мәсәлән, *Тишекколак, Тәмлетамак, Сыңарколак, Бүзтана, Акпеси, Караайгыр* кебек кушаматларны ике нигез кушылу нәтиҗәсендә дә, сүзтезмәнең кушма сүзгә әйләнүе юлы белән дә барлыкка килгән дияргә була.

Төрле хайваннарның кушаматлары бер-берсеннән фонетик, семантик үзенчәлекләре һ.б. буенча да аерыла. Мәсәлән, ясалышы буенча караганда, эт кушаматларында кечерәйтү (иркәләү-назлау)

кушымчасының азрак, песи кушаматларында күбрәк (*Йомшаккай, Мияукай*) кулланылуы күренә. Семантик үзенчәлекләре буенча, песи исемнәрендә дә, эт исемнәрендә дә күпчелекне антопонимнар алып тора. Фонетик үзенчәлекләре ягыннан карaганда, эт исемнәрендә калын тартыкларның, бигрәк тә [р] авазының күп булуы күзгә ташлана (*Рекс, Ральф, Тырнак, Сарбай* һ.б.). Песи кушаматларында [м], [л] кебек нечкә, йомшак сузыклар күбрәк (*Мияубикә, Мыраужан, Милка*), ә [с], [ш] авазлары сирәгрәк һ.б. Димәк, этләрнең кушаматлары ир-атларч – җитди, конкрет, төгәл, ә песиләрнең кушаматлары – йомшак, нәфис. Зоонимнар ясалышында фонетик үзенчәлекләрнең мөһимлеген галимнәр дә ассызыклый. Д.И. Ермолович фикеренчә, зооним өчен, башка исемнәр белән чагыштырганда, аның тышкы формасы бик мөһим дә түгел. Чөнки кушаматлар беренче чиратта хайванны чакыру өчен кулланыла. Димәк, кушаматлардагы билгеле бер авазлар тезмәсе аларга тәэсир итәргә тиеш. Юкка гына кличка сүзе *клич, кликнуть* сүзләреннән ясалмаган, ди автор (Ермолович, 2001: 115).

Алда карап үтелгән кушымчалау, сүзләр кушылу (шул исәптән, сүзтезмәнең кушма сүзгә күчүе) һәм конверсия ысулы белән ясалган хайван кушаматлары телебездә шактый актив. Шулай да, алар, нигездә, күбрәк авыл җирлегендә кулланыла. Шәһәр этләренә һәм песиләренә күбесенчә *Рекс, Джек, Кечкенә*, *Матур*, *Шаян, Йомшак* һ.б. кебек җыйнак кына тамыр зоонимнар сайларга тырышалар.

Хайван кушаматларына күзәтү ясау телебездә аларның шактый актив кулланылуын күрсәтә. Тик, шуңа да карамастан, татар телендә зоонимнар фәнни яктан өйрәнелмәгән әле. Мисаллардан күренгәнчә, эт, песи, сыер, ат һ.б. исемнәре татар теленең үз сүзләре, төрки-татар атамалары, гарәп-фарсы алынмалары һәм чит телләрдән кергән сүзләргә нигезләнеп барлыкка килгән. Кушаматлар, гадәттә, хайваннарның төсен, аерылып торган билгесен, үзенчәлеген һ.б. истә тотып бирелә. Чагыштырмача еш кулланыла торган кеше исемнәренең зооним булып китүе дә гадәти күренеш. Шул ук вакытта, бары тик әдәби әсәрләрдә генә очрый торган поэтик зоонимнар да, татар халкының иҗат мөмкинлекләрен, фантазиясен күрсәтә торган үзенчәлекле, оригиналь кушаматлар да аз түгел.

## ТАТАР МИФОНИМИКАСЫ

### § 49. Мифонимика фәненә гомуми билгеләмә

Мифонимика – ономастиканың мифоантропоним, мифотопоним, мифофитоним, теоним, демоним кебек антропонимик берәмлекләренең телдәге функцияләрен, мәгънәләрен һәм төзелешләрен, барлыкка килү закончалыкларын өйрәнә торган тармагы (Энциклопедический словарь-справочник..., 2008: 107). Әкият, дастан, риваять, табышмак, мәкаль-әйтем кебек фольклор жанрларында төрле ышануларга хыял нигезендә барлыкка килгән онимнар тупламасы мифонимия дип атала (Суперанская, 2006: 180). Ономастиканың аерым бер подсистемасын тәшкил иткән мифонимиягә кеше исемнәре, хайван, үсемлек, географик һәм космографик объект атамалары, шулай ук чынлыкта яшәмәгән предмет, объект исемнәре керә.

Когнитив аспекттан караганда, мифонимнар дөньяның мифологик моделен барлыкка китергән мифологик фикерләү формасын чагылдырулары белән аерылып торалар.

Этнолингвистик аспекттан чыгып караганда, мифонимнар мифологик фикерләүне имплицит шәкелдә чагылдырган этномәдәни тел тамгалары булып киләләр.

Семантик аспектта исә, мифонимнар денотатны атау белән бергә, беренчел эчтәлек планын үзгәртүләре һәм мәгънәнең төрле төсмерләрен контекст эчендә белдерә алулары белән билгеләнәләр. Ономастикада мифонимнарны төрлечә атау күзәтелә. Фольклор текстларының өйрәнү объекты булган мифонимнар фәнни хезмәтләрдә әдәби онимнар (Фонякова, 1990), мифонимнар (Подольская, 1988: 87; Суперанская, 2006: 180), фольклоронимы (Калинкин, 1999: 40) дип тә аталып йөртеләләр.

Кайбер хезмәтләрдә мифонимнар уртаклык исемнәргә тиңләштереләләр. Бу исә билгеләмәдә дә чагыла.

Мифоним – илаһи көчләргә яки уйдырма каһарманнарга бирелгән уртаклык яки ялгызлык исеме. Мифонимнар әкиятләрдә, легенда, мифларда, героик эпоста, риваятьләрдә, шулай ук теологик трактатларда, мөселман һәм христиан, буддистларның изге китапларында чагылыш таба.

Рус теле белемендә XX гасыр ахырында Д.К. Зеленин (1991), А.Н. Веселовский (1989), О.М. Фрейденберг (1978),

П.Г. Богатырев (1971) хезмәтләрендә мифонимнарның үсеш-үзгәреш үзенчәлекләре лингвофольклористика кысаларында билгеләнсә, XX гасыр ахырына таба исә әлеге юнәлеш С.Е. Никитина (1993, 1999), А.Т. Хроленко (2008) хезмәтләрендә үстерелә. Славян һәм рус телендә мифонимнар мәсьәләсе этнолингвистика кысаларында Т.А. Агапкина (2002), Е.И. Алещенко (2008), О.В. Белова (2005), Е.Л. Березович (2010), (2016), О.В. Волощенко (2006), О.Г. Горбачевой (2008), Н.В. Дранникова (2006), Т.И. Кондратьева (1967), (2004), С.Е. Никитина (1993, 2009), В.Я. Пропп (1946), С.М. һәм Н.И. Толстойлар (2013), В.Н. Топоров (1974), А.В. Юдин (2007) тарафыннан өйрәнелә.

Е.Л. Березович топонимия һәм фольклор арасындагы тәэсир итешү проблемасына мөрәҗәгать итеп, болай дип искәртә: «топонимнарның фольклор ремотивациясе гомумтел ремотивациясе белән аңлатыла, шул рәвешле топонимнарның эчке формасы халык авыз иҗаты ярдәмендә ачыла» (Березович, 2016: 159).

Төрки-татар мифонимнарын өйрәнә башлауның беренче тәҗрибәсен Ибне Фадланның сәяхәтнамәсендә күзәтергә мөмкин. Ул, беренчеләрдән булып, Идел буенда алыплар турындагы легендада мифонимнарның кулланылышы хакында бәян итә. Алга таба мифонимнарны өйрәнүнең беренче тәҗрибәләре Әбү Хәмид әл-Гарнати хезмәте (X–XI гасырлар), «Кодекс Куманикус» (XIV гасыр), «Казан тарихы» (XVI йөз) кебек тарихи ядкәрләрдә дә күзәтелә. XVIII гасырда исә Г.Ф. Миллерның «Описание живущих в Казанской губернии языческих народов» хезмәтендә текст ахырында мифологик эчтәлекле терминнарны аерып чыгару тәҗрибәсе күрсәтелә һәм автор аларның рус теленә тәрҗемәсен дә китерә (*Бог – Тере Гудай, Дьявол – Шайтан, Гора – Ата, Бугор – Им-ат*а һ.б.). Н.Ф Катановның «Алфавитный указатель собственных имен, встречающихся в 1-м томе «Образцов народной литературы тюркских племен» (Катанов, 1888) хезмәте мифонимнарны өйрәнүнең әһәмиятле чыганагы булып санала, әлеге хезмәттә фольклор исемнәре тарихи-лингвистик аспектта тикшерелә. Ул төзегән Күрсәткечтә фольклорда кулланылган каһарманнарның исемнәре, аларның вазифалары, исем семантикасында чагылыш тапкан традицион эпитетлар саналып китә. Н.Ф. Катановның әлеге хезмәте төрки мифонимика үсешенә җитди адым ясалган хезмәт саналырга хаклы. XIX гасырның икенче яртысында К. Насыйри

тарафыннан татар фольклористикасында беренче тапкыр мифологик персонажларны төркемләү (су астында торучы әкәмәтләр, җир өстендә яшәүче әкәмәтләр) омтылышы ясала, елан белән бәйле *Ак елан, Аждаһа, Юха елан* кебек персонажларның генезисы, функцияләре билгеләнә, татар халкының ышанулар системасында «ия»ле авыруларның үзенчәлекләре тасвирлана.

Совет чорында Н. Исәнбәт татар мифларыннан материал туплый һәм аларны татар халык иҗатының афористик жанрларына багышланган саллы томнарына һәм башка хезмәтләренә кертә. XX гасыр ахырында исә төрки-татар мифологиясен һәм аның мифонимнарын өйрәнүгә Х. Ярми (1967), Ф.И. Урманчиев (1980, 1984, 2015), М.Х. Бакиров (2001, 2008, 2012), Х.Ш. Мәхмүтов (2002, 2012), Г.Х. Гыйльманов (1996, 1999), К.М. Миңнуллин (1998, 1999, 2000, 2001, 2003), Л.Ш. Җамалетдинов (2015), А.Х. Садыйкова (2014), Ф.З. Яхин (2004), Л.Х. Мөхәммәтҗанова (2002, 2015) һ.б. фольклористларның хезмәтләрендә җитди игътибар бирелә.

Г.Ф. Саттаров, Ф.Й. Йосыпов, Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, М.И. Әхмәтҗанов һ.б. хезмәтләрендә төрле этник төркемнәрдә чагылыш тапкан мифонимнарны барлау, аларны классификацияләү максаты куела. Татар фольклорының кече жанрларында кулланылган мифонимнарны тарихи-лингвистик аспектта тикшерү Г.Р. Галиуллина (2009), А.Д. Батталова (2011), З.А. Бикташирова, Г.С. Хаҗиева (2012, 2017), Х.Ш. Мәхмүтов (1995, 2002, 2012) хезмәтләрендә яктыртала.

Мифонимнар якут (Филиппова, 2000), башкорт (Хисамитдинова, 2010; Бухарова, 2009), азәрбайҗан (Халыгов, 2004: 25), төрек (Caferoğlu, 1959: 59–80; Hüsenov, 2010: 48–49; Türkmen, 2010: 101 – 119; Şahin, 2016: 64–69), казак (Керимбаева, 2004; Керимбаев, 2004), шор (Токмашев, 2005) телләрендә өйрәнелә. И. Шахин, төрек теле белемендә антропонимик терминологиянең тар мәгънәдә өйрәнелүе мифонимнарны фольлористика фәне кысаларында гына каралуга китерә, ди. Ул, фикерен дәвам итеп, мифонимнарны лингвистик, морфологик, семантик үсеш-үзгәрешләрен ономастиканың өйрәнү объекты буларак өйрәнелергә тиешлегенә басым ясый (Şahin, 2016: 68).

Борынгы заманнарда кеше үзен табигать дөньясыннан аерып карамый һәм әйләнә-тирәдәге барлык җанлы һәм җансыз

әйберләрне җанландырырга тырыша, аларны үзе кебек яши, кайгыра, көлә, сөйләшә белә, дип исәпли. Ыруглык җәмгыятендә барлыкка килгән мифологик карашлар, реаль яшәеш белән берләшеп, табигать дөньясы һәм кешелек дөньясы арасында гармония тудыра. Билгеле булганча, мифологиянең нигезендә анимизм, тотемизм, антропоморфизм, магизм һәм фетишизм кебек борынгы фикерләү формалары ята. Беренчел яки башлангыч тойгы-тәэсирләргә таянып эш итүләре белән характерланган конкрет әйбер-күренешләрдән аерылып торган фикерләү формалары татар исемнәрендә дә чагылыш таба. Татар исемнәренең борынгы төрки катламы тәңречелек концепциясендә кеше һәм табигать стихиясе бәйләнешен характерлый. Татар халкының мифологик мирасын югары мифологиягә һәм түбән мифологиягә бүлеп карау кабул ителгән. Төрки-татар мифологиясендә тәңречелек тәгълиматына, югары аллаларга бәйле мифонимнарга *Тәңре, Җир-Су, Умай, Алас* кебек исемнәр керә. «Күк-Тәңре, Умай, Җир-Су тәңреләренең борынгы төркиләр күзаллавында “югары аллалар” пантеоны тәшкил итүе Орхон-Енисей язмаларында да ачык чагылыш тапкан» (Татар мифлары, 1996: 20). «Түбән мифология»гә исә Алла статусына ия булмаган ияләр, кара көчләр, рухлар, йола-гадәтләр, ышанулар, кешенең көндәлек яшәеше белән бәйле мифологик персонажларның исемнәре керә. Түбән мифология персонажларының исемнәренә бәйләнешле текстлар татар халкы мәдәниятенең локаль вариантларында чагылыш таба (Татар мифлары, 1996, Татар мифлары, 1999; Татар мифологиясе, 2008).

Тәңре – төрки халыкларда синкретик күренеш. Ул, фәлсәфи субстанция буларак, һәрнәрсәне барлыкка китерүнең сәбәбе булып тора (Бер Тәңре!) һәм, теистик субстанция буларак, нәсел башы, яхшылык һәм яманлыкның чыганагы (Тәңребиргән! ) (Татар мифологиясе, 2011: 115). Орхон-Енисей язмаларында, чынбарлык Тәңре тарафыннан яратылган, дип языла. Тәңре – борынгы төрки дөньяның югары хакимлеккә ия көче.

Төркиләр аны Күк Тәңре дип тә атаганнар. Космосның бер өлеше тәңре буларак руник текстларада *kök tenri* дип аталган һәм борынгы төрки чыганакларда төрле формада чагылыш таба: *kök (kök qalyq, qalyq* «һава»); шуңа күрә аның тагы бер мәгънәсе якын күк йөзе, кошларга якын күк йөзе белән дә бәйләнешле аңлатыла (Кляшторный, 1981: 121). Тәңре дөньядагы һәр-

нәрсә белән, кеше язмышлары белән идарә итә. Борынгы кеше космосны, галәмне яраткан Күк Тәңрегә буйсына (Исхаков, 2007: 39; Дәүләтшин, 1999: 79). Борынгы кеше галәм, хаос җиһанны тудырган күк алласына буйсына, Тәңре кулында яши. Илаһи көчнең атамасы булган *Тәңре* сүзе (Гумилев, 1994: 340; Дәүләтштин, 1999: 58–59) татар исемнәрендә (*Тәңребиргән, Тәңребирде, Тәңрегол* һ.б.) кулланылган һәм казак (Кульдеева, 2001: 117), үзбәк (Бегматов, 1965: 35), кыргыз (Жапаров, 1992: 132), төрек (Эрол, 1992: 61), һәм башка төрки халыкларның уртак хәзинәсен тәшкил иткән.

Анимистик ышануларга нигезләнгән мифонимнар күк җисемнәренә, айга, кояшка табынуга бәйле компонентлар нигезендә ясалганнар һәм фольклор текстларында еш күзәтеләләр. Кеше һәм табигать бәйләнеше турыдан-туры Күк Тәңре атрибутларыннан саналган кояш, ай, йолдызлар культы атамаларыннан ясалган борынгы төрки исемнәрдә чагыла. Әкият персонажларының исемнәрендә кояшның, табигать белән бәйләнелешле компонентларның исем составында кулланылышы билгеләнә: *Таңбатыр, Төнбатыр, Кичбатыр* («Таңбатыр», Татар халык әкиятләре. 1: 241), *Ташказар, Тимербатыр, Бакырбатыр* («Камырбатыр», Татар халык әкиятләре: 301), *Айгалибатыр* (Татар халык әкиятләре: 211), *Ташбатыр, Имәнбатыр* («Кырык уллы кеше», Татар халык әкиятләре: 379) һ.б. Шулай ук батырларның исемнәрендә *таш, имән* кебек характерлый торган компонентларның килеп чыгышы анимистик күзаллауларга барып тоташа.

Тотемистик ышануларга бәйле исемнәр хайван, кош-корт атамаларына нигезләнеп ясалалар. Борынгы Орхон-Енисей язмаларында тотем хайван яки кош исемен кеше исеме итеп куллануның киң таралган булуы һәм татар фольклор әсәрләрендә дә чагылыш табуы әнә шул борынгы традицияләргә барып тоташа. Мәсәлән, «Кара Күкел» дастанында баш каһарман Кара Күкел, батырлык эшләгәннән соң, үз исемен *Кучкар Алыпка* алыштыра. «Баланың исеме *Кучкар Алып. Кучкар Алып*, шул җирдә атасыннан рөхсәт алып, алыплык эзләп китте» дип сөйләнә дастаннарда (Татар эпосы, 211). Борынгы төрки ташъязмаларында *qočγar* компоненты *qočγar töläs tirig* исемендә очрый һәм әлеге исем борынгы төркиләрнең Күк Тәңрегә бәйләнелешле космогоник ышанулары белән тыгыз бәйләнгән (Саттаров, 1990: 56).

Татар фольклорында гомумтөрки бүре культына нигезләнгән татар мифонимнарын очратырга мөмкин. Төркиләр һәм монголларда *бүре* уртак тотем хайван саналып, аңа табыну борынгы ата-бабаларга хөрмәт белән карау итеп билгеләнгән (Безертдинов, 2001: 52). Борынгы Кытай чыганакларына караганда, төрки атлы гаскәрләрнең иң яхшыларын «бүреләр» дип йөрткәннәр, борынгы төрки язмаларда «аларга күк көч биргәнгә күрә, минем атам каганның гаскәре бүре кебек» диелә. *Бүре* сүзе борынгы төркиләрдә кеше исемнәре ясалышында да киң кулланыла. Моны аеруча затлы нәселдән чыккан кеше исемнәрендә күреп була» (Дәүләтшин, 1999: 65). Болгар-татарларда *бүре* сүзен изге, илаһи сүз санап кешегә исем итеп бирү йоласы барлыкка килә. Әлеге сүз борынгы төрки телдә *бүре* сүзенең синонимы булган *кашкар, кашкур, корт*, монгол телендә *ашан* һәм *чаны* сүзләрен ир балаларга исем итеп кушканнар (Саттаров, 1990: 16). Р.Г. Әхмәтьянов *бүре* сүзенең борынгы ирани телләрдән алынуын һәм мари телендә *пириге, пирагу,* мокшыда *виргас* сүзләренең кулланылуын искәртеп китә (Татар теленең этимологик сүзлеге, т. 1, 2015: 222). Балага тотем исеме бирү гадәте тотем көчен балага юнәлдерү теләге белән бәйле карала. Баланы тотем хайван яки кош сакласын дигән теләк белән шундый исем биргәннәр (Саттаров, 1990: 14; Галиуллина, 2008: 55).

Төрки халыкларда жансыз предметларга табыну-ышану нигезендә барлыкка килгән мифонимнар да билгеләнәләр. Төрки халыкларда *тимер* җансыз предметларны олылау, изгеләштерү стихиясен чагылдыра. Тимер төрки халыкларның килеп чыгышы белән бәйле күп кенә легенда-риваятьләрдә дә телгә алына, «һуннар “Марс кылычы” булып саналган тимергә табыналар, кесәләрендә бөти урынында йөргән тимер пычакны үзләре белән йөртәләр. Төрки империясенең чикләрендә Византия илчеләренә дини тантаналы кичәләр барышында тимер бүләк итәләр» (Гумилев, 1963: 123). Борынгы төрки сүзлектә *Temür Tuya, Baj Temür, Eltemür, Esân Temür* кебек ир-ат исемнәре теркәлгән (ДТС, 1969: 533). Димәк, тимернең ныклыгына ышану мотивы бүгенге көн татар исемнәрендә дә сакланган дип әйтергә нигез бар.

Борынгы төрки сүзлектә *таш* – *tas* компонентының 1) таш; 2) күренеш, тышкы күренеш кебек мәгънәләре күрсәтелгән (ДТС, 1969: 539). Татар исемнәрендә әлеге компонент *таш* мәгънәсен

белдерә. Бу антропокомпонентта борынгыларның ир баланың таш, тимер кебек нык булуын теләү мотивы сакланган. Борынгыдан яшәп килгән җансыз предметларга табыну, аларны изгеләштерү *Ташбакты, Ташкай, Ташкабан* кебек исемнәрдә чагылган (Саттаров, 1990: Галиуллина, 2009: 97).

Шулай итеп, мифонимнар халыкның менталитетын, аның мәдәни-тарихи һәм мифологик нигезләрен, аның бөтен потенциаль үзенчәлекләрен актуальләштерүдә, телнең этонмәдәни тирәлеген билгеләүдә мөһим роль уйныйлар. Мифонимнар фольклор дөнья картинасын ачуда тамга, билге ролен үтәп,аерым бер вакыт аралыгыдагы контекст эчендә актуальләшәләр. Аларның мәгънә үсеше халыкның күзаллавын, матди һәм рухи тормышын чагылдыра. Мифонимнарның контекст эчендәге гомумиләштерелгән мәгънәләре ачыла, ассоциатив мәгънә үсешенең юлларын ачыклана.

## § 50. Татар телендә мифонимнарны төркемләү

Төрки-татар мифологиясендә мифонимнар тәңречелек тәкълиматына нигезләнгән көчләргә, төрле ияләр һәм түбән рухларга аерымланалар (Татар мифлары, 1996: 8). Әлеге бүленеш приципларын исәпкә алып, мифонимнарны тәңречелек тәгълиматы белән бәйле югары алла атамаларына (Җир-Су, Умай, Алас һ.б.), «түбән көчләрне» тәшкил иткән, алла статусында булмаган ияләр, кара көчләр, рухлар, һәм йола гадәтләре, ышанулар, кешенең көндәлек яшәеше белән бәйле мифологик персонаж исемнәренә аерып карарга мөмкин. Г.Х. Гыйльманов билгеләвенчә, «аллалар сыйныфыннан аермалы буларак, түбән мифология күк дөньясы белән түгел, күбрәк Җир дөньясы, кеше тормышы белән бәйләнгән» (Татар мифлары, 1999: 4). Мифонимнарның, «югары» һәм «түбән» көчләргә аерымлануларыннан чыгып, ике төре – теоним һәм демонимнар билгеләнә.  Ф.И. Урманчиев «Татар мифологиясе» сүзлегендә аллалар, алиһәләр, явыз затлар белән бәйләнешле, «түбән» мифология каһарманнарын аерып күрсәтә (Татар мифологиясе, 2008: 17–25).

Теонимнар – мифонимнарның төре, илаһи көчләрнең исемнәрен тәшкил итәләр (Подольская, 1978: 125). Теонимнар борынгы төрки чорда ук барлыкка килгәннәр. Билгеле булганча, төрки халыкларның рухи мәдәнияте катлаулы һәм зур үсешкә ия була.

Төрки-татар теонимнарыннан Умай – борынгы төркиләрдә хатын-кыз башлангычын гәүдәләндергән уңдырышлылык алиһәсе. *Умай* сүзе борынгы заманнарда б.э.к. кергән булырга тиеш. *Умай* сүзе татар телендә *омай* > *ымай* > *май* күчешләре кичерә. *Май* татар сөйләшләрендә «күп; муллык» сүзен аңлата (Татар теленең этимологик сүзлеге, т. 2, 2015: 347). Беренче тапкыр Умай мифонимы VII–VIII гасырларда рун язмасында телгә алына. Күк алласы Тәңренең хатыны дип кабул ителә. Аерым галимнәр фикеренчә, килеп чыгышы ягыннан *Умай* Иран мифологиясендәге Хумай-Һомай кош образы белән дә бәйле санала. Умайның вазифасы төрле халыклар мифологиясендә төрлечә күзаллана. Себер татарларында Умай турында мөһим мәгълүматлар сакланып калган. Мәсәлән, «Себер татарларында Умайны бала кендеге белән дә тиңләштерәләр. Моның нигезендә дә шул ук мәгънә ята: кешенең асылын билгеләүче, аңа сулыш, җан өрүче» (Татар мифлары, 1996: 21). Бу исә, үз чиратында Себер татарларының башка төрки халыклар, бигрәк тә шул тирәдәге алтайлылар, хакаслар, телеутлар белән тыгыз этник һәм этник-мәдәни бәйләнешләрдә булуын төгәл раслый (Татар мифологиясе, 2011: 148). Татарларда Умай турында карашлар кайбер башка төрки халыклардагы кебек төгәл һәм эзлекле түгел.

Төрки-татар дөньясында Урта дөнья алласы булып гәүдәләнгән *Җир-су, Йер-су(б)* җир һәм су гәүдәләнешен чагылдыра (Татар мифологиясе, 2009: 65). Орхон-Енисей язмаларында беренче тапкыр Күлтәгин истәлегендә телгә алына: «Төрекләрнең югары күге, төрекләрнең изге Җир-суы шулай дип әйттеләр: “Төрки халкы юкка чыкмасын иде!” – дип әйттеләр». Изге Җир-су борынгы төркиләрне һәрвакыт саклап, һәрбер эшләрендә ярдәм итеп торган Җир-су – төрле урыннарның, табигать атрибутларының (тау, урман, елга, күлләрнең) рух хуҗасы булып та саналган. Г. Дәүләтшин фикеренчә, *Җир-су* – Урта җир, Урта дөнья, Җир йөзе – Җир өсте Алласы. Аның фикеренә, җир-су туган як тауларын, елгаларын, күлләрен, урманнарын һәм кырларын олылау, билгеле бер дәрәҗәдә илаһилаштыру белән бәйләнгән (Дәүләтшин, 1999: 56).

Мифологиянең түбән көчләрен төрле демоннар, кечкенә илаһи көчләр, ияләр, җеннәр тәшкил итәләр (Давлетшина, 2011: 60). Демоннар белән кешеләр арасындагы туганлык һәм көнкүреш мөнәсәбәтләре дә билгеләнәләр. Мифологик тикшеренүләргә ка-

раганда, «түбән көчләр» «югары көчләргә» караганда борынгырак, чөнки әлеге катлам коллектив күзаллауга нигезләнә. Мифонимнарның «түбән» катлавын чагылдырган төрен *демонимнар* дип атап йөртәләр (Şahin, 2016: 67; Давлетшин, 2016; Җәүһәрова, 2012: 53).

Демонимнарның көндәлек тормыш белән бәйләнгән төркеменә «түбән» көчләрнең атамалары керә: *Бичура, Өй иясе, Су анасы, Урам иясе, Тыкрык иясе, Ындыр иясе, Умарталык иясе* һ.б. Татар халкының традицион мәдәниятендә гомуми һәм борынгыдан килгән карашлар буенча, кешенең тирә-ягында булган һәрнәрсәнең, предметларның, хәтта табигать күренешләренең үз иясе була. Ияләр үзләренең төп вазифаларын башкарган урыннарда: өйләрдә, абзарларда, су, елга, күлләрдә гомер итәләр. Татар рухи мәдәниятенең локаль вариантларында атамаларда төрлелек күзәтелә. Томск татарларында Су ияләренең, Урман иясе белән бәйле риваять-легендаларның күплеге билгеләнә (Татар мифлары, 1996: 127; Татар мифологиясе, 2011: 73; Закирова, 2016: 300).

Йорт иясе, абзар иясе турындагы сюжетларның Томск татарларындагы башка локаль төркемнәр белән аваздашлыгы әйтелә. Свердловск өлкәсе татарларында *Сыу ийәсе, Сыу инәсе, Урман ийәсе, Абзар ийәсе, Мал хуҗасы, Абзар хуҗасы, Өй хуҗасы, Йорт хуҗасы Мижа хуҗасы, Өй ийәсе, Йорт ийәсе, Урам ийәсе, Каралды ийәсе, Ат ийәсе* мифонимнары чагылыш таба (Баязитова, 2002: 351–358).

Төрле вариантларда аталып йөртелә торган *Хозер Ильяс* персонажын (*Хызыр, Хозер, Хозер бабай, Хызыр Ильяс* һ.б.) юл иясе дип йөртәләр (Давлетшина, 2011: 61). Татар халкы ышануларында киң таралыш тапкан Хозыр Ильясның юл иясе буларак кабул ителүе, аның составындагы Ильяс образы белән бәйле тәгаенләнә. Хизр, Хидр – мифик пәйгамбәр. Хидр дигән могҗизалы зат турында легендалар Шумер-Аккад заманнарыннан булган. Шумерча бу сүз «яшел кеше, мәңге яшел» мәгънәсендә дә булган (Татар теленең этимологик сүзлеге, т. 2, 2015: 392). Татар халкының ышануларында *Хозер Ильяс* юлчыларга юлдаш, адашкан кешеләргә ярдәм итә торган ак сакаллы карт буларак ачыклана. Ислам динендә Ильяс пәйгамбәр (христиан динендә Илия) буларак билгеле әлеге персонаж «җирдә һәм суда сәяхәт итүчеләрне яклаучы» буларак характерлана. Татар паремиологик фондында *Хозыр* компоненты

белән бәйләнешле «Авызына Хозыр төкергән» гыйбарәсе кызу канлы, акыллы кеше турында әйтелә, татар телендә Хозыр Ильяс мифонимының тулы идиоматизация кичерүе күзәтелә (Галиуллина, 2008: 139).

Ислам мифологиясе белән бергә кергән демонимнарга *Җен, Шайтан, Иблис, Дәҗҗәл* һ.б.ны кертеп карарга мөмкин. Мифологик караш буенча, алар җир өстендә, без яшәгән гадәти дөньяда гомер кичерәләр. Төрки-татар мифологиясендә ислам мифологиясеннән алынган демонимнарның берсе – *Җен* – явыз рух, Аллаһ тарафыннан барлыкка китерелгән өч төркем акыллы затларның берсе. Р.Г. Әхмәтьянов *Җен* демонимын түбәндәгечә аңлата «*җен* диал. йен «злой дух, бес, джинн» ~ башк. *йен* > мар. диал. *зын,* удм. *зин* < гар. *җинн* «җен; яшерен зат» – *җен* «яшерү» фигыленнән. *Әҗинә* «хатын җен, җен хатыны» (Татар теленең этимологик сүзлеге, т. 1, 2015: 265). «Җен» – нинди дә булса вазифа үтәүгә карап, кеше кыяфәтенә, предмет, атмосфера күренешенә керә ала торган, күренми торган демонимик зат. Җеннәр безнең тормышыбызга үтеп, кешегә күренми генә гаиләләре белән параллель тормышта яши алалар. «Җен демонимы ислам дине белән килеп керә һәм киң тарала, локаль мәдәнияткә нисбәтле трансформациялән̣ә һәм борынгы төрки мифологиянең архаик системасының җимерелү процессында яңа интерпретация ала» (Давлетшина, 2016: 27) Коръән тәкълиматы буенча, Җеннәр төтенсез уттан яратылганнар, теләсә нинди кыяфәткә керә алалар; үтә катлаулы эшләрне җиңел башкаралар. Җирдә Адәм галәйһиссәләмгә кадәр үк яшәгәннәр, гадәттә кешеләрнең дошманы буларак сурәтләнәләр. Адәм балалары белән Җеннәрнең үзара мөнәсәбәтләре, Коръәндә әйтелгәнчә, шактый кырыс юнәлеш ала. Җеннәрнең бер төркеме Корьәнгә иман китереп, ислам динен кабул итә һәм аңа тугрылыклы булып кала, икенче төркеме исә Иблискә ияреп, Аллаһка иман китерүдән баш тарта һәм мәҗүсилектә кала.

Борынгы гарәп һәм ислам мифологиясеннән төрки-татар мифологиясенә үтеп кергән *Дәҗҗәл* (гар. «алдакчы, ялганчы») демонимы христиан динендәге Антихристка туры килә. «Даджал (دَجَّالٌ гарәп “ялганчы”) – антихрист, антимессия, ахырзаманда килүче» (Исламская энциклопедия, 2009). Гарәп телендәге *Дәтьял* русларда «антихрист; изверг» дигәнне аңлата. Р.Г. Әхмәтьянов карашынча, *Дәтьял* демонимының килеп чыгышы гарәпчәдән булмыйча,

башка чыганакка да карарга мөмкин: *Дециал* «унынчы бала» исеме *Дектиан* дип әйтелгән, тарихта *Дециал* дип билгеле (Татар теленең этимологик сүзлег, т. 1, 2005: 241). Татар телендә *дәҗҗал* сүзе күчерелмә мәгънәдә «ялганчы, алдакчы» дигәнне дә аңлата (ТТАС, 2005: 154). *Дәҗҗал* хәдисләрдә һәм ахырзаман белән бәйләнешле дастан-кыйссаларда сөйләнелә. Мөселман карашлары буенча, Дәҗҗалның эш-гамәлләре Иблис белән бәйләнгән.

Демонимнарның икенче төркемен аллалар дәрәҗәсендә торган, ниндидер гайре табигый көч-куәткә, кодрәткә ия көчләрнең атамалары тәшкил итәләр. Көндәлек тормышта очраган көчләрдән аермалы буларак, алар башка дөньяда яшәеш күрәләр. Төрки-татар мифологиясендә төрле ияләргә багышланган мифологик хикәятләр җитди урын алып тора. *Су анасы* һәм *су атасы, су иясе* образлары барча төрки халыкларда (бигрәк тә кыпчакларда) очрый. Фольклордагы *Сусылу* образы татар-башкортларда гына чагылыш таба (Татар теленең этимологик сүзлеге, т. 2, 2015: 176). Татар диалектларында *суwәсе* «су иясе» (ТТЗДС, 2009: 582), сумийә «су иясе» (ТТЗДС, 2009: 586) кебек вариантларда борынгы фонетик яңгыраш һәм күчеш чагыла. Су асты патшалыгы белән бәйле *Су анасы* образы – киң таралган сюжетларның берсе. Әлеге образ озын чәчле, куркыныч хатын-кыз образында күзаллана. Шулай ук демонимнар арасында татар фольклорында *Су иясе, Су анасы, Су бабасы* образлары да очрый. Су кызы образы татар халкының иң борынгы «Түләк һәм Сусылу» дастанында чагылыш таба.

Татар мифологиясенең түбән көчләренә кергән *Бичура* демонимы төрки-татар дөньясында киң таралган. *Бичура* – диал. *пичура, мичура, бисура, мисура* «домовой». *Бичен, Мичкәй, Присура, Мичура* вариантлары, бичуралар мич тирәсендә яшиләр дигән мифның чагылышы (Татар теленең этимологик сүзлеге, т. 1, 2015: 191). *Бичура* – йорт иясе, йорт хуҗасы, йорт пәрие (ТТАС, т. 1, 2015: 545). *Мич артында мичура билен буып утыра (себерке)* дигән татар табышмагында *Бичура* демонимы чагылыш таба. Бичураның шактый катлаулы, каршылыклы, өй-йорт тирәсендә, хәтта урманнарда гомер итүче (маймыл, Баба-яга) затларга да якын торган хәшәрәт булуы билгеләнә (Татар мифологиясе, 2008: 227). Татар мифологиясендә Бичураларның ике төре билгеләнә: бер төркеме кешеләргә вак-төяк явызлыклар эшләп торса, икенчеләре яхшылыклар кыла икән.

Димәк, мифонимнар илаһи көчләрнең, аллаларның, алла дәрәҗәсендәге алиһәләрнең атамаларына һәм көндәлек яшәеш белән аллалар дәрәҗәсендә торган, ниндидер гайре табигый көч-куәткә, кодрәткә ия көчләрнең атамаларына аерылалар.

## § 51. Мифонимнарның кулланылыш үзенчәлекләре

Мифонимнарның кулланылышы гаять дәрәҗәдә үзенчәлекле. Алар кече һәм зур фольклор жанр төрләрендә дә очрый. Фольклорның эпик жанрларында каһарманның исеме аның характер үзенчәлеген, яшен, эпик дөньядагы функциясен, уңай яки тискәре персонаж булу-булмавын ачыклый. Фольклор әсәрендә сүзнең мәгънәсе контексттан тыш мәгълүматка – мифларга, гореф-гадәтләргә, сынамышларга һ.б.га барып тоташа, текстның синкретик структурасында һәм контекст бәйләнешендә генә бөтен тулылыгы белән ачыла. Хәзерге татар прозасында да мифонимнарның кулланылышы күзәтелә. Л.Х. Дәүләтшина билгеләвенчә, бер яктан, әдәби сүз сәнгатендә мифонимнарны чагылдыруда архаик мифологик структура, борынгы архетиплар барлана (Ә. Еники, М. Мәһдиев, М. Юныс, А.Гыйләҗев), икенче яктан, әдәбият мифның әдәби трансформациясе процессына аяк баса, әдәби образлар һәм мотивлар хикәяләү юлында мифологик катламда ачылалар (Н. Гыйматдинова, Г. Гыйльманов, Ф.Бәйрәмова) (Давлетшина, 2005: 16).

Мифонимнарның кече афористик жанрларда кулланылышы милләтнең стереотип һәм архетип образларын, тел шәхесен, милләтнең үзаңын ачыкларга ярдәм итә. Паремияләрдә кулланылган мифонимнар, гомумиләштерүдән тыш, индивидуальләштереләләр, шул рәвешле, этномәдәни мәгълүматны чагылдыралар. Татар паремиологик фондында Сөләйман пәйгамбәр белән бәйләнелешеле исемнәр дә зур күпчелекне тәшкил итәләр. Сөләйман исеме гарәп телендә «саклый торган» дигән мәгънәдә килә (Саттаров, 2006: 55; Мусульманские имена, 2007: 224). Билгеле булганча, *Сөләйман* – Коръән сюжетына бәйләнелешле персонаж, акыллы һәм тәкъвалы патша, Библиядәге *Соломонга* туры килә. Ул Алла тарафыннан бирелгән балдак көченә ия булган яхшы тылсымчы (Татар энциклопедиясе, т. 5, 2010: 468). *Сөләйман* исеме түбәндәге паремиологик берәмлекләрдә урын алган: *Сөләйман йөзеге;*

*Йөзек кем кулында булса – шул Сөләйман; Йөзеге барда – Сөләйман, йөзеге юкта – сөмәйгән; Сөләйман үлде – диюләр котылды* һ.б. (Татар халык мәкальләре, 2010: 554). Ислам мифологиясендә Сөләйман пәйгамбәргә һәм аның Аллаһының 99 исеме язылган йөзегенә зур игътибар бирелә. Татар күзаллавында әлеге йөзеккә ия булган кеше бөтен дөньяга хаким була ала дигән фикер таралган. Шуңа күрә татар теленең паремиологик фондында да Сөләйман пәйгамбәргә нисбәтле мәкаль һәм әйтемнәр, табышмаклар барлыкка килгән. *Суда – Сөләйманмын* (сөлек) (Татар халык табышмаклары, 2014: 96) табышмагы Сөләйман пәйгамбәр һәм сөлек арасында тыгыз бәйләнешне аңлата һәм су өстендә торган Сөләйман тәхете турындагы риваятьләргә барып тоташа. Татар телендә кулланылган *«Сөләйман йөзеге»* гыйбарәсе Сөләйман йөзегенә бәйләнешле чиксез хакимлеккә ия булу мәгънәсен аңлата (Мәхмүтов, 2008: 298). Әлеге фразеологик берәмлек йөзеккә хас булган коннотатив мәгънә нәтиҗәсендә барлыкка килә. Корьәнең «Бакча» сүрәсенең 31–34 аятьләрендә Сөләйман кичке намазы турында онытканга, Аллаһ аннан йөзеген тартып ала. Беркөнне Сөләйман йөзекне хатынына калдыра һәм Сөләйман кыяфәтендә җен килеп, йөзекне урлый һәм дөнья хакименә әйләнә. Сөләйман тәүбә итә һәм Аллаһ фатыйхасы белән йөзеген генә түгел һәм хакимлекне үзенә ала. *Йөзек кем кулында булса – шул Сөләйман* дигән әйтем Корьән сюжетларыннан чыгып семантик үзгәреш кичергән.

Татарларда ислам дине белән бәйләнешле пәйгамбәр исемнәре нигезендә ясалган теонимнарның семантик потенциалы аерым бер этномәдәни тирәлек турындагы мәгълүматларны чагылдыралар: *Һәрбер Мөхәммәт пәйгамбәр булмый; Тау Мөхәммәт янына килмәсә, Мөхәммәт тау янына килер* һ.б. Ономатолог Г.Р. Галиуллина фикеренчә, татар мәдәниятендә Мөхәммәт исеменең эчке формасы киңәюе күзәтелә. Халык күзаллавында Мөхәммәт дин символы буларак чагыла һәм аның, берникадәр дәрәҗәдә, Аллага якынлыгы билгеләнә (Галиуллина, 2008: 133). Әлеге исемнәрнең күбесе Коръән сюжетларыннан алынган, М.Ш. Мәхмүтов билгеләвенчә, «Коръәндәге һәр сүрә гаҗәеп гүзәл һәм гыйбрәтле риваять-легендалар белән бизәлгән, аерым аятьләре исә тапкыр һәм хикмәтле афоризмнар булып яңгырый» (Махмутов, 2008: 4). Татар халкының мәкаль һәм әйтемнәрендә иң еш кулланыла торган

исем Мөхәммәд пәйгамбәргә бәйләнелешле исемнәр: *Ел – елга, ел Мөхәммәткә җиткәндә; Син дә мин, Мөхәммәт әмин; Мөхәммәткә өммәт булмыйм.* Мәкаль һәм әйтемнәрдәге кайбер мисаллар образлылык тенденцияләре хакында сөйли. Мәсәлән, татар телендә *Гайшә* исеме гарәп телендә «яшәүче, тере, имин, тыныч, чәчәк атучы» (Мусульманские имена, 2007: 306) дигәнне аңлата һәм *Минем телем түгел, Идел кичкән инәкә теле; Минем кулым түгел, Әйшә-Батма кулы* дигән әйтемдә исемнең семантик көче ачыла төшә, денотат белән бәйләнеше барлыкка килә. Билгеле булганча, татар мифологиясендә *Айшә-Батма* барлык хатын-кызларның да яклаучысы булып тора (Урманчеев, 2008: 269). *Батма – Фатыйма* шул ук вакытта Мөхәммәд пәйгамбәрнең хатыны Гайшәнең кызы. Татар мифологиясендә *Айшә-Батма кулы* бөтен төрки дөньясына мәшһүр, шул ук вакытта ислам дөньясына танылган яхшылык, киң күнеллелек төшенчәләре белән бәйләнгән (Урманчеев, 2008: 270).

Коръән сюжетларында *Нух* – Мөхәммәд пәйгамбәрнең дәвамчысы буларак характерлана (Татар энциклопедиясе, 2008: 503). Нух пәйгамбәр кешелек тарихын Туфан суыннан соң янадан башлап җибәрүче, шунлыктан аның образы ислам дөньясында, шул исәптән татар халкында, бигрәк тә татар язма әдәбиятында, шактый зур урын яулап ала (Татар мифологиясе, 2009: 260). Язма әдәбиятта да, фольклорда да Нух пәйгамбәр исеменә мөрәҗәгать ителә икән, димәк, сүз бик борынгы заманнар турында бара. *Нух* антропокомпонентлы паремияләрнең семантикасы пәйгамбәр турындагы риваятьләргә барып тоташа: *Нух заманыннан бирле; Нух заманнарыннан калма; Нухтан калган; Нух каргасы* һ.б. Риваятьләрдә Нух пәйгамбәрдән тормыш турында сорагач ул болай дип җавап бирә: *Ике ишекле өй кебек, берсеннән кердем, икенчесеннән чыктым*. Вакыт фәлсәфәсе түбәндәге гыйбарәләрдә урын ала: *Нух заманыннан бирле, Нух заманнарыннан калма, Нухтан калган* һ.б.

*Алып* мифонимы реаль яшәүче кеше белән бәйләнешле, көч, батырлык кебек төшенчәләрнең эпос, татар халык әкиятләрендә, паремияләрдә гиперболизацияләнгән формасында чагылыш тапкан. *Алып орлыгы, Алпамыш йокысы, Алпамыш батыр йокысы белән йоклый* әйтемнәрендә *Алып* исеменең деонимизация кичерүен күзәтергә мөмкин. Этномәдәни спецификага ия аппелятивлар барлыкка килүдә *Алып-батырга* барып тоташкан оним

чыганагы зур роль уйный. *Алып* мифонимы табышмакларда да очрый: *Алты аягы бар – Алып түгел, Дүрт күзе бар – дию түгел; Аркасында кылдан җебе – эрләп суккан җебе түгел (үрмәкүч)* (Татар халык табышмаклары, 2014: 139); *Әнә бара Алып, Колакларын салып; Киндер күкрәге, Тимердер йөрәге (бүре)* (Татар халык табышмаклары, 2014: 112). «Алпамыш» дастанының төп герое исеме дастанның төрле версияләрендә төрлечә бирелгән: алтай вариантында – *Алып-Манаш*, үзбәк вариантында – *Алпамыш*, казак вариантында – *Алпамыс,* татар вариантында – *Алпамша, Алпамыш, Алыпмәмшән* буларак бирелә. Барлык исемнәр дә алтай вариантындагы – *Алып-Манаш* исеменә барып тоташа. Исемнәрнең төрле вариантта кулланылышы мәгънәнең метафорага әйләнү мөмкинлегенең киң булуы һәм исемнең поэтик табигате турында сөйли. Татар әкиятләрендәге һәм дастаннарындагы *Алпамыш* исеме кыпчак эпосында кулланылган *Алып-Манаш* исеменең кыскартылган варианты булырга мөмкин. *Манаш* сүзе бераз карасы булган ак мәгънәсендә дә кулланыла, шуңа күрә *Алып Манаш* исеме атка атланган батыр мәгънәсендә дә килә (Татар теленең этимологик сүзлеге, т. 2, 2015: 96). Татар телендә *Алпамша* исеме уртаклык исеменә күчеп, «зур гәүдәле кеше» дигән мәгънәне аңлата, татар теленең диалектларында *алпамша* сүзе «мифик образ; зур гәүдәле көчле батыр» дигәнне аңлата (ТТЗДС, 2009: 36). Шулай ук татар диалектларында *алпамыш йокосо* дигән фразеологик әйтем киң таралаган (ТТЗДС, 2009: 412). *Алпамша – Алпамыш* исеме татар телендә *алып + шаһ* компонентларыннан торган сүзләр нигезендә барлыкка килгән (ТТАС, 2005: 35). Ф.И. Урманчиев фикеренчә, фарсы чыгышлы «шаһ» компоненты төп каһарманның затлы нәселдән булуына ишарәли (Урманчиев, 2015: 121). Шул рәвешле, *алып, батыр* компонентлары, исем составында килеп, эпик әсәрләрдә уртаклык исеменә әйләнә, персонажның физик, психологик үзенчәлекләрен чагылдыра, нәсел җебен барлау вазифасын үти. *Алып* антропонимы – гомумтөрки титул, XIII–XIV гасырларга караган эпитафияләрдә сакланган. Ибне Фадлан сәяхәтнамәсендә алыплар гигант тән төзелешенә һәм зур көчкә ия, могҗиза тудырырга сәләтле кешеләр буларак тасвирланалар. Борынгы чорларда *Алып* кешеләрнең яшәве турындагы ышану-легендалар хәзерге татарлар арасында да урын ала. Мәхмүт Кашгари «Диване лөгатет-төрк» энциклопедик сүзлегендә *алп* сүзенә

«көчле, алып, баһадир» дип аңлатма бирә (Махмуд ал-Кашгари, 2010: 85). Татар риваятьләрендә Идел буе болгарларының килеп чыгышын Алып исеменә бәйле рәвештә аңлату да сакланып калган. Күренекле мәгърифәтче К. Насыйри болай дип яза: «Кая барсаң да Алып турында хикәятләр ишетергә була. Күп кенә авылларда, тау битендә Алып чабатасын каккан, дип тә әйтәләр. Шуңа күрә әлеге хикәятләр кайчандыр зур кеше яшәве турында дәлил булып торалар» (Насыйри, 1974: 83). Шул рәвешле, тарихи һәм этнографик чыганакларда алыпларның реаль яшәеше исбат ителеп, әлеге күренешләр фольклор әсәрләренең сюжетларына килеп керә, образны гиперболизацияләүдә зур роль уйный.

Телнең этномәдәни тирәлегендә мифонимнар үзенчәлекле ономастик парадигманы реконструцияләп, халык турында мәдәни-тарихи, мифологик, этномәдәни мәгълүматны поэтик чагылдыру вазифасын үтиләр. Мифонимнар мәгънә бердәмлеген һәм кешенең тирә-юнь турындагы гомуммәгълүматны кабул итү дәрәҗәсен, шулай ук телнең этномәдәни тирәлеген ачыкларга ярдәм итә. Мифонимнарның диахроник семантик үсеше халыкның психологик торышын, күзаллауларын ачарга, әлеге әсәрнең барлыкка китерүдә зур роль уйнаган гасыр үзенчәлекләрен барларга мөмкинлек бирә.

## ТАТАР ПРАГМАТОНИМИКАСЫ

### § 52. Прагматонимика фәненә гомуми билгеләмә

Соңгы елларда ономастиканың периферия өлкәсендә торган берәмлекләрен өйрәнү шактый активлашты. Билгеле булганча, ономастик кырның үзәгеннән читтә торган, беркадәр күмәклек сүзләргә якын, шул ук вакытта семиотик билге вазифасын үтәгән, ялгызлык исемнәренә хас үзенчәлекләргә ия булган товар атамалары, азык-төлек, төрле марка, парфюмерия продуктлары һ.б.ш.ларның атамалары барлык телләрдә дә шактый иркен таралыш тапты. Моның сәбәбе – дөньяда барган иҗтимагый-иктисади, мәдәни процесслар. Бу күренеш җитештерүчеләрне генә түгел, тел белгечләренең дә атама бирү, номинацияләү проблемасына игътибарын җәлеп итә. Төрле марка, товар атамалары, исем булудан тыш, сатып алучыларга, кулланучыларга йөз тота, шунлыктан алар

реклама кысасында да кулланылып, аларның игътибарын җәлеп итә һәм эстетик функцияләр башкара (Гафурова, 2012: 64).

Соңгы елларда тел белемендә төрле марка, продукция атамаларын *прагматоним* термины белән атау гамәлгә кереп бара.

Прагматоним дип аерым бер оешмада җитештерелә торган товар маркаларын атыйлар (Крюкова, 2004: 16).

Прагматонимнар үзләренә генә хас үзенчәлекләргә ия:

1) атама тулы бер товарлар сериясенә, шул ук вакытта аерым бер товарлар рәтенең элементына кагылырга мөмкин. Мәсәлән: *«Авылдаш» каймагы, «Авылдаш» эремчеге* сөт ризыклары сериясе;

2) җитештерү һәм сәүдә өлкәсендә мөһим функция башкаруы, реклама ролен үтәве сәбәпле, эстетик һәм кызыктыру ягыннан отышлы сайлануы мөһим. Мәсәлән: *«Татарстан» торты, Тәті курчаклар;*

3) экстралингвистик факторлар белән тыгыз мөнәсәбәттә яши, аерым алганда, алар конкрет объект белән хокукый яктан бәйләнешле булганлыктан, законга, хокукый нормаларга буйсындырыла.

Прагматонимнарда аерым бер товарны җитешерү һәм кулланучыга тәкъдим итү хокукы индивидуальләштереп бирелә, шунлыктан аның семантик структурасында товар сыйфатлары, үзенчәлекләре турындагы мәгълүмат та урын ала. Мәсәлән: *Арча читекләре, Болгар суы, LG суыткычы* һ.б. Прагматонимның әлеге сыйфаты бу төр ялгызлык исемнәренең күмәклек сүзләр рәтенә күчү мөмкинлекләрен арттыра, мондый күчеш кичергән прагматонимнарга мисал итеп, *нейлон, термос, кашемир* кебек сүзләрне китерергә кирәк, алар кайчандыр товар атамалары буларак кулланылып, хәзер апеллятив лексика составында йөриләр.

Прагматонимнарны башка төр ялгызлык исемнәреннән аера торган бер әһәмиятле үзенчәлек аларның реклама текстында төп берәмлекләрнең берсе булуында чагыла. Реклама максатыннан кулланыла торган ялгызлык исемнәрен берләштереп, «реклама исеме» термины белән атау ватан ономастикасы фәнендә инде үз урынын тапты. Россиядә беренчеләрдән булып периферик ялгызлык исемнәрен өйрәнгән И.В. Крюкова реклама исемнәре рәтендә карала торган эргоним (оешма атамалары), прагматоним (товар маркалары атамалары), гемероним (массакүләм мәгълүмат чаралары атамалары), геортоним (фестиваль, конкурс, концерт һ.б. атамалары), порейонимнарны (транспорт чаралары атамалары)

комплекслы өйрәнеп, аларны, иктисади яктан алга киткән илләрдә телнең көндәлек яшәешендә аерылгысыз кулланыла торган лексик катлам, дип билгели һәм, аларны берләштерә торган үзенчәлек буларак, прагматик аспектлары һәм реклама теленә караулары буенча аера (Крюкова 2004: 7).

Прагматонимнар, үзенчәлекле реклама теле берәмлеге буларак, дифференциацияләү, мәгълүмати, саклау, гарантияләү һәм психологик функцияләрне башкаралар. Дифференциацияләү функциясе товар җитештерүчене, тәэмин итүче яки сәүдә оешмаларын индивидуальләштерүгә юнәлгән. Мәсәлән: *«Сәлимә» сөте, «Авылдаш» сөте.*

Мәгълүмати функция дифференциацияләү функциясе белән тыгыз бәйле, атама товарның сыйфаты һәм җитештерүчесе турында мәгълүмат җиткерү өчен хезмәт итә. Мәсәлән: *«Биектау» конфетлары, «Баллы» торты*. Прагматонимнарның тагын бер функциясе – психологик функция. Әлеге функция даими сатып алучыда товарга ышаныч уята, ул инде тәкъдим ителгән товарның сыйфаты югары икәнлеген күптәннән белә. Мәсәлән: «*Бәхетле» торты, «Чаллы икмәге*».

Саклау һәм гарантияләү функцияләре татар прагматонимнарында хәләл продукциясе атамаларында күрсәтелә: иттән эшләнгән ризык атамалары *«Хәләл» колбаса, «Хәләл» ветчина;* «*Хәер», «Сәдака» чәйләре* һ.б.

Тел берәмлеге буларак, прагматонимның мәгънәсе функциональ-характерлау үзлегенә ия булган берничә компоненттан оеша: көнкүреш, төркемләү, индивидуальләштерү һәм прагматик компонентлардан. Прагматонимның семантик структурасындагы беренче өч компонент сатып алучыга атама мәгънәсеннән аңлашылган мәгълүматны җиткерә. Мәсәлән: *«Тәмле» сдобасы, «Kuktara» чуен савыт-саба сериясе, «Талкан» продукциясе, «Икмәк» ипие* һ.б. атамаларның эчтәлегенә һәм аларның нинди тип сатып алучыга юнәлгәнлегенә бик җиңел төшенеп була.

Прагматик компонентка килгәндә, еш кына прагматонимнарның аерым бер төркем сатып алучыга юнәлгәнлеге күренеп тора (Исангузина, 2008: 991). Алар сатып алучы нәрсә аласын аңларлык референтка хас билгеләр җыелмасын гына түгел, сатып алучы ихтыяҗын канәгатьләндерерлек мәгълүматны да җиткерергә сәләтле. Мәсәлән, татлы ризыкларның атамалары – балалар һәм

хатын-кызларга (*«Назлы» торты, «Әкият» перәнниге*), бизәнү әйберләре – хатын-кызларга (*«Сөембикә» алкалары, «Фирдәүс» кремы, «Талир» косметика линиясе, «Асылташ» беләзеге*), эчемлекләр – ир-атка (*«Ханская» аракысы, «Бөгелмә» бальзамы*), дини эчтәлектәге әйберләр исә дин тотучыларга (*«Рамазан» казылыгы, «Хәләл» косметика линиясе*) юнәлгән була, ит ризыклары, икмәк ризыклары атамалары киң катлам сатып алучылар ихтыяҗына туры килерлек итеп сайлана (*«Тормыш», «Фитнес» икмәкләре*).

Тел белемендә прагматонимнарны өйрәнү шактый соң башланды, шулай ук *прагматоним* терминының барлыкка килү һәм төгәл формалашу тарихы шактый дәвамлы барды. Бу, беренче чиратта, әлеге терминның эчтәлеге, ономастик берәмлекләр арасында тоткан урыны, җәмгыятьтә товар, марка атамаларының роле, аларны махсус өйрәнү мөмкинлекләре белән бәйле булды.

Рус телендәге прагматонимнар белән кызыксыну XX гасырның 60–70 нче елларында башлана. Илебездә лексиканың әлеге катламына багышланган беренче махсус лингвистик хезмәтләр языла. Прагматонимнарның функциональ һәм семантик үзенчәлекләренә билгеләмә бирү, аларның ономастик статусларын аңлату юнәлешендә А.В. Суперанская, Т.А. Соболева, О. Винцлер, П.Т. Поротников, В. Манчак, Н.Н. Волкова кебек лингвистлар эшләгән. Прагматонимнарны ялгызлык исемнәре буларак өйрәнүгә, З.П. Комолова, Н.Д. Голев, Л.А. Капанадзе, И.В. Крюкова, И.М. Копыленко, А.А. Исакова, О.В. Чеботарева, Ж.Б. Кошпанова үз өлешләрен кертәләр.

Һичшиксез, рус телендәге ялгызлык исемнәрен классификацияләүдә А.В. Суперанская хезмәтләре зур роль уйный. Ул әлеге төр берәмлекләрне *товар тамгалары* термины белән билгеләп, аларны ономастиканың состав өлешенә тулысынча кермиләр, чөнки ялгызлык исемнәре билгеле бер объектны индивидуальләштерү нәтиҗәсендә туалар, ә товар тамгалары бер типтагы әйберләрне объектларны атау өчен кулланылалар, ди. Нәтиҗәдә, А.В Суперанская прагматонимнарны ялгызлык исемнәре рәтенә кертеп карамау яклы була (Суперанская, 1973: 211–213). Галимә соңрак басылган хезмәтләрендә бу төр берәмлекләрнең индивидуальләштерелү үзенчәлеген таный.

Н.В. Подольская үзенең «Словарь русской ономастической терминологии» хезмәтендә прагматонимнарга түбәндәге билгеләмәне

бирә: «прагматоним – онимның бер төре. Хәзергә әлеге термин шартлы рәвештә кеше эшчәнлегенең прагматик даирәсендә практика, предмет өлкәсе белән бәйләнешле денотатка ия булган төрле категория ялгызлык исемнәрен белдерә, шулай ук биредә хрематоним, урбаноним, ойконим, ойкодомоним, порейоним, дромоним, агрооним карала». Шунда ук сүзлекнең беренче басмасындагы прагматоним терминының биредә товар знагы (билгесе) терминына алыштырылуын искәртә (Подольская, 1988: 110) .

Шунда ук *товар тамгасы* (билгесе) сүзлек статьясында мондый билгеләмә урын ала: «Товар тамгасы – товар маркасының сүз белән бирелеше, бер үк дәрәҗәдә бер сериядән булган һәр аерым экземплярга, шулай ук тулаем сериягә карый» (шунда ук: 126).

В.И. Супрун бу төр берәмлекләрне ономастик кырның периферијасенә кертеп, *прагмоним* термины белән күрсәтә (Супрун, 2000: 17).

Үзенчәлекле ялгызлык исемнәре буларак, прагматонимнар лингвистлар тарафыннан берничә юнәлештә өйрәнелә башладылар: лингвистик статусы, структур-семантик үзенчәлекләре, лингвомәдәни үзенчәлеге, хәзерге җәмгыятьтә прагмотонимик тирәлекнең үсеше, реклама текстында функциясе. Прагматонимнарны өйрәнү белән, лингвистикадан тыш, икътисад, маркетинг, социология кебек фәнни дисциплиналар да шөгыльләнә. Әлеге позицияләрдән чыгып, коммерция ягыннан эффектив товар билгеләре тудыру ысуллары карала.

Соңгы берничә дистә ел прагматонимнар реклама тексты кысасында актив өйрәнелә башлады. Мәсәлән, рус һәм инглиз телендәге прагмотонимик дискурсны Н.В. Вертянкина (2005), хәзерге рус телендәге ризык атамаларын О.Е. Яковлева (2006), рус телендәге прагматонимнарның семиотик типларын семантик, прагматик, лингвомәдәни аспектларда И.И. Фәйзуллина (2009) өйрәнде. Соңгы елларда лингвомәдәни яссылыкта өйрәнү шактый еш күренә башлады. Мәсәлән, Э.Р. Ясавеева реклама дискурсында прагматонимнар кулланылуын өйрәнә (2004), О.В. Глухова рус һәм инглиз лингвомәдәни чикләрендәге товар тамгаларының сүз белән бирелешен ономастика һәм лингвомәдәни позицияләреннән чыгып тикшерә (2010) .

Татар теле белемендә прагматонимнарга багышланган хезмәтләр бик аз, монографик хезмәтләр бөтенләй юк. Мәсьәләнең ае-

рым аспектлары Г.Ф. Саттаров, Г.Р. Галиуллина, И.Ә. Латыйпова, Р.М. Әмирова, А.Ә. Гафуроваларның хезмәтләрендә чагылыш таба. Шулай ук соңгы берничә ел дәвамында Казан федераль университеты магистрлары һәм аспирантларының әлеге өлкә буенча аерым фәнни эшләре, мәкаләләре дөнья күрә башлады. Аерым алганда, Э.Р. Сабирова (Сабирова, Галиуллина, 2017), А.А. Абдрахманова (Abdrakhmanova, Galiullina, Khadieva, 2016) хезмәтләрен атарга кирәк.

Шулай итеп, татар телендә прагматонимика тармагы ономастик даирәнең перифериясендә урнашкан үзенчәлекле тармак санала. Аның барлыкка килүе һәм яшәеше экстралингвистик факторларга тыгыз бәйле. Татар гуманитар фәнендә бу төр берәмлекләрне өйрәнү әлегә башлангыч хәлдә генә.

## § 53. Татар прагматопонимнарын номинацияләү принциплары

Башка төр ялгызлык исемнәре кебек үк, прагматонимнар да халыкның көнкүреше, мәдәни үзенчәлеге, рухи дөньясы, иҗтимагый торышы, тарихы турында мәгълүмат саклыйлар. XX гасыр ахырында җәмгыять һәм сәясәттәге үзгәрешләр бу төр берәмлекләрнең барлыкка килүе, яшәеше һәм кулланылышына тәэсир иттеләр. Бүгенге көндә кулланылышта булган прагматонимнарның төрле теллардән (аеруча рус, инглиз телләреннән) алынуына карамастан, татар телендәге прагматонимнар уникальлеге һәм кабатланмас булулары белән аерылып тора, һәм бу үзенчәлекләр аларның нәкъ менә милли колорит һәм төсмергә ия булулары, татар теле закончалыкларына буйсынып ясалуы, атамаларда татар мәдәниятенең элементлары чагылу исәбенә икәнен ассызыклау кирәк.

Прагматоним ул – билгеле бер максат белән генә тудырылган ясалма берәмлек. Аның ни рәвешле ясалуы, нинди эчтәлеккә ия булуы һәм тышкы формасы турыдан-туры аның яшәешенә тәэсир итә, ә инде бу төр берәмлекләрнең прагматик вазифасын, маркетинг кысаларында реальләшүен исәпкә алсак, аларның ясалышы, номинацияләү принципларының хәлиткеч әһәмияткә ия булуы ачык чагыла.

Прагматонимнар ясау процессы *неймингтан* (исем ясау) – истә кала торган, матур, уңышлы яңгырашлы товар, проект һәм оешма атамаларын уйлап табуга юнәлдерелгән комплекслы эш

төрләреннән башлана. Атама уйлап табу – фантазия генә түгел, ә филолог, психолог һәм маркетологның бергә куйган хезмәте. Шул очракта ул эстетик зәвыклы гына түгел, бәлки, товарның үзенә генә хас үзенчәлекләрен дә яктырта ала.

Атамалар өчен гомуми таләпләр – төгәллек, кыскалык, эмоциональлек һәм аһәңлелек. Товар, марка, әйбер атамасы туры лексик мәгънәсеннән, эмоциональ һәм стилистик бизәлешеннән, ассоциатив рәтеннән тыш, аның нигезендә яткан сүзләрнең этимологиясенә, структурасына (морфология) һәм эстетикасына (матур яңгырашлылыгына, эчке ритмлы булуына, графикасына) бәйле. Бу үзенчәлекләр бренд уйлап тапканда исәпкә алынырга тиеш.

Атама уйлап тапканда, коммуникатив бурычлар да билгеләнә. Беренче чиратта, бренд яки атаманың телен сайлау әһәмиятле, бу – атаманың кайсы илдә, территориядә кулланучысын табуга бәйле. Искәртергә кирәк, татар телендәге атамаларның зур күпчелеге Татарстан Республикасы җирлегендә эшләнгән товарларныкы, алар татар телен яхшы белгән яки һәрдаим ишетеп торган кулланучыга аталган. Сүзнең эмоциональ фоны да атама сайлауда зур роль уйный. Сүздәге авазлар тезмәсе, атама тудырган ассоциацияләр товарның алга таба кулланылышка керүенә тәэсир итә. Шуңа бәйле идеаль атамага куелган таләпләрдән кыскалык, чынбарлык белән бәйлелек, җиңел истә калучанлык, матур яңгырашлы һәм язылышлы, тискәре эмоцияләрләрдән азат булуы, сатучы һәм сатып алучы аралашуында «күпер» булдыра алуы зур роль уйный.

Прагматонимнарны, кулланылыш үзенчәлекләреннән чыгып, берничә төп төркемгә аеру зарур:

*Беренчел прагматонимнар,* ягъни әлегә кадәр прагматоним буларак кулланылышта булмаган атамалар. Аларның прагматик функциясе яңгырашка һәм график бирелешкә нигезләнгән. Мәсәлән, *«Азәрчәй» – Азәрбайҗан чәе* дигән сүзтезмәдән кыскартып ясалган атама*; «Таң» сөте, «Аккош» конфеты, «Ландыш» печеньесы, «Алтын» чәе* составындагы *аккош, ландыш, алтын* сүзләре ономастиканың башка өлкәләрендә еш кулланылса да (мисал өчен, *«Аккош» рестораны, Аккош күле, «Ландыш» чәчтарашханәсе, «Алтын» ювелир кибете* һ.б.), прагматоним буларак беренче очрый.

*Икенчел прагматонимнар,* ягъни телдә булган атамаларны трансформацияләү. Алар, прагматоним буларак, телдә бар,

әмма яңадан икенче бер товар атамасы буларак икенчел функциядә куллана башлыйлар. Мәсәлән: *«Рамазан» чәе – «Рамазан» казылыгы, «Яшьлек» рулеты – «Яшьлек» колбасасы, «Бәхетле» сыр таякчыклары – «Бәхетле» торты, «Сабантуй» шашлыгы – «Сабантуй» торты, «Тәмле» сосискалары – «Тәмле» сдобасы, «Бәйрәм» прәннекләре – «Бәйрәм» торты – «Бәйрәм» чәе* һ.б.

Татар прагматонимнарын, номинацияләү, атама бирү үзенчәлекләреннән чыгып, мотивлашкан һәм мотивлашмаган төрләргә бүлеп карыйлар. Бу бүленеш эргонимия өлкәсендә дә кабул ителгән, мәсәлән, Р.М. Әмированың «Казан шәһәре татар эргонимиясе» хезмәтендә бу бүленеш күзәтелә (Әмирова, 2011: 228), шулай ук әлеге хезмәттә дә эргонимнар төркемләвендә дә шул бүленеш бирелгән.

*Мотивлашкан прагматонимнар*да товар атамасының аерым билгеләр белән бәйләнеше күзәтелә:

1) товарның җитештерү урыны атамада чагылыш таба: *«Чишмәле» сөте, «Яр Чаллы» чәкчәге, «Биектау» конфеты, «Мамадыш» сыры* һ.б.;

2) ассоциатив күзаллауларга нигезләнгән прагматонимнар: *«Тәмле» сдобасы, «Баллы» торты, «Назлы» торты* һ.б. Ассоциатив күзаллаулар төрле булырга мөмкин, мәсәлән, матурлык, нәзакәтлелек белән ассоцияцияләнгән хатын-кыз исемнәреннән барлыкка килгән атамалар: *«Гөлнара» чәе, «Алия» торты, «Резеда» конфеты* һ.б; географик, топонимик ассоциация нигезендәге прагматонимнар: *«Авылдаш» каймагы, «Авыл» коймаклары, «Авылым сөте» катыгы* һ.б.; образлы күзаллау нигезендә барлыкка килгән атамалар: *«Ватан» каймагы, «Яшьлек» рулеты, «Аккош» конфеты, «Әкият» торты* һ.б.

Кайбер атамалар төгәл ассоциация тудыралар, мәсәлән, *«Тормыш» ипие, «Бәйрәм» прәннекләре, «Кияү» пилмәне. «Тормыш» ипие* – икмәкнең нинди авырлыклар белән табыннарга килүен аңлата, күбесенчә халыкның кыен үткәне белән аваздаш. *«Кияү»* пилмәннәре татар халкының йолалары белән бәйле, *«Бәйрәм»* прәннекләре – нинди дә булса бәйрәмдә табынга куела торган ризык мәгънәсендә килә.

*Мотивлашмаган прагматонимнар* дигәндә, прагматоним белән аталган товар арасында туры бәйләнеш булмаган атамалар күзаллана. Алар түбәндәгеләр:

1) үсемлекләр, җәнлекләр, кош атамаларыннан ясалган прагматонимнар: *«Ак каен» печеньесы, «Сандугач» конфеты, «Аккош» конфеты, «Карлыгач» конфеты* һ.б.;

2) табигать күренешләре атамалары нигезендә ясалган прагматонимнар: *«Чишмә» каймагы, «Таң» каймагы, «Урман» минераль суы, «Кышкы әкият» чәе, «Яз» торты* һ.б.;

3) мифологик, тарихи геройлар, образлар исеменнән ясалган прагматонимнар: *«Тулпар» туңдырмасы, «Ак барс» ветчинасы, «Сөембикә» торты;*

4) уңай семантикалы абстракт лексика нигезендә барлыкка килгән прагматонимнар: *«Батыр» туңдырмасы, «Шифа» минераль суы, «Алтын» чәе, «Бәйрәм» чәе, «Әкият» торты* һ.б.

Бу төр прагматонимнар, нигездә, очраклы ассоциацияләр һәм матур яңгырашлы, уңай семантикалы, әмма эчтәлегендә объект белән бәйләнеше булмаган сүзләр нигезендә барлыкка килә.

Ономастик лексиканың кайсы гына төрен алсак та, аларның һәрберсе үзендә халык тарихын, милләт язмышын, мәдәни бәйләнешләрны чагылдыра. Татарстан җирлеге элек-электән үзендә Көнчыгыш һәм Көнбатыш цивилизацияләрен берләштергән үзәк булып торган. Биредә кулланышта йөргән һәрбер оним үзендә төрле мәдәниятләргә караган үзенчәлекләрне, традицияләрне һәм бәйләнешләрны чагылдыра. Бу сыйфат телебездә шактый соң барлыкка килгән прагматонимнар өлкәсендә дә дәвам итә. Гомумән, соңгы берничә дистә ел эчендә татар прагматопонимиясе шактый үзгәреш кичерде, составы һәм эчтәлеге ягыннан милли төсмергә баеды.

Прагматонимнар арасында, төп урынны алып торган рус яисә Европа телләреннән кергән сүзләргә нигезләнеп ясалган атамалар белән беррәттән, халкыбызның һәм башка төрки телләрнең милли мәдәниятенә, традицияләренә, милли үзенчәлекләренә нигезләнеп ясалган прагматонимнар да актив таралыш тапты.

Татар милли мәдәниятен чагылдырган прагматонимнарны ике зур төркемгә аерып карау зарур.

Беренче төркемне *төрки-татар чыгышлы прагматонимнар* хасил итә. Аларда халкыбыз тарихы, рухи һәм матди мәдәнияте, гореф-гадәтләре, күзаллаулары, милли менталитеты, психологиясе чагылыш таба. Мәсәлән, *«Сөембикә» торты, «Болгар» чәкчәге, «Тулпар» туңдырмасы, «Ак Барс» колбасасы* һ.б. Бу атамалар татар халкы тарихы һәм мифологиясендә тирән эз калдырган шәхес

яки образларның исемнәренә бәйле барлыкка килгән. Татар милләтеннән булган кешеләр аңында ул аерым ассоциацияләр тудыра, мәсәлән, *«Сөембикә» торты* атамасын алыйк. Сөембикә – халкыбыз тарихында тирән эз калдырган, фаҗигале язмышка ия ханбикә. Ул милләт аңында азатлык, ирек символы, милләт горурлыгы, гүзәл хатын-кыз рәвешендә дә күзаллана. Татар халкы өчен бу прагматоним чын милли атама буларак кабул ителә.

Чын татарча милли атамалардан шулай ук *«Болгар» чәк-чәге, «Болгар» минераль суы* прагматонимнарын китерергә мөмкин. Татарлар тарихында зур урын алып торган Болгар шәһәренең атамасын прагматонимнар ролендә куллану да халкыбызның милли күзаллаулары, үткән тарихы хакында сөйли.

*«Сандугач» торты, «Карлыгач» конфеты* прагматонимнарында татар халкы фольклорында традицион булган кош образлары кулланылган. Шулай ук әлеге кош образлары татар халкының бик күп җырларында очрый.

*Тулпар* мифологик персонаж исеме *«Тулпар» туңдырмасы* атамасында очрый. Тулпар образы татар, башкорт, кыргыз һәм казак мифологиясендә канатлы (оча торган) ат буларак мәгълүм (Урманчиев, 2015: 278). Ул борынгы грек мифологиясендәге Пегас белән тәңгәлләшә.

Икенче төркемгә *татар халкының дини дөнья картинасын чагылдырган* прагматонимнарны кертәбез. Татар рухи мәдәниятенең аерылгысыз өлеше булган ислам дине милләт формалашуында һәм алдагы үсешендә зур роль уйнады. XX гасыр ахырында илдә барган иҗтимагый үзгәрешләр, дин һәм сүз ирегe игълан ителү нәтиҗәсендә мөселманлык, ислам дине кануннары белән бәйле прагматонимнар барлыкка килде. Мәсәлән: *«Рамазан» колбасасы, «Җомга» колбасасы, «Сәдака» чәе, «Хәергә» чәе, «Мәрьям» чәе* һ.б. Алар хакында беркадәр алдагы бүлекчәдә әйтелеп үтелде. Бу төр атамаларны йөрткән товарлар татар халкы арасында шактый популяр. Алар, бер яктан, халкыбызның дини гореф-гадәтләре, ышанулары хакында бәян итсә, икенче яктан, бу прагматонимнар татар халкының ислам дөньясы белән булган багланышларын чагылдырган тел берәмлекләре булып та торалар. Мәсәлән, күп кенә атамаларда урын алган Халәл азык-төлек стандарты комитеты атамасы булган Халәл (HALAL) брендын алыйк. *Хәләл* (гар. حلال – *рөхсәт ителгән*) – «ислам буенча рөхсәт ителгән барлык әйбер»

(хәрәмгә капма-каршы). Бу лексема безгә гарәп теленнән кергән һәм ул ислам кануннары нигезендә әзерләнгән ризык, ислам дине тарафыннан рөхсәт ителә торган эш-шөгыль мәгънәсендә аңлашыла. Халәл бренды Татарстан Республикасында товар җитештерә торган шактый фирма, кибет һәм оешмаларда кулланыла, мәсәлән, *«Бәхетле-халәл», «Итле» кулланылышы чикләнгән җәмгыять, «Тәмле» кулланылышы чикләнгән җәмгыять, «Халәл-Үзәк» сату үзәге, «Тарханская» суы, «Мюстела» косметика линиясе, «Казы» премиум-класс гастрономиясе һәм кондитер товарлары бренды «Bateel»* һ.б.

Югарыда саналган атамаларда, бер яктан, халкыбызның милли үзаңы, дини ышанулары, икенчедән, ислам дине кануннары нигезендә яшәү рәвеше, шуңа омтылышы чагылыш таба. Шунысын да искәртергә кирәк: мөселман дине белән бәйле мондый атамалар XX гасыр ахырларында, илдә барган зур иҗтимагый процесслар нәтиҗәсендә кулланылышка кереп китте һәм активлашты.

Күренгәнчә, татар прагматонимикасы илдәге сәяси-иҗтимагый вакыйганы, күпмилләтле республикабызның мәдәни-рухи тормышын, дини гореф-гадәтләрне, милли йолаларны чагылдыра алуы ягыннан да әһәмияткә ия һәм игътибарга лаек ономастик тармак булып тора. Икетеллелек, глобальләштерү шартларында татар теленә башка телләрдән кергән сүз һәм аерым конструкцияләр еш кулланыла. Аларның сөйләм телендә һәм матур әдәбият телендә урынсыз кулланылуын искәртеп, халыкта туган теленә ихтирам тәрбияләү – этномәдәни лексиканың мөһим бурычы. Тулаем алганда, прагматонимика ландшафтында чын милли атамалар чагыштырмача күп түгел. Шуңа карамастан, алар аерым игътибарга лаек һәм мөһим урын алып торалар. Бу төр атамаларның һәрберсе татар халкының мифик, мәдәни күзаллауларын чагылдыра. Прагматонимнарда чагылыш тапкан халык авыз иҗатының тотрыклы образлары, тарихи лексика халыкның милли-тарихи хәтерен яңарта.

Шулай итеп, прагматонимнар ономастик даирәнең үзенчәлекле сегменты булып тора. Аларның күптөрлелеге һәм күпсанлы булуы, бер яктан, хәзерге маркетингның бурычлары белән, икенче яктан, бер типтагы товарларга атама бирү кирәклеге белән бәйле. Бу – ономастиконның кешелек тормышының һәр ягын биләп алуын раслый.

## § 54. Татар прагматонимнары төзелеш-ясалышында төп үзенчәлекләр

Татар телендә кулланыла торган прагматонимнарның ясалышы моңа кадәр махсус өйрәнелмәде. Тикшерүләр күрсәткәнчә, прагматонимнар башка төр ялгызлык исемнәренә хас үзенчәлекләр нигезендә ясалалар. Составлары ягыннан татар телендә аларның түбәндәге төрләре күзәтелә:

а) бер сүздән торган (беркомпонентлы) прагматонимнар – бу лексемалар телнең төп сүзлек составыннан алынган. Мәсәлән: *«Чишмә» каймагы, «Бәйрәм» колбасасы, «Карлыгач» конфеты, «Назлы» торты, «Резеда» конфеты, «Батыр» туңдырмасы, «Бүләк» бәлеше, «Башкирхан» балы, «Казан» токмачы* һ.б.;

б) ике яки берничә сүздән торган прагматонимнар – сүзтезмәләр, предикатив берәмлекләр. Мәсәлән: *«Авылым сөте» катыгы, «Ак барс» ветчинасы, «Яр Чаллы» чәкчәге, «Ак каен» печеньесы, «Курай крае» сөт продукциясе* һ.б.

Татар телендә бер компонентлы конструкцияләр өстенлек иткәнен билгеләп үтәргә кирәк.

Прагматонимнар ясалышында ике төрле үзенчәлек күзгә ташлана: күмәклек сүзләрдән прагматоним ясалу – онимлашу күренеше һәм трансонимлашу күренеше, ягъни башка төрдәге онимның прагматоним составында кулланылуы.

Онимлашуны, ягъни күмәклек сүзнең прагматоним рәтенә күчүен, Н.В. Подольская фикеренә нигезләнеп, семантик һәм грамматик онимлашу ысулларына аерабыз. Галимә семантик онимлашу вакытында ясагыч сүздә ниндидер үзгәрешләр күзәтелмәвен, ә грамматик онимлашу сүзнең морфема составындагы үзгәрешләрне (кушымчалау, плюрализация, сүзләр кушу, гибридлашу һ.б.) яки синтаксик ысулны (сүзтезмә исем, исем-фразалар барлыкка килү) билгели (Подольская, 1988: 92).

Тамыр сүзләр нигезендә ясалган прагматонимнар телдә иң зур күпчелекне тәшкил итә: *«Шифа» минераль суы, «Алтын» чәе, «Авыл» коймаклары, «Әкият» торты, «Батыр» туңдырмасы, «Ватан» каймагы, «Бәйрәм» торты, «Карлыгач» конфеты , «Кияү» пилмәне* һ.б.

Прагматонимнарның лексик-семантик ысул белән ясалышы өч яссылыкта бара: семантик онимлашу, трансонимлашу, башка телләрдән сүзләр алу.

Семантик онимлашу гади, метафорик формаларда була.

*Гади семантик онимлашу* вакытында прагматоним эчтәлегендә аталган предмет, сыйфат, билге һ.б. турыдан-туры чагылыш таба. Мәсәлән: *«Икмәк» ипие, «Milli kiem» маркасы, «Бизәк» товар маркасы, Талкан продукциясе* һ.б. Татар теленә мөнәсәбәтле барлыкка килгән прагматонимнарда бу төр киң таралыш тапмаган.

*Метафорик онимлашу* апеллятив аңлаткан сыйфат, билге, предметның реаль яки күзалланган охшашлыгына нигезләнгән. *«Ак каен» шампуне*, *«Ekiyat» милли кием бренды, «Тормыш» икмәге, «Рәхәт» чәе, «Кияү» пилмәне, «Урман» минераль суы, «Шатлык» газлы эчемлеге* һ.б. шундыйлардан.

Татар телендә прагматонимнарның *трансонимлашу юлы белән ясалышы* иң киң таралган төр исәпләнә. Прагматонимнар рәтенә күчкән башка төр онимнарның түбәндәге модельләре очрый:

1) антропонимнарның прагматонимга әйләнүе, мәсәлән, *«Айгөл» коймаклары, «Мәрьям» чәе, «Сөембикә» торты,* милли кием һәм күн эшләнмәләр бренды *«ALSU»* һ.б. Товарга атама биргәндә кеше исемен бирү дөньякүләм таралыш тапкан ысул санала. Инглиз теленнән кергән товар билгеләрен карап үтсәк, «*Mars*» *шоколады* атамасы Америка эшмәкәре Форрест Марс исеменә нисбәтле бирелгән, *«Lipton» чәе* шул исемдәге брендны барлыкка китергән Томас Липтон исеме белән бәйле. Рус телендәге *«Быстров» боткалары, «Коркунов» шоколады, «Махеевъ» майонезы* шулай ук моңа мисал булып тора.

Кайбер очракларда җитештерүче исеме белән берничек тә бәйләнмәгән исемнәр дә кулланыла. Мәсәлән: *«Аленка» шоколады, «Гита» чәе.* Татар телендә исә бу күренеш ешрак очрый. Мәсәлән: *«Алия» торты, «Сөембикә» торты* һ.б.;

2) топонимнарның прагматоним рәтенә күчүе: *«Мамадыш» сыры, «Яр Чаллы» чәкчәге, «Биектау» конфеты, «Казан» чәкчәге, «Чишмәле» сөте, «Әлдермеш» суы, «Kuktara» чуен савыт-саба сериясе* һ.б. Әйтергә кирәк, бу төр трансонимлашу күренешендә иң киң таралган модель булып тора.

Лексик-семантик ысулның бер төре буларак, *башка телләрдән сүзләр алу* да карала. Татар җирлегендә кулланылган зур күпчелек прагматонимнарны әлеге төр хасил итә. Чыганак телгә бәйле аларның төп ике төркеме аерыла:

1) гарәп һәм фарсы чыгышлы прагматонимнар. Бу төр берәмлекләрнең зур күпчелеге татар теле җирлегендә прагматоним рәтенә күчкән. Прагматоним буларак, алар чыганак телдән алынмаганлыктан, татар теленең сүзлек составында булган гарәп һәм фарсы алынмалары нигезендә ясалганлыктан, без аларны күмәклек сүзләрнең онимлашуы рәтендә карыйбыз. Әлеге алынмалар мөселман товарлары белән бәйле килеп керәләр. Мәсәлән: *«Рамазан» колбасасы, «Сәдәка» чәе, «Хәергә» чәе, «Җомга» колбасасы.* Биредә *«Рамазан» колбасасы, «Җомга» колбасасы*ның шундый исемнәр белән аталуы аларның хәләл продукция булуы белән бәйле булса, *«Сәдака» чәе, «Хәергә» чәе* кебекләре исә мөселман бәйрәмнәрендә бүләк өчен махсус чыгарылган товарлар;

2) рус һәм Европа телләреннән прагматоним буларак килеп кергән алынмаларның татар җирлегендә бик актив кулланылышы иҗтимагый-иктисади, сәяси факторлар белән бәйле. Әлеге алынмаалрны ике төркемгә аерырга кирәк:

а) график һәм грамматик яктан өлешчә яраклаштырылган прагматонимнар. Иң күп очракта яраклаштыру рус теле җирлегендә барганлыктан, аларның тышкы формалары тулысынча татар теле закончалыкларына туры килми: торт исемнәре: *«Барби», «Арабелла», «Чикита», «Кокоала», «Мулен Руж», «Трюфель», «Наполеон», «Солнышко»;* икмәк атамалары: «*Посольский», «Татарский», «Трюффо»* пирожное, *«Даниссимо»* эремчеге һ.б.;

ә) варваризмнар арасында иң киң таралганы – чит ил брендлары, марка атамалары. Мәсәлән: *Amritta, Adidas, Alba, Colin's, Dars, Dixis, Ecco* һ.б.; шулай ук чит ил лексемаларын куллану киң таралыш тапкан: «*Love» сыек сабын*, *«Nefco Auto Flash» автошампуне, «Visit Tatarstan»* косметика маркасы һ.б.

Шулай ук варваризмнар төркеменә чит телнең формаль элементлары белән ясалган прагматонимнарны да кертеп карарга мөмкин. Мәсәлән, бал атамасы «*Baldan*»; сумка бренды «*ALSU*»; бренд атамасы «*MILLI», «Kuktmara» чуен савыт-саба сериясе, «Татарча casual»* заманча милли киемнәре*, «Chak-chak»* һ.б.

Татар телендә г р а м м а т и к  о н и м л а ш у юлы белән прагматонимнар ясалу берничә төрле сүз ясалыш моделе нигезендә бара: кушымчалау, сүзләр кыскарту, нигезләр кушу һәм башка телдән алынмалар үтеп керү.

*Кушымчалау ысулы белән прагматонимнар ясалу* татар телендәге сүз ясалыш закончалыклары нигезендә, телнең актив сүз ясагыч чаралары ярдәмендә бара. Прагматоним исем сүз төркеменә карый торган берәмлек булганлыктан, аның ясалыш модельләре исемнәр ясалышында катнаша торган кушымчаларга бәйле. Искәртергә кирәкле бер үзенчәлек: прагматонимнар ясалышында телнең иң продуктив кушымчалары гына диярлек катнаша, пассивлаша башлаган, телдә яңа төр исемнәр ясаудан читләшкән кушымчалар прагматоним ясалышында күзәтелмиләр. Шулай итеп, хәзерге татар телендә кулланыла торган прагматонимнар составында түбәндәге кушымчаларны билгелибез:

нигез + *-даш/-дәш, -таш/-тәш* кушымчалары белән исем ясалышын борынгыдан килә торган сүз ясалыш калыбына кертергә мөмкин, һәм ул еш кулланыла, продуктив санала. Мәсәлән: *классташ, сабакташ, якташ*. Әлеге кушымча кулланып ясалган күмәклек сүзләренең онимлашуы очраклары түбәндәге прагматонимнарда күзәтелә: *«Авылдаш» каймагы, «Авылдаш» сөте, «Якташ» колбасасы, «Юлдаш» ит фаршы* һ.б.;

нигез + *-лык/-лек* кушымчасы белән ясалган исемнәрнең, башлыча, билге мәгънәсен гомумиләштергән, абстракт исемнәр ясалган очраклары прагматонимнар рәтенә күчкән: *«Дуслык» сарделькалары, «Яшьлек» рулеты* һ.б.;

нигез + *-лы/-ле* моделе прагматонимнар өлкәсендә иң киң таралган. Бу кушымча хәзерге татар телендә иң күп сүз ясаучы кушымчаларның берсе санала. Ул, фактлар күрсәткәнчә, полифункциональ кушымча булып тора: исемнәр ясауда да (*уфалы, бөгелмәле*), сыйфатлар (*сәләтле, акыллы*) ясауда да катнаша. Тел материалын тикшерү *-лы/-ле* кушымчасы, абстракт исемнәргәялганганда, сыйфат ясаучы кушымча буларак килүен күрсәтә: *тәм + ле, күңел + ле, сизем + ле* (Татар грамматикасы, т. 1, 2015: 376). Әлеге кушымчаның сүз ясалышы ягыннан мәгънәви кыры киң булса да, прагматонимнарда ‘предметка хас уңай билге’ мәгънәсе өстенлек итә: *«Чишмәле» сөте, «Тәмле» сдобасы, «Баллы» торты, «Назлы» торты, «Бәхетле» торты, «Ипле» кош теле, «Бәрәкәтле» эремчеге* һ.б.;

нигез + *-гы/-ге, -кы/-ке* моделе киң таралыш тапмаган, без аны *«Кышкы әкият» чәе* мисалында очратабыз.

Шулай итеп, прагматонимнар ясауда еш кулланыла торган кушымчалар булып *-даш/-дәш, -таш/-тәш, -лык/-лек, -лы/-л*е са-

нала, калган кушымчалар товар атамаларын ясауда яисә бөтенләй кулланылмый, яисә бик аз санда файдаланыла.

*Нигезләр кушылу ысулы белән ясалган кушма прагматонимнар.* Татар телендә нигезләр тезүле бәйләнеш юлы белән дә, ияртүле бәйләнеш юлы белән дә кушма исемнәр ясаганнар һәм ясыйлар (Татар грамматикасы, т. 1, 2015: 268). Исем сүз төркеменә караган прагматонимнарда да бу үзенчәлек саклана.

Парлы сүзләр төрки телләрнең төп үзенчәлекләренең берсе булып тора, татар теленең лексик системасында да алар киң таралыш тапкан. Компонентлары тезүле бәйләнешкә нигезләнеп ясалган прагматонимнар, сирәк булса да, телдә очрый. Мәсәлән: *«Аштау», «Тау-су» минераль сулары.*

Ияртүле бәйләнештә булган компонентлар кушылып ясалган прагматонимнарның түбәндәге типлары очрый:

а) исем + исем тибы: *«Сөембикә» торты, «Сабантуй» колбасасы, Әлдермеш суы* һ.б.;

ә) сыйфат + исем тибы: *«Аккош» конфеты, «Ак каен» печеньесы, «Ак барс» ветчинасы;*

б) җөмлә тибы прагматонимнар арасында сирәк булса да очрый. Мәсәлән, *«Сәлам, Мәрьям»* бренды.

*Сүзне кыскарту (аббревиация) юлы* ономастик кырның перифериясендә урнашкан эргонимнарда шактый актив, ә прагматонимиядә сирәк күзәтелә. Татар теле җирлегендә бренд хуҗасы Миләүшә Мусина исеме һәм фамилиясе нигезендә ясалган *«MISA»* брендын китерә алабыз.

Конверсия ысулы белән ясалган прагматонимнар телдә аз, бирегә «*Ихластан*» токмач атамасын кертергә була.

Шулай итеп, татар телендә прагматонимнар ясалышы, башлыча, телдәге сүз ясалыш модельләренең иң активлары ярдәмендә башкарыла. Бу төр берәмлекләрнең башка телләрдән күпләп үтеп керүе нәтиҗәсендә, ясалыш һәм кулланылышларында чит ил элементларын да очратабыз. Прагматонимнарның структур үзенчәлекләре аларның яшәешендә һәм товарның кулланучысын табуда әһәмиятле. Дөрес, уңышлы, заман таләбенә туры килгән прагматоним прагматик эффект тудыруда төп рольне уйный.

# ПОЭТИК ОНОМАСТИКА

## § 55. Поэтик ономастиканы өйрәнү тарихы

Ономастика өлкәсендә яңадан-яңа эзләнүләр нәтиҗәсе буларак, ялгызлык исемнәренең матур әдәбият әсәрләрендә башкарган функцияләренең теоретик һәм гамәли әһәмияте киңрәк планда ачыла. Шул рәвешле, ономастиканың әдәби әсәрләрдә онимнарның кулланылыш үзенчәлеген өйрәнә торган тармагы аерым үсеш ала. Аны *шагыйранә* яисә *поэтик ономастика* дип атап йөртә башлыйлар.

XX гасырның урталарында поэтик ономастика буенча эзләнүләр аерым мәкалә-очеркларда гына чагылган булса, хәзерге вакытта исә гомуми тел белемендә, шул исәптән төрки-татар тел белемендә дә бу өлкәгә караган шактый күләмдә махсус монографик хезмәтләр, җыентыклар дөнья күрә, кандидатлык һәм докторлык диссертацияләре яклана. Гомуми һәм шәхси поэтика, стилистика, матур әдәбият теле, текст лингвистикасы өлкәсендә тикшеренүләрнең киңәеп китүе аркасында әдәби текстларда кулланылган ялгызлык исемнәрне өйрәнү тагын да активлаша. Озак вакытлар дәвамында поэтик ономастика галимнәрне бары тик гамәли характердагы тармак буларак кына кызыксындыра: әдәби текстларга билгеле бер аңлатмалар бирү, әдәби әсәрләрнең ономастик сүзлекләрен төзү һ.б. Мәсәлән, XX гасырның 40–50 нче елларында рус тел белемендә А.С. Пушкин (В.В. Виноградов, 1941), Н.В. Гоголь (В.Н. Михайлов, 1954); М.Е. Салтыков-Щедрин (А.С. Бушмин, 1959) иҗатын яктырткан хезмәтләр шундыйлардан. Шул ук вакытта ялгызлык исемнәренең поэтикасына караган гомуми мәсьәләләр, төп теоретик нигезләмәләр дә эшләнә башлый.

Әлеге яссылыкта рус тел белемендә берничә авторның иҗатын чагыштырмача, киңрәк планда өйрәнүгә корылган М.И. Привалова (1952), М.И. Черемисина (1958), Р.П. Шагинян һәм Э.Б. Магазаник (1958) хезмәтләре игътибарга лаек (Фомин, 2004: 114). Алга таба, матур әдәбиятта кулланылган ялгызлык исемнәрен өйрәнү проблемасы киңрәк планда ачылып, алда искә алынган гамәли бурычлардан тирәнрәк, тулырак күзаллана башлый. Әле 1963 елда ук академик В.В. Виноградов билгеләгәнчә, «матур әдәбиятта билгеле бер исем, фамилия, кушаматларның сайлап кулланылуы, аларның төрле жанр һәм стильләрдә аерыла торган структур үзенчәлекләре, кабатланмас үрнәкләре, башкарган функцияләре һәм башка шундый сораулар берничек тә аз гына мисаллар белән ачыла алмаячак. Бу – матур әдәбият стилистикасының бик зур һәм катлаулы темасы» (Виноградов, 1963: 38).

Әдәбиятта кулланылган ялгызлык исемнәрен XX гасырның 50 нче елларында Советлар Союзының төрле фәнни үзәкләрендә төрле галимнәр бер үк вакытта диярлек өйрәнә башлый. Әлеге проблематика буенча беренчеләрдән булып кандидатлык диссертациясен В.Н. Михайлов яклый, (1956). Украинада – Ю.А. Карпенко, Л.И. Колоколова, Үзбәкстанда – Э.Б. Магазаник һәм С.И. Зинин, Азәрбайҗанда – З.П. Жаплова, Грузиядә – Д.С. Мгеладзе һәм Н.П. Колесников, Россиядә – М.С. Альтман, С.А. Копорский, М.И. Черемисина, С.Е. Шаталов һәм башка бер төркем галимнәр төрле язучыларның иҗатында кулланылган ялгызлык исемнәрен өйрәнүгә керешә. Бу, үз чиратында, күп кенә телче һәм әдәбиятчыларның матур әдәбият ономастикасын үзтикшеренү объекты булган мөстәкыйль статуслы фәнни тармак итеп тануга китерә.

Бүгенге көнгә ономастик лексиканың поэтик һәм лингвистик үзенчәлекләрен өйрәнүнең методологик һәм фәнни-теоретик нигезләре эшләнеп беткән диярлек мөмкин. Ватан ономастикасында әдәби текст лексикасы кысаларында ономастик катламның мөһимлеге, авторлар тарафыннан индивидуаль кулланылышы, онимнарны сайлап алуда иҗтимагый-тарихи, сәнгати факторларның роле тирәнтен өйрәнелә. Совет телчесе Ю.А Карпенко ялгызлык исемнәренең матур әдәбият әсәрләрендә кулланылыш үзенчәлекләрен, төзелешен, килеп чыгышын, ялгызлык исемнәренең асылын өйрәнеп, аның концепциясен эшли. Тикшерүчеләрнең игътибарын поэтик антропонимнар ешрак җәлеп иткәнгә, матур

әдәбияттагы ономопоэтик лексиканың әлеге категориясе күбрәк өйрәнелә (Султанова, 2016: 61). А.Ф. Лосев, М.В. Карпенко, В.Н. Михайлов, А.В. Суперанская, В.И. Супрун һ.б.ның хезмәтләрендә семантик мотивациягә ия булган исемнәрнең поэтик үзенчәлекләре киң яссылыкта яктыртыла. Л.М. Буштян, Л.И.Андреева, М.В. Голомидова, Г.Ф. Ковалев, В.М. Калинкин, Э.Б. Магазаник хезмәтләрендә поэтик ономастиканың төп аспектлары монографик планда тикшерелә. Ә менә поэтик топонимнарның кулланылыш үзенчәлекләре, әсәрдәге роле проблемасы азрак өйрәнелгән. Әдәби текстның поэтик структурасын формалаштыруда топонимнарның роле һәм урыны К.М. Илисханова, М.В. Горбаневский, И.П. Литвин, И.М. Шапиро, М.Н. Морозова хезмәтләрендә карала.

Төрки тел белемендә поэтик ономастика мәсьәләләре аеруча татар телчеләре хезмәтләрендә тирәнтен өйрәнелә. Беренче башлап бу өлкәгә XX гасырның 70 нче елларында Г.Ф. Саттаров игътибар итә. Казан төрки-татар ономастика фәнни мәктәбенә нигез салучы һәм бу өлкәгә зур өлеш кертүче галим, «Этапы развития и очередные задачи татарской ономастики» хезмәтендә бирелгән максат-бурычларның берсе буларак, матур әдәбият әсәрләрендә очраган ялгызлык исемнәренең (антропоним һәм топонимнарның) поэтик-стилистик үзенчәлекләрен өйрәнүне күрсәтә, ә 1993 елда чыккан мәкаләсендә бу өлкәне махсус тикшеренү көтүен билгели (Саттаров, 1993:180–184).

Поэтик ономастика бүгенге татар тел белемендә актив өйрәнелә торган тармакларның берсе булып тора. Хәзерге вакытта татар әдәбиятының шагыйранә (поэтик) ономастикасын өйрәнүгә багышланган дистәләгән фәнни хезмәтләрне атап китү мөмкин. Г.Ф. Саттаров җитәкчелегендә язылган диссертацияләр татар әдипләренең ялгызлык исемнәрен куллану үзенчәлекләрен киң планда тикшерүне башлап җибәрә. Нәтиҗәдә М. Мәһдиев прозасында кулланылган ялгызлык исемнәр (Р.Х. Гаррапова, 2000), татар халык җырларының лингвистик үзенчәлекләре һәм поэтик ономастикасы (А.Р. Биктимерова, 2002), М. Җәлил либреттоларында кулланылган исемнәрнең үзенчәлекләре (С.С. Арсланова, 2004), Г. Бәширов әсәрләрендәге ялгызлык исемнәренең текстта башкарган лингвопоэтик вазифалары (В.М. Гарипова-Хасаншина, 2004), Ә. Еники иҗатында кулланылган барлык төр поэтонимнарның әсәр тукымасын барлыкка китерүдәге роле, сәнгати-стилистик

функцияләре (Г.Х. Зиннатуллина, 2005), Ш. Галиев һәм Р. Миңнуллинның балалар өчен язылган шигырьләрендә тудырылган ономастиконның үзенчәлекләре (Л.М. Хамитова, 2007), Т. Миңнуллин драмаларында кулланылган ономастик берәмлекләр (Ф.Ф. Нуруллина, 2011) монографик планда, комплекслы рәвештә өйрәнелә.

Хәзерге вакытта поэтик ономастика үзенең тикшерү объектына, үзанализ методларына ия булган мөстәкыйль фән буларак карала. Ул лексикология, поэтика һәм текст лингвистикасы, семиотика, стилистика белән тыгыз бәйләнештә актив үсеш кичерә.

## § 56. Поэтик ономастика төшенчәсенә гомуми билгеләмә

П о э т и к о н о м а с т и к а дип матур әдәбият әсәрләрендә барлык төр ялгызлык исемнәрен, аларның барлыкка килү принципларын, стилистик һәм идеологик функцияләрен өйрәнә, авторның дөньяга карашын чагылдыра торган ономастиканың махсус тармагы атала (Подольская, 1988: 96). Поэтик ономастиканың тикшерү объекты – әдәби әсәрләрнең басма характердагы текстлары. Шулар нигезендә генә поэтонимнарга әдәби әсәрнең идеясен һәм язучының иҗади осталыгын күздә тоткан хәлдә анализ ясала. Еш кына поэтонимнарга тулы, системалы анализ ясау өчен өстәмә чыганаклар да игътибарга алына. Мондый өстәмә чаралар рәтенә авторның кульязмалары, әдәби әсәрнең якынча вариантлары, корректура битләре, язучының куен дәфтәрендәге язмалар, әсәрне иҗат итү алдыннан ул җыйган барлык төр материаллар керә.

Мөстәкыйль фән буларак аерымлану процессы бу фәннең билгеле бер атамасын формалаштыруны да таләп итә. Кайвакыт яңа фәнгә атама булырдай термин табу шактый озакка сузыла. Андый очракларда галимнәр төрле терминологик вариантлар куллана. Поэтик ономастика белән дә шулайрак килеп чыга. Мәсәлән, антропонимнарның стилистик үзенчәлекләрен өйрәнүгә зур өлеш керткән К.Б. Зайцева лингвостилистиканың әдәби әсәрләрдә кулланылган ялгызлык исемнәрен өйрәнә торган бүлеген «*стилистик ономастика*» дип, ә аның тармакларын «*стилистик антропонимия*», «*стилистик топонимия*» һ.б. дип йөртергә тәкъдим итә (Зайцева, 1973: 30). Ономастиканың теоретик нигезен формалаштыручыларның берсе М.В. Карпенко «*әдәби антропонимика*» дигән термин тәкъдим итә (Карпенко, 1970: 13). Шушы ук термин

антропонимнарның барлыкка килү, кулланылыш үзенчәлекләрен монографик планда өйрәнгән Л.М. Щетинин хезмәтләрендә очрый. Ялгызлык исемнәренең матур әдәбиятта кулланылыш мөмкинлекләрен тикшергән ономатологлар Э.Б.Магазаник һәм Л.И. Ройзензон фикеренчә, әдәби әсәрләрдәге ялгызлык исемнәрен анализлаган вакытта «*ономопоэтика*» һәм «*ономостилистика*» дигән төшенчәләрне аерып карарга кирәк. Беренче терминның ялгызлык исемнәрнең әдәбият белеме белән бәйле үзенчәлекләре, ә икенче терминның бары тик лингвистик аспект белән бәйле булуына басым ясала (Магазаник, Ройзензон, 1974: 7). Э.Б. Магазаник алдагы хезмәтләрендә, шул исәптән «Кыскача әдәби энциклопедия»дә дә, «*поэтик ономастика*» терминын куллана. «Теория и методика ономастических исследований» (1986) дип аталган коллектив монографиядә исә бернинди аңлатмаларсыз, синонимнар буларак *«әдәби ономастика», «поэтик ономастика», «әдәби текстның ономастикасы»* дигән терминнар кулланыла. Н.В. Подольскаяның «Рус ономастик терминологиясе сүзлеге»нең беренче басмасында (1978) «поэтик ономастика» мөстәкыйль термин буларак тасвирланмый, ләкин «Ономастика» бүлекчәсендә бу терминның «*әдәбият ономастикасы*» дигән тезмә терминның бер өлеше булуы турында әйтелә. Әмма шушы ук сүзлектә, аерым мәкаләләр рәвешендә, «*поэтик антропонимика*» («антропонимиканың әдәби антропонимнар, аларның әдәбиятта кулланылыш мөмкинлекләрен өйрәнә торган тармагы») һәм «*поэтик топонимика*» («топонимиканың әдәби әсәрләрләрдә топонимнарның барлыкка килүен һәм кулланылуын өйрәнә торган тармагы») терминарының билгеләмәләре бирелә. Искәрмә рәвешендә, «*поэтик антропонимика*» терминына, синоним буларак, «*әдәби антропонимика*» һәм «*стилистик антропонимика*» терминнарының кулланылуы әйтелә.

Поэтик ономастиканың мөстәкыйль фән буларак аерылып чыгуы аның үзенә генә хас булган махсус терминнар системасы барлыкка китерүне дә таләп итә. Матур әдәбиятта кулланылган ялгызлык исемнәренә анализ ясаганда һәм әдәби образны персонификацияләштергән вакытта традицион рәвештә *исем* яисә *ялгызлык исем* терминнарын кулланалар. Матур әдәбият текстларында алар тагы да конкретлаштырыла: әдәби герой, әдәби персонаж исеме. «Персонаж исеме – әдәби образны барлыкка китерүче чараларның берсе, ул геройның социаль чыгышын, теге яки

бу урынчылыкның милли колоритын, ә инде вакыйгалар үткәнгә карасa, тарихи дөреслекне дә чагылдырырга сәләтле» (Никонов, 1974: 234). Әмма бу билгеләмәдә әдәбиятта кулланылган ялгызлык исемнәренең җәмгыять һәм иҗтимагый шартлар белән тыгыз бәйле булуы гына ассызыклана, ә аларның әдәби әсәр структурасында үзенчәлекле, мөстәкыйль берәмлек булуы телгә алынмый. Озак вакытлар дәвамында әдәби әсәрләрдә кулланылган ялгызлык исемнәрен атау өчен, күпчелек очракта, әдәби антропоним термины («персонажларны атап килгән һәртөрле ялгызлык исемнәр») кулланыла (Силаева, 1977: 152). Үз вакытында М.В. Карпенко, *әдәби антропонимнар* дигәндә, язучы тудырган ялгызлык исемнәрен генә күз алдында тота. Бу очракта әсәрләрдә кулланылган реаль тарихи шәхесләрнең исемнәре геройларның исем-атамалары сыйфатында каралмый да (Карпенко, 1970: 24). Соңга таба бу төр чикләүләр юкка чыга. Әдәби антропонимнар дип персонификацияләнгән әдәби образны атауда кулланылган барлык ялгызлык исемнәрен атап йөртә башлыйлар. Матур әдәбият текстларында кулланылган топоним, зоонимнарны анализлаганда әдәби топоним, әдәби зооним терминнары кулланыла башлый. Ләкин шулай да, әдәби әсәрләрдә кулланылган барлык төр ялгызлык исемнәрне атарга сәләтле булган термин кирәк була. Поэтик ономастика очен мондый термин – поэтоним. Бу терминны әдәбият белгечләре шартлы экзотик, мифологик, ягъни нинди дә булса поэтик мәгънәгә ия булган ялгызлык исемнәрне атау өчен дә кулланалар (Фомин, 2009: 58). Поэтик ономастика әлеге терминның мәгънәви эчтәлеген киңәйтүне таләп итә: «Поэтик исем (поэтоним) – матур әдәбиятта кулланыла торган һәм әсәр телендә, номинатив мәгънәдән тыш, тасвирлама, стилистик һәм идеологик функцияләр башкара торган исем. Кагыйдә буларак, ул уйлап чыгарылган исемнәр категориясенә карый, ләкин, еш кына, язучылар реаль кулланылыштагы исемнәрне яисә аларның комбинацияләрен куллана» (Подольская, 1988: 108). Димәк, әдәби текстларда кулланылган ялгызлык исемнәренең төрләрен төгәлрәк ачыклау максатында, поэтик антропоним, поэтик топоним, поэтик зооним һ.б. терминнар куллану үзен тулысынча аклый.

Поэтик ономастиканың үзенә генә хас билгеләре бар. Ул гомумхалык ономастикасы нигезендә барлыкка килә һәм аңа таяна. Язучы реаль ономастикадан, телдәге исем кушу традицияләреннән,

калыпларыннан читкә китә алмый. Билгеле, язучы аерым телгә хас булган ономастик ресурслардан гына файдаланып калмый. Еш кына ул, исем кушу сәнгатенә бирелеп, иҗади фикерне тормышка ашыру максатында яңа, үзе уйлап чыгарган исемнәр дә кулланырга мөмкин, мәсәлән, *Күсия, Акъәби* исемнәре. Ләкин бу очракта да гомумхалык ономастик системасы язучы алдына үз калыпларын, үз таләпләрен куя. Язучы ономастик модельләргә үзгәреш кертергә, ономастик кагыйдәләрне бераз интерпретацияләргә мөмкин, әмма төп принципларны бозмый. Әдәби әсәрдәге персонаж исемнәре һәм географик объект атамалары аларны билгеле бер урын (ил, тел), чор, иҗтимагый тирәлек белән бәйли. Шуңа да язучы ономастик кагыйдәләргә буйсынмыйча булдыра алмый. Ә менә фәнни фантастика турында аерым әйтү кирәк. Мондый төр әсәрләрдә вакыт һәм пространство күчешләре (алдагы ерак киләчәк, башка галәм тормышы) еш күзәтелә, ә алар ономастик трансформацияләрдән, үзгәрешләрдән башка була да алмый. Ләкин нинди генә яңа исем уйлап табылмасын, ул барыбер кабул ителгән антропонимик система калыпларыннан читкә чыкмый (Карпенко, 1986, 34).

Конкрет ялгызлык исемен сайлау – авторның субъектив эше. Язучы ялгызлык исемнәрен генә түгел, әдәби әсәрнең ономастик тирәлегенә кергән һәрбер компонентны сайлап яисә үзгәртеп куллана. Ул персонажларның характерын, шөгылен, рухи һәм физик үзенчәлекләрен белә. Һәм бу очракта ялгызлык исем персонажның инде билгеле булган сыйфатлары һәм әсәрнең максатлары белән нindидер бәйләнешкә кермичә булдыра алмый. Бу бәйләнешләр катлаулы һәм төрле булсалар да, алар һәрчак планлаштырылган, автор тарафыннан махсус рәвештә кертелмәгән булырга да мөмкин.

Әдәби ономастика – сөйләм факты. Әдәби исем мөстәкыйль кулланылган, символга әйләнгән очракта гына сөйләмнән телгә күчә ала (*Мәҗнүн, Зөләйха, Зөһрә, Галиябану* һ.б.) Мәсәлән, XX гасыр башы татар әдәбияты турында сүз барганда *Хәятләр* (Ф. Әмирханның «Хәят» повесте), *Мәрьямнәр* (Г. Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр» романы) шул чор татар аристократ хатын-кызларының яшәү рәвешен, характер сыйфатларын чагылдыра торган символик исемнәр буларак кабул ителә. Моның өчен әсәрнең популярлыгы җәмгыятьтә нindидер күренеш яки иҗтимагый типны билгеләү, атау өчен барлыкка килгән ихтыяҗ белән үрелеп

китәргә тиеш. Әдәби ономастиканың тел күренеше түгел, ә сөйләм күренеше булуы аның күп кенә сыйфатларын, аерым алганда, реаль ялгызлык исемнәренең әсәр кысаларында башкарган функцияләрен аңлауны җиңеләйтә. Әдәби текстта тарихи шәхес исемнәре, реаль топонимнар поэтик ономастиканың компонентларына әверелә һәм «сөйли» башлый.

Әдәби әсәрдә ялгызлык исемнәренең бик тә үзенчәлекле бер төре – ул әсәрнең атамасы. Әсәрләрнең, аларның өлешләре, бүлекләренең атамалары – ялгызлык исемнәре, чөнки алар аерым бер объект атамасы булып килә. Ялгызлык исемнәренең гомуми төркемнәре арасында әсәр атамаларын хрематонимнарга (матди мәдәниятнең аерым предметлары атамалары, исемнәре) кертеп карарга мөмкин. Әлеге аспект – поэтик ономастиканы гомумхалык ономастикасыннан аерып торган мөһим үзенчәлекләрнең берсе (Карпенко, 1986: 39).

Поэтик ономастика, гомуми ономастика кебек үк, төрле гуманитар фәннәр кисешендә барлыкка килә. Әдәби текстларда урын алган поэтонимнарны анализлаган вакытта тел белеме, әдәбият белеме, социология, тарих, психология һ.б. фәннәргә караган методлар кулланыла. Мондый «катламлылык» поэтик ономастиканың үзенчәлеге белән аңлатыла. Ономастик эзләнүләрнең катлаулы һәм комплекслы булуы «билгеле бер ялгызлык исемнәренең аерым, изоляциядә карауны кабул итмичә, аларны өйрәнүдә төп шарт итеп күптөрле лингвистик һәм экстралингвистик бәйләнешләрне, факторларны күздә тотуны таләп итә» (Суперанская, 2007: 14). Әлеге таләп матур әдәбиятта кулланылган поэтонимнарга да тулысынча кагыла.

Поэтик ономастиканың тел гыйлеме һәм әдәбият белеме белән бәйләнеше аеруча көчле. Озак вакытлар дәвамында поэтонимнарны өйрәнү гамәли планда әдәбият белемендә алып барыла. «Әдәби әсәрнең ономастикасы авторның дөньяга карашы һәм шәхси күзаллавын анализлаудан башлана» дигән фикер дә әйтелә, ягъни башта әдәбият белгече тикшеренүләр алып бара, аннан соң гына тел белгече эшкә керешә (Полякова, 2009: 6). Әдәбият белеменең, әдәбият тарихының теоретик алымнары «поэтонимнар һәм әдәби агымнар», «поэтонимнар һәм әдәби чор», «поэтоним һәм әсәрнең идеясе» кебек темаларны ачарга ярдәм итә. Бу очракта төп игътибар поэтонимнарның иҗтимагый яисә экспрессив якларын ачуга

түгел, ә аларның әсәрнең төп идеясен, конкрет фикерен баетудагы ролен билгеләүгә юнәлтелә. Поэтонимнарны әдәбият белеме ягыннан якын килеп тикшерү поэтонимнарны сайлау һәм куллануга экстралингвистик факторларның (стиль, жанр, сурәтләнә торган чор, әсәрнең идеясе, иҗтимагый закончалыклар) йогынтысын исәпкә алып анализлауны күздә тота. Э.Б. Магазаник фикеренчә, «Әгәр дә Д.И. Фонвизинның “Недоросль” әсәрендә Скотинин Иванов фамилиясен алса, а Правдин Сидоров буларак йөрсә, комедиянең идеясе үзгәрмичә, образларның сәнгатьлелеге кимеп, аларның укучыга экспрессив йогынтысы гына азрак булыр иде. Ә менә А.С. Пушкинның “Барышня-крестьянка” әсәрендә Лиза исемен үзгәртү бөтен әсәрнең мәгънәсен аңлауга зур зыян китерер иде, чөнки бу исемнең бик мөһим әдәби-семантик үзенчәлеге героиняның Н.М. Карамзинның “Бедная Лиза” әсәрендәге героиня белән охшашлыгы нигезендә генә ачыла» (Магазаник, 1974: 7).

Әдәби образ тудыруда поэтонимнар башкарган функцияләрне анализлау объектив рәвештә лингвистика һәм әдәбият белеме методларының үрелеп баруын күздә тота. Поэтонимнарны лингвистик яктан тикшерү поэтонимнарның әдәби текст структурасы белән үзара тыгыз бәйләнеш проблемасын алгы планга чыгара. Шул ук вакытта, поэтонимнар телдәге һәм сөйләмдәге специфик лексик берәмлекләр буларак та карала. Һәрбер поэтоним әдәби тексттагы сәнгати сөйләмнең тулылыгын формалаштыра торган башка элементлар белән аерылгысыз бәйләнештә була. Алар әдәби текстка очраклы рәвештә генә кертелми, әдәби әсәрнең гомуми архитектоникасы һәм эчтәлеге белән керешеп китә. Поэтонимнарны анализлаган вакытта текст лингвистикасы таләпләрен күздә тоту мәҗбүри.

Хәзерге вакытта поэтик ономастика поэтонимнарны анализлауда гуманитар фәннәр кулланган алымнарның синтезын тәшкил иткән үз алымнарын формалаштыра. Әдәби образ тудыруда поэтонимнарның семантик экспрессиясен, символикасын һәм фонетик тышчасын анализлау семасиология, лексикология, фонетика, сүз ясалышы, стилистика тәҗрибәсенә таянып эшләнә. Бу очракта поэтонимнарның семантик-стилистик функциясе алгы планга чыгарыла. Ялгызлык исемнәр әдәби сөйләм стилистикасының гына түгел, ә поэтика, поэтик сөйләм теориясе һ.б. фәннәрнең өйрәнү объектына әверелә. Поэтик ономастиканың социология белән

бәйләнеше дә бәхәссез. Поэтонимга, потенциаль рәвештә, өстәмә иҗтимагый тасвирламалар салына, аларны теге яки бу әдәби образны ачуда, һичшиксез, истә тоту мәҗбүри. Поэтик ономастика поэтонимнарның барлыкка килү процессын күзәтә, ә бу исә иҗади процессның психологисен өйрәнү мөмкинлеген дә бирә.

Поэтик ономастика берничә мөстәкыйль тармакны үз эченә ала: поэтик антропонимика, поэтик топонимика, поэтик зоонимика, поэтик теонимика, поэтик прагматонимика. Алдагы бүлекчәләрдә аларның үзенчәлекләренә киңрәк тукталырбыз.

Поэтик ономастика терминнары турында сүз алып барганда, һичшиксез, ономастик тирәлек (ономастическое пространство) турында әйтеп үтү зарур.

Ономастик тирәлек дип билгеле бер халык телендә, реаль, гипотетик һәм фантастик объектларны атау өчен кулланылган ялгызлык исемнәренең кушылмасын атыйлар (Супрун, 2012: 4). Әдәби әсәрнең ономастик тирәлеге дип әдәби текст кысаларында кулланылган барлык төр поэтонимнар атала. Мәсәлән: аерым бер әсәрдә кулланылган герой-персонаж исемнәре, вакыйга бара торган урынчылык, аның белән бәйле булган башка географик объект (шәһәр, авыл, елга, чишмә, тау һ.б.) атамалары, ниндидер мифологик зат исемнәре, товар-әйбер, кешенең җитештерү эшчәнлеге белән бәйле ниндидер берләшмә, җәмгыять һ.б. атамалар. Бер яктан, ономастик тирәлек әсәрнең гомуми образлар системасының бер тармагы булып тора, ә икенче яктан, автор иҗатының үзенчәлекләрен, жанр һәм стиль ягыннан аерымлыкларын, әсәр эчтәлегенең сурәтләнә торган чор, әсәрнең иҗат ителү вакыты белән бәйләнешен чагылдыра. Әдәби әсәрнең ономастик тирәлеге язучы кулланган ономастик системаны, әдәби әсәрдәге поэтонимнарның үзара катлаулы бәйләнешләрен, аларның текстта башкарган функцияләрен, язучының индивидуаль стиле, әдәби телнең гомуми закончалыклары яссылыгында тулы күзалларга мөмкинлек бирә. Поэтонимнарның ономастик кырлары эпик әсәрләрдә аеруча киң планда ачыла, чөнки аларда төрледән-төрле поэтонимнарның сөйләмә, энциклопедик характердагы, тел тарихына караган мәгълүматлар киң кулланыла.

Әдәби әсәрнең ономастик тирәлегенә башка онимнар үтеп керә алмый. Шушы үзенчәлек поэтик ономастик тирәлекне

милли ономастика тирәлегеннән принципиаль рәвештә аерып тора. Соңгысы өчен эчтәлеге ягыннан да үзгәрә торган микъдари динамика хас.

Әдәби әсәрләрдә поэтик антропонимнарның күләме башка поэтонимнардан, шул исәптән, топонимнардан да, күпкә артык була. Әлеге күренеш әдәби әсәрләрнең ономастик тирәлегенә хас иң мөһим үзенчәлек булып санала.

Шул рәвешле, поэтик ономастика төрле фәннәр белән катлаулы бәйләнештә тора. Күп кенә гуманитар фәннәрдәге алымнарның синтезын куллану поэтик ономастиканың үзенә индивидуальләшү мөмкинлеге бирә. Озак вакытлар дәвамында кулланма характерда булып, әдәбият белеме һәм стилистика, тел белеме һәм текстология, тарих һәм социология фәннәре арасында йөргән поэтик ономастика бүгенге көндә үзтикшеренү объекты, алымнары, максат һәм бурычлары булган мөстәкыйль фән булып саналырга хаклы.

## § 57. Поэтик антропонимика

Поэтик антропонимика матур әдәбият һәм фольклор әсәрләрендә кеше исемнәренең кулланылыш үзенчәлеген өйрәнә. Әдәби геройга, персонажга исем сайлау әсәрнең жанры һәм сәнгати-эстетик максаты белән тыгыз бәйле. Әдәби антропоним стилистик, иҗтимагый-идеологик, эстетик, психологик функцияләр башкарып, персонажның характеристикасына әверелә.

Ономастикада «поэтик антропоним» төшенчәсе күптөрле аңлатмаларга ия. Кайбер мәкаләләрдә, әдәби антропонимнар дип бары тик исем-характеристикалар гына саналырга мөмкин, дигән фикер үткәрелә (Зинин, 1980: 23), икенчеләрендә исә әдәби антропонимнар рәтенә һәрбер ялгызлык исем, шул исәптән тарихи шәхесләр һәм мифологик геройлар исемнәре дә кертеп карала. Мәсәлән, ялгызлык исемнәренең этимологиясен тирәнтен өйрәнгән В.Н. Михайлов әдәби әсәрләрдә әдип тудырган исемнәр (*Фамусов, Хлестова)* һәм «әзер» исемнәрне (*Александр Андреевич, Лиза, Петрушка*) аерып чыгарырга тәкъдим итә (Михайлов, 1965: 55). Ә матур әдәбият әсәрләрендә тарихи шәхесләрнең исемнәрен куллану үзенчәлекләрен өйрәнеп, галим аларның стилистик һәм экспрессив мөмкинлекләре хакында түбәндәгеләрне билгели: «Тарихи ялгызлык исем, әсәрнең сәнгати формасының бер элементына әверелгәч, еш кына, үзенең потенциаль семантик-экспрессив

мөмкинлекләрен, суггестив сыйфатларын күпкә арттыра» (Михайлов, 1965: 9).

Г.А. Силаева тарихи шәхес исемнәрен дә әдәби антропонимнар рәтендә карарга кирәклеген әйтә (Силаева, 1977: 153). Әлеге төр антропонимнар автор образын, аның дөньяга карашын чагылдырып киләләр, авторның максатларын тормышка ашыруда актив роль уйныйлар һәм билгеле бер стилистик вазифалар да башкаралар, әсәрнең ономастиконын формалаштыруга йогынты ясыйлар.

Күпчелек ономатолог галимнәр (Л.И. Андреева, Г.И. Силаева, В.Н. Михайлов, А.В. Пузырев һ.б.) матур әдәбият әсәрләрендә кулланылган барлык антропонимнарны да поэтик категорияләр буларак тикшерергә тәкъдим итәләр, чөнки әсәрдә урын алган һәр антропоним әсәр структурасына әдип тарафыннан аңлы рәвештә, ниндидер максатларны күздә тотып кертелә. Шуңа да поэтик атропонимнар, герой-персонажларны атап кына калмыйча, хәбәр итү, геройны характерлау, экспрессия кебек категорияләрне дә белдереп килүгә сәләтле булалар.

Әдәби антропонимнарның семантикасы да шагыйранә ономастикада шактый кызыклы, күп игътибар җәлеп иткән мәсьәлә булып санала. Әлеге мәсьәләгә лексик планда якын килгән Л.И. Андреева әдәби антропонимнарга хас төп өч мөнәсәбәт булуын күрсәтә: денотатив, сигнификатив һәм структур (Андреева, 1995: 157). Шушы мөнәсәбәтләрнең комплекслы чагылышы әдәби антропонимнар семантикасының үзенчәлеген билгели.

Поэтик антропонимнарның денотатив мәгънәсе (субъект яки объект белән бәйләнеш) аларның үзенчәлеген билгеләүдә мөһим роль уйный. Әдәби антропонимнарның реаль антропонимнардан аермасы шуннан гыйбарәт: поэтик антропонимнарның денотатларын матди предметлар (яки реаль затлар) түгел, ә әдип хыялы тудырган идеаль (уйланма) предмет һәм затлар тәшкил итә. Икенчедән, әдәби әсәр персонажының бары аңа гына хас үз исеме була (ул исем реаль булмаска да мөмкин), һәм әдәби әсәрдә очраган теге яки бу исемне әйтүгә, укучы аңында шул герой белән бәйләнешле күренешләр чылбыры барлыкка килә. Әдәби антропонимнарның денотатив мәгънәсе үзенең тагы да ачыграк конкретлылыгы белән аерылып тора. Язучы геройларына теләсә нинди түгел, ә аның яшенә, характерына, социаль чыгышына туры килгән исем сайлый. Мәсәлән, бүгенге тормышны, катнаш гаилә вәкилләрен

сурәтләгән әсәрдә *Габделнур, Әбүбәкер, Гыйниятулла, Бибихәдичә, Галиябану, Шәрифә* кебек антропонимнарның бала исемнәре буларак кулланылуы мөмкин түгел. Алар урынына язучылар *Альберт, Артур, Тимур, Азалия, Камилла, София* һ.б.ш. исемнәр сайлаячак. Еш кына әдәбиятта төп герой исеме буларак традицион, укучыга яхшы таныш булган исемнәр кулланыла. Мәсәлән, шундый исемнәрнең берсе – *Ләйлә* (гарәп теленнән – «төн, кич, кара чәчле»). Г. Бәшировның «Гыйбрәт» романында әлеге антропоним укытучы кыз язмышының Шәрык әдәбиятындагы легендар героиня язмышы белән охшаш булуын ассызыклап күрсәтү максатында кулланыла. Нәтиҗәдә романдагы Ләйлә образында ике референтның бербөтен булып кушылуы күзәтелә (Гарипова-Хәсәншина, 2004: 16).

Поэтик антропонимнарның үзенчәлекләре аларның сигнификатив мәгънәсе (төшенчә белән бәйләнеш) белән дә бәйле. Әдәби антропонимнарның сигнификатив мәгънәсе, реаль исемнәр белән чагыштырганда, махсус рәвештә көчәйтелгән була. Укучы аңында туган абстракция әдәби әсәрнең персонажы яисә типиклашкан герой белән бәйләнә. Күпчелек очракта мондый сигнификат реаль тормышның чагылышы булып тора, әмма бу инде – автор күзаллавы аша үткәрелгән чынбарлык. Мәсәлән, Ә. Еники иҗатында кулланылган *Гөләндәм* («Гөләндәм туташ хатирәсе» повесте) исеме. Фарсы теленнән кергән бу исем «гөл кебек зифа; гөл гәүдәле» дигән мәгънәгә ия (Саттаров, 1998: 361). Әсәр күпмедер күләмдә тарихи вакыйгаларны яктыртып, реаль шәхесләрнең истәлекләре нигезендә язылган. Язучы истәлек иясенең (С. Сәйдәшевның сөйгәне) исемен үзгәртүен үзе үк язып үтә. Әмма *Гөләндәм* исеме, прототибының исемен гади алыштыру белән чикләнмичә, инде әдәби әсәр образына әверелгән героиняның аерылмас үзенчәлеге булып китә. Әдип бу образны аерым бер җылылык, нәзакәтлек белән сурәтли. Повестьта хикәяләү Гөләндәмнең үз исеменнән барганга, әсәрдә аның төгәл портретын табып булмый. Шуңа күрә бөтен нечкәлекләре белән яратып, тәфсилләп сурәтләнгән Салихның сөйгән ярын укучы үзе күз алдына китерә. Килеш-килбәте, үзен-үзе тотышыннан нәфислек һәм затлылык бөркелеп торган Салих янында шундый ук гүзәл-нәфис, тыйнак һәм сөйкемле хатын-кыз булырга тиеш. Укучы бу образны гөлдәй зифа буйлы, саф күңелле, бөтен яктан сөйгәненә пар килгән итеп күзаллый.

Әсәрдәге Салихның үзе өчен дә сөйгәне гөлчәчәктәй саф, кадерле һәм нәзакәтле зат булып әверелә. Ягъни әдип саф, эчкерсез хисләрне сурәтләгән повестеның төп героинясына аның эчке дөньясын һәм тышкы матурлыгын тагы да ассызыклаган исем табарга тырышкан. Укучы күңелендә Гөләндәм исеме зур талант иясен үзенә гашыйк иткән, үзендә татар хатын-кызларына хас иң асыл сыйфатларны берләштергән, сылу гәүдәле һәм саф күңелле күркәм хатын-кыз образы буларак саклана (Зиннәтуллина, 2005: 97).

Әдәби антропонимнарның структур мәгънәсе номинацияләүнең характеры белән бәйле, ягъни бу аспект та әдип тарафыннан махсус кулланыла. Реаль антропонимнарның төзелеше башлыча информатив функция генә башкара. Әдәби әсәрдә ялгызлык исемнәренең төзелеше дә нидер аңлата, ул нәрсә беләндер мөнәсәбәттә торырга тиеш. Мәсәлән, М. Әмирнең «Пар күгәрчен» әсәрендә бер үк антропонимның ситуациягә бәйле рәвештә төрле вариантта кулланылуын күзәтергә мөмкин: *Камалетдин Кәлимуллин* (ячейка секретаре вазифасын башкаручы буларак таныштырганда), *Камай* (геройны яшьтәшләре, чордашлары шулай атап йөртә), *Камалетдин балам* (әсәрдәге Фатыйма әби геройга шул рәвешле эндәшә).

Шул рәвешле, әдәби антропонимнарга хас денотатив, сигнификатив, структур мәгънәләрнең чагылыш үзенчәлекләре аларның семантикасын актуальләштерә, еш кына, исем персонажның характеристикасына әверелә.

Әдәби антропонимнар матур әдәбият телендә өч төрле функция башкара: тасвирлау, номинацияләү һәм идеологик функцияләр. Шушы функцияләрнең кайсысы өстенлек итүенә карап, поэтик антропонимнарны түбәндәге өч төркемгә аерып карау кабул ителгән:

1. Исем-характеристикалар.
2. Герой-персонажларны читләтеп характерлаган исемнәр.
3. Нейтраль характерда булган әдәби антропонимнар.

Исем-характеристикалар. Бу төр исемнәрдә әдәби антропонимнарга хас тасвирлау функциясе өстенлек ала. Алар геройны турыдан-туры, ачык итеп сурәтләү мөмкинлегенә ия. Мондый әдәби антропонимнарны рус ономатологлары «говорящие имена» (Магазаник, 1978: 27, Безрукова, 2009: 21) дип тә йөртәләр. Мәсәлән, классик язучыбыз Әмирхан ага Еникинең «Әйтелмәгән васыять» хикәясендәге төп герой исеме *Акъәби* шундыйлардан.

Бу антропонимның очраклы гына кулланылмавы аның тышкы формасыннан, үзенчәлекле компонентлар җыелмасына *(ак + әби)* ия булуыннан ук тоемлана. Татар телендә *ак* сүзе «пакь, саф, керсез; якты, нурлы; күркәм, гүзәл, асыл; гадел, тугры, намуслы, ышанычлы, изге; бәхет, шатлык, сөенеч» һ.б. мәгънәләргә ия (ТТАС, т. 2, 2016: 96). Әдип бу кушма исемне әбинең чын исеме буларак куллана, югыйсә әсәрдән бу образның чын исеме *Акбикә* икәне дә билгеле: «Минем исемем Акбикә… Кыз чагымда мине Аксылу дип йөртәләр иде, кияүгә чыккач, Аккилен булдым, аннары Акҗиңгә, ә хәзер менә Акъәби…» (Еники, 2001: 27). Аңлашылганча, әдип, махсус рәвештә, әлеге образ исеменең беренче компоненты булган *ак* сүзенә басым ясый һәм нәкъ менә шул компонент образга характеристика бирү максатыннан кулланыла. Ягъни бу әби соңгы көннәренә, актык сулышына кадәр исемендә чагылган аклык-сафлыкка тугрылык саклаган. Әлеге фикерне әсәрдәге шагыйрь сүзләре дә исбатлый: «Димәк, син гомерең буена ак кеше булгансың икән. Ак күңелле, пакь күңелле кеше» (Еники, 2001: 28).

Образның төп, беренчел исеме «онытылу» *(Акбикә)* һәм, гомеренең төрле чорларында исеменең икенче компоненты *(Сылу, Килен, Җиңгә)* үзгәрсә дә, беренче компонентының үзгәрмичә саклануы аклык, сафлык, рухи гүзәллек символы булган бу образның Юлкотлы авылының гади карчыгы гына түгел, ә бөтен татар-башкорт халкының изге анасы булуын гомумиләштереп сурәтли.

Аңлашылганча, әлеге әдәби антропоним этимологик (исем нигезендәге күмәклек сүз) мәгънәсе көчле булуы белән аерылып тора. Антропонимның бу үзенчәлекләре аңа әсәрнең идеясе, төзелеше белән бербөтен булып кушылуына сәбәп була. Акъәби образы – рухи сафлыкны югалтмаска, саклап калырга өндәп яшәгән изге зат ул. Бу очракта әдәбиятта типиклаштыру күренеше – антропонимның үзе атап килгән герой-персонаж белән керешеп-берегеп китүе хакында сүз алып барырга мөмкин. Әдип уңышлы сайлаган әлеге тип поэтик исемнәр әсәр кысаларыннан читтә дә геройны ачык күзалларга, характерларга мөмкинлек бирә. Бу очракта ялгызлык исемнәренә хас конкретлык-индивидуальлек үзенчәлеге гомумиләштерү белән янәшә кулланыла башлый.

Герой-персонажларны читләтеп характерлаган исемнәр. Әлеге антропонимнарда идеологик функция, яшерен экспрессия көчле. Исеменнән үк аңлашылганча, бу төр поэтик

антропонимнар геройның ниндидер үзенчәлекләренә, теге яки бу сыйфатларына, социаль чыгышларына һ.б. шундый билгеләргә ишарә ясый, ягъни алар ниндидер яшерен мәгънәгә ия була. Аларның өстәмә, яшерен мәгънәләрен укучы күреп бетермәскә дә мөмкин, әмма бу үзенчәлекләрне тану образны кабул итүдә, авторның геройга булган субъектив мөнәсәбәтен ачыклауда зур ярдәм итә.

М. Әмирнең «Саф күңел» романында кулланылган *Гашия* антропонимын карап үтик. Гашия – романның бик тә үзенчәлекле һәм истә кала торган, катлаулы образларының берсе. Әсәрдә бу исемнең башка персонажлар тарафыннан әлеге образга карата бирелгән субъектив бәясе белән бәйле күп кенә синонимик вариантлары кулланыла. Болардан кала, әсәрдә игътибарга лаек тагын бер бик кызыклы эпизод урын ала, ул да кеше һәм аның исемен субъектив кабул итү белән бәйле. Бу уңайдан Гашиянең тормыш иптәше Хәйрулла сүзләре төп билгеләмәгә әверелә: «Һәй, тискәре! – диде Хәйрулла шунда. – Тискәре булмасаң, синең исемең дә Гашия булмас иде, Гайшә булыр иде. Тискәрегә әйләндерелгән Гайшә бит син!» (Әмир, 1987: 122). Әлеге сүзләр түбәндәгеләр турында сөйли: гарәп теленнән кергән *Гайшә* исеме – «тере, хәрәкәтчән», ә *Гашия* – «кич» дигән мәгънәгә ия (Саттаров, 1998: 64) булган хатын-кыз исемнәре. Хәйрулла өчен *Гашия Гайшә* исеменең бер варианты гына. Икенчедән, әлеге вариантның барлыкка килүен Хәйрулла билгеле бер закончалык белән аңлата. Гашиядә татар хатын-кызларына хас булган сабырлык, тыйнаклык, оялчанлык кебек сыйфатлар юк. Беркемгә дә буйсынмау, кирелек, үткен теле аркасында башкалардан аерылып торуын күрсәтү максатыннан, Хәйрулла аның исемен махсус рәвештә үзгәртеп куллана.

Нейтраль характердагы әдәби антропонимнар. Бу төр исемнәрдә бары номинацияләү функциясе генә өстенлек итә. Алар татарлар арасында кулланыла торган гадәти исемнәрне тәшкил итәләр һәм, геройларның бернинди аерым сыйфатларына ишарә итмәгән хәлдә, әсәрнең ономастика катламын формалаштыру өчен төп нигез булып торалар. Эмоциональлеге һәм экспрессиясе ягыннан аерылып тормасалар да, мондый исемнәр әсәрнең гомуми лингвистик, поэтик структурасын оештыра торган әһәмиятле элементлар буларак карала. Үзеннән-үзе аңлашылганча, алар күбесенчә эпизодик персонажларны атап килиләр.

Әдәби антропонимнарны анализлау аларның әдәби әсәрдә тоткан урынын, тулы канлы әдәби образ тудырудагы ролен, башкарган функцияләренең (номинатив, идеологик, тасвирлама) никадәр зур, мөһим булуын ачык дәлилли. Гомумән алганда, поэтик антропонимия мәсьәләләре катлаулы һәм күпкырлы өйрәнү таләп итәләр. Матур әдәбият әсәрләрендә кулланылган ялгызлык исемнәрен анализлауда бердәм алымнарны эшләү, аларның әдәби текстта башкарган вазифаларының классификациясен булдыру, әдәби персонаж исеме буларак хезмәт иткән исемнең өстәмә мәгънә белдерү үзенчәлекләрен ачып бетерү перспектив юнәлешләр булып кала. Проза әсәрләре белән чагыштырганда, шигъри текстларның антропонимикасы яңа эзләнүләр таләп итә торган өлкә. Татар әдипләре әсәрләрендә тудырылган антропонимик системаларны чагыштырма планда өйрәнү дә көнүзәк мәсьәләләрнең берсе булып тора.

## § 58. Поэтик топонимика

Билгеле булганча, топонимнар ономастик лексиканың төп өлешен тәшкил итәләр. Кешелек җәмгыяте үзен чолгап алган тирәлекнең элементларын аерып атапмыйча, исем бирмичә яши алмый. Кеше өчен әһәмияте булган һәр географик объект индивидуаль исем таләп итә. Шуңа да топонимнарның җәмгыятьтә башкарган төп вазифасы – чиксез киңлектә юнәлеш бирү һәм географик объектларны тәңгәлләштерү.

Матур әдәбият әсәрендә кулланылган географик атамалар – әсәр стиленең мөһим, алыштыргысыз компоненты. Әлеге поэтик категория, әдәби антропонимнар кебек үк, күп функцияле булуы белән характерлана. Аерым алганда, индивидуаль географик объектларны номинацияләү чарасы булудан бигрәк, алар әсәрдә сүз барган вакыйгаларның төгәл локаль ориентациясен булдыру, һәм әсәр геройларының бу урыннарга эмоциональ-эстетик мөнәсәбәтен дә чагылдыру мөмкинлегенә ия.

Поэтик топонимия – әдәби әсәрләрдә кулланылган географик объект атамаларының җыелмасы. Алда әйтелгәнчә, әсәрләрдә кулланылган поэтик топонимнар – әсәрнең лингвистик структурасында мөһим урын алып торган берәмлекләрнең берсе.

Кешеләр яшәгән һәр урынчылыкта топонимнарның күләме бик зур. Географик атамалар турындагы фән тарих, география,

этнография, картография белән тыгыз бәйләнештә үсә, шуңа да топонимиканы өйрәнү халыкның тарихына караган күп кенә фактларны, теге яки бу халыкның таралыш чикләрен, телләрнең баштагы таралыш өлкәләрен, икътисади һәм мәдәни үзәкләрнең географиясен күзалларга мөмкинлек бирә. Матур әдәбият әсәрләрендә кулланылган топонимнарны өйрәнү дә шушы ук яссылыкта алып барыла. Шунлыктан поэтик топонимнарны өйрәнү аларның әдәби әсәрләрдә башкарган функцияләренең күп төрле булуын һәм вакыйга барган урынны күрсәтү белән генә чикләнмәвен раслый.

Әдәби топонимнарны функциональ-стилистик яссылыкта тикшереп язылган хезмәтләр рус һәм төрки, татар тел белемнәрендә шактый. Алар арасында В.А. Никонов, Т.А. Иванова, Л.В. Доровских, Е.М. Поспелов, Б.А. Серебрянников, В.Н. Топоров, А.И. Попов, А.К. Матвеев, Г.Ф. Саттаров, Р.Х. Гаррапова, А.Р. Биктимерова, В.М. Гарипова-Хасаншина, Г.Х. Зиннәтуллина һ.б.ның хезмәтләрен атарга мөмкин. Мәсәлән, М.И. Цветаева, К.Г. Паустовский, А.Т. Твардовский текстларындагы топонимик система М.В. Горбаневский мәкаләләрендә яктыртыла (Фомин, 2004: 109). Поэтик топонимиканың төп сораулары Г.Ф. Ковалев, М.Э. Рут, О.И. Фонякова, В.К. Харченко һәм кайбер башка тикшеренүчеләрнең хезмәтләрендә чагылыш таба (Ковалев, 2004: 4). М. Мәһдиев прозасында кулланылган географик атамалар Р.Х. Гаррапова (Гаррапова, 2000), татар халык җырларында чагылыш тапкан поэтик топонимика А.Р. Биктимерова (Биктимерова, 2003), Г. Бәширов әсәрләрендәге поэтик топонимнар В.М. Гарипова-Хасаншина (Гарипова-Хасаншина, 2004), Ә. Еники иҗатында кулланылган географик объект атамалары һәм аларның стилистик үзенчәлекләре Г.Х. Зиннәтуллина (Зиннатуллина, 2005), Т. Миңнуллин драмаларында кулланылган топонимик берәмлекләр Ф.Ф. Нуруллина (Нуруллина, 2011) хезмәтләрендә өйрәнелә. Әлеге хезмәтләрдә топонимнарны өйрәнү язучы кулланган метод-алымнар, авторның индивидуаль стиль үзенчәлекләре, әсәрнең жанры, текстның тематикасы һәм эстетик максатлары яссылыгында комплекслы планда алып барыла.

Ялгызлык исемнәрне өйрәнү һәм анализлау ниндидер классификацияләрдән башка тормышка ашырыла алмый. Ономастик күренешләр бик киң кырлы булу сәбәпле, аларны берләштерү

дә төрле нигездә алып барыла. Әмма шунысы игътибарга лаек: ономастик материалның бары топонимнар катламы гына иң еш һәм төрле яктан тәңгәлләштерелгән булуы белән аерылып тора. Әлеге бүленешләрдә, барыннан да бигрәк, торак пункт атамалары гына үзәктә булып, төп игътибар топонигез мәсьәләләренә юнәлә, атамаларның барлыкка килүе һәм теге яки бу урынчылыкның тарихы яктыртыла.

1973 елда А.В. Суперанская «Общая теория имени собственного» дигән хезмәтендә барлык ономастик берәмлекләргә дә караган бүленеш типларын тәкъдим итә. Әлеге бүленеш алдагы барлык классификацияләрдән тулылыгы, тирәнлеге белән аерылып тора, чөнки биредә географик атамаларның лингвистик һәм экстралингвистик үзенчәлекләре дә исәпкә алына. Шуңа да әлеге алым топонимнарны, шул исәптән поэтик топонимнарны да, тикшерүдә иң уңышлысы дип исәпләнә. Алда санап үтелгән, татар поэтик топонимикасына караган хезмәтләрдә дә шушы ук бүленеш саклана.

Шунысын да искәртергә кирәк: бер тип исемнәр өчен – бер төрле, икенчеләре өчен исә башка характеристика актуаль булырга мөмкин. Бу характеристикаларның бер өлеше тел белеме белән бәйле, калганнары логик, тарихи, иҗтимагый, поэтик булсалар да, алар барысы да ономастикада чагылыш таба; ләкин шул ук вакытта әлеге аспектлар бер-берсеннән нык аерыла, берсе икенчесенең дәвамы яки аныклавы була алмый.

Ономатолог галимнәр билгеләвенчә, топонимик лексиканың семантикасы, мәгънәви эчтәлеге катлаулырак, баерак. Бу борынгыдан килгән традиция белән аңлатыла: элек-электән урынчылык атамасын нинди дә булса шәхес яки вакыйгага бәйләү тенденциясе яшәп килә. Шул рәвешле, онимның эчке мәгънәсендә лингвистик (сөйләм) һәм экстралингвистик (мөһим мәгълүматны эченә алган мәгънәви компонент) катламнар урын ала. Мәгънәви компонент зуррак әһәмияткә ия, чөнки ул билгеле бер төбәкнең үсеш-үзгәреш тарихын, аның мәдәни-тарихи, географик һ.б. үзенчәлекләрен чагылдыра. Географик атама бай ассоциатив нигезгә ия, тополексемалар сәнгатьлелеге белән аерыла. Шуңа күрә, еш кына, теге яки бу тополексема безнең аңыбызда кайсыдыр чор, тарихта ниндидер эз калдырган шәхес белән ассоциацияләнә.

Шушы яссылыкта матур әдәбият телендә кулланылган топонимнар, үзләренең төп номинатив мәгънәләреннән тыш, өстәмә

мәгънәләр белән баетыла. Алар исә, бер яктан, ассоциатив нигез, икенче яктан, язучының эмоциональ бәяләве, дөньяга карашы белән бәйләнгән була. Мәсәлән, *Себер* топонимы Г. Бәшировның «Җидегән чишмә» романында нейтраль мәгънәдә, билгеле бер урынчылык атамасы буларак кына кулланылса, әдипнең «Туган ягым яшел бишек» әсәрендә исә ачык пейоратив, ягъни тискәре эчтәлекле топонимга әверелә. Эчтәлекне ачу барышында әлеге топонимның экспрессиясе, кире йогынтысы арта һәм ул патша хакимиятенең атрибутына әверелә (Гарипова-Хәсәншина, 2004: 21). Топонимнар төрле авторларның поэтик текстларында башка күп төрле функцияләр дә башкара. Мәсәлән, билгеле бер урынчылыкның кабатланмас колоритын гәүдәләндергән, милли гореф-гадәтләр, ышанулар символы булган *Изге чишмә* атамасы сәнгати югарылыкта сурәтләнә: «*Тау астында **Изге чишмә** ага. Ул чишмәгә милләттәшләрем килеп баш ияләр, дога кылалар... **Изге чишмә** бит ул халык хәтере*» (Т. Миңнуллин. «Кулъяулык»).

Поэтик топонимнарның матур әдәбият әсәрләрендә кулланылышы тарихи яктан билгеләнә. Һәр язучы теге яки бу әсәрендә топонимнарны үзенең иҗади методы, конкрет идея, сәнгати максатларыннан чыгып куллана. Топонимнарның кулланылышы аерым бер чор, әдәби агым, язучының дөньяга карашы, аның иҗтимагый аңына бәйле була. Мәсәлән, поэтик топонимнарның сүз барган объект турында өстәмә, тарихи мәгълүмат бирү максатында кулланылган очраклары еш күзәтелә: «*Безнең авыл башкорт җиренә XVIII гасырның ахырларында гына **Тамбов губернасыннан** күчеп килеп утырган. «**Каргалы**» дигән исемне дә аңа шушы яңа җиргә килеп утыргач кына биргәннәр, югыйсә тегендә, **Тамбов җирендә** чакта, авылның исеме «**Иди**» булган, диләр. Димәк, безнең борынгы, төп җирләр **Россиянең** үзәгендә, тагы да конкретлаштырып әйткәндә, **Темников дигән шәһәр** тирәсендә булган икән – без әнә шуннан чыккан халык*» (Ә. Еники. «Соңгы китап»). Топонимнарның әлеге сыйфаты, тарихи күзлектән караганда, бик мөһим, чөнки географик объектның эчтәлеге һәм тышкы формасы тарихи яктан үзгәреш кичерергә, чорга бәйле рәвештә үзгәртелергә мөмкин: «*Урамнарның да күбесе иске исемнәрен саклыйлар иде әле. Бауман урамы ул чакта **Большая Проломная**, янәшәсендәге Профсоюзная – **Малая Проломная**, Куйбышев урамы – **Рыбнорядская,** Бутлеров урамы **Старо-Горшечная** дип йөртелә иде. Кольцо*

*дигәнебез ул чакта вак кына кибетләр белән шыгрым тулы иде... **Мәскәуский** (хәзерге Киров) урамындагы бакча урынында толчок иде»* (Ә. Еники. «Соңгы китап»).

Шуңа да һәр географик атама артында билгеле бер чор, традиция, милләт язмышы яки тарихи шәхес табыла. Ә шигъри текстларда топонимнар тагы да сәнгатьле, тагы да эчтәлекле була:

***Казан** белән **Идел** язмышына*
*Тәңгәл минем илем язмышы.*
*Ишетелә **Идел** төпләреннән*
*Бурлакларның моңлы тавышы.*
*Шушы елга мәңге берләштергән*
***Татарстан** белән **Болгарны**.*
*Битләремдә җылы җилләр тоям, –*
*Алар килгән кичеп чорларны*
(Г. Рәхим).

Географик атамаларның зур күпчелеге әдәби текстларда номинатив функция башкара, чөнки әсәрдә кулланылган тополексемалар реаль чынбарлык белән бәйләнә, хакыйкый картина тудыра. Географик атамаларны куллану әсәрдә сурәтләнә торган вакыйгаларның эчтәлеге яисә объектларның үзенчәлеге пространствода хәрәкәт итүне конкретлаштыру (кая? кайдан?) белән аңлатыла. Бу төр контекстларда топонимнар үзләренең төп функциясендә чыгыш ясый: географик объектны аеру һәм бу урынчылык белән әсәрдә сурәтләнгән вакыйгаларны бәйли: *«Без килеп урнашкан **Рахманкол авылы** яныннан **Урал-Җаек елгасы** акмый ич, ә **Уфа-су** агып ята. **Уфа** үзе **Агыйделгә** коя. **Свердловск өлкәсенең Красноуфимск шәһәре, Башкортостанның башкаласы Өфе** дә шушы Уфа-су буенда..»* (Р. Сибат. «Сәридә»). *Югыйсә мин инде авылның үзебез тирә урамнарын, **Озын күпер** буйларын, **Аръякларны, Кызыл ярларны, Тугай урамнарын, Югары оч белән Түбән очны, Миркәйләр тыкрыгын, Мәчет тыкрыгын, Мулла елгасы урамын, Коры елганы һәм Бикчабар елгасын, Дуйлар тыкрыгын, Алма бакчасы** дип йөртелгән, әмма хәзер инде анда сыңар миләш тә үсмәгән тирәләрне, **Болын ягының** барлык урамнарын, алай гынамы, **Түбән як белән Югары як** зиратларына хәтле дә япа-ялгыз барып, айкап-айкап кайткалаганым ... булды әлбәттә* (Г. Үзиле. «Ленин, Дәрья Петровна, мин һәм башкалар»).

Әлеге төп функциядән тыш, тексттагы топонимнар тасвирлама мәгънә белән дә баетылырга мөмкин. Бу очракта алар атала торган объектның төрледән-төрле якларын ачыклап, тасвирлап килә. «*Бусы менә **Кечкенә Абзан**... Каралты-куралары, бәрәңге бакчалары болынга таба караган. Болын тип-тигез, чып-чуар чәчәк кенә, **Түреш** үзе күренми дә, аның кай тирәдәнрәк акканын бары яшел талларга яки биек, карт тирәкләргә карап кына чамалап була... Бик күңелле, бик сөйкемле җирдә утыра икән бу **Кечкенә Абзан**»* (Ә. Еники. «Җиз кыңгырау»).

Географик атамалар тирә-якта ориентлашу чарасы буларак кына кулланылып калмыйча, эмоциональ-эстетик бәяләмә белән дә баетылган булырга мөмкин. Мондый мисалларда сурәтләнә торган объектның кабатланмас гүзәллеге дә, авторның аңа карата шәхси мөнәсәбәте дә ачык чагыла. Мәсәлән, түбәндәге мисалда экспрессивлык топоним кулланылган җөмләнең төзелешеннән, андагы сүзләр җыелмасыннан ук тоемлана: «***Кәлтә тавы** авылны өч яклап уратып алган. Читтәнрәк карасаң, чыннан да, зур бер кәлтә авылны җилләрдән ышыкларга тырышып бөгәрләнеп яткан кебек. Тау түгел инде ул үзе, кечкенә генә калкулык. Тик Кавказларны күрмәгән авыл кешесенә – тауларның да тавы. Калкулыкның эчке ягы буйлап инеш ага. Ә Кәлтә тавының нәк уртасында инешкә чишмә кушылып китә. Шул чишмә янына басып башыңны югары күтәрсәң, Кәлтә тавының түбәсен күрәсең*» (Р. Сабыр. «Гәрәшәй түбәсе»).

Моннан тыш, географик атамалар әдәби әсәрләрдә сүз уйнату чарасы буларак та уңышлы кулланылырга мөмкин. Бу очракта топонимның лексик мәгънәсе алгы планга чыгарыла: «*Менә шулай, **Чәчәкле** мәктәбенә яшьлек чәчәген коярга кайткан яшь иптәш... Әлегә рәхәтләнеп укыту белән генә шөгыльләнегез...*» (Җ. Дәрзаман. «Җан авазы»).

Аңлашылганча, топонимнар әсәрдә сүз бара торган географик урынчылыкны тагы да төгәлрәк сурәтләргә, авыл-калаларның үсеш тарихын, аларның табигый-географик һәм мәдәни-тарихи үзенчәлекләрен язучының бу объектка булган шәхси мөнәсәбәте белән тыгыз үреп күрсәтергә сәләтле. Поэтик топонимнарның әдәби әсәрләрдә башкарган төп вазифасы – герой-персонажларның хәрәкәт тирәлеген тудыру, вакыйгалар бара торган урынны географик яктан конкретлаштыру. Әдәби топонимнарның әдәби текст

кысаларындагы икенче вазифасы – сурәтләү чаралары ясауда катнашу, әсәр текстының эмоциональ фонын булдыру.

## § 59. Идеоматика

Идеоматика – поэтик ономастиканың әсәр исемнәрен тикшерү, текстка исем бирү процессының үзенчәлекләрен ачыклау белән шөгыльләнә торган тармагы. Идеонимнар (грек. *idea* – төр, форма, башлангыч + *onym* – исем) – матур әдәбият, сәнгать әсәрләренең исем-атамалары. Н.В. Подольская *идеоним* термины астында денотатлары (ялгызлык исемне йөртүче теләсә нинди объект) акыл эшчәнлеге, идеологик һәм сәнгать өлкәсенә караган исем-атамаларны берләштереп карый (Подольская, 1998: 61).

Әдәби әсәр ономастиконы бер-берсе белән бәйле һәм берсен-берсе билгели торган элементлар системасын тәшкил итә. Әлеге элементларның тулы мәгънәви һәм эстетик әһәмияте поэтик сөйләмне (киң мәгънәдә) форма һәм эчтәлекнең аерылгысыз бердәмлеге итеп караган очракта гына тулы ачыла. Коммуникатив функция белән беррәттән, эстетик функция дә башкарганга күрә, әдәби текстта кулланылган һәр онимның үзенчәлекле яклары була. Бу яктан идеонимнар аерым урын били, чөнки әсәр исеме текстта әдип тудырган чынбарлыкны кабул итү өчен башлангыч этап булып тора. Әдәби әсәрнең исеме авторның дөньяга карашын чагылдырган, әсәрдә тудырылган чынбарлыкның үзенчәлекләрен, сурәтләү алымнарының адекватлык һәм типиклык кебек үзлекләрен билгели торган мөһим тупламга әверелә. Ул текстта сурәтләнгән фактларны гомумиләштереп атый. Әсәрнең «йөзен ачарга», аның укучы күңелендә бу әсәрне башка әсәрләрдән аерырга ярдәм итә торган, укучы аңында онытылмас хатирәләр уятырга сәләтле булган, гомергә исендә кала торган бик әһәмиятле элементы – аның исеме.

Шул ук вакытта, әсәрнең атамасы итеп сайланган сүзнең сыйфатлары әдәби иҗаттан тыш ачыла алмый. Идеоним сәнгати сөйләмгә үзенә хас лексик, грамматик, структур һ.б. телгә караган сыйфатларны алып килә. Әмма әдәби әсәр элементына әверелгәч, ул яңа, моңарчы ачылып җитмәгән сыйфатлар белән баетыла: дистантлы урнашкан берәмлекләр белән семантик бәйләнешләргә керү мөмкинлеге, бер үк вакытта берничә мәгънәгә ия булу, тирәсендәге лексик бәйләнеш һәм синтаксик структурага карап, эмоциональ-бәяләү мәгънәләре кабул итү һ.б. Болар барысы да, по-

этик контекст эчендә, әсәрнең исеме булып килгән сүзгә моңарчы очрамаган күләм өсти, аның мәгълүмати мөмкинлекләрен күпкә арттыра.

Әсәр атамаларының мөһим шәхси, ассоциатив-бәяләү коннотацияләрен сыйдыру мөмкинлеге әдипләрдән әлеге берәмлекләрне сайлау мәсьәләсенә аеруча игътибарлы булуны сорый.

Сәнгать әсәренә исем-атама булып йөрүче берәмлекләр комплекслы өйрәнүне таләп итә. Шуңа да поэтик ономастиканың идеоматика тармагы әсәр исемнәренең текст белән бәйләнешен, әсәрне атау принципларын һәм моңа этәрә торган факторларны, исемнәрдә чагылган традиционлык һәм новаторлыкны, исемнең структур төзелеше, семантик һәм стилистик үзенчәлекләрен өйрәнүне максат итә. Гомумән алганда, тикшеренүчеләрдән әсәр атамаларын тел чарасы буларак та, аларның контекстуаль кулланылыш үзенчәлекләрен тикшерү дә таләп ителә.

Матур әдәбият әсәрләренең атамаларын филологик проблема буларак өйрәнү XX гасырның 30 нчы елларында башланып китә. Әлеге мәсьәләгә беренче булып С.Д. Кржижановский системалы якын килергә омтыла. Аның «Поэтика заглавий» (1931), дип исемләнгән хезмәтендә идеонимнарга лингвистик, поэтик, фәлсәфи һәм семиотик яссылыкта анализ ясала. Галим әсәр исемен китапның иң мөһим өлеше дип күрсәтә. Аның исбатлавынча, идеонимнарда язучының стиль үзенчәлекләре һәм сәнгатьле фикер сөреше чагыла (Кржижановский, 1931: 3).

Дөрестән дә, әсәрнең исеме – аның төп, иң мөһим компоненты. Һәр әсәрнең башы, уртасы, ахыры булган кебек, исеме дә булырга тиеш. Әсәрнең атамасы – авторның укучысы белән барган аралашуында беренче сүз, беренче адым. Әсәрнең исеме укучының күңеленә, йөрәгенә юл ача.

Бүгенге көндә идеонимнар проблемасын лингвистик, лингвостилистик һәм әдәби планда яктырткан фәнни хезмәтләр шактый. Рус тел белемендә әлеге проблема А.В. Суперанская, И.В. Арнольд, И.Р. Гальперин, В.А. Кухаренко, И.В. Фоменко, А. Харченко, Э.Б. Магазаник һ.б.ның хезмәтләрендә чагылыш таба. Татар филологиясендә әлеге мәсьәлә Г.Ф. Саттаров, Ф.С. Сафиуллина, И.Б. Бәширова, Р.Х. Гаррапова, А.Р. Биктимерова, В.М. Гарипова-Хасаншина, Г.Х. Зиннәтуллина, Ф.Ф. Нуруллина һ.б.ның хезмәтләрендә яктыртыла.

Барлык тикшеренүчеләр исбатлаганча, әдәби әсәрләргә бирелгән исем аларның ясалышына да, эмоциональ яңгырашына да игътибарлы булуны, һәр автор иҗатына үзенчәлекле якын килүне таләп итә. Исемнәр сәнгати текст эчтәлеген ачып кына калмыйча, әсәр язмышын хәл итүдә дә зур роль башкаралар. Әлеге мәсьәләләрне төрле яктан якын килеп чагылдырган классификацияләр поэтик ономастика тармагында шактый күп урын ала. Мәсәлән, исем-атамалар структуралары ягыннан бер сүз (*«Намус», «Гыйбрәт», «Шәҗәрә», «Уяну»*), сүзтезмә (*«Мәдрәсә җимеше», «Уйналмаган скрипка», «Төнге бәрелеш», «Саз чәчәге»*), җөмлә белән белдерелгән (*«Без дә солдатлар идек», «Туган ягым – яшел бишек», «Монда тудык, монда үстек», «Сөлге булсын бүләгем», «Кояш көлми дә, елмаймый да»*) исемнәргә берләшә. Ясалыш принцибы искә алынганда, исем-атамалар аппелятив лексикага караган һәм ономастик берәмлеккә нигезләнгән идеонимнарга аерыла. Мәсәлән, *«Гөлҗиһан малайлары», «Зөләйха», «Гөләндәм туташ хәтирәсе», «Ике Апуш», «Айбикә», «Колыма хикәяләре», «Сиваш», «Агыйдел», «Тын океанда көрәш», «Сөләйман солтан»* кебек әсәр атамалары антропоним һәм топонимнар нигезендә барлыкка килә. Ә инде исемнәрнең әсәр эчтәлеге белән бәйләнешен истә тотканда, идеонимнар исем-тема, исем-проблема, исем-идея, исем-метафора, исем-тезис дигән төркемнәргә аерылырга мөмкин. Мәсәлән, Т. Миңнуллинның «*Нигез ташлары*» әсәренең атамасы исем-метафора вазифасын башкара. Әсәрдә йорт, нигез – күпланлы символик образ, чөнки ул кешене туган җире, газиз халкы белән бәйләп тора (Нуруллина, 2011: 13).

Әдәби әсәр исеме – әдипнең күп эзләнүләре, уйлану-чагыштырулары нәтиҗәсендә генә барлыкка килгән иҗат сөзмәсе. Әсәрнең исеме уңышлы сайланганда гына ул укучы күңеленә тирән үтеп керә ала, халык хәтерендә сакланган «визит карточкасына» әверелә (Хусаинова, 2014: 14).

Барлык әдипләр дә әсәргә исем бирү, аны башлап җибәрүне иң катлаулы, четерекле процесс дип билгелиләр. Үз иҗат җимешенә уңышлы исем сайлау әдип алдына бик күп бурыч-максатлар куя, әсәрнең гомуми «бәясенә» бик мөһим өстәлмәләр кертә. «Башлам укучыны сөйләнәчәк вакыйгаларны кабул итү өчен әзерли, аның күңел ишеген ача. Әсәрнең исеме – укучының игътибарын җәлеп итәрдәй мәгънәви, аһәңле, камил, эмоциональ булырга

тиеш, укучыны алда сөйләнәчәк вакыйгалар эченә үзе артыннан калдырмыйча алып кереп китәргә тиеш» (Сафиуллина, 1985: 3). Әсәрнең атамасы буларак сайланган сүз, текст эчтәлеге белән турыдан-туры бәйләнешне саклаган хәлдә, номинатив функциядән тыш, сәнгати-поэтик вазифа башкара башлый. Нәтиҗәдә ул гомумиләштерү, абстракция, символика белән баетыла. Мәсәлән, *«Сарут»* (Г. Бәширов) идеонимының нигезендә яткан сүзнең лексик мәгънәсе – чүп үләне. Хикәядә әлеге сүз төп геройның характеристикасы буларак кулланыла. Җәмгыять өчен Мифтах Шәмгунов нәкъ чүп үләне кебек – аннан бернинди дә файда да юк: «*Әйтерсең, ул бөтенләй кеше дә түгел, әнә юл кырыендагы черек төп! Тибеп түндердең – эшең бетте!*» (Гарипова-Хасаншина, 2004: 12).

Еш кына язучылар идеонимнар итеп кыска, үтемле, бер генә сүздән торган атамалар сайлый: *«Әҗәт», «Танышлык», «Сөяркә», «Үч»* һ.б. Гадәттә, бер сүз белән аталган әсәр исемнәренең зур күпчелеге исем сүз төркеменә карый, чөнки исем, сүз төркеме буларак, киң мәгънәсендә предметлыкны белдереп, көчле абстракцияләүгә сәләтле. Нигезендә исем сүз төркеме яткан идеонимнарда исемгә хас булган идентификацияләү (атау) күренеше төп функциягә әверелә. Башка сүз төркемнәре нигезендә ясалган атамаларда исә предикацияләү өстенлек ала: *«Сыну», «Кызару», «Онытырлык түгел», «Бары тик беренче»* һ.б.

Бер сүз белән аталган әсәр исемнәренә гаять катлаулы функция йөкләнә: иң үтемле һәм кыска рәвештә әсәрнең төп идеясен җиткерү, укучыга тиешле юнәлеш күрсәтү. Мондый идеонимнар үзгә яңгырашка, оригинальлеккә, эмоциональ-экспрессив мәгънәгә ия була. Аеруча тирән фикергә корылган, берничә фәлсәфи катламнан торган «көчле» әсәрләр, гадәттә, нәкъ менә бер генә сүз белән атала. Мәсәлән: А. Островскийның «Гроза», И. Гончаровның «Обрыв», Л. Толстойның «Детство», Э. Золяның «Жерминаль», Г. Бәшировның «Намус», М. Әмирнең «Агыйдел», Ә. Еникинең «Рәшә», Т. Миңнуллинның «Шәҗәрә», Н. Гыйматдинованың «Тамга», Зөлфәт Хәкимнең «Гөнаһ», «Легионер» һ.б. Әсәрне бер сүз белән генә атаганда, язучыдан бу атаманың яңгырашына да, мәгънә сыйдырышлылыгына да, эмоциональлегенә дә игътибар белән килү таләп ителә. Бу чаралар укучының игътибарын әдип күрсәтергә теләгән чынбарлыкка, әйтергә теләгән уй-фикерләренә, төптә яткан хис-тойгыларга юнәлтергә мөмкинлек бирә. Мәсәлән,

татар әдәбиятының классик язучысы Әмирхан ага Еники иҗатын шушы яссылыкта караганда «гади», «гадәти» булып күренгән әсәр исемнәренең акрынлап ачылуы күзәтелә. Сюжет артыннан барып, алар көтелмәгән мәгънә, фикри куәт белән байый: *«Бала», «Бөке», «Ялгызлык», «Шаяру», «Сыбызгы», «Матурлык», «Коръәнхафиз», «Картлар», «Курай», «Тынычлану»* һ.б. Әлеге әсәрләр – әдипнең иң уңышлы, көчле дип бәяләнергә хаклы әсәрләре.

Идеонимнарның авазлар составы, аларның укучы аңында семантик ассоциацияләр тудыру сәләтен куллану нәтиҗәсендә сүзнең мәгънәви чикләре киңәя. Кайвакыт хәтта идеонимның һәм әсәр темасының яңгырашындагы охшашлык өстәмә экспрессия һәм эмоциональлек тудыруга сәбәп була. Әлеге алымны *«Сиваш»* идеонимы (Г. Бәширов) мисалында күзәтергә мөмкин: *Сиваш – Сугыш. Сиваш* топонимы әсәрдә сурәтләнә торган вакыйгалар өчен эмоциональ фон вазифасын башкара. Әдип укучы аңында ассоциацияләр чылбыры формалаштыруга ирешә: Сиваш – берни дә кире кайтармый торган сазлык. Сугыш – тереклекне, кешелек дөньясын юк итүче афәт, сазлык (Гарипова-Хасаншина, 2004: 13).

Татар теле төрле типтагы сүзтезмәләргә гаҗәп бай. Сүзтезмәләр әйбер, күренеш-процессны аерым сүзгә караганда төгәлрәк атый алу сыйфатына ия; ягъни алар теге яки бу сыйфатларны, билге-үзенчәлекләрне тулырак, ачыграк рәвештә күзалларга ярдәм итәләр. Идеонимнар арасында да сүзтезмә белән аталган әсәр исемнәре киң кулланыла. Гадәттә «исем + исем», «сыйфат + исем», «сан + исем», «алмашлык + исем» модельләре еш очрый: *«Пар күгәрчен», «Саф күңел», «Җан көеге»* (М. Әмир), *«Тромбон һәм кыз», «Асылмалы лампа», «Йөзек кашы», «Утызынчы ел», «Сипкелле малай»* (Ф. Хөсни), *«Китек ай», «Җан сурәте», «Төнге кош», «Хак чишмәсе», «Тәкъдиргә юл»* (Г. Гыйльманов), *«Урланган ай», «Ут һәм су», «Таш китап», «Тау ягы повесте», «Аязучан болытлы һава», «Аргы як»* (Ә. Баянов), *«Җан авазы»* (Җ. Дәрзаман), *«Бүре каны», «Бер тамчы ярату», «Тамга», «Пәри утарында», «Ак торна каргышы», «Парлы ялгыз»* (Н. Гыйматдинова), *«Кырык сырт»* (Ф. Бәйрәмова), *«Өч аяклы ат», «Татар солдаты»* (А. Хәлим), *«Убырлар уянган чак», «Бердәнбер һәм кабатланмас»* (М. Кәбиров) һ.б.

Нигезендә җөмлә яткан идеонимнар әсәрнең төп идеясен туплап, җыйнап, нәтиҗә ясау рәвешендә бирергә сәләтле. Еш кына

әлеге төр идеонимнар әсәр эчтәлеген аңлауда психологик ачкыч ролен башкара. Әсәр исемнәре объектның әйләнә-тирә һәм вакыт белән турыдан-туры бәйләнеше булуын таләп итми, шуңа да идеонимнар буларак мәкаль-әйтемнәр *(«Ай булмаса, йолдыз бар»),* императив формалар *(«Дачалар мөбарәк булсын!», «Сөлге булсын бүләгем!», «Юлчы! Спартага хәбәр ит...»)* еш кулланыла. Башка төр атамалар белән чагыштырганда, нигезендә җөмлә яткан идеонимнар сан ягыннан азчылыкны тәшкил итә: *«Без китәбез, сез каласыз», «Ай булмаса, йолдыз бар», «Монда тудык, монда үстек»* (Т. Миңнуллин), *«Кем гаепле?», «Берәү килә, берәү китә»* (Ф. Хөсни), *«Туган ягым – яшел бишек», «Бибек нигә елый», «И язмыш, язмыш...»* (Г. Бәширов), «*Без дә солдатлар идек*», «*Мәчет җылый*», «*Кем җырлады?*» (Ә. Еники), *«Без – кырык беренче ел балалары»* (М. Мәһдиев), *«Кенәри – читлек кошы» (Р. Мөхәммәдиев), «Итил суы ака торур»* (Н. Фәттах), *«Мәхәббәттә гөнаһ бар»* (Н. Гыйматдинова), *«Яшьлегемне эзлим», «Тавыш – табигать бүләге»* (Ә. Баянов) һ.б.

Нигезендә җөмлә яткан идеонимнар арасында үзенчәлекле яңгырашка ия булган, абстракциягә корылган «*Итил суы ака торур*» романы аерым урын били. Нурихан Фәттахның әлеге әсәрендә Идел-Чулман болгарлары дәүләтнең оешуы, төрле ыру-кабиләләрне берләштерү тарихы тасвирлана. Роман исеме – борынгы җырның беренче юлы. Шуннан чыгып, исеменең мәгънәсе – Идел ярларына сыеша алмый, иреккә омтыла. Иреккә чыга, җәелә һәм шулай итеп тереклек өчен уңайлы шартлар тудыра.

Әмирхан Еникинең сугыш темасын психологизм алымнары ярдәмендә үзенчәлекле ачып биргән әсәре «*Кем җырлады*?» дип исемләнгән. Әсәрнең исеме сорау җөмлә белән белдерелгән һәм ул күпкырлы семантик мөмкинлекләрне үз эченә ала. Беренче карашка әсәрнең үзәгендә яшь лейтенантның аяныч үлеме, гомеренең соңгы минутларында сөйгәненең җырын, моңын ишетү вакыйгасы ята кебек. Башта егетне сөйгәненең тавышын ишетү бик гаҗәпләндерсә, соңыннан исә бөтенесе дә онытыла, үзәктә җыр гына торып кала. «*Искиткеч таныш, якын тавышны ишетеп, беренче тирән тетрәнүдән соң егетнең рухи хәлендә гаҗәеп бер үзгәреш туды: ул җырлаучының кем булуы белән кызыксынмас булды. Күрәсең, аның сүнеп бетмәгән аңы могҗиза булуына – Таһирәнең кул сузымы гына җирдә җырлап торуына ышана алмады. Хәер, кем*

*җырласа да барыбер түгелмени, тик җыр булсын, җыр туктамасын. Татар җыры, Таһирә җыры, туган ил җыры…Аһ, монардан да кадерлерәк һәм ләззәтлерәк нәрсә булырга мөмкинме соң?!»*. Әсәрдә җыр – туган ил, туган җир символы. Автор фикеренчә, аннан да кадерлерәк нәрсә булырга мөмкин түгел. Чөнки туган ил төшенчәсе туып-үскән йортыңны, газиз кешеләреңне, өзелеп сөйгән ярыңны да үз эчендә берләштерә. Ә Таһирәнең җырлары бер-бер артлы җанга якын шул төшенчәләрне хәтердә яңартырга ярдәм итә. Һәм бу тойгылар яссылыгында егетнең үлем газаплары, бөтен сыкрану-сызланулары онытыла. Хикәядә туган ил, туган туфрак хисе барлык нәрсәләрдән дә өстен, кыйммәтрәк булуы турындагы фикер үткәрелә. Әсәрнең исеменә үк туган илнең символы булган җыр образын чыгару бу хиснең олылыгын, бөеклеген ассызыклау максатында кулланылган.

Гомумән алганда, әдәби әсәр исемнәре поэтик ономастиканың шактый катлаулы һәм ныклы өйрәнүне таләп итә торган өлкәләреннән берсе. Әсәрне формалаштыра, бербөтен система итеп күзалларга ярдәм итә торган идеонимнар өстәмә тикшеренүләр, эзләнүләр таләп итә. Тикшеренүчеләр алдында әсәр исемнәренең структур төзелешен, семантик табигатен, текст белән бәйләнеш дәрәҗәсен, исем кушу принципларын һәм моңа тәэсир итүче факторларны, идеонимда чагылган новаторлык һәм традиционлык, авторның иҗади үзенчәлекләрен чагылдырудагы ролен билгеләү төп максат булып тора.

## § 60. Поэтик ономастиканың башка тармаклары

Алда билгеләп үтелгәнчә, поэтик ономастика матур әдәбият әсәрләрендә кулланылган барлык төр ялгызлык исемнәрне, аларның барлыкка килү принципларын, стилистик һәм идеологик функцияләрен өйрәнә. Шуңа күрә, поэтик антропоним һәм топонимнар гына түгел, ә әдәби әсәрдә кулланылган башка төр ялгызлык исемнәр дә поэтик ономастика игътибарыннан читтә калмый. Бәхәссез, поэтик ономастиканың поэтик антропонимика, поэтик топонимика тармаклары күбрәк, киңрәк планда өйрәнелгән. Болардан кала әдәби әсәр тукымасында башка төр ялгызлык исемнәрне дә очратырга мөмкин. Алар әдәби текстта автор тудырган тирә-як образының, эстетик һәм мәгълүмати яктан, объектив тамгалары

булып торалар. Әлеге поэтонимнар әсәрдә стилистик вазифа башкарып, текстныербөтен итеп оештыручы берәмлекләр булып хезмәт итәләр. Бу берәмлекләр әдәби текстны композицион яктан оештыралар, аның бөтенлеген, тулылыгын, өлешләре арасындагы үзара бәйләнешне тәэмин итәләр. Әлеге поэтик катлам эчендә зоонимнар, теонимнар һәм прагматонимнар аерым урын били.

Поэтик зоонимика – матур әдәбият әсәрләрендә зоонимнарның (кош-корт, хайван кушаматлары) бирелү сәбәпләрен, поэтик максатларда кулланылыш мөмкинлекләрен тикшерә. Поэтик зооним дип әдәби текст кысаларында кулланылган йорт яисә кыргый хайван, кош-корт кушаматларын атап йөртәләр. Әлеге төр поэтонимнарны анализлау барышында кош-корт, хайван кушаматларына исем бирү принциплары, әлеге атамаларның килеп чыгышы, үзгәреше, географик таралыш үзенчәлекләре, теге яки бу зоонимик системаның төзелеше һәм үсеше әдәби әсәрнең төп идеясен, конкрет фикерен баетуда билгеле бер роль уйнавы ачыклана.

Алда әйтелгәнчә, теге яки бу ономастик система билгеле бер халыкның милли үзенчәлекләрен һәм мәдәниятен билгели торган мөһим күрсәткеч булып тора.

Зоонимнар – кеше тормышының, аның дөньяны танып белү процессының аерылгысыз өлеше. Авыл хуҗалыгында, көндәлек тормышта элек-электән йорт хайваннары кешенең аерылгысыз юлдашы һәм ярдәмчесе булып торган. Матур әдәбият әсәрләрендә хайван, кош-кортларның шәхси кушаматлары кулланылу – әдипләрнең кешелек дөньясының хайваннар дөньясы белән турыдан-туры бәйләнешен тану факты ул (Елистратова, 2015: 119). Халыкның дөньяга карашы, менталитеты ул тудырган зоонимнар системасында да ачык чагыла. Мәсәлән, татар җирлегендә, татар әдипләре әсәрләрендә тудырылган поэтик зоонимнарны тикшерү билгеле бер закончалыкны күзәтергә мөмкинлек бирә. Татар халкы хайваннарга исем-атама сайлаганда апеллятив лексикага өстенлек бирә. Ә рус зоонимнары арасында кеше исемнәре нигезендә барлыкка килгән кушаматлар ешрак кулланыла: *Васька* (песи), *Иванчик* (ат), *Манюнечка* (песи), *Иван Иваныч* (каз), *Федор Тимофеич* (песи) һ.б. (Барджакова, 2013: 282). Татар зоонимнары кушамат хуҗасының тышкы кыяфәтен яисә характер үзенчәлекләрен чагылдырып килә. Мәсәлән, хайваннарның тышкы үзенчәлекләрен чагылдырган, аерым сыйфатларын ассызыклап күрсәткән

кушаматлар: эт кушаматлары – *Акбай* (Г. Тукай, Ф. Шәфигуллин, Т. Миңнуллин), *Караборын* (Һ. Такташ), *Актырнак* (Ф. Хөснинең «Утызынчы ел» һәм «Йөзек кашы» повестьлары, Р. Гыйззәтуллин, Т. Миңнуллин), *Дүрткүз* (А. Алиш, Т. Миңнуллин), *Актүш* (Л. Ихсанова, Р. Гыйззәтуллин, Т. Миңнуллин), *Сарбай* (Ш. Маннапов, Т. Миңнуллин), *Муйнак* (Т. Миңнуллин); ат кушаматлары – *Бурлы бия* (кара бурлы), *Күк бия*, *Кола айгыр*, *Алмачуар* (Г. Ибраһимов), *Тимеркүк бия* (Ш. Әхмәдиев); умарта корты кушаматы – *Нечкәбил*; сыерчык баласы – *Озын томшык* (А. Хәсәнов) һ.б.

Балалар өчен язылган әсәрләрдә әдипләр хайваннарны аеруча җылылык белән, кушаматның бирелү сәбәпләрен тәфсилләп сурәтли: *«Үзе чем-кара, ялтыравыклы йонлы, ап-ак муенлы. Алгы тәпиләре аның ак перчатка кигән кебек ап-аклар. Ә күзләре соп-сорылар. Ике кашы өстендә бармак башы кадәрле генә соры йон таплары бар. Алар нәкъ күз урыны кебек булып торалар. Шуңа күрә без эт баласын* ***Дүрткүз*** *дип атадык»* (А. Алиш). *«Бик матур көчек иде ул. Ап-ак түше кара костюм эченнән күренеп торган ак күлмәккә охшый иде. Малай аңа* ***Актүш*** *дип эндәште»* (Л. Ихсанова). *«Сары йомгак сыман бу маэмайны каяндыр Кадыйр абый алып кайтты. Сары булганы өчен, Аңа* ***Сарбай*** *дип исем куштык»* (Ш. Маннапов).

Кушаматны йөрткән хайванның характер үзенчәлекләрен күрсәткән зоонимнар. Әлеге яссылыкта караганда Т. Миңнуллинның авыл эте *Акбайга* багышланган әсәрләре аерым урын били. Әлеге әсәрләрнең геройлары – йорт хайваннары (этләр, песиләр һ.б.), аларда кешеләргә хас булган бөтен сыйфатлар чагыла. Әдип бик уңышлы алым куллана: образларның характер сыйфатларын аларның кушаматларында ук ачып бирә: *Тәмлетамак* – тәмле ашарга яратучы, иркә, хәйләкәр песи. Төп герой Акбайның җан дошманы булган әлеге песи үзен болайрак сурәтли: «*...Нәселем шул, нәсәбем шул, иң яраткан кәсебем шул – хәйләләми, алдаламый торалмыйм*». Шушы ук әсәрдә усаллыклары аркасында бүреләргә әйләнә башлаган *Хәйләкәр, Усал, Гайрәтле, Әшәке* кушаматлы этләр дә бар.

Башка әдипләр иҗатында да характер сыйфатлары кушаматларында чагылган зоонимнар кулланыла: *Чукмар* – чукырга бик оста һәм *Тукмар* – бик оста тукый торган әтәчләр (А. Алиш); *Звонок* (М. Әмирнең «Саф күңел» романы) – нечкә, әмма көчле тавыш

белән өрә торган эт; *Кылыч* (Ә. Еникинең «Уяну» повесте) – ялтыравык («кылыч кебек ялтырый») йонлы, хәрәкәтчән үгез; *Зирәк* («Уяну») – аеруча акыллы, көтү башындагы сыер; *Баяр* («Уяну») – горур, «бояр кебек», зур гәүдәле нәсел үгезе. Ә. Еникинең колхоз, авыл тормышын яктырткан «Уяну» повестендә күп кенә сыер кушаматлары кулланылган. Аларның күпчелеге үсемлекләр дөньясы белән бәйле апеллятив лексикага барып тоташа: *Алма, Хөрмә, Роза, Алчәчәк, Балан.* Билгеле булганча, татар ономастиконында чәчәк, гөл, җимешне белдерүче сүзләр – матурлык, нәфислек символы. Әлеге кушаматларны фермада эшләгән хатын-кызлар терлекләрнең тышкы үзенчәлекләрен ассызыклау максатында сайлаган. Ә бу, үз чиратында, әдипнең әлеге ханымнарның терлекләргә аеруча җылы мөнәсәбәтен, назлап эндәшүен, аларның үзләренә йөкләтелгән бурычларын яратып башкаруын чагылдырырга омтылуының күрсәткече булып тора.

Поэтик зоонимнарның әдәби әсәрләрдә трансонимизация ярдәмендә барлыкка килгәннәре дә кызыклы нәтиҗәләр чыгарырга мөмкинлек бирә. Поэтик зоонимнарның зур күпчелеген кеше исемнәре нигезендә барлыкка килгән кушаматлар алып тора (Барджакова, 2013: 283). Әдәби әсәрләрдә трансонимизация күренеше нигезендә барлыкка килгән зоонимнар өч төрле юл белән ясала: 1. Кешенең шәхси исеме, фамилиясе нигезендә. 2. Мифик затлар исеме нигезендә. 3. Башка әдәби әсәрләрдәге геройлар исеме нигезендә. Бу очракта ялгызлык исемнәренең ономастиканың бер катламыннан икенчесенә күчеше күзәтелә. Ләкин татар әдәби әсәрләрен анализлау күрсәткәнчә, татар җирлегендә мондый төр поэтик зоонимнар гаять сирәк кулланыла. Мәсәлән, Ә. Еники иҗатында кеше исеме нигезендә барлыкка килгән бер генә кушамат очрый – *Сөембикә* («Уяну» повесте). Тарихның төрле этаплары һәм вакыйгалары кешеләр хәтеренә аерым шәхесләр һәм аларның үзенчәлекләре аркылы сеңеп кала. Әлеге күренекле затларның исемнәре аларның характер сыйфатлары, кылган гамәлләре, ниндидер башка үзенчәлекләре турындагы мәгълүматлар белән баетыла. Аңлашылганча, *Сөембикә* кушаматы Казан ханлыгының соңгы патшабикәсе исеме нигезендә барлыкка килгән. Әлеге кушамат терлекнең башка хайваннардан тышкы кыяфәте белән генә түгел, үз-үзен тотышы, зиһене, салмаклыгы белән аерылып торуы аркасында сайланган.

Т. Миңнуллинның балалар өчен язылган «Авыл эте Акбай» пьесасында трансонимизация нигезендә барлыкка килгән ике кушамат кулланыла – *Чарли* һәм *Денди*. Алар – шәһәр этләре пудель һәм дог. Әлеге образлар, купшылыклары, хуҗалары тарафыннан кадерләнеп-иркәләнеп яшәгәнгә күрә, авыл эте Акбайга капма-каршы куеп сурәтләнә. Әлеге образлар каршылыгы әсәрнең онимнар системасында да чагылыш таба – татар җирлегендә актив кулланылышка ия, традицион кушаматлы авыл этләре *Акбай, Сарбай, Муйнак*ларга инглиз чыгышлы *Чарли* һәм *Денди*лар каршы куела.

Кешеләрнең көндәлек тормышындагы кебек үк, әсәрләрдә дә зоонимнарның иркәләү-кечерәйтү формалары кулланыла. Зооморф геройларга кеше исемнәре белән омонимик мөнәсәбәттә торучы иркәләүле кушаматлар бирелә: *Тимеркәй, Розочка* (Ә. Еники). Әлеге зоонимнар геройның характерын тасвирламыйча, бары тик хуҗасының әлеге йорт хайванына булган җылы мөнәсәбәтен генә чагылдыра.

Башка әдәби әсәрләрдәге геройлар исеме нигезендә барлыкка килгән кушаматларны анализлаганда хайван кушаматының аның характер сыйфатлары, ниндидер аерымлыклары белән бәйләнеше интерпретацияләнә. Күренгәнчә, әдәби әсәрләрдә кулланылган зоонимнар поэтоним ролен башкаралар – хайван, кош-кортларның характер сыйфатларын яисә хуҗаларының аларга булган мөнәсәбәтен чагылдырып, ачыклап киләләр.

Поэтик ономастиканың тагын бер тармагы – поэтик теонимика. Поэтик теонимика – мифологик зат, илаһи көч, Алла исемнәренең әсәр поэтикасын тудырудагы ролен өйрәнә. Аңлашылганча, әгәр дә әдәби әсәрнең сюжеты, тематикасы мифология, дин белән бәйле булмаса, теонимнар әсәрдә сюжеттан тыш кына кулланыла. Алар поэтик алымнарда, төрле стилистик фигуралар тудыруда гына катнашалар. Шуңа карамастан, дини-мифологик характердагы исемнәр әсәрнең бик тә үзенчәлекле катламын тәшкил итә. Текст кысаларында алар әсәрдә хәрәкәт итүче геройларны характерлый, теге яисә бу фикерне оригиналь формада җиткерә, сурәтләнгән геройның тормыш позициясен, халыкның дөньяга карашын укучыга образлы һәм үтемле рәвештә тәкъдим итә, логик чагыштырулар эчендә кулланыла. Аерым алганда, матур әдәбият әсәрләрендә дини-мифологик исемнәрне куллануның түбәндәге очраклары еш очрый:

1) образлылык, әсәрнең эмоциональлеген арттыру: «*Икенче көнне без, **Хөзер Ильясны** көткәндәй, аны (докторны) көтеп алдык*» (Ә. Еники. «Соңгы китап»). «*Моңарчы мин аны, таңда **Хозыр Ильястай** пәйда булган теге гөнаһсыз зат кебек, Алла белән сөйләшкәндәй, бары үзалдыма гына пышылдый идем*» (Н. Гамбәр. «Ма-ту-у-у»). *Карты да гади картка охшамаган анысы. Кем белә... Аны кешеләрнең җан-аһларын ишетеп килеп чыккан **Хозыр Ильяс** түгелдер, дип кем әйтә ала?Ахырзаман пәйгамбәредер ул, бәлки?»* (Г. Гыйльманов. «Албастылар»). *Хозыр Ильяс* – татар әдәбиятында (Ә. Еники, Г. Бәширов, Т. Миңнуллин, Г. Гыйльманов һ.б.ның әсәрләрендә) еш кулланыла торган мифологик образларның берсе. *Ильяс* – Ибраһим пәйгамбәрдән соң яшәгән изге шәхес. Аның шәҗәрәсе Нух пәйгамбәрнең улы Самга барып тоташа. Ләкин ислам динендә ул үзе дә пәйгамбәргә тиңләнә, шуңа да аның исеме янәшәсендә *Хозыр* («пәйгамбәр, нәби») компоненты кулланыла. Аллаһы Тәгалә Хозырга могҗизалар тудыру сәләтен насыйп итә. Мәсәлән, чүлдә ул кайда гына утырса да, яшел чирәм үсеп чыга торган була. Коръән аятьләрендә (18: 60–82) аның Муса пәйгамбәр белән очрашуы әйтелә. Аллаһы Тәгалә аның җанына кеше кыяфәтенә кереп, әле дә чиста күңелле кешеләргә ярдәмгә килергә мөмкинлек биргән (Али-заде, 2007: 311). Китерелгән беренче мисалда да авыру кешенең туганнары табибны зур өметләр баглап, көтеп алалар. Чарасыз калган авыл кешеләре өчен доктор – соңгы, бердәнбер ышаныч, шуңа күрә аның килүе изге, ярдәм итәргә сәләтле зат Хозыр Ильяс белән тиңләнә. Икенче мисалда исә Хозыр Ильясның көтмәгәндә, һич уйламаганда килеп чыга торган сыйфаты чагыштыру кысаларында кулланыла.

«*Безнең белән бит ул юньләп яши алмыйча да калды – без, **Сак белән Сок** шикелле, ничә тапкыр икебез ике якка киттек тә югалдык*» (Ә. Еники. «Соңгы китап»). *Сак белән Сок* – татар халкына яхшы таныш булган, матур әдәбият әсәрләрендә дә бик актив кулланылган, еш интерпретацияләнгән образлар. Сак һәм Сок – әниләренең рәнҗешен, каргышын алып, мифик кошлар кыяфәтенә кергән ике бертуган, игезәк малайлар. Шул рәнҗеш аркасында алар бу дөньяда мәңге күрешә, очраша алмауга дучар ителә. Китерелгән әдәби мисалда әдип тормыш мәшәкатьләре аркасында төрле якка китеп, төрлечә яшәгән, туганнары, якыннары, әниләре белән дә бик сирәк очрашу сәбәпле газапланып яшәгән

бертуган агай-эненең эчке халәтен мифик образлар ярдәмендә тасвир итә. Тормышта да кешеләр Сак белән Сок кебек көрешә алмыйча яши.

«*Зөфәр, кемнәндер ишеткән* ***Сөләйман патша*** *сүзләрен исенә төшерде: «Һавада кош эзе, ташта елан эзе, хатыннарда ирләр эзе калмый», – имеш. Хатын-кызның йөрәген күрә белмәгән кеше өчен бу бик хикмәтле сүзләр иде*» (Ә. Еники. «Рәшә»). *Сөләйман* – ислам динендә билгеле шәхесләрнең берсе, Даут пәйгамбәрнең улы. Библиядә ул яһүдиләрнең Соломон патшасы буларак сурәтләнә. Әтисеннән ул бик күп гыйлемгә өйрәнә һәм аңа Аллаһ пәйгамбәрлек дәрәҗәсен дә насыйп итә. Ул барлык тере җан ияләренең телен аңлый, алар өстеннән дә хакимлек итә, өстәвенә, җеннәр дә аңа буйсына торган була. Әтисенең үлеменнән соң Сөләйман яһүдләрнең патшасы булып тора. Бөтен кешелек дөньясына Сөләйман патша гаять зирәк, хикмәтле һәм гадел хаким буларак билгеле. Ә. Еники повестендагы тәкәббер, таш йөрәкле, байлыктан кала бернинди кыйммәтләрне танымаучы Зөфәр өчен дә Сөләйман патша сүзләре хикмәтле хаклык буларак кабул ителә.

***«Фәрештә****! Күңеленнән генә шулай кабатлады ул. Үзен айнырга, уянырга, уйланырга мәҗбүр иткән гүзәл затка ул шулкадәр рәхмәтле, мәхәббәтле, ул аның алдына егылып гомер буе табынырга да әзер иде кебек. .... Ул дулкын бөтен тәнеңне ялмап ала да күзәнәкләреңә канат куя, аларны бәхет күгендә тибрәнергә мәҗбүр итә, үзеңне күз йомган арада миллионлаган кисәкләргә таралып кабат җыелгандай сизәсең. Яңадан тугандай буласың. Һәрбер күзәнәгеңнән сафлык, матурлык, наз сирпелеп тора. Рөстәм дә шундый халәттә иде.* ***Фәрештәгә*** *якынайган саен ул үзенең гайрәтләнә баруын, көч-кәренең кабат кайтуын тойды, әйтерсең, ул адымнан-адымга, мизгелдән-мизгелгә яңара иде»* (М. Кәбиров. «Фәрештә»). Фәрештәләр – Алла белән кешеләр арасында арадашлык итүчеләр. Алар кешегә күренмиләр, Аллага якын урында гына яшиләр. Ислам дине Алланың бик күп фәрештәләре бар дип исәпли. Исламда һәр кешене ике фәрештә саклый, алар – изгелек фәрештәсе һәм явызлык фәрештәсе – кешенең изге эшләрен дә, гөнаһларын да даими теркәп баралар, диелә (Ислам. Белешмә сүзлек, 1993: 145). Фәрештәләр – гөнаһсыз, самими, илаһи затлар. М. Кәбиров әсәренең төп герое Рөстәм дә тормыш төпкелләреннән бары сөйгәне ярдәмендә генә чыга ала. Илаһи көч,

сафлык символына әверелгән фәрештә кыз образы егетнең дөньяга карашы үзгәрү, үзендә яшәү көче таба алуга сәбәпче була;

2) сөйләмгә милли колорит өстәү, халкыбызның этнографик үзенчәлекләрен, дөньяга карашын, менталитетын чагылдыру. Әдәби геройларның үзләре өчен әлеге антропонимнар, мифологик затлар реаль тирәлекнең бер өлеше булып тора. Татар халкының бөек шагыйре Г. Тукай иҗатында мәңгеләштерү алган ***Шүрәле*** образы шундыйлардан: «*Яп-ялангач, нәп-нәзек, ләкин кеше төсле үзе; урта бармак буйлыгы бар маңлаенда мөгезе*». Әлеге мифик зат һәрбер татар кешесенә кечкенәдән таныш. *Шүрәле, Убыр* – татар һәм башкорт әкиятләрендә очрый торган антропоморф характердагы мифик затлар, урман ияләре. Г. Гыйльмановның «Албастылар» әсәрендә алар нәкъ шушы яссылыкта сурәтләнгән: «*Хәлимнең этисе дә бик сәер югалган. Сания авырга калгач, туачак балага бишек ясау өчен, карама ботаклары сайларга кереп киткән җиреннән чыкмаган. Төрлечә юрап карыйлар.* ***Шүрәле, Убыр, Албасты*** *хакында искә төшерәләр*». Т. Миңнуллин иҗатында исә әлеге мифик зат интерпретацияләнеп, чисталык, сафлык, тугрылык кебек сыйфатларны үзендә җыйган зат буларак, яңа формада тәкъдим ителә («Шүрәле-җанкисәгем» пьесасы).

«*Ә баксаң, төшкә кергән дөя ул* ***Газраил*** *имеш!*» (Ә. Еники. «Соңгы китап»). *Газраил* – исламда һәм яһүдиләрдә билгеле булган үлем фәрештәсе. Ул Аллага иң якын дүрт фәрештәнең берсе булып, кешеләргә фани дөнья белән хушлашырга ярдәм итә (Али-заде, 2007: 43). Китерелгән мисалда төрки-татар халкының дини ышанулары, төш юрау элементлары урын ала.

«*Күл асты патшасының бу сылу кызы, шаһзадә Түләкнең үзенә якынлашуын сизгәч, таштан тизрәк суга сикергән, ләкин озын кара чәчләре күпмедер вакыт су өстендә батмыйча торган, менә шул чакта егет тә тиз генә сикереп, кызның батарга өлгермәгән чәчләреннән эләктереп алган да* ***Сусылу*** *артыннан күл төбенә төшеп тә киткән имеш*» (Ә. Еники. «Соңгы китап»). Әлеге мисалда сүз төрки-татар мохитендә бик популяр булган «Түләк һәм Сусылу» дастаны һәм аның төп геройлары турында бара. Әдип укучысына *Аслы күл* турында сөйләгәндә, милли колоритны җиткерү максатында, әлеге күл белән бәйле дастаннан бер өзек китерә. Дастанда сүз башкорт халкының легендар батыры Зәй улы Түләкнең Аслы күл һәм Кандырның хакиме булган су

патшасының кызы Сусылуга булган кайнар мәхәббәте сурәтләнә. Фольклор әсәрләре борын-борыннан тарихның аерылмас юлдашы булып, халыкның бәясез рухи байлыгын тәшкил итә. Шуңа да атаклы дастан әдипләр игътибарыннан читтә кала алмый.

«*Безнең Кибәхуҗа тегүчеләре Сакмар суы буенда* ***Сак белән Сокның*** *үзләрен күреп, тавышларын ишетеп кайтканнар*» (Г. Бәширов). Бу мисалда да төрки-татар мифологиясенең билгеле образлары реаль тирәлек, реаль кешеләр белән бербөтен итеп сурәтләнә: *Сак белән Сок* бар, аларның ачыргаланып кычкыруын ишеткән кешеләр дә бар.

Тәңречелек заманыннан калган ышанулар белән бәйле *Май* образы, аның турындагы мәгълүмат Г. Гыйльмановның «Күрәзә» әсәрендә урын ала. *Май* – Галәм рухы, дөнья иясе. Әсәрдә әлеге образ үзе белән түбәндәгечә «таныштыра»: *«Җир кешеләре мине Тәңре иркәсе, Бәхет кошы, җан өләшүче тереклек иясе дип беләләр...Ә Бәхет кошы хакындагы мифларыгыз белән бөтен җырларыгыз, әкият-дастаннарыгыз тулган... Тик шунысы гына: кешеләр хәзер мине ишетмиләр, ишетсәләр дә – тыңламыйлар..».* Әлеге мисал, ислам дине кабул ителүгә күп гасырлар үтүгә карамастан, халык хәтерендә сакланып калган этнографик үзенчәлекләрнең чагылышы булып тора.

Гомумән алганда, әдәби текстларда кулланылган дини-мифологик исемнәрнең төп вазифасы әсәрнең эмоциональ-экспрессивлыгын арттыру, образлылыкны көчәйтү, халыкның милли күзаллавын чагылдырудан гыйбарәт. Бу төр исемнәр, ассоциатив мөмкинлекләре аркасында, халык мәдәниятенә хас булган фрагментларны чагылдыруга сәләтле. Аларның күпчелеге халык авыз иҗаты, ислам дине белән бәйле персонажлар, шуңа да алар матур әдәбият әсәрләренең, әдипләр иҗатының татар халкының күпгасырлык рухи кыйммәтләре белән бәйләнешен дәлилли.

Әдәби әсәрләрнең ономастик тирәлегендә тагын бер катлам – товар-әйбер, кешенең җитештерү эшчәнлеге белән бәйле ниндидер берләшмә, җәмгыять һ.б. атамалары үзенчәлекле урын алып тора. Әлеге төр атамалар әдәби әсәрнең ономастик тирәлегенә кертелү сәбәпләре, текстта башкарган поэтик вазифалары һәм семантик үзенчәлекләре, барлыкка килү алымнары һәм төзелешләре ягыннан бик тә охшаш. Беренчедән, алар барысы да реклама коммуникацияләре өлкәсенә карый, икенчедән, аларның әсәрдә башкарган

функцияләре, мәгънәви мотивациясе, төзелеш-ясалыш калыплары ягыннан уртак яклары шактый. Аларның бер-берсе белән керешеп китүе, омонимнар булып килүе гадәти күренеш. Мәсәлән, «*Ватаным Татарстан*» – газета атамасын да (товар – прагматоним), кешеләр коллективын да (редакция – эргоним) белдерә. Шуңа күрә бер төркем галимнәр (А. Беспалова, Г. Чармэссон, А. Соломоник, М. Новичихина, И. Крыкова һ.б.) эргоним һәм товар атамаларын берләштереп, аларны гомуми *коммерция атамалары* (коммерческая номинация) термины астында тикшерә.

Поэтик прагматоним һәм эргонимнарның иң югары концентрациясе шәһәр кысаларында бара торган заманча массакүләм әдәбият әсәрләрендә күзәтелә.

Эргоним һәм прагматонимнарның стилистик вазифасы контекст белән бәйләнешкә керү, билгеле бер вакыт аралыгы, ниндидер вакыйга яисә объектның урнашуы хакында мәгълүмат бирү, әсәр геройларын характерлау чарасы буларак кулланылудан гыйбарәт. Әсәрләрдә әлеге функцияне билгеле бер урынчылыкта гына танылу алган прагматонимнар да, прагматоним-глобализмнар да башкарырга сәләтле. Беренчеләре – геройларның социаль яктан түбән статуслы булуын, ә икенчеләре – геройларның шактый югары матди дәрәҗәсе турында сөйли. Мәсәлән, Т. Галиуллинның «Тәүбә» романында төп герой Сәет Сакмановның үзе, аның ышанычлы кешесе – шоферы Замирның иҗтимагый статусы үзгәрү, матди мөмкинлекләре арту машина маркаларының алышынуы барып тоташа: «*Ул аны армиядән кайту уңаена ук үзенә алды, иске “**Москвич**”ка утыртты, читтән торып укырга кертте... Машинаны гел алыштырып тордылар, чит ил “**Кадиллак**”ларында да борын чөеп алдылар. Хәзер дә “**Роллес-Ройс**” маркалысы гаражда хуҗасын көтеп, әзер тора*».

Шул ук әсәрдә геройларның мул тормышы, гамьсез яшәүләре суыткычларының маркалары, саны һәм нәрсә белән тутырылганы аркылы сурәтләнә: «*Әзерлек әгъләдән булып чыкты. Нинди генә нигъмәтләр юк иде “**Әни**” исемле төрек һәм “**Стинол**” атлы суыткычларда. Икесе дә затлы балык, ысланган ит, тел, тавык ите кебек азык-төлек, сулар, исерткечләр белән дыңгычлап тутырылган*».

Поэтик прагматонимнар һәм эргонимнарны әдипләр әдәби текстта сәнгати детализация чарасы, декорация буларак

кулланалар. Мондый атамалар әсәрдә сурәтләнә торган чор үзенчәлекләрен, геройларның һәм авторның шәхси зәвыкларын чагылдырып киләләр. Мәсәлән, әсәрдә вакыйгалар бара торган чорны һәм аның сәнәгатен: *«Индустриализация башланган вакытлар иде бит... Ул вакытта инде фабрикалар белән идарә итәр өчен “Мехкомбинат” дигән нәрсә дә оештырылган иде – мин менә шунда барып кердем»* (Ә. Еники. «Вөждан»). «*Дүртенче курста укыганда “**Урак-Чүкеч**” заводында эшләүче дус егетләреннән берсе, көтмәгәндә-уйламаганда дигәндәй, аңа эш тәкъдим итте*» (Җ. Дәрзаман. «Җан авазы»); әсәрдә сурәтләнгән чордагы кыйммәтләрне: «*Әледән-әле Хоста-Гагры ягына таба экскурсантлар төягән түбәсе ачык машиналар үтеп китәләр, ниндидер үзләренә генә хас тавыш чыгарып чапкан шәп, чибәр “**Зим**”нар, “**Зис**”лар, “**Победа**”лар бер-бер артлы узып кына торалар»* (Ә. Еники. «Йөрәк сере»). *«...Юл аша чыкканда машина астына керә язды. “**Волга**” хуҗасы тәгәрмәчләрен чыйнатып тормоз бирде дә, пипләтеп йодрыгын болгады* (М. Кәбиров. «Фәрештә»).

Прагматоним, эргонимнарның эмоциональ-стилистик вазифасы авторның сурәтләнә торган вакыйгаларга шәхси мөнәсәбәтен, хисләрен белдерергә сәләтле булуында ачыла. Мәсәлән, Ә. Баяновның «Урланган ай» әсәрендә төп героиня Марва өчен «Слава» маркалы сәгать аның үткәне белән бәйле кадерле истәлек булып тора: «*Нәрсәдер эзләп, Марва шкатулка эчен шалтыратты. Кулына иске сәгать эләккәч кенә нәрсә эзләгәне хәтеренә килде. Менә шушы бит – сәгать, “**Слава**” дигән сәгать!... Монысы исән икән... Марва, хәзерге сәгатен тартмага салгач, кулына иске “**Слава**”-сын тагып, ишек төбенә килде...»*.

Поэтик прагматонимнар һәм эргонимнарның комик эффект барлыкка китерү максатында сүз уйнатуда катнашуы кызыклы күренеш: «*Әнә Казанның ислемай фабрикасы зарплатаны “**Огуречный**” лосьон белән түләгән. “**Оргсинтез**” заводы табаклар биргән.. Ә уенчыклар фабрикасы җәйге ялга китүчеләргә отпускной акчаны “**Ванька-Встанька**” дигән курчаклар белән түләргә җыена, ди, тик уйнап утыр!»* (К. Кәримов. «Бака каргышы»). *«Аптырагач, завгар да әнә үзенең “**Жигули**”енә соляркага эшли торган “**Беларусь**” моторы куйды...*» (К. Кәримов. «Бака каргышы»).

Шул рәвешле, прагматонимнар, реклама чарасы буларак кына түгел,  персонажларны, әсәрдә сурәтләнә торган билгеле бер чорның икътисадын, сәясәтен һәм вакыйга бара торган урынны характерлау максатында да, троплар һәм стилистик фигуралар кысаларында сурәтләү чарасы буларак та уңышлы кулланыла.

Йомгак ясап, шуны әйтергә мөмкин: матур әдәбият әсәрләрендә кулланылган һәр ялгызлык исем (антропоним, топоним, идеоним, зооним, теоним, эргоним, прагматоним һ.б.) – әдәби текст кысаларында язучы тудырган чынбарлыкның аерылгысыз өлеше. Әдәби әсәрнең ономастик системасы язучының дөньяга карашын, төп иҗат принципларын чагылдыручы мөһим катлам. Поэтонимнар әдәби текстның лингвистик һәм поэтик төзелешен, язучының шәхси стилен формалаштыруда мөһим чараларның берсе булып хезмәт итә.

## ЙОМГАК

Ономастика – кешелек үсешенең һәм яшәешенең барлык өлкәләрен чагылдырырга сәләтле ялгызлык исемнәрен өйрәнә торган фән. Тормыш-көнкүрештә теге яки бу субъект яки объектны башкалардан аерып атау иҗтыяҗы туганда, ялгызлык исемнәре кулланыла. Бу төр берәмлекләр, күмәклек сүзләреннән аермалы буларак, универсаль кулланылышка ия, алар сүз буларак кына түгел, бәлки милли дөнья картинасын барлыкка китерүдә дә зур роль башкаралар. Шунлыктан ялгызлык исемнәре телнең лексик фондында тел тамгасы, билгесе сыйфатына ия булган үзенчәлекле тел берәмлекләре буларак аерылып торалар. Шулай итеп, ялгызлык исемнәре – тел үсешендә һәм кулланылышында барлыкка килгән гаять әһәмиятле һәм көтелмәгән күренешләрне күрсәтә торган лексик берәмлекләр. Аларны өйрәнү һәм анализлау тел үсеше баскычларын, халыкның тарихи, мәдәни үткәнен, иҗтимагый тормышында барган үзенчәлекләрне ачыкларга һәм киләчәктә телдә барлыкка килергә мөмкин булган яңа күренешләрне билгеләргә ярдәм итә.

*Татар лексикологиясе* хезмәтенең өченче томы ономастика фәне һәм аның тармакларының формалашу тарихын һәм хәзерге халәтен, татар телендә кулланылышта йөргән ялгызлык исемнәренең үзенчәлекләрен өйрәнүгә багышланды. Хезмәттә ялгызлык исемнәрен өйрәнү ономастиканың тармаклары кысасында бирелеп, бу төр берәмлекләрнең барлыкка килү, үсеш-үзгәрешен, кулланылыш үзенчәлекләрен ачыклау тел белеме һәм ономастика фәне казанышларына нигезләнеп башкарылды, шулай ук, ялгызлык исемнәренең үзенчәлекле табигатен истә тотып, та-

рих, әдәбият, лингвокультурология, этнолингвистика, география, астрономия, мифология, социолингвистика һ.б. фәннәр материалына да мөрәҗәгать ителде.

Материалны өйрәнү ономастика фәнендә кабул ителгән калып буенча барды, аерым алганда барлык төр ялгызлык исемнәренең генетик катламнарын, атама бирү мотивларын, төзелеш-ясалыш үзенчәлекләрен тикшерү хезмәтнең үзәгенә алынды. Хәзерге татар телендә орфографиясе һәм рус теленә транслитерацияләү моментлары кыенлык тудырган берәмлекләргә аерым игътибар бирелде.

Монографиядә материалны урнаштыру тәртибе ялгызлык исемнәренең ономастик даирәдә тоткан урыныннан чыгып башкарылды. Иң беренче чиратта, ономастик даирәнең үзәген тәшкил иткән антропонимика һәм топонимика тармаклары өйрәнелде. Әйтергә кирәк, ономастиканың бу тармаклары җентекле тикшерелгән өлкәләрдән санала. Татар теле белемендә әлеге тармакларның аерым аспектларына багышланган шактый күләмдә фәнни монографик хезмәтләр язылган.

Ономастик диарәнең периферриясендә урнашкан эргонимика, этнонимика, космонимика, зоонимика, мифонимика, прагматонимика тармакларын өйрәнү татар теле белемендә чагыштырмача соң башланды. Эргонимика, этнонимика өлкәләрен өйрәнүгә йөз тоткан монографик хезмәтләр соңгы елларда язылса да, тиешле дәрәҗәдә өйрәнелгән дип әйтергә иртәрәк әле. Бүгенге көндә урбанонимика, космонимика, зоонимика, прагматонимика, мифонимика кебек тармакларны җентекле өйрәнү таләп ителә.

Хезмәттә аерым урынны поэтик ономастика алып тора. Тел белеме, стилистика һәм әдәбият белеме фәннәренең чигендә барлыкка килгән әлеге тармак татар теле белемендә XX йөзнең ахырларында гына тирәнтен өйрәнелә башласа да, шактый казанышларга ия тармак санала.

Ялгызлык исемнәрен гомуми лексик фондтагы башка төр берәмлекләрдән аерып торган төп сыйфатла: аларның аерым бер субъект яки объектка бәйлелеге, ялгызлык исеме белән атала торган объект яки субъектның һәрвакыт билгеле һәм чикле күләмдә булуы; төшенчә белән бәйләнешнең ныклы булмавы; ясалыш һәм кулланылышлары ягыннан билгеле бер дәрәҗәдә иркенлеккә ия булулары; телнең функциональ мөмкинлекләреннән чыгып,

күмәклек сүзләре рәтенә күчә алулары һәм шул сыйфатта үзләренең табигатьләрендә һәм ялгызлык, һәм күмәклек сүзләренә хас үзенчәлекләрне саклый алулары. Ялгызлык исемнәренең мәгънәви һәм функциональ потенциалы зур, алар, татар теленең эчке ресурсларыннан тыш, башка телләрдән һәм мәдәниятләрдән алынган семантик мөмкинлекләрне дә үзләренә туплаган, сөйләмдә яңадан-яңа мәгънә төсмерләре белән тулыланырга сәләтле гаять дәрәҗәдә катлаулы берәмлекләр булып саналалар.

Килеп чыгышлары ягыннан ялгызлык исемнәре гомуми лексик фондка хас үзенчәлекләргә ия, төп лексик составны төрки-татар чыгышлы онимнар алып тора, шулай ук алынма берәмлекләрнең зур өлешен гарәп, фарсы, рус һәм Европа телләреннән кергән сүзләр тәшкил итә. Шуның белән бергә, үзенчәлекле якларыннан аерым катламнарда (мәсәлән топонимиядә) борынгы алынмалар сакланып калуын, фин-угор сүзләренең шактый киң таралыш табуын билгеләү зарур. Шулай ук аерым тармакларда (мәсәлән космонимия, эргонимия һәм прогматонимиядә) рус һәм Европа алынмаларының күпләп кулланылуы күзгә ташлана.

Атама бирү мотивлары ягыннан һәр тармакка хас үзенчәлекле сыйфатлар бар. Номинация принциплары буенча барлык тармакларга хас үзенчәлекләрдән халыкның милли күзаллавы, психологиясе, тарихи үткәне белән бәйле атамалар зур урынны алып торуын искәртсәк, антропонимия, урбанонимия, эргонимия, прагматонимия, зоонимия һәм поэтик ономастикада субъектив факторларның, ягъни аерым шәхесләрнең атама бирүдәге рольләрен ассызыклау кирәк. Бу төр атамаларның нинди максатлардан һәм нинди мотивтан чыгып исем бирелүен ачыклау, еш кына, авырлыклар да тудыра.

Сүз ясалыш үзенчәлекләренә килсәк, күмәклек сүзләрдән аермалы буларак, ялгызлык исемнәренең ясалышы телдә продуктив булган модельләр нигезендә бара. Топоним һәм этнонимнар составында борынгы кушымчаларны очратсак та, башка төр онимнарда, башлыча, хәзерге телдә продуктив саналган кушымчалар ялгызлык исемнәрен ясауда актив кулланыла. Тагын бер үзенчәлек: ялгызлык исемнәренең һәр катламында диярлек, форма ясагыч *-лар* кушымчасын очратабыз. Күмәклек сүзләрдә бу кушымча бәйләгеч функция башкарса, әлеге төр лексик берәмлекләрдә, еш кына, сүз ясагыч ролендә кулланыла. Моннан кала, антропоним, урбаноним,

эргоним, космоним, прагматоним, поэтик онимнар составында чит теллəрдəн кергəн сүз ясагыч элементлар да очрый.

Шулай итеп, ономастик берəмлеклəр лексик фондның үзенчəлекле сегменты булып тора. Аларның күптөрлелеге һəм күпсанлы булуы, бер яктан, хəзерге заман талəплəренə туры килсə, икенче яктан, халыкның һəм телебезнең эволюцион процесслары белəн бəйле. Бу – ономастиконның кешелек тормышындагы һəр өлкəне билəп алуын раслый.

Шул рəвешле, хəзерге татар телендə ономастика фəне шактый зур казанышларга ирешкəн аерым бер тармакны тəшкил итə. Аның тəгаен билгелəнгəн өйрəнү объекты, бурычлары, даими тулылынып һəм яңарып торган методологиясе бар. Бүгенге көндə татар ономастикасы лингвистик яссылыкта гына түгел, гуманитар фəннəр өлкəсендəге предметара бəйлəнеш нəтиҗəсендə барлыкка килгəн яңа юнəлешлəрдə дə үсеш кичерə. Хəзерге татар ономастикасы фəненең, ирешкəн уңышлары белəн бергə, килəчəктə монографик тикшеренүлəр талəп иткəн өлкəлəре дə бар. Моңарчы махсус өйрəнелгəн аспектларны да, гуманитар фəннəр яулаган казанышлар югарылыгына күтəрү өчен, тагын да җентекле тикшерү перспективада кала бирə.

# КУЛЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ

## Татар телендә


*Алишев С.Х.* Татар тарихчылары:монография. Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. 206 б.

*Атласи Һ.М.* Себер тарихы. Сөенбикә. Казан ханлыгы: монография. Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. 446 б.

*Әмирова Р.М.* Казан шәһәре татар эргонимиясе: монография. Казан: «Отечество», 2013. 210 б.

*Әфләтунов Ә.Ш.* БАССРның Көнбатыш һәм Көньяк-Көнбатыш өлешендә яшәүче татарлар сөйләшенең тел үзенчәлекләре: филол. фән. канд. ... дис. Казан, 1960. 297 б.

*Әхмәтгалиев Ә.* Янарташлар яуган җирдә // Гасырлар авазы – Эхо веков. − 2004. № 2. Б. 86.

*Әхмәтҗанов М.И.* XVII–XVIII гасыр татар ташбилгеләре: монография. Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. 260 б.

*Әхмәтҗанов М.И.* Дастаннар ватаны: Кама аръягының көнчыгыш төбәкләре һәм татар әдәбияты тарихы. Казан: Мәгариф, 1999. 159 б.

*Әхмәтҗанов М.И.* Биектау төбәгенең XIII–XVII гасырлардан калган татар эпиграфикасы // Очерки истории Высокогорского района Республики Татарстан. Казань: Мастер-Лайн. 1999. С. 99–120.

*Әхмәтҗанов М.И.* Татар шәҗәрәләре: монография. Казан: Татар. кит. нәшр.,1995. 128 б.

*Бакиров М.Х.* Риваятьләр һәм легендалар. Риваятьләрнең жанр сыйфатлары һәм төрләре // Фәнни язмалар – 2006. Казан дәүләт университеты, татар филологиясе һәм тарихы факультеты. Казан: Казан ун-ты нәшр., 2007. Б. 62–74.

*Баязитова Ф.С.* Урта Урал (Сведловск өлкәсе) татарлары: монография Казан: Фикер, 2002. 416 б.

*Биктимирова А.Р.* Юлдаш йолдызлар // Фәнни язмалар – 2006. Казан дәүләт университеты, татар филологиясе һәм тарихы факультеты. Казан: Казан ун-ты нәшр., 2007. Б. 92–99.

Борынгы татар әдәбияты. Казан: Татар. кит. нәшр., 1963. 578 б.

*Галиуллина Г.Р.* Татар теле. Лексикология: таблицалар, схемалар, анализ үрнәкләре, күнегүләр, сүзлекчә: Югары сыйныф укучылары һәм студентлар өчен. Казан: Мәгариф, 2007. 95 б.

*Галиуллина Г.Р., Сабирова Э.Р.* Прагматонимнар һәм аларны татар теле дәресләрендә куллану мөмкинлеге // Сохранение и развитие родных языков в условиях многонационального государства: проблемы и перспективы: материалы Международной научно-практической конференции (Казань, 19–21 октября 2017 г.) / под ред. Р.Р. Замалетдинова. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2017. С. 66–68.

*Ганиев Ф.Ә.* Хәзерге татар әдәби теле: Сүзьясалышы. Казан: Мәгариф, 2000. 271 б.

*Гарипова Ф.Г.* Авыл – милләтебезнең җаны. Казан,2011. 431 б.

*Гарипова Ф.Г.* Исемнәрдә – ил тарихы. Казан: Татар. кит. нәшр, 1994. 264 б.

*Гариф Н.* Тарихи чыганакларда төрки-татар исемнәре һәм географик атамалар. Казан: ТФА. Тарих институты басмаханәсе, 2011. 240 б.

*Гафурова А.Ә.* Татар реклама текстларында кулланылган ономастик лексиканың төп төркемчәләре // Фәнни язмалар – 2008. Казан дәүләт университеты, татар филологиясе һәм тарихы факультеты. Казан: Ихлас, 2010. Б. 42–45.

*Дәүләтшин Г.М.* Төрки – татар рухи мәдәнияте. Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. 512 б.

Еники Ә. Әсәрләр:5 томда.Казан:Татар кит.нәшр., 2001. Т. 2. 447 б.

*Җәләй Л.* Татар теленең тарихи морфологиясе (очерклар). Казан: Фикер, 2000. 287 б.

*Җамалетдинов Р.Р.* Тел һәм мәдәният: Татар лингвокультурологиясе нигезләре. Казан: Мәгариф, 2006. 351 б.

*Җәүһәрова Ф.Х.* Татарларда мал тоту традициясенә бәйле мифологик күзаллаулар // Татар халык иҗаты. Фәнни эзләнүләр һәм фольклор үрнәкләре (фәнни конференцияләр материаллары җыентыгы) (7 нче китап). Казан: Ихлас, 2012. Б. 50–53.

*Зәкиев М.З.* Татар халкы теленең барлыкка килүе. Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. 302 б.

*Зәкиев М.З.* Төрки-татар этногенезы. М.: Инсан, 1998. 624 б.

*Исәнбәт Н.С.* Татар халык мәкальләре:мәкальләр җыелмасы: 3 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 2010. Т. 2. 799 б.

*Мәрҗани Ш.* Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар: Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр / төз. һәм тәрҗ. Ә.Н. Хәйруллин; редкол.: Я.Г. Абдуллин, Җ.И. Гыйльманов, С.Х. Алишев, М.В. Гайнетдинов, Р.Г. Әмирханов, Р.М. Әмирханов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. 415 б.

*Мәхмүтов Х.Ш.* Гыйбәрәләр тарихыннан сәхифәләр (Этимологик эзләнүләр). Казан: Алма-Лит, 2008. 464 б.

*Мәхмүтов Х.Ш.* Язылмаган кануннар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1995. 172 б.

Милли-мәдәни мирасыбыз: Мари Эл татарлары. Бәрәңге. Казан, 2012. 376 б.

Милли-мәдәни мирасыбыз: Түбән Новгород. Казан – Түбән Новгород – Мәскәү: «Мәдинә» нәшрият йорты, 2011. 400 б.

*Миңнуллин К.М.*Басма сүз һәм татар җырлары: монография. Казан: Мәгариф, 2000. 157 б.

*Миңнуллин К.М.* Һәр чорның үз җыры. Казан: Мәгариф, 2003. 400 б.

*Миңнуллин К.М.* Шигърият һәм җыр. Казан: Мәгариф, 1998. 287 б.

*Насыйри К.* Сайланма әсәрләр. Ике томда. Казан: Татар.кит. нәшр., 1974. Т. 1. 339 б.

*Насыйри К.* Сайланма әсәрләр. Ике томда. Казан: Татар. кит. нәшр.,1975. Т. 2. 318 б.

*Низамов И.М.* Ярдәмең берлән синең… Казан: Мәгариф, 2008. 239 б.

*Ногмани Р.* Кайдан килә «Казан» атамасы? // Социалистик Татарстан. 1990. 24 гыйнвар.

Сарман ягы – нурлы як [электрон чыганак]: http://sarmanyaq.ucoz.ru/load/sarman_rajony_atamalary/1-1-0-1.

*Саттар-Мулилле Г.* Татар зоонимиясе (кече туганнарыбызның исемнәре) // Татарстан хәбәрләре. 1994. 16 апрель.

*Саттар-Мулилле Г.* Татар исемнәре ни сөйли? Казан: Раннур, 1998. 488 б.

*Саттаров Г.Ф.* Атамалар дөньясына сәяхәт: монография. Казан: Татар. кит. нәшр., 1992. 240 б.

*Саттаров Г.Ф.* Башкалабыз урамнарына – милли рух // Казан утлары, 1993. № 1. Б. 164–168.

*Саттаров Г.Ф.* Мәктәптә туган як ономастикасы: монография. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. 208 б.

*Саттаров Г.Ф.* Татар антропонимикасы: монография. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1990. 276 б.

*Саттаров Г.Ф.* Татар топонимиясе. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1998. 438 б.

*Саттаров Г.Ф.* Татарларда кушаматлар // Совет мәктәбе. 1973. № 9. Б. 46–49.

*Саттаров Г.Ф.* Татарстан АССРның антропотопонимнары. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1973. 296 б.

*Саттаров Г.Ф.* Ни өчен шулай аталган? Татарстан топонимнары. Казан: Татар. кит. нәшр., 1971. 127 б.

*Сафиуллина Ф.С., Зәкиев М.З.* Хәзерге татар әдәби теле: Педагогия училищелары, гимназияләр өчен дәреслек. Казан: Мәгариф, 1994. 320 б.

*Сафиуллина Ф.С.*Сүзиясебеләнйөри. Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. 136 б.

*Сафиуллина Ф.С.* Татар әдәби теле. Лексикология. Казан: Хәтер, 1998. 171 б.

ТатарстанАССРтарихы / редкол. Җ.И. Гильманов, М.К. Мөхәррәмов, Ю.И. Смыков һ.б. Казан: Татар. кит. нәшр., 1970. 744 б.

Татар грамматикасы: 3 томда. М.: Инсан; Казань: Фикер, 1998. Т.1. 512 б.

Татар грамматикасы: 3 томда / проект җит. М.З. Зәкиев; Ф.М. Хисамова ред. Тулыландырылган 2 нче басма. Казан: ТӘһСИ, 2015. Т. 1. 512 б.

Татар лексикологиясе: 3 томда /авт.: М.З. Зәкиев, Г.Р. Галиуллина, Р.Ф. Фәттахова, Ә.К. Булатова / проект җит. М.З. Зәкиев; ред. Г.Р. Галиуллина. Казан: ТӘһСИ, 2015. Т. 1. 352 б.

Татар мифлары: ияләр, ышанулар, ырымнар, фаллар, им-томнар, сынамышлар, йолалар. Казан: Татар кит.нәшр., 1996. 388 б.

Татар халык иҗаты. Дастаннар / Ф. Урманчеев ред. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. 384 б.

Татар халык мәкальләре: 3 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 2010. Т. 1. 623 б.

Татар халык мәкальләре: 3 томда. Казан: Татар.кит. нәшр., 2010. Т. 2. 749 б.

Татар халык мәкальләре: 3 томда. Казан: Татар.кит. нәшр., 2010. Т. 3. 799 б.

Татар халык иҗаты. Мәкальләр һәм әйтемнәр / төз. Х.Ш. Мәхмүтов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. 525 б.

Татар халык иҗаты: Риваятьләр һәм легендалар / төз. С.М. Гыйләҗетдинов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. 232 б.

Татар халык табышмаклары / төз. Н. Исәнбәт. Казан: Татар. кит. нәшр., 1970. 560 б.

Татар халык табышмаклары / төз. Х.Ш. Мәхмүтов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. 270 б.

Татар эпосы. Дастаннар / төз. Ф.И. Урманчеев. Казан: Раннур, 2004. 640 б.

*Тумашева Д.Г.* Хәзерге татар әдәби теле морфологиясе. Казан, 1964. 222 б.

*Фасеев Ф.С.* Татар телендә терминология нигезләре. Казан: Татар.кит. нәшр., 1969. 200 б.

*Фәхреддинев Р.* Болгар вә Казан төрекләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. 287 б.

*Хаҗиева Г.С.* Телнең этнокультур пространствосында татар кушаматлары // Актуальные проблемы современной фольклористики. Вып. 1. Казань: Ихлас, 2017. С. 231–235.

*Хаҗиева-Демирбаш Г.С.* Г.Ибраһимов идиостилендә кушаматлар // Наследие Галимджана Ибрагимова в контексте многообразия культур: материалы международной конференции, посвященной 130-летию со дня рождения Г. Ибрагимова / сост. Ф.Х. Миннуллина, А.Ф. Ганиева. Казань: ИЯЛИ, 2016. С. 297–301.

*Хаков В.Х.* Татар милли әдәби теленең барлыкка килүе һәм үсеше. Казан: Татар. кит. нәшр., 1972. 224 б.

*Хангилдин В.Н.* Татар теле грамматикасы. Казан: Татар. кит. нәшр., 1959. 243 б.

*Хисамова Ф.М.* Татар теле морфологиясе: югары уку йортлары өчен дәреслек. Казан: Казан ун-ты нәшр., 2006. 335 б.

*Һадиев И.Г., Мәрдәнов Р.* Мамадыш төбәгенең ташъязма истәлекләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. 199 б.

*Юсупов Р.А.* Мәгълүмат чаралары һәм сөйләм культурасы // Татар теленең терминологиясен камилләштерү проблемалары. Казан: Алма-Лит, 2006. Б. 25–33.

*Юсупов Р.А.* Тәрҗемә һәм сөйләм культурасы. Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. 238 б.

*Яхин Ф.З.* Татар шигъриятендә дини мистика һәм мифология. Казан: Татар дәүләт гуманитар ин-ты, 2000. 286 б.

**Рус телендә**

*Абдрахманов М.А., Бонюхов А.А.* Топонимические названия Шории // Языки и топонимия Сибири. Томск, 1966.

*Абдимуратов К.* Топонимия Каракалпакии: автореф. дис. … канд. наук. Нукус, 1966. 18 с.

*Абдуллина Г.Р., Гайнуллина Г.Д.* Наименования небесных тел (на материале башкирского языка) // Научно-методический электронный журнал «Концепт». 2014. Т. 20. С. 1141–1145. URL: http://e-koncept.ru/2014/54492.htm.

*Абдуллина Г.Р.* Космонимы в башкирском языке (в сравнении с другими тюркскими языками) // Ученые записки Крымского федерального университета имени В. И. Вернадского. Серия «Филологические науки». Т. 2 (68). № 3. 2016. С. 297–311.

*Абу-л-гази.* Родословное древо тюрков / пер. и предисл. Г.С. Саблукова // Известия общества археологии, истории и этнографии при Казанском университете. Т. 21. Вып. 5–6. Казань, 1906.

*Авакова Р.А., Нукежанова Ж.Г.* Космонимы в словаре «Дивану Лугат Ит-Тюрк» Махмуда Кашкари // Kaznu Bulletin. Oriental series. №2 (63). 2013. С. 48–53.

*Агафонов Н.Я*. Историческая объяснительная записка наименования Казанских улиц // Материалы к вопросу переименования улиц города Казани. Казань, 1899. 42 с.

*Аджи Мурад*. Тайна опустевшего храма // Литературная Россия. №12. 25 март, 2005. С. 12–18.

*Айдаров Г.* Язык орхонских памятников древнетюркской письменности VIII в.: монография. Алма-Ата: Наука, 1971. 376 с.

*Акишев К.А.* Курган Иссык. Искусство саков Казахстана. М.: Искусство, 1978. 132 с.

*Аманжолов А.С.* Руноподобная надпись из сакского захоронения близ Алма-Аты // Вестник АН КазССР, 1971. № 12 (320). С. 64–66.

*Амиров К.Ф.* Казань: где эта улица, где этот дом? Казань: Казань, 1995. 320 с.

*Амирова Д.Р.*Этнографические топонимы Азербайджана: автореф. дис. ...канд. филол наук. Баку, 1992. 24 с.

*Андреева Л.И.* Специфика имени собственного и возможности её использования в художественном тексте: дис. … канд. филол. наук. Балашов, 1995. 205 с.

*Аронов К.Г.* Этнолингвистическая природа народных космонимов в казахском языке: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Алма-Ата, 1992. 22 с.

*Арутюнова Н.Д.*Типы языковых значений: Оценка. Событие. Факт: монография. М.: Наука, 1988. 341с.

*Астафьева И.А.*Способы номинации в ситуации города (на материале ойкодомонимов г. Омска): автореф. дис.... канд. филол. наук. М., 1996. 19 с.

*Атаниязов С.* Географические термины в топонимике Туркменстан // АН ТАССР. Серия обществ. Наук. №1. 1969.

*Ахатова З.Ф.* Топонимия Нижнего Прикамья Татарстана: автореф. дис. …канд. филол. наук. Казань, 1994. 18 с.

*Ахметзянов М.И.* Татарские шеджере: монография. Казань: Татар. кн. изд-во, 1991. 152с.

*Ахметьянов Р.Г.* Некоторые названия лошадей в татарском языке // Советская тюркология. 1975. № 2. С. 69–76.

*Ахметьянов Р.Г.* О топониме «Казань» (по поводу статьи В.Л. Егорова «О времени возникновения Казани») // Ученые записки КГПИ. Вып. 150. Сб. 7. Казань, 1975. С. 133–136.

*Ахметьянов Р.Г.* Общая лексика материальной культуры народов Среднего Поволжья. М.: Наука, 1988. 200 с.

*Ашмарин Н.И.* Болгары и чуваши. Казань, 1902. 132 с.

*Бабенко Л.Г.* Филологический анализ художественного текста. основы теории, принципы и аспекты анализа. М.: Академический проект; Екатеринбург: Деловая книга, 2004. 464 с.

*Баирова Л.В.* Клички домашних животных в бурятском языке // Вопросы ономастики. 1975. № 10. С. 142–146.

*Баласагунский Ю*. Благодатное знание. М.: Наука, 1983. 557 с.

*Барандеев А.В.* История географических названий: Русская топонимия в терминах. М.: Книжный дом «ЛИБРОКОМ», 2012. 142 с.

*Барашков В.Ф.* Названия водных источников Ульяновской области // Ономастика Поволжья. Уфа, 1973. – вып. 3. – С. 20-31.

*Барджакова Ю.А.*Зоонимы как «говорящие» имена в творчестве А.П. Чехова, образованные от собственных имен людей жакова // Študentská vedecká a umelecká konferencia, sekcia lingvistiky, 2013. С. 281–285.URL: http://lib.knigi-x.ru/23raznoe/17407-1-sekcia-lingvistiky-281-zoonimi-kak-govoryaschie-imena-tvorchestve-chehova-obrazovannie-sobstvennih-imen-lyudey-j.php.

*Бартольд В.В.*Сочинения. Работы по истории и филологии тюркских и монгольских народов М.: Восточная литература, 2002. Т. 5. 757 с.

*Бартольд В.В.* Сочинения: в 2-х томах. М.: Наука, 1963. Т. 1. 1024 с.

*Баскаков Н.А.* Введение в изучение тюркских языков. М.: Высшая школа, 1969. 383 с.

*Баскаков Н.А.* Клички собак у каракалпаков // Ономастика Средней Азии. М.: Наука, 1978. С.206–209.

*Баязитова Ф.С.* Татарские говоры Нижнего Прикамья: автореф. дис. ...канд. филол. наук. Казань, 1973. 30 с.

*Белова О.В.* Этнокультурные стереотипы в славянской народной традиции: монография. М.: Индрик, 2005. 409 с.

*Белокопытов В.И., Шевченко И.Я.*Их именами названы улицы Казани. Казань: Татар. кн. изд-во, 1973. 527 с.

*Березович Е.Л.* Русская народная топонимия как концептуальное семантическое пространство // Лингвистическая ретроспектива, современность и перспектива города и деревни. Пермь, 1999. С.13-27.

*Березович Е.Л.* Русская топонимия в этнолингвистическом аспекте: Пространство и человек. М.: Книжный дом «ЛИБРОКОМ», 2009. 43 с.

*Березович Е.Л.* Русская топонимия в этнолингвистическом аспекте: Мифопоэтический образ пространства. М.: КомКнига, 2010. 240 с.

*Берестнев Г.И.*Семантика русского языка в когнитивном аспекте: учебное пособие. Калининград: Изд-во Казан.ун-та, 2002. 157с.

*Бертельс Е.Э.* Хибат аль-Хакаик Ахмада Югнаки. Ташкент: Труды Среднеазиатского гос. ун-та. Новая серия, 1945. С. 29–45.

*Биджиева Ф.И.* История возникновения и развития карачаевских фамилий XVI – концеXX вв.: автореф. дис.... канд. филол. наук. Карачаевск, 2002. 27 с.

*Биктимирова А.Р.* Лингвистическая и ономастическая поэтика татарских народных песен: автореф. дис.… канд. филол. наук. Казань, 2003. 25 с.

*Битанова А.С.* Из наблюдений над казахской топонимикой Кустанайской области // Вопросы топонимики. Вып1. Свердловск, 1962.

*Богатырев П.Г., Якобсон Р.О.* Фольклор как особая форма творчества [Электронный ресурс] // Вопросы народного творчества. М., 1971.С. 369–383 (http://www.ruthenia.ru/folklore/jackobson1.htm).

*Бондалетов В.Л.* Русская ономастика. М.: Просвещение, 1983. 224 с.

*Бонюхов А.А.* Структура и семантика шорских топонимов: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Томск, 1972. 19 с.

*Будагов Б.А.* Физико-географическая основа топонимов // Топонимика в региональных географических исследованиях. Всесоюзная конференция. Тезисы. М., 1984. С.9–12.

*Будагов Р.А.* Человек и его язык: монография. М.: Изд-во МГУ, 1974. 264 с.

*Будагов Л.З.* Сравнительный словарь турецко-татарских наречий: в 2-х томах. СПб, 1869. Т.1. 810 с.; 1871. Т. 2. 415 с.

*Бузакова Р.Н.* Особенности мордовских зоонимов // Ономастика Поволжья. Уфа, 1973. № 3. С. 386–390.

*Бурганова Н.Б.* К вопросу о формировании земледельческой лексики в татарском языке // Лексика и стилистика татарского языка. Казань: ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова, 1982. С. 45–51.

*Бушаков В.А.* Термины, обозначающие селения и крепости, в топонимии Крыма // Советская Тюркология. 1985. № 5. С. 28–37.

*Бушмакин С.К.* Воршудные имена – микроэтнонимы удмуртов // Этнонимы. М.: Наука, 1970. С. 168–176.

*Валиева М.З.* Историко-лингвистический анализ татарских женских имен:автореф. дис.… канд. филол. наук. Казань, 2007. 23с.

*Вафеев Р.А., Выхрыстюк М.С., Файзуллина Г.Ч.* Фамилии тюркского происхождения ревизских сказках города Тобольска XVIII века: структурно-семантический аспект // Вестник Челябинского государственного университета. Филология. Искусствоведение. Вып. 69. 2012. №23 (277). С. 32–35.

*Введенская Л.А., Колесников Н.П.* От названий к именам. Ростов-на-Дону: Феникс, 1985. 544 с.

*Вайсгербер Й.Л.* Родной язык и формирование духа / Пер. с нем.. вступ. ст. и коммент. О.А. Радченко. М.: Едиториал УРСС, 2004. 232 с.

*Вежбицкая А.* Язык. Культура. Познание. М.: Русские словари, 1996. 416 с.

*Вершинин В.И.* Наши фамилии. Йошкар-Ола: Издание автора, 2016. 203 с.

*Вершинин В.И.* Антропонимы: Фамилии. Имена. Йошкар-Ола: Издание автора, 2015. 145 с.

*Веселовский А.Н.* Историческая поэтика. М.: Высшая школа, 1989. 408 с.

*Виноградов В.В.* Стилистика. Теория поэтической речи. Поэтика. М.: Наука, 1963. 253 с.

*Волощенко О.В.* Языковые основы фольклора в свете явлений традиционной народной культуры: на материале русской волшебной сказки: автореф. дис.… канд. филол. наук. Воронеж, 2006. 25 с.

*Воробьёв И.А.* К вопросу о лексическом значении имен собственных // Актуальные проблемы лексикологии: Доклады лингвистической конференции. Ч.1. – Томск: Изд-во Томск. ун-та, 1971. С.1–8.

*Воронцова Ю.Б.* Коллективные прозвища в русских говорах: автореф. дис.… канд. филол. наук. Екатеринбург, 2002. 17 с.

*Габаши Х.Г.* Муфассал тарих-и Кавем-и Турки. Уфа, 1909. 56 с.

*Габишева Л.Л.* Слово в контексте мифопоэтической картины. М.: РГГУ, 2003. 192 с.

*Гаджиев И.З.* Зоонимы в азербайджанском языке // Ономастика Кавказа. Орджоникидзе, 1980. С.161–162.

*Галиуллина Г.Р.* Антропонимия татар города Казани в XX веке (на материале личных имен): автореф. дис.… канд. филол. наук. Казань, 1999. 20с.

*Галиуллина Г.Р.* Космологические воззрения в татарской антропонимической картине мира // Ученые записки Казанского государственного университета. Т. 150. Книга 2. Казань, 2008. С. 197–204.

*Галиуллина Г.Р.* О формировании и развитии татарского антропонимикона(по материалам писцовых книг Казани и Казанского уезда XVI века)//Средневековые тюрко-татарские государства. Сборник статей. Вып. 6. Материалы международной научной конференции «Средневековые тюрко-татарские государства и их соседи в системе международных отношений (XV–XVIII вв.)» (г.Казань, 14–15 марта 2014 г.). Казань: Институт истории им. Ш.Марджани АН РТ, 2014. С. 195–198.

*Галиуллина Г.Р.* Татарская антропонимия в лингвокультурологическом аспекте: автореф. дис. …д-ра филол. наук.Казань, 2009. 43с.

*Галиуллина Г.Р.* Татарские личные имена в контексте лингвокультурных традиций: монография. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2008. 352 с.

*Галиуллина Г.Р.* Личные имена татар в XX веке. Казань: Матбугат йорты, 2000. 114 с.

*Галиуллина Г.Р., Бадертдинов Р.Б.* Функционирование антропонимов в качестве эргонимов в татарском лингвокультурном пространстве // Ученые записки Казанского государственного университета. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2008. Т. 150. Кн. 2. С. 95–99.

*Галиуллина Г.Р., Ильдарханова Ф.А., Галиева Г.И.* Этнокультурные традиции как основа укрепления семьи (на примере Тетюшского муниципального района Республики Татарстан). Казань: Изд-во «Отечество», 2011. 118 с.

*Галиуллина Г.Р.*Культурно-религиозные традиции в тюрко-татарской антропонимии (на примере писцовых книг г. Казани и Казанского уезда XVI века)// И.А. Бодуэн де Куртенэ и мировая лингвистика Международная конференция (V Бодуэновские чтения): труды и материалы. Под общей редакцией К.Р. Галиуллина, Е.А. Горобец, Г.А. Николаева. Казань, 2015. С. 70 –71.

*Ганиев Ф.А.* Образование сложных слов в татарском языке. М.: Наука, 1982. 149 с.

*Ганиев Ф.А.* Современный татарский литературный язык: суффиксальное и фонетическое словообразование. Казань: Дом печати, 2005. 360 с.

*Ганиев Ф.А.* Суффиксальное словообразование в современном татарском литературном языке. Казань: Татар. кн. изд-во, 1974. 231 с.

*Ганиева Г.Р.* Фразеологические единицы с компонентом именем собственным в английском, русском и татарском языках. Нижнекамск: Нижнекамский химико-технологический институт (филиал) ФГБОУ ВПО «КНИТУ», 2012. 109 с.

*Гареева А.*Клички домашних животных в английском, русском и татарском языках [Электронный ресурс]: https://nsportal.ru/ap/library/drugoe/2015/01/27/klichki-domashnikh-zhivotnykh-v-angliyskom-russkom-i-tatarskom-yazykakh).

*Гарипова Н.Д.* Заметки об иранских элементах в топонимии Башкирии // Топонимика Востока. Новые исследования. М.: Наука, 1964. С.185–189.

*Гарипов Т.М.* О кличках животных у башкир: Доклады АН СССР. Серия 8. Л., 1928. № 15. С. 328–330.

*Гарипов Т.М., Кузеев Р.Г.* Преемственность и сменяемость этнических культур (ирано-тюркские историко-лингвистические связи в Урало-Поволжье) // Взаимодействие и взаимовлияние цивилизации и культур на востоке. М., 1988. С. 14–16.

*Гарипова Ф.Г.* Исследования по гидронимии Татарстана. М.: Наука, 1991. 294 с.

*Гарипова Ф.Г.* Татарская гидронимия (вопросы этногенеза татарского народа по данным гидронимии). Казань: ИЯЛИ, 1998. 571 с.

*Гарипова Ф.Г.* Татарская гидронимия. Казань: Полиграфическо-издательский комбинат, 1998. 572 с.

*Гарипова-Хасаншина В.М.*Поэтическая ономастика прозы Г. Баширова: автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 2004. 24 с.

*Гасимова С.И.* Историко-лингвистический анализ татарских прозвищ: автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 2006. 25 с.

*Гафурова А.А.* Специфика функционирования ономастической лексики в татарских и англоязычных рекламных текстах: дис. …канд. филол. наук. Казань, 2012. 246 с.

*Гейбуллаев Г.А.* Топонимия Азербайджана (историко-этнографическое исследование): монография. Баку: Элм, 1986. 198с.

*Генинг В.Ф., Халиков А.Х.* Ранние болгары на Волге. М.: Наука, 1964. 201 с.

*Глинских Г.В.* Мансийские субстратные топонимы в русских говорах по р. Тавде // Этимологические исследования. Вып. 1: Этимология русских диалектных слов. Свердловск, 1978. С. 109-179.

*Голомидова М.В.* Искусственная номинация в ономастике. Екатеринбург, 1998. 232 с.

*Горбаневский М.В.* Русская городская топонимия: Проблемы историко-культурного изучения и современного лексикографического описания: дис. ... д-ра филол. наук. М., 1994. 432 с.

*Горбачева О.Г.* Ономастическое пространство русских народных и авторских сказок: автореф. дис. … канд. филол. наук. Брянск, 2008. 25 с.

*Гриценко К.Ф.* Названия рек и озер Якутии: автореф. дис. … канд. филол. наук. Томск, 1968. 20 с.

*Грумм-Гржимайло Г.Е.* Белокурая раса в Средней Азии // Гумилев Л.Н. История народа хунну. М.,1998. С.340–348.

*Гумилев Л.Н.* Древние тюрки. М.: Наука, 1967. 501 с.

*Давлетшин Г.М.* Астроном города Болгара Мас’уди аль-Булгари // Вестник Казанского государственного университета культуры и искусств. Казань: КГУКИ, 2015. № 3. С. 35–37.

*Давлетшина Л.Х.* Мифологизм в татарской прозе конца XX – начала XXI веков: автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 2005. 25 с.

*Давлетшина Л.Х.* Религиозно-мифологические представления о «нечистой силе» в традиции тюменских татар // Филологические науки. Вопросы теории и практики. Тамбов: Грамота, 2016. № 9. Ч. 1. С. 25 –27.

*Давлетшина Л.Х.* «Хызыр Ильяс» в традиционной культуре татар // Вестник Башкирского университета, 2011.№3.URL: http://cyberleninka.ru/article/n/hyzyr-ilyas-v-traditsionnoy-kulture-tatar (дата обращения: 24.08.2017).

*Давлетшина Л.Х.* К проблеме изучения низшей мифологии: мифологический персонаж // Вестник КГПУ им. В.П. Астафьева, 2011. № 3. URL: http://cyberleninka.ru/article/n/k-probleme-izucheniya-nizshey-mifologii-mifologicheskiy-personazh (дата обращения: 24.08.2017).

*Дарзаманова Г.З.* Фразеологические единицы и паремии с антропонима и в русском, татарском и английском языках: автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 2002. 21 с.

*Дмитриев В.Д.* О происхождении чувашского народа // Материалы по истории Чувашской АССР. Чебоксары: Чувашгосиздат, Вып. 1. 1958. С. 50–61.

*Дмитриев Н.К.* Собачьи клички у башкир // Доклады АН СССР. Серия 8. Л., 1928. № 15. 14 с.

*Дмитриев Н.К.* Строй тюркских языков. М.: Изд-во Восточной литературы, 1962. 607 с.

*Добродомов И.Г.* География и этимология // Вопросы географии. Топонимия Центральной России. М, 1974.

*Доватур А.И., Каллистов Д.П., Шишова И.А.* Народы нашей страны в «Истории Геродота». М.: Наука, 1982. 455 с.

*Донидзе Г.И.* Гидронимические термины в тюркских языках // Ономастика. М.: Наука, 1969.

*Донскова Г.Л.* Сравнительно-сопоставительная характеристика динамики эргонимической номинации Нижнего Поволжья и Западного Казахстана: дис. ... канд. филол. наук. Пятигорск: Изд-во Пятигор. гос. лингв. ун-та, 2004. 251 с.

*Дранникова Н.В.* Локально-групповые прозвища в традиционной культуре: функциональность, жанровая система, этнопоэтика Русского Севера: автореф. дис. ... д-ра филол. наук. Архангельск, 2005. 56 с.

Древнетюркская поэзия VI–XII веков / пер. А. Преловского; стихотворная реконстр., науч. пер., сост., вступ. статья, комментарии И.В. Стеблевой. М.: Раритет, 1993. 176 с.

*Дубова Н.Г.* Некоторые особенности кличек охотничих собак // Вопросы ономастики. Свердловск, 1980. № 14. С. 145–149.

*Дубровина Л.В.* Официальные названия лечебных учреждений в Великобритании и США // Ономастика: Типология. Стратиграфия. М.: Наука, 1988. С. 99–107.

*Егоров В.Г.* О времени возникновения Казани // Советская археология. 1975. №4. С. 80–87.

*Емельянова А.М.* Эргонимы в лингвистическом ландшафте полиэтнического города (на примере названий деловых, коммерческих, культурных, спортивных объектов г. Уфы): дис. … канд. филол. наук. Уфа: Изд-во БГУ, 2007. 162 с.

*Еремеев Д.Е.* К семантике тюркской этнонимии // Этнонимы. М.: Мысль, 1970. С. 133–141.

*Ермолович Д.И.* Имена собственные на стыке языков и культур. М.: Р. Валент, 2001.200 с.

*Жапаров Ш.* Кыргызская антропонимия. Бишкек: Илим, 1992. 188 с.

*Жирмунский В.М.* Тюркский героический эпос. Л.: Наука, 1974. 727 с.

*Жучкевич В.А.* Общая топонимика. Минск: Высшая школа, 1980. 287 с.

*Зайцева К.Б.* Английская стилистическая ономастика. Тексты лекций. Одесса, 1973. 134 с.

*Закиев М.З.* История татарского народа (этнические корни, формирование и развитие). М.: Инсан, 2008. 560 с.

*Закиев М.З.* Проблема языка и происхождение волжских татар. Казань: Татар. кн. изд-во, 1986. 302 с.

*Закиев М.З.* Происхождение тюрков и татар. М.: Инсан, 2003. 496 с.

*Закиев М.З.* Татары: проблемы истории и языка. Казань: ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова,1995. 463 с.

*Закирова И.Г.* Дастан «Ак Кубек» тюркских народов // Вестник Чувашского университета. 2009. № 4. С. 296–301.

*Залялиева М.А.* Историко-лингвистические исследования татарских личных имён русского и западноевропейского происхождения: автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 1985. 21с.

*Заринский П.* Очерки древней Казани. Казань: Губерн. тип., 1877. 220 с.

*Зеленин Д.К.* Восточнославянская этнография. М.: Наука, 1991. 511 с.

*Зинин С.И.* Из истории лексикографирования собственных имен художественной литературы. Ташкент: Научн. тр. ТашГУ, 1980. Вып. 629. С. 83–89.

*Зиннатуллина Г.Х.* Поэтическая ономастика прозы А. Еники: автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 2005. 25 с.

*Золотницкий Н.И.* Лингвистическая заметка о названиях Булгар, Биляр, Моркваши. Казань, 1884. 24 с.

*Ибрагим Т.К., Султанов Ф.М., Юзеев А.Н.* Татарская религиозно-философская мысль в общемусульманском контексте. Казань: Татар. кн. изд-во, 2002.239 с.

*Иванова А.М., Хазиева-Демирбаш Г.С.* Сравнительно-сопоставительный анализ антропонимов коранических персонажей в афористических жанрах татарского и турецкого фольклора // Вестник Чувашского университета. 2017. № 2. С. 203–207.

*Иванова А.М., Хазиева-Демирбаш Г.С.* Сравнительно-сопоставительный анализ охранительных имен в тюркских языках // Филологические науки. Вопросы теории и практики. 2017. № 5. Ч. 3. С. 87–90.

*Износков И.А.* Список населенных мест Казанского уезда с кратким их описанием. Казань, 1885. 208 с.

*Износков И.А.* Список населенных мест Казанской губернии: Лаишевский уезд. Казань, 1893. 80 с.

*Износков И.А.* Список населенных мест Мамадышского уезда. // Труды IV археологического съезда в России. Т.1. Казань, 1884. 119 с.

*Имаева Г.З.* Типологические сближения в восточнославянских и тюркоязычных сказках. Казань: ИЯЛИ, 2009. 216 с.

*Исангузина И.И.* Прагматонимы в ономастическом пространстве: семантический, лингвокультурологический и синтаксический аспекты (на примере названий кондитерских изделий) // Вестник Башкирского университета. Уфа: Башкирский государственный университет, 2008. №4. С. 990–993.

*Исмагулова Б.Х., Баяндина С.Ж.* Ономастическое пространство казахского фольклора // Материалы международного конгресса «Актуальные проблемы комплексного исследования алтаистики и тюркологии. Кокшетау, 2009. С. 187–192.

История таджикского народа. Т. 1. М., 1965.

История татар. Народы степной Евразии в древности. Казань: Рухият, 2002. Т. 1. 552 с.

История татарской АССР / под. ред. М.К. Мухарямова. Казань: Татар. кн. изд-во. 1980. 256 с.

*Исхаков Д.М. Измайлов И.Л.* Этнополитическая история татар (III – середина XVI вв.). Казань: РИЦ «Школа», 2007. 356.

*Исхакова Г.А.* О названиях мастей лошадей в татарском языке // Вестник Чувашского университета. 2008. № 3. С. 122–129.

*Исхакова Х.Ф.* Сопоставительная грамматика татарских и русских собственных имен. М.: Наука, 2000. 108 с.

*Кадирова Э.Х.* Космонимы в тюрко-татарских письменных памятниках // Материалы XII Международной научной конференции «Ономастика Поволжья». Казань: Отечество, 2010. С. 334 –336.

*Калинин Н.* Казань XVIII века: по неизданным картографическим и иконографическим материалам. Казань: Лито-тип.Татполиграфа, 1929.

*Калинкин В. М.* Поэтика онима. Донецк: Донеччина, 1999. 408 с.

*Камалов А.А*. Башкирская топонимия. Уфа: Китап, 1994. 304 с.

*Камалов А.А*. Гидронимия Башкирии: автореф. дис. … канд. филол. наук. Уфа, 1969. 28 с.

*Камалов А.А.* Некоторые вопросы изучения топонимии Башкирии // Ономастика Поволжья. Вып. 3. Уфа, 1973. С. 201–209.

*Карамзин Н.М.* История государства Российского (Репринтное воспроизведение издания 1842 –1844 годов). Кн. 1. М.: Книга, 1988. 186 с.

*Караулов Ю.Н.* Русский язык и языковая личность Текст. М.: Наука, 1987. 264 с.

*Карнович Е.П.* Родовые прозвания и титулы в России и слияние иноземцев с русскими. СПб., 1886. 248 с.

*Карпенко М.В.* Русская антропонимика. Конспект лекций спецкурса. Одесса, 1970. 42 с.

*Карпенко Ю.А.* Имя собственное в художественной литературе // Филологические науки. 1986. № 4. С.34 –40.

*Карпенко Ю.А.* Названия звездного неба. М.: Наука, 1981. 184 с.

*Карпенко Ю.А*. Специфика ономастики // Русская ономастика. Одесса: Изд-во ОГПИ, 1984. С. 3–16.

*Карташева И.Ю.* Прозвища как явление русского устного народного творчества:автореф. дис. … канд. филол. наук. Челябинск, 1985. 17 с.

*Касимов Э.С.* Сатира и юмор в татарских народных сказках автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 1966. 26 с.

*Катанов Н.Ф.* Алфавитный указатель собственных имен, встречающихся в первом томе Образцов народной литературы тюркских племен, собранных В.В. Радловым: Представлено Акад. в заседании Ист.-филол. отд. 22 сент. 1887 г. / сост. Н.Ф. Катанов. Санкт-Петербург: Тип. Имп. Акад. наук, 1888. 34 с.

*Катанов Н.Ф.* Опыт исследования урянхайского языка, с указанием главнейших родственных отношений его к другим языкам тюркского корня. Казань: Типо-лит. Имп. Казан. ун-та, 1903. 882 с.

*Кацитадзе Э.А.* Метафоризация зоонимов в немецком языке: автореф. дис. … канд. филол. наук. Тбилиси, 1985. 20 с.

*Керимбаев Д.М.* Состав и этнолингвистическая характеристика собственных имён казахского фольклора: автореф. дис. … канд. филол. наук. Алматы, 2004. 28 с.

*Керимбаева С.Е.* Ономастическая экспликация мифологической модели мира в казахском языке: автореф. дис. … канд. филол. наук. Алматы, 2004. 28 с.

*Киекбаев Д.Г.* Вопросы башкирской топонимики // Уч. Зап. Башкирского пед. института. Серия филологическая. Вып. 8. Уфа, 1956. С. 230–-247.

*Китайгородская М.В.* Активные социолингвистические процессы в сфере городских наименований: московские вывески //

Современный русский язык. Социальная и функциональная дифференциация. М.: Язык славянской культуры, 2003. С. 127–150.

Книга Большому Чертежу / под ред. К.Н. Сербиной. М., 1950. С. 143–144.

*Ковалевский А.П.* Книга Ахмеда ибн-Фадлана и его путешествие на Волгу в 921–922 гг. Харьков, 1956. 343 с.

*Ковалев Г.Ф.*Писатель. Имя. Текст. Воронеж: ВГУ, 2004. 340 с.

*Ковалевский А.П.* Книга Ахмеда ибн-Фадлана и его путешествие на Волгу в 921-922 гг. Харьков, 1956. 343 с.

*Кондратьева Т.Н.* Собственные имена в месяцесловах, пословицах, поговорках, загадках, заговорах и сказках русского народа. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2004. 340 с.

*Кондратьева Т.И.* Собственные имена в русском эпосе. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1967. 244 с.

*Кононов А.Н.* Махмуд Кашгарский и его «Дивану лугат-ит турк» // Советская Тюркология. 1972. № 1. С. 3–17.

*Кононов А.Н.* Родословная туркмен: Сочинение Абу-л-Гази, хана Хивинского. М. – Л., 1958. 193 с.

*Копорский С.А.* О лексико-семантических особенностях наименований (названия кинотеатров) // Мысли о современном русском языке. М.: Наука, 1969. 178–184 с.

*Кормушин И.В.* Тюркские енисейские эпитафии: грамматика, текстология. М.: Наука, 2008. 342 с.

*Королева И.А.* Становление русской антропонимической системы: автореф. дис. … д-ра филол. наук. М., 2000. 56 с.

*Кржижановский С.С.* Поэтика заглавий. М.: Изд-во «Никитинские субботники», 1931. 35 с.

*Крипке С.* Тождество и необходимость // Новое в зарубежной лингвистике. Вып. XIII. М., 1982. С. 27–40.

*Крыкова И.В.* Англоязычные эргонимы и словесные товарные знаки Японии как опосредованное отражение национальной культуры: автореф. дис. … канд. филол. наук. Владивосток, 2004. 24 с.

*Крюкова И.В.* Рекламное имя: от изобретения до прецендентности. Волгоград: Перемена, 2004. 288 с.

*Крючкова М.Я.*Многокомпонентные эргонимы в аспекте орфографии: проблемы совершенствования нормы правописания: автореф. дис. … канд. филол. наук. Волгоград, 2003. 19 с.

*Кторова А.* Сладостный дар: Рассказы об именах, фамилиях и названиях в русской и иноязычной речи. Вашингтон: Изд-во Н.А. Frager & Co, 1990. Вып. 1. 112 с.

*Кубрякова Е.С.*Номинативные комплексы из нескольких существительных и их типовые значения // Коммуникативные аспекты значения: Межвузовский сборник научных работ. Волгоград: Изд-во ВГПИ, 1990. С. 15–23.

*Курбанов А.М.* Основы Азербайджанской ономалогии. Баку: Нурлан, 2004. Т. 2. 504 с.

*Кусимова Т.Х., Бикколова С.А.* Башкирские имена. Уфа: Китап, 2005. 224 с.

*Лайпанов К.Т., Мизиев И.М.* О происхождении тюркских народов. Черкесск: ПУЛ, 1993. 140 с.

*Лангнер А.Н.* Функционально-семантические и словообразовательные особенности прозвищ: автореф. дис. … канд. филол. наук. Белгород, 2010. 25 с.

*Ласынова Н.А*. Оронимия юго-восточного Башкортостана: автореф. дис. … канд. филол. наук. Уфа, 2004. 10 с.

*Леви-Строс К.* Структурная антропология. М.: Наука, 1983. 536 с.

*Лейбниц Г.В.* Сборник писем и материалов Лейбница, относящихся к России и Петру Великому. СПб., 1873. 211 с.

Лызлов А. Скифская история / подг. текста, комментарии, аннотир. указатель имён А.П. Богданов; отв. ред. д.и.н. Е.В. Чистякова. М.: Наука, 1990. 520 с.

*Магазаник Э.Б.* Ономапоэтика или говорящие имена в литературе. Ташкент: Фан, 1978. 146 с.

*Магазаник Э.Б., Ройзензон Л.И.* Ономастилистика и ономапоэтика. Труды Самаркандского ун-та. Самарканд: Изд-во Самарканд. ун-та, 1974. 264с.

Мадеева *Г.Б.* Ономастическое пространство современного Казахстана: структура, семантика, прецедентность, лематизация: автореф. дис. … д-ра филол. наук. Алматы, 2005. 64 с.

*Мазитова Ф.Л.* Историко-лингвистический анализ татарских фамилий: автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 1986. 27 с.

*Малов С.Е.* Памятники древнетюркской письменности (тексты и исследования). М. – Л.: Изд-во АН СССР, 1951. 447с.

*Малов С.Е.* Памятники древнетюркской письменности: Тексты и исследования. М.: Книга по Требованию, 2012. 93 с.

*Малыгин В.* Легенды и географические названия / В. Малыгин // Сибирские огни. 1926. № 4. С. 134.

*Мамай Х.* Аланы в Пиренеях // Тюркология. 2004. № 5. С. 60–62.

*Мартьянова С.А.* Лексика писцовых книг города Казани XVI–XVII вв. // Ученые записки Казанского университета. Казань. Т. 112, кн. 6. 1952. С. 110–115.

*Марченкова Ю.Ю.* Фамилии Рославльского края: синхронический и диахронический аспекты: автореф. дис. … канд. филол. наук. Смоленск, 2006. 26 с.

*Маслова И.Б.* Космонимы и астронимы как ономастические единицы (на материалы тюркского фольклора) [Электронный ресурс]. URL: http://konspektim.ru/ib-maslova/ (дата обращения: 20.12.2017).

*Махпиров В.У.* Древнетюркская ономастика (имена собственных в «Дивану лугат-ит – турк»). Алма-Ата: Гылым, 1990. 159с.

*Маюрова Ж.Д.* Сложные прозвища у бурят: Структура и семантика: автореф. дис. … канд. филол. наук. Иркутск, 2001. 26 с.

*Мечковская Н.Б.* Язык и религия. М.: Агенство «ФАИР», 1998. 352 с.

*Мизиев И.М.* Шаги к истокам этнической истории Центрального Кавказа. Нальчик: Эльбрус, 1986. 184 с.

*Микина Е.Г.* Из истории французской эргонимии. М.: Наука, 1993. 160 с.

*Миннуллин К.М.* Песня как искусство слова: автореф. дис. д-ра филол. наук. Казань, 2001. 56 с.

*Миргалимова З.Ф.* Названия млекопитающих в татарском литературном языке: автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 2007. 22 с.

*Миронюк Л.Ф.* Семантическая типология славянских зооморфических глаголов. Днепропетровск: Днепрепетровский государственный университет, 1987. 80 с.

*Михайлов В.Н.* Собственное имя как стилистическая категория в русской литературе. Луцк: Луцкая областная типография, 1965. 197 с.

*Мокиенко В.М., Фонякова О.И.* Способы называния в зоонимии // Ономастика Поволжья. Вып. 4. Саранск, 1976. С. 317–322.

*Молчанова О.Т.* Структурные типы тюркских топонимов Горного Алтая. Саратов: Изд-во Саратов. ун-та, 1982. 256 с.

*Морковкин В.В., Денисов П.Н.* Словарь сочетаемости слов русского языка. М.: Русский язык, 1983. 688 с.

*Морошкин М.Я.* Славянский именослов. Собрание славянских личных имен. Санкт-Петербург, 1867. 213 с.

*Мурзаев Э.М.* География в названиях. М.: Наука, 1982. 177 с.

*Мурзаев Э.М.*Очерки топонимики. М.: Мысль, 1974. 382 с.

*Мурзаев Э.М.* Тюркские географические названия. М.: Восточная литература, 1996. 254 с.

*Мусаева Р.А.* Кумыкская антропонимика: прозвища и имена: автореф. дис. … канд. филол. наук. Махачкала, 2008. 22 с.

*Мусукаев Б.Х.* О топонимии высокогорья Балкарии. Нальчик. 1980.

*Мухаметзянова Л.Х.* Книжный дастан в творчестве казанских татар // Вестник ТГГПУ. 2011. № 4 (26). С. 247–249.

*Мухаметшин Р.М.* Ислам в Татарстане. М.: Логос, 2007. 96 с.

*Невоструев К. И.* Список писцовых книг по г. Казани с уездов / Издан Советом Казанской духовной академии к IV Археологическому съезду в Казани. Казань: Тип. Имп. ун-та, 1877. 88 с.

*Нейхардт А.А.* Скифский рассказ Геродота в отечественной историографии. Л.: Наука, 1982. 240 с.

*Нестеров В.А.*Населенные пункты Чувашской АССР, 1917–1981 гг.: Справочник об адм.-террит. Делении. Чебоксары: Чуваш. кн. изд-во, 1981. 352 с.

*Ниетбаева К.А.* Историко-лингвистический анализ казахских фамилий: автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 1993. 24 с.

*Никитина С.Е.* Устная народная культура и языковое сознание. М.: Наука, 1993. 189 с.

*Никонов В.А.* Имя и общество. М.: Наука, 1974. 277 с.

*Никонов В.А.* Космонимия Поволжья // Ономастика Поволжья. Материалы XII Международной научной конференции «Ономастика Поволжья». Уфа, 1973. С. 373–382.

*Никулина* З.П. Из наблюдений над группой прозвищ по внешнему признаку // Имя нарицательное и собственное. М.: Наука, 1978. С. 173–180.

*Носенко Н.В.* Названия городских объектов Новосибирска: структурно-семантический и коммуникативно-прагматический аспекты: дис. ... канд. филол. наук. Новосибирск, 2007. 219 с.

*Нуруллина Ф.Ф.* Поэтическая ономастика драматургии Туфана Миннуллина: дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2011. 264 с.

Общее языкознание. Методы лингвистических исследований / под ред. Б.А. Серебрянникова. М.: Наука, 1973. 319 с.

Ономастика Поволжья. Материалы XII Международной научной конференции «Ономастика Поволжья». Уфа, 1973. 432 с.

*Остроумов В.П.* Казань. Очерки по истории города и его архитектуры. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1978.294 с.

*Отин Е.С.*Из истории русской эргонимии // Материалы к серии «Народы и культуры». Вып. XXV: Ономастика. Кн. 1. Имя и культура. М.: Наука, 1993. Ч.1. С.110–123.

*Парфенова Н.Н.* Русские фамилии конца XVI–XVIII вв.: По архивным источникам Зауралья: автореф. дис. … канд. филол. наук. М., 2002. 26 с.

*Пашкевич А.А.* Особенности кличек животных как именных классов / Известия Российского государственного педагогического университета им. А.И.Герцена. 2006. № 19. Т. 2. С. 60–64.

Перечневая книга Свияжского уезда: по материалам писцового описания 1646–1652 годов / под ред. Д.А. Мустафиной. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2004. 168 с.

Писцовая книга Казанского уезда 1602–1603 годов / под науч. ред. И.П. Ермолаева, М.А. Усманова. Казань: Изд-во Казан.ун-та, 1979. 239 с.

Писцовая книга Казанского уезда 1602–1603 годов / под науч. ред. Ермолаева И.П., Усманова М.А. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1978. 239 с.

Писцовая книга Казанского уезда 1647–1656 годов: Публикация текста. М.: Институт Российской истории РАН, 2001. 541 с.

Писцовая книга Казанского уезда 1647–1657 годов / составители: И.П. Ермолаев, Д.А. Мустафина. М., 2001. 540 с.

Писцовое описание Казани и Казанского уезда 1565–1568 годов: Публикация текста / Казан. гос. ун-т; изд. подг. Д.А. Мустафиной. Казань: Изд-во «Фән» Академии наук РТ, 2006. 660 с.

Писцовые книги Казанского уезда 1685–1687 гг.: публикация описаний Зюрейской дороги / изд. подгот. Д.А. Мустафиной. Казань: Казанский государственный университет, 2009. 425 с.

*Плавинская Л.С.* Фамилии рязанского дворянства XVI–XVIII вв. и их отражение в местной топонимии: автореф. дис. … канд. филол. наук. Смоленск, 2013. 26 с.

*Подольская Н.В.*Ономастическое словообразование (сопоставительный анализ на материале восточной онимии): автореф. дис. ... канд. филол. наук. М., 1990. 20 с.

*Подольская Н.В.* Урбанонимия Центральных областей РСФСР // Вопросы географии. М., 1974. № 94. С. 123–129.

*Подольская Н.В., Суперанская А.В.* Терминология ономастики // Вопросы языкознания. 1969. № 4. С. 140–146.

*Полякова Н.А.* Топология поэтической ономастики: на материале английской литературы: дис. ... канд. филол. наук. М., 2009. 178 с.

*Попов А.И.* Названия народов СССР. Введение в этнонимику. Л.: Наука. Ленингр. отд-ние, 1973. 72 с.

*Поротников П.Т.* Из Уральской зоонимии // Восточнославянская ономастика. М.: Наука, 1972.С. 210–251.

*Поставалова В.И.* Картина мира в жизнедеятельности человека // Роль человеческого фактора в языке. Язык и картина мира. М.: Наука, 1988. С. 9-69.

Похозяйственная книга Базарно-Матакского с/с Алькеевского р-на ТАССР.Ф. р-4855. Оп. 2. д. 109 за 1938 г.

*Прманова Н.А.* Ойконимия Казахстана в контексте тюркской языковой картины мира. Казань: Школа, 2011. 180 с.

*Прокуровская Н.А.* Город в зеркале своего языка (на языковом материале г. Ижевска). Ижевск: Изд-во ИГПИ, 1996. 228 с.

*Пропп В.Я.* Исторические корни волшебной сказки. Л.: Изд-во Ленинградского ун-та, 1946. 340 с.

*Пропп В.Я.* Морфология сказки. М.: Наука, 1969. 167 с.

*Пропп В.Я.* Русский героический эпос. М.: Государственное издательство художественной литературы, 1958. 604 с.

*Прюллер П.К.* Эстонская народная астрономия // Историко-астрономические исследования. М., 1966. Вып. 9. 145–169.

*Радлов В.В.* Опыт словаря тюркских наречий. СПб., 1911. Т. 4. 107 с.

*Радлов В.В.* Опыт словаря тюркских наречий. М.: Книга по Требованию, 2011. Т. 1. 555 с.

*Разумов Р.В.* Система урбанонимов русского провинциального города конца XVIII–XX веков: на примере Костромы, Рыбинска и Ярославля: дис. … канд. филол. наук. Ярославль, 2003. 293 с.

*Рамстедт Г.И.* Введение в алтайское языкознание: Морфология. М.: Изд-во вост. лит-ры, 1957. 253 с.

*Рассел Б.*Дескрипции // Новое в зарубежной лингвистике. М.: Радуга, 1982. Вып. 13. С. 41–54.

*Рассел Б.*Философия логического атомизма / пер. с англ. В.А. Суровцева. Томск: Водолей, 1999. 192 с.

*Рашид ад-Дин.* Сборник летописей / пер. с персидского О.И. Смирновой,ред. проф. А.А. Семенова. М.-Л.: Изд-во Академии Наук СССР, 1952. Т. 1, кн. 2. 550 с.

Ревизская сказка Малмыжского помещества. Ф. 3. Оп. 2. № 438.

Ревизская сказка о купцах мещанах и цеховых г. Казани русского и татарского сословиях (1891–1879) // ЦГА РТ. Ф. 3. Оп. 2.

Ревизская сказка о числах душ третьей ревизии Арской дороги Бакиловой, Тимофеева, Шариповой, Кульметьевой, Аптыковой,

Абдулькаримова, Тимкиной, Бикеевой и прочих сотен 1762 г. Ф. 3. Оп. 2. д. №434.

Ревизская сказка Чистопольского духовного правления за 1850. Ф. 3. Оп. 2. № 260.

Ревизские сказки на 1762 г. Ф. 3.Оп. 2. д. № 432.

Ревизские сказки на 1762 г. Ф. 3.Оп. 2. д. № 427.

*Реформатский А.А.* Введение в языковедение / под ред. В.А. Виноградова. М.: Аспект Пресс, 1996, 536 с.

*Рут М.Э.* Принципы номинации некоторых астрономических объектов // Вопросы топономастики / МВ и ССО РСФСР, Урал. гос. ун-т им. А.М. Горького / отв. ред. А.К. Матвеев. Свердловск: УрГУ, 1970. Вып. 4. С. 102–107.

*Рут М.Э.* Русская народная астронимия. Учебное пособие. Свердловск: УрГУ, 1987. 68 с.

*Рут М.Э.*Образная номинация в русской ономастике. М.: Изд-во ЛКИ, 2008. 192 с.

*Рядченко Н.Г.* Зоонимия как особый класс ономастической лексики //Актуальные вопросы ономастики. Киев, 1988. С. 88–97.

*Садыкова Р.К.* Историко-лингвистический анализ тюрко-татарской топонимии Ульяновской области РФ: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2003. 26с.

*Самойлович А.Н.* Богатый и бедный в тюркских языках // Тюркское языкознание. Филология. Руника / Сост. и отв. ред. Г.Ф. Благова, Д.М. Насилов. М.: Восточная литература, 2005. С. 291–330.

*Саттаров Г.Ф.* Булгаризмы в топонимии Татарии и анропонимии казанских татар // Резюме рефератов XV Международного конгресса по ономастике. Лейпциг, 13–17 август, 1984.С. 56.

*Саттаров Г.Ф.* Булгарский пласт топонимии и антропонимии казанских татар // Ономастика Татарии. Казань: КГУ, 1989. С. 5–28.

*Саттаров Г.Ф.*Татарская лексикология и ономастика: отчет о научно-исследовательской работе. Казань: Изд-во Казань ун-та, 1980. 24 с.

*Саттаров Г.Ф.* Отглагольная антропонимия Республики Татарстан // Ономастика Поволжья: Сборник материалов XII Международной научной конференции (Казань, 14–16 сентября 2010 г.). Казань: Отечество, 2010. С. 22–27.

*Саттаров Г.Ф.* Этапы развития и очередные задачи татарской ономастики. Казань: КГУ 1970. 87 с.

*Сафаров П.Р.* Некоторые замечания по узбекской зоонимии // Вопросы ономастики. Горький, 1971. Вып. 2. С. 299–302.

*Севортян Э.В.* Аффиксы именного словообразования в азербайджанском языке. Опыт сравнительного исследования. М.: Наука, 1966. 437 с.

*Селищев А.М.* Из старой и новой топонимии // Избранные труды. М.: Просвещение, 1968. С. 45–96.

*Селищев А.М.* Труды по русскому языку. // Язык и общество. М.: Языки славянской культуры, 2003. 632 с.

*Силаева Г.А.* О содержании понятия «литературный антропоним» // Русская ономастика. Рязань, 1977. С. 152–56.

*Сепеев Г.А.* Восточные марийцы: Историко-этнографическое исследование материальной культуры. Йошкар-Ола: Марийск. кн. изд-во, 1975. 247 с.

*Серебренников Б.А.* Происхождение марийского народа по данным языка // Происхождение марийского народа. Йошкар-Ола, 1957. С. 165-180.

*Смирнов А.А.* Из зоонимии Горьковской области // Ономастика Поволжья. Горький, 1971. Вып. 2. С. 299–302.

*Смирнова Т.Г.* Фамилии Тамбовской области в антропонимической системе языка: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Тамбов, 2003. 26 с.

*Спасский Н.А.* Очерки по родиноведению. Казанская губерния. Казань: Типо-лит.Имп. ун-та, 1910. 165 с.

Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков. Лексика: 2-е изд., доп. М.: Наука, 2001. 822 с.

Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков. Пратюркский язык-основа. Картина тюркского этноса по данным языка / отв. ред. Э.Р. Тенишев, А.В. Дыбо. М.: Наука, 2006. 908 с.

*Сталмане В.Э.* Ономастическая лексикография. М.: Наука, 1989. 113 с.

Становление и расцвет Золотой Орды. Источники по истории Улуса Джучи (1266 – 1359 гг.). Казань: Татар. кн. изд-во, 2011. 438 с.

*Старостин С.А.* Труды по языкознанию. М.: «Языки славянских культур», 2007. С. 779–793.

*Стебелева И.В.* Поэзия тюрков VI–VIII веков. М.: Наука, 1965. 147 с.

*Султанова А.Ш.* История становления и развития башкирской поэтической ономастики // Вестник Оренбургского государственного университета, 2016. № 7 (195). С. 60–65.

*Султаньяев О.А.* Топонимика Кокчетавской области: автореф. дис. … канд.филол. наук. Томск, 1969. 30 с.

*Сум П.Ф.* Исторические рассуждения о происхождении народов, населявших в средние века Польшу, Россию и земли между Каспийским и Черным морем, а также Европейскую Турцию на севере от Дуная. М., 1846. Часть «О хазарах». 57 с.

*Сунчелей Б., Гаффарова Г.* Письменные источники о космологических воззрениях, верованиях, обычаях и обрядах древних тюрок // Гасырлар авазы – Эхо веков. 2005. № 2. С. 312–319.

*Суперанская А.В.*Общая теория имени собственного. М.: Наука, 1973. 420 с.

*Суперанская А.В.* Апеллятив-онома // Имя нарицательное и собственное: Сб. науч. ст. / Отв. ред. А.В. Суперанская. М.: Наука, 1978. С. 5–33.

*Суперанская А.В.* Лингвистический аспект ономастических исследований // Вопросы ономастики. Самарканд, 1976. Вып. 3. С. 5–12.

*Суперанская А.В.* Общая теория имени собственного. М.: Наука, 1973. 234 с.

*Суперанская А.В*. Общая теория имени собственного. М.: Книжный дом «ЛИБРОКОМ», 2012. 368 с.

*Суперанская А.В.* Ономастические универсалии // Восточнославянская ономастика. М: Наука, 1972. С. 346–356.

*Суперанская А.В.* Применение метода лингвистической статистики к изучению топонимической системы г. Москвы // Лингвистическая терминология и прикладная топономастика. М.: Наука, 1964. С. 119–134.

*Суперанская А.В.* Прописная и строчная буква в собственных именах разных категорий. Орфография собственных имен. М., 1965. 206 с.

*Суперанская А.В.* Структура имени собственного. Фонология и морфология. М.: Наука,1969. 206 с.

*Суперанская А.В.* Типология именования внутригородских объектов Москвы // Географические названия в Москве. Серия «Вопросы географии». М.: Мысль, 1985. С. 160–170.

*Суперанская А.В.* Что такое топонимика? М.: Наука, 1984. 182 с.

*Суперанская А.В., Сталтмане В.Э., Подольская Н.В., Султанов А.Х.* Теория и методика ономастических исследований. Издание третье. М.: Книжный дом «ЛИБРОКОМ», 2009. 256 с.

*Суперанская А.В., Сталтмане В.Э. и др.* Теория и методика ономастических исследований. Изд. 2-е. М.: ЛКИ, 2007. 256 с.

*Супрун В.И.* Ономастическое поле русского языка и его художественно-эстетический потенциал. Волгоград: Перемена, 2000. 172 с.

*Супрун В.И.* Художественно-эстетический потенциал ономастического поля русского языка // Лингвистика на рубеже веков: актуальные проблемы и новые подходы: кол. моногр. В 2 ч. / под общ. ред. Е.В. Брысиной, Е.Б. Никифоровой. Волгоград: Перемена, 2012. Ч. 2. С. 4–59.

*Сызранова Г.Ю.* Ономастика: учеб. пособие. Тольятти: Изд-во ТГУ, 2013. 248 с.

Татарское народное творчество. Сказки о животных и волшебные сказки: в 15-и томах Казань: Раннур, 1999. Т.1. 350 с.

Татарское народное творчество. Волшебные сказки: в 15-и томах. Казань: Раннур, 2001. Т. 2. 400 с.

Татар шәҗәрәләре тарихы. Казан: Яңалиф, 2003. 104 б.

*Татищев В.Н.* История Российская. М. – Л., 1962. Т. 1. 500 с.

*Ташицкий В.* Место ономастики среди других гуманитарных наук // Вопросы языкознания. 1961. № 2. С.3–11.

*Тенишев Э.Р.* О методах и источниках сравнительно-исторических исследований тюркских языков // Советская тюркология. № 5. 1973. С. 119–124.

Теория и методика ономастических исследований. М.: Наука, 1986. 256 с.

*Тепляшина Т.И.* Еще раз о топоформанте -ым (-им) // Ономастика. М.: Наука, 1969. С. 216–220.

*Тепляшина Т.И.* Язык бесермян. М.: Наука, 1970. 288 с.

*Тимерханов А.А.* Язык и стиль татарского документа. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2005. 312 с.

*Тимирханова Г.С.* Антропонимия татар г. Набережные Челны Республики Татарстан в XX веке: на примере личных имен и фамилий: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Елабуга, 2002. 25 с.

*Токмашев Д.М.*Антропонимы в шорском героическом эпосе: Сравнительно-исторический аспект: дис. ... канд. филол. наук. Новокузнецк, 2005. 220 с.

*Толстая С.М.* Пространство слова. Лексическая семантика в общеславянской перспективе. М.: Индрик, 2008. 527 с.

*Толстой Н.И.* Еще раз о «семантике» имени собственного // Избранные труды. Т.1. Славянская лексикология и семасиология. М.: Языки славянской культуры, 1997. С.395–397.

*Толстой Н.И., Толстая С.М.* Славянская этнолингвистика: вопросы теории. М.: Институт славяноведения РАН, 2013. 240 с.

*Топоров В.Н.* Исследования в области славянских древностей: Лексические и фразеологические вопросы реконструкции текстов. М.: Наука, 1974. 342 с.

*Топорова Т.В.* Язык в зеркале культуры: древнегерманские двучленные имена собственные. М.: Школа «Языки русской культуры», 1996. 253 с.

*Тортунова И.А.* Эргоним как результат речетворчества // Научный диалог, 2012.№ 3. Филология. С. 124–137.

*Трофимова У.М., Трофимова М.* О некоторых принципах наименования животных (на материале кличек кошек и собак г. Бийска) // Актуальные проблемы современного словообразования. Кемерово, 2011. С. 508–511.

*Тураева А.Р.* Социолингвистический и структурно-семантический аспекты эргонимических комплексов на юге Великобритании и России: дис. ... канд. филол. наук. Пятигорск, 2012. 251 с.

*Унбегаун Б.О.* Русские фамилии / Под общ.ред. Б.А. Успенского. М.: Прогресс, 1989. 444 с.

*Усманова М.Г.* Имя отчей земли. Историко-лингвистическое исследование топонимии бассейна реки Сакмар. Уфа: Китап, 1994. 272 с.

*Урманче Ф.* Тюркский героический эпос. Казань: ИЯЛИ, 2015. 448 с.

*Урманчеев Ф.И.* Имя эпического героя // Советская тюркология. 1986. № 4. С. 22–34 .

*Урманчеев Ф.И.* Сказание «Йир Тюшлюк» у тюркоязычных народов // Советская тюркология. 1978. № 1. С. 53–63.

*Урманчеев Ф.И.* Традиции тюркского эпоса в сказании «Джик мэрген» // Советская тюркология. 1980. № 4. С. 34–42.

*Урманчеев Ф.И.* По следам Белого волка. Ранние этнокультурные взаимосвязи тюрко-татарских племен. Казань: ИЯЛИ, 1994. С. 125.

*Урманчеев Ф.И.* Эпические сказания татарского народа. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1980. 118 с.

*Ушакова Н.Н.* Прозвища и личные неофициальные имена (К вопросу о границах прозвища) // Имя нарицательные и собственное. М.: Наука, 1978. С.146–173.

*Фахрутдинов Р.Г., Фахрутдинов Р.Р.* История татарского народа. Казань: Татар. кн. изд-во, 2015. 407 с.

*Фахрутдинов Р.Г.* История татарского народа и Татарстана. Казань: Магариф, 1995. 255 с.

*Федоров Я.А., Федоров Г.С.* Ранние тюрки на Северном Кавказе. М., 1978.

*Филькова А.Ю.* Историко-лингвистический анализ полисонимов тюркского происхождения РСФСР: дис.... канд. филол наук. Казань, 1989. 227 с.

*Фомин А.А.*Литературная ономастика в России: итоги и перспективы // Вопросы ономастики. 2004. № 1. С. 108–120.

*Фомин А.А.* Всегда ли литературная ономастика тождественна поэтической ономастике? // Вопросы ономастики. 2009. № 7. С. 57–68.

*Фонг Ф.В.* Вторая жизнь антропонимов в эргонимах // Русский язык за рубежом. 2009. № 6. С. 44–45.

*Фонякова О.И.* Имя собственное в художественном тексте. Л.: ЛГУ, 1990. 103 с.

*Фреге Г.* Логические исследования. Томск: Водолей, 1997. 127 с.

*Фреге Г.*Смысл и денотат // Семиотика и информатика. № 8. 1977. С. 181–210.

*Фролов Н.К.* Избранные работы по языкознанию : в 2 т. Тюмень: Изд-во Тюм. гос. ун-та, 2005. Т. 1: Антропонимика. Русский язык и культура речи. 512 с.

*Фролов Н.К.* Русские антропонимы в пространстве отечественной лексикографии // Виноградовские чтения: материалы Всерос. науч.-практ. конф. Тобольск, 2005. С. 183–184.

*Фукс К.Ф.* Казанские татары в статическом и этнографическом отношениях. Казань: Фонд ТЯК, 1991. 210 с.

*Хадиева (Закирова) Г.К.* Историко-лингвистический анализ ойконимии Казанского ханства: автореф. дис. ... канд. филол наук. Казань, 1998. 23 с.

*Хадиева Г.К.* Ойконимия периода Казанского ханства (по писцовым книгам). Казань:КГУ, 2004. 196 с.

*Хазиев Р.И.* Историко-лингвистический анализ ойконимии Юго-Восточного Закамья Татарстана: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2000. 26с.

*Хазиева Г.С.* Историко-лингвистический анализ татарских мужских личных имен: автореф. дис. ... канд. филол наук. Казань, 2007. 23 с.

*Хазиева-Демирбаш Г.С.* Антропонимическое пространство татарских и турецких загадок // Вестник Челябинского государственного университета. 2014. № 3. С. 128–130.

*Хазиева-Демирбаш Г.С.* Изучение онимов в тюркской фольклорной ономастике // Филологические науки. Вопросы теории и практики. Тамбов: Грамота. 2016. № 6. Ч. 1. С. 174–176.

*Хазиева-Демирбаш Г.С.* Татарские личные имена в этнокультурном пространстве языка. Казань: Магариф – Вакыт, 2017. 444 с.

*Хайруллин М.Б.* Проблемы развития лексической системы татарского литературного языка. Казань: Таң – Заря. 2000. 204 с.

*Хакимзянов Ф.С.* Язык эпитафий волжских булгар. М.: Наука, 1978. 206 с.

*Халыгов Ф.Р.* Фольклорная ономастика азербайджанского языка: автореф. дис. ... д-ра филол. наук. Баку, 2004. 55 с.

*Ханичев Р.З.* Сопоставительная характеристика процессов деонимизации в русском и английском языках: автореф. дис. ... канд. филол наук. М., 2004.26 с.

*Хвольсон Д.А.* Известия о хазарах, буртасах, болгарах, мадьярах, славянах и русских Абу-Али Ахмеда бен Омар ибн Даста, неизвестного досель арабского писателя начала X веков. СПб., 1868.

*Хисамитдинова Ф.Г.* Избранные труды. Ономастика. Том II. Уфа: ИИЯЛ УНЦ РАН, 2016. 374 с.

*Хисамитдинова Ф.Г.* Лексико-семантическая классификация названий населенных пунктов (по материалам «Топографии Оренбургской») // Вопросы топонимики Башкирии. Уфа, 1981. С. 29–40.

*Хисамов О.Р.* Историко-лингвистический анализ ойконимии Западного Закамья Татарстана: автореф. дис. ... канд. филол наук. Казань, 2001. 20 с.

*Хисамов О.Р.* Тюрко-татарская топонимия Томской области // Милли-мәдәни мирасыбыз. Томск өлкәсе татарлары. Казан: ИЯЛИ, 2016. С. 11–52.

*Хожалепесова Ю.Н.* Прозвища в системе каракалпакской антропонимии: автореф. дис. ... канд. филол наук. Нукус, 1996. 26 с.

*Храпченко М.Б.* Художественное творчество, действительность, человек // Сборник сочинений. М., 1982. С. 328.

*Хусаинова, Л.М.* Башкирская ономастика: микротопонимия, поэтическая ономастика. Стерлитамак: РИО СФ БашГУ, 2014. 120 с.

*Хуснуллина З.М.* Историко-лингвистический анализ татарских фамилий г. Казани: автореф. дис. ... канд. филол наук. Казань, 2006. 22 с.

*Черниховская Е.М.* История разработки топонимических классификаций // Развитие методов топонимических исследований. М.: Наука, 1970. С.55–65.

*Чернышев Е.И.* Селения Казанского ханства (по писцовым книгам) // Вопросы тюркоязычных народов Среднего Поволжья. Казань, 1971. С. 284–292.

*Чернышев Е.И.* Селения Казанского ханства (по писцовым книгам) // Исторические судьбы народов Поволжья и Приуралья. Казань, 2014. С. 264–302.

*Чучка П.П.* О венгерских антропонимах и зоонимах в украинских говорах Закарпатья // Вопросы финно-угорского языкознания. Вып. 3. М.: Наука, 1965. С. 78–85.

*Шайхулов А.Г.* Татарские и башкирские личные имена тюркского происхождения. Уфа: Изд-во БГУ, 1983. 72 с.

*Шайхулов А.Г., Раемгужина З.М.* Башкирские и татарские имена собственные. Уфа: БГУ, 2006. 90 с.

*Шакуров Р.З.* Топони бассейна р. Демы. дис. …канд. филол. наук. М., 1973.

*Шарафутдинов Д.Р., Тагиров Э.Р.* Основные формы календарных праздников: идейно-мировоззренческие и космологические основы // Сабантуй в локальном и глобальном цивилизационном пространстве (Потенциал идей культуры мира в традиционных праздниках народов планеты). Казань: Центр оперативной печати, 2004. Разд. 2, 3. С. 15–47.

*Шарафутдинов Д., Шириязданова И.* Письменные источники о космологических воззрениях, верованиях, обычаях и обрядах древних тюрок // Гасырлар авазы. – Эхо веков. 2008. № 2. С. 311–317.

*Шведова Н.Л.* Функциональная специфика прагматонимов (на материале современной массовой литературы): автореф. дис. … канд. филол. наук. Волгоград, 2011. 25 с.

*Шевчик А.В.* Комплексное мотивологическое исследование зоонимов русского языка: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Томск, 2011. 20 с.

*Шмелева Т.В.* Ономастика Учебное пособие. Славянск-на-Кубани: ИЦ филиала ФГБОУ ВПО «КубГУ» в г. Славянске-на-Кубани, 2013. 161 с.

*Шостка Е.С.* Прозвища Тамбовской области: языковой и социокультурный аспект: автореф. дис. … канд. филол. наук. Тамбов, 2009. 26 б.

*Шпар Т.В.* Прозвищные антропонимические номинации в социолингвистическом аспекте: автореф. дис. … канд. филол. наук. Уфа, 2012.26 с.

*Шпилевский С.М.* Древние города и другие булгаро-татарские памятники в Казанской губернии. Казань, 1877. 585 с.

*Щетинин Л.М.* Слова, имена, вещи. Очерки об именах. Ростов-на-Дону: Изд-во Рост. ун-та, 1966. 119 с.

*Щетинин Л.М.*Имена и названия. Ростов-на-До-ну: Изд-во Рост. ун-та, 1968. 215 с.

*Эйхвальд Э.И.* О древнейших обиталищах всех племен славянских, финских, турецких и монгольских в Южной России по Геродоту // Библиотека для чтения. Т. 27. СПб., 1838.

*Эседов А.А.* Отраслевая лексика лезгинского языка: названия животных и птиц: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Махачкала, 2003. 22 с.

Этнонимы: Сборник статей / Институт этнографии им. Н.Н. Миклухо-Маклая АН СССР; Отв. ред. В.А. Никонов. М.: Наука, 1970. 271 с.

*Юдин А.В.* Ономастикон восточнославянских загадок. М.: ОГИ, 2007. 120 с.

*Юсифов Ю.Г.* Зоологическая лексика азербайджанского языка (на основе фитонимов): автореф. дис. ... канд. филол. наук. Баку, 1985. 20 с.

*Юсупов Г.В.* Булгаро-татарская эпиграфика и топонимика как источник исследования этногенеза казанских татар // Вопросы этногенеза тюркоязычных народов Среднего Поволжья. Казань, 1971. С. 217–231.

*Юсупов Г.В.* Ведение в булгаро-татарскую эпиграфику. М. – Л.: Изд-во АН СССР, 1960. 165 с.

*Юсупов Р.А.* Проблемы культуры родной речи в условиях развивающегося двуязычия // Современные языковые процессы в Республики Татарстан и Российской Федерации: законодательство о языках в действии. Казань: Татар. кн. изд-во, 1996. С. 73–79.

*Юхма М.Н.* Заметки о чувашской космонимии // Восточная ономастика. М.: Наука, 1980. 264 с.

Языки мира: тюркские языки. М.: Издательский дом «Кыргызстан», 1997. 543 с.

*Янко-Триницкий Н.А.* Собственные наименования предметов // Русский язык в школе. 1997. № 6. С. 93–97.

## Чит телдә

*Abdrakhmanova A.A., Galiullina G.R., Khadieva G.K.* The national mindset verbalization through the Tatar pragmatonims // Journal of Language and Literature. 2016. Vol. 7. No. 1. PP. 190–193.

*Aksan D.*Her yönüyle dil. Ana çizgileriyle dilbilim. Ankara: Türk Dil Kurumu, 2000.

Azerbaycan kişi adları. / M.N. Çobanov; haz. Cengiz Alyılmaz. Erzurum: Atatürk Üniversitesi Türkiyat Araştırmaları Enstitüsü, 1993. 88 s.

*Binark N., Arslanbek S.* Tanzimattan bugüne Türk yazı hayatında takma adlar indeksi. Ankara: Türk Kütüphaneciler Derneği, 1971. 34 s.

*Çobanov M.N.*, *Alyılmaz C.* Azerbaycan kişi adları. Erzurum: Atatürk Üniversitesi Türkiyat Araştırmaları Enstitüsü, 1993. 88 s.

*Elçin Ş.* Halk edebiyatına Giriş. Ankara: Feryal Matbaası, 1998. 762 s.

*Erol A*. Adlarımız. Istanbul: Turan Kültür Vakfi, 1999. 610 s.

*Doerfer G.* Türkische und mongilische Elemente im Neupersischen. Wiesbaden. T. I, 1963; T. II, 1965; T. III, 1967.

*Durmuş I.* Iskıtler (sakalar). Ankara, 1993. 168 s.

*Januzaqov J., Esbayeva K.S.* Kazak Türklerinde kişi adları. Ankara: Türk Dil Kurumu, 2003. 102 s.

*Kafesoglu I.* Ogurlar // Turk Diinyasi El Kitabi. Birinci Cilt. Ankara, 1992. 156–159 s.

*Kenan Karacanlar Y.* Takma adlar. İstanbul: Tüm Yayınlar, 1977. 143 s.

*Kibar O.* Türk Kültüründe Ad Verme: Kişi Adları Üzerine Bir Tasnif Denemesi. Ankara: Akçağ yayınları, 2005. 239 s.

*Kuun Geza*. Codex Cumanicus. Budapest: Oriental Reprints. 1981. 54, CXXXIV, 395 oldal.

*Mordtmann A.D.* Über die Keilinschriften sweiter Gattung // Zeitschrift der Deutschen morgenländischen Gesellschaft – XIV, 1870. (http://menadoc.bibliothek.uni-halle.de/dmg/periodical/structure/2327)

*Niebuhr B.G.*Vorträge über alte Geschichte, 3 Bde., hrsg. v. Marcus Niebuhr, Berlin; 1. Bd., 1847. 444 p.

*Şahin İ.* Adbilim (Çerçeve, Terim, Yöntem ve Sınıflandırmalarıyla). Ankara: Pigem Akademi, 2016. 155 s.

*Sakaoğlu S.* Türk Ad Bilimi. Ankara: Türk Dil Kurumu, 2000. 150 s.

*Semih M.* Türk edebiyatında mahlaslar, takma adlar, tapşırmalar ve lakaplar. İstanbul: Anahtar Kitaplar Yayınevi, 1993. 84 s.

Takma adlar / Y. Kenan Karacanlar. İstanbul: Tüm Yayınlar, 1977. 143 s.

Tanzimattan bugüne Türk yazı hayatında takma adlar indeksi / Naile Binark, Saide Arslanbek. Ankara: Türk Kütüphaneciler Derneği, 1971. 34 s.

*Tekin T.* Orhon Yazıtları. Ankara: Türk Dil Kurumu, 2008. 200 s.

*Zeki Velidi Tjgan*. Umumi Türk Tarihine giriş. 3 baskı. Istanbul. 538 s.

*Zekiev M.Z.* Turklerin ve Tatarlain kőkeni. Istanbul, 2006. 520 s.

*Агасыоглу Ф.* Азер халгы.Баку, 2000. 249 б.

*Жанузак Т.* Есімдер сыры. Алмааты, 2004. 208 б.

*Жапаров Ш.* Адам аттары – эл байлыгы. Бишкек: “Текник” ББ, 2009. 560 б.

*Чучка П.П.* Слов’янське / неслов’янське в зоонiмiі Закарпаття // Українська славістична конференція. Чернівці, 1964. С. 61–63.

**Сүзлекләр**

*Абаев В.И.* Историко-этимологический словарь осетинского языка. М. – Л.: Изд-во Академии наук СССР, 1958. 658 с.

*Али-заде А.* Исламский энциклопедический словарь. М.: Ансар, 2007. 400 с.

*Әхмәтьянов Р.Г.* Татар теленең этимологик сүзлеге: 2 томда. Казан: Мәгариф – Вакыт, 2015. Т. 1. 543 б.; 2015. Т. 2. 567 б.

*Галеев М.С., Тимергалин А.К.* Русча-татарча астрономик терминнар сүзлеге. Казан: Татар. кит. нәшр., 1974. 64 б.

Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге: татар әдәбиятында кулланылган гарәп һәм фарсы сүзләре / К.З. Хәмзин, М.И. Мәхмүтов, Г.Ш. Сәйфуллин. Казан: Татар. кит. нәшр., 1965. 853 б.

*Гарипова Ф.Г.* Татарстан гидронимнары сүзлеге. Первая книга. Казань, 1984. 225б.

Древнетюркский словарь / авторы-сост. Т.А. Боровкова, Л.В. Дмитриева и др.; под ред. В.М. Наделяева, Д.М. Насилова и др. Л. Наука, 1969. 677 с.

*Егоров В.Г.* Этимологический словарь чувашского языка. Чебоксары: Чувашский государственный институт гуманитарных наук, 1964. 355 с.

*Епишкин Н.И.* Исторический словарь галлицизмов русского языка. М.: ЭТС, 2010. 5140 с.

Диалектологик сүзлек. Казан: Татар. кит. нәшр., 1958. 260 б.

Ислам. Белешмә сүзлек. Казан: Татар. кит.нәшр. 191 б.

*Кошгарий М.* Туркий сузлар девони (Девону луготит турк). Тошкент, 1960. Т. 1. 499 б.; 1961. Т. 2. 427 б.; 1963. Т. 3. 463 б.

Марийско-русский словарь / авт. сост. А.А. Асылбаев, В.М. Васильев, П.Б. Рыбаков и др. М.: ГИИНС, 1956. 863 с.

*Махмуд ал-Кашгари.* Диван лугат ат-турк (Свод тюркских слов): в 3 т. / пер. с араб. А.Р. Рустамова, под ред. И.В. Кормушина, прим. И.В. Кормушина, Е.А. Поцелуевского, А.Р. Рустамова; Институт вос-

токоведения РАН: Институт языкознания РАН. М.: Восточная литература, 2010. Т.1. 461 с.

*Махмуд ал-Кашгари*. Диван Лугат ат-Турк / перев. З-А.М. Ауезовича. – Алматы: Дайк-Пресс, 2005. 1288 с.

*Молчанова О.Т.* Топонимический словарь Горного Алтая. Горно-Алтайск: Горно-Алтайское отд. Алтайского кн. изд-ва, 1979. 398 с.

*Мурзаев Э.М.* Словарь народных географических терминов. М.: Мысль, 1984. 654 с.

Мусульманские имена. Словарь-справочник. СПб.: Диля, 2007. 448 с.

Населенные пункты Республики Татарстан: Краткий справочник. Казань: Институт Татарской энциклопедии АН РТ, 1997. 390 с.

Персидско-русский словарь / сост. Б.В. Миллер. 3-е изд. М.: ГИС, 1960. 668 с.

*Подольская Н.В.* Словарь ономастической терминологии. М.: Наука, 1978. 256 с.

*Подольская Н.В.* Словарь русский ономастической терминологии. М.: Наука, 1988. 135 с.

*Поспелов Е.М.* Топонимический словарь. М.: ООО «Изд-во Астрель»: ООО Изд-во АСТ», 2002. 229 с.,

Русско-киргизский словарь / под ред. К.Х. Юдахина. М.: ГИИНС, 1957. 891 с.

*Саттаров Г.Ф.* Татар исемнәре ни сөйли? Казан: Раннур, 1998. 486 б.

*Саттаров Г.Ф.* Татар исемнәре сүзлеге. Казан: Татар. кит. нәшр., 1981. 256 б.

*Севортян Э.В.* Этимологический словарь тюркских языков: Общетюркские и межтюркские основы на гласные. М.: Наука, 1974. Т. 1. 768 с; 1978. Т. 2. 349 с; 1980. Т. 3. 395 с.

Справочник личных имен народов РСФСР. 4-е изд.: М.: Наука., 1989. 654 с.

Справочник личных имен народов РСФСР / под ред. А.В. Суперанской (отв. ред.), Ю.М. Гусева. 2-е изд., перераб. и доп. М:. Русский язык, 1979. 576 с.

Сравнительный словарь тунгусо-маньчжурских языков / авт. сост. А.В. Горцевская, В.Д. Колесникова, О.А. Константинова. В 2 томах. М.: Наука, Т. 1. 1975, т.2. 1977.

*Суперанская А.В.*Словарь русских личных имён. М.: АСТ, 1998. 528 с.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Казан: Матбугат йорты, 2005. 848 б.

Татар теленең зур диалектологик сүзлеге / төз.: Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, З.Р. Садыйкова, Т.Х. Хәйретдинова. Казан: Татар.кит. нәшр., 2009. 836 б.

Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек: 3 томда: / төз. Фатих Урманче. Казан: Мәгариф, 2008.Т. 1. 303 б.

Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек: 3 томда: / төз. Фатих Урманче. Казан: Мәгариф, 2009. Т. 1. 343 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге/ ред. Ф.Ф. Гаффарова, Г.Г. Саберова, Ф.И. Таһирова: Казан: ТӘһСИ, 2015. Т. 1: А–В. 712 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге / ред. Ф.Ә. Ганиев, К.С. Миннибаев, Ф.М. Газизова, Г.Г. Саберова, Ф.Ф. Гаффарова. Казан: Матбугат йорты, 2005. 848 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: 3 томда / төз.: И.А. Абдуллин, Г.Х. Ахунҗанов, Ф.М. Газизова. Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. Т. 1. 475 б.; Т. 2 / төз.: И.А. Абдуллин, Г.Х. Ахунҗанов, С.Б. Вахитова. Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. 726 б.; Т. 3 / төз.: И.А. Абдуллин, С.Б. Вахитова, Ф.М. Газизова. Казан: Татар. кит. нәшр., 1981. 832 б.

Татар теленең диалектологик сүзлеге. Казан, 1969.

Татар теленең зур диалектологик сүзлеге / төз.: Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, З.Р. Садыйкова, Т.Х. Хәйретдинова. Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. 839 б.

Татарско-русский словарь личных имен и фамилий = Татарча-русча кеше исемнәре һәм фамилияләр сүзлеге / авт.-сост. Г.Ф. Саттаров, Р.Г. Ахметьянов, Ф.А. Ганиев и др. Казань: Татар. кн. изд-во, 2006. 375 с.

Татарско-русский словарь: В 2-х. Т. 1 (А–Л). Казань, Алма-Лит, 2007. 727 с.

Татар энциклопедия сүзлеге.Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. 839 б.

Татарская энциклопедия: в 6 т. / Гл. ред. М.Х. Хасанов, ред. Г.С. Сабирзянов. Казань: Институт Татарской энциклопедии АН РТ, 2008, Т. 4: М–П. 768 с.

Татарская энциклопедия: в 6 т. / гл. ред. М.Х. Хасанов., ответ. Ред. Г.С. Сабирзянов. Казань: Институт Татарской энциклопедии АН РТ, 2010. Т. 5: Р-–Т. 2010. 736 с.

Татарская энциклопедия: в 6 т. / гл. ред. А.М. Мазгаров, ответ. ред. Г.С. Сабирзянов. Казань: Институт Татарской энциклопедии АН РТ, 2014. Т. 6: У–Я. 720 с.

*Тимергалин А.К.* Миллият сүзлеге. Казан: Мәгариф, 2007. 575 б.

*Тумашева Д.Г.* Словарь диалектов сибирских татар. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1992. 255 с.

*Хисамитдинова Ф.Г.* Мифологический словарь башкирского. М.: Наука, 2010. 456 с.

*Фасмер М*. Этимологический словарь русского языка: в 4-х т. / пер. с нем. 2-е изд., стереотип. М.: Прогресс, 1987. Т. 3. 832 с.

Энциклопедический словарь-справочник лингвистических терминов и понятий. Русский язык: в 2-х томах / сост. А.Н. Тихонов, Р.И. Хашимов, Г.С. Журавлева и др.; под общ. ред. А.Н. Тихонова, Р.И. Хашимова. М.: Флинта: Наука, 2008. Т. 1. 820 с.

Языкознание. Большой энциклопедический словарь / гл. ред. В.Н. Ярцева. 2-е изд. М.: Большая Российская энциклопедия, 2000. 688 с.

*Dilçin C.* Adlar sözlüğü. İstanbul: Kültür Yayınları, 2014. 440 s.

https://ru.wikipedia.org

*Kaşgarlı M.* Divanü Lügat-it-Türk. Çev. B. Atalay. Çilt 4. Ankara, 2006. 530 p.

*Kaşgarlı M.* Divanu Lugat-it-Türk Tercumesi. 3 baski. IV cilt. Ankara: «Endeks», 1992. 887 s.

Башкорт һөйләштәренең һүзлеге. Өфө, 1970. Т. 2. 327 б.

КЫСКАРТЫЛМАЛАР

ДС – Диалектологик сүзлек. Казан: Татар. кит. нәшр., 1958. 260 б.

ДТС – Древнетюркский словарь / авторы-сост.: Т.А. Боровкова, Л.В. Дмитриева и др.; под ред. В.М. Наделяева, Д.М. Насилова и др. Л. Наука, 1969. 677 с.

ГТРАС – Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге: татар әдәбиятында кулланылган гарәп һәм фарсы сүзләре / К.З. Хәмзин, М.И. Мәхмүтов, Г.Ш. Сәйфуллин. Казан: Татар. кит. нәшр., 1965. 853 б.

ТТАС – Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: 3 томда / төз.: И.А. Абдуллин, Г.Х. Ахунҗанов, Ф.М. Газизова. Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. Т. 1. 475 б.; Т. 2 / төз.: И.А. Абдуллин, Г.Х. Ахунҗанов, С.Б. Вахитова. Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. 726 б.; Т. 3 / төз.: И.А. Абдуллин, С.Б. Вахитова, Ф.М. Газизова. Казан: Татар. кит. нәшр., 1981. 832 б.;

ТТАС – Татар теленең аңлатмалы сүзлеге / ред. Ф.Ә. Ганиев, К.С. Миннибаев, Ф.М. Газизова, Г.Г. Саберова, Ф.Ф. Гаффарова. Казан: Матбугат йорты, 2005. 848 б.;

ТТАС – Татар теленең аңлатмалы сүзлеге / ред. Ф.Ф. Гаффарова, Г.Г. Саберова, Ф.И. Таһирова: Казан: ТӘһСИ, 2015. Т. 1: А–В. 712 б.

ТТДС – Татар теленең диалектологик сүзлеге. Казан, 1969.

ТТЗДС – Татар теленең зур диалектологик сүзлеге / төз.: Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, З.Р. Садыйкова, Т.Х. Хәйретдинова. Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. 839 б.

ЭЧТӘЛЕК

КЕРЕШ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 5
Татар ономастикасы фәненә кереш . . . . . . . . . . . . . . . 8
§ 1. Ономастика фәне турында төшенчә, аның өйрәнү объекты һәм юнәлешләре . . . . . . . . . . . . . . . . . 8
§ 2. Ялгызлык исемнәренең семантик һәм функциональ үзенчәлекләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 19
ТАТАР АНТРОПОНИМИКАСЫ . . . . . . . . . . . . . . . . 29
§ 3. Татар антропонимикасын өйрәнү тарихы . . . . . . . . . 29
§ 4. Антропонимика фәненә гомуми билгеләмә . . . . . . . . 40
Татар кеше исемнәре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 46
§ 5. Татар кеше исемнәренең генетик катламнары . . . . . . 49
§ 6. Татар халкында исем бирү мотивлары . . . . . . . . . . 60
§ 7. Татар кеше исемнәренең төзелеш-ясалышында төп үзенчәлекләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 79
§ 8. Татар кеше исемнәренең орфографиясе һәм транслитерация мәсьәләсе . . . . . . . . . . . . . . . . 84
Татар фамилияләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 90
§ 9. Татар фамилияләренең формалашу тарихы . . . . . . . . 90
§ 10. Татар фамилияләренең төзелеш-ясалышында төп үзенчәлекләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 96
§ 11. Татар фамилияләренең орфографиясе һәм транслитерация мәсьәләсе . . . . . . . . . . . . . . . 100
Татар кушаматлары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 103
§ 12. Кушаматларның төрләре . . . . . . . . . . . . . . . . . 103
§ 13. Татар халкында кушамат бирү мотивлары . . . . . . 110
ТАТАР ТОПОНИМИКАСЫ . . . . . . . . . . . . . . . . . . 115
§14. Топонимика фәненә гомуми билгеләмә . . . . . . . . . 115
§ 15. Топонимика фәненең тармаклары . . . . . . . . . . . . 120
Татар гидронимикасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 125
§ 16. Татар гидронимиясен өйрәнү тарихы . . . . . . . . . 125
§ 17. Гидронимик терминнар . . . . . . . . . . . . . . . . . 132

§ 18. Татар гидронимнарының этнолингвистик
катламнары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 141
§ 19. Татар гидронимнарын номинацияләү принциплары . 154
§ 20. Татар гидронимнары төзелеш-ясалышында
төп үзенчәлекләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 162
Татар ойконимикасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 168
§ 21. Татар ойконимикасын өйрәнү тарихы . . . . . . . . . 168
§ 22. Ойконимик терминнар һәм аларның орфографиясе . . 177
§ 23. Татар ойконимнарының этнолингвистик
катламнары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 192
§ 24. Татар ойконимнарын номинацияләү принциплары . . 206
§ 25. Татар ойконимнары төзелеш-ясалышында
төп үзенчәлекләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 222
Татар оронимикасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 233
§ 26. Татар оронимикасын өйрәнү тарихы . . . . . . . . . 233
§ 27. Татар оронимнарының этнолингвистик
катламнар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 237
§ 28. Татар оронимнарын номинацияләү принциплары . . . 255
§ 29. Татар оронимнары төзелеш-ясалышында
төп үзенчәлекләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 273
Татар урбанонимикасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 281
§ 30. Урбанонимика фәненә билгеләмә . . . . . . . . . . . 281
§ 31. Урбанонимнарның орфографиясе
һәм транслитерация мәсьәләсе . . . . . . . . . . . . . . . 293
§ 32. Урбанонимнарны номинацияләү принциплары . . . . 296
§ 33. Татар урбанонимнары төзелеш-ясалышында
төп үзенчәлекләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 302
ТАТАР ЭРГОНИМИКАСЫ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 304
§ 34. Эргонимика фәненә гомуми билгеләмә . . . . . . . . 304
§ 35. Эргонимнарның генетик катламнары . . . . . . . . . 310
§ 36. Татар эргонимнарын номинацияләү принциплары . . 319
§ 37. Татар эргонимнары төзелеш-ясалышында
төп үзенчәлекләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 325
§ 38. Татар эргонимнарының орфографиясе
һәм транслитерация мәсьәләсе . . . . . . . . . . . . . . . 333
ТАТАР ЭТНОНИМИКАСЫ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 342
§ 39. Этнонимика фәненә гомуми билгеләмә . . . . . . . . 342
§ 40. Этнонимнарның этимологиясе . . . . . . . . . . . . . 347

§ 41. *Казан* атамасының этимологиясе . . . . . . . . . . . 358
ТАТАР ОНОМАСТИКАСЫНЫҢ БАШКА ТАРМАКЛАРЫ . . 363
Татар космонимикасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 363
§ 42. Космонимика фәненә гомуми билгеләмә . . . . . . . 363
§ 43. Татар телендә космонимик лексиканың үсеш тарихы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 368
§ 44. Татар телендә космонимнарны төркемләү . . . . . . . 374
§ 45. Космонимнар төзелеш-ясалышында төп үзенчәлекләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 394
Татар зоонимикасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 399
§ 46. Татар зоонимикасына гомуми билгеләмә . . . . . . . 399
§ 47. Татар телендә зоонимнарны төркемләү . . . . . . . . 405
§ 48. Зоонимнар төзелеш-ясалышында төп үзенчәлекләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 415
Татар мифонимикасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 421
§ 49. Мифонимика фәненә гомуми билгеләмә . . . . . . . . 421
§ 50. Татар телендә мифонимнарны төркемләү . . . . . . . 427
§ 51. Мифонимнарның кулланылыш үзенчәлекләре . . . . 432
Татар прагматонимикасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 436
§ 52. Прагматонимика фәненә гомуми билгеләмә . . . . . 436
§ 53. Татар прагматопонимнарын номинацияләү принциплары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 441
§ 54. Татар прагматонимнары төзелеш-ясалышында төп үзенчәлекләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 447
ПОЭТИК ОНОМАСТИКА . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 452
§ 55. Поэтик ономастиканы өйрәнү тарихы . . . . . . . . . 452
§ 56. Поэтик ономастика төшенчәсенә гомуми билгеләмә . . 455
§ 57. Поэтик антропонимика . . . . . . . . . . . . . . . . . . 462
§ 58. Поэтик топонимика . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 468
§ 59. Идеоматика . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 474
§ 60. Поэтик ономастиканың башка тармаклары . . . . . . 480
ЙОМГАК . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 492
ӘДӘБИЯТ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 496
КЫСКАРТЫЛМАЛАР . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 532

Научное издание

**ЛЕКСИКОЛОГИЯ ТАТАРСКОГО ЯЗЫКА**

III том
Первая часть

*На татарском языке*

Редакторы: *Я.М. Абдулкадырова, А.К. Булатова*
Компьютерная вёрстка *Н.Т. Абдуллиной*
Дизайн обложки *Л.Ш. Давлетшиной*

Подписано в печать: 23.12.2017.
Печать офсетная. Гарнитура «Times».
Формат: 60×84 1/16.
Усл.-печ. л. 31,2. Уч.-изд. л. 27,6. Тираж 650. Заказ

Оригинал-макет подготовлен
в Институте языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ
420111, Казань, ул. К. Маркса, 12

Издательство Академии наук Республики Татарстан
420111, Казань, ул. Баумана, 20